ISSN 0206-4189


# КАЗАН УТЛАРЫ

8.2004




Индекс 73210

# ТАТАРСТАН—МИНЕМ РЕСПУБЛИКАМ



# Казан утлары
# Qazan utları

2004

# 8

(982)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Ихтыяр Гаязов, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Харрас ӘЮП. Тартылган кыл сыман... Шигырьләр. .......... 5
Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН. Айбиби. Роман. .......... 10
Шамил МАННАПОВ. Тормыш сиратын кичкәндә. Шигырьләр. .......... 82
Әхмәт РӘШИТ. Галия апа. Хикәя. .......... 87
Луиза ЯНСУАР. Йолдыз бәхете. Шигырьләр. .......... 93

**ФӘН**

Солтан ШӘМСИ. Күк капусы ачылса. Тарихи-фәлсәфи бәян. .......... 98
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. .......... 168

**ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Гыйбрәтләр алырлык үткән юл *(Язучылар оешмасының 70 еллыгы уңаеннан кайбер күзәтүләр, хатирә-уйланулар)* .......... 116

**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Илшат ВӘЛИУЛЛА. Яңа маяклар эзләгәндә... .......... 136

**ХӘТЕР**

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Тәнкыйть күгендәге йолдыз *(Фәрваз Миңнуллинның тууына 70 ел)* .......... 144
Мостафа Рүштү ӘРДӘЛҺУН. Гаяз Исхакыйның тапшырылмаган хаты. .......... 183

**КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНА 200 ЕЛ**

Сәвия МИХАЙЛОВА. Россия халыкларының милли мирасы. .......... 151

**СӘНГАТЬ**

Госман ӘХМӘТҖАН. Сәхипҗамалның дәвамы. .......... 171

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Рәшит ФАЗЛЫЕВ. Бергә көлү күңелле. .......... 177
Коръән татар телендә. .......... 181

Котлыйбыз! *(Яхъя Халитовка 75 яшь.)* .......... 185
"Казан утлары" архивыннан .......... 186
Язучылар берлегенең яңа әгъзалары. .......... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан .......... 189

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман М. ХАБИБУЛЛИНА "Айбиби" (продолжение); рассказ А. РАШИТА "Галия апа"; стихи Х. АЮП, Ш. МАННАПОВА, Л. ЯНСУАР.
"Наука": С. ШАМСИ. "Когда откроются Звездные Ворота" (продолжение); А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
"К истории литературы": статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА "Славный и поучительный путь" (к 70-летию Союза писателей Татарстана).
Дискуссия "Герой нашего времени": статья И. ВАЛИУЛЛЫ "В поисках новых маяков".
"Память": статья Т. ГАЛИУЛЛИНА посвящена творчеству критика Ф. МИННУЛЛИНА (к 70 летию писателя); М.Р. АРДАЛХУН. "Неотправленное письмо Г. Исхаки".
"200 лет Казанскому университету": статья С. МИХАЙЛОВОЙ "Национальное наследие народов России".
"Искусство": статья Г. АХМЕТЗЯНОВА посвящена творчеству актрисы Асии Галиевой.
"Книжное обозрение": Р. ФАЗЛИЕВ рецензирует книгу М. САЛИМОВА "Посмеемся вместе!"
Коран на татарском языке.
Из фотоархива журнала.
Новые члены Союза писателей.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: главное здание Казанского Государственного университета—фото Н. ИСМАГИЛОВА; ученый Р. ФАХРУТДИНОВ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": Novel by M. KHABIBULLIN: "Aibibi" (Continuation); Story by A. RASHIT "Galia Apa"; verses by Kh. AYUP, Sh. MANNAPOV, L. YANSUAR.
"Science": S. SHAMSI "When star gates open" (Continuation); A. TIMERGALIN "Vocabulary of the nation".
To the history of literature: Article by R. FAJZULLIN "Glorious and educational way" (to the 70th anniversary of the Union of writers of Tatarstan).
Discussion "Hero of our time": article by I. VALIULLA "In searches of new beacons".
Memory: article by T. GALIULLIN devoted to epy creativity of the critic F. MINNULLIN (to the 70th anniversary of the writer); M. R. ARDALKHUN "The not sent letter of G. Iskhaki".
The 200th anniversary of the Kazan University: the article by S. MIKHAYLOVA "National heritage of peoples of Russia".
Art: article by G. AKHMETZYANOV is devoted to creativity of the actress Asiya Galieva.
Books review: R. FAZLIEV reviews the book by M. SALIMOV "Let's laugh together!".
Al Quran in Tatar language.
From photo-archive of magazine.
New members of the Union of writer.
Diary of public-cultural life.
On our covers: the main building of the Kazan State university — the photo by N. ISMAGILOV; the scientist R. FARKHUTDINOV.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.07.2004 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7025. Заказ Э—530
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2004 ел.



Харрас
Әюп

# ТАРТЫЛГАН КЫЛ СЫМАН...

## Җил дә бар...

Замананың тыны кысылганда
Сабый чакларымнан җил бәрә,
Нарасый җил...
Авыл хатыннары
Анда һаман ашлык җилгәрә:

Агач көрәк белән бер-бер артлы
Һаваларга бодай сибәләр,
Моңланалар...
Минем җырда гына
Калганнарын, ахры, сизәләр.

Шыбыр-шыбыр ашлык ява күктән,
Чәчләремә тула бодайлар,
Дәфтәремә тула...
Шөкер, димен,
Теләк теләгәнгә—Ходай бар!

Нарасый җил...
Бәндәләргә карап,
Җилләр әле нигә картайсын?!
Без дә картаймабыз:
Дәверләрнең
Игелеген кире кайтарсын...

...Анда һаман ашлык җилгәрәләр,
Белмиләрме—монда зир-зәбәр.
Бөтенесе үзебезнең башка!
Җилгәрмибез—
Юкса җил дә бар...

Харрас ӘЮП (1946) —*шагыйрь; "Сабыр савытлары", "Җәяүле буран", "Биш вакыт намаз" һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Дөньялыкны узып барган чакта
Тик бер генә тапкыр кычкырдым—
Мин шунда ук инде беркая да
Куна алмый торган кош булдым.

Миннән башка җирдә бу Ходайның
Аз микәнни гаҗиз кошлары?—
Ни гомерләр инде бәндәләрнең
Яшен сөртә канат очлары!

Тик канатлар өлгererлек түгел,
Мин дә сөртеп бетерәлмамын.
Оча икән кошлар
Кешеләрнең
Күктә йөртер өчен җаннарын.

Беркая да инде кундырмыйлар,
Тәңредән каһәр алдыммы?—
Дөньялыктан узып бара идем,
Мәңгелеккә шунда калдырды...

***

Күпме гомерләр үтмәде,
Ничәмә-ничә еллар...
Ул беркая да китмәде,
Шушында бит ул, ул бар!

Әнә бит: чәчкә күзеннән
Мөлдерәп карап тора.
Чайкалыр... Калма үзеннән,
Ярат та ярат кына.

Юлларның болай буталып
Калырын каян белим?
Мин үзем, үзем бит аны
Чәчкәгә әйләндердем.

Ялгыз чәчкә иртә сулар,
Түзгәндер лә моңарчы.
Ул шушында... Көтәсе бар
Үзем чәчкә булганчы...

***

Кояш чыгар.
Сулар сулкылдашыр.
Еракларга сузылып җил исәр...
Искән җилдә, исен җыялмыйча,
Иләсләнеп йөрер бу исәр:

Тауга менәр,
Үзәннәргә төшәр,
Урманнарга кереп югалыр...
Юкка гына,
Юкка гына йөрер,—
Әйталмаслар икән шуңа бер!

Иләс-миләс килеш китеп барыр.
Өсләренә кыргый гөл үсәр...
Акыллылар арта барган саен,
Шул исәрне эзләп җил исәр...

***

**Тартылган кыл сыман зыңлап тора**
**Шыр ялангыч калган бу киңлекләр.**
**Ямансудыр... Бәйрәм түгел инде**
**Җир йөзенә килгән ятимлекләр.**

**Кими бара дөнья:**
**Арабыздан**
**Җелек кебек замандашлар китә.**
**Кителә чор...**
**Бөтенлектән безне**
**Нигә болай иртә мәхрүм итә?!**

**Сагыш арта. Чаларадыр чәчләр.**
**Олыгая адәм балалары.**
**Киткәннәре—җилдер,**
**Шул җилләрдә**
**Саргаялар икән калганнары.**

**Бер-бер артлы замандашлар китә,**
**Өлгералмыйсыңдыр кул болгарга.**
**Карап торасыңдыр**
**Күз алдында**
**Бетә барган фани дөньяларга...**

## Хәвеф

*Мөслимдәге музейдан кыйммәтле экспонат—мамонт сөяге югалуга карата*

**Исләремә төшермәгез берүк,**
**Исәпләсәң—исең китәрлек:**
**Кем уйлаган илеңдәге хәвеф**
**Мамонтларга барып җитәр дип,**

**Яткан җирләреннән мамонтларны**
**Күтәрер дип затсыз замана?!**
**Дөнья—музей,**
**Хәлләреңнән килсә,**
**Әйләнеп үт, кермә-карама.**

**Аның тере "экспонатлары"**
**Үлгәнгә дә бирми тынгылык.**
**Үткәннәрдән киләчәккә чаклы**
**Күпме ялган йөри чын булып!**

**И вакланды кеше дигәнебез,**
**Кая бара илләр, халыклар?!**
**Дөньяларны иңләп афәт килә,**
**Коткарыгыз безне, мамонтлар!..**

## Тоз сибәләр...

**Бар дөньяны гел тигезләп килде,**
**Аермыйча дуска-дошманга,**
**Бик сагаеп ява быел карлар...**
**Сагаерлык бардыр кышларга:**

**Тоз сибәләр кышның өсләренә,**
**Тоз сибәләр—чыда-чыдама.**
**Казан урамнары инде тагын**
**Манма булып яшькә чылана.**

**Болай да гел яра гына бит ул,**
**Бәйли алмый икән кыш кереп.**
**Тоз сибәләр...**
**Тавыш-тынсыз гына**
**Елый Казан—булмый кычкырып!**

## Кайсыгыз?

*...Кәккүк, чыпчык,*
*Тәрәзәдән очып чык...*
Бала уйнату

**Тәрәзәдән очып чыкмады ул.**
**Белалмадым каян килгәнен:**
**Пыялага бәрелде дә чыпчык,**
**Егылып төште...**
**Тагын кемнәрнең**
**Хәбәрләрен алып килүедер...**
**Илдә чыпчык үлми иде дә,**
**Нинди гөнаһ шомлыклары икән,**
**Ни булды соң әле иленә?!**

**Илдә чыпчык үлми иде дә бит,**
**Кырылса да асыл ир-аты.**
**Башкайларын юкка ташка ормас—**
**Шул кошларда мәллә чираты?!**
**Пыяланы ваталмады мескен...**
**Чыпчык кына бит ул димәгез,**
**Кемнәр өчен шушы чыпчыклардан**
**Кадерлерәк әле илдә без?**

**—Кәккүк, чыпчык,—диеп, кулларында**
**Сикертерләр инде ул кемне дә.**
**Каян белсен сабый болай да бер**
**Калачагын чыпчык көненә!**
**Тәрәзәдән очып чыгасы юк,**
**Алданмагыз, кире кайтыгыз!**
**...Танымыйча калдым:**
**Пыяланы**
**Ваталмады бүген кайсыгыз?!**

***

**Йөрәгемдә йөрткәнгәме—**
**Гөл диделәр ярамны.**
**Гөл диделәр...**
**Алсуланып,**
**Яраннарга таралды.**

**Минем генә ярам түгел,**
**Тимәгез яраннарга:**
**Ал буласылары бардыр**
**Заманнар каралганда...**

## Арыш басуында

**Кыштыр-кыштыр арыш башаклары...**
**Күзгә яшьләр килә кайчакларны,**
**Басуларга чыксаң ялгызың.**
**Ураклары тынган әнкәйләрнең...**
**Шул малайга бер сүз әйталмадым,**
**Сослан төпләрендә калдырдым.**

Арыш арасында—зәңгәр чәчәк.
Дәшәлмичә тора җилдә чәчәп,
Төсмерләдем шундук, таныдым:
Юк, кермәгән иде искә бер дә
Басу уртасында чәчкәләргә
Әйләнәсе сабый чагымның.

Арыш башаклары пышылдаша...
Искән җилгә алар кушылмаса,
Бу чәчкәне кемнәр юатыр?
Башлар чайкап, хәлләреңә кереп,
Синең өчен саргаядыр кебек:
Басуларга чыксаң, уй артыр...

## И эзләрсез әле...

“Кара да гына урман, караңгы төн...”
Кем баласы урман эчләрендә?
Төнгә каршы кая бара болай,
Ни гомерләр җырга күчкәненә?

Урман эчләрендә кем ярасы?—
Кагылмагыз берүк, сорамагыз.
Ил кадәрле ил имгәнгән чакта
Бер ялгызы сызлар бу ярагыз...

Җан ачысы белән кычкырасы—
Урман эчләрендә урман икән.
Карурманнар булып, башкайларны
Заманалар көтеп торган икән!

Агачлардан-агачларга сугыл:
Тып-тын калып тыңлар алар сине.
Булыр әле илләрнең дә бәлки
Үз баласын берәр аңлар көне.

Төнгә каршы кая бара болай?—
Кайгыларга кабат сала безне.
И эзләрсез әле
Урманнарда
Адаштырып киткән балагызны...

***

Дөньялыкны кичеп чыгып барам,
Үзем генә белгән юл кала...
Сулкылдаган күкрәгемне куеп,
Бер суларга җитте бу ара.

Үзем генә белгән юлым кала,
Бүтәннәрнең миндә ни гаме?!
Кайгыларың чаклы дөнья бит ул—
Бер сулышта кичеп чык аны!..

## Мөсәгыйт Хәбибуллин

## АЙБИБИ

ТАРИХИ РОМАН

VIII

Өлкән равва Харәзем әмире тарафыннан Ибраһим исемен алып, кайтып төште һәм Аккала күперен узуга, үзен каршы алучы раввадан:

—Кахан кайда?—дип сорады.

Равва анын белән исәнләште дә тәхет ягына таба күрсәтте. Өлкән равва Ибраһим зур-зур адымнар белән сарайга таба юнәлде һәм үзенә ияргән имамнар белән тәхет ягына ук узды. Йосыф кахан каханбәге Сабир белән нидер сөйләшеп утыра иде, өлкән равваны һәм аңа ияргән чалмалы имамнарны күрде дә аягүрә басты. Каханга өлкән равва һәм имамнар баш иеп, сәлам юлладылар. Йосыф кахан өлкән раввага уң як урындыкка, имамнарга сул як урындыкларга утырырга ишарә ясады.

Имамнар, шул исәптән өлкән равва да, дөя йоны тутырган артсыз урындыкларга утыруга, авыз эчләреннән дога укып, "Аллаһу әкбәр!" дип битләрен сыпырдылар, шуннан соң гына каханга һәм каханбәккә сәлам юлладылар.

Дога кылу галәмәте үткәч, Йосыф кахан өлкән раввага карады. Бу инде: "Йә, ни йөк белән кайттың?"—дигәнне аңлата иде.

—Харәзем әмире тарафыннан угыз ханы кисәтелде, алар иртәгә үк илдән чыгып китәчәкләр, бүген исә өч имам безнең йөзбашларыбыз озатуында яу килгән төмәнбашларга юнәләчәкләр. Моның өчен сездән фатиха кирәк, галиҗәнапләре Йосыф кахан.

Йосыф кахан янә барысын да күздән кичерде һәм гаскәрбашы Сабирга карап:

—Өч имамга да йөзбашлар бир, имамнарны угызларга озата барсыннар. Бу минем әмерем генә түгел, Харәзем әмиренеке дә, каханбәк Сабир.

—Баш өсте, галиҗәнапләре!—дип сикереп торды каханбәк Сабир һәм ишеккә таба китте... Имамнар дәррәү аңа ияределәр.

Тәхет ягында өлкән равва белән Йосыф кахан гына калдылар.

—Мин моның ахыры ни белән бетәсен белмим, Йосыф углан, әмма мин син кушкан йөк-йомышны җиренә җиткереп үтәдем. Үзем әмир каршында ук Ислам динен кабул иттем, әмма күңелем түрендә Яхвам калды. Аны минем күңелемнән беркем дә җуеп ала алмас.

—Минем дә,—диде Йосыф кахан һәм, килеп, өлкән равваны кочты.

—Мин Хазарстанны саклап калырга телим, нинди юллар белән булса

*Дәвамы. Башы 7 санда.*

да. Тиздән без дәшкән викинглар килеп төшәрләр һәм без аларны мөселманнар өстенә җибәрербез, алар Харәземне дә читләтеп үтмәсләр һәм без тәүгечә барчасы белән идарә итәрбез, атакай.

Шушы хәлләрдән соң бер ай да үтмәде, Йосыф кахан табын җыйды. Табынга җыелган каханбәк, бәкләр, угыз төмәннәрен ил-далаларына борып җибәргән имамнар да, тарханнар да бар иде. Йосыф кахан аларга барысын да ирештерде. Кара Болгар каханы Сарманайның узынуын, Дунай буе канкардәшләребезгә кат-кат яу йөрүе турында да, үзенең тиздән шул тарафларга яу чыгарга җыенуы хакында да әйтте. Табындагы барчасы да кахан белән килештеләр. Йосыф кахан угызларны Хазарстан җирләреннән вә үләнле болыннардан китәргә мәҗбүр иткән имамнарга үзенең рәхмәтен җиткерде һәм аларны сараенда калдырасы, киңәшчеләре итәсе хакында әйтте. Имамнар каханның бу сүзләрен: "Амин!" дип куәтләп, кабул иттеләр.

Табыннан соң Йосыф кахан менә ничәнче көн инде, сарайдагы гадәти чират тәртибен бозып, Айбибине үз янына дәштерде. Айбиби Йосыф кахан кырына кинәнә-кинәнә килде. Һәм алар һәр килгән төндә бер-берсен сөешеп туймадылар. Каханның бу хәленә раввалар гына түгел, сарайдагы бернигә дә исләре китмәгән хәрам атакайлар да игътибар иттеләр, сарай куштаннары турында әйтеп тә торасы юк.

Әнә шундаен төннәрнең берсендә Айбиби Йосыф каханның кочагына инде дә әкрен генә: "Мин чынлап та балага уздым, каханым",—диде. Кахан бермәлгә дәшми ятты. Ахыр, ниһаять, аңына барып җитте—Айбибинең башын артка каерып, күзләренә карады.

—Димәк, син теге вакытта шаярып әйтмәдең?

—Чынлап, Йосыфҗан, чынлап.

—Минем Мөхәммәд хан кызларының берсеннән бер угылым үсә инде, Айбиби, син дә миңа угыл бала тапсаң... Мин синеме!..

—Нишләтерсең мине, каханым, нишләтер идең?

—Гадәттә мин йөкле хатыннарымны илләренә кайтарып җибәрә идем. Ә менә син миңа угыл бала тапсаң.

—Мин хатыннарымның барчасын да куып таратачакмын, Айбиби җан, барысын да.

Айбиби бер сүз дә әйтмәде, чөнки каханның сүзләренә ышанмады. Кем моны аңа рөхсәт итәр? Раввалар килешерме, кахан бит бу гамәле белән аларның кануннарын бозачак.

Ләкин Йосыф кахан һәр адымын табын җыеп, киңәшчеләре белән килешеп, уртак тел тапкач кына ясады. Хатыннарын тарату турында ул башта табын җыеп сөйләшергә, аксакаллары белән киңәшергә булды. Иң әүвәл аның бу адымын имамнар яклап чыктылар, өлкән равва да каханның бу адымын хуплады, раввалар да кахан белән килештеләр. Хәер, равваларны өлкән равва кисәткән булгандыр, чөнки һәр табынга алар башта үзләре табын җыеп, киңәшеп, уртак бер фикергә килеп керерләр иде. Менә шул табында Йосыф кахан Византиягә яу кузгалырга нияте булуы хакында да әйтте. Император Никифор Фокеның яшь сәргаскәр Иоанн Цимисхий тарафыннан үтерелеп, тәхеткә утыруы хакында да җиткерде. Тәхеттә утырганда император Никифор яу йөрүдән башы чыкмаган Сарманай кахан Кырым тарханы улы Калакир аша мең ярым кадак алтын җибәргән икән. Әмма бер шарт белән—шул алтынны аклау өчен Сарманай кахан Дунай буе болгарларына яу йөрергә тиеш булачак. Сарманай кахан күп тә үтми гаскәре белән Дунай буйларына яу кузгалачак, дигән хәбәр ирешкән, диде Йосыф кахан табын аксакалларына. Шунда өлкән равва:

—Безгә дә Византия тарафларына яу кузгалып, бер җайдан Сарманай каханны да акылга утыртып кайту мәслихәт булыр иде,—диде.

Табындагылар һәммәсе дә өлкән равва белән килештеләр. Бары тик имам хәзрәтләренең берсе генә:

—Кахан галиҗәнапләре, Византия императорында яман утчагыр бар. Ахыр килеп, үч-үчкә илтмәсме?—дигән булды. Ләкин аңа бөтенләй игътибар итмәделәр, табын шаулаша башлады, кахан белән барысы да килештеләр.

Табын таралгач, Йосыф кахан Сабирга тәхет ягында калырга кушты. Барысы да таралып, тәхет ягыннан чыгып беткәч, кахан аңа кечкенә өстәл янына утырырга ымлады.

—Каханбәгем, бүген үк Мөхәммәд ханга чапкының җибәр. Византиягә таба яу кузгалсын. Әйттер, кахан белән Далада очрашырсыз дип.

—Галиҗанәпләре, Мөхәммәд ханның Дунай буе Пәһлеван ханга ярдәмгә кузгалуы хәерлерәк булыр иде шикелле миңа.

Йосыф кахан сул кулын уң кулы белән каплады.

—Каханбәк Сабир, Болгарстан да, Хазарстан да, Дунай буенда көн күргән Бәгырь вә Пәһлеван ханнар да, хәтта анда көн күргән антлар да безнең Атилла бабаларыбыздан килгән канкардәшләребез. Мин бабам Мөхәммәд ханның канкардәше Пәһлеван ханны юлбасар нәселдән килгән Сарманайга каршы яу чыгуына каршы түгел. Ләкин бабам онытмасын иде...—Йосыф кахан бер ноктага текәлеп, нидер уйлап утырды, шуннан соң гына:—Бабамның гына куәте җитәр микән ул юлбасар каханга. Аның кулында яман варяглар, дөнья халкына баскынчылар яманаты чыккан варяглар, —диде.

—Сез хаклы, без бергә булырга тиешбез, галиҗәнапләре,—диде каханбәк Сабир, гәрчә каханның тел төбен аңлап житкермәсә дә.—Мин бу хакта, Мөхәммәд ханга хәбәр ирештергән идем инде, галиҗәнапләре.

—Өлгерсең, каханбәгем, өлгерсең, мактыйм. Алай да, каханбәгем, сиңа киңәшем бар, ягъни синең белән киңәшәсе бер үтә четерекле кыласы гамәлем бар. Мин, каханбәк Сабир, хатыннарымны илләренә кайтарып җибәрергә булдым.

—Һәммәсен дәме?

—Әйе, каханбәгем, әйе, һәммәсен дә. Янымда бары тик бер хатыным—Айбиби калыр.

Каханбәк Сабир шикләнебрәк каханның күзләренә карады. Ул каханның сүзенә ышанып җитмәде бугай, чөнки яхшы белә иде—өлкән равва һәм аның раввалары бар бит әле. Алар ни әйтә, бигрәк тә өлкән равва. Ләкин бу хакта теге якка да, бу якка да Йосыф каханга сүз әйтергә, яисә киңәш бирергә кыймады. Инде хатыннарын куарга тели икән, аларны югары бәһагә Фанәргүр базарына илтеп саттырсын. Азмы, күпме, казнага акча керер. Яуга хәзерләнгәндә ул акча сөннәтле казакларга түләргә ярап куяр. Бу—бер. Икенчедән, хатыннарны саткан акча турыдан-туры өлкән равва кулына керәчәк. Ә гаскәр җыярга, нигездә, раввалар катнаша. Бажайларны да алар яллады, угызларның беришен дә, сөннәтле казакларны да, поскан казакларны да, гаярьләрне дә. Яу уңышлы үткән хәлдә, моңа каханбәк Сабирның иманы камил иде, Йосыф кахан яңа туган айдай җиңүче йөзендә Хазарстанга кайтып төшәчәк. Шулай иткәндә раввалар да, өлкән равва да борынгы бабалары кебек каханның муенына ефәк бавы сала алмаслар. Ләкин моның өчен Йосыф каханның яубаш булуы зарур. Каханбәк сукыр түгел, күрә—яубаш булырга кахан үзе дә әзер.

—Димәк, сезнең әмер белән мин кичекмәстән төмәннәрем барлый башлыйм, галиҗәнапләре?—диде, ниһаять, каханбәк Сабир.

—Башла!—диде катгый рәвештә Йосыф кахан һәм сүзе бетүен аңлатып, торып басты.

## IX

Йосыф кахан яу кузгалуны һәркөн күз угында тотты, акча табучы өлкән равваны да, төмәннәр өчен җавап бирүче каханбәк Сабирны да, олаучылар башы әрмәнле Вартанны да ашыктырды. Барысы да әзер булгач, ул янә табын җыйды һәм раввларына яуның төп максатын аңлатты. Ул моннан гыйбарәт иде. Сарманай каханны һәм Византия императоры Никифор Фокены төрле котыртулар аша үзара сугыштыруга ирешү. Моның өчен Йосыф кахан Византиягә дә һәм Кияли каласына да үзенең йөзләрчә шымчыларын җибәргән иде инде. Яу чыгу мәсьәләсендә Йосыф кахан табынга кереп утырган имам хәзрәтләре белән дә киңәшкәндәй итте. Имеш, бик

кыенга кала башласа, ул, Йосыф кахан, Харәзем әмире Мөхәммәтгалигә мөрәҗәгать итә аламы?.. Имамнар ышандырдылар —итә ала.

Шунда табын җыены барганда ук тәхет ягына Йосыф каханның ышанычлы шымчыларыннан берсе килеп керде һәм табындагыларның һәммәсенә дә баш иеп, сәлам юллагач, кахан кырына узды һәм илбашына яңа хәбәр җиткерде. Йосыф кахан аның иңенә кулын куйды һәм барчасы алдында да:

—Минем ышанычлы адәмем безгә сөенче алып кайткан, җыендашларым. Византия императоры Никифор Фоке үтерелгән, аның урынына олуг император булган Константинның кызына өйләнгән яшь сәргаскәр Иоанн Цимисхәй утырган, безнең кардәшләребез болгарларны яулаган Сарманай каханга каршы яу кузгалткан. Безгә ашыгыч төстә яшь император Иоанн Цимисхәй белән солых төзергә һәм тиз арада шул тарафларга яуга кузгалырга кирәк. Әйе, сузмыйча.

—Иоанн Цимисхәй белән Сарманай сөйләшүләр генә алып баралар әле, галиҗәнапләре,—диде каханның ышанычлы шымчысы.

—Сөйләшә торсыннар,—диде аңа каршы Йосыф кахан.—Ә без кузгала башларбыз. Хак, безнең төп дошманыбыз Сарманай кахан түгел, Кияли түрәләре безгә һәрдаим ясак түләп тордылар. Әмма Сарманай кахан тәмам узынды, хәтта безнең Сарыкалага яу килергә кыйды. Димәк, Иоанн Цимисхәй кахан Сарманай дружинасына бер яктан ябырылса, без икенче яктан ябырылырбыз. Мин әйттем!

* * *

Иртәгә яу кузгалабыз дигән кичне, Йосыф кахан үз кырына Булат бәкне чакыртып алды.

—Утырып тыңла, Булат бәк. Сиңа әмерем шул булыр: мин яу кузгалуга ук, син, минем хатыннарымны таратасың. Үз ирекләренә куй.

Булат бәк Аккалага да, Ханбалыкка да баш иде. Ул Йосыф каханга тугры хезмәт итте, кахан да Булат бәктән канәгать иде. Күп сөйләшми, кушканны җиренә җиткереп үти, әмма Булат бәк Йосыф каханга ышанып житмәде. “Ничек инде хатыннарны куарга, өлкән равва ни әйтер. Бит башта ул әмер бирер иде...”

Алай да сорап куйды:

—Айбиби хатын да кайтып китәрме, галиҗәнапләре?

—Айбиби хатын сарайда калыр, бәк.

—Кахан белән яу китәм дисә?.. Төрки ханбикәләрдә бу хәл булгалаган, галиҗәнапләре.

Йосыф кахан елмайды, аркасын тәхетенә терәбрәк утырды.

—Айбиби хатын сарайда калыр дидем түгелме мин сиңа, Булат бәк?!

—Яхшы, галиҗәнапләре, мин ялгышканмын.

—Калалар өчен генә түгел, калага кергән-чыккан, килгән-киткән халыклар өчен дә син җаваплы, Булат бәк, син!

—Мин кемгә буйсынырга тиеш булачакмын, галиҗәнапләре?

Йосыф кахан тәхетеннән күтәрелде, үз каршында бер тезенә төшеп торган Булат бәк янына килде, башына кулын куйды.

—Булат бәк, миңа, миңа буйсыначаксың!.. Аккала белән ике арада чапкыннарым йөреп торыр. Мәгәр үзең дә колакларыңны шәлперәйтеп, көтеп торма. Син кала башлыгы, кала тарханы, Булат бәк! Сиңа равваларым ярдәм итәрләр.

—Яхшы, галиҗәнапләре,—диде Булат бәк килешеп. Йосыф кахан аңа чыгып кит дип, кул ишарәсе ясады.

Сарайдан чыгуга, Булат бәк эчке бер кимсенү тоеп, күпергә таба атлады. Күперне чыкканда Булат бәк Йосыф каханның баш хатыны Айбибине күз алдына китерде. Гүзәл иде Айбиби хатын, моның өстенә яшь, шуңа күрә булса кирәк, бу хатын сарайга килә-килүгә Йосыф кахан үзгәрде, раввалар әйтүе хак булса, хатынны кәнаралаш үзенә тарттыра башлады, ахыр һәркөн дияргә була. Моны Булат бәк аңлады да, аңламады да. Аңлады—үзе дә

хатыны Таңгөл кырына ашкынып, күрергә сагынып, тансыклап кайтыр иде, аңламады—кырык хатын тота ич кахан, кырык! Айбибигә гашыйк булуыдыр. Бит Булат бәк үзе дә Таңгөлен күрде дә тәмам телсез калды. Ни дә булса әйтер иде, әйтер сүзе аяк астына төшеп киткән кебек—сүзе табылмады. Кызның иңнәрендә көянтә-чиләкләр, атламый кебек кыз, гүя йөзә инде менә, су өстеннән йөзгән үрдәк кебек, юк, аккош кебек. Горур, тәкәббер, янбашлары уйный, шуңамы, күргән саен күрәсе килә, күзләр дә кызганнан-кыза бара. Җитмәсә, әнә шул серле адымнары белән үзенә дәшә, дәшеп кенә калмый җепкә бәйләп тарта. Түзмәде Булат бәк, меңбаш булган кеше ич, тәвәккәлләп, кызның каршына килеп басты. Кыз курыкмады, тик әллә ничек серле бер караш ташлады да, егетне урап-әйләнеп чыкты һәм ары китте. Күзләрендә кызның күбәләк җилпенгәндәй керфекләре һәм серле карашы гына Булат бәкнең йөрәк түренә кереп калды.

—Кем кызы бу чибәр?—дип сорады таныш сәүдәгәрдән.

—Габдулла бай кызы. Юкка күзең кыздырма, егет. Ничәмә яучыны борды инде бу гүзәл зат. Бора да җибәрә, бора да җибәрә. Атасы да: "Кыз үзе сайласын иш буласы кешесен",—дип кинәнгән була.

—Әтисеме шулай ди?

—Әтисе инде, әтисе. Бай яһүд сәүдәгәре дә улына сорап карады. Кыз үзе риза булса, бирәм диган атасы. Аннары: "Егет үзе килсен", дип шарт куйган.

—Кем шарт куйган?

—Кыз инде, кыз.

—Кызның аты ничек?

—Таң гөле, Таңгөл. Исемне дә куша белгәннәр бит үзенә.

Булат бәк Болгар базарына күз ташлады, яр буендагы мәһабәт өйгә. Ә анда Идел яр буенда сары кирпечтән күтәрелгән капкаларына кадәр бизәкле өй. Ханбалыкта яндырылган кирпечтән өй салырга кахан гына рөхсәт бирә. Димәк, Габдулла сәүдәгәрнең сарайда ышанычлы кешесе бар. Ә ышанычлы кеше—өлкән равва.

—Байның хатыны яһүдә, шулаймы?

—Яһүдә, шуннан ни, адәм баласы?

—Кибетеңеракмы?

—Ике өй аша.

—Әйдә, минем синең кибетеңне күрәсем килә. Ошаса, бер-бер нәрсә алырмын да...

—Мин кораллар сатмыйм, кием-салым белән генә сату итәм. Атың ничек соң ил бәндәсе?

—Сарай бәге мин, агай-эне, сарай бәге. Әле генә кахан янынннан чыктым.

Сәүдәгәр Булат бәккә борылып карады да, исе китмәгәндәй кибет ишеген ачты.

—Габдулла байның тагын кызлары бармы?

—Таңгөлнең үсмер туганы бар. Божыр да божыр, ул да божыр. Әллә кахан бәгенә кыз ошадымы?—дип сорады сәүдәгәр киштәгә киемнәр тезәтезә.—Сиңа бер киңәш кахан бәге. Син кызга туганы аша үтеп кер. Бүген нигәдер күренмәде, кыз елгага суга төшкәндә энесе гел озата төшә.

—Саклый, димәк...

—Саклаганны сакларммын дигән Хода, кахан бәге. Синең булачак кайнешең яхшы корал, хәрби киемнәр ярата. Син әнә шуннан башла. Әйе, бер дә яучылар җибәреп торма. Үзең йөр. Кыз сиңа өйрәнсен, күрә йөрсен. Хатын-кыз күргәнгә ябыша, күрмәгәннән кача.

—Әйдә, синең киңәшеңне тотып карыйк. Бир әнә теге җемелдәп торган укалы җиләнне, нәкышлы хәнҗәрне, укалы түбәтәйне һәм болгари читекне. Бир, бир, бәһасендә тормам. Тагын әнә теге руннар пәкесен бир, ике җәплене.

Киемнәрне ефәк капчыкка тутырып чыкты да Булат бәк, елгага таба китте. Елга яр кырында гына челтерәп чишмә ага, әнә шул чишмәдән су алырга төшә Габдулла бай кызы Таңгөл. Атының тезгенен хайванның

бәкәленә элде дә, ерак йөрмә дип утларга жибәрде, ә үзе елга ярына утырды да кызны көтәргә булды. Габдулла байның бер эчәсе килмәсә бер килер, гүзәл кызын суга жибәрер, әнә шунда Булат бәк кызга йөгән "кигерер". Сабыр, сабыр, Булат бәк, сабыр ит. Ашыкма. Кыз сиңа өйрәнсен. Бер күрен, ике күрен, өч күрен.

Ләкин эңгер-меңгер вакыт житте, кыз чишмәгә суга төшмәде дә төшмәде. Бу ни бу?! Габдулла бай бөтенләй чәй эчми яши микәнни? Өенә барып чыкса?.. Караңгы төшә башлады. Булат бәкнең аты да пошкырына, ашап туйды, иясенә дәшкәндәй итә. Инде нишләргә?.. Әллә соң иртә таң белән бире килергәме? Бүләкләр кулда... Менә шунда инде караңгы төшеп килгәндә чиләкләр тавышы ишетелде. Булат бәкнең колагы шаулап китте, йөрәге колак төбендә үк дөп-дөп тибә башлады.

Ул әкрен генә торды да чишмәгә таба кузгалды. Таңгөл чиләкләренә су алып маташа иде, артында ук аяк тавышы ишетеп, торып басты, шул мәлдә үк яман тавыш килде.

—Тукта! Тагын бер адым, мин сине укка алам!

Булат бәк борылып карады һәм эңгер караңгыда угын җәягә элгән Таңгөлнең энесен шәйләде.

—Мин коралсыз, батыр егет, —дип кулларын җәйде Булат бәк. Элек һәрдаим җансакчыларын үз янында йөртер иде, бүген исә әллә ни булды Булат бәк белән, каханнан чыкканнан соң барыр юлын югалткандай йөри. Әллә соң Хода үзе китердеме аны монда—Таңгөл янына. Бәлкем бу кыз минем язмышымдыр...

—Тагын бер адым!—дип кабатлады укчы малай.

—Апаң су алсын инде, булышыйм апаңа су алырга,—диган булды Булат бәк.

—Тагын бер адым!—дип кабатлады янә бер тапкыр үсмер.

—Мин сиңа, мәргән егет, изге ният белән килдем, ишетәсеңме, изге ният белән. Күрәсең, минем кулларым буш. Атым өстә утлый, карак та, бур да түгел мин.

—Камил, Камил!—диде, ниһаять, апасы Таңгөл.—Куй, ук-җәяң. Миңа чиләкләремне яр өстенә алып менәргә ярдәм ит.

—Алып менсен янындагы бүкәй. Бу минем боерыгым,—диде үсмер.

Үсмер шулай диюгә, Булат Таңгөл янына килде һәм гүзәл кызның татлы исләреннән башы әйләнеп киткәндәй булды. Чиләкләрне биргәндә, чиләк тоткасы белән бергә кызның да йомшак бармакларына кагылып алды. Аннары җайлы гына ике чиләккә дә мөлдерәмә салкын чишмә суын тутырып алды да йөгерә-атлый, әмма бер тамчы суны да түкми, яр өстенә менде һәм чиләкләрне куеп, кыз артыннан чишмә янына төште, кыз кулын сузуга, күтәреп алды, очыртып яр өстенә алып менде, чиләкләре янына бастырды. Кулыннан тотты да, ике тезенә төшеп, кызның эңгер-меңгердә тагын да серләләнеп киткән күзләренә карап:

—Мин сиңа яучы җибәрәм, Таңгөл,—диде.

Ул арада алар янына батыр үсмер килеп басты, үрелеп, Булат бәкнең иңенә суккалады:

—Сиңа китәргә вакыт, житте,—диде.

—Ә мин сиңа, кайнеш, рун пәкесе алып килдем, җилән...

—Күрсәт,—диде боерулы аһәңдә үсмер.

Булат бәк атына сызгырды, ат килеп житүгә, иярenә таккан капчыкны алды да, капчыктан җиләнне чыгарып үсмернең иңбашына салды, рун пәкесен кулына тоттырды. Үсмер бермәлгә югалып калды, моңа кадәр күпме генә яучылар килмәсен бер генәсе дә бу кадәр тамаша бүләк китермәгәннәр иде Камилгә. Ә бусы мулдан җибәргән.

—Син кайта тор,—диде үсмер, бүләкләр кулына керүгә.

Апасы көянтәсенә чиләкләрне элде һәм куера төшкән эңгергә кереп чумды.

—Апаңны югалтсаң?—диде Булат бәк.

—Мин мәче кебек төнлә дә күрәм,—диде үсмер эре генә.

—Үскәч мин сине үз кырыма алам, сарайга хезмәткә,—диде Булат бәк һәм атының тезгененнән алды.

—Ә син апамның күңелен яуларга теләсәң, яучы булып үзең кил, адәм баласы.

—Үзем?!

—Әйе, үзең. Ә хәзер кит. Бүләкләрең өчен рәхмәт. Ошадың син миңа. Апам әтине түгел, мине тыңлый, мине! Белеп кит!

Шулай диде дә үсмер апасы артыннан йөгерде. Булат бәк бермәлгә ошбу үсмергә ни әйтергә белми торды, ахырдан атына атланды да Аккала күперенә таба чапты.

Ни гаҗәп, чишмә янына икенче килүендә Булат бәкне үсмер кайнеше үтә гаҗәпләндерде:

—Минем җизнәм буласың килсә, бүген үк урла Таңгөл апамны. Иртәгә Биләмҗир тарханы улыннан безгә яучы килә, апамның тарханның угланын күргәне бар, ошаткан иде, риза булып куюы бар, ә син миңа ошадың,—диде.

Үсмер егеттән Булат бәк моны көтмәгән иде, бертын ни әйтергә белми торды, чөнки һич тә моңа әзер түгел иде:

—Кайдан, чишмә янынnанмы?—дип сорады.

—Әйе, кич суга төшкәч урла,—диде үсмер.

Булат бәк тәвәккәлләде, үзе белән ике җансакчысын да алып, кичке якта елга буена, чишмә чыккан төбәккә юнәлде. Буласы кайнеш анда иде инде.

—Хәзер апам килеп җитә, мин бу хакта апама да әйттем инде. Урла. Ләкин минем белән бер җансакчыңны калдырырсың. Мин аның аяк-кулларын бәйләп, атама алып кайтырмын. Ә ул атама булган хәлнең асылын сөйләп бирер. Аңлаштыкмы?—диде булачак кайнеш.

—Аңладым, кайнеш, аңладым,—дип, Булат бәк эңгер иңеп килгән вакытта чишмә янында Таңгөлне көтәргә булды. Ләкин Таңгөл ашыкмады, күренмәде дә күренмәде. Чарасызлана башлаган Булат бәк гасабилана башлады, хәтта янәшәсендә басып торган булачак кайнешеннән:

—Атаң ул-бу сизмәгәндер бит?—дип сорап куйды.

—Юк, сизмәде. Яучы килеп төшкән булса гына инде,—диде.

—Яучы бүген килергә тиеш идемени?

—Бүген килергә тиеш иде. Сабыр ит, булачак җизнәй, төшәр апам суга, төшәр. Атам ни дә булса төпченәдер. Беркөнне дә шикләнеп, нигә син, кызым, эңгер төшкәндә чишмәгә суга йөри башладың әле?—дип зарланып алган иде.

Шунда, Ходайның хикмәте, эңгерне ерып, чиләкләрен бер кулына тоткан, көянтәсен икенче кулына, Таңгөл килеп җитте. Булат кызны күрде дә, килеп җитәр-җитмәс аңа таба китте, чиләк-көянтәсен алып, җиргә куйды һәм Таңгөлне кулына күтәрде. Шулчак булачак кайнеш аңа:

—Җизнәй буласы кеше, куй, калдыр апамны, юкса укка алам!—дип янамасынмы.

—Без бит сөйләшкән идек инде, кайнеш,—дигән булды әле булса кулында тоткан кызны җибәрмичә. Моның өстенә кыз аның муенына сарылган, кайнар сулышы белән муенын пешерә иде.

—Җансакчың кая?

Шунда гына эшнең асылына төшенеп, Булат бәк караңгылыкка кычкырды.

—Хаҗибәй, бире кил!

Җансакчы килүгә, үсмер малай аңа җиргә ятырга кушты, әмма теге икеләнә калды.

—Җиргә ят!—дип боерды аңа үсмер Камил.

—Ят инде, ят!—диде ана Булат бәк.—Ят!

Теге сузылып яткач, үсмер Камил беркемгә дә игътибар итми, җансакчының кулларын ефәк бау белән бәйләде, ахыр аякларын, шуннан соң гына булачак җизнәсенә:

—Атына сызгыр!—диде.

Булат бәк сызгыруга, ат жилле генә чаптырып килде, оста яугир буларак, Булат бәк кызны ияргә утыртты, үзе дә атланды һәм булачак кайнешенә:

—Ышан, Камил кайнеш, мин апанны рәнҗетмәм, кайту белән мулладан никах укытырмын.

—Сыза тор, атамның сизеп алуы бар,—диде аңа кырыс кына үсмер егет. Энесенең җавабына башта апасы кеткелдәп көлеп җибәрде, аңа ияреп Булат бәк елмайды, чөнки кай тарафтандыр анын колагына ат тояклары тавышы килгәндәй булды.

Инде кайнеше булып киткән Камил атасыннан ничек котылгандыр, Булат бәк сорашмады, әмма Габдулла бай улы Камил әсир итеп алган җансакчысын туй булгач кына азат итте һәм түрдә кукраеп утырган кияве-нә:

—Яучы җибәргән булсаң да синдәй егеткә кызымны биргән булыр идем, кияү,—диде. Шунда атасы сүзенә куәт өстәп, ишек янында утырган Камил әйтә салды.

—Ай-һай, атам. Син Булат җизнәйнен җансакчысын гына түгел, мине дә: "Апанны саклый алмадын, малай актыгы", дип, кар базына ташлаган идең,—диде.

—Ташладым, хак. Вәләкин эшнең асылын әйтүгә икегезне дә чыгарып, табыныма утырттым,—диде ата кеше.

Әнә шулай өйләнгән иде Йосыф каханның кала тарханы Булат бәк. Һәй яратты да соң Таңгөлен Булат бәк. Кич кояш баюга, ятулары була—таң ата. Төнне-төнгә кушасы килгән чаклары да булды, яшерә алмый, яшерәсе дә килми. Ә кайчак, буш вакытлары булган чакта Таңгөлен далага алып чыгып китәр иде дә инеш буендагы куе таллыкка алып кереп, сөеп туймастай яратыр иде. Булды, булды андый чаклары да. Үлепләр яратты Таңгөлен, үлепләр...

Яратыр-сөяр иде дә Дала төлкеләрен вә йомраннарын куркытып: "Яратам, яратам мин сине, Таңгөлем",—дип, кулына күтәреп алып, зыр-зыр әйләндерер иде. Мәхәббәт уты татлы айдан соң сүрелә, диләр. Сазаган ир-егетләр әйтсә әйтәләрдер моны. Булат бәк Таңгөлен айлар үтә-үтә дә тансыклады, юксынып-сагынып өйгә кайтты, кайтып керүгә, кулына күтәреп алды да берданберен түшәккә илтеп салды... Әллә ни булды Булат бәк белән, әллә ни күңелен тартып торды Таңгөлгә! Ятса—ул, торса—ул. Әллә соң Йосыф кахан да анын сыман гашыйк булдымы Айбиби хатынга. Бит кырык хатынга ия кеше иде. Кырык хатынга! Ә хәзер аңа бер Айбиби генә кирәк. Шаккатмалы хәл. Хәзер Булат бәк ул яуга китүгә кырык хатынның берсен дә сарайда калдырырга тиеш түгел, кырык хатынның берсен дә. Бары тик сарай күрке булып Айбиби калачак. Димәк, каханга минем чирем кагылган, мәхәббәт чире. Тикмәгә генә раввалар: "Мәхәббәт ул чир",—димиләр икән шул. Мәхәббәт чире белән чирләгән була инде Йосыф кахан. Имамнар мәхәббәтне: "Аллаһы бүләге",—дигән булалар. Ни генә булмасын, мәхәббәт бар, дигән нәтиҗәгә килде Булат бәк.

Ул сарай күперennән чыгып, атын өенә таба борды. Кала тарханы булса да, ни өчендер аңа сарай раввалары Аккалага өй салырга рөхсәт итмәделәр. Имеш, ул гынамы, болгар төркие? Болгар төркиләре гыйлемле халык. Шунын өчен болгар төркиләре белән сарай раввалары арасында һәрчак бәхәс барды: кем өстен?! Әйе, кем өстен Хазарстанда—яһүдләрме, төрки болгарларымы? Чөнки бу халык борын-борын заманнардан бирле ошбу төбәкләрдә көн күреп, Атилла баһадир чорларын хәтерләтәләр һәм нәкъ менә төрки болгарлары "акацирлар" йөзендә Атилла ханның төп көчен тәшкил иткәннәр. Моны да яхшы белә иде сарай яһүдләре. Шуңа карамастан, соңгы йөзъеллыкта Хазарстан белән яһүд раввалары идарә итә башлады. Әмма каханны—илбашын төркиләрдән сайладылар, йә булмаса кушылган гаиләдән килгән ир-атны тәхеткә утырттылар. Тик менә тәхеткә Йосыф кахан килгәч, сарай халкы шомлана башлады. Йосыф кахан баш калкытып кына калмады, үзенең кем каныннан килүен дә аңлатырга ке-

реште. Өлкән равва белән аның куштаннары бу хакта ничек уйлыйлардыр, әмма Булат бәк кала тарханы буларак яхшы белгән иде—төркиләр янә өстен чыга башладылар. Булат бәк бу хәлгә кинәнде. Шул ук вакытта ул рavваларны да хөрмәт итте. Чөнки ил байлыгы алар кулында иде. Мул акча исә көчле гаскәр, ә көчле гаскәр—ил куәте.

X

Төрки болгарларының кахан сараена үтеп керүләренә бер дә шаккатасы түгел иде. Кубрат хан чорларында ук инде, Хазар каханаты белән берләшеп алган Кубрат ханның баш улы Батбай аксакаллары кахан сараендагы табыннарда утырганнар. Хазарстан сараен үз кулларына төшергән рavвалар да Муса пәйгамбәр кануннарына таянып яшәгән төрки болгарларын ят итмәделәр. Ул гынамы, талмудта яһүд руханилары төркиләрне "Туран" аты белән телгә алалар. Ул вакытта дөнья төркиләрен үз тарихларына фарсылар кертеп җибәрәләр. Аталары, каханнарның нигез ташлары "турандардан" чыккангамы, бу хакта Йосыф кахан да яхшы белә иде. Чөнки нәкъ шул борынгы төркиләрнең ак тәнле кавемендәге кыз аның куенында. Дөньядагы бөтен бәла-казаларны яһүдләрдән күргән, куәтләнеп киткән римләннәр дә, фарсылар да бу илләргә христиан дине үтеп кергәндә, яһүдләрне илләреннән куа башлый. Төрле илләр буйлап саташып йөргән равваларны Хазарстан каханы кабул итә. Имеш, китаплы халык. Хазарстан каханаты нәкъ менә ил-халык белән идарә итүне үз кулларына алгач көчәеп вә куәтләнеп китә. Шул сәбәпле булса кирәк, Хазар каханы Идел буе төрки болгарлары белән бер тапкыр да сугышмады. Ислам динен кабул иткән имамнар да, кахан равvалары да нинди дер юллар белән тату яшәүгә ирештеләр. Хак, Ислам дине хакында Болгар мөселманнары белән еш кына бәхәсләр туа тора, хәтта кахан мөселманнарны илдән дә кугалады. Вәләкин бу ике ил халкы беркайчан да зурдан кубып орышмады. Ни өчендер, сәүдәгәрләренең һәм равваларының сүзләрен тынлап, Йосыф кахан башкисәр викингларны дәшергә булды. Ләкин әле бу тиз генә булмас, викинглардан хәбәр килмәде, килгән хәлдә дә ул башкисәр халыкны Идел тамагы аша уздыру турында гына сүз барачак. Ләкин Йосыф кахан өчен каладыр бер дошман—Византия һәм каханат канаты астыннан чыгарга теләгән Сарманай. Дәүләт хакиме буларак, Йосыф кахан Идел буйларында көн күргән төрки халыклар белән тату яшәргә тырышты. Аларга ярдәмгә бай сәүдәгәрләрен җибәрде, шәһәрләрдә сәүдә кальга-калалары күтәртте, төрки бәкләренә вә әмирләренә чибәр яһүдә кызларын озатты. Бу яһүдләрнең ата-бабаларыннан килгән сәясәт иде. Әнә шул яһүдә хатыннардан туган ир балаларны сараена тарттырды, укытты, илбашлары итте. Инде күптән даны еракларга таралган Ефәк юлы да Хазарстан сәүдәгәрләре кулында иде. Шуларның барысын да бер җепкә тезеп уйлый торгач, Йосыф кахан: "Мин дөрес юлда!",—дигән фикергә килде.

Кич белән ул янә үз кырына Айбибине чакыртты. Хәрам атакай Айбиби хатынны ятакка кертте дә ишек яры торып калды.

—Нәрсә булды, нигә торып каттың?!—дип хәрам атага карады Йосыф кахан.

—Хатыннар таратылгач без сарайда калырбызмы, балакай?

—Калырсыз,—диде Йосыф кахан һәм кул селекте.

Айбиби ни кылырга белми, аның кырында басып тора иде, Йосыф кахан, гадәттәгечә, аны кулына күтәрде дә ятагына таба алып китте. Алып барганда хатынның билен кыса төште булса кирәк, Айбиби: "Ай!",— дип кычкырып җибәрде. Йосыф кахан аны сак кына ятакка салды һәм сорап куйды:

—Ни булды, Айбиби җан?

Айбиби каханның күзләренә карады һәм тыенкы гына:

—Бәбиемне рәнҗетә күрмә,—диде.

Менә кайчан каханга кинәт канат үсте, менә кайчан ир уртасы кеше үзүзен белештермичә очынып, бүлмә буйлап йөреп килде һәм хатын янына ятты, ул гынамы, көйли-көйли шигырь әйтте:

*Без бергә, бергә, бәгырь, син дә, мин дә бәхетле.*
*Синең белән бер тән, бер җан булдык, бәгырь, бу көндә...*

Чынлап та, ни булды аңа кинәт, нигә бу хәлгә, ул бу хәбәргә шулай шатланды? Бит мондый хәбәрне бер Айбиби хатыннан гына ишетмәде, аның кырына кергән һәр хатын булмаса да, күпләре балага уздым дип каханны куандырмакчы иттеләр, ләкин бер тапкыр да бу чиккә житеп шатланмаган иде. Житмәсә, Айбибинең апасыннан Тамантархан Галидә инде бәлигъ булган улы бар. Ләкин күнеле белән сизә-тоя иде Йосыф кахан, Айбиби хатын углан бала тапканда аны шул углан алыштырачак.

Шул уй башына килүгә, Йосыф кахан хатынны кочагына индерде, сак кына назлый башлады.

—Йосыфжан, Йосыфжаным,—диде Айбиби ир-канатына.—Мина ирештерделәр, син хатыннарыңны куарга әмер биргәнсең икән. Аккошларыңны мин үзем генә ашатырмынмы?

Самими иде Айбиби, ләкин самими янында самими. Йосыф кахан белә иде, Айбиби хатын белемле, теләсә кем белән бәхәсләшә ала, бу хатыннан хәтта өлкән равва да курка төшә. Ләкин самими кебек күренгән Айбиби хатын аккошларга гашыйк иде.

—Аккошларны ашатучылар табылыр, син миңа малай тап, Айбиби жан, малай. Менә шунда мин сине күккә чөячәкмен.

—Мин куркам, син яуга китәсең ич!

—Мин яудан исән-имин кайтырмын, Айбиби. Кайтырмын да сине Далага алып чыгармын. Иксез-чиксез Далага. Һәм шунда мин мәңге синең белән калырга ант эчәрмен, мәңге!..

—Аккошлар култыгына каракош төшә. Ә ул яман кош, явыз кош!

—Каракош суга төшми, Айбиби жан. Ул тирәктә утыра, аккошлардан көнләшә, үлепләр көнләшә.

—Синең әләмеңдә дә аккош сурәте, Йосыфжан. Ә Византия императоры әләмендә каракош тамгасы.

—Менә шуның өчен мин Византия императоры тарафына яу кузгалам да инде, Айбиби жан. Каракош тамгасын сайлаган Византия императоры. Ә каракош явызлык билгесе.

—Аккошлар култыгында монсарлары да бар. Мин аларны кызганам, Йосыфжан.

—Ишләрен укка алганнар аларның, Айбиби. Алар жансөйгәннәрен югалтканнар. Чөнки аккошлар бер генә тапкыр кавыша, ә ишен югалткан аккош яңадан бер генә аккош белән дә кавышмый. Ялгыз яши, ялгыз үлә.

—Мин дә гүргә кергәнчегә кадәр бер сине яратырмын, Йосыфжаным. Еш кына мин үземне әнә шул ялгыз калган аккош итеп тоям. Барма яуга, каханбәгең генә жибәр.

—Юк инде, Айбиби жан, мин бу яуга барырмын. Чөнки бу яудан соң мин равваларыма буйсынмый башлаячакмын. Тик син елама. Көт, сабыр ит. Нык бул. Мин кайтырмын һәм без һәркөн улыбызны житәкләп, аккошларны ашатырга төшәрбез.

—Нигә соң миңа кадәр күп хатын тоттың, Йосыфжан бәгырь?

—Бу раввалар йөге иде. Мин алардан өстен чыкмаган хәлдә, алар мине юк итәчәкләр.

—Ефәк бау белән буыпмы?

—Ефәк бау белән буып, Айбиби жан. Яудан кайткач, алар моны кылырга кыймаслар.

Йосыф кахан Айбибинең иреннәренә баш бармагын куйды.

—Йосыфжан...

—Яудан кайткач, мин бары тик синең белән генә торачакмын. Тик син башта миңа углан бәби тап.

—Йорт зирәклек белән корылыр, акыл белән ныгытылыр, ахмаклык белән сүтелер, диган Сөләйман пәйгамбәр.

Гадәттәгечә, Йосыф кахан Айбибинең сүзләренә гажәпләнә калды. Бу хатын барысын да белә иде, хәтта пәйгамбәрләрнең гыйбарәләрен дә.

—Сөләйман пәйгамбәрнең вәгазьләрен беләсең—мин шат, Айбиби җан. Ләкин син мине мактамасаң иде, чөнки Сөләйман пәйгамбәр мактауны яратмаган, ул бу хакта: "Сине үз халкың түгел, башка халык мактасын",—дигән.

—Ләкин бит синең раввaларың һәрдаим Сөләйман пәйгамбәр вәгазьләрен тәкърарлыйлар, ялкынланып сөйлиләр һәм алар һәрвакыт хаклы. Ә Сөләйман пәйгамбәр бу хакта: "Ялкынлы тел белән мәкерле күңел, көмеш йөгертелгән савыт кына ул",—дигән.

—Син дә, раввалар да хаклы, Айбиби җан. Артык акыллы хатынны ирләр яратып бетерми. Син мине акылың һәм тапкыр сүзләрең белән түгел, аккошларың белән үз иттең.

—Син илбашы, акыллы кеше, Йосыфҗан. Акны карадан аера белерсең дип ышанам. Мин сине яратам һәм мин синнән углан бала табачакмын, Аллаһы боерган итсә. Һәм Аллаһым миңа бу гамәлемдә ярдәмгә килер.

Әнә шулай сөйләшә-сөйләшә йокыга киткәннәрен сизми дә калдылар. Ишек шакыгач кына, Айбиби дерт итеп уянып китте һәм Йосыфына кагылды. Йосыф кахан күзләрен ачты, бертын түшәмгә карап ятты.

—Мин хәзер әзер булам,—диде ул.

Торып киенделәр, юынып табынга утырдылар. Шуннан соң гына Йосыф кахан Айбибине ишеккә кадәр озата килде, битеннән үбеп, колагына:

—Бирешмә, Айбиби җан, мин кайтырмын,—диде. Икенче мәлдә инде кахан: "Кертегез хәрби киемнәремне!"—дип кычкырды.

Киенеп тәхет ягына чыккач, кахан кырына беренчеләрдән булып өлкән равва керде, аның артыннан ук каханбәк Сабир.

—Галиҗанәпләре, барысы да әзер!—дип тураебрак басты каханбәк—Сезгә кара бия дирбияләнде, җайдак атта кара бия булыр.

—Өлкән равва Ибраһим,—дип кинәт бер читтә басып торган өлкән раввага дәште Йосыф кахан. Сарай синең кулда, кала Булат бәк кулында булыр.

—Хуш, Йосыф углан, хуш. Ак юл сезгә,—диде өлкән равва.

—Тәңребез юлдаш булыр, иншалла!—дип әйтеп ташлады каханбәк Сабир.

Ни кахан Йосыф, ни ишекъяры торучы сакчылар моңа игътибар итмәделәр, ә менә өлкән равва куырылып куйгандай итте. Ул арада тәхет ягына имам хәзрәтләре керде һәм изге юлга чыгар алдыннан Аллаһыбызга дога кылыйк дип, ишек кырындагы түмәргә утырды. Йосыф кахан белән өлкән равва күзгә-күз карашып алдылар да аяк өсте генә имам белән бергә битләрен сыпырдылар.

Хазарстан яһүдләре өчен генә түгел, сарай куштаннары өчен дә ят чара иде бу. Әмма нишләмәк кирәк, өлкән равва үзе үк Харәземгә барып Ибраһим исемен алып кайтты. Йосыф кахан аңа "өлкән раввам Ибраһим" дип дәшкәч тә өлкән равва сискәнеп киткән иде, ләкин моңа игътибар итүче булмагач, уздырып җибәрде. Ахыр килеп, моңа бик үк гаҗәпләнәсе дә юк, Харәземдә генә түгел, Ханбалыкта да күпчелекне мөселманнар тәшкил итәләр иде инде. Бары тик шуңа күрә генә чарасыз калган раввалар сарайларын утрауга салдырдылар. Ләкин утрауларга качып кына диннәрдән котылып булмый икән шул. Әнә шуны аңлады өлкән равва Йосыф каханны яуга озатканда.

***

Сара анакай атна дигәндә Аккалага кайтып төште. Һәм Гаязетдин углан белән. Ни хикмәт, өлкән равва кулыннан әмерне алуга, Сара анакай бер көн дә кунмый, Казан тарафларына юлга чыкты. Бу хакта Айбибигә өлкән равва әйтте.

—Нигә алай, безне дә күрмичә?—диде Айбиби.

—Сара анакай Аккаланы да, Ханбалыкны да яратмады, Айбиби хатын. Була бит шулай яратмаган кешеләрең, яратмаган калаларың, яратмаган ирләрең, хатыннарың... Әйтик Хадичә хатын Йосыф каханны яратмады. Һәм шул сәбәпле без аны беренчеләрдән иленә озаттык, табибәсе белән

бергә.

Айбиби үзалдына елмаеп куйды һәм уйлады: “Димәк, өлкән равва Исламның егет кеше икәнен белми калган”,—дип кинәнде.

Айбиби бала итәкле кулмәгенең итәген күтәрә төшеп, баскычтан сарайга күтәрелә башлады, өлкән равва аңа иярде.

—Өлкән равва, сезне сарайда Рәшидә абыстай көтә,—диде Айбиби артына әйләнеп карамый гына.

—Рәшидә абыстай, мине?!—дип гаҗәпләнде өлкән равва һәм ничәнчедер баскычта туктап калды.

—Әйе, аның сезне күрәсе, ни турындадыр киңәшәсе килә,—диде Айбиби һәм баскычлардан менеп баскач кына борылып, өлкән раввага карады.

—Мин хаким дә, хөкемдар да түгел, Айбиби хатын.

—Сез хаким дә, хөкемдар да, өлкән равва. Аннары Аккаланың ачкычы да сезнең кулда.

—Төп ачкыч Булат бәк кулында, Айбиби хатын.

—Ә сез, баш равва, сарай әүлиясе, кылычсыз баһадир, акыл иясе, каханның уң кулы, өлкән киңәшчесе. Сезнең киңәштән башка каханыбыз кыл да кыймылдатмый, өлкән равва.

Айбиби хатын аңа өстәнрәк карап тора иде, өч баскычка түбәндә басып торган өлкән равва үзе дә аңламаган кимсенү тойды. Әйтерсең баш хатын анардан да өстен иде. Ә бит һәр биләмәдән аның теләге белән теге йә бу тарханның кызын Аккалага тарттырдылар. Шул исәптән Айбиби хатынны да. Ә бу хатын мөслимә. Шушы мөслимә хатын килгәч, сарайның астыөскә килә башлады түгелме?.. Харәзем әмире имамнары да шушы хатын килгәч, тәхет ягына кадәр үттеләр, хәтта каханга үз киңәшләрен бирә башладылар. Хак, һәр хакимнең тәүге максаты кул астындагы түрә-тарханнарны, сарай куштаннарын, шул исәптән равваларны да куркытып тору, тик өлкән равваны түгел. Әйе, түгел иде. Бүген исә... Заманында Булан каханнан барысы да дер селкенеп, куркып торганнар. Явызларга—явыз була, баш игәннәрне мактый Булан кахан. Ләкин һәр кахан өчен дә үтә начар нәтиҗәгә китерә торган бу гамәл ил халкын үчкә китерәчәк, шул исәптән сарай куштаннарын да. Тик бит Булан кахан явызларны, кылган явызлыклары өчен кичерә дә, гафу итә дә белгән. Әмма кайбер сарай кануннарын бозган аксөякләрне, рәхимсез рәвештә, җәзага тарттырган.

Моны ул кул астындагылар узынып китмәсеннәр, кемгә хезмәт итүләре хакында онытмасыннар өчен эшли. Ул вакытта бүгенге өлкән равва да үз адашының шәкерте иде әле. Ибраһим равваның исәеп килгән чагы, ә ни сәбәпледер Булан кахан аның остазы өлкән равваны куралмый башлады. Мөселманнарны яклаган өчен, диделәр. Шуннан кисәктән көннәрдән бер көнне аның адашы вә остазы юкка чыкты. Ә икенче көнне Булан кахан яшь Ибраһимны үзенә дәшеп алды һәм кистереп:

—Бүгеннән сарайда син булырсың өлкән равва,—диде.

Шуннан күп тә үтми Булан каханны чәнчеп үтерделәр. Кем, ни өчен—һичкем белмәде. Ил тәхетенә Йосыф углан утырды. Яшь Ибраһим аның өлкән раввасы вә киңәшчесе булып китте. Сарайга Идел буе Болгарыннан Мөхәммәд ханның Айгөл кызын тарттырдылар. Ләкин ул бала тапты да якты дөньядан китте. Менә хәзер аның алдында Мөхәммәд ханның икенче кызы. Тәкәббер, горур, биленә таянып, эре сөйләшә. Кахан Йосыф исә моңа кадәр булмаган хәлгә барды—яуга киткәндә Булат бәккә сарайдагы барча хатыннарын да илләренә озатып, бер Айбиби хатынны гына калдырырга дип әмер-фәрман биреп китте. Ибраһим равва белән киңәшмичә. Әллә соң шулай тараламы империяләр. Әйтик, Иран, Рим империяләре. Әмма Хазарстанда барысы да әйбәт иде, тик менә хатын килгәч, әллә ни булды, кахан да үзгәрде, сарай куштаннары да өлкән равваны санга сукмый башладылар, мөселманнар да, имамнары да тәхет ягына кадәр үтеп керделәр. Барысына да кахан гаепле—кырык хатынын куарга фәрман язып, бер шушы хатынны калдыра. Нәрсә бу? Әллә соң чынлап та бу мәхәббәт дигән хикмәт бармы? Йосыф кахан кырык яшенә килеп житкәндә шушы

хатынга күзе-башы тонар хәлгә җитеп гашыйк булды. Моңа ышануы кыен иде, гәрчә хатын күзалмастай гүзәл булса да...

—Мин керермен Рәшидә абыстай янына, юк, мин аны үземә дәштерермен, Айбиби хатын,—диде, ниһаять, өлкән равва. Һәм Айбиби, борылып, китеп баруга, үзе дә әкрен генә кузгалды.

"Тарихтан гыйбрәт алу кирәк иде Йосыф каханга, тарихтан»,—дип авыз эченнән тәкърарлады өлкән равва һәм ни өчендер борынгы бабаларының хаталарын искә алды. Шул ук вакытта сарай ишеген үтеп баручы Айбиби хатынга янә күз ташлауга: "Алиһә икән шул, бу бала, алиһә",—дип мыгырдап куйды. Зиһене фәлсәфи китапларны укып, тарихта булган хәлләрне мантыйки рәвештә хәл итәргә көйләнгән булганга, бүлмәсенә кереп, йомшак кәнәфигә утыргач та бабалары тарихын күзаллаудан ерак китмәде. Моның сәбәбен белә иде кебек өлкән равва Ибраһим, шул ук вакытта еш кына яһүд тарихларында бабалары кылган хаталарны зиһене аша кат-кат уздырыр иде.

Борын-борын заманнарда яшәгән бабалары мисырлылар әсирлегеннән исән-имин котылып, ассириялеләрдән шаһиншаһ Кир ярдәме белән азат ителеп, туган туфракларына кайткач, ни өчен соң әле өсләренә ябырылган римләннәргә каршы тора алмыйлар? Бу тарихны да яхшы белә иде өлкән равва. Йосыф Флавий язган "Яһүдләр сугышы" китабын кат-кат укыганы бар. Ошбу канлы сугыш римләннәр тәхетендә Кай Калигулла утырганда була. Рим легионерлары бабаларының җирләренә вә калаларына басып керә. Яһүдләрнең гаскәриләр башында торган Йосыф Флавийны богаулап Римгә алып китәләр. Ул анда укый, белем ала һәм егерме алты яшендә хөкем утырышында катнашып, үлемгә хөкем ителгән якташларын, йолып алып кала. Империя кануннарын яхшы белмәгән хәлдә, ай-һай, ирешә алыр иде микән моңа Йосыф Флавий. Шул хәлдән соң Рим кануннарын яхшы өйрәнгән Йосыф иленә кайта һәм үз халкын империягә каршы баш күтәрергә котырта. Ул арада Рим тәхетенә Нерон утыра. Йосыф Флавий, тарихчы буларак, үз-үзенә ачыш ясый: "Яһүдләр үзләренең тарихларын булган хәлләргә таянып язсалар, эллиннар үз тарихларын әкиятләргә, легендаларга әверелдерә". Тарихчы Йосыф яһүдләр тарихын язганда Хактәгаләгә йөз тота. Әйтик, Птоломей VI чорында яһүдләргә Антиах ябырыла. Кала артыннан калаларны ала-ала бабаларын җинә һәм равваларга шарт куя: моннан ары балаларыгызны сөннәткә утыртмыйсыз, корбан чалуда чучкага өстенлек бирәсез!

Изге алтүргә чучка баласын кертеп, корбан итүне яһүд раввалары кабул итми. Җиңүчеләр яһүд халкын моңа кадәр тарихта булмаган җәзалар белән җәзалыйлар. Халык моңа түзми, баш күтәрә. Мәдин каласы раввасы Хасманайның улы Маттай җиңүчеләрдән Синай тавына кача, ахыр аннан төшеп, үз кырына ишләрен җыеп, баскынчылар өстенә ябырыла. Баскынчыларны түрәсе булган сәргаскәрне хәнҗәр белән чәнчеп үтерә һәм илен азат итә. Шуннан соң ил белән үзе идарә итә башлый. Маттан вафат булгач, тәхетне өлкән улы Яһүдкә калдыра. Яһүдне тәхеттә Яһүдәта алыштыра. Баскынчы Гиркан яһүдләрнең аталары булган Давытның каберен ача. Ә Давыт яһүдләрнең иң бай патшалары була. Һәм патша табутындагы 3000 талантны ала, шулардан 300 талантны Яһүдстанны ташлап киткән хәлдә сезгә бирәм дип ышандыра. Әнә шулай Гиркан беренчеләрдән булып бабаларының каберен ача һәм андагы хәзинәдән файдалана. Шул хәлләрдән соң яһүдләр тәхетенә Иоханан килә һәм ил белән күп еллар идарә итә. Ул үлгәч, тәхеткә бавилләр әсирлегеннән кайткан Аристабал утыра. Аны үз туганы чәнчеп үтерә. Ниһаять, Яһүдстан тәхетенә Рим императоры Цезарь ярдәмендә Ирод килә. Иродны илбашына аның тарафдарлары Антоний күтәрә һәм сенатта раслатуга ирешә. Әнә шулай Капитолиядән фатиха алып, Ирод Римнән туган иленә кайта һәм ил белән идарә итә башлый. Әлбәттә, Рим вассалы булган Ирод патшаны халык яратмый. Әйе, кем була соң яһүдләрнең тарихын язып калдырган Йосыф Флавий? Йосыф Флавий—яһүдләр тарихчысы? Гайсә пәйгамбәр еллар саны белән

37 елда туа, әнисе ягыннан Маккавәйләр буыныннан. Йосыф Флавий яһүд мөгаллимнәреннән генә сабак алмый, грек каһиннарыннан сабак ала, грек философларының мәктәпләрендә укый. Егерме алты яшендә Римгә килә һәм биредә император Нерон артисты Алигәр аша Неронның хатыны Поппей белән таныша. Нәкъ менә Поппей ярдәме белән Йосыф Флавий яһүд равваларын үлемнән коткарып кала. Башта ул римләннәр яклы фирка әһеле булып йөри, соңыннан азатлык өчен көрәшкән яһүдләрнең сәргаскәре булып китә. Тиз арада үзенә ун мең гаскәри жыя, аларны коралландыра. Башкаласы итеп алган Йопатан һәм Тиверанд, Гамали, Вирасай, Тарихәй һ.б. калаларны кулына төшерә. Бу хәлне ишетеп, Рим империясе аңа каршы сугышларда җинүләрдән җинүләргә барган полковник Веспасианны җибәрә. Көчле кагортлар, җиңелүне белмәгән легионерлары белән Веспасиан тиз арада Йосыф яулаган һәм нығыткан калаларны үз кулына төшерә. Йосыф үз кешеләре белән Иотапат кальгасына кереп бикләнә. Вәләкин бик күп югалтулар аша булса да исән кала—кырык иптәше белән кирмән эчендәге тау куышына чигенә. Кальганы кулга төшергән Веспасиан Йосыф качкан тау куышына илчеләрен җибәрә: "Бирел, бирелгән хәлдә мин сезнең барыгызны да исән калдырачакмын", ди. Әмма Йосыф бирелик дисә дә иптәшләре: "Без азатлык өчен нинди югалтуларга дучар ителдек, шәһит киткән ишләребез күзенә ничек күренербез", дип, Йосыфка каршы төшәләр. Шунда хәйләкәр Йосыф ишләренә болай ди: "Инде шәһит киткән ишләребезгә корбан булырга теләмибез икән, һәр икебез жирәбә тотышып, кем баш чыга ишен үтерсен",—дигән тәкъдим ясый. Үлемгә дучар ителгән ишләре, дошман кулыннан үлгәнче, үз ишем кулыннан шәһит китеп, оҗмахка керим дип бер-берсен үтерәләр. Исән каладыр Йосыф белән аның бер иптәше генә. Шунда Йосыф ана тәкъдим ясый: "Бирелик, берберебезне үтерсәк, дошман кинәнер генә, бирелсәк, исән калсак, без римләннәргә каршы тагын көрәшербез һәм халкыбыз алдында йөзебез ак булыр",—ди. Иптәше килешә. Һәм алар кулга-кул тотышып, чатыр корып, яһүдләрнең храмы мәйданы алдында утырган Веспасиан янына керәләр. Керә-керүгә, чатыр түрендә җәелеп утырган Веспасианга Йосыф болай ди: "Тагын ике айдан син император буласың, синнән соң империя тәхетен улың Тит биләячәк..." Җинүче буларак, полковник Веспасиан аның бу күрәзәлегенә ышанмый, шаркылдап көлә генә. Әмма Йосыф күрәзәчене җәзаларга бирми, ике ай буена бу яһүдне күз карасы кебек саклагыз, дип легионерларына тапшыра. Ни хикмәт ике айдан чынлап та император Нерон үтерелә һәм җинүләрдән җинүләргә барган Веспасианны сенат Римгә дәшә, һәм аны император итеп күтәрәләр. Римгә кайтып киткәндә ул Йосыфны улы Титка биреп калдыра. Әтисе сенат тарафыннан расланып Рим тәхетенә утыргач, Тит яһүдләрнең барлык изге китапларын Йосыфка кайтарып бирә һәм әсир ителгән булсалар да храмга кереп бикләнгән йөз туксан равваны азат итә. Әнә шунда Йосыф Титның фамилиясен ала, Тит, аны Римгә алып кайта, хәтта атасы сараена сәркәтип итеп куя, һәм аны дәрәҗәле Рим гражданины итә. Үзенең соңгы елларына кадәр Йосыф Флавий император сараенда хезмәт итә һәм шунда яһүдләр тарихын язарга керешә. Йосыф Флавийның төп максаты элегерәк яһүдләр тарихын язган һәм хакыйкатьтән ерак йөргән Юста Тижериадка каршы чыгу була. Чөнки Римгә килеп урнашкан бу кеше Йосыф Флавийны Рим империясенә каршы чыгасың, дип гаепли. Йосыф Флавий хакыйки тарихны язып, яһүдләр турында римләннәр язган әкият-легендаларны юкка чыгарырга тели һәм нindидер күләмдә мона ирешә дә. Тик нигә яһүд халкын һәр империя эзәрлекли һәм хәтта кууга кадәр барып җитә соң?! Менә моны аңлый да, аңламый да иде өлкән равва Ибраһим.

Килә бер чор Бөек Рим империясе таркала башлый һәм колачына христианнар хәрәкәтен алган Константин үз дошманы Лициниийны юк итеп, башкаласын Византия төбәгенә күчерә һәм шуннан торып империя белән идарә итә башлый. Ләкин Йосыф Флавий язган яһүдләр тарихы бу императорның да өстәлендә ята. Чөнки христиан дине шул тарафлардагы Галиләй-

дән килгән була һәм күп кенә вакыйгалар яһүдиләр тарихыннан алына. Йосыф Флавий китабында: "Империяләр мәңгегә килми, ә халык мәңгелек, чөнки аны Ходай яраткан",—дигән сүзләр дә була. Яһүдстан римләннәр заманыннан ук таратылырга дучар ителә. Гарәпләр дә исраил балаларын читләтеп үтми. Яхва аллаһыларына тугры калган рәнҗетелгән яһүдләр Иранга юнәлә, вәләкин әүвәл яһүд халкын фарсы аксөякләре колач җәеп каршы алсалар да, еллар үтә-үтә яһүдләрдә нииндидер мәкер күреп, аларны илләреннән куалар. Җитмәсә Византия императоры, бигрәк тә пасха көннәрендә, яһүдләрне эзәрлекли башлый, борынгы яһүд диненә тугры калып, ит ашамаган яһүдләрнең авызларына кургашын койдыртa һәм күбесен хәтта чукынырга мәҗбүр итә. Чарасыз калган яһүдләр янә дөнья буйлап сәфәр чыгалар һәм, ниһаять, Хазарстан төркиләренә килеп елышалар. Ә Хазарстан төркиләре аларны араларына алу өчен табын җыя һәм табында: "Нишлибез, алабызмы илебезгә бу илдән-илгә куылган халыкны, юкмы, аксакаллар?"—дигән мәсьәләне күтәрә. Кахан дәшми. Бу четерекле мәсьәләне аксакалларына хәл итәргә куша. Шунда бер аксакал тора да: "Алыйк үз арабызга илдән-илгә куылган бичараларны, чөнки яһүдләр китаплы халык",—дигән фикер әйтә. Әнә шулай илләр буйлап, кангырып йөргән яһүдләр Хазарстан төркиләре тарафыннан кардәшләре кебек кабул ителә.

Өлкән равва кәнәфиендә борсаланып куйды һәм ишек сакчысына:

—Миңа Рәшидә абыстайны дәш,—дип, урыныннан торып, йөреп килде.

Ни өчен Иран шаһиншаһы иленнән куа соң әле яһүдләрне?..

Әйе, үтә үткен яһүд раввалары яһүдләрнең чибәр һәм күп телдә сөйләшә алган кызларын шаһиншаһ сараена уздыралар. Шаһиншаһ аларны бик теләп кабул итә, хәтта берничәсенә өйләнә дә. Ә яһүдәләрдән туган балаларны раввалар үзләре укыта. Белемле яһүд егетләре шаһиншаһ сараена үтеп керә, вәзирләрен алыштырыр дәрәҗәгә җитеп, шаһиншаһка якынлаша. Вәләкин кайсыдыр шаһиншаһ яһүдләр дине сарайга үтеп керә башлагач, курка кала һәм аларны сарайдан гына түгел, илдән куарга әмер бирә. Ә менә Хазарстан төркиләре аларны кабул итәләр. Ул гынамы, төркиләрнең бәкләре, түмәнбашлары, хәтта ханнары яһүдләрнең гүзәл кызларына өйләнә, ә тегеләр үзләре тапкан балаларны Миша кануннарына һәм Талмудка таянып, сарай мәдрәсәсендә тәрбияли. Кахан сарае яһүд кызлары белән тула. Кахан шул чиккә җитеп байый ки, Идел уртасындагы утраyга Аккала күтәртә. Сарай кальга-дивар белән уратып алына, зур кала—Ханбалыкка чыгу өчен күпер салына. Әнә шулай яһүдләр Хазарстанны үз кулларына ала башлый. Моны да яхшы белә иде өлкән равва Ибраһим. Тик нигәдер күңелендә канәгатьсезлек туа башлады. Хәзер генә түгел, бу хәл аның белән элек тә булгалады, ләкин болай ук шомга калдырмаган иде әле. Чөнки Йосыф кахан юлдан язды. Моның төп сәбәбен өлкән равва Айбибидән күрә. Ә бит төркиләрне һич кенә дә кысрыклау булмады. Аларның мөселманы да, мәҗүсие дә үз диннәрендә калды. Империядән качып төркиләр арасына килгән христианны да кысмадылар яһүдләр, гәрчә Византия императорлары яһүдләрне илләреннән куса да. Әйе, әнә шулай уйлана-уйлана өлкән равва бөтен хатаны әле Айбиби хатынга такты, әле үз җирләрен кулларында тота алмаган, үзара ызгышып, илләрен вә җирләрен югалткан бабаларын орышты. Ләкин бит тарих раслый, бабалары үз җирләрен, үз илләрен кан коймый гына дошманга бирмәгән, ил-калаларын, храмнарын сакларга тырышкан. Әйе, күп кырганнар яһүд халкын римләннәр, ләкин ошбу куәткә ия империя Яһүдстан җирендә ятып калган канкардәшләренең—легионерларының санын үз тарихларында күрсәтмиләр, ә менә илватаннарын саклаганда шәһит киткән яһүдләрне бермә-бер диярлек артык күрсәтәләр.

Рим империясенең коллар чоры бик тә аяныч бетә—менә бүген яһүдләр идарә иткән Хазарстан төркиләре каһарманы Атилла хан Рим капкасына кадәр барып җитә һәм Римне тез чүктерә. Рим императоры Валентиан яубаш баһадир каршына чыгарга курка, үзенең рухание папа Левне егерме бер пот алтын биреп чыгара. Мескен папа каһарман баһадир алдына ки-

леп тезләнә, каланы җимермә, алып кит бар байлыгыбызны дип ялвара. Атилла хан каланы җимерми, кире борыла. Әмма ялган тарих язучы Рим куштаннары үз тарихларына: “Җинүче кылычын йөрткән Атилла күктәге кылыч тоткан Ходадан курыкты да кире иленә таба борылды”, дип язып куялар. Моны да яхшы белә иде өлкән равва Ибраһим. Ә бит әнә шул бөек халык, Рим империясен буйсындырып кайткан төркиләр, яһүдләрне үзләре арасына алдылар. “Бәлкем, мин ялгышамдыр, Йосыф балакай дөрес эшләгәндер. Бит Хазарстанның төп терәге төрки бәкләре һәм ханнары, бер дә мәҗүси Сарманай кахан түгел. Җитмәсә кахан ел саен юлбасарлык кыла, Хазарстан канаты астына кергән халыкларыннан рөхсәтсез ясак җыя...”

Ишек шакыдылар. Өлкән равва сискәнеп китте, чөнки уйга чумып утыра иде.

—Керегез—кер,—диде ул һәм торып басты.

Рәшидә абыстай керде, яулык очы белән авызын каплады, әйтерсең авызыннан артык сүз чыгып китүдән курка иде.

Өлкән равва кул ишарәсе белән аңа кечкенә өстәл янына узарга дәште. Кечкенә өстәлдә Коръән Шәриф ята, өлкән равваның кулында Талмуд иде. Абыстай каплаган авызын ачып:

—Өлкән равва Коръән Шәриф укый?!—диде.

—Һәр изге китап—белем чишмәсе,—диде өлкән равва өстәл янына килеп, кечкенә урындыкка утырды, абыстайга урын күрсәтте. Өлкән равва кулындагы китапны Коръән Шәриф белән янәшә өстәлгә куйды һәм абыстайның күзләренә карады. Айбиби хатынныкы кебек абыстайның да күзләре зәңгәр иде.

—Сезне минем кырга Айбиби хатын җибәрде, шулаймы Рәшидә абыстай?

—Юк, Ибраһим, сезнең кырга мин үзем килдем. Йомышым бар сезгә.

—Имам хәзрәтләре җибәрдеме, аның сүзен үтисезме, абыстай?

—Юк, мине сезнең янга кем дә җибәрмәде, өлкән равва Ибраһим, мин үзем килдем, үзем...

Өлкән равва уңайсызлана калды, аңа исеме белән бик сирәк кешеләр дәшә иде. Хатын-кыз авызыннан үз исемен ишеткәч, дорфарак сораулар биргәненә үкенү тойды. Ул янә каршында утырган абыстайның күзләренә карады һәм кинәт әллә нишләп китте. Кемгә булса ошаттымы, күңеле шулай якын иттеме абыстайны, аңламады. Тик абыстайның итагатьле итеп елмаюы, серле итеп күзләренә каравы йөрәгенә оялаган иде инде. Ул моны жаны-тәне белән тойды.

Талмуд бик матур итеп болгари күн белән тышланган. Бисмиллахиррахман иррахим, дип, Рәшидә абыстай аны кулына алды, күпертек иреннәре белән үпкәндәй итте, күкрәгенә кысты. Шуннан соң гына:—Илаһым, аермасаң иде ил бәндәсен дүрт китаптан: бере—Инҗил, бере—Тәүрәт, бере—Зәбүр, бере—Коръән,—дип, китапны кире өстәлгә куйды.

Ибраһим равва ни әйтергә белми бермәлгә югалып калды. Чынын гына әйткәндә, абыстайдан ул моны көтмәгән иде. Ничекләр итеп елмая, үз итеп елмая, ә бит менә шул елмаюны ул бу хатыннан беренче очрашуда ук күрергә теләгән иде. Сүз дә юк, Рәшидә абыстай Рим матронасы түгел, кочагына кереп оялларга тормас, вәләкин үзе үк синең бүлмәңә килеп кергән икән, моның бер-бер сәбәбе булырга тиештер бит инде?.. Тик нинди сәбәп? Менә шуны беләсе килә иде аның Идел буйларында үскән һәм әле хатын-кыз кодрәтен вә гүзәллеген югалтмаган абыстайдан.

—Сез әйткән китапларның дүртесе дә Аллаһ җимешләредер, абыстай.

—Сез хаклы Ибраһим, һәр китап, ул тормыш агачы, бар халык арасында яшәүнең асылы, дөньялыкта яшәү мәгънәсе. Әнә шул китаплардагы мәгънәне аңлап яшәүчеләр бар, аңламаучылар бар. Безләрне мин аңлаучыларга кертәм, Ибраһим.

Бу ни инде тагын, нигә Ибраһим моңа кадәр булмаган каушау тоя? Ни дә булса әйтергә тиештер бит инде...

—Кахан яуда, без монда, абыстай. Ил мәшәкатен өстемә аударып китте

илбашыбыз. Хатыннарын илләренә озатырга әмер-фәрман биреп киткән каханыбыз.

— Бу хакта Айбиби белән киңәште микән соң ул, Ибраһим?

"Менә абыстай белән исемнәребез атап кына сөйләшә башладык. Хәерле булсын",—дип уйлады өлкән равва.

Өлкән равва Ибраһим Харәземгә барып, мөселман динен кабул итеп кайтса да, күңеле вә йөрәге һәм җаны-тәне белән Яхвасына тугры кала бирә иде. Ул бу мәсьәләгә фәлсәфи яктан килә. Ислам дине дә шул ук Тәңре һәм Яхва кебек илаһлар утырткан изге агач җимешләре. Тик бу ике динне бабаларыбыз берләштерә генә алмаган. Ә менә Аллаһ илчесе пәйгамбәр Мөхәммәдерәсүлуллаһы, Аллаһы иңдергән вәгазьләрга таянып, үзенә бер юл сайлый. Бик ихтимал, аңа чынлап та Аллаһ үзе изге китапларның берсе—Коръән Шәрифне ирештергәндер. Ни генә димә, төркиләр белән яһүдләр Хазарстан җирендә бер халык булып оешып киткәннәр икән, монда Аллаһның да теләге булмагандыр дип әйтергә кем кыяр?!

Өлкән равва Ибраһим каршында утырган абыстайга янә бер тапкыр игътибар белән карап алды. Абыстай тоташ актан киенгән иде, күлмәгенең бала итәкләренә генә зәңгәрсу тасма бөргән һәм башындагы яулыгы да шул тасма төсендә. Моңа өстәп, абыстайның зәңгәр күзләре килеп кушыла. Идел буе төрки-болгар хатын-кызлары киемне дә сайлый беләләр иде. Болын күрке—чәчкә булса, хатын-кыз күрке—кием ич. Болар кара гарәп хатын-кызлары кебек бер дә тоташ карадан киенеп, бит-башларын пәрәнҗәгә томалап йөрмиләр. Ә бит гарәп хатыннары да шул ук мөслимәләр, шул ук җир йөзендә яши. Каршында утырган хатын бер дә кара гарәп хатынына охшамаган иде. Шушы уйлардан соң Ибраһим ошбу хатын йөзендә моңа кадәр күзенә чалынмаган, чалынып та күңел игътибарыннан читтә кала биргән назлылык галәмәте күрде. Абыстайда бар хатын-кыздагы кебек күркәмлек, мөлаемлек, итагатьлелек күзгә чалына, шул ук вакытта нәзбереклелек тә бар. Ә бит нәзбереклекне Ходай Тәгалә бар хатын-кызга да тулы килеш бирмәгән. Биргән булса, бар хатын-кыз да ил гүзәле булыр иде. Кемдер аңа әйткән иде: "Кыз бала ана кулындагы камыр ул, сабый чакта ана кеше үз баласын ничек әвәли, үскәч тә ул баладан ана биргән гүзәллек китми. Айбиби хатынны Рәшидә абыстай әвәләп үстергән, үзенә охшатып, үз холкын, үз кыланышларын, үз мөлаемлеген дә биреп. Өлкән равваның бүлмәсенә моңа кадәр бер генә хатын-кызның да аяк басканы юк иде. Рәшидә абыстай беренчеләрдән булып бусагасына атлап керде.

—Китап уку зур бәхет ул, Ибраһим, зур бәхет,—дип, кузгалгандай итеп куйды Рәшидә абыстай. Шунда өлкән раввага кисәктән курку килде. Китә ич! Җибәрмә!

Аның башына шаулап кан сугандай булды. Ул янә бер тапкыр Рәшидә абыстайга назга тансыклаган ирләр күзлегеннән карады. Карады һәм үз-үзенә таң калды. Күзе төште бит аның абыстайга! Йоклап яткан ирлек гайрәтен уятты абыстай. Аның яшендә бик сирәк була торган хәл бу! Менә кайчан Йосыф балакайның хәленә керде өлкән равва. Кырык хатыны була торып, бер хатынга ябышып калуын аңлады. Чынлап та, баштагы мәлдә Йосыф балакайның Айбиби хатын тирәсендә дивана хәленә килеп гашыйк булып йөрүен бөтенләй аңламады ул, аңларга да теләмәде. Һәм хәзер, бүген, менә шул мәлдә дивана хәленә төшеп булмаса да аның күңеленә тымызык бер мәхәббәт хисе кисәк өермәгә әверелеп килеп тулды. Айбиби хатын Йосыф каханны сихерләде, дигән фикер белән килешер-килешмәс аптырап та йөргән иде ул. Хәзер әнә шушындый ук сихер кармагына үзе эләгә түгелме?.. Кахан Айбибидән башкаларны күрергә дә теләмәде. Йә дигәндә, йә дип, өлкән раввага табынып торган Йосыф балакай Айбиби килгәч тәмам үзгәрде дә куйды. Авыр кичерде Ибраһим равва каханның бу мавыгуын, үтә авыр кичерде. Башта татлы айлары узгач, оныт дип өмет итте, көтте, сабыр итте. Тик бер ябышкан купмый икән шул, Йосыф кахан бар хатыннарыннан да баш тартып, ятагына һәрчак

Айбибине чакыра башлагач, тәмам аптыраштa калган иде. Инде үзе менә шул хәлгә калып утыра түгелме! Әйе, каршында утырган абыстай да ул кичергән тойгыларны кичереп утырса?.. Илбашының рухани атасы ич ул—ерак бабаларын Бөек Кир азат иткәч, Ярми күрәзә кебек, халкының динен, телен саклап калу өчен борчылып яшәгән рухани. Аның улы Язикәй анда күккә омтылган туксан метрлы манараны да, асылынып торган ожмах бакчасын да, елга суы кебек кешеләр һәм кәрваннар агып торган Иштар капкасын да күргәндер. Йөзменнәрдән арткан кала халкы—бавилләр, халдиләр, ассирәйләр, иләмәтләр, гарәпләр, финикәйләр, яһүдләр һәм греклар арасында яшәп, Ефрат аша салынган күпер аша чыкканда, үз халкы шушы дөнья ташкынына әверелгән халык арасында эреп, юкка чыгар дип курыккандыр. Баштагы мәлдә Ибраһим равва да Ханбалыкта шулай дип куркып яшәгән иде. Хәзер, шөкер кыла, ул яһүдләрне аерды—аерым Айбалда каласында көн күрәләр, ләкин төрки тел үтемлерәк, яһүдләргә якынрак булдымы, яһүд халкы төрки телдә сөйләшә башласа да, динен онытмады, ташламады, күңеле белән Яхвага тугры яши. Инде әсирлектәге яһүдләр өстендә "Аллаһ кылычы" булып эленеп торган фарсыларның Мардук алласы да һәм бавилләрнең патшалары да гасырлар туфрагы астында калды. Ә бит үз заманында шушы шәһәрдәге кебек анда да үзенең көчекуәте, мәһабәтлеге, күзне камаштырырлык җемелдәве белән дөнья халыкларын шаккатырган каласы да яһүдләрне йота. Ләкин аларның күбесе ерак Синай тауларын онытмый, илләрен фиргавеннәр җимергәч тә күңелләре белән Исраилгә тартыла. Ярми улы Язикәй көннәрдән бер көнне төш күрә һәм Яхва алласы аңа әйтә: "... мин сезне илегездән ераклаштырып дөнья илләре буенча таратсам да, сезгә мин көчле гыйбадәтханә булып торырмын һәм сезгә бердәм йөрәк бирермен, ә таш булып каткан йөрәгегезне алырмын, һәм җан индергән йөрәк бирермен, әмма ул йөрәк минем сезгә индергән җан булыр. Мин сезнең Аллаһыгыз булырмын..."

588 нче елда (б.э.к.) Мисыр тәхетенә фиргәвен Хофра утыра. Бөек фиргавен Нохоның улы: "Яһүдләр әсирлектә яшәгәндә дә үз аллаларына тугры" дип, ташка суктырып калдыра.

Бу уйлану иде. Бу тарихка төшеп, бабалары кылган хаталарны кабатламас өчен чара эзләү иде. Рәшидә абыстай аны оныткандай, изге китапларны актарып, укып утыра. Ә Ибраһим равва тарихка кереп чумды, уе-хисе, акылы-зиһене белән хәтерендә калган бабаларының тарих сәхифәләрен актарды.

Шунда, кинәт, Рәшидә абыстай бер китаптан мондый юлларны укый башлады. "Руфиянең ире Яһүд котмәгәндә вафат була. Тол калган яшь хатын Яһүднең атасы кырында калыргамы, китәргәме дип, уйланып утыра. Әтисе аңа әйтә: "Инде нишлисең, килен?" Килене атасына әйтә: "Кая син китәсең—мин шунда барам, кая син туктыйсың, кая яшисең һәм мин шунда яшәрмен. Синең халкың—минем халкым, синең Аллаң—минем Аллам, кая син үләсең, мин шунда үләрмен, кая сине күмәләр, мин шунда синең каберенә кереп ятырмын. Аллаң мине кабул итсен һәм догасын бирсен, үлем генә аерса—аерыр синнән мине," ди. Аллаһ изге җанны кабул итә—Вафлимәдә Руфия үз иренең туганы Ваузәгә кияүгә чыга, ә аның оныгының оныгы Давыт яһүдләрнең иң куәтле патшалары була".

Өлкән равва Ибраһим тәмам өнсез калды, ул моны Рәшидә абыстайдан һич тә көтмәгән иде. Ул торды да Рәшидә абыстай каршына тезләнде, башын аның тезләренә салды. Абыстай дәшми һәм ул да. Әллә соң йөрәкләре сөйләшәме?.. Әгәр абыстай да ул кичергән тойгыларны кичерсә?.. Ул нишләргә тиеш, илбашы киңәшчесе һәм рухани?..

Көрсенеп куйды бугай, ни өчен иңәнлеген үзе дә аңламый калды. Рәшидә абыстай аның башына кулын куйды һәм:

—Борчылмагыз, бер дә борчылмагыз, Ибраһим равва. Йосыф кияү әмирнең имамнарын сараеңа уздырган икән, ул бер дә гөнаһ кылмаган, бу гамәле белән ил-халкын гына түгел, аркадашларын да саклап калган. Бездә: "Бер тиредән тун тегеп булмаса да, бер хатын белән гомер итеп була",—диләр

Ибраһим. Хак, Аллаһыбыз фатихасы белән шактый хатын тотканнар бар... Сөләйман пәйгамбәр дә күп хатынлыкны хуп күргән, ләкин ул бит моны чарасызлыктан барган. Халкы дөнья халыклары арасында эреп бетүдән курыккан.

Өлкән равва башын күтәрде, Рәшидә абыстайның күзләренә карады.

—Борынгы акыл ияләре киләчәкне гүзәллек коткарачак дигәннәр, әллә соң чынлап та шулаймы, абыстаем? Айбиби хатын аккошлар ярата. Бер ялгыз калган аккош аның яныннан да китми...

—Аккошлар оҗмах кошлары, аларны яратмый мөмкин түгел, Ибраһим.

—Кешелекне, бик ихтимал, чынлап та гүзәллек коткарыр, тик империяләрне түгел, Рәшидә абыстай. Империяләр башта ил-халыкларны яулый, аннары ирек дауларга керешкән үз халыклары белән пычакка-пычак килеп орышалар. Ә без—Аллаһыбыз каргаган халык, алар арасында тулганабыз.

—Һәр халыкка да Аллаһы тәгалә җир-ил бүлеп биргән, Ибраһим, бары тик Аллаһ бүлеп биргән җирдә яшәсә генә теге йә бу халык бәхетле була, дигәннәр борынгылар да. Мул үләнле тугай-болыннар, елга буйларын сайлап ил-җирләр гизсәгез дә, сез, китаплы халык буларак, һаман үз динегезгә тугры калуыгызны дәвам итәсез.

Рәшидә абыстай әкрен генә кузгала башлады. Шунда өлкән равва аның биленә кулын салды, әмма абыстай һуштан язган сыман аһ итте дә тахтага сузылып ятты. Өлкән равва ни кылырга белми аптырый калды. Әмма абыстай әкрен генә күзләрен ачты һәм:

—Курыктым мин синнән, Ибраһим,—диде.

— Сез миңа ошадыгыз, абыстай, ошадыгыз.

—Без фикердәшләр булып кына калыйк, раввам, фикердәшләр.

—Юк инде, абыстай, йә сез минем гомер юлдашым, йә бер елга суын эчеп яши торган ике зат булып калыйк.

— Тик бит, раввам, без икебез елганың ике ярында басып торабыз икән ич.

—Мин сезне бүген җибәрмим, абыстай.

Рәшидә абыстай бүлмәне күздән кичерде, нинди дер бер уфтану белән күрсенеп куйды.

—Гөнаһлы булабыз бит, раввам, гөнаһлы... Ярый, раввам, син мине үзең килеп алырсың,—диде дә, торып, ишеккә таба юнәлде.

Егет чактагы житезлек белән равва Ибраһим аның каршына төште.

—Өстәл хәстәрләтимме, абыстаем?

—Өстәлдә бал, ятакта хатын-кыз булганда йокы да татлы була, раввам,—диде абыстай һәм равваның янагына кагылып алды. Кырык яшен тутырып узган хатын кулыннан хушисләр килде, равва аның кулын эләктереп, кул аркасын үбеп алганын сизми дә калды.

## IX

Иртәнге аштан соң өлкән равва Ибраһим елга ягындагы бакчага чыкты. Башында һаман шул бер уй бөтерелде. Зәңгәр күккә карады, очы-кырые булмаган җиһанда кояштан башка берни дә юк иде. Бары тик офык читендә генә болытлар куерып килә. "Сөенче" китабында мондый юллар бар: "Дөньядагы мин бар иткән барча тереклек тә үз халкының нәселен саклау өчен кулыннан килгәннең барысын да кылырга тиеш. Мин барча адәми затларга да, кош-кортларга да, җәнлек-хайваннарга да саклану кораллары бирдем: керпегә—чәнечкеләр, бүрегә—үткен тешләр, кешегә—акыл. Ләкин ошбу дөньяда һәр тереклек иясе үз кануны белән яши, әмма әкәмтөкәмне ат басып китә, керпене хәйләкәр төлке суга ташлап ашый, бүрене—юлбарыс ботарлый, ә кешегә Аллаһы акыл бирә. Әнә шул акыл иясе дәверләр үтә-үтә бер-берсен кыру өчен камилдән-камил корал житештерә, үз-үзенә дошман таба һәм камил корал вә акыл аша теге йә бу халыкны яулый һәм кул астына ала, аңа телен, динен, гореф-гадәтләрен тага башлый. Заманында Византия Хазарстанга грек уты белән янады. Әмма төркиләрнең атлы гаскәре Византия белән көрәшкә чыкты. Әнә шулай куәтле им-

перия белән Хазарстанга тыныч-имин яшәргә мөмкинлек туды. Тик озак дәвам итәрме бу хәл... Хазарстан ялланган гаскәр белән үз илен һәм халкын саклый. Ялланган гаскәр дәүләткә бик кыйммәткә төшә. Моны да яхшы белә иде өлкән равва Ибраһим. Нигә батыр яһүдләр үз илләрен саклый алмадылар икән?.. Кем гаепле мона?.. Гайсә пәйгамбәрме?! Юк, тагын бер тапкыр юк. Ул, бичара, бары тик тынычлык тели, үз үлеме аша халыкка тынычлык китерә. Тик аның үлеме генә халыкка тынычлык китерми. Дөнья халыклары үзара сугышулардан туктый алмый интегә. Төркиләр баһадиры колбиләүчелеккә дә чик куйды. Әмма дөньяда орыш-сугышлар һаман туктамый. Житмәсә, өлкән равва үзе үк, мөселманнардан котылырга теләп, баскынчы викингларны үз иленә дәште. Бөек Римгә халык каргышы аша Аллаһы каһәре төшә. Бу империя инде сүтелеп, таралып килә. Әмма руханилар тарафыннан изгеләр санына кертелгән император Константин көнчыгышта яһүд халкының Гайсәсен алып, христиан дине уйлап тапты һәм каһәр яуган империя оештырып җибәрде. Шушы каһәр төшкән империя тора-бара Исраил балаларының жирләрен дә кул астына алды. Бүген инде Исраил балаларына ул тарафларга барырга да ярамый башлады. Кайчан Хода яһүд халкын Аллаһ сайлаган жиргә кайтарыр да, ирекле рәвештә дөнья күтәргә мөмкинлек бирер?.. Бер Хода белсә беләдер моны. Әмма туган туфракны кайтып күрәсе килә. Килерме ул көн! Күрерме ул көнне Хазарстанда көн күргән өлкән равва Ибраһим?! Килер, өлкән равва Ибраһим мона жаны-тәне белән ышана иде. Әйе, һәр яһүд кебек...

Хазарстандагы хезмәтен ул бик ерактан башлады. Башта адашы Ибраһим кул астында хезмәт итте. Ә инде ул олыгаеп, йөрмәс хәлгә килгәч, Хазарстан каханы Булан яшь Ибраһимны үз кырына алды. Тагын да гажәбрәге шул булды—аның хакында берәү дә кызыксынмады, гүя аны Яхвалары үз кырына алган иде. Яшь Ибраһим да бу хакта кемнән дә булса сорарга кыймады. Бары тик Хазарстан сәүдәгәрләре Ефәк юлын үз кулларына алгач кына, Ибраһимга адашы Исраил жиренә киткән дигән хәбәр иреште. Соңгы елларда көчәеп киткән гарәп сәүдәгәрләре Ефәк юлын үз кулларына ала башладылар. Бу хәл өлкән равва Ибраһимны янә пошаманга салды. Житмәсә, кара гарәпләр үз тарихларын яһүд равваларына илтеп ялгадылар. Шаккатмалы хәл иде бу! Әрсез гарәпләр үз диннәрен Идел буенда көн күргән болгар төркиләренә китереп бәйләделәр һәм, иң гажәбе, тыныч рәвештә. Идел буе Болгары ханы Алмас хәлифәнең юмакай сүзләренә алданып, Ислам динен кабул итә. Әйе, хәйләкәр хәлифә аңа тау-тау алтын вәгъдә итә, имеш, минем дин аша син Хазар каханаты кул астыннан чыгачаксың. Бу хәбәр килеп ирешүгә, Идел буе төркиләрен кул асларында калдыру өчен, Хазарстан раввалары Алмас ханга ташламалар ясарга мәжбүр булдылар. Алмас ханга хәлифәдән берни ди таммады. Ләкин гарәпләр барыбер оттылар, чөнки төрки болгарлары аша гарәпләр үз диннәре белән дала угызларына, ары таба кыпчакларга үтеп керделәр.

Хазарстан каханы Римнән, Иран нан, Византиядән куылган яһүдләрне китаплы халык дип кабул иткән иде. Әнә шул китаплы халык тора-бара Хазарстанның идарә түрәләрен, бәкләрен әкрен-әкрен генә үз кулларына алды һәм ил белән идарә итә башлады. Хазарстанга күчеп килгән равваларның төп хыялы көчле төрки халыклары белән туган жирләрен кулга төшерү иде. Әмма ул теләк-максат чынга ашмады, гарәпләр өлгеррәк булып чыкты. Инде хәзер әрсез гарәпләр яһүдләрнең туган туфракларын гына түгел, куәтле төркиләрнең дә жирләренә кул суза башладылар. Чарасыз калган өлкән равва алардан котылу өчен яман викингларны чакырырга мәжбүр булды. Бу бик яман юлга заманында Виншамин кахан да баса. Викинглар көче белән мөселман илләрен талата, гәрчә шушы яулардан меңләгән викинглардан унлабы гына исән-имин әйләнеп кайтса да. Аның каравы, ясакчылары исәбенә кергән викинглар каханны алтынга күмәләр. Ләкин “жилдән килгән—жилгә китәр”, дигәннәр. Виншамин кахан берни дә отмый. Менә хәзер Хазарстан янә шул юлга басарга әзерләнде. Ләкин

ахыры ничек бетәр? Берәү дә белми иде, хәтта өлкән равва үзе дә.

Бик озак карап һәм уйга калып утырды өлкән равва хозур бакчада. Ахыр кахан чатыр кырына узды, киез җәйгән ташка утырды.

Хазарстан илен, нигездә, төркиләр саклый иде. Өлкән равва төрки бәкләре белән беркайчан да бәхәскә кермәде. Аларга гүзәл яһүд кызларын кияүгә бирде, үз кешеләре итте. Өлкән равва һәрдаим Яхвасыннан могҗиза көтте. Бавилләргә могҗиза йөзендә Бөек Кирны кайчандыр китерә бит. Китерә. Һәм шул адәм аларны әсирлектән азат итә. Кабатланырмы ул могҗиза тагын бер?! Кабатланырга тиеш, чөнки өлкән равва Ибраһим гына түгел, бөтен дөнья яһүдләре моны телиләр иде. Хак, Хазарстанда да начар яшәмиләр алар, бар нәрсә үз кулларында. Сугышчан төркиләр ярдәме белән Хазарстан тәмам чәчкә атты. Хазарстан белән чиннар да, фарсылар да, византия греклары да исәпләшергә тиеш булдылар. Бәхәссез, бу да җину иде. Тик менә ялгыз калуы гына бераз эчен пошыра иде өлкән равваның. Бал чәчкәседәй чибәр яһүдә кызга өйләнеп тә уңмады. Бер Хода белә ни сәбәпледер, шул хатын Дала бәгенә иярде дә китте. Башта өлкән равва яугирләре белән куып тотарга һәм хатынны кылычтан уздырырга теләгән иде, әмма уйлана торгач, бу адымны ясамаска булды. Әйе, шул мәлдә Коръәндә булган Аллаһ сүзләре исенә төште. Анда мондый юлларны укыган иде ул: "Хатын-кыздагы мәхәббәт, иминлек, кызгану хисе ул затка Аллаһ тарафыннан бирелгән. Үз кырындагы хатын-кызны сүздән, иректән мәхрүм итсәң, ул йортка игелек тә, тынычлык та, гаделлек тә иңмәс..."

Шул сүзләрне күнеленнән кичерүгә, өлкән равва утырган урыныннан торды да аккошлар ашаткан су буена таба кузгалды. Бу урын аңа кай ягы беләндер оҗмахка охшаган кебек тоела иде. Әйе, Аллаһының оҗмахында да шушындый урыннар бардыр. Судагы аккошлар гына түгел, аяк астындагы алтын төсендәге ком да биредә күнелне сафландыра, йөрәкне тынычландыра иде. Кинәт кенә күнелдәге якты хисләр кузгалып куя, офык читендә төрки бәге белән качкан гүзәл хатыны күз алдына килгәндәй була. Ул әле таллыктагы күл өстенә тәңкәләрен җәеп яткан төнбоек өстендә пәйда була, әле гүя, аккошлар арасында йөзеп йөри. Хатыны ташлап киткәннән соң өлкән равва беркемгә дә гашыйк була алмады. Ул бөтен гомерен каханат белән идарә итүгә багышлады. Һәм бу өлкәдә күп нәрсәләргә ирешә дә кебек. Әйе, ирешә. Тик соңгы вакытта үзе тәхеткә күтәргән Йосыф балакай гына баш бирми башлады. Моның сәбәбен дә белә иде өлкән равва—Айбиби хатын гаепле. Шул бозды карусыз аны тыңлаган Йосыф баланы.

Кирәк бит, нәкъ аның турында уйлаганда Айбиби хатын күренде. Каханбикә өстендә ерак чиннардан китерелгән тукымадан тегелгән яшькелт төстәге атлас күлмәк. Башында алтын җепләр белән тукылган калфак кырын төшкән. Муенында өрфия яулык. Күлмәге су төсендә булгангамы, өлкән равва Айбиби хатынны судан чыгып килгән алиһәгә охшатты. Айбиби хатын өлкән грavvаны күрдеме, күрмичәме аккошларга җим ашата башлады. Ул су кырына бөтенләй якын килде һәм тәмам су төсенә керде. Акошлар аның кулыннан җим ала. Томшыкларын шыкылдаталар, кинәнәләр, су өстендә биеп алалар, гүя ашаткан өчен хатынга рәхмәт укыйлар иде. Кинәнде бугай Айбиби хатын.

Булат бәк калган хатыннарның барчасын да бүләкләр төяп, илләренә озатты. Ярый торган хәл идеме бу! Ичмасам кахан аның белән киңәшеп тә тормады. Бәхәссез, бу хәлгә өлкән равваның ачуы чыкты, тик һични кыла алмады. Ә бит Айбибине генә түгел, барча хатыннарны да Йосыф балакайга өлкән равва үзе тарттырган иде. Хәзер исә үзе үк әнә шул гүзәл затларны күралмый башлады. Бигрәк тә Айбибине...

Әллә соң шушы бала өчен Йосыфтан көнләшәме?.. Юк, тагын бер тапкыр юк. Айбибине сарайга тарттыргач, һәм шушы гүзәл затны Дала ханы улы Айдар кулыннан тартып алгач диярргә була, өлкән равва куанып бетә алмаган иде. Аннары шушы баланы тәрбияләп үстергән Рәшидә абыстай белән таныште. Яшерми, ошады ана абыстай. Тик ул ана бик акыллы күренде. Ә бит борынгылар: "Акыллы акыллыны яратмас", дигәннәр. Әллә соң яһүдләр үз-

ләре кебек бик борынгы тарихлы халыкка тап булдылармы?.. Исраил балалары төрки кавемнәр тарафыннан йотылырга дучар ителделәрме?.. Китапта: “Чит-ят җирләргә киткән халык, җирле халык арасында көн күрә-күрә башта телен, аннары җырын онытыр”,—диелгән ич. Бер дә гаҗәп түгел, андый хәлләр дә булгалап тора. Бу хакта да яхшы хәбәрдар иде өлкән равва.

Өлкән равва Ибраһим аяк астындагы җир сулышын ишетергә теләп, аякларына карады. Күп кенә кешеләр бәхетне күктән көтә, бактың исә, адәм баласы тулы бәхетне җирдән, туган туфрактан ала икән ич! Ул, ниһаять, һичнигә карамый ил дилбегәсен үз кулына алырга тиеш. Ул болай да Тәүрәт кануннарын бозуга таба бара. Үзе сайлаган Йосыф каханны ефәк бау көтә. Һәм ул моны үзе кылыр, үзе!

Тик кай чорда яши ул, кай илдә?! Сугышчан төркиләр арасында түгелме? Тәвәккәл, батыр, кыю халык, иң гаҗәбе, туган туфрагын саклап, кан коюны бәхеткә саный. Моның өстенә күпләре мөселманнар, кара гарәпләргә диннәре аша бәйле халык. Ахыр килеп, биредәге яһүдләр тулы канлы Исраил балаларымы? Бармы, калдымы тулы канлы яһүдләр Хазарстанда! Күпме яһүдә кызлары төрки бәкләренә ябышып кияүгә чыкты, күпмеләре бабаларын искә дә алмый башлады. Юк, елга агышын кинәт кенә борып җибәрү мөмкин булмаган кебек, халыкны да тиз генә үзгәртеп булмый икән. Хазарстанда әле кан кушу дәвам итә һәм бу гамәлнең башында өлкән равва үзе тора!.. Тик бит кул кушырып утыру да бернинди нәтиҗә бирмәячәк. Хак, моны да яхшы аңлый иде өлкән равва Ибраһим.

Шушындый фәлсәфи уйларга чумып торган өлкән равва кырына Айбиби хатын килеп басты.

—Саумысез, өлкән равва! Нинди уйларга баттыгыз? Икенче тапкыр дәшәм бит инде үзегезгә.

Өлкән равва башын иеп кенә исәнләште. Айбиби хатынга текәлебрәк карады. Тәмам алиһә иде хатын. Бирсә бирер икән Хода адәм баласына гүзәллекне. Аның күзләренә карап торган хатын тыенкы гына елмая иде. Хәтта сәер итеп елмаюында да ниндидер сихрилек күрде өлкән равва. Әллә соң әнә шул елмаюындамы бу хатынның мәхәббәте? Шул елмаюы белән Йосыф каханны әсир иттеме?

Өлкән равва дәшмәгәч, Айбиби хатын өрфия яулыгы белән авызын каплады. Зәңгәр күзләре генә калгач, хатын тагын да гүзәлләнеп киткәндәй булды. Хатынның бу карашында сихри шигырь юлларыдай гүзәллек тулып ята иде. Аккошлар култыгына сарай җарияләре төште, бераз шаулашалар иде, әмма өлкән равва белән Айбиби хатынны күрделәр дә шым булдылар. Алар артыннан төшә килгән мөгаллимә абыстай кыл тарта, шунда ук кубыз зеңләп куйды.

—Сарайга таба кузгалыйк, Айбиби хатын. Минем сезгә сүзем бар,—диде, ниһаять, өлкән равва һәм үзе алдан кузгалды. Өлкән равва каршына таба җария атлый, юри янбашларын уйната булса кирәк. Өрфә ыштаны биленнән дә узмаган, мул җиңле күлмәк дигәне дә кендеккә җитми туктаган. Җария шундаен сыгылмалы сынлы, зифа буйлы иде ки, озын муеныңдагы алсу шарфы сүтелеп, кош булып очып китәр сыман. Биюче җария, янбаш белән биюче, җәннәт алиһәсе. Һәрхәлдә, өлкән равва Ибраһимга шулай тоелды. Җария аның кырыннан үтеп китте, өлкән равва хәтта аның сулышын, битенә сарылып киткән тән җилен тойды. Кайда йөри ул, әллә соң чынлап та җәннәттәме?..

—Өлкән равва, өлкән равва,—диде Айбиби хатын.—Мин сезгә өченче тапкыр дәшәм инде, ә сез барасыз да барасыз. Теге каракош Аккошлар култыгыннан китми дә башлады.

—Ике аккошның башына җитте инде ул, мәлгун, кай арада ташлана да, кай арада кошның күкрәген яра, кай арада ботарлый, Йосыф углан укчылар да куйган булды инде. Хак, берсен укка алдылар. Ләкин җирдә явызлык бетәме,—диде өлкән равва барыр җайда башка берәүгә җавап биргәндәй.

Өлкән равва туктады, борылып, каракош утырган агачка карады һәм

уйлап куйды: “Ә бит бу каракошның илгә яман хәбәр китерүе дә бар. Әйтик, бик ихтимал, ул Йосыф кахан язмышы артыннан килгәндер,—диде эченнән генә һәм янә сарайга таба кузгалды.—Ләкин Йосыф кахан ошбу дөньядан китү белән генә Хазарстан яшәүдән туктамас. Яшәү дәвам итәр, ә менә син, гүзәл хатын, иреңнән мәхрүм калырсың”,—дип, артыннан килгән Айбибигә әйләнеп карады өлкән равва. Мәгәр уйлаган уен Айбиби хатынның күзенә бәреп әйтергә кыймады. «Ил башына үлем килсә, гаепне хатын-кыздан эзлә»,—дигән борынгылар. Ә бит тарихта мисаллары да күп булган. Әйтик, Бөек Искәндәр фарсыларны җингәч, аның каршына бер бите ай, бер бите кояш булган гүзәлне китереп бастыралар. Искәндәр күрә дә сылу затны, гашыйк була. Ул хәтта урыныннан кубып, чынмы бу, күктән төшкән алиһә түгелме дип, кызның беләгеннән тотып карый. Ләкин шунда кызны китерүче әйтә: “Дарий шаһиншаһның кызын китердем сезгә, галиҗанәбем. Нә кылыйм, сезнең чатырда калдырыйкмы, сатып җибәрикме?”

Шаһиншаһ үз каршындагы гүзәлнең Дарий кызы икәнне белгәч, Бөек Искәндәр үзенең кем икәнен раслау өчен кире урынына утыра һәм әйтә: “Мин фарсыларның ирләрен җиңдем, килешмәс миңа аның кызыннан җинелү”. Тик шулай булдымы икән, грек халкы Искәндәрнең данын тарихларга калдыру өчен кеше ышанмастай ялганнарга барган. Бу хакта да яхшы белә иде өлкән равва. Чынында исә, Бөек Искәндәр Дарий шаһиншаһның гүзәл кызын үзе белән йөртә, ахыр аны яһүд сәүдәгәренә сатып җибәрә. Менә бусы хактыр, чөнки бу хакта Исраил балалары тарихларында искәртелә. Әйе, Искәндәр даны еракларга таралган фарсыларны җиңә, ләкин Дарий шаһиншаһның гүзәл кызын түгел. Безнең Йосыф балакай да шул сукмакка төшеп бармыйммы?.. Чик, чик куярга кирәк моңа!

Янә тарихтан бер мисал. Фарсылар шаһиншаһы Баһрамның беренче хатыныннан туган улы, атасының яшь хатынына кызыга. Бит бу хәл булмый. Ләкин мәкер тулы хатын шаһиншаһына: “Синең улың мине ятагына дәште”,—дип әйтә. Ялган хәбәр. Эш киресенчә була, хатын үзе яшь егеткә тәкъдим итә: “Мине ятагына алмасаң, атаңа җиткерәчәкмен”, ди. Әйе, яный. Ләкин саф күңелле яшь кеше бу хыянәткә бармый. Шаһиншаһ вәзирен дәшеп ала һәм улын зинданга ташларга боера. Әмма улы бу хәлне белеп ала һәм төрки тураннарга кача. Сөмбел атлы була егет. Туран ханы егетне бик теләп кабул итә һәм сараенда яшәргә рөхсәт бирә. Улының качып китүен ишетүгә, шаһиншаһ аны үтерергә ике җәлладын җибәрә. Һәм алар илче йөзендә Туран ханы сараена үтеп керәләр дә Сөмбелне бакчага дәшеп алалар. Икенче көнне генә бер гаепсез угланны йөрәгенә хәнҗәр кадалган килеш хан бакчасында табалар. Бу үлемдә дә хатын-кыз гаепле була ич!

Безнең хәлдә дә Йосыфның үлемен бу гүзәл хатынга тагып булыр иде, ләкин өлкән равва моңа бармас. Чөнки ефәк бау белән каханнарны буып үтерү күптән инде гадәткә кергән. Шуның өчен яһүдләрнең аталарының аталары Давыт пәйгамбәр хатын-кыз турында болай дигән: “Хатының сүзен тыңлап, теге йә бу ил түрәсе кул астындагы кешеләрне илдән куарга яки җәза бирергә җыенса, ул затлы вә зыялы ир-ат буларак, киресен эшләргә тиеш. Хатының сүзен тыңлап гамәлләр кыла башласаң, кылган гамәлләрең беркайчан да синең файдаңа булмас”. Хатыны Өлкән раввага хыянәт иткәч, ул да ни кылырга белми чарасыз калган иде.

Өлкән равва тирә-ягына карады, ул арада Айбиби хатын каядыр китеп барган иде инде. “Китә бир”,—диде ул битараф бер рәвештә, чөнки аның бу хатын белән бер дә сөйләшәсе килми, ә менә Рәшидә абыстай белән әңгәмә корып утырасы килә иде. Акыллы хатын, җитмәсә, бар нәрсәдән дә хәбәрдар.

Өлкән равва йөзмә күпергә чыга торган ишекләргә якынайды, әмма күпер тирәсендә шау-шу ишетеп, туктап калды. Йөзмә күпер аша баһадир яугире Карун һәм аның ишләре белән Йосыф кахан кайтып килә иде. Ана сарай сакчылары урра кычкыралар, хәтта кемдер быргы тавышы чыгарды.

Йосыф кахан ап-ак атта, башындагы алтын төсендәге очлымы кояшта ялтйолт итә. Сарай баскычына житкәч, кахан атыннан төште, биленә таккан кылычын сул кулы белән тота төшеп, ашыга-ашыга менә башлады. Өлкән равва аның каршысына чыгасы итте, әмма икенче мәлдә ишек артына посты. Бары тик кахан үтеп киткәч кенә, өлкән равва ишек артыннан чыкты һәм һични булмаган кебек, сакчыларга күз дә ташламый, әкрен генә баскычлардан түбән төшә башлады. Ул күрде, Йосыф кахан төп гаскәрен Далада калдырып, Карун атаман яугирләре белән генә кайткан, ашыккан. Кем янына?.. Әлбәттә инде Айбиби хатын янына. Өлкән равва белән барысы да сәламләшәләр, димәк, өлкән равва әле үз көчендә. Ул ышана иде, Йосыф каханнан котылгач, аны тагы да хөрмәт итә башларлар. Өлкән равва корал амбарлары тарафына таба атлады. Амбарлар яр астында, сарайдан читтәрәк салынган иде. Тар сукмактан түбән таба төште һәм шунда аның каршында сәер бер карт пәйда булды.

—Сәлам юллый сина Исраил баласы Ибраһим.

—Сәлам, картлач. Кем син?

—Мосафир мин, мосафир, Исраил баласы Ибраһим.

—Йомышың әйт, дөнья мосафире.

—Саул мин, Саул. Чит илләрдән юл тотам, сиңа, ил руханиена. Йосыф каханга ерак Андалусиядән хат китердем. Хөрмәткә ия кардәшебез Әл-Шафрук жибәрде. Ләкин мин әүвәл сине күрергә теләдем. Миңа сәүдәгәрләрең ирештерде, Йосыф балакайга ефәк бау салырга жыенасыз икән.

—Юк сүз. Кеше сүзе кеше үтерер, диләр.

—Әл-Шафрут сине кисәтә, өлкән равва Ибраһим, Йосыф балакайга хыянәт итсәң Яхвабыз сине мәнге кичермәс. Яхва аны үз канаты астында саклый. Тәүрәткә тугры булган халкыбызны барча илләрдән куганда да Йосыф углан Исраил балаларын үз кырына жыйды, сугышчан төркиләр белән уртак тел тапты. Ә син, өлкән равва Ибраһим, дөньяга сибелгән яһүдләрне туган туфрагыбызга жыю урынына, кулыңа ефәк бау алырга торасың. Син, Исраил баласы вә рухание буларак, үзең яшәгән халыкны күккә күтәреп мактамасаң да, тату яшәргә өндә. Киресен кылганда сәнең иленә дә Яхва каһәре төшәчәк, син аны дошман йөзендә котмә, Аллаһы Тәгаләнең кодрәте зур, ул синең гөнаһлы башыңа каһәр жибәрү өчен башка юлларын да табар. Менә сиңа Давыт пәйгамбәр Исраил балаларына биреп калдырган Тәүрәт. Ал-ал, курыкма!

Сәер карт Ибраһимны, гүя сихерләде—баш түбәсенә ак чәпләшкә каплаган, бит-йөзен сакал-мыек баскан картның кулыннан тышы ялтырап беткән китапны алды һәм кинәт нииндидер авырлык тоеп, тезенә чүкте. Ул башын күтәргәндә аның каршындагы серле карт юкка чыккан иде инде. Өлкән равва: "Жир уптымы әллә үзен?" дип як-ягына каранды. Ләкин берәү дә аның кырында юк иде. Кулындагы китапны ачты, шулчак аның йөзенә яшен чаткысыдай куе яктылык бәрде. Өлкән равва күзләрен йомды, бөтен тәне буйлап тетрәнү узуын тоеп, китапны кире япты. Һәм янә кинәттән гаеп булган мосафирны эзләде. Тәмам чарасыз калды, якындагы ташка утырды да дога кылды һәм куллары калтыравын тоеп, Яхвасына мөрәжәгать итте: "Син Исраил балалары өчен генә түгел, син дөнья халкы өчен дә бердәнбер һәм мәңгелек!"

## XII

Каласына кайтып, гүзәл хатыны янында бер төн уздыргач кына Йосыф кахан тәхет ягына чыгып, кылган гамәлләренә, үз-үзенә хисап бирергә керешге. Яу чыгып дөрес эшләдеме ул? Жавабы бер булды—дөрес эшләде. Шөкер, барысы да әйбәт булды. Сарманай каханны да акылга утыртты, дөресрәге, юк иттерде. Башбаштак вә үтә явыз каханның язмышы нәкъ ул уйлаганча бетте. Хак, Түрә хан кулына мул итеп алтын салды һәм ул Сарманай каханны Киялигә кайтармаска вәгъдә итте. Һәм кайтармады да.

Әле булса хәтерендә, күчмә төркиләрнең юлдашы булган, талгын жилгә

дә баш иярга торган кылганнарны куып барганда, башына төрле уйлар килгән иде. Ниятенә ирешерме? Әмма шымчыларына рәхмәт, барысын да житкереп тордылар. Шул ук шымчылары ниндидер юллар белән Византия императоры Никифор Фокены тәхеттән азат итәргә ирештеләр. Яшь сәргаскәр Иоанн Цимисхий ихтирамга лаек мәрхүм Константинның кызына өйләнә һәм: "Илгә хыянәт иттен!"—дип, Никифорны үтерә. Йосыф каханның шымчылары котыртуы буенча яшь император Дунай буе болгарларын туздырырга яу килгән Сарманай каханга каршы кузгала... Килә һәм Сарманай каханга шарт куя: "Император Никифор биргән унбиш кадак алтынны кире кайтар һәм яхшы чакта Дунай буе Болгарын ташлап кит!" Баскынчы варягның моңа җен ачулары чыга һәм ул яшь императорның илчеләренә болай дип җавап бирә: "Мин сине моннан куып кына калмам, патшакалаңа барып, Аурупа белән идарә итә башлармын. Орыш белән куркытырга мин сиңа бала-чагамы әллә!"

Сарманай кахан белән Византия императоры Иоанн Цимисхий арасында сугыш әнә шулай башланып китә. Ул арада Йосыф каханның каханбәге көчле атлы гаскәре белән Кырымга юнәлә—Кырым халкын талый, ары таба Киялигә таба кузгала.

Тик илгә кайтуга, аның кәефен кырдылар. Кемнендер котыртуы буенча, кара мәзиннәр Ханбалыктагы синогогларны җимергәннәр. Кайта-кайтуга Йосыф кахан кара мәзиннәрне тотарга һәм зинданга ташларга кушты. Мин алардан сорауны үзем алырмын, диде. Өлкән равва үзе күренмәде, ләкин кахан кырына ярдәмчесен җибәргән иде. Кара мәзиннәрне хөкем итүне үз кулына алырга теләгән, әмма Булат бәк аңа моны кылырга бирмәгән: "Кара мәзиннәрне үзем хөкем итәм", дип әйтеп әйтте Йосыф кахан дигән. Һәм Йосыф кахан аңа шулай дип җиткергән иде дә. Чөнки яудан кайткач, Йосыф кахан үзендә көч-куәт иңүен тойды һәм өлкән раввага баш бирмәскә, дигән фикергә килде. Бу хакта аңа кайта-кайтуга Айбиби хатын да искәртте. Хак, хатын сүзен ул колак яныннан гына уздырды, вә ләкин исеннән дә чыгармады. Чөнки беләсе килә иде: кем кушуы буенча кара мәзиннәр синогогларны җимергәннәр?.. Кара халык—кара сарык, бер генә мәзин дә моңа баш алып керешмәскә тиеш иде кебек. Мөселман халкына хас сыйфат түгел бу, һәрхәлдә Хазарстанда яшәгән мөселман халкына. Шуңа күрә өлкән равваның ярдәмчесенә: "Мин кара мәзиннәр хыянәтенә үч итеп, Ханбалыктагы мәчетләрне, чиркәүләрне җимерергә әмер бирмәм, миннән моны көтмәгез. Мин башта хыянәтнең асылына төшенермен",—диде.

Ахыр килеп, яудан кайтыр юлында ул бабасы Мөхәммәд ханны очратты. Идел буе ханы ике төмән белән Дунай буенда көн күргән кардәшләрен якларга кузгалган булган икән. Хәер, Йосыф кахан үзе дә бу хакта бабасына ирештергән иде. Әле дә булса күз алдында, бабасы белән алар Тын елгасы буенда очраштылар һәм яугирләренә ял бирделәр.

Йосыф кахан бабасын чатырына алып керде, кунак итте. Табынга утырып, берәр касә кымыз эчкәч, Йосыф кахан бабасына болай диде: "Мин шат, бик шат сине күрүгә, бабам. Без үз дигәнебезгә ирештек. Киялидә хәзер Якуб олан утыра, Иске урыста—Олег олан. Уйнаштан туган угланны Кияли аксакаллары Холмградка озатканнар. Без янә барысыннан да өстен булып калдык, бабам".

"Хазарстан үз куәтендә, кияү, үз куәтендә,—дигән иде бабасы. Һәм өстәде:—Сиңа янаучылар булыр, сак бул кияү..." Әмма кемнән сакланырга тиешлеген әйтмәде, алай да Йосыф кахан бераз чамалый иде—раввалардан, үзенең раввaларыннан.

Икенче көнне кояш чыгуга, Йосыф кахан бабасын озатып җибәрде, ә үзе ашыгыч төстә Башкаласына юнәлде. Бабасы күңеленә ниндидер шом салган иде.

Төрле диннәргә йөз тоткан халыклар яшәгән ил белән идарә итү җинел түгел иде Йосыф каханга. Гәрчә аны әүвәл башта айга ике-өч тапкыр гына халыкка чыгарып күрсәтсәләр дә, ул, тәхеткә килгәч, яһүд раввалары

китергән бу йола-гадәтне юкка чыгара башлады. Ә инде сарайга Айбиби хатын килгәч, раввaларны бөтенләй тыңламыйча—табыннарда үз фикерен уздырды. Раввaларның берише аның белән килеште, өлкән равва яклылары йөзләрен чытып утырды. Барысын да күрде Йосыф кахан, сукыр түгел иде. Ул күзәтә иде, соңгы елларда теге йә бу ил, җир өчен генә түгел, дин өчен сугыша башлады. Ил-җирне басып алып, яуланган халыкны үз диненә көчләп керткән яулаучылар ешаеп бара. Әйтик, кара гарәпләр үз диннәрен Хазарстан төркиләренә көчләп тагалар. Куәтле хәлиф сәргаскәре Мәрванда Идел буенда һәм Кавказ тарафларында көн күргән төркиләрне шулай итә. Ә бит дин кабул итү кешенең йөрәге аша узарга тиеш, кылыч белән янап түгел. Кая монда гаделлек!

Йосыф кахан бетекчесен дәштерде. Бетекчесе кереп, кечкенә өстәл янына бөкләнеп утыргач, каурый каләмен чәченә тигезеп алды да Йосыф каханга карады.

—Яз! Яз, сәне...

Шулчак ишектә Ханбалык имамы күренде. Яшел чалмалы имамны күргәч, Йосыф кахан бетекчесенә чыгып торырга кушты.

—Исән-имин яудан кайттыгызмы, Йосыф балакай!

—Шөкер кылам, имам хәзрәтләре, шөкер кылам. Тик бит мина кайта-кайтуга яман хәбәр иреште. Кара мәзиннәр кардәш яһүдләрегезнең храмын җимергәннәр.

—Каһәр аларга, Йосыф балакай, каһәр!

—Мин аларны зинданга ташлаттым. Соңрак хөкем итәрмен.

—Кахан хәзрәтләре, каханатның куәте бердәмлектә, татулыкта, дустанәлектә, мәрхәмәтлелектә, кулга-кул тотынып яшәүдә. Мәзиннәр гафиллек кылганнар. Өлкән равва Ибраһим да сезнең карар-фәрман белән килешкән икән.

—Килеште, килешми кая барсын,—диде Йосыф кахан һәм тәхеткә аркасын терәбрәк утырды.—Мин ил-халкым исән-имин һәм житешле яшәсен дип, ерак җирләргә яу йөреп кайттым, ә монда мәнсез мәзиннәр яһүд туганнарының изге йортларын җимереп ята. Мин моның өчен аларны зур мәйданга чыгарып, бөтен кала халкы алдында дар агачына астырырга тиеш идем. Шулаймы, имам хәзрәтләре?! Кыргый гамәл бу, борынгы римләннәргә хас гамәл. Мин Ханбалыктагы мәчетләрне дә җимертә ала идем, ләкин явызлык—явызлыкка китерер дип моңа бармадым. Әмма кара мәзиннәргә җәза яман булыр, имам хәзрәтләре.

Йосыф кахан шуның белән сүзем бетте дигән сыман, кул селтәде, бу инде чыгып кит дигәнне аңлата иде.

Имам хәзрәтләре артыннан ишек ябылуга, тәхет ягына Айбиби хатын килеп керде.

—Каханым Йосыфҗан. Аккошлар култыгында бер аккошны каракош ботарлаган, түшен ярган да...

—Укчылар ни караган!

—Бичара аккош бөтенләй минем кулга өйрәнеп беткән иде.

— Йә-йә, бала-чага булма, Айбиби җан. Аккош адәм баласы түгел, мин адәм балаларын да хөкем итәргә жыенам әле.

Айбиби каядыр укыган иде: «Ир куәте тау-таш актарыр», дигән сүзләрне. Йосыф кахан шулай диюгә, Айбиби кинәт кенә тынычлана калды, гәрчә вакыт-вакыт кошлар кебек туган якларына очып китәсе килсә дә, ир кырында һәрчак тынычланыр, сихри көчкә ия булган ошбу кеше янында үзе дә батыраеп китәр иде. Ул арада аш ягына килеп керделәр, Йосыф кахан табында утырганнарга, Айбиби хатынның кулыннан тоткан килеш түргә узды. Утырыштылар, дога кылдылар.

Йосыф кахан утыра-утыруга үзе аш башларга тиеш иде, әмма хөрмәт йөзеннән, нәкъ китап кушканча, өлкәннәргә мөрәҗәгать итте.

—Ризыктан рәхим итик, өлкәннәр.

Раввaларның да, имамнарның да бер табында утырулары начар түгел иде, тик күңелдә нindидер кимсену хисе бар. Бит теләп кабул итмәде ул

Харәзем имамнарын, теләп кабул итмәде. Ни хикмәт, үзе әкрен генә тукланды, үзе борынгы бабалары турында уйлады. Сигезенче гасырда бабалары Булан яһүд равваларыннан яңа исем ала—Сабраилә. Булан каханның нә ислам, нә христиан диннәрен кабул итәсе килми, аның бу диннәргә кагылмый гына үзенә бер дине булган дәүләт төзисе килә һәм яһүдләр динендә туктала. Чөнки табында инде Ираннан, Византиядән куылган раввалар утыра, алар арасында Ефәк юлында йөргән исемле сәүдәгәрләр дә бар. Ә алар акчалы халык, акчалы гына түгел, канкардәшләре аша бөтен илләр белән элемтәдә торалар, Ефәк юлы да алар кулында. Һәм Хазарстан куәтләнеп киткәч, бу хәл шулай була да. Ары таба Хазарстан тәхетендә Үбәдәй, Хиския, Манасси, Нисси, Минегем, Веньямин, Шарон-Булан утырып ала. Ниһаять, тәхеткә Йосыф углан килә. Аны да раввалар сайлый—бар ягын да искә алып: бабалары яһүд булсын, аналары турында әйтеп тә торасы юк, гәрчә төп чыгышлары төрки булса да. Хак, төрки халыклары аларны беркайчан да яһүд исемнәре белән атамадылар, исемнәрен үз телләренә җайлап, үзләренчә дәштеләр һәм яздылар.

Тарихта шунысы билгеле: милади белән 737 елда гарәпләрнең сәргаскәре Мәрван Тимер Капка аша узып, зур югалтулар белән Хазарстан каханын җинә, башкаласын ала, гаиләсен, туганнарын әсир итә. Кахан Далага качарга мәҗбүр була. Хәйләкәр сәргаскәр дала халкын җинә алмавын аңлап, каханга илчеләрен җибәрә, ә илчеләр Хазарстан каханына сәргаскәрнең шартын куялар: “Ислам динен кабул ит! Кабул иткән хәлдә мин сиңа иленҗирең, башкалаң гына түгел, гаиләңне дә кайтарып бирәм!” Кахан риза була. Әмма күп тә үтми, янә яһүдләр диненә кайта. Менә Хазарстан янә бер тапкыр ислам динен кабул итәргә мәҗбүр ителде. Ләкин бу озакка барырмы? Бармас. Раввалар сарайга кереп оялаган имамнарга тешләрен кайрый, моның өстенә хәйләкәр раввалар кара мәзиннәргә бик күп акча түләп, яһүдләрнең синогогларын җимертәләр. Имамнарның хыянәтеме бу, әллә соң равваларның астыртын сәясәтеме?! Йосыф кахан шуның асылына төшенергә тели иде. Бәхәссез, өлкән равва үз равваларын гына түгел, яһүдләр яклы сарай куштаннарын да каханга каршы котыртып ята. Моны эчке бер сиземләү белән тоеп йөри иде Йосыф. Бәлкем әле ефәк бауны да кулланырга телидер. Элек баш бирмәгән каханнардан раввалар Ефәк бау аша котылганнар бит. Чөнки сарай гына түгел, хәтта тәхет тә раввалар кулында. Ә башлап йөрүчеләр хәрам атакайлар булачак. Бу хакта да яхшы белә иде Йосыф кахан. Инде нишләргә тиеш ул?.. Әллә соң башлап үзе һөҗүмгә күчсенме?.. Әйтик, иң әүвәл имамнарны сарайдан илләренә кудыртыр. Һәйбәтләп, кунакка озаткан кебек, олылап хәтта?.. Аннары ил язмышын да, тәхет язмышын да, үз язмышын да җайга салыр...

## XIII

Иртәгә Далага чыгасылары турында Йосыф кахан хатыны Айбибидән башка беркемгә дә әйтмәде. Бу аның яудан кайтканнан соң дөньяви агышка үзгә карашы иде. Яманлыкка да, изгелеккә дә ул тәҗрибәне раввалардан туплады. Хәзер һәр кылган һәм кыласы гамәлен үзбаш эшләде, теге йә бу әмер-фәрманын чыгарганда Айбиби хатын белән дә киңәшеп алгалады. Фикер уртаклыклары тәңгәл килгәндә алар икесе дә киңәнделәр һәм бербәрсенә тагын да якыная төштеләр. Хатыннарын илләренә кайтарып җибәргәч, Йосыф кахан күп вакытын эшкә бирде. Дәүләт даирәсендә эшләгән кешеләргә игътибарлырак булырга тырышты, һәрхәлдә, үзен мөстәкыйль илбашы итеп күрсәтте. Йосыф кахандагы бу үзгәрешне күреп-күзәтеп торган өлкән равва ни кылырга белми гасага сабышты. Әүвәл ул Айбиби хатын белән сөйләшергә булды, әмма хатынның булган әңгәмәне көне белән каханга житкерүе бар иде, моның өстенә каханбикә йөкле, соңгы көннәрен чүпләп ята. Сөйләшү килеп чыкмаса, хатынны юкка борчырмын, хатынга ул-бу була калса, Йосыф аны кичермәс дип уйлады. Бу инде өлкән равва өчен көтелмәгән яңалык иде. Әйе, курка башлады түгелме үзе тәхеткә утырткан баладан?..

Алай да тәвәккәлләде, көннәрдән бер көнне туп-туры Йосыф кахан утырган тәхет ягына килеп керде. Керде, сәлам юллады һәм, гадәттәгечә, каханның уң ягындагы түмәргә килеп утырды. Бик озак дәшми торды, аралары суынып бара ич, ничекләр беренче булып сүз катсын.

—Йә, атакай, нә йомыш?—диде ана Йосыф кахан, башын чөя төшеп.

—Кхм, Йосыф балакай, сиңа сөенеч китердем әле, ә син иртәгә Далага чыгарга җыенасың икән. Кхм, әйе, йончыгып китмәгәе дим, киленне әйтәм.

—Өлкән равва, Далага чыгу минем эш, сөенечен әйт.

—Сөенеч,—дип башын күтәрде һәм Йосыф каханның күзләренә карады өлкән равва.—Әйе шул, сөенеч шул, Йосыф кахан, Иделнең өске ягыннан викинглар төшеп килә. Тиздән Аккалада булырлар. Шул хакта әйтергә дип кергән идем.

Йосыф кахан тәхет терәгенә аркасын турайтыбрак утырды.

—Минем өчен яман сөенеч бу, өлкән раввам. Викингларны мин чакырмадым, син чакырттың. Үзең каршы ал, үзең хәл дә ит.

—Мин Харальд корольгә ышанычлы сәүдәгәремне сәнең белән киңәшеп җибәргән идем кебек, Йосыф балакай...

—Нигә безгә ул сугыш чукмарлары, атакай?!

—Викингларны элек тә яллаганнар. Көчле, кодрәтле, куәтле халык. Вениамин кахан үз вакытында викинглар ярдәме белән кара гарәпләр явыннан котыла, хазар диңгезенә чыгарып, мөселманнарның калаларын талатып, Ефәк юлын тагы да ныгыта. Безгә бүген Харәзем әмире үз динен тага башлады. Викинглар аркасында Харәзем әмиреннән дә котылырбыз. Харальд король ышандырган, таланган малның яртысын сездә калдырырмын дигән. Викингларны Харальд корольның энесе Гудред җитәкли икән.

—Харальд Соры Тире турында минем дә сәүдәгәрләрдән ишеткәнем бар, атакай. Ләкин мин ул баскынчыларга ышанып җитмим.

—Ышанырга туры килер, балакай. Мөстәкыйль һәм бәйсез ил белән идарә итәм дисәң, ышанырга туры килер.

—Баскынчы викингларга таянып, төрки туганнарыбызга бау салыйкмы, атакай? Ни күрсәк ил белән күрербез, ләкин викингларны диңгезгә уздырмаска кирәк.

—Ул викинг дигәннәреннән, балакай, Казан каласында гаилә корып калганнары да бар.

—Туфрак чакыра кешене, атакай, кендек каны тамган туфрак.

—Нинди туфрак та, нинди кан, балакай...

—Дөнья явызлык белән тулды. Соңгы елларда гына күпме халыкны кузгаттылар, күпме халык яңа җирләргә куылды, күчеп утырырга мәҗбүр булды. Шул исәптән безнең бабаларыбыз да.

Өлкән равва үзе сабак биреп үстергән Йосыф каханга гаҗәпләнү катыш аптырап карап алды. Ә бит кахан хак әйтә. Тик ни чара кылмак кирәк, Яхвабыз безне шулай йөрткәч.

—Йөкле Айбиби хатынны Далага алып чыгасыңмы?

—Алып чыгам, атакай. Дала һавасын сулап кайтырбыз.

—Миңа яңалык артыннан яңалык ирешеп тора, Йосыф балакай.

—Нинди яңалык?

—Кияли тәхетенә ике туганын үтереп колбикә Малушадан туган Ульдәмир утырган икән. Кырында баскынчы варяглар ди. Сәүдәгәрләрем житкерделәр. Ульдәмир мин кахан дип күкрәк кага икән.

—Утыра бирсен, ясагын гына түләсен.

—Кул астында яманнан да яман варяг дип аталган сугышчылар, ди, җибәрмәс ул безгә ясакны, атасы да баш тартып ята иде инде.

Йосыф кахан дәшмәде. Аның беркем белән дә сугышасы килми иде. Кияли каханы Ульдәмир аның тарафына килгән хәлдә ул аңа каршы чыгар, әмма үзе ул тарафларга бармас.

—Викингларны безгә барыбер каршы алырга туры килер, балакай.

Йосыф кахан янә дәшмәде, аның инде ары таба өлкән равва белән сөйләшәсе килми, моны өлкән равва да сизеп алды һәм әкрен генә ишеккә

таба юнәлде. Йосыф кахан аның бөкрәя төшкән аркасына карап калды. Иртәгә ул Далага чыгачак, шунда саф дала һавасында барысы турында да уйланыр һәм нинди дер бер нәтиҗәгә килер. Шул мәлдә, ни сәбәпледер, Йосыф каханның күз алдына Айбибинең апасы Айгөл килде. Мөхәммәд ханның тәүге кызын да яраткан иде ул. Әмма бала тапкач, ул, нигәдер, Айгөл янына кермәде. Килене янында анасы Сара утыра, хатын ир бала тапкач, шатлыктан Айгөл янына улын чакыртты. Анасы чакырткач, алай да Йосыф бала тапкан хатын янына керде, әмма хатын җан тәслим кылган иде инде. Бу хакта белгәч, Йосыф борылды да чыгып китте, хәтта анасы кулындагы балага да карамады. Соңыннан, тәхет ягына чыгып утыргач, йөрәге чәнчеп куйган иде. Чөнки бу хатынга ул: "Бәби тапканда янында булырмын",—дип вәгъдә иткән иде. Вәгъдәсендә тора алмады. Хәер, ул вакытларда шул ук өлкән равва барча бала тапкан хатыннарны илләренә озата торды, ә кахан титулын йөрткән Йосыф гүя аның кулында курчак иде, хәтта нишлим дип, киңәшеп тә тормады. Менә ни өчен аның өлкән раввага карата фикере үзгәрде, эрактан килә икән ич бу рәнҗү, хәтта бала чактан ук. Анасы да икенче көнне үк исән калган баланы алды да Тамантархан төбәгенә китеп барды. Соңыннан гына белде, кинәт кенә китеп баруының сәбәбе—янә шул өлкән равва Ибраһимда булган икән. Ул һичкемгә әйтми анасының кулын сораган, кахан хатынына өйләнәсе иткән, ә анасы Сара аның белән сөйләшергә дә теләмәгән.

Тик Айбиби белән инде ул тәүге хатаны кылмас. Айбиби хатын да аңа исән-имин ир бала тапса, сәясәттән тагын да ерагая төшәр. Сәясәттән ерагаер, ләкин ил белән идарә итүне үз кулына алыр. Ниһаять, ул үзенең кем икәнен күрсәтергә тиеш. Бүген үк! Юк, иртәгәдән. Һичкемгә әйтми Айбиби хатынын һәм хезмәтчеләрен алыр да Далага чыгып китәр. Каханбәге Сабирны дәшәр. Озатсын, күз-колак булсын...

Иртән-иртүк ашап-эчкәч, Далага чыгарга җыена башладылар. Хәер, каханбәк Сабир барысын да әзерләп куйган иде инде, Айбиби хатын батырланып атка атланырга иткән иде, Рәшидә абыстай бирмәде, каханбәк Сабир да киңәш итмәде. Имеш, килешми йөкле хатынга атка атланып йөрү.

—Ә бит безнең әбиләребез бәбиләрен ат өстендә тапканнар,—дип әтәчләнеп карады Айбиби. Ләкин аңа ары таба авыз ачарга ирек бирмәделәр, бигрәк тә Рәшидә абыстай белән кендек әбисе. Киңәштеләр-киңәштеләр дә Айбибине сиртмәле арбага утыртырга булдылар, Йосыф кахан арба белән янәшә ат өстендә барыр, диделәр.

Йосыф кахан берсе белән дә сүз көрәштермәде, ул барысы белән дә килеште, бары тик Айбибинең нурлы йөзен күреп, елмайды гына.

Күк йөзе аяз, Далада тыныч иде. Сәер төбәккә утырган иде Ханбалык. Каладан чыгып, капканы узуга ук дала башлана. Ары-бире йомраннар йөгерешә, ул арада өннәренә җитүгә, тырпаеп басалар да әче итеп сызгыралар. Эремнән-эремгә кунып уткойрыклар күченә. Алар шулай без куркыткан бөҗәкләрне тоталар, диде аңа янәшәсендә утырган Рәшидә абыстай. Айбибинең күз карашы әле офык читенә юнәлә, әле ир-канаты Йосыфка күчә. Шул ук вакытта карынындагы баланың тибешүен тоеп, үзалдына елмаеп куя. Әллә соң ул да сизәме Даланы, бабаларыбыз даласын?.. Сабыр-сабыр ит, балакаем. Мин сине тиздән табармын, боерган итсә, Даладан кайткач та күп тә үтми син дә якты дөньяга чыгарсың һәм атаң сине кулына алыр да Тәңребезгә күрсәтер. Шулай иткәннәр борынгы бабаларыбыз, дип уйланып барды Айбиби.

Инеш буендагы бик матур болынга тукталдылар. Хезмәтчеләр казан асып җибәрде, ирләр сарыкларны чалдылар. Күп тә үтми казаннар кайнап чыкты, далага ит исе таралды. Йосыф кахан Айбибине култыклады да инешкә таба алып китте. Ир-канаты әле аның калкып торган корсагына кагылып ала, әле аркасыннан сыйпый, әле туктап күзләренә карый. Карый да нәүмизләнеп сорап куя:

—Куркасыңмы, бәгырь?

—Янымда син булганда мин бернидән дә курыкмыйм, Йосыф җаным.

Йосыф кахан хатынның чинаяктай ак битенә кагылып ала, биленнән кочмакчы итә, әмма кулы җитми, шуңа икесе дә көлешеп алалар.

—Без икәү шул инде, икәү, әтисе.

Шулчак нидер була, Айбиби «аh!» диде дә җиргә таба иелә башлады.

—Йосыф җаным, мин үземә күз тигердем, күз,—дип, тәмам хәле китеп иренең кулына ябышты. Курка калган Йосыф хатынны кулына күтәреп, корылып беткән чатырга таба кузгалды һәм кычкырды:

—Сабир каханбәк, Сабир каханбәгем, егетләрең җибәр, егетләрең!..

Ул арада таза ике егет килеп җитә, кахан кулыннан аh-ух килгән хатынны күтәреп алдылар да чатырга таба йөгерделәр. Йосыф кахан аларга иярде, ләкин чатыр каршында егетләр кулыннан эчкәре алып кереп киткән хатын янына аны уздырмадылар.

—Кендек әбисе кая, кендек әбисе!—дип чарасыз калгандай арлы-бирле йөрде Йосыф кахан.

Чатыр япмасын ачып Рәшидә абыстай чыкты.

—Кендек әбисе дә, мин дә монда кияү, сабыр ит, барысы да, иншалла, әйбәт булыр.

Йосыф каханга сабырлык килмәде, ул чатыр тирәли йөрергә кереште: бер әйләнә, ике, өч—санын онытты. Ә чатыр эченнән килгән үзәк өзгеч һәр тавыш йөрәгенә ук булып кадалды. Ниһаять, чатыр япмасын ачып, Рәшидә абыстай чыкты, Йосыф каханны чакырып, эчкәре уздырды. Яктыда кергәнгәме, Йосыф каханның күзләре күрмәс булды, әмма түрдә яткан Айбибине шәйләде, ул да түгел, кендек әбисе кулындагы нарасыйга күзе төште.

—Менә кара улыңның ирлек горурлыгын, Айбибиең малай тапты, Йосыф кахан, малай!

Йосыф кахан баланы тоткан кендек әбигә якын ук килде, нарасыйга кулын сузды, бала шундук аның бармагын эләктереп алды һәм, һәрхәлдә аңа шулай тоелды, шундаен иттереп бармагын кысты ки, Йосыф кахан: "Зур үскән, зур!" дип әйткәнен сизми дә калды. Аннары Айбиби янына килде, хәлсезләнеп калган хатынның битенә кулын куйды, һәм: "Нык бул, нык бул!"—диде.

Чатырдан чыккач, ул бар көченә кычкырып җибәрде:

—Сабир каханбәк, Сабир каханбәк, Айбиби хатын миңа малай тапты, малай!

Һәммәсе дә: хезмәтчеләр дә, пешекчеләр дә, гаскәриләр дә "Урра!" кычкырдылар, хәтта бу тавышка әлегә кадәр йокымсырап торган Дала уянып киткәндәй булды. Ул арада кымызчыларның берсе Йосыф кахан кулына кымыз тулы касә тоттырды. Илбашы касәне күтәреп эчеп җибәрде дә савытны болынга таба атты. Касә артыннан яшь-җилбәзәк кенә түгел, олысы-кечесе дә ташландылар, чөнки беләләр иде—кахан касәне китергән кешене буш итмәячәк, кимендә дирбияле алмачуар атын бирәчәк.

Ул арада Йосыф кахан янә чатырга әйләнеп керде, шыншый башлаган баланы кулына алды, сабый еларга җыенып, йөзен чытты.

—Еласын, еласын, кияү, күз яше сулышны ача, йөрәкне йомшарта,—диде Рәшидә абыстай.

Сарайга кайткач, хезмәтче хатыннар арасында сөйләшү булып алды.

—Айбибие малай тапкач, каханыбыз әллә күз яше белән елады инде.

—Хатыным югалтырмын дип елады ул, җүләр баш.

—Кырык хатын тоткан кахан хатын өчен елый диме, ахмак?!

— Син үзең ахмак. Гүзәлләрнең гүзәле ич бусы, күз алмаслык чибәр.

—Кем күрде, чынлап та күз яше белән еладымы кахан?

—Мин күрдем, мин,—диде кендек әбисе.—Мөлдерәмә күз яше белән елады. Бәхеттән, кинәт кенә иңенә ишелеп төшкән бәхеттән елады каханыбыз. Кеше бәхеттән ешрак елый, балакайлар.

— Елагандыр, ир бала ил киләчәге бит, ир куанычы гына түгел,—диде, әңгәмәгә нокта куеп, хатын-кызлар янындагы бер ир-ат.

* * *

Туп кебек угыл тапкач, Айбиби хатын йөзендә тәмам күктәге йолдызлар биешә башлагандай үзгәреш булды. Һәм каханбикә көне белән сарай куштаннары алдында тәгаен бер башка үсте. Хәрам атакайлар Айбиби янында тәгәрәп кенә дигәндәй йөриләр. Айбиби нарасыен күтәреп, еш кына Аккошлар култыгы буендагы чатыр кырына чыгып, җофар тиресе җәйгән ташка утырып баласын имезә. Саф һавада бала йокымсырый, ахыр кинәт уянып китә һәм ашыга-кабалана чупыл-чупыл янә имә башлый.

—Ашыкма, ашыкма алай, Ибраһимым. Ананда сөт житәрлек...

Ибраһим диде дә Айбиби, сискәнеп киткәндәй булды. Һәм ни өчендер тирәктә утырган каракошны күреп йөрәге жуу итеп китте, хәтта колаклары шаулап алды. Әйе, каракош анын йөрәгенә һәрвакыт шом салды. Каракошка күзе төшкән саен куркып китә иде. Әнә шул курку бүген дә кабатланды. Хәзер инде үзе һәм аккошлары өчен генә түгел, баласы өчен дә курыкты. Яман каракош анын күз алдында берничә тапкыр кушшы үрдәкләрне алды һәм хәтта аккошларны ботарларга да өлгерде. Бу хакта ул Йосыфына да әйткәләде, әмма ир-заты моңа игътибар итмәде. Кошларнын үз дөньясы, кешеләрнең үз дөньясы, дип кенә котылды. Нинди туймас каракош ул, нигә көннәр буена шул тирәктә утыра, нигә аны, ниһаять, укчылар укка алмыйлар. Менә минем улым гына үсеп житсен әле, күрмәгәнегезне күрсәтер үзегезгә. Тотар да укка алыр үзегезне. Әйеме, улым, әйеме Ибраһимым!

Янә Ибраһимым диде дә Айбиби суда йөзгән үрдәкләргә, аккошларга карады. Нигә әле ул улына Ибраһим исеме куштырды? Әллә соң имам хәзрәтләре: “Матур исем, уртак пәйгамбәребезнең исеме”,—дип куәтләгәнгәме? Ни гажәп, имам хәзрәтләрен өлкән равва да яклады, Йосыф та бу исем белән килеште. Аннары баланы сөннәткә утырту да бик тиз хәл ителде. Билгеле инде, баланы беренче көннән үк карарга Рәшидә абыстай алынды. Бу хакта Айбиби Йосыф белән дә сөйләшкән иде инде. Рәшидә абыстайга бала караганда ярдәм итәргә ике хәрам атакайны билгеләделәр. Шунда өлкән равва әйтеп куйды: “Мин дә баланы күз угында тотармын”. Моңа берәү дә игътибар итмәде, ә менә Айбиби шул сүзләрдән соң йөрәгенә ук кадалгандай күкрәгенә кулын куйган иде.

Бу хәлләр тар табында хәл ителгәнгәме, сарайда моңа бик үк игътибар итмәделәр, ягъни балага исем кушу, аны сөннәткә утырту сарай халкы өчен әллә ни зур вакыйга булмады. Рәшидә абыстайга баланы карарга аерым бер бүлмә бирелде, кояш ягында, жылы, һәйбәт итеп жиһазланган. Күрше бүлмәгә хәрам атакайлар урнаштылар. Кин, иркен иде бүлмә. Әнә шулай бала мәшәкате хәл ителгәч, Рәшидә абыстай баланы анасы янына имезергә генә йөртә башлады. Бала имеп туюга, Рәшидә абыстай аны бүлмәгә алып кайтты, жырлый-жырлый йоклатты. Ни гаҗәп, тамагы туйганчы имгәч, бала ана кулында чакта ук йокыга китә иде. Йокласа да, йокламаса да Рәшидә абыстай анын белән матур-матур сүзләр табып сөйләште, гүя нарасый барысын да анлый иде, ә инде сабый чәбәләнеп ятканда тәгаен гел аңа: “Әйт әле, әйт әле, әннә, әттә”, дип әйт дип эндәшер, ә бала шуңа охшаш сүзләр чыгарып дәшсә, куанычыннан нарасыйны кулына алыр иде дә тәрәзә каршына килеп: “Әнә күрәсеңме тирәкне, күрәсеңме, син тиздән шул тирәк кебек зур булып үсәрсең һәм атаң кебек ил белән идарә итәрсең”,—дип тәкрарлар иде.

Көннәрдән бер көнне, әнә шулай сөйләшә-сөйләшә баланы йоклатканда, Рәшидә абыстай бүлмәсенә шакымый-нитми өлкән равва килеп керде. Рәшидә абыстай сискәнеп китте.

—Абау, Ибраһим, куркыттың ич,—дип әйткәнен сизми дә калды. Якын кешеләр арасында гына була торган бу әйтем алар өчен шулкадәр көтелмәгән хәл булды ки, икесе дә гаепле кешеләр сыман күзгә-күз карашып алдылар да елмаештылар.

—Мин сиңа китап китергән идем, Рәшидә абыстай.

Өлкән равва “сиңа” диюгә, Рәшидә абыстай сәерсенеп, әмма үпкәләми

өлкән равва Ибраһимга күз ташлап алды, әмма бер сүз дә әйтмәде, бары тик ирен чите белән елмаеп кына куйды. Алай да рәхмәт йөзеннән:

—Син бик кирәк китап китергәнсең, Ибраһим, рәхмәт инде. Кайчак бала йоклаганда укыйсы килә,—диде Рәшидә абыстай үзе дә "син"гә күчеп.

—Мин бүген беренче тапкыр намазга утырып карадым, Рәшидә абыстай, булмады, барып чыкмады, башка әллә нинди уйлар килә.

—Беренче тапкыр булмаса, икенче тапкырында булыр, Ибраһим. Булыр ул, булыр. Күңелең кинәт кенә кабул итмәгәндер, ә тора-тора күңелең дә кабул итәр, иншалла, итәр. Изге гамәлгә утырганда күңелгә яман уйлар килү гөнаһ түгел, алардан намаз аша котылырга теләү изге гамәл, Аллаһыдан ярлыкавын сорау кирәк. Китабың ни хакында соң?.. Фарсы патшалыгында хикмәтле хикәятләр дисеңме?.. Син миңа яһүд пәйгамбәрләре турында да китап вәгъдә иткән идең түгелме, Ибраһим!

—Анысын да китерермен, Рәшидә абыстай, китерермен. Тик бит әле илдә дөньялар бозылып тора, абыстай...

—Ни булды алай, Ибраһим?

—Ханбалыкта кара мәзиннәр яһүдләрнең изге йортлары—синогогны җимергәннәр, ковчегка ут салганнар иде бит абыстай, ковчегка... Ә бит без бергә яшәгән халык, бер тамырдан чыккан. Төрек баласы Мәхмүд Газнави күп еллар Иран империясе тәхетендә утыра. Хазарстан белән тату яшәүгә йөз тота.

—Ибраһим, бик кычкырып сөйләшмә әле, баланы уятырсың.

Сәясәткә кереп киткән өлкән равва кисәк сөйләүдән туктады, як-ягына карап алды.

—Әйе шул, әйе шул, гүзәл абыстай, сүз башым башка иде ич—никах укыту иде.

Өлкән равва, үзенең кем булуы хакында онытып җибәргән сыман, бүлмәгә күз йөртеп чыкты, бераз гына елмаеп һәм көлемсерәп торган Рәшидә абыстайда карашын туктатты да күкрәгенә кулын куеп, баш иде.

—Җомгага кадәр, абыстаем,—диде дә, борылып чыгып китте.

Өлкән равва Ибраһим артыннан ишек ябылуга, Рәшидә абыстай иңбашын сикертеп куйды һәм ул калдырган китапны кулына алды. Кулына алуы булды, аның бөтен тәне буйлап яшен чаткысыдай тетрәнү узды. Ул коты алынып, китапны кире өстәлгә ташлады һәм догасын укый-укый өлкән равва чыгып киткән ишеккә карады.

Рәшидә абыстай Хазарстанга килгәнче үк инде өлкән равваның сарайда кем булуын яхшы белә иде. Өлкән равва Ибраһим Йосыф каханның киңәшчесе генә түгел, хакиме дә, хөкемдары да. Сарайда кылынган сәяси хәлләр, хәтта уеннар да барчасы аның башында туа, кахан аша гамәлгә аша иде. Түрә хан Мөхәммәд ханның кызын улына сорап Болгарга җибәрүен ишетүгә—бу ике зур кавемнең кушылып китүләреннән куркып, өлкән равва яучылыкта азау тешләре чыккан Равваларын Идел буена озатты. Яучылар "каган исеменнән" ханга кызын Хазарстанга озаткан хәлдә алтын таулар вәгъдә итә, ягъни ташламалар ясарга. Моңа, әлбәттә, Идел буе төрки болгарлары ышанып җитмәделәр, ләкин аксакаллар һәм Мөхәммәд хан үзе риза булгач, дәшмәс булдылар. Кыскасы, һәр чорның үз сәясәте, үз кыйбласы, үз фәлсәфәсе була. Һәрхәлдә, бик күп сәяси хикмәтләрне күргән борынгы халык буларак, Идел буе төрки болгарлары һәм аларның ханы раввалар белән килешергә дигән фикергә килә.

Ә Мөхәммәд ханның баш тартырга да хакы бар иде. Хан инде бер кызын кахан кырына җибәреп үз башына хәсрәт алды. Үз аллалары Яхвадан башканы күрмәгән, күрергә дә теләмәгән, үзләренең Муса пәйгамбәр заманнарыннан ук килгән Тора-Талмудларына ябышып ятуларын фанатикларча дәвам иткән яһүдләр үк булмасалар да, төрки телдә сөйләшкән хазарлыларны Рәшидә абыстайга да аңлавы кыен иде. Нигә өлкән равва ислам динен кабул итәргә ашыкмый, төрле сәбәпләр таба. Ул гынамы, сарайга килеп оялаган Харәзем әмире имамнарын илдән куарга җыена дигән хәбәр ирештергән иде инде бер хәрам атакай аңа. Иң әүвәл Рәшидә абыстай

өлкән равваның кылын тартып карарга булды. Вә ләкин моның өчен аңа өлкән равва Ибраһим белән якынаерга кирәк иде. Хак, бу теләк белән янәшә, хатын-кызларда була торган мине дә яраталар дигән горурлык хисе дә бар иде абыстайда. Ни генә булмасын, "мин ялгышмыйм", ә өлкән равва ялгышадыр ип йлый иде Рәшидә абыстай. Йосыф каханның йөрәген Айбиби яулаган кебек, нинди юллар белән бу кешенең күңеленә үтеп кереп, йөрәген яуларга?

Башына шундый уйлар килүгә, Рәшидә абыстай күрше бүлмәдәге хәрам атакайларны дәшеп, җомгага кадәр Ибраһим янына кереп чыгарга булды. Имам да килгәндер инде. Әйдә, укытсын никахны.

Хәрам атакайларга йоклаган баланы калдырып, уянса әнисенә илтегез дип, Рәшидә абыстай бәйрәмгә баргандай матур итеп киенде дә, тәвәккәлләп, өлкән равва бүлмәсенә таба кузгалды. Оялу да, бераз курку да һәм, яшерми, өлкән раввага бераз мәхәббәте дә бар иде. Бу мәхәббәте яшьлектәге тәүге мәхәббәтләрдән дә татлырак булыр сыман тоелды аңа, чөнки нигәдер күңеле ашкына, җиңелчә генә булса да йөрәге ешрак тибә башлаган иде.

## XVI

Йосыф кахан әкрен генә үз көченә керә барды. Ул инде сарайда өлкән равваның нинди сәясәт алып барганын бераз чамалый—яудан кайтыр алдыннан гына сатлык кара мәзиннәргә учлап акча түләп, Ханбалыктагы синогогларны җимерткән һәм Йосыф кахан кулы белән аларны зинданга ташлаткан. Шарун равва бу хәлгә тәмам ышана калган Йосыф каханның күзен ачты. Синогогларны җимерүне өлкән равва үзе оештырган. Шушы вакыйга-гамәлне корал итеп алып, өлкән равва сарайдагы имамнарны гына түгел, Рәшидә абыстай белән Айбиби хатынны да Аккаладан кудырмакчы, бер җайдан христианнарны да. Аннары Йосыф каханга керешер. Йосыф каханга карата аның кулында ефәк бау бар. Рәхмәт Шарунга, Йосыфны әллә чынлап та үз итеп, әллә үзе өлкән равва булырга теләп, аңа барысын да җиткерде.

Шарун равваның өлкән равва булырга теләвенә бер дә гаҗәпләнәсе түгел, чөнки бу кеше үзен Булан каханның оныгы дип йөри иде. Хак, кырык хатыннан туган улларны вә оныкларны барлаучы юк, вә ләкин өлкән равва аларның барысын да белмәсә дә беришен күз угында тота һәм теләсә кайсысын кахан итеп тәхеткә күтәрә ала иде. Йосыф кахан өлкән равваның ни кылырга җыенуын яхшы белгәнгә, бу кешегә каршы ни эшли алуы турында уйлана башлады. Өлкән равва сарайдагы имамнарны һәм Рәшидә абыстай белән Айбибине кудырып кына тынычланмас, каханбәк Сабир белән кала тарханы Булат бәккә дә кул сузар. Бу ике кеше дә мөселманнар, җомга намазына кадәр йөриләр. Шул ук вакытта өлкән равва белә иде—Хазарстан тынычлыгы әнә шул каханбәк һәм бәкләр кулында. Хәтта Аккала да алар кулында. Ни генә булмасын, өлкән равва мөселманнарны һәм христианнарны илдән кудырачак. Кемнән кудыртачак? Шул ук төрки бәкләреннән. Ил белән кем идарә итә соң? Хазарстан яһүдләре төркиләр дөньясы уртасында калсалар да ил белән идарә итүне үз кулларында тота. Тик менә Йосыф балакай кисәк кенә үзгәрде. Викингларны чакыру мәсьәләсендә дә сыртын кабартты, имеш, үзең чакырттың, үзең хәл дә ит. Ни гаҗәп, Айбиби хатын да сарайга килә-килүгә өлкән равваны өнәп бетермәде. Беренче кинәшчең синең, өлкән равва түгел, ә Айбиби хатын, диде Шарун равва. "Хатының тыңла, үзенчә эшлә", дигән гыйбарә дә бар ич әле.

Әйе, Йосыф кахан өлкән равва белән бер-бер чара күрергә тиеш. Тик нинди юл белән? Иртәгә табын. Раввалар бу табында мөселманнарны һәм христианнарны каладан куарга карар чыгарачаклар. Һәм куа да башларлар, ә ул—илбашы бу чарадан читтә калыр. Кыл бер-бер чара, өлгеррәк бул, Йосыфҗан! Шулай дип әйтер иде Айбиби хатын. Ләкин бу хакта Йосыфына бер сүз дә әйтергә теләми, бала белән мәшгуль. Инде нишләргә тиеш ул?..

Йосыф кахан тәхетеннән купты, ишекле-түрле йөрергә кереште. Әйе, иртәгә түгел, бүген үк табын жыярга тиеш ул... Юк, башта Шарунны чакыртырга. Аннары имамнарны дәшәргә. Имамнарны илдән куу дигән сүз табын аша чыгарга тиеш түгел, ул хәл итәргә тиеш моны. Бүген, хәзер үк. Ашык Йосыф, ил өстенә югарыдан яман викинглар төшә, аннан соң булып куюы бар.

—Йомышчым, Шарун равваны дәш!

—Баш өсте, галижәнапләре.

Күп тә үтми болары минем кешеләр дип, ике ише белән Шарун равва килеп керде. Йосыф кахан аларга аяк өсте генә үз фикерен житкерде. Шарун аны хуплады. Аларны бүлмәгә чыгарды, шәрабчысына грек шәрабы бирергә кушты, ә үзе өлкән имамны дәштерде. Ләкин тәхет ягына сорамыйнитми тарханбәк Булат килеп керде.

—Бик вакытлы йөрисең, тарханбәгем. Идел буйлап викинглар төшә, кальгадагы гаскәрне күздән кичер, коралларын барла, булмаса, корал амбарларыннан бирергә куш. Тиз йөр!

—Баш өсте, галижәнапләре!—диде Булат бәк һәм чыгып та китте. Булат бәк артыннан ишек ябылырга да өлгермәде, имам күренде. Ул кәрә-керүгә, ишек кырындагы түмәргә утырды, дога кылды, шуннан соң гына каханга сәлам юллады.

Йосыф кахан тәхеткә утырган иде инде, ул да дога кылгандай итте. Һәм:

—Уз, хәзрәт, түрдән уз, түр түмәргә утыр,—диде.

Имам хәзрәтләре түргә узды, кахан күрсәткән түмәргә утырды һәм янә дога кылды, ике куллап йомры сакалын сыпырып алды.

—Каханга Аллаһыбыз куәт бирсен,—диде.

Йосыф кахан тамак кырды, сезгә әйтер сүзем бар дигәндәй, кулын күтәргәндәй итте.

—Имам хәзрәтләре, сез әлегә кадәр мәнем табынымның иң күркәм кунагы булдыгыз. Тик яман хәбәр ирешде бит әле. Безнең илгә викинглар яу чыккан, мин беләм, алар Аккаланы да читләтеп үтмәсләр... Әйе...

Имам хәзрәтләре бу хакта хәбәрдар икән инде, Йосыф каханны тыңлагач, як-ягына карап алды.

—Без ни кылырга тиеш инде, кахан хәзрәтләре?

—Сез, бүген үк илегезгә таба кузгалырсыз. Буш китмәссез. Һәммәгезгә дә тулы дирбияле ат булыр.

—Хуш, хуш...

—Мин сезне, имам хәзрәтләре, әмирегезне хөрмәт итеп, колач жәеп кабул иттем, сараема уздырдым, табынымда утырттым. Илдән тынычлык китәргә тора. Әмирегезгә шулай дип әйтегез. Сезнең бүген үк китүегез хәерлерәк булыр. Юлыгызга житәрлек акча бирелер. Казнабашка әйтелгән.

—Бихуш, яхшы,—диде имам хәзрәтләре.—Без хәзер үк кузгалыйкмы?

— Хәзер үк!

Имам хәзрәтләре чыгып киткәч, Йосыф кахан Шарун раввага дәште һәм имамнарны озатырга кушты. Шарун равва ишләре белән аның әмерен үтәргә чыгып киткәч, Йосыф кахан янә тәхетенә утырды да тирән итеп көрсенеп куйды. Аның өчен янә бик тә авыр бер эш калган иде—Айбиби хатын. Ул аны да озатырга тиеш. Әмма ничек, ничекләр әйтергә тиеш ул аңа?.. Авыр аңа, аның Айбибине һәм баланы бер дә жибәрәсе килми иде. Тик бит хәл итте инде, кире чигенү булырга тиеш түгел!

Башта сандыгыннан үзенә дә, хатынына да, балага да гарәп остасыннан ясаткан бөтиләрне алды. Һәр бөтигә дә аларның сурәтләре ясалган гарәп һәм яһүд хәрефләре белән исемнәре язылган иде. Ул бу бөтиләрне аерылышканда бирергә дип ясатмады, балага елы тулгач бирергә иде исәбе, әмма нишләмәк кирәк, хәзер бирергә туры килер, вакытлыча булса да аерылышалар ич. Бөтиләрне учына кыскан килеш, Йосыф кахан Айбиби бүлмәсенә таба кузгалды. Ләкин Айбиби бүлмәсендә юк иде. Шуннан ул

Аккошлар култыгына юнәлде. Ул анардан берни дә яшермәс, барысын да әйтер. Айбиби бүген үк Болгарга таба кузгалырга тиеш. Озатуны оештыруны Булат бәккә йөкләр. Тик башта Айбибинең ризалыгын алырга кирәк иде аңа. Айбибидәге күз камашырлык матурлык, үзенә тартып торган серле итеп елмаюы аны беренче күрүдә үк әсир иткән иде. Башта ул бу хәл үтәр дип уйлады, әмма үтмәде, Айбиби хатынны күргән саен күрәсе, тыңлаган саен тынлыйсы килде. Ә инде Айбиби аңа углан бала да тапкач, ул, гомумән, югалып калды. Моның өстенә күптән түгел бабасыннан илчеләр килде, Мөхәммәд хан оныгына бүләкләр җибәргән, ә үзе авырып китеп, ятакка калган икән. Моңа кадәр ул Айбиби хатынны кырына чакыртып алыр иде, бүген исә үзе аның янына юнәлде. Аягы атлады, ә күңеле икеләнде—әйтер сүзен әйтә алырмы, югалып калмасмы?.. Йосыф каханның күңеле тыныч түгел иде. Моның өстенә үзе дә авырып киткәч, тәхетне кемгә васыять итүе турында бабасы бер кәлимә сүз дә язмаган. Илче дә бу хакта бер сүз әйтмәгәч, Йосыф кахан уйлап куйган иде—Идел буе Болгар тәхетенә ханны үзе тәкъдим итәр. Үзе! Шунда ук башына бер уй килде—бүген Казанда тархан булып утырган Гаязетдин угланны тәкъдим итәргә...

Сарайдан чыгып, Аккошлар култыгына таба атлаганда бу уй Йосыф каханның тәмам бөтен зиһенен биләде. Бу хакта ул Айбибигә дә әйтер—житкерсен атасына. Ни гаҗәп, бу арада аның ягына өлкән равва керми башлады. Ни сәбәпледер Йосыф каханның да күрәсе килми иде аны. Кичә ятагына кергәч, бу хакта Айбиби хатынга да әйткән иде, тик хатын бер дә исе китмичә: "Үз җаена яши бирсен, Йосыфҗан",—дип кенә җөпләде.

Айбиби чатыр каршындагы түмәрдә бала имезеп утыра иде, кырын күзе белән генә ир-канатының килүен күргәч, торасы итте, әмма Йосыф кахан кулын күтәрде.

—Юу-ук, күтәрелә күрмә!—диде.

Йосыф кахан хатыны кырына килеп утырды, култык ягындагы аккошларга күз төшереп алды.

—Безнең янга килергә булдыңмы, әтием?—диде Айбиби бала теле белән әйткәндәй.

—Башына йөз кайгы төшкәч килде улы кырына, Айбиби хатын, мең төрле уй төшкәч. Бабай анда ятакта ята икән, авырып киткән, тәхетне кемгә васыять итте икән, Айбиби?.. Синең белән дә киңәшмәдеме?..

Якында гына хәрәм атакайлар утыралар иде, Йосыф кахан аларга: "Югалыгыз күз алдымнан!"—дип кул селтәде. Хәрам атакайларны чатыр яныннан гүя җил алды.

—Атам авырып киткәнен ишеттем, Йосыфҗан, ишеттем... Борчылма, каханым, атам Болгар тәхетенә лаеклы кеше табар.

—Табуын-табар анысы, Айбиби, тик бит бер дә киңәш-сабак итмәде.

—Йосыфҗан, Идел буе Болгарында борын-борын заманнардан ук ханны сезнең равваларыгыз кебек төрки аксакаллары хәл итәләр. Гадел рәвештә. Йосыф җаным, борынгы бабаларыбыз үз ханнарын ак киезгә утыртып, өч тапкыр кулларында күтәргәннәр, соныннан өч тапкыр чатыр тирәли әйләндереп чыгарганнар, шуннан соң гына тәхеткә утыртканнар. Тәхеткә утыргач, аның кулына алтын саплы Тәңре кылычы тоттырганнар.

—Бездә, Айбиби хатын, кахан сайлаганда, башта аны ефәк бау белән сулышы кысылганчы буалар һәм аңа сорау бирәләр: ничә ел тәхеттә утырырга, ил белән идарә итәргә исәбең, дип...

—Сине дә тәхеткә шулай утырттылармы, Йосыфҗан?

—Мине дә, Айбиби җан, мине дә.

—Ә син ничә ел тәхеттә утырам дип әйттең?

—Хәтерләмим, Айбиби җан, хәтерләмим.

—Безнең борынгы бабаларыбызның бабасы Атилла ханны да киезгә күтәреп тәхеткә утыртканнар, дигән иде мина имам хәзрәтләре.

—Аннары Атилла хан Римгә кадәр барып җиткән, шулаймы Айбиби җан?

—Шулай, каханым. Идел тамагына кайтып утырган төркиләр дә Атилла

белән Ауропага барганнар. Сонра еллар үтә-үтә Атилла хан оныгының оныгы Кубрат хан Таман ярымутравына үзенә ыстан төзи һәм башкаласы Фанәгүрне атый. Калганын үзең дә беләсең, каханым.

—Хазарстан каханы Болгар ханы Кубрат белән орыша, төрки болгарлары ханының улларын тарата.

—Син хаклы, каханым. Ике туган халык сугыша, бер-берсен кыра.

—Безгә бүген иң яман баскынчылар килеп ята дигән хәбәр иреште, Айбиби җан, иң яман баскынчылар—викинглар. Явызлыклары белән даннары дөнья халыкларына таралган юлбасарлар. Шуның өчен мин сезне, Айбиби җан, Болгарга кунакка җибәреп торырга булдым.

Бу хәбәр аңына житүгә, Айбиби бераз дәшми торды. Бу ни бу! Шатланырга тиешме ул моңа, әллә Йосыф кахан шул юл белән алардан котылырга телиме?..

—Бу шулай кирәкме, Йосыфҗан, моны син чынлап та шулай телисенме?..

—Сез минем бу дөньяда иң кадерле кешеләрем, Айбиби җаным, иң кадерле кешеләрем. Сугыш булыр, пиратларның Аккалага бәреп керүләре бар. Мин сине гүзәллегең өчен генә түгел, акылың өчен дә яраттым. Син мине рух байлыгың белән дә әсир иттең, Айбиби җан. Сез бүген үк Болгарга китәрсез. Бүген үк, Айбиби җан.

Айбиби өчен бөтенләй көтелмәгән хәл иде бу. Ләкин кайтарып сорарга кыймады. Йосыф кахан сак кына баланы кулына алды, йокымсырап киткән баланың маңгаеннан үпте һәм торып басты.

—Рәшидә абыстай да минем белән китәрме, Йосыфҗан?

—Рәшидә абыстай да китәр. Сезне озатырга Булат бәк кешеләр бирер. Борчылма, Айбиби җан, барысы да әйбәт булыр. Имам хәзрәтләрен мин озаттырдым инде, Айбиби җан.

Хазарстан каханы Йосыф сүзләренә сәерсенеп калса да, ул аңа ышана иде, гәрчә буласы хәлләргә шомланыбрак куйса да ир-канатына бер сүз дә әйтмәде. Хәер, нәрсә әйтә ала иде ул аңа?..

Һични! Чөнки бу чорда хатын ир белән, ир ил белән идарә итә торган заман иде. Ә һәр заман хатын-кызга үз шартларын куйды, вәзгыятькә буйсынмый булдыра алмады Мөхәммәд хан кызы Айбиби, чөнки ул да шушы чорның корбаны.

## XV

Каханбәк Сабир Йосыф кахан белән көнбатышка яу йөрсә дә, күнеле һәм дөньяга карашы белән өлкән равва Ибраһим яклы иде. Юк, хатыны яһүдә булганы өчен генә түгел, кылган гамәлләре, акылы белән Йосыф каханнан өстен булганын күреп. Өлкән равваның өстенлеге нидән гыйбарәт иде соң, бу хакта беркайчан да төбенә кадәр төшеп уйламады.

Булат бәк исә кала-сарай карачысы. Ул бер тапкыр да яуга чыкмады, әмма калада тәртип урнаштыруда, аның кебек кешене табу кыен иде. Ул илгә килгән чин вә дала сәүдәгәрләре белән дә, румнар белән дә, фарсылар белән дә уртак тел таба белде һәм һәммәсе белән дә алар телендә сөйләште. Аккалага да, Ханбалыкка да Булат бәк күз-колак булып тора, каханга да ул нәүбәт торып керми, ишек шакып та, ишек ярында торган айбалталарын чалыштырган сакчылар белән дә исәпләшеп тормый, чөнки аларны үзе куя һәм хезмәт хакын да казнабаштан акча алып, үзе түли иде. Әмма Булат бәк өлкән равваны өнәп бетермәде. Хәер, моңа гаҗәпләнәсе түгел, Булат бәкнең хатыны яһүдә түгел, төрки болгары, балаларын да сарайда укытмый, кала мәдрәсәсендә укыта. Булат бәккә берәү дә сүз әйтә алмады, чөнки һәр эшен җиренә җиткереп башкара иде. Шуларның барысын да исәпкә алыпмы, өлкән равва Булат бәккә янә бер йөк өстәде: яһүдә хатыннардан туган, сарайда белем алган яһүд балаларын сарай мәктәбен тәмамлаганнан соң җылы җиргә эшкә урнаштырырга. Бу өстенлекне әллә күрәләр иде төрки бәкләре вә морзалары, әллә юк, әмма бу хәл Булат бәкнең ачуын китерә башлады. Моңа кадәр ул раввалар чыгарган бу канунга буй-

сынды һәм дәшми генә эшен башкарды. Әмма өлкән равва теләге белән Идел буе Болгары Мөхәммәд ханның икенче кызын Йосыф каханга кырык беренче хатын йөзендә тарттыргач, Булат бәктә үзе дә аңлап бетермәгән көчеш булды, аң күчеше. Ул раввваларга бөтенләй башка күзлектән карый башлады. Нигә әле яһүдә хатыннардан туган балалар гына илнең иң дәрәҗәле мәктәбендә укырга тиешләр! Нигә төрки хатыннардан туган балалар ул өстенлекләрдән мәхрүм ителә?! Кем чыгарган бу канунны! Ә бит әнә шул куштан яһүдләр төркиләр житештергән ипине ашый, раввалар турында әйтәсе дә юк, балда-майда гына йөзәләр. Бер генә яһүд тә йөзем үстерми, балык тотмый, тез тинентен су ерып, дөге житештерми. Ул гынамы, сарай мәктәбен тәмамлагач, сәләтлеме ул бала, юкмы, йә Ефәк юлында тамгачы булып китә, йә төрки бәкләре вә морзаларында сәркәтип булып утыра, гаскәргә дә аларның бик сирәкләрен генә алалар. Орыш кырыннан качса да яһүд баласына җәза юк. Бу нинди Аллаһ сайлаган халык!

Элегрәк Булат бәк Хазарстан тәхетендә курчак йөзендә утырган Йосыф каханга әллә ни шаккатмый иде. Хазарстанда борын заманнардан килә бу гадәт. Әмма Йосыф кахан кырык хатынын аерып җибәргәч, Булат бәк гаҗәпсенде-гаҗәпсенүен, барыбер артык исе китмәде. Тик Айбибине күргәч кенә өнсез калгандай булды. "Күр инде, алиһә икән бит бу гүзәл җан, алиһә икән ич!"

Шушы хәлдән соң, Булат бәк, кала тарханы буларак, Йосыф кахан белән дә килеште, өлкән равваның да хәленә керде. Чөнки, хак булса, хатыннарны куу мәсьәләсен Йосыф кахан берүзе хәл иткән, дигән хәбәр ирешкән иде ана. Димәк, яһүд булулары белән мактанып йөргән куштаннарның Йосыф кахан борыннарына чиртте. Кинәнде Булат бәк, яшерми. Ләкин шул ук көнне диярргә була, бер куштан аның янына килде дә: "Булат бәк, минем дә кызым буй алды, тап әле шуңа арурак кияү-егет",—дип әйтмәсенме. Нә сабыры текәнсә дә яһүд агасына, дөресрәге, ярымяһүд агасына бер сүз дә әйтмәде Булат бәк, тик янак итен генә чәйнәде. Әмма: "Карап карармын",—дип әйтмичә дә булдыра алмады. Сарай куштаннарының кыз балаларын кияүгә бирүне, егетләрне бай яһүд сәүдәгәрләренең кызларына өйләндерүне дә йөкләгәч (бу да раввалар чыгарган карар иде) Булат бәк тәмам чыгырыннан чыкты, һәм шул сорау белән мөрәҗәгать иткән яһүдне эт итеп орышып ташлады. Ә ул сарай корты икән, шундук өлкән раввага житкергән, ә тегесе Булат бәкне үзенә чакыртты.

—Булат бәк,—диде кәнәфигә аркасын терәп утырган өлкән равва,—бу нинди хәл инде, безнең хөрмәткә ия раввваларыбызны орыша башлагансың. Бер дә ярый торган нәрсә түгел бу, Булат бәк. Син хәзер аны эзләп тап та гафу үтен... Бу булыр—бер, икенчедән, тамгачыларына әйт, яһүд сәүдәгәрләренең тауарларын тамгасыз гына базарларга уздырсыннар. Кахан карары вә фәрманы дип кабул ит.

Менә кайчан Булат бәк чыгырыннан чыкты.

—Мин ул яһүдә кызларына бала табарга да булышыйммы, өлкән равва?

Өлкән равва әкрен генә каршында басып торган Булат бәккә башын күтәреп карады, әмма, ни гаҗәп, бер сүз дә әйтмәде. Бары тик: "Бар, юлында бул",—дип, кулын гына селтәде.

Сарайдан чыгып барганда Булат бәккә каханбәк Сабир очрады, әмма гаскәрбаш аңа кул бирү генә түгел, хәтта исәнләшмәде дә, әйтерсең лә Булат бәк аның өчен юк иде. Ә әйтәсе сүзе бар иде Булат бәкнең каханбәккә. Кичәгенәк угланы Асылбәк аны туктатты да: "Мина да бер чибәр яһүдә кызын тап әле",—дип, көлемсерәп алды. Каханбәк Сабир улы Асылбәк сарайда казнабаш янында ярдәмче булып йөри иде, яшь, чибәр, башында чәпләшкә, ак җилпәзәк кигән, борын астында сызылып киткән кара мыек. Балда-майда йөзә егет. Заманында Йосыф каханның хатыннарына да күз салгалый икән дип җиткергәннәр иде хәрам атакайлар Булат бәккә. Әмма Булат бәк моңа игътибар итмәгән иде. Йосыф каханнын хатыннарына кул салган кешеләр гомерләрен зинданда бетерделәр, һәм моны кем дә түгел, кахан әмере белән Булат бәк үзе башкарды. Кахан зинданыннан берәүнен

дә исән чыкканы юк әле. Булат бәк ана: “Зиндан жылый анда сине көтеп”,—дип, шаяртып китсә дә, күрде ич, Асылбәк углан тәмам йөзгә үзгәреп калган иде.

Кала-салаларда Булат бәк тәртипне саклады, берәр жирдә каханга, йә булмаса түрә яһүдләргә карата начар сүз әйтсәләр—үзенең елгыр яугирләре белән шундук барып житте һәм тиешле чарасын күрде. Ә менә сарай сорыкортлары белән уртак тел таба алмады, гәрчә Аккала куштаннарына кадәр ана буйсынсалар да, нигездә куштаннарны өлкән равва үз кулында тотты. Ничәмә еллар эшләп, каханда хезмәттә торып, Булат бәк барыбер сарайда барган хәлләргә төшенеп житмәде һәм төшенергә дә теләмәде бугай. Ана Ханбалыкта да эш бик житкән иде. Хак, бер хәлне бик тә беләсе килде—кахан зинданга яптырган мәзиннәрне чыгарырга фәрман бирерме, юкмы? Әллә булмаса башларын кистерерме?..

Тагын бер яман хәбәр анын эчен тырный иде—Иделнең югары башыннан төшеп килгән викинглар белән орыш булырмы? Бит алар телиләрме моны, юкмы, Аккала аша үтәргә тиеш булачаклар?.. Равва Шарун ана үтеп барышлый гына: “Аккалага викинглар килә, дингезгә чыгачаклар, сезнең мөселман калаларын талаячаклар, юлбасарларны кахан үзе чакырган дияр идем, ялгышырмын дип куркам, ә менә өлкән равва чакыруын Харальд корольгә үзем озаттым, карт төлкегә ышанып булмый, каланны нык сакла”,—дип, китеп барган иде. Ышанды да, ышанмады да Булат бәк Шарун раввага, чөнки анын элек тә шаярткалаганы бар иде. Шаяртуынын чынга ашкан чаклары да булды, булмады түгел, ләкин зурдан кубып викингларны чакыруны күз алдына китерә алмады Булат бәк. Шул ук вакытта белә иде, сәясәткә кереп чумган яһүд түрәләреннән барысын да көтәргә була. Тукта, тукта, Харәзем әмире имамнарын озата да башламадымы кахан?.. Үзе үк, кунактан киткән кебек һәйбәт дирбияле атлар белән, кесә тутырып акча бирә-бирә?.. Ни булыр бу?! Сөннәтле казаклар да ни өчендер Ханбалыкта уралалар. Моны ничек анларга, ә кала тарханы берни дә белми?!.. Өлкән раввамы, кахан үземе чарасыз калды?.. Чөнки анын ярдәме белән Идел буе Болгарлары гына түгел, Харәзем сәүдәгәрләре дә Ефәк юлын үз кулларына төшереп ята, яһүд сәүдәгәрләре күптән инде шул хакта зарланып йөриләр. Хак, Булат бәк мона кинәнде генә. Төрки мөселманнарынын сәүдә мәсьәләсендә уҗәтлек күрсәтүләре анын өчен куанычлы хәл булса да, Булат бәк бераз курка калды. Алай да башта ул жансакчысы Актайны каравыл йортына чакыртып алды. Теге килеп кергәч, ана янәшәсендәге түмәрдән урын күрсәтте.

—Утыр, Актай, йөк-йомышым тынла. Сәхибулла йөзбашын ал да Болгарга юнәл. Анда Мөхәммәд хан ятакка калган икән, авырып киткән. Хәйлә генә түгелме, чынлап та урынга калганмы хан? Калган булса, кемгә тәхетне васыять иткән? Сора, тартынып торма. Дунай буе Пәһлеван ханнын улы Шамгун анын кул астына килгән иде, ул ни кылып ята, чынлап та Пәһлеван хан угылымы? Пәһлеван хан угылы булса, кемгә йөз тота, илаһи диндәме?.. Аннары тагын бер үтенеч, Мөхәммәд хан кырында каханнын кешесе утыра булса кирәктер. Анын күзенә чалынмаска тырыш. Син кахан илчесе түгел, Тамантархан Гали илчесе. Искәрдең?!

—Баш өсте, Булат бәк.

Кайчандыр Актай каханда йөзбаш булып йөргән иде, Сабир каханбәк белән килешеп, Булат бәк Актайны үз кырына алды. Ошады егет Булатка. Һәм ул ана үзенә ышанган кебек ышана башлады. Булат бәк каршында басып торган егеткә карады да: “Нинди асыл егетләребез бар, ә кахан Карунны дәшкән”,—дип көрсенеп куйды.

—Хәзер үк китәсез, күпергә кадәр үзем озатырмын,—диде Булат бәк һәм ишеккә таба алдан кузгалды.

Йөзбашын күпердән чыгарып жибәргәч кенә, Булат бәк кире сарайга таба борылды. Сарайга кереп барганда ана равва Шарун очрады.

—Булат бәк,—диде ул кала тарханына.—Әйтергә онытканмын. Кахан үзенә яна ярдәмче алды. Үгез дә үгез, ул да үгез.

Булат бәк анын кырыннан бер сүз әйтми үтеп китте. Каханнын үз кырына

батырларны җыюына бер дә шаккатасы түгел, викингларны көтә. Үгез дигәне атаман Карун яугире булса кирәктер. Инде тәхет ягына кереп барганда, аның каршында Рәшидә абыстай пәйда булды. Абыстай өлкән равва бүлмәсеннән чыгып килә иде, Булат бәкне күрде дә кала тарханының тәгаен юлына аркылы төште.

—Булатҗан,—диде ул якын ук килеп.—Тыңла әле, мине тыңла дим. Сак бул, бәгем, кахан барча мөселманнарны да каладан куарга әмер биргән. Олан белән Айбибине дә, мине дә Болгарга, ары таба Казанга озатып ята. Без бүген үк чыгып китәбез. Ни булган икән каханга, Булат бәгем?..

Шул вакыт өлкән равваның бүлмә ишеге ачылды, ишектә өлкән равва күренде.

—Башта бире кереп чык әле, Булат бәк. Кер әйдә, кер, нигә туктап калдың!..

Урлашканда тотылгандай, Булат бәк тәхет ягындагы сакчыларга күз төшереп алды да өлкән равва бүлмәсенә таба борылды.

—Кер-кер, түрдән утыр,—диде аңа өлкән равва.

—Рәшидә абыстай сездән чыгып бара иде кебек, өлкән равва?

—Рәшидә абыстайга тимә, Булат бәк. Аны куеп тор.

—Абыстайның күзләрендә йолдызлар биешә иде, өлкән равва,—дип елмайды Булат бәк көлемсерәп.—Кәефләр ничек соң, өлкән равва? Изге юлдасыздыр бит?..

—Гөнаһ кылмадым, мин шуны яхшы беләм, Булат бәк. Ләкин моны куеп торыйк әле, кала тарханы Булат бәк.

Өлкән равва аны кечкенә өстәл янына дәште.

—Кунак кабул иттең, димәк, өлкән равва?

—Һәй, кем бар анда, кымыз керт!—дип бавырчысына дәште өлкән равва, Булат бәкнең сүзләрен колак яныннан уздырып.

Кымызчы чокырларга кымыз койгач, Булат бәк рәхәтләнеп эчеп куйды.

—Дала кымызы, кыпчакларныкы, тамакны ярып керә. Шөкер итәм әле, өлкән равва, каханыбыз Йосыф бер хатын белән генә тора башлады.

—Нигә алай дисең, Булат бәк? Хатын янына хатын сыя, диләр бит төркиләр.

—Сыюын сыя анысы, тик бит һәр хатынның үз кубызы була. Һәрберсе үз кубызына биетә башлый.

—Әйт әле, Булат җан, кем адәм баласын оҗмахтан кудырта?

—Һауа анакай, Һауа анакай, өлкән равва.

—Ә шулай да минем Һауа анабызны гаеплисем килми, Булат бәк. Аллаһы Тәгалә һәр ир-зат адәм баласына да орлык биргән, ә ул коелырга тиеш. Коела торган урыны—хатын-кыз. Аны тора-бара мәхәббәт дип атый башлыйлар, нечкәртәләр, кисәкләргә бүлгәлиләр. Сөләйман пәйгамбәр исә, күп хатынлыкка чарасыздан бара, күп кенә асыл егетләре орыш кырында ятып калгач, тол калган хатыннарны үз учагына алырга мәҗбүр була.

—Алай булгач, безнең каханыбыз да күп хатын тотып изге гамәл кылган булып чыга бит, өлкән равва.

—Хак Тәгалә шулай, Булат бәк. Ләкин каханыбыз үз кадерен үзе белмәде. Хәзер инде без хәл иттек, аны зур сынау көтә.

—Яман йола,—диде Булат бәк башын чайкап.—Яман йола. Ә минә хатын-кызларга килгәндә, миңа калса, бөтен яманлык алардан башлана, өлкән равва.

—Әйтмә алай дип, Булат бәк. Хатын-кыз куены оҗмах ул, оҗмах, Булат бәк. Йә, куеп торыйк ул хакта. Мине бүген синең диндәшләрең борчый, Булат бәк, синогогларны җимергән кара мәзиннәр, каланың кара халкы. Хак, син аларны тиз тоттың, үтә гаеплеләрен зинданга ташладың. Ә бит храмнарны җимерүдә анда шактый халык катнашкан булган, Булат бәк.

—Әйе, катнашкан. Ләкин мин, өлкән равва, кала тарханы буларак, аларның иң яманнарын гына зинданга ташлаттым, анда да кахан үзе әмер биргәч кенә.

—Үч-үчкә илтмәсме соң, Булат бәк? Миңа иреште, бай сәүдәгәрләребез

мәчетләрне җимерергә гаярь егетләрне яллап йөриләр икән.

—Ә миңа ирештерделәр, өлкән равва, кемдер Хазарстанга сөннәтле казак атаманы Карунны чакырткан. Егетләрен, башкисәрләрен дим, кала читендә калдырып, Карун үзе сарайга ук үткән икән. Ә мин Аккала тарханы ул хакта бернәрсә дә белмим. Карунның кем икәнен мин бик яхшы беләм, алтынга ул үз атасын да дар агачына асачак.

—Карунны мин чакыртмадым, Булат бәк. Бу хәл кахан эше булса кирәк-тер. Яудан кайткач кахан тәмам үзгәрде, хатыныннан аерып алып та булмый башлады үзен. Мин түгел, кахан уйный башлады ил язмышы белән, Булат бәк.

Булат бәк туктады, күзен-кашын җимереп, баш түбәсенә кара төстәге чәпләшкә каплаган өлкән раввага карап торды.

—Сез түгел, димәк, өлкән равва?

—Ышан, Булат бәк, без раввалар үзебез каханны хөкем итәргә җыенабыз.

Өлкән равва аякларын алыштыргалап, бер урында таптанып алды.

—Бу хакмы, өлкән равва?

—Бу чараны һәр чорда да үтәгәннәр, Булат бәк.

—Бер дә гадел чара түгел, өлкән равва. Әйтегез әле, өлкән равва, бу хакта кахан беләме?

—Мин сиңа дәүләт даирәсендә утырган раввалар серен әйттем, Булат бәк. Башыңда акылың булса, сер сакларсың дип ышанам мин сиңа.

—Өлкән равва,—диде Булат бәк руханиның чапан якасыннан эләктереп,—Өлкән равва, ә бит сезнең викингларыгыз белән каханның Карун атаман китергән егетләре канга-кан килеп орышулары бар. Мин нишләргә тиеш булачакмын ул чакта, кемне якларга?.. Мин беләм, хәбәрдар, сөннәтле казаклар көймәче викингларның кан дошманнары. Теге елда, Карун яуга киткәч, Ука елгасы буйлап килеп, бөтен хатын-кызларны диярлек тәяп алып киткәннәр иде. Беришен Хазарстанга китереп саттылар, күбесен Византия сәүдәгәрләренә бирeп җибәрделәр. Кем уздырды Идел тамагы аша баскынчы викингларны, өлкән равва? Сез ич!..

—Булды андый хәл, Булат бәк, булды. Әмма үткән эшкә—салават.

Булат бәк өлкән равваның якасыннан җибәрде, арлы-бирле йөреп килде.

—Минем әллә нигә кулым кычыта, өлкән равва. Сез раввалар каханнан котылырга телисез, кахан белән бергә ил дә җимерелмәсме соң?.. Бу хәл илдән мөселманнарны куудан башланмасмы?..

—Без Хазарстаннан синогогларны җимерүдә катнашкан мөселманнарны гына куачакбыз, Булат бәк, аннары аларны котырткан бай мөселман сәүдәгәрләрен, руханиларны, имамнардан алып, мулла-мунтагайларны. Курыкма, Булат бәк, бу чара сезгә кагылмый...

—Ләкин минем халкыма кагыла, өлкән равва, миңә шул туфракта көн күргән халкыма! Бар кеше дә үтә яман карак та, үтә яман диндар да булмый.

—Без төрки кардәшләребезнең кадерен беләбез, Булат бәк, бик яхшы беләбез. Халкыбыз илдән-илгә каңгырып йөргәндә бабаларыгыз безне үз өргәләренә алдылар.

Булат бәк дәшмәде. Өлкән равва хаклы иде. Бу чынлап та шулай була. Булат бәк үзе дә кахан сараендагы мәктәптә равва мөгаллимнәреннән сабак алды. Тик яши-яши кечкенә Хазарстан дәүләтен империя иткән дөнья илләрен вә халыкларын яуларга керешкән Византия, Хәлифәлек куәтле илләргә көндәш булырлык үсте, даны еракларга таралды. Хазарстан белән сәүдә итмәгән халык юктыр. Тик бит шул ук раввалар бүген үзләре зур дәрәҗәгә күтәргән илне таратырга җыеналар. Көн эчендә диярлек бер дәүләттә ике түрә барлыкка килде. Берсе—өлкән равва, икенчесе—кахан. Кайсын якларга тиеш Булат бәк? Борын заманнарда куәтле төрки каханатыннан беренчеләрдән булып, Дулу нәселе аерылып чыга. Дулу өргәсенә кергән баһадир Атилла хан Римгә кадәр барып житә һәм шунда башын сала. Бит аның гаскәрендә Ашин ыруыннан да гаскәриләр була. Беришләре шушы төбәкләргә әйләнеп кайта, аларга көнчыгыштан килгән канкардәшлә-

ре килеп кушыла һәм Хазарстан дәүләтен төзи. Дулу ыруыннан чыккан Кубрат хан исә жиденче гасыр башларында үзенә дәүләт оештыра. Соңыннан бу ике кавем канга-кан килеп сугышалар—тәхет бүлешәләр. Төрки кавемнәренә хас сыйфат бу. Хак, дәһшәтле дәүләт башлыгы Кубрат хан дәүләт оештырып калдыра. Жиденче гасырларда була бу. Тик уллары аталары аякландырып калдырган дәүләтне саклый алмыйлар. Шуңа карамастан, берәм-берәм үз дәүләтләрен оештыруга ирешәләр. Шуларның берсе Идел буе Болгар дәүләте—Дулу ыруыннан килгән куәтле кавем. Менә кемгә таянырга тиеш иде Йосыф кахан, ә ул ызгыш-талаш аша илләрен вә жирләрен югалткан өлкән раввага йөз тота. Хак, яһүд раввалары Хазарстанның дәрәжәсен күтәрделәр—Йосыф кахан идарә иткән дәүләткә дистәләрчә халыклар ясак түли, сөннәтле казаклар да, посканнар да каханга тугырылыклы хезмәт итә. Тик кайчанга кадәр дәвам итәр бу хәл. Бит раввалар үзләре үк төркиләр төзегән дәүләтне жимерергә керешеп баралар. Әйе, чит ил юлбасарларын яллый-яллый. Менә шуны аңламый иде Булат бәк. Түзмәде кала тарханы—өлкән равва янынннан чыгып китәр алдыннан руханиның күзләренә карап болай диде:

—Өлкән равва, борынгы бабаларыгыз кебек безнең бабаларыбыз төзегән илне жимерергә телисез икән, һичьюгы каханбәк Сабир һәм минем белән киңәшер идегез. Мин сезгә моны кылырга бирмәм, өлкән равва. Ишетәсезме, бирмәм!..

Шул сүзләрне өлкән равваның күзләренә бәреп әйтергә дә өлгерми калды, ишектә Йосыф ханның йомышчысы күренде.

—Булат бәк, сезне кахан дәшә. Тиз булыгыз!

—Мин хәзер анда булырмын. Тик башта өске кирмәнгә менеп, тупчыларым, укчыларым, сөңгечеләремне күздән кичерим. Ил өстенә яу килә!

Булат бәк шул сүзләрне әйтүгә, йомышчы яһүд белән өлкән равва күзгә-күз карашып алдылар. Хәер, болай кыю рәвештә өлкән равва белән сөйләшүенә Булат бәк үзе дә: "Минме бу?" дип, үз-үзен тотып карау дәрәжәсенә житеп килә иде инде.

Булат бәк кальганы саклаучыларның һәммәсен дә күздән кичергәч кенә аска төште, артыннан ияреп йөргән раввaларга һәм сөннәтле казакларга да игътибар итми, туп-туры кахан янына юнәлде. Кахан ишегендә торучы сакчылар айбалталарын читкә алдылар һәм килер жайдан Булат бәк тәхет ягына узды. Ул, гадәттәгечә, аяк киемнәрен салып тормады, әмма каханга житәрәк төркиләрчә бер тезенә төште.

—Мин сезнең алда, галижәнапләре!

—Тор!—диде ана Йосыф кахан.—Башта зиндан ачкычын бир!

—Галижанәпләре,—диде Булат бәк аягүрә торып басуга. Ләкин ана Йосыф кахан сүз әйтергә бирмәде.

—Зиндан ачкычын!—дип кычкырды.

Әгәр дә мәгәр аяк астындагы жир идәне-ние белән убыла дисәләр, Булат бәк Йосыф каханның боерыгына ышана төшкән дә булыр иде, ләкин бит кахан анардан—кала тарханыннан зиндан ачкычын сорый. Ә бит кахан аңа ул ачкычны үз кулы белән биргән иде. Булат бәк, биленә таккан күн капчыктан Болгар остасы ясаган ачкычны чыгарды һәм сүзсез генә Йосыф каханга сузды. Ачкычны кулына алуга, Йосыф кахан Булат бәкнең артында пәйда булган раввaларга:

—Зинданга!—дип боерды.

Булат бәк тәмам өнсез калды, аны шундук ике яктан эләктереп алдылар һәм сөйрәп диярлек, зинданга таба алып киттеләр. Булат бәкнең яшен тизлеге белән зиһене аша: "Үзем төзеткән зинданда үтерәчәкләр",—дигән уй килде. Күптән түгел генә Булат бәк үзе бер ярсу йөрәкле сөннәтле казакны шушы зинданга китереп ташлаткан иде. Ишекне дә үзе ачты, яһүд сәүдәгәренең кызын урлаган егетне дә зинданга ташлатып, үзе бикләде. Хак, кахан әмере белән егетне чыгарып жибәрде, әмма ни өчен аны зинданга ташлыйлар? Ни гаебе бар?! Булат бәк белми иде. Теге вакытта кыз урлаган егетне өлкән равва зинданга ташларга боерган иде. Өлкән равва

егетне зинданга ташлатты, ә кахан бу хәлне ишеткәч, Булат бәкне үз кырына чакырып алды һәм егетне чыгарып җибәрергә кушты. Менә хәзер Булат бәкнен үзен зинданга ташлыйлар.

Һәм ташладылар да.

Иң сәере Булат бәк каршылык күрсәтмәде, акланырга да теләмәде. Хәер, кем алдында, нинди гаебе бар иде анын—ул белми иде.

Ишекләр ябылгач, чылтырап йозаклар бикләнгәч, Булат бәк аркасы белән ишеккә сөялде дә, булган хәлгә чарасыз калып, анын җыя алмый торды. Һәм ул кинәт тамагы ертылырдай хәлгә җитеп, бар көченә кычкырып җибәрде. Ләкин берәү дә аны ишетмәде, берәү дә ана җавап бирмәде. Ул белә иде—зиндан елга астында, өстән су ага, тавышны ишетү мөмкин түгел, балыклар исә аңа җавапсыз калачаклар. Әмма ул тагын-тагын кычкырды, тамагы әрнешә башлагач кына, кычкырудан туктап, сыдырылып, арты белән төшеп утырды. Булган хәлгә кинәт кенә ышануы кыен иде. Булат бәк ике якка башын чайкый-чайкый ыңгыраша башлады. Эчке әрнүе шул чиккә җитте ки, йөрәге дөп-дөп тибүгә, колаклары чыңлауга, тамак төбенә яшь төере килеп тыгылды, күзләреннән яшь бөртекләре атылып чыкты һәм яшь бөртеге белән бергә бәгыре катты, ул анын җуйган кешедәй, тораташтай катып калды.

## XVI

Таман ярымутравы тарханы Гали Йосыф каханга дигән хатны әйбәтләп төрде дә мөһерен сукты һәм сөенче йөртүчесе Чатан Чокырга бирде һәм унбашы Сабырга:

—Чокырны син озатасын, бер атналык ризык ал,—диде.

—Мин анда калырмынмы, галиҗанәбем?—диде сөенче йөртүче Чокыр.

—Ислам кардәшеннең йомышын йомышлагач кына, туган туфракка таба юл алырсын, кара аны, кардәшем башыннан бер чәче дә төшмәсен.

—Баш өсте, тарханым, барысы да сез әйткәнчә булыр, Ханбалыкка беренче тапкыр гына баруым түгел.

Әнә шулай алар иртән таң белән Ханбалыкка таба кузгалдылар. Каланы чыгып, олы юлга төшүгә, берара атларын җилле генә юырттырып бардылар да төркем башында барган Чокыр атын Ислам белән янәшә куеп, атлатып кына бара башладылар.

—Әйт әле, Ислам кордаш, яшерми әйт, тархан әйтмешли, чынлап та син Йосыф кахан кулындагы Мөхәммәд хан кызы артыннан йөрисеңме?..—Ислам җавап бирергә авызын гына ачкан иде, Чокыр аны туктатты.—Сабыр ит. Башта мин сөйлим. Канкардәше буларак Гали тархан Мөхәммәд ханны якын итә. Без борынгы төрки бабаларыбыз кавеменнән ич. Гали тарханның бабасының бабасы кара гарәп сәргаскәре Мәрванга каршы сугышкан кеше. Бер сүз белән хөрмәткә ия нәселдән.

—Моның белән ни әйтергә телисең, Чокыр кордаш?

—Гали тарханның әйткәне хак булса, Йосыф кахан авыр хәлдә калган икән. Өлкән равва каладагы мөселманнардан котылырга исәп тотып, яман баскынчы викингларны дәшкән, дигән фараз йөри. Мин шуны да ачыклап кайтырга тиешмен, кордаш.

—Викинглар элек тә баркаслары белән Идел буйлап төшкәләгәннәр. Ил-халкын талаганнар да кире киткәннәр. Ә халык калган, халык янә аякланып, ил-каласын торгызган.

—Ләкин бит хәзерге баскынчылар изге йортларны да җимерәләр, андагы байлыкларны да талап китәләр, ди.

—Минем аларда кайгым юк, кордаш. Миңа бүген Айбибине күрергә кирәк, таш яуса да мин аны күрермен.

—Сарайга үтеп керергә исәбеңме, кордаш?

—Кирәк икән сарайга да үтәрмен.

—Ай-һай, кордаш, Аккалага үтә алырсыңмы икән. Анда синең белән минем кебекләрне энә күзеннән уздырып кертәләр. Ә Айбиби хатын Аккалада,—диде башын чөя төшеп Чокыр.—Айбиби хатын бала тапкан икән ич

инде, җүләр баш, бала тапкан, таштай-тукмактай углан бала! Баш сала торган хыял бу, кордаш, баш сала торган. Биримме үзенә бер киңәш?.. Бир дисәң, тыңла. Мин Аккаланы яхшы беләм. Куенымда Таман тарханы Гали биргән мөһерле хат бар. Мин ул хатны Йосыф каханның үз кулына кертеп бирергә тиешмен. Тархан әмере.

—Димәк, син, Чокыр кордаш, үзең белән мине дә Аккалага алып керә аласың...

Чокыр як-якка башын чайкап куйды, көлемсерәп:

—Һич мөмкин хәл түгел, кордаш. Хатны мин үзем генә кертә алам. Аннары Айбибине күрүем дә шикле, чөнки миннән каханның бүреләре күзләрен дә алмыйлар.

—Нинди бүреләр?

—Раввалары.

—Ә миңа калса, Сарайны сөннәтле казаклар саклый.

—Сөннәтле казакларны беркайчан да сарайга кертмәделәр. Сөннәтле казаклар бары тик ялланып кына сугышалар, Ислам кордаш. Сарайны Таман тархан яугирләре саклый, безнең егетләр!

—Сират күперен үтәргә кирәк икән, мин сират күперен дә үтәрмен, әмма Айбиби кырына узармын, Чокыр кордаш.

Әлегә кадәр уйнап-шаярып кына сөйләшеп килгән Чокырның Исламга ачуы килдеме, беравык дәшми барды. Ул бераз аптырашта калган иде. Бер бала тапкан хатынга шулай дивана хәленә калып гашыйк булу мөмкин хәлме?.. Мөмкин булса, сәламәтме ул егет, ягъни үз акылындамы?.. Чокыр шулай уйланып барды-барды да янә Ислам ягына күз төшереп алды, янәсе, чынлап та үз акылындамы син, егет. Юк, җитди сөйләшә егет, сагышы йөзенә үк бәреп чыккан.

—Аккалага үтәргә бер юл бар-барын, кордаш Ислам.

—Нинди юл?—дип, иярендә күтәрелә төште Ислам.

—Ул юлны минем атам сала. Елга астыннан үтә ул юл. Туп-туры сарайга алып керә. Булан кахан чорында була бу хәл. Анда эшләгән кешеләрнең Булан кахан барысын да кылычтан уздырта. Ә менә атама тими. Беркемгә дә дәшмәскә, әйтмәскә дип ант иттерә дә иленә кайтарып җибәрә.

—Бу чынлап та шулаймы, Чокыр кордаш!

—Чокыр беркайчан да ике сөйләмәде, Ислам кордаш. Күрдем ич, син чынлап та Йосыф кахан хатынына гашыйк. Мәхәббәткә хыянәт иткән кеше тәмугъта яначак, ди иде минем атам. Кем, кайсыгыз хыянәт итте яшьлектәге мәхәббәтегезгә?.. Курыкма, дөресен әйт?..

—Минем аны гаепләргә хакым юк, кордаш. Айбибине атасы Мөхәммәд хан кахан равваларына биреп җибәрде. Калганы миңа караңгыдыр.

—Бәлкем ул үзе теләп Йосыф каханга... Кеше күңеле карурман, диләр бит.

—Мин аны яраттым, мин аңа үлепләр гашыйк булдым, Чокыр кордаш, үлепләр гашыйк булдым. Мин аны күреп сөйләшмәсәм, аның авызыннан ихлас сүзләрен ишетмәсәм—үләчәкмен. Кайда, ни сәбәпле—белмим. Ләкин мин кылыч йөзеннән булса да Сарайга узарга һәм сөйгәнемнең күзенә карап: “Син, Айбиби җаным, мине оныттыңмы әллә?” дип сорарга тиешмен.

—Мин аңладым син дивана башны, ни өчен чәчкә кебек Хәдичә хатынны туган иленә озатканыңны аңладым. Ә бит ул синең күзеңә генә карап тора иде. Син, җүләр баш, нидер әйтерсең дип, алып калырсың дип!..

Ислам, бик ихтимал, беренче тапкырдыр, Тәңресе алдына төшкәндәй Аллаһысына мөрәҗәгать итте: “И Ходаем, бир миңа куәт, бир миңа көч, өстә кодрәтең колыңа—бир мөмкинлек сөйгәнемнең йөзенә багарга. Мин анардан бары тик бер сүз сорармын: оныттымы мине, Идел буең, аккошларың?! Әллә яшьлек мәхәббәтең мәңгегә йөрәгеннән җуйдымы? Жуеламы икән кеше күңелендә язгы ташкын сулары кебек йөрәк түренә кереп оялаган сафтан-саф мәхәббәт!..

* * *

Чокыр шапырынмаган икән, Аккалага җитүгә, аларны карусыз күпердән уздырдылар. Сөенче йөртүче Чокыр атыннан төшми генә аларга Таман тархан мөһер суккан хат-төргәкне күрсәтте, ә Исламны минем жансакчым дип янәшәсендә тотты. Сакчылар Таман тарханы Гали бәкне яхшы беләләр иде, көймәле күпердән генә түгел, аларны сарай капкасына кадәр уздырдылар. Сакчыларга якыная башлауга, Чокыр хат-төргәкне баш очына күтәреп:

—Таман тарханы Гали бәкнең Хазарстан каханы Йосыф каханга сөенче хаты!—дип кычкыра-кычкыра сакчыларга хатны бирә, тегеләр мөһерне карыйлар да төргәкне ана кайтаралар. Ни кычкырса да, ни шапырынса да Сарай сакчылары Исламны кахан кырына уздырмадылар, ә Чокыр һаман кычкырды.

—Кычкырма ул хәтле,—диде сакчыларның берсе.—Каханның улы Ибраһимны уятуың бар,—дип куйды очлым башына тутый кош каурые элгән сакчы.

—Кырык хатынга бер генә улымыни?—дип шаяртырга теләде Чокыр, әмма аның авызын бик тиз капладылар.

—Бер хатын белән яши хәзер кахан, бер хатын белән. Бик күп кычкырсаң, богаулап алырым да үзеңне Ханбалыкка озатырмын, тагылып йөргән якташыңны әллә кайчан суга ташладык инде.

—Карале, Атнабай, кордаш бит син? Нигә алай бик койты сөйләшәсең? Атаң хат яза белми, сина әйтергә кушты, туганнарга каты бәрелмәсен, Тәңре алдында каргармын үзен диде. Атаң синең акыл иясе, хөрмәткә ия зат иде. Син дә, мин әйтәм, үскәнсең, кахан сарае кадәр кахан сараен саклыйсың, әй!

Сакчы Атнабай аны әллә тыңламый иде, әллә тыңлап юри ишетмәгәнгә салышты, төргәкнең мөһерен әйләндерә-тулгандыра карады да:

—Ярлык-тәңкәң үзең беләнме?—дип сорады.

—Ярлык-тәңкәсез йомышчы буламы, кордаш. Менә ул! Бак! Кахан үзе мөһер суккан.

—Кахан сине кабул итәр, ләкин башта өлкән раввага күренерсең. Искәрдеңме, кордаш!

—Искәрми буламы...

Йомышчы Чокыр сарае мәйданын үтүгә, өлкән равва ишегенә юнәлде, ишеген шакыды. Аңа баш түбәсен ак чәпләшкә белән каплаган сакалмыексыз хәрам атакай ишек ачты.

Чокыр бусаганы атлап узды һәм өлкән раввага күзе төшүгә, бер тезенә чүкте.

—Галиҗанәпләре өлкән равва, Таман тарханы Гали бәк Йосыф каханга хат юллаган иде.

—Үзең кертеп бир!—дип кырт кисте өлкән равва. Чокыр сикереп торды, ишектән чыгып, кахан бүлмәсенә таба атлады. Ишекъяры ике айбалта тоткан сакчы тора, айбалталарын чалыштырганнар. Чокыр аларга мөһерле төргәкне күрсәтте, әмма бер сүз дә әйтмәде, чалышкан айбалталар ничек бар шулай калды. Ишек ачылды, аннан бер равва чыкты. Хатны Чокыр кулыннан алды да "кит" дип, кул селтәде.

—Мин каханга хатны үзем бирергә тиешмен, равва.

Равва хәтта ана таба күз дә ташламады, борылды да тәхет ягына кереп китте.

—Миңа китәргәме?—дип сорады айбалта тоткан сакчылардан Чокыр, ләкин алар каткан агач кебек тик тора бирделәр. Чокыр бер урында таптанып алды һәм кире борылды. Ислам аны күпер башында зарыгып көтеп тора иде инде.

—Минем эш бетте, хат кахан кулында, мин буш,—диде Чокыр.—Әйдә, калага чыгабыз да тамак ялгап алабыз.

—Яугирләр белән нишлисең?—дип сорады Ислам.

—Мин аларны кайтарып җибәрәм, ә синең белән, әйтәм бит, Болгар

базарында ашап чыгабыз, шуннан соң синең кайгыңны кайгыртырбыз,— диде Чокыр.

Тамак ялгап чыккач, Идел елгасының сулъяк ярына урнашкан өйләр яныннан бара-бара бер тыкрыкка килеп чыктылар, тыкрыктан елга буена төштеләр. Яр буенда көймәче тора, Чокыр әкрен генә аның янына юнәлде, ә Ислам аның артыннан титаклады.

—Менә нәрсә, кордаш,—диде ул көймәче янына житүгә.—Бу егеткә Аккошлар култыгына эләгергә кирәк. Бәһадән тормас.

Көймәче мыегын сыпырып алды, килеште, Исламны ым кагып кына көймәгә узарга дәште. Ислам кузгаласы иткән иде, Чокыр аның җиңеннән эләктереп алды.

—Тукта, сабыр ит. Мин сиңа елга астыннан юл уза дип әкият сөйләмәдем. Менә сиңа су асты юлына ачкыч. Атам миңа аны истәлек итеп калдырган иде. Искәр: йозакны ачканда бер тапкыр уңга, ике тапкыр сулга борасы. Бу булыр—бер. Икенчедән, табибә киеме үзең беләнме?

—Капчыгымда,—диде Ислам көймәчегә карап.

—Аккошлар култыгына житкәндә эңгер иңгән булыр. Эңгер иңүгә, көймәче сине Аккошлар култыгына кертер. Комлыктан ерак түгел, каханның чатыры бар. Кеше-кара булмаса, шул чатырга кер дә өстеңне алыштыр. Тик сак бул, кеше-фәлән күренсә, хатын-кыз кебек яулык очың белән авызың капла. Исәнләшмә, тын гына үтеп кит. Башта Айбиби хатын бүлмәсенә кагыл, Айбиби анда булмаса, сарайга үт. Әйе, зур сынау узасың бар, кордаш. Сиңа кахан ятагына узарга туры килер, ә анда сакчылар. Гадәттә алар кахан янына кергән хатын-кызны туктатмыйлар. Сарайда инде шәмнәргә ут салган булырлар. Салмаган булсалар, шәм салучыны көтеп тор һәм Айбибине сора. Мин аның табибәсе, каханбикә дәшкән иде диген. Ул сине Айбиби бүлмәсенең янына ук илтеп туктатыр. Эчкәре кермәс, чөнки хәрам атакайларга кахан хатыннары кырына керергә тыела. Айбиби хатын кахан ятагында дисә, шәм салучы дип, ишекне шакымый гына кер, мыштым гына. Сакчыларга игътибар итмә, синең өчен алар юклар. Калганы Тәңре кулында, йә исән-имин Айбиби кырына барып басасың, йә...

—Аңладым, кордаш.

—Ул-бу була калса, сарайның елгага таба төшә торган тарлавыгы аша кахан зинданына йөгер. Анда тоныкк кына шәмнәр янар. Ишеккә килеп төртелүгә, йозакны ач та су юлына кер. Эчкәре үтүгә, шудыргычны этәреп куй. Куй дим. Зиндан су юлына барып төртелергә тиеш. Анда да ишек, ләкин бикле булмаска тиеш. Атам шулай дигән иде. Анда эләксән, ул юл сине туп-туры Ханбалыкка алып чыгачак. Ханбалык яклап су астына керәсе капкада безнең кордашлар тора... Калганын Аллаһыга тапшыр. Иншалла, хәлеңә керерләр. Юк, син алар янына хатын-кыз киемендә чыкма инде, кордаш. Өстең алыштыр, тегеләрнең шикләре төшүе бар. Каханның бер хатыны шул юлдан качарга ниятли, ләкин сакчылар кулына эләгә... Калганын үзең беләсең... Күптән булган хәл, халык әле булса гыйбрәт итеп сөйли... Исән-имин Ханбалыкка чыксаң, Болгар базарындагы Шәрык мәчетенә кер. Шәрык мәчетен кахан җимертергә кушса да, соңыннан, тимәскә кушкан дигән хәбәр ирешә. Калганын үзең беләсең, Болгар базарындагы сәүдәгәрләргә ияр дә иленә кайтып кит. Шул булыр минем сиңа киңәшем, шашкан мәхәббәт диванасына...

Чокыр аны кочагына алды, хәерле юл теләде һәм колагына:

—Шулай баш алыр дәрәҗәгә житеп гашыйк булып йөрүеңә мин көнләшәм, кордаш!—дип, Исламны көймәгә таба этәреп җибәрде.

* * *

Аккала янына житкәндә эңгер иңгән иде инде. Комлыкка килеп төртелүгә, Ислам көймәдән төште, төенчеген чишеп, көймәчегә дүрт көмеш дирһәм сузды. Рәхмәт әйтте. Ул аңа көймәгә утыргач ук алты дирһәм бирәсе иткән иде, ләкин сөйләшкәнчә дүртне генә бирде. Көймәче, ашыга-ашыга ишеп китеп баргач, Ислам дәшергә кыймады, учын кыздыра башлаган

ике дирһәмне суга ташлады. Догасын укыды. Инде караңгы төшә башлаган булса да, кахан чатыры күренә иде әле. Ислам шунда таба атлады. Кыю рәвештә, чатыр япмасын ачып, эчкәре үтте. Тиз-тиз генә хатын-кыз киемен киенеп, ир-ат киемнәрен төенчегенә бәйләде дә чатырдан чыкты. Сарай яклап таштан сукмак түшәлгән, шул сукмактан әкрен генә сарайга таба кузгалды. Һәм атлаган саен үз-үзен тынычландырды. Курыкма, сиңа кем дә тимәс. Син кахан хатыны Айбибинең табибәсе. Әмма сарайга якынайган саен йөрәге ешрак тибә башлады. Күр әле, сарай тирәсендә бер генә җан иясе дә юк. Ишекъяры житкәч, бертын йөрәк тибешен тоеп, туктап торды. Ахыр сарайның ишеген ачты, эчкәре үтте. Ишек янында ук шәмнәр яна, шәмнәргә ут салучы аларны кабызып кына йөри иде әле, Ислам аның янына узды һәм кыяр-кыймас кына:

—Мин Йосыф кахан хатынының табибәсе, шәм салучы, миңа аны табарга кирәк,—диде.

Шәм салучы хәтта аңа әйләнеп тә карамады.

—Каханбикә Йосыф кахан кырында, кояш баер алдыннан гына кереп киттеләр. Хәзер инде сиңа, табибәкәй, иртәнгә кадәр көтәргә туры килер, чөнки...

—Мин аны күрергә тиеш, ул авырып тора иде, үзе мине дәштерде,—диде Ислам тавышын нечкәртә төшеп.

—Алайса, әйдә, үзем озатам,—диде шәм салучы һәм алдан китте.

Шәм салучы артыннан атлаганда Исламга янә курку килде. “Күр инде, Чокыр кордаш әйтмешли, ул чынлап та баш китәрдәй эшләр кылып йөри икән ич...”

—Менә бу ишекне ачасың да керәсең, хөрмәткә ия табибә, тавышың матур, үзең дә чибәрсеңдер инде...

Ислам аңа җавап бирмәде, ишекне әкрен генә ачты да эчкәре узды.

—Кем бар анда?—дип сорады бер хатын-кыз, Ислам шундук Айбибинең тавышын таныды.

—Мин бу, мин, синең якташың Ислам,—дигәнен сизми дә калды. Тавыш түр яктан килгән иде, чыгучы булмагач, Ислам тынып калды. Чөнки ул бер ялгышны җибәргән иде инде. Ләкин шундук икенче бер ишектән ике равва килеп чыктылар, җилле генә аңа таба юнәлделәр. Исламның коты алынды, ул тиз генә ишекне ачты да чыгып йөгерде. Чокыр әйткәнчә, елга ягына таба. Йөгерә торгач, ниндидер ишеккә төртелеп, туктады, дөп-дөп итеп типкән йөрәге ярсудан гаҗиз калып, ишекнең йозагын капшап тапты. Шул вакыт артында аяк тавышлары ишетте. Ул арада эчкәре яктан берәү:

—Зинһар, зинһар ачыгыз, минем бер гаебем дә юк. Юк! Зинһар...

Ислам ачкычны кесәсеннән алды, калтыранган куллары белән йозак тишеген эзли башлады. Тапты. Ачкычны тыкты. Әмма ишеккә үк беркетелгән йозак ачылмады. Ә артындагы аяк тавышлары колак төбендә үк кебек иде инде. Шунда кинәт, Чокырның бер тапкыр уңга, ике тапкыр сулга борырга дигән сүзләре хәтеренә төште. Һәм шулай итте, ишек ачылды. Тик инде аһ-ух килә-килә аның артында: “Тукта! Тукта! Кем син!”—дигән аваз ишетелүгә, каерып ишекне ачты. Ишекне ачуы булды, берәү аны эләктереп алды һәм эчкәре суырды һәм бар көченә ишекне япты да шуыргычны этәреп куйды. Тышта кычкырдылар-кыркырдылар да китеп бардылар. Эчтәге кеше, ниһаять, аваз салды, Исламны капшап карады.

—Йа Ходай, хатын-кыз. Кем син, кахан җариясеме?

—Мин хатын-кыз түгел, мин ир-егет, Мөхәммәд хан табибы улы Ислам,—диде егет ары таба ни әйтергә белми куркып.

Ишеккә тагын килеп орылдылар.

—Булат бәк, Булат бәк, ишекне ач, Кахан сине кичерде, кичерде,—дип кычкыра башладылар.

—Кем син Алла бәндәсе. Хәер, кем генә булсаң да син мине коткардың, агай-эне, коткардың. Кем сине ташлады зинданга?

—Мин үзем кердем, үзем...

—Үзен?!—дип сорады исе-акылы китеп Булат бәк.—Үзен?!

—Кем сиңа ачкыч бирде, кахан үземе?

—Таман тарханы йомышчысы Чокыр. Мин Айбибине эзләп килдем, Булат бәк.

—Йосыф кахан хатыны Айбиби! Кем була ул сиңа?

—Минем яшьлек мәхәббәтем ул, тәүге мәхәббәтем.

Булат бәк арты белән жиргә утырды, маңгаен кулларына салды, икенче мәлдә инде Исламның аякларын кочаклады.

—Мәхәббәт юлында йөргән изге зат син, Ислам кордаш. Барысына да ышанып була, ләкин инде бер бала тапкан хатын артыннан шулай йөрү—мөмкин хәлме, балакай! Житмәсә ул хатын кахан хатыны! Шул хыялың аша Кахан зинданына килеп керүеңне мин берәүгә дә аңлата алмам, егетем. Тик шуны беләм, син минем коткаручым, Аллаһы Тәгалә җибәргән изге зат син, егеткәем! Ә хәзер син өстең алыштыр, хәтерем ялгышмаса, Айбиби хатынны Йосыф кахан баласы вә абыстае белән Идел буе Болгарына кунакка җибәрергә җыена, дигән хәбәр ирешкән иде миңа. Шуның өчен сиңа да, миңа да моннан котылу жаен эзләргә кирәк, егетем.

—Чокыр кордаш, әйткән иде кахан зинданы елга аша су астыннан үткән юлга барып чыга дип. Хак булса...

—Минем дә ишеткәнем булды ул хакта, ләкин әлеге юл аша Ханбалыкка чыкканым булмады. Зинданның су юлы капкасында сакчылар йөзендә каханның җәлладлары торалар. Менә анысын мин беләм, егетем. Бик яхшы беләм. Ләкин алар һәммәсе дә миңа буйсыналар иде. Әйе, иде...

Булат бәк аягына басты, кесәсеннән чакма ташы чыгарып, ут алды, уң яктагы майлы пумаланы алып, ут салды.

—Без нишлибез хәзер, Булат бәк?

—Шул юлны эзләп китәбез, зинданнан су асты юлын. Ханбалыкка чыга торган юлны. Киттек.

Булат бәк шәмдәлен Ислам ягына юнәлтеп, өс-башына игътибар итте.

—Мин киендем инде, Булат бәк.

—Бик әйбәт. Тик ишеккә житкәч, җәлладлар капкасы алдында мин синең өс-башың ерткалап, авызың сугып канатырмын, егетем. Әйе, син минем әсирем. Мин сине казыйга илтәм, хөкем итәргә.

—Ни өчен?

—Ярлыксыз Аккалага үткән өчен, егетем. Әйдә, кузгалдык.

—Мин Мөхәммәд хан кызы Айбибигә гашыйк идем, Булат бәк,—диядия аның артыннан кузгалды Ислам.—Мин аны бер күрү өчен үләргә дә әзер.

—Башта без, егеткәем, бу мәхшәрдән котылыйк. Ярты ел эчендә каханатның асты-өскә килде. Ата—улны, ана—кызны белми башлады. Раввалар сөннәтле казаклар ярдәме белән Ханбалыктан мөселманнарны куа башладылар. Күрәсең, сарайда хезмәт итсәм дә аның очы миңа да килеп ялганды. Безгә ничеккенәләр булса да моннан таярга кирәк.

—Кай тарафларга, кая?

—Болгарга, бабаларыбыз Йортына, егеткәем. Иң элек раввалар кулыннан ычкынырга кирәк, раввалар кулыннан. Хәтерем ялгышмаса, су асты юлына ишек шул тирәдә булырга тиеш,—диде дә Булат бәк, сул кулы белән Исламның авызына тондырды, теге йөзен каплап торганда бер җинен умырып төшерде.—Менә шулай.

—Кан китте бит, Булат бәк, авыздан кан китте.

—Авыздан тиз генә кан китми, борыннан китә, егетем. Түз. Әйдә, ары таба киттек, калышма.

Чынлап та Булат бәк ерак та китми, ишеккә тап булды. Ишекне ачар алдыннан Исламның башыннан эләктереп алды да ишекне ачты.

—Һа-а!—диде ишекнең су юлы ягында торган җәллад.—Булат бәк үзе. Безгәме китерден?

—Юк, казыйга илтәм, башта ул хөкем чыгара.

—Калага үткәнме, елга ашамы? Кичә без көймәчене тоттык инде, балык-

ларга ташладык.

—Шәп иткәнсез,—диде Булат бәк һәм җәллад янынннан үтеп китте.

Кала капкасы янында да Булат бәкнең егетләре тора иде, ул анда да Исламны сөйрәп китерде.

—Кемгә булса да һөҗүм иткәнме әллә, Булат бәк?

—Өлкән раввага ташланган, өлкән раввага.

—Казыйга илтәсең, димәк. Бит казыйны кудылар түгелме соң, Булат бәк?!

—Казые булмаса, раввасы табылыр, кайгырма, кордаш. Хөкемдарсыз дәүләт булмый.

—Анысы хак,—диде сакчыларның берсе ишекне ача-ача.

Калага чыгуга, Булат бәк Исламны җибәрде, канлы авызын сөртергә кесәсеннән кульяулык алып бирде.

—Сөртен дә, әйдә тизрәк Болгар базарына, Шәрык мәчетенә.

Базарга тиз килеп җиттеләр, урамда халык юк диярлек, халык олау-олау каланы ташлап китә. Мәчеткә җиткәч, киң капканы ачып, эчкәре үттеләр. Мәчет баскычларыннан менеп, ишекне ачтылар. Аларны мәзин каршы алды.

—Әйдүк, әйдүк, Булат бәк. Мулла сезне көтә.

—Ничек көтә?!—дип туктап калды Булат бәк.

—Безгә җиткерделәр инде, сезне... кһм...

Булат бәк мәзинне тыңлап бетермәде, башындагы каешланып беткән түбәтәенә кагылып, күзенә кадәр төшерде дә түр яктагы мулла ишегенә таба атлады. Ишекне ачып керүгә, аңа таба мулла кузгалды.

—Йа Алла Мөхәммәдрәселулла, Булат бәк. Котылдың?..

—Котылдык, котылдык, меллам. Менә бу егет коткарды. Мөхәммәт ханның табиб улы Ислам.

Мулла Ислам ягына күз төшереп алды да:

—Башта дога кылыйк, Булат бәк,—дип түмәргә утырды.

Дога кылгач, янә исәнләштеләр, хәл-әхвәлләрен сораштылар.

—Мине, меллам, калада барган хәлләр кызыксындыра?

—Тынычлан, Булат бәк. Хәзер өс-башыгызны алыштырыгыз. Юыныгыз. Ашап-эчеп алыйк. Шуннан соң барысын да җайлап сөйләшербез.

—Ат-корал булырмы, мелла?

—Аты-дирбиясе дә, коралы да булыр, Булат бәк. Каханга ялланган сөннәтле казаклар Харәзем базарындагы сәүдәгәрләрне каладан куа да башладылар инде. Болай орыш-сугышсыз гына куалар дип ишеттем. Иншалла, без дә исән-имин чыгып китәрбез, Булат бәк. Мин егетләремне дә хәзерләп куйдым инде.

* * *

Иртән аларны мулла уятты.

—Торыгыз, Булат бәк. Кузгала башларга кирәк. Сөннәтле казаклар елга буендагы мәчетне туздырып ташлаганнар. Алдан раввалар йөри дигән сүз дә ирешге.

Булат бәк сикереп торды, аннан-моннан битен-башын юды да Исламны ияртеп ишегалдына чыкты. Ишегалдында ун-унбишләп җайдак егет тора, дирбияле ике атның тезгеннәреннән тоткан мәзин көтә иде. Булат бәк аның кулыннан сугышчы киемнәрен тартып алды да, кире ашханәгә керде, тиз генә киенеп, ишегалдына чыкты. Ислам аңардан бер тотам да калмый йөрде.

Мулла хәзрәтләре мәчет болдырына чыккан да намазлык өстендә аларга якты юл теләи. Булат бәк сикереп атына атланды, мулла намазлыгыннан торып, аягүрә басты.

—Оланнар, кордашлар, мөэмин-мөселманнарым, Йосыф кахан раввалары йөз оятларын югалтып, безне каладан куа башладылар. Орышмый-сугышмый гына чыгып китик, Аллаһның кодрәте илә раввалар үз акылларына килерләр, иншалла. Бүген исә алар иблис коткысында. Булат углан, мин сиңа үз егетләремнең язмышын тапшырам. Каладан чыгарак, елга буендагы мәчеткә кагылып китәрсез. Иртән шул тирәдә раввалар белән

сөннәтле казаклар йөргәннәр иде. Мәчет мулласының хәлен белеп китәрсез. Ак юл сезгә, оланнар.

—Сез, сез беркая да китмисезмени, меллә абзый?

—Мин мәчетемне сакларга калам, Булат углан. Мәчет язмышы, минем язмышым. Ходай язганы булыр. Өнемә качарга мин йомран түгел. Казаклар очрасалар, орышмагыз, узып китегез. Акыллы кеше корал күтәрмәгән кешегә тимәс. Хушыгыз, оланнар!..

Кузгалдылар. Булат бәк мәчеттән берара киткәч, атын җилле генә куалап, елга буендагы мәчеткә юнәлде, аңа кырыклап яраны иярде. Кырык яугир белән генә сугыш вә орышларда азау тешләре чыккан казакларга каршы торып булмас, ләкин инде Булат бәк тәвәккәлләгән иде. Азлармы, күпләрме—ул беренчеләрдән булып орышка ташланыр. Калганы Ходай кулында.

Елга буе урамына борылуга, алда утызлап казак күренде. Сөннәтле казаклар урам уртасына ук туктаганнар, гүя урамга аркылы ятканнар иде.

Казакларга житәрәк, Булат бәк туктады, кынысыннан кылычын суырып чыгарды. Бу инде орышка ишарә иде. Сөннәтле казаклар аны таныдылар—Аккала белән Ханбалык тарханы, кайчандыр төмәнбашмы, меңбашмы булган. Кылыч белән ут уйната, уктан очкан кошны ала. Ләкин бит куркып чигенгән сөннәтле казакларга үлем. Кахан кануны.

—Һәй, казак туганнар, посканнарданмы, сөннәтлеләрдәнме сез?.. Уздырыгыз безне. Мин—сезне күрмәдем, сез—безне. Китегез юлымнан!..

Казаклар үзара киңәшеп алдылар. Кайсыдыр батыр бәккә юл бирергә киңәш итте, күрәсең, атларын якындагы тыкырыкка бордылар. Булат бәк кылычын кынысына тыкты, камчысы белән атына сыдырды.

—Элдер, малкай!

Ишләре аңа иярделәр. Елга буендагы мәчеткә житәрәк, Булат бәк атын тыя төште, ишләренә әйләнеп карады. Ым кагып кына Исламны янына дәшеп алды.

—Басу капкасында раввалар чуала. Син алдан кузгал, ә мин елга буйлап, артларыннан төшәм.

—Икегә бүленәбезме?

—Юк, син егетләр белән китәсең, мин берүзем. Инде сезне уздырмыйлар икән, орышыгыз.

Ислам алдан китте, яугирләре аңа иярде, Булат бәк исә, кемнендер тыкырыгы аша, Идел елгасына таба төшеп китте.

Капкага житәрәк, Ислам атын тыя төште, җәясенә ук элде. Ул күрде: капкада ике равва тора, кулларында сөңге, ләкин арырак өч-дүрт казак утыра, атларын чирәмгә утларга җибәргәннәр. Җәясенә ук элгән бер төркем яугирләр капкага килеп житсәләр дә, ни өчендер сөннәтле казаклар кузгалып та карамадылар. Капкада торучы раввалар исә сөңгеләрен чалыштырдылар. Сөңгеләрен чалыштырулары булды, алар өстенә кырыклап ук очты. Раввалар егылды. Сөннәтле казаклар атларына атландылар да елга ягына таба чаптылар. Ләкин аларны Булат бәк көтеп торган икән, казакларның барысын да укка ала башлады.

Булат бәк Исламга кул изәде, ә үзе елга буена таба чапты. Анда унлап равва көймәләргә төялеп маташа, ашыгалар, кабаланалар иде. Килер җайдан Булат бәк аларның икесен укка алды, өчесе исә көймәгә утырып, ашыга-ашыга Аккалага таба ишә башлады. Аның янына Ислам килеп житте, ул да көймәгә таба ук атты. Ләкин Булат бәк кулын күтәрде.

—Ук белән елганы тутырып булмас, укларның кирәге чыгар әле, кардәшләр,—диде.

—Хәзер кая, Булат бәк?

—Елга буендагы мәчеткә, бәкләр урамына!

Мәчеткә килеп житәрәк күренде: капка янында ук мәет ята. Булат бәк атыннан төшеп, мәетне бер читкә алып куйды да мәчеткә таба китте. Ислам аны куып житте.

—Булат бәк, сине кахан кичергән дә булыр иде.

—Кахан равваларга әсир төшкән кеше, табиб Ислам. Үз вазифасын үтә-

мәгән каханны һәрчак ефәк бау көтте. Мина калса, ул да чарасыз калгандыр.

—Карга карганың күзен чукымый, Булат бәк.

—Мине кахан түгел, өлкән равва Ибраһим зинданга ташлатты, табиб Ислам,—диде дә Булат бәк йөгерә-атлый баскычлардан өскә менә башлады.

Ишек янында аркасына ук кадалган мәзин ята, акайган күзләре белән манара башындагы яшелгә буялган айга төбәлгән. Мәчеткә керделәр. Керделәр дә тәмам өнсез калгандай, биредә булган хәлгә таң калып, бермәл карап тордылар. Күренеш яман иде: мәчеткә сөннәтле казаклар белән раввалар халык намаз укыганда килеп кергәннәр булса кирәк, күбесенең башлары гәүдәләреннән аерылган иде, гәүдәләре тезләнгән килеш каткан, аяк астындагы келәмдә кан күлдәвекләре.

Исе-акылын җуяр дәрәҗәгә җитеп, булган мәхшәргә карап торганда беренче булып Ислам сүз катты.

—Булат бәк, кардәшләребезне ишегалдына чыгарып җирлик тә юлыбызны дәвам итик. Каханның безнең өскә равваларын җибәрүе бар.

—Әйе, әйе, табиб Ислам. Җирлик тә китик. Һәм тизрәк. Бар, көрәкләр барлый тор, егетләргә кабер казырга куш, мин шәһит киткән мөселманнарымны чыгара торам.

Кабер әзер булгач, һәммә шәһит киткән мөэминнең дә башын гәүдәсенә җайлап, иплләп кенә кулдан-кулга кабергә төшерделәр. Бер яугир мәдһи булып чыкты, дога укыды һәм шәһит киткән мөселманнарны дәшми-тынмый гына күмделәр дә атларына таба кузгалдылар. Табиб Ислам кызышкан кулларының калтыравын тоеп, аты янына килүгә, уч төбен ат ялы астына тыгып торды—тынычлана төште.

Ул арада Булат бәк:

—Атларга!—дип боерды.

Җилле генә юырттырып, Идел елгасы буйлап тезелеп киткән Бәкләр урамына таба киттеләр. Күп тә үтми, Булат бәк сарыга буялган капка каршына килеп туктады һәм кычкырып җибәрде.

—Анасы! Бу—мин, ач капканы!

Капка ачылды, Булат бәк яраннары белән ишегалдына үтте. Ул арада Булат бәк янына өстенә камалы камзул кигән хатын килде.

—Ни булды, атасы?!

—Анасы, хезмәтчеләренә, карачыларыңа әйт, егетләремә ашарга хәстәрләсеннәр. Ә үзең кирәк-яракларыңны җыештыра тор. Китәбез, йортны ташлап китәбез. Илгә яу килә.

Хатын аһ итте дә ике кулы белән йөзен каплады. Әмма бик тиз исенә килде, атларыннан төшеп, тезгеннәрен киртәгә бәйләп торган хәрби киемдәге егетләрне күрде дә ашыгып кереп китте. Әмма болдырга җитүгә, кисәк туктады һәм борылып:

—Атасы, кай тарафка?..

—Болгарга, Болгарга, анасы. Ашык!.. Иң кирәкле әйберләреңне генә ал.

Барысы да җыелгач, ашап-эчкәч, кай тарафтандыр капка карачысы килеп чыкты.

—Син кайда йөрисең эт ялаган нәмәстәкәй!—дип ябырылды аңа ачуы ташкан Булат бәк.—Олау башында бул!—Булат бәк урам якка чыгып, кузгалырга әзер булган олауга күз ташлап алды:

—Кузгалдык!

Олы юлга төшкәч, атын куаламый гына барган Булат бәк белән Ислам тигезләште. Булат бәк берничә тапкыр артына әйләнеп карады, матур итеп, манаралап салынган өй ерактан ук күзгә ташлана иде.

—Өйне үзебезнең Болгар осталары салды. Мөэминнәрне җирләгән мәхәллә мәчетен дә мин күтәрткән идем, үз исәбемә. Такта-агачны Казан тирәләреннән сал белән китерткән идем. Күрдеңме өемне, көлеп тора кебек, алтын куллы осталар эшләгәч. Шуның өчен каерылып карарга куркам, әмма йөрәк түзми, йөрәккә кан сава. Ә бит мин, Ислам туган, хезмәтемне

Мөхәммәд хан сараенда башлаган идем. Бермәлне, бәйгеләр уздырганда, кахан кешесе мине күзәтеп торган. Анда мин беренче урынны алган идем—уктан алуда да, сөңге ташлауда да, кылыч белән алышуда да, көрәштә дә. Әнә шул кеше мине Аккалага тарттырды. Әлбәттә инде Мөхәммәд хан риза булган. Менә шулай мин сарай куштаны булып киткән идем. Өй күтәрттем, мәчет салдырдым һәм елга буйлап "Бәк"ләр урамы булдырдым. Тукта, сез бара торыгыз, мин Мөслимә абыстайның хәлен белеп килим әле. Бик кайгырмасын, баш исән булсын, мал булыр ул. Мал хезмәт яраткан кешедән йөз чөерми...

Мөслимә хатынның хәлен белеп, җәмәгатенең кайгысын уртаклашып, бераз тынычландырып килгәч, Исламның ни турында уйлап баруын белгән кебек, Булат бәк:

—Табиб Ислам, табиб Ислам дим. Без Яңа Саксинга керәбезме, үтеп китикме?—дип сорады.

—Бу калада борынгы Биләмҗирдән күчеп утырган халык яши бугай бит, Булат бәк.

—Әйе, безнең борынгы бабаларыбыз. Тик хәзер бу каланы кыпчаклар басты. Элек угызлар, баҗайлар ыстан торалар иде. Хәзер монда барысы да буталып бетте инде, Ислам туган. Иң гаҗәбе, бу калада кахан баскакларын тотмый, ясак җыярга да яһүд сәүдәгәрләрен җибәрми, саксиннарның үзләреннән җыйдырта.

—Эти дә шулай ди торган иде аны.

—Дала халыклары каласы бу. Бер генә сәүдәгәрнең дә бу каланы читләтеп үткәне юктыр. Викинглар да бу калага баш тыгарга курка, әйе, нә явыз халык булса да куркалар.

Ул арада алар янына җилле генә юырттырып, ат менгән бер углан килде.

—Ярдәм итегез, атам, бер арбаның көпчәге ватылды.

—Җай көпчәк юкмыни?

—Бар-барын да арбаны күтәрә алмыйбыз.

Булат бәк Исламга карады.

—Барып киләбезме?

Ислам сүзсез атын бора башлады. Көпчәге ватылган арба янына тиз килеп җиттеләр, җыелышып, бер сулыштан арбаны күтәрделәр дә, күчәргә дегет сөртеп, көпчәкне кигерделәр. Ислам арба тирәсендә боҗырдай йөгереп, теге йә моны кылырга әмер биреп торган Булат бәкнең улына игътибар итте.

—Улың сарай мәктәбендә укый идеме, Булат бәк? Аты ничек әле?

—Хәбир, Хәбир атлы. Ушлы малай. Мин аны сарай мәктәбенә бирмәдем, аерым мөгаллимдә укыттым, Ислам туган, Сарай мәктәбендә Тәүрәтне укытып бала башын катыралар.

—Улына ничә яшь инде?

—Быел кылыч такты.

—Димәк, ундүрт яшен тутырды.

—Тутырды, тутырды, Ислам туган. Ушлы егет булып килә инде. Атам мин дә синең кебек мәргән булам дип әтәчләнә. Менә нәрсә, Ислам туган, берсекөнгә без Саксинга житәрбез. Әмма олау анда бармас. Без елга буенда калырбыз. Ә сез Саксиндагы хәлләрне белеп килерсез. Әйе, керергә ярыймы калага, юкмы. Ни дисәң дә, кала кахан кулында. Аның монда сөннәтле казакларны җибәрүе дә бар. Килештекме?..

—Ике көнгә якын юл үтәсе бар бит әле, Булат бәк.

—Иншалла, үтәрбез. Мин шуны яхшы аңлыйм, безне куа чыкмаслар, раввалар белән сөннәтле казакларга калада да эш житәрлек. Мин киттем, ә каханбәк Сабир, гомумән, каладагы тәртипләрне белми. Аннары аны, хәтерем ялгышмаса, Йосыф кахан Харәзем әмиренә җибәрергә тора иде, имеш, килешү төзергә. Имеш, кахан аның диненә кагылмый, ә ул Харәзем әмире эшенә тыкшынмый. Бер сүз белән, каханның Аккаладан имамнарны озатуы да шуннан. Йосыф кахан Харәзем әмире белән тыныч яшәргә

тели. Бу сәясәтнең каханның чираттагы хәйләсе икәнен ахмак кеше белмәсә белмәстер, Ислам туган. Ә бит мондый хәл булган инде, гарәп сәргаскәре килгәч, кахан ислам динен кабул иткән була, гарәпләр китүгә, янадан үз диненә кайта. Харәзем әмире моны белә булса кирәктер, өлкән равва оештырган гади кармакка эләкмәс дип уйлыйм мин. Сәясәтенең житдилеген күрсәтү өчен, кахан исеме белән өлкән равва каханбәге Сабирны бер төмәне белән шул тарафка жибәрер, башта каханбәк угыз ханына тукталыр, аның белән килешү төзер, ахыр Харәзем әмиренә юнәлер...

—Сез, Булат бәк сарайда булган бар нәрсәдән дә хәбәрдар булгансыз икән.

—Сарайда ул-бу шылт иттеме, ышанычлы кешеләрем иң әүвәл мина житкерәләр иде, табиб Ислам, мина...

Барысын да алдан сөйләшкәнчә хәл иттеләр. Булат бәк бериш халык белән елга буенда калды, ә Ислам дүрт яугир һәм Булат бәкнең улы Хәбир белән Саксин каласына юнәлделәр. Максатлары—калада булган хәлләрне белү иде. Кузгалыр алдыннан Булат бәк улы Хәбирне үз кырына дәшеп алды.

—Улым, син калага кермәссең, табиб абыең гына узар. Табиб ич ул, аны кем дә туктатмас.

—Ә ук-жәяләр?

—Ук-жәясен синдә калдырып торыр. Искәрдеңме?!

—Искәрдем, атам.

—Искәрсәң, Аллага тапшырып кузгалыгыз. Имин юл сезгә.

Ярты көн дә үтмәде, алар Яна Саксин каласының капкасы янына килеп туктадылар. Капкадан олау узып бара иде, бераз көтеп тордылар. Шулчак Исламның башына бер уй килде, яугирләрне дә, Хәбирне дә калага алып кермәскә, үзе генә керсен һәм табиб йөзендә. Бит моны Булат бәк тә шулай теләгән иде.

—Егетләр, Хәбир энем, сез хәзер берара китәсез дә атларыгызны тышауламыйча гына чирәмгә жибәреп, тезгеннәрен бәкәлләренә бәйлисез, аннан соң минем каладан чыкканны көтәсез. Искәрдек!

—Искәрдек!—диде барысы өчен дә Хәбир углан.

Ислам көлемсерәп куйды һәм олау үткәнне көтте дә капкага таба кузгалды. Капканы үтеп бара иде инде, каравылчы өеннән берәү чыкты.

—Һәй, Исраил баласы, кай тарафка, кайдан?

—Болгар базарына?

—Кемең югалттың анда? Болгар базары сүтелде һәм бер Болгар базары гына түгел. Бар да каланы ташлап китә башлады, угызы-бажае, грегыәрмәне. Менә соңгы олау китте, әрмәннәр, Казаннан кайталар. Син кем соң, ни югалттың?

—Мин табиб, Болгар ханы табибы улы Ислам.

Баш сакчы булса кирәк, чөнки үтә койты сөйләшә иде, болдырдан төште, Ислам янына ук килде.

—Күтең ияренә ябышмагандыр бит, кордаш?

—Юк анысы,—Ислам атыннан төште, баш сакчыга сәлам юллады, һәм болдырга чыгып баскан тагын өч сакчыга күз төшереп алды.—Мин табиб.

—Ишеттем,—диде баш сакчы коры гына.—Кай тарафтан, кай тарафка сәфәрең?

—Ханбалыктан Болгарга дип чыккан идем. Әйтәм бит, Болгар ханы табибы улы мин.

—Табиб, димәк. Менә минем ярам сызлый. Дунай буе сугышында алдым. Кайчак аз гына һава алышынса да төннәр буена йоклый алмый чыгам.

—Син ана бәвелендә кайнатып, кыр әреме төнәтмәсе сөрт, югандай итәр.

—Бәвелгә салып күпме кайнатырга соң?

—Табак-чүен төбендә бер бармак калынлык калганчы.

—Һы,—диде баш сакчы янә бер тапкыр Исламны баштан-аяк күздән кичереп.—Бар, барасы жиренә, тик озын-озак йөрмә. Тукта! Ханбалыкта ниләр бар?

—Мәхшәр анда, кордаш, мәхшәр.

—Тагын угызлар яу килделәрме әллә?

—Юк, бу юлы ниндидер кыргый варяглар диме...

—Аларны сөннәтле казаклар тиз турарлар. Бар инде, йөри бир,—диде, ниһаять, баш сакчы.

Ислам атына атланды, жилле генә Болгар базарына таба юнәлде. Базар капкасына житәрәк күрде, шул тирәдә өч-дүрт сөннәтле казак урала. Ислам тиз генә атын кире борды. Кала капкасы янында аны янә баш сакчы туктатты.

—Тпру, туктап тор. Базарда ни күрдең?

—Сөннәтле казаклар...

—Сиңа моннан таю әйбәтрәк булыр, кордаш. Рәшидә абыстай да базарга гына узам диган иде, сөннәтле казакларны күргән дә шундык кире борылды.

—Нинди Рәшидә абыстай?—диде Ислам атыннан төшә-төшә.

—Нинди булсын, хан кызын Йосыф каханга илтеп биргән абыстай. Ул да Болгарга кайтып бара иде, бире кагылды, ләкин сөннәтле казакларны күргән дә коты алынган.

—Рәшидә абыстай арбада үзе генә идеме?

—Үзе генә иде кебек. Мин инде шушындый олуг кешене тикшереп тормадым. Тизрәк тай моннан дидем дә, жибәрдем. Әйе, сиңа да шул киңәшне тотарга кирәк, табиб. Сөннәтле казаклар белән өлкән равванның ышанычлы кешесе идарә итә. Ә ул монда, калада...

Ислам сикереп атына атланды, чаптырып капканы үтеп китте. Ишләре ул килә-килүгә ат менгәннәр иде инде, күрәсең, ияләренең чаптырып килүеннән үк аңлаганнардыр. Хәбир янына килеп туктауга, Ислам аңардан кылычын, жәясен, садагын, укларын сорады. Хәбир кып-кызыл булды, колаклары ут кебек яна башлады.

—Уклар кая?

Яугирләр көлештеләр, ә Хәбир күтәрелеп карарга кыймый, борын астыннан гына:

—Төлкене куа киткән идем... Ала алмадым.

Ислам көрсенеп куйды.

—Атаң бу хакта әйтсәм, беләсеңме ул сине нишләтә, Хәбир?

—Мин гаепле, гаепле, Ислам абый... Кичер...

—Ярый, кузгалдык! Безгә ашыгырга кирәк.

Атын юырттырып юлга төшүгә, Ислам Хәбир белән булган хәлне онытты да, аның бөтен уй-хисен Рәшидә абыстай биләде. Нишләп йөри Рәшидә абыстай? Болгарга кайтамы! Үзе генәме?.. Айбиби кая? Аккалада калдымы? Калса, ни өчен калды?.. Кахан жибәрмәдеме?.. Айбиби исенә төшүгә, шундук Идел буе, ап-ак күлмәк кигән кыз, аккошлар күз алдына килде.

Ул арада алда олау күренде. Чаптырып килү жаеннан, Ислам, аттан сикереп төшеп, атлар тоткан баш олаучыдан сорады.

—Булат бәк кайда?

Олаубаш каерылып, артына карады, икенче арбада барган Булат бәккә таба ишарә ясады. Ул арада арбадан Мөслимә абыстай төште, Хәбир әнисе янына килеп туктаган иде инде. Аттан төшкән улын әнисе кочагына алды, һәм кычкырып елап жибәрде. Исламның йөрәге кысылып куйды. Ни булды?! Булат бәк кая? Аның башына килгән беренче уй шул булды. Хәбир әнисе кочагыннан ычкынды да чирәмгә утырып, ике кулы белән жирне төя башлады. Ислам Мөслимә абыстайга, аның яшьле күзләренә карап алды да Хәбир янына килде.

—Ни булды, Хәбир?

—Әтине һәм аның яраннарын варяглар үзләре белән алып киткәннәр... Аккалага таба...

Олаубаш Исламга барысын да тәфсилләп сөйләп бирде.

—Булат бәкне яраннары белән көймәләренә утыртып, Аккалага алып киттеләр.

—Кемнәр?

—Варяглар, баскынчы пиратлар, юлбасарлар. Аларның бирегә беренче тапкыр гына килүләре түгел инде. Киткәндә Булат бәк әйтте, Болгарга туктап тормагыз, туры Казанга китегез, Гаязетдин тархан каласына. Юлбасарлар Болгарда булганнар инде. Шәмгун хан аларны кальгага уздырмаган, бик каты орышканнар.

—Атың ничек олаубаш?

—Садретдин мин, табиб Ислам, Садретдин.

—Әйдә, кузгат олавынны, Садретдин агай. Юл кешесенең юлда булуы хәерле. Казанга. Булат бәк әмере мина, аткан укты.

Баскынчы варяглар ат көтүенә кагылмаганнар, әмма һәр көймәгә өчәр сарык суеп ташлаганнар. Олаубаш хак булса, Булат бәк әйткән имеш, аны әсир итмәделәр, ул әсир түгел, аны тылмач йөзендә алып китәләр... Бик ихтимал, Булат бәкне юлбасарлар тылмачлары итеп тә алганнардыр. Тик нигә аның егермеләп яугирен алып китәргә?..

Ислам Мөслимә абыстайны тынычландырды, Хәбирне үзе белән алды һәм юлыбызны дәвам итик, дип олауга кузгалырга боерды. Бер көн эчендә аның башына мең төрле бәла төште. Шул ук вакытта күнелен Айбиби биләп алган иде, Рәшидә абыстай янында Айбиби дә булганмы? Булса, нигә аны баш сакчы күрмәгән?..

—Әйе,—диде барыр җайда Хәбир үсмергә Ислам,—без туры килсәк, мәнсез варяглар безне дә әсир итеп алып киткән булырлар иде. Менә нәрсә, Хәбир, әйдә без яугирләр белән алдан китик, көн авышып килә, әнә теге инеш янында төн кунырбыз. Олау килгән арада без ут ала торырбыз, туктар өчен яхшы урын эзләрбез.

Һәм шулай иттеләр дә. Тугайрак урында туктадылар, коры-сары җыйдылар да ут алдылар. Олау килеп җиткәндә дөрләп ут яна иде инде.

—Ислам абый,—диде Хәбир углан.—Әнә теге әрәмәлек артында үрдәкләр бакылдыйлар. Шунда барып килим әле, бәлкем...

—Ничә угың калды?

—Ике.

—Димәк, ике үрдәк аласың,—дип елмайды Ислам.

Аның кинаясен аңлап алган Хәбир, учакка агачлар ташлый башлады.

—Елга еракмы?

—Якын, әрәмә артында гына. Анда аккошлар да төшкән иде.

Аккошлар сүзен ишетүгә, Исламның йөрәге жуу итеп китте һәм янә Идел буенда суга кереп аккошлар белән сөйләшкән Айбиби күз алдына килде. Шунда күнеленә якын сүзләр туды.

*Мәхәббәтем югалттым дип,*
*Башым ташка орыйммы,*
*Дәрвиш хәлләренә төшеп,*
*Сагыш җыруым җырлыйммы?..*

Ялгыз калганда адәм баласы сагышка бирелүчән. Чарасыз калыр дәрәҗәгә җитеп, ашмас хыялларыннан нидер өмет итеп йөрүен бераз абайлый иде Ислам. Ләкин бит ул адәм баласы. Әнә шул кечкенә җыру да аның күнеленә өмет, юаныч китерде. Олау да килеп житә инде, учак дөрләп яна, ә Исламның күнеленнән Айбиби китми. Ул арада, кай тарафтандыр, күк йөзен кургашындай авыр болытлар томалады. Янгыр болытымы дип, Ислам күккә карады. Юк, бу кара болыт кына түгел, жир йөзенә ниндидер афәт килә сыман. Курку юк иде, күк күкрәп, яшеннәр яшьнәтеп, коеп яуган янгырларны күргәне бар аның. Тик бу болыт тоташ ташкынны хәтерләтә. Көтүләре белән олау килеп житсә, шушында ышыкланып шалашлар ясарга булыр дип уйлап куйды Ислам, һәм учакка коры-сары ташлады да Хәбиргә кычкырды.

—Хәбир, мин олауга каршы киттем. Учакны сүндерә күрмә!

—Ярый, ярый, Ислам абый,—диде ике кулына ике турсык* тоткан Хәбир.

—Мин олауга каршы барам. Күрәсең, бик каты янгыр килә.

Учак яккан төшкә килеп җитәрәк эре-эре яңгыр тамчылары тама башлады. Атларны туардылар да болынга ашарга җибәреп, арбаларны киез белән бөркәргә керештеләр. Күчмә халыкның яңгырдан качар өчен бердәнбер чарасы киез белән капланган бериш булган. Олаубаш Садретдин, хезмәтчеләрнең берсенә чыбыркы бирде.

—Башта елга буена төшеп атларны эчерәсең, аннары болында утлатасың.

Көтүче егет атларны елгага таба куып алып китте, сарык көтүчесе дә малларын шунда таба куалады. Ирләр учак өстенә казан аскан арада, олаучы Садретдин көтүдән тотып калган өч сарыкны чалды, тиресен тунап, тиреләр өстенә итләрне кискәләп куеп, хатын-кызларга дәште. Хәбир турсык артыннан турсык белән елгадан су ташыды. Яңгыр бер читкәрәк киттеме, бераз дөбердәп, юлчыларны куркытып алды да туктады. Ләкин офыкта янә болытлар күренде. Мал чалган олаубаш офыкка карап-карап алды да:

—Иртәгә килер бу яңгыр, Алла саклый күрсен, бик хәтәр күренә,—диде.

—Авызыңнан җил алсын, олаубаш,—диде аңа бер пешекче хатын.

Сарык ите казанда гөбер-гөбер кайный башлады, җил астына урнашкан кешеләргә тәмле ит исе килеп җитте, ашказанын җилкендереп, тамакны кычытып куйды. Теләсәләр-теләмәсәләр дә алар әкрен генә казанлы учак тирәсенә җыела башладылар.

—Сабыр, сабыр, балакайлар,—диде аларга өлкән бавырчы апай.—Аз гына сабыр итегез. Хәзер итне алабыз да дөге салабыз. Дөге озак пешми ул, миңа әрәмәгә төшеп, чәй өчен үләннәр җыеп китерегез.

Өлкән бавырчы хатын әйтерсең лә гомер буена гел аш кына пешергән иде, һәммәсен дә нәүбәтләп казанга сала барды: тозын, борычын, суганын, хәтта кишерен дә оста итеп турап салды. Менә шунда инде чынлап та тамак кытыклап кына калмады, ашыйсыны китереп, авыз сулары килде.

—Буламы инде ашың, Мәрхәбә апа? Эчтә бүреләр улый башлады.

Мәрхәбә апа яугир егетләргә карап алды һәм:

—Садретдин, Садретдин, бир үзләренә бот сөякләрен, кимерә торсыннар,—дип, олаубашка дәште.

Уен-көлке белән табынга утырдылар, тамаклары ялгангач, су буена төшеп, казанны юып менделәр дә чәй кайнатырга булдылар. Чәй дигәненә җыйган үләннәрне салып җибәрделәр. Мәтрүшкә дә, җир җиләге яфраклары да, карлыган яфраклары да, хәтта кемдер табып китергән бөтнек яфраклары да бар иде. Моның өстенә, иң соныннан, чин сәүдәгәрләреннән алган чәй салдылар. Табынга зур коштабак белән бал китерелде.

* * *

Иртән бик иртә кузгалдылар. Көн бик салынкы иде, күк йөзен кара болыт томалаган, көнбатыш тарафыннан кара болытлар белән бергә күнелгә шом төшкән иде. Ислам үсмер Хәбирне олаубаш янында калдырды да яугирләре белән барасы юлны карап елга буйлап китте.

Елганы кичәргә кичү эзли торгач, алар бер көтүчегә тап булдылар.

—Кинәле елгасында адым саен кичү, кордашлар. Чак кына өстәрәк атлап чыгардай кичү бар. Мин малларымны шуннан чыгарам,—диде.

Олауны кичүдән чыгарып, кузгалганнар гына иде, шаулап яңгыр ява башлады. Яңгыр шул чиккә җитеп шаулап яуды ки, олау туктады, сарыклар олау тирәсенә елышты, атлар аптырап калгандай тын гына басып тордылар. Ләкин яңгыр ничек килгән булса, шулай тиз үтеп тә китте. Шөкер, өлгерделәр, әле генә чыккан кичү тәмам күтәрелде, елга ярларына кадәр тулышып ага башлады.

Хәбир углан атын Ислам белән янәшә атлатты.

—Ислам абый, Йосыф каханның Айбиби хатыны Казанга киткәндер, Рәшидә абыстай белән бергә.

Исламның колаклары торды.

---

*Турсык—күн капчык.

— Син моны каян беләсен?

—Әнинең ахирәте—ишектә сакта торучы бер агайның хатыны. Анда булган барлык яналыкларны да житкерә тора.

—Сине кем укытты?

—Башта раввалар, аннары имамнар. Әти әйтә, раввалар үз куллары белән үзләре төзегән дәүләтне җимерәләр. Җимерә башладылар да инде, диде. Мин әтием белән еш кына шул хакта бәхәсләшә идем.

—Карап-карап торам да, Хәбир туган, сиңа кахан сараенда гына эшлисе калган икән.

—Ә нигә, эшләгән дә булыр идем, Ислам абый. Бер равваның әтигә әйткәне дә бар иде: "Малаең үтә дә ушлы, Булат бәк, без аны сарайга хезмәткә алырбыз", дип, тик әти, әллә нигә мәктәптән алып, мәдрәсәгә күчерде.

—Кайсысында уку кызыграк иде соң?

—Белем алу кызык түгел, Ислам абый. Мин мәктәпкә дә, мәдрәсәгә дә кызык өчен йөрмәдем, белем алу өчен йөрдем.

—Гафу ит, Хәбир туган, гафу ит. Син акылың белән зурларча фикер йөртәсең, ә кылган гамәлләрең балаларныкы.

—Бәхәсләшмим, бу шулай. Мин бер тапкыр равваны да шаккаттырган идем. Нигә мин әйтәм, хөрмәткә ия раввам, сез китапка табынасыз, ә без Аллаһы Тәгаләгә?

—Китап—белем чишмәсе,—диде равва.—Ә Аллаһ сине дөнья көтәргә өйрәтә. Ә дөньяны китап укымый көтеп булмый.

—Нигә соң сез яһүдләр китапның һәр хәрефе өчен төннәр буена бәхәсләшәсез?

—Яһүдне китап шулай тәрбияли, олан. Тыңла мине, әгәр дә мәгәр яһүд адәменә иртәгә үтә куәтле давыллы яңгыр явачак, ә син яһүд булганга күрә исән калачаксың дисәләр, яһүд аяк астындагы җир убылса да шул төбәктә басып торачак. Иң гаҗәбе, ул исән калачагына ышана диде. Булат бәк улы, диде.

—Искитмәле, Хәбир, искитмәле. Болгарда каласы итсәң, мин сине, сарай мәдрәсәсенә мөгаллим итеп тәкъдим итәчәкмен.

—Олуг хан, Мөхәммәд вафат. Ил башында Дунайдан килгән Шәмгун хан утыра. Аның кем икәнен син дә, мин дә белмибез, Ислам абый. Сабыр итик, язмыштан—узмыш юк, дигәннәр борынгылар.

—Синең Йосыф кахан белән дә сөйләшкәнең булдымы?

—Булды, мәдрәсәгә күчәргә ул миңа киңәш бирде. Син ике халыкның телен дә, динен дә белергә тиешсең,—диде.

—Хатыны Айбибине дә...

—Юк, Ислам абый, минем аны күргәнем булмады.

—Менә кахан Йосыф сине якын иткән, киңәшен биргән, ә соңра атаңны зинданга ташлаткан.

—Чарасыздандыр. Хак булса, өлкән равва аңа бау салырга җыенган, ләкин Йосыф кахан көтмәгәндә ил белән үзе идарә итә башлаган. Бусы инде мин киткәч булган хәл, бу хакта миңа атам сөйләгән иде.

—Асыл егет, акыллы кеше булып китәрсең син, Хәбир туган. Язмыш аермаса, иншалла, без бергә булырбыз. Атам бит мине сарай табибы итеп әзерләгән иде. Мин синең белән юлга чыгуыма мыскал да үкенмим. Акыллы юлдаш барган юлыңа ак җәймә җәяр, ахмак юлдаш кырлы таш түшәр, ди.

—Ислам абый, Ислам абый, карале,—диде артына каерылып,—безне кемнәрдер куа килә.

—Көтеп алабызмы, каршы барабызмы, Хәбир?

—Кораллы кешеләр булса, көтеп алыйк, кораллары булмаса каршы барыйк, Ислам абый.

—Ә олау?

—Олау китә торсын. Әнә, көн тагын ямьсезләнә башлады.

Шулвакыт Хәбир кычкырып җибәрде.

—Ислам абый, әти бит бу, алдан чабучы, әти, минем әти!..

## XVII

Арбага җигелгән атлар сабыр гына атлый. Күчәр башында утырган ат тотучы йокымсырап бара. Айбиби куенына кереп йоклаган балага бага. Бала мышный-мышный йоклый. Имә дә йоклый, имә дә йоклый. Ә Айбибинең күзенә йокы керми. Үткән төндә дә рәтләп йоклый алмады. Аны тәмам уй басты. Ние белән, кай сыйфатлары белән Йосыф каханны үзенә генә карата алды ул? Кырык төндә кырык хатын белән йоклаган кахан кисәк барысыннан да баш тартып, аның белән генә торып калды. Нәкъ шул хәлдән соң сарай раввалары аны гына түгел, каханның үзен дә куралмый башладылар. Ярый әле Рәшидә абыстай өлкән рavваны акылы белән дә, ягымлылыгы белән дә тынычландыра алды. Аннары балага Ибраһим исеме кушу да өлкән раввага ошады бугай. Бала да тапкач, Йосыф кахан исә Айбибигә кайнап ябышты.

Әйе, ул Хазарстанга курка-курка, әмма кызыксыну аша килгән иде. Курыкмаслык та түгел иде шул—кырык хатыны булган каханга тарттырдылар ич! Ә менә кырык хатыннан арынып, Йосыфҗаны белән бер тән, бер җан булып яши башлагач, сөю-назлауның кызыгы бетәр кебек тоелган иде, әмма алай булмады, аларның мәхәббәтләре яңадан дөрләп кабынып китте. Йосыфы назлаганда ул тәмам күгәрчен кебек гөрли башлар иде. Якынлык кылганнан соң Айбиби үзен ялгызагын көймәгә салып, елга буйлап агызып җибәрелгән кешедәй тояр иде. Көймә чайкала-чайкала шуа, ә аны кемдер күккә чакыра кебек, зәңгәр күктә йөзгән ак болытлар дәшә сыман. Аһ ул төннәр!..

Айбиби хатирәләреннән арынып, баланы күкрәгенә кыса төште. Күңел түрендә Йосыф каханга бераз гына үпкә дә бар сыман, шул ук вакытта күкрәк түрендә сагышлы хатирә дулкыннары да тулгана иде.

Әллә белеп, әллә нидер сизенеп, иртәгә-берсекөнгә Болгарга таба кузгалыр алдыннан Айбиби Аккошлар култыгына төште. Аны күргә, ялгызак аккош ашыга-ашыга янына йөзеп килде, килде дә кинәнә-кинәнә түгәрәк ясап йөзә башлады, ә үзе бертуктаусыз саубуллашкандай башын иде. Ә бит, аккошкаем, нидер сизенгән булган, Айбибинең китәсен сизгән. Ничекләр, ничекләр сизгән ул аны?.. Сагышланган да кебек, янына суга да дәшә сыман, әмма һични кыла алмавын да сизә. Ә Айбиби аны аңламады, аккош тикторганда су өстендә канатларын җилпи-җилпи биергә керешште. Ул да түгел, йөгереп китеп, һавага күтәрелде, аның колак яныннан ук канатларын чажлатып, очып узды һәм күздән язды. Айбиби һични аңламады. Кинәт аның күзләре яшь белән тулды, үкси ук башлады. Ахыр елады-елады да чатырга кереп ятты һәм шундук йокыга да китте.

Айбибигә янә моңсу булып китте. Ни өчен Йосыф кахан үзе озатмады аларны. Һич югы Ханбалыкка кадәр озатсын иде. Ул үзен әле генә болыннан өзеп, юл өстенә ташлаган чәчкәдәй хис итте, бер әкәмтөкәм шикелле эченә кереп бикләнде. Рәшидә абыйстай да Айбибинең хәлен белгән сыман берни сорашмады, сүз башларга кыймады. Айбиби исә уй җепләрен янә Йосыф каханга ялгап җибәрде. Аккалага килә-килүгә, баш хатын да булып киткәч, күлмәкләрен дә көнаралаш алыштыра башлады. Баш хатын буларак аны яраттылар, аңа сокландылар, зурладылар. Айбиби моны бөтен барлыгы белән тойды. Күлмәкләрне аңа Болгар тегүчеләре җибәреп торырлар иде. Купшылык, гүзәллек, матур киенү аңа үзенә дә ошый иде. Айбиби хатын узганда сарай куштаннары аның артыннан карап калырлар, соклануларын яшермичә, ай-һай дип башларын чайкап куярлар иде. Каханбикә ләбаса! Төрки кызлары борын-борын заманнардан ук зәвыклы киенергә, купшы-кылтыйрак йөрергә яратканнар. Мөхәммәд атасы сөйләве хак булса, борынгы Кытай императоры Цыймасин төрки кызлары киенгән кебек киенеп йөргән чин кызларын Кытай дивары аша гуннар иленә куган. Имеш, бозмасыннар борынгы чин бабаларының гореф-гадәтлә-

рен. Чин кызлары да матур киенергә теләгән, аякларына агач калып киеп йөриселәре килмәгән. Агач калыпны кызларына Кытай императорлары аяклары кечкенә булсын дип, унжиде яшькә кадәр көчләп кидергәннәр. Кем дә кем күрше гуннарның бизәкле күн итекләрен кия, ул кызны гуннарга биреп җибәргәннәр. Соңрак Кытай кызлары үзләре үк төрки-гуннар хатын-кызлары киемнәрен киеп, базарларга чыга башлагач, император фәрманы белән илдән күпләп китә башлаганнар. Император, имеш, болай халык китә башласа илдә кызларыбыз да калмас дип, хатын-кызларына төркиләрнең аяк киемнәрен дә кияргә рөхсәт иткән. Дала төркиләре бер чиннар белән генә түгел, фарсылар белән дә сәүдә иткәннәр һәм Ефәк юлын үз кулларында тотканнар. Бу хакта да аз-маз хәбәрдар иде Айбиби. Болгарга кытай сәүдәгәрләре атлас тукымалар, чәй, алмалар белән бергә Шайтан каласында коелган һәм каланың кальгаларына куелган туплар өчен дары да китерерләр иде. Дарыны хан сатып алыр, Айбиби атасы янына кереп, Кытай сәүдәгәрләренә карап торыр, ә алар исә Айбибидән күзләрен дә алмаслар иде. Сәүдәгәрләрне атасы кабул иткәндә, Айбиби алар янына ялтыравык күлмәкләр киеп, аягына кызыл читек элеп, кашларын каралтып, керфекләренә сөрмә тартып, уң битенә һинд сәүдәгәрләре китергән миңне ябыштырып чыгар иде. Сәүдәгәрләр аны күрерләр иде дә тәмам өнсез калырлар иде. Иң гаҗәбе, Айбиби Аккаланың өлкән рухание белән үзен тиң күрә башлады. Очраган саен бәхәскә керде, үз сүзен һәрдаим өстен чыгарырга тырышты.

Менә егерме көн инде алар юлда. Хәзер үзе дә, бала да юлга күнегә башладылар. Айбиби көннәр буена арба япмасын ачык тотты—табигатькә карап бара. Һәр сәгать вә минут саен алышынып торган күренеш аның дикъкатен үзенә җәлеп итте, булган хәлләргә карата истәлек-хатирәләрен оныттырып торды.

Бүген дә көн үтеп бара икән инде, кичкә авышып килә, кошлар төн кунарга елга буендагы тирәкләргә таба оча. Кисәк кенә барысын да бер читкә куеп, кемнеңдер арба тәгәрмәче шыгырдый башлый, шуңа эче пошкан олаубаш, әйләнеп:

—Кара аны, малай актыгы, ыстан туктагач, көпчәгең майланган булсын!—дип кычкыра. Ул арада арбаларга җиккән атлар, бер-берсе белән сөйләшеп алгандай, пошкырышып куялар.

Арбаның түр ягыннан Рәшидә абыстай дәшә.

—Айбиби, баланы имезеп аласыңмы әллә, уянды, боргалана башлады.

—Бир монда, ул да табигатькә карап барсын. Менә күзем ала алмый барам, Болгарга якынлашабыз бит инде, үз якларыбызга.

Айбиби дәшми генә баланы кулына алды, изү бавын чишеп, балага имчәк каптырды. Бала ике кулы белән әнисенең күкрәгенә чытырдап ябышты.

—Авырттырасың бит, улым, улыкаем!—диде аңа Айбиби. Бала, гүя анасын аңлады, бармакларын җибәрә төште.—Ачыктыңмыни, улыкаем? Әйт әле, нинди төш күрдең?.. Әйтмисеңмени?..

—Имә дә йоклый, имә дә йоклый сабый, килеште үзенә юл,—диде Рәшидә абыстай.

Айбиби дәшмәде, тик бернәрсәне аңлады, алар Болгарга кайталар, ары таба Казанга үтәрләр. Барысын да Йосыф кахан кушканча эшләрләр. Тагын Йосыф кахан тел очына килеп кунды. Нигә шулай борчый ул аны, нигә хәтерен бимазалый?.. Килер ул, аларны Казанга ук килеп алыр.

—Рәшидә абыстай, Бозаулыктан Казан еракмы?

—Бер атналык юл кала, бер атнадан Казанда булырбыз, иншалла, балакай. Алпар йөзбаш Кенәле елгасы буенда туктарбыз диде.

—Без Болгарга кермибезмени, абыстай?

—Олау кермәс,—диде Алпар йөзбаш.—Теләсәң без кереп чыгарбыз. Атаң каберен күреп, зыярат кылырбыз. Туганың Гаязетдин дә безне көтә.

Кахан аңа сөенчесен җибәрде, безне Мишә елгасына килеп каршы алырга әмер җибәргән.

—Нигә мин бу хакта белмим, абыстай?

—Бала муенында ни дә, үз муенында ни, балакай. Килер ул безнең арттан, килер, балакай. Бала муенына ул бөтине тиккә генә тагып җибәрде дисеңме?..

—Мин курка башладым, анакай. Хазарстанда орыш-фәлән булса...

—Анысы инде Ходай кулында, Ходай ни язган булса, шул булыр.

—Атам вафаты турында хәбәр дә итмәделәр.

—Кияү сине борчырга теләмәде, балакай, мин дә. Үлгән артыннан үлеп булмый. Әнә хәзер Болгар тәхетендә Шәмгун хан утыра, ди. Атаң утыртып калдырган, кардәш дунайлылардан. Алпар йөзбаш әйтә, баскынчы варягларны кальга-калага уздырмаган, бик күпләре кала диварлары буенда ятып калганнар.

Бала бер гамьсез күкрәген имә, ә анасы эчендә хәсрәт уты көйри. Күз алдына янә Йосыф кахан килеп баса. Сугыш киеменнән. Кальга диварларында туплар, сарай тирәсендә сөннәтле казаклар арлы-бирле йөриләр, шунда ук раввалар, сарай куштаннары. Сарай гүя умарта оясы иде. Бу күренешне сиртмәле арбага утырганда гына күз угында тотып калды Айбиби. Нинди мәхшәр килә иде Аккалага? Айбиби белә дә, белми дә иде.

—Абыстаем, әйт әле, Йосыф кахан миңа сер итеп кенә Аккалага өлкән равва викингларны дәшкән диде, хакмы бу, син белмәдеңме?

Рәшидә абыстай Айбибидән моны көтмәгән иде, аның янына ук күчеп утырды.

—Хак та, хак та түгел. Өлкән равва миңа: “Абыстаем, без моны бер табында хәл иттек”, диде.

—Димәк, сез атам үлеме турында да, викинглар килүе хакында да алдан ук белгәнсез һәм шуңа безне Йосыф кахан ашыга-кабалана Болгарга озатты...

—Хак сүзгә җавабым юктыр, балакай. Ләкин моны кахан чарасыздан кылды, сезне саклап калырга теләде. Соңгы көннәрдә Йосыф кахан берәүгә дә ышанмый башлады, рavваларына да, өлкән раввага да... Әйтсәм әйтим инде, балакай, без өлкән равва белән никах укыттык. Имам хәзрәтләре укыды.

Айбиби күзләрен зур ачып Рәшидә абыстайга карады. Ул аңардан берни дә сорамады. Сорар әмәле калмаган иде. Дөресрәге—оялды. Соңыннан гына, Кенәле елгасына җитеп, ыстан туктагач кына:

—Син аны яраттыңмы, абыстаем?—диде.

Рәшидә абыстай арбадан төште, Айбибигә төшәргә ярдәм итте һәм хезмәтче хатын кулыннан баланы алгач:

—Адәм җанының адәм җанына сыенырга теләве нәҗеслеккә керми, балакай. Мин никахсыз аның кырына ятмадым, Аллаһ алдында күңелем пакь,—диде.

Нәрсә әйтә ала иде Айбиби. Һични! Абыстай хаклы иде.

—Әллә соң казан аскан җиргә кадәр җәяүләп атлыйбызмы, абыстаем,—диде Айбиби.

—Әйдә соң,—диде битараф бер халәттә абыстай.

“Ни хакым бар минем аңа үпкәләргә! Ни хакым!”—дип, үз-үзен орышты Айбиби.

Алар казан аскан төбәккә җиткәндә кояш баюга таба тәгәри иде инде.

—Аш пешкән, киезгә ашъяулык җәйгән, әйдәгез ашап-эчеп алыгыз да су буена төшеп менәрсез. Монда шундаен матур,—диде пешекче апа.

Ашап-эчкәч, Айбиби тынычлана төште. Нигә әле ул кырык яшен яңа тутырган җиләктәй абыстаеның эчке тормышына тыкшына! Ахмакмы әллә син?!. Гафу үтен син аңардан, кичерүен сора, ике затның бергә кавышуы гөнаһмы?

Су буена төшкәч, Айбиби учлап-учлап су алды да битенә бөркеде һәм шуннан соң тагын да тынычланып киткәндәй булды.

Шул вакыт ул ары табарак, камышлар янында аккошларны күрде. Күрде дә өнсез калып, аягүрә басты, үзе дә сизми: "Би-би, би-би, би-би",—дия башлады.

Әмма аңа игътибар итүче булмады. Аккошлар шактый еракталар. Ә инде алар кырына үтәргә Айбиби кыймады, анда таллыклар аша барасы. "Мин аларны иртән-иртүк килеп күрермен",—дип үз-үзен юатты Айбиби.

* * *

Юл газабы, гүр газабы, диләр, алай да ай ярым дигәндә, мең бәладән соң Болгар күренде. Басу капкасына җиткәч, алар арбасы янына Алпар йөзбаш килде.

—Мин калага керергә киңәш итмәс идем, каханбикә,—диде ул кала читендәге яндырылган өйләрне күреп.—Каланы викинглар талаган булса кирәк.

—Минем әтиемнең каберен күрәсем килә, йөзбаш Алпар.

—Мин сезгә бер арба белән генә керергә киңәш итәр идем, курыкмагыз, озатырга унбашым бирермен, ягъни ун яугирем.

Айбиби Рәшидә абыстайның күзләренә карады, имеш, нишлибез?

—Керәбез,—диде Рәшидә абыстай.—Борчылма, йөзбаш, без озак тормабыз.

—Якшы, абыстай.

Алпар йөзбаш ун яугирен чакырып алды, сиртмәле арбадан артык әйберләрне бушаттырды да кучәрбаш биреп, бала белән Айбибигә утырырга кушты. Рәшидә абыстай икенче як ишектән кереп утырды.

—Кузгал. Аллага тапшырдык, кучәрбаш...

Кала аларны колач җәеп каршы алмады. Шәһәр капкасында сакчылар да юк. Бу хәл Айбибине борчуга салды. Йөзбаш Алпар олауны капкадан да уздырмады. Яр буйларыннан ерактарак өйләр исән калган булсалар да, нигәдер ул өйләрнең ишегаллары да, базар куышына утыртылган кибетләрнең ишекләре дә богау йозагында иде. Иң сәере, урамнарда ник бер кеше күренсен. Чатта утырган мәчетнең дә баскычлары җимерек, бер-ике келәм мәчет ишеге янында ята. Рәшидә абыстай кучәрбашында утырган егеткә туктарга кушты. Җилле генә төште дә, мәчеткә таба китте, ачык ишектән сагая калып эчкәре үтте. Биредә бар нәрсә дә таланган, идәннәр шәп-шәрә иде. Димәк, юлбасар викинглар мәчеттәге келәмнәрне алып киткәннәр, икесе баскычта төшеп калган, каракның көче җитмәгәнме... Рәшидә абыстай догасын укый-укый:

—Әйдә, оланнар, кальга-калага,—диде.

Кальга-калада, ягъни хан сарае капкасында ике сакчы тора иде, алар Болгар яугирләрен күрүгә, капкаларны ачтылар. Сакчыларның берсе Айбибине танырдымы, Рәшидә абыстайнымы, аларны күрүгә, күкрәгенә кулын куеп, баш ия-ия эчкәре уздырды. Рәшидә абыстай ханнар каберен белә иде, кучәрбашка шунда барырга кушты. Атлар челтәрле тимер коймага җитеп туктадылар. Әүвәл арбадан Рәшидә абыстай төште, аннары Айбиби. Арбадагы карачы хатын Айбибигә баланы бирде. Бала уяу, як-ягына карый, әйтерсең лә нидер аңлый, нидер күрә иде. Ханнар зиратында урткойрыклар очынып йөри, чыркылдыйлар, ул да түгел, каяндыр килеп чыккан саескан шыркылдап ала. Шушы тавышларгамы борчыла балакай, дип уйлады Айбиби.

Тимер капка янында ап-ак сакаллы бабай күренде.

—Тукта, тукта, кемне күрәм, Рәшидә абыстай түгелме, ә син, балакай, син—Айбиби, хан кызы Айбиби?!

Карт кабалана-кабалана тимер капканың богау йозагын ачты, кунакларны, зыярат кылырга килгән баласын күтәргән хан кызын алдан уздырды.

—Саумы, бабакай!

—Саумы, саумы, иминме, балакай? Бәби белән үк кайтып төштегезме? Атаң кабере түрдәрәк, әнә теге миләш үскән җирдә,—диде карт һәм үзе үк алдан китте.

—Баланның аты ничек соң?—дип сорады зират сакчысы карт.

—Ибраһим,—диде Айбиби.

—Пәйгамбәребез исеме икән,—диде карт.

Ниһаять, кабер янына җиттеләр. Каберга җитүгә, Айбиби баланы карачы хатынга бирде дә ике тезенә төшеп, белгән догаларын укыды. Рәшидә абыстай да аннан калышмады.

—Хатын-кызга зиратка узарга кушмыйлар да,—дигән булды карт. Айбиби аның учына ике дирһәм салды һәм шуны гына көткән кебек, карт кабер янындагы түмәргә утырып, дога кылды. Айбиби ары таба үтте, әтисе Талиб каберенә. Ул анда тезләнеп кенә калмады, үлән баскан кабер туфрагын кочаклады һәм эченнән: "Тыныч йокла, әтием, тыныч йокла, кызың сине онытмады, онытмады..." Ахыр белгән догаларын укыды, бер уч туфрак алды да кулъяулыгына төреп, түшенә куйды.

Кире кайтканда, җимерелгән өйләрне, ишекләре аерылып ачылган, таланган кибетләрне күреп, Айбибинең җаны сыкранды. Һәм аның кайчандыр гөрләп торган базарлары, халык тулы урамнарының бушап калуларын күреп, тизрәк бу каладан чыгып китәсе килде. Һәм шулай иттеләр дә. Каладан чыгуга, йөзбаш Алпар олауны Казан юлына төшерде, шуннан соң гына Айбиби арбасы янына килде.

—Айбиби каханбикә, калада халык калмаганга шаккатмагыз, халык нигездә Биләргә—эчкәрерәк, баскынчы викинглар күзеннән ераграк җиргә күчеп китте. Су юлы белән йөриләр бит викинглар, яссы төпле баркаслары белән елга комлыгына кадәр чыгалар.

—Монсу, кала бушап калган, илгә афәт килгән, каланы күреп чыктым, күнелем шом белән тулды. Ул каһәр баскынчылар Казанга да кергән булсалар, йөзбаш?

—Казанның кальгасы тау башында, каханбикә. Баскынчы викинглар бер тапкыр гына килмәделәр инде Болгарга. Кальгага үтә алмадылар. Әле дә йөзләрчә яугирләре кальга дивары буенда ятып калды. Кальганы Шәмгун хан бирмәде, акырып-бакырып ябырылып килгән дошман өстенә туплардан аттылар. Шул хәлдән соң Шәмгун хан башкаланы Биләргә күчерергә булды. Халыкның күбесе инде күчеп тә киткән. Безнең янга кар базына качып калган бер карт килгән иде, шул сөйләде. Казан тарафларына да күчеп китүчеләр булган икән, каханбикә Айбиби. Шәмгун хан сарай куштаннарын гына түгел, үзе белән хезмәтчеләрен дә, төзүчеләрен дә алган икән.

—Без дә кузгалыйк, әрвахларыбыз рухына дога кылдык, атам-анамның каберен күрдек, изге гамәл кылдык.

—Мин дә Талибымны күргәндәй булдым, балакай,—диде Рәшидә абыстай арбага таба кузгала-кузгала. Әмма Айбиби аның сүзләрен ишетмәгәнгә сабышты, әле булса янында басып торган йөзбаш Алпарга:

—Без дә кузгалыйк, йөзбаш,—диде.

Әнә шулай хан кызы Айбиби ерак Хазарстанны ташлап туган якларына әйләнеп кайтса да биредә калмады—язмышы аны Болгар дәүләтенең чиге сыман булган Казан каласына алып китте.

* * *

Өч көннән соң гына олау Чулман елгасына килеп җитте, мең бәла белән аръякка чыктылар һәм яр өстендәге чирәмлектә төн кунып китәргә булдылар. Бериш халык Алабуга авылына юнәлде, аннан ике чиләк сөт, катык алып килделәр һәм бер капчык көлчә-ипи алып кайттылар. Айбиби балага сөт эчерәсе иткән иде, Рәшидә абыстай каршы төште.

—Синең үз сөтең дә савып алырлык, балакай. Эчермә, эче бозылып куюы бар, килешмәс дим. Сабый гына бит әле ул, сабый гына.

Айбиби янына йөзбаш Алпар килде.

—Каханбикә, безне Мишә елгасы ярында Гаязетдин тархан көтәргә тиеш. Һәрхәлдә, Йосыф кахан миңа шулай дигән иде. Ул анда Аккошлар күле янында сезгә утар салдырткан икән.

Мишә елгасына җитә алмадылар. Бик көчле яңгыр яуды, туктап, яңгыр туктаганны көттеләр һәм шунда ниндидер чишмә буенда төн кунарга булдылар. Яңгырдан соң һава сафланып киткән иде. Хатын-кызлар аш пешергән арада Айбиби чишмә янына төште, учына салкын чишмә суы җыеп, рәхәтләнеп эчте. Һәм баласы чишмә суы яратканны искәреп, пешекчеләр янына менде, агай табак алып, балага су эчерәсе итте. Әмма моны Рәшидә абыстай күреп алды һәм коты алынып:

—Нишләвең бу! Салкын чишмә суы ла! Баланың тамагына тиюе бар. Китер җылытып китерим. Җиз савыт бар, учак янып тора.

Суны җылытып китерде, әмма бала нигәдер судан йөзен чөерде.

—Анасының сөтен сорый,—диде карачы хатын.

Айбиби киезгә утырды да баланы кулына алып, туйганчы имезде. Имеп туйган бала әнисе белән сөйләшкәндәй э-э, мә-мә дигән булды.

—Әннә, диген әле Ибраһим улым. Әннә диген.

Әмма бала һаман бер авазны кабатлады: “Ә-ә, мәә”.

Ләкин хәтта шушы аваз да Айбибинең күңелен күтәреп җибәрде. Ул арада чишмә янындагы әрәмәлектән карачы хатын бөрлегән җыеп китерде. Һәм савытка салып юды да Айбибигә бирде.

—Каптырып кара әле шуны балага, Айбиби.

Айбиби бер бөрлегәнне алды да бала авызына каптырды. Башта бала һични аңламый йөзен чытты, аннары авызын мәзәк итеп чапылдата башлады.

—Ошады бөрлегән, ошады,—диде Айбиби кинәнеп.—Аша әле, улым, аша, оҗмах җимеше бу, оҗмах җимеше. Бала тагын ике бөрлегән ашады. Олылар барысы да кинәнделәр.

Гаязетдин тархан Йосыфҗан турында горурланып сөйләгән икән. Бу хакта ишеткәч, Айбибинең күңеле иренә карата йомшара төште. Юк, ул безне кумады, ул безне кунакка гына озатты. Шулай бит, улым, әти безне кунакка гына озатты бит, диде Айбиби арбага утыргач, улының киң итеп ачылган чем-кара күзләренә карап. Ләкин Гаязетдинне күз алдына китерә алмады. Йосыфка ошаган булса, кара-тутсыл йөзле, кара чәчле булырга тиештер. Ләкин аңа анасы Сара аксыл-җирән чәчле, яшел күзле, дигән иде Йосыфҗанны. Айбибигә бер хәрам ата житкергән иде инде, кайчандыр, өлкән равваның хатыны бер төрки бәгенә ябышып качкач, өлкән равва тол калган Сара каханбикәнең кулын сораган, имеш. Әмма каханбикә Сара аның белән сөйләшергә дә теләмәгән, икенче көнне үк вафат булган Айгөл килененең улы Гаязетдинне алган да Таман тарханы Гали иленә китеп барган. Һәм Гаязетдин бәлигъ булганчы бер тапкыр да Хазарстанга әйләнеп кайтмаган. Әнә шулай Гаязетдин углан Таман тархан төбәгендә үскән, яхшы мөгаллимнәрдән белем-сабак алган, хәтта фарсыларда, грекларда йөреп, азмы-күпме тел өйрәнгән икән...

Икенче көнне Мишә елгасына җиткәнгә кадәр Айбиби шул хакта уйланды. Йосыф каханның улы Гаязетдин Казанда, анасы Сара да анда булса кирәктер. Ир-канаты Йосыф каханның улы Аккош күле янында утар күтәрткән, өй-йортлары, каралты-куралары белән. Димәк, әйткән сүзе хак булса, ул аларны—улы Ибраһим белән хатыны Айбибине, шуннан килеп алачак... Куанычлы хәбәр иде бу Айбиби өчен. Тик әллә нигә барыбер күңел төпкелендә шик саклана. Нигә ул—аның җанкисәге, шул хакта Хазарстанда ук әйтмәде?! Ни өчен яшерде?! Үзенә, аңа, балага бөтиләр ясаткан, димәк, аерыласыларын алдан ук белгән, ә бәлкем, мәңгегәдер...

Күр инде, нинди уйлар гына килми күңелгә юлда барганда... Ә Аккошлар күленә көтү-көтү аккошлар төшә икән, шунда бибиләрен чыгаралар, дип кинәндерде Айбибине йөзбаш Алпар. Йөзбаш үзе дә шул яклардан икән. Аккошлар! Аның ялгызагы да шул күлдән түгелме икән, шушында югалтмадымы икән ишен?.. Ни генә булмасын, бу хәбәр ирешкәч, Айби-

бигә күнеллерәк булып китте. Һәм йокы аралаш кукрәгең имгән баланы кыса төшеп: "Без синең белән, улым, аккошлар күленә төшәрбез, аларны ашатырбыз. Ишетәсенме, улым, Ибраһим, дим. Күзләреңне ач инде, болай да юл буена диярлек йоклап кайтасың. Казанга якынлашабыз, әнә, Гаязетдин абаңның каласына. Ул анда таш кальгалар эчендә мәһабәт сарайда утыра, диделәр. Без аларга барырбыз, әбиеңне күрербез, Сара әбиеңне. Ул синең сөннәт горурлыгың күрер, шатланыр..."

Айбиби шулай диде дә бу хәлнең булуына шикләнеп куйды. Сара ана Йосыф кахан тәхеттә утырганда бер тапкыр да диярлек улы янына кайтмый, Гаязетдин онығы белән илдән илләргә йөри, хәтта изге җирләре Исраилгә барганнар, дип тә әйткән иде Йосыфы.

—Бик сагышка батып кайтма әле, балакай,—диде Рәшидә абыстай Айбибинең уйга калуын күреп.—Аккошлар шушы төбәкләрдә бибиләрен чыгаралар. Рәхәтләнеп ашатырсың...

Айбиби бертын дәшми торды. Һәм уйлады: "Соң биредәге аккошлар янында аның Йосыфы булырмы? Күл буеннан аны кулына күтәреп кем алып кайтыр, Рәшидә абыстаем, кем?.." Йөрәк сыкравы иде бу, ни әйтергә белми гаҗизләнүдән иде. Илләә ни әйтә ала ул Рәшидә абыстаена. Һични! Шулай да җавапсыз калмады.

—Без бергәләп ашатырбыз аларны, абыстаем-анам, бергәләп,—диде һәм йокыга киткән баланы аңа сузды:—Мәле баланы, абыстай, бераз атлап барыйм, әллә нигә аякларым оеп китте.

Рәшидә абыстай да, кучәрбаш кырына ук күчеп утырган карачы хатын да елмаешып алдылар. Казанга якынлашып киләләр ич инде, гомер итәселәре төбәккә. Анда Аккошлар күле, анда алар өчен мәһабәт наратчыршы урманы эченә салынган йорт-каралты, зур бер утар. Һәм ул утарны Йосыф кахан аларга дип салдырырга кушкан, Казанда тархан булып утыручы улы Гаязетдингә—Казан тарханына.

## XVIII

Мишә елгасын иртәнге якта кичтеләр. Барысы да кичеп беткәч, Казан яклап бер төркем атлыларны күреп, йөзбаш Алпар Айбиби арбасы янына килде.

—Тархан Гаязетдин бу, каханбикә Айбиби.

Ни өчен, Гаязетдинне күрмәс борын ук, Айбибигә каушау килде. Айбиби арбадан төште, аның артыннан Рәшидә абыстай, һәммәсе дә казанлыларны көттеләр. Алданрак килгән җайдак, олауга җитәрәк, атын чаптыра ук башлады. Менә аларны инде, бигрәк тә алдан килүче җайдакны, Айбиби ап-ачык күрә. Шушы җайдак якынайган саен ул үзендә гасабилану тойды, ахыр ни кылырга белми әле Рәшидә абыстайга, әле баланы тотып арбадан төшеп килгән карачы хатынга карады һәм каударлана төшеп:

—Бир әле кулыма баланы, бир әле!—дип, карачы хатынга таба кузгалды. Баланы кулына алып, килүче җайдакларга борылып каравы булды, аһ! итте. Аларга таба, нәкъ ул баскан арба кырына таба, йә Ходаем, Йосыф кахан үзе килә. Айбиби: "Йосыфҗан!",—дип кычкырырга иткән иде, Алпар йөзбаш, инде арба янына килеп җитәр-җитмәс атыннан төшкән кешегә:

—Рәхим ит, галиҗәнапләре Гаязетдин!—дип, Казан тарханын каршы алды. Гаязетдин аның белән күреште, Рәшидә абыстайга күкрәгенә кулын куеп баш игәндәй итте һәм Айбиби янына таба килә башлады. Айбиби тораташтай катып калды, чөнки аның алдында, кулын балага сузган, суеп каплагандай Йосыфы тора иде. Гаязетдин тархан аңа килеп җитәр-җитмәс, бары тик бер адым кала туктады һәм бер тезенә төшеп, борынгы төркиләрчә Айбибигә сәлам юллады һәм күтәрелде дә якын ук иелде, җофар юрганга төргән балага үрелде. Айбибинең башы әйләнеп китте, гүя балага Йосыфы үрелгән иде.

—Җингәчәй,—диде ап-ачык итеп Гаязетдин тархан.—Җиңгәчәй, төкле

аягыгыз белән Казан жиренә. Бирегез, бирегез әле энемне үземә, багыйм әле булачак баһадирга...

Айбиби баланы аңа бирде, вә ләкин үзе баскан жирендә кинәт жиргә таба иелә башлагандай итте. Моны күреп, Рәшидә абыстай аның култык астыннан эләктереп алды.

—Айбиби, Айбиби!—дип, аны уятып жибәрде.

—Аллага шөкер, сезне күрер көнебез дә бар икән,—диде Айбиби.

—Күрдегез, күрдегез, жиңгәчәй. Менә без дә сезне күрдек,—диде һәм егетләренә:—Олауны алып китә торыгыз!—дип боерды.

Рәшидә абыстай Айбибинең колагына үрелә төшеп:

—Ни булды сиңа, балакай?—диде.

Менә кайчан ихлас күңелдән, инде аек күздән беренче тапкыр Гаязетдин тарханның йөзенә бакты Айбиби. Һәм янә әллә нишләп китте. Йосыф бит ул, Казан төбәгенә килеп чыккан Йосыфы! Шул чиккә житеп бер-берсенә охшарлар икән. Йа Хода! Күзләре дә, карашы да Йосыфныкы кебек чем кара, йомры сакалы да хәтта, тик бераз кечкенәрәк кенә, ә тавышы—игезәк балаларда да бу хәтле охшашлык булмыйдыр. Әллә соң Гаязетдин бала Йосыфныкы түгелме, игезәк балалар тапканмы Сара каханбикә?..

Ул арада Гаязетдин Йосыф тавышы белән артында басып торган җансакчыларына:

—Казан асыгыз, бераз чәйләп алыйк, шуннан соң кузгалырбыз. Шулаймы, жиңгәчәй?—дип, баланы анасына бирде. Айбиби аның белән килешеп, баш какты.

Баланы кулына алуга, булган хәлгә бөтенләй башка күз белән карады Айбиби. Әйе, бу кеше Йосыфжаны түгел, аның улы Гаязетдин тархан һәм ул аларны каршы алырга килгән, бериш яугирләре белән. Тик Айбиби һаман исә аңына килә алмый тора. Күр инде гәүдә-сыны да Йосыфныкы бит...

—Киез җәелде, табынга узыгыз, жиңгәчәй,—диде аның янына ук килеп Гаязетдин тархан. Күзләренә бакты да Айбиби бөтен тәне буйлап тетрәнү узуын тойды.

—Әйе, әйе, абыйсы, без хәзер,—дип, Айбиби каушавын тыярга теләп, арба артына баласын пес иттерергә дип кузгалды.

Баланың җофар юрганын Рәшидә абыстайга бирде. Рәшидә абыстай: “Бир баланы, үзем бушандырыйм”,—дисә дә баланы бирмәде, аңа бераз гына тынычланырга, җилкенгән күңелен тыярга кирәк иде. “Йосыф булып, шулай кыланса?”—дигән уен күңеленнән куарга итте, әмма бу уй күңелгә кереп оялаган иде инде. “Бит ул сакалны бераз кыркырга да була”,—дип, Айбиби һаман тәүге шиген нигезләргә тырышты, гәрчә күңеле белән Гаязетдин тарханның Йосыфы түгеллегенә инанган булса да.

Кызгылт-сары һәм саргылт төскә шакмаклап сугылган ашъяулык тирәли чәй эчәргә утыргач та, Айбиби юк-юк та, Гаязетдин ягына карап алгалады. Юк, аның Йосыфы түгел бу кеше, кыланышлары башка, сөйләгән теле дә катырак, Таман тархан төркиләренең сөйләменә тартым. Тик шуңа карамастан, Айбибигә Гаязетдинне күргәч күңеллерәк булып китте. Ул хәтта юлда булган бер хәлне дә сөйләп бирде, әмма каушый төшеп. Гаязетдин тархан аны бирелеп тыңлады, нигәдер туптуры карап, дикъкать белән. Һәрхәлдә, нининдер томан эчендә тулганган Айбибигә шулайрак тоелды.

Ары таба, чәй эчеп кузгалгач, Гаязетдин тархан Айбибидән сорады.

—Туры утаргамы, әллә булмаса Казан аша барабызмы, жиңгәчәй?—диде.

Айбиби баланы тотып, янәшәсендә утырган Рәшидә абыстайга таба борылды.

—Утарда бар да әзерме соң Гаязетдин углан?

—Барысы да әзер, абыстай, барысы да. Хезмәтчеләр дә, карачылар да, сакчылар да анда инде. Атна буена барысын да хәстәрләп, көтеп торалар.

—Алайса, Гаязетдин, безне туры Аккошлар утарына илтегез.

—Аккошлар күле янындагы утарга, Айбиби җиңгәчәй,—дип атын куа төшеп, алдан китте Гаязетдин.

—Уф Аллам,—диде Айбиби уфтанып.—Рәшидә абыстай, барысы да чынмы бу, безне чынлап та Гаязетдин тархан каршы алдымы?..

—Бик матур кеше, әдәпле сөйләшә, җиңгәчәй дип кенә тора. Иншалла, барысы да әйбәт булыр, балакай. Рәхмәт инде кияүгә, әллә кайлардан яу йөреп кайтса да, улына хәбәр иткән, ә бусы аның үтенечен аяк астына салмыйча, утар кадәр утар салдырган, хәтта хезмәтчеләрен дә булдырган.

—Житмәсә утары куе нарат урманы эчендәге Аккошлар күле янында икән, абыстаем.

—Сине, балакай, хәрам атакайлар әйтмешли, фәрештәләр үпкәннәрдер, фәрештәләр. Хазарстанга килә-килүгә кияүне нишләттең әнә. Кырык хатыннан аерып алдың.

Кеше еш кына үз эченә кереп бикләнә икән. Айбиби үз язмышын үзе ясадымы? Юк ич, юк! Аны Йосыф каханга барырга атасы Мөхәммәд хан мәҗбүр итте. Аңа беркем дә кирәкми иде әле, аның хәтта күзе төшкән егете дә юк иде. Ул, гүя, ирекккә җибәрелгән сайрар кош иде.

Ул баланы имезергә кулына алды. Бала тынычсызланган кебек, боргалана, нидер көтә сыман. Бу балада аның һәм Йосыф каханның каны. Кара күз, чак кына озынчарак йөз, юка иреннәр. Кара шул баланы, үстер, тәрбиялә кеше йөзендә, әгәр дә мәгәр тәҗрибәле мөгаллимнәрдән сабак алса, югалмас, дөнья арбасыннан төшеп калмас, иншалла. Айбиби үз-үзен шулай дип тынычландырса да, имчәк каптырып, бала имә башлагач, кинәнеп үк куйды. Аның баласы бар, яраткан кешесеннән тапкан улы. Казан төбәгенә кайтабыз. Рәшидә абыстай әйтмешли, барысы да әйбәт булыр, иншалла.

Агач күпердән Казан елгасын уздылар. Күперне чыгуга, алар арбасы янына янә Гаязетдин тархан килеп китте. Имеш, барысы да әйбәтме, туктап ял итмисезме?.. Юк, берсенең дә туктыйсы да, ял итәсе дә килми иде. Казан елгасы артта калгач, бертын баруга олауны куып җиттеләр. Айбиби утырган күчәрбаш олауны җилле генә узып китте, ә Гаязетдин тархан үз яугирләре белән тагы да алданрак бара башлады.

—Хәтерем ялгышмаса,—диде Рәшидә абыстай,—Аккошлар күле Иделнең борынгы юлында, шул юлда төрле-төрле зурлыктагы күлләр хасил булган, әнә шул күлләрнең берсен аккошлар үзләренә сайлаганнар. Бу хакта миңа мәрхүм атаң Талиб сөйләгән иде, хәтта бер барып күрсәтәм дип тә ышандырган иде. Ул вакытта күрергә язмады инде, иншалла, бу юлы күрермен.

—Күрерсең дә, шушында яшәрбез дә, абыстаем.

—Язган булса,—диде Рәшидә абыстай серле генә итеп.

Айбиби аны шундук анлады. Абыстае бит никахлы кеше. Көтмәгәндә шул кеше бирегә килеп төшсә?.. Ялгыз гына ошбу явызлык белән тулы дөньяны көтүләре ай-һай авырдыр. Ярты гомерен инде Рәшидә абыстай аңа багышлады. Кырык яшьлек хатында мәхәббәтнең сөт өсте, диләр бит. Дөньяда яшәгән һәр гүзәл затны яратып та, сөеп тә бетермәле түгел, телисеңме моны, юкмы, сиңа барыбер тулы канлы мәхәббәтне бер кеше генә бирәчәк. Калганнары сан ягыннан гына хәтереңдә калыр. Ә менә берсе—җан биргәндә дә синең белән булыр, дип Рәшидә абыстай үзе үк сөйли иде ич. Ә күрде-сиздe Айбиби, Рәшидә абыстае тикмәгә генә өлкән равваны телгә алмый. Бик ихтимал, Йосыф кахан Казан тарафына килергә вәгъдә иткән кебек, ул да аның кырына килеп чыгарга вәгъдә иткәндер.

Айбиби яңа җирне кызыксынып карап барды. Аланнар аша, куе нарат урманнары аша барганда, тып-тын торган җилсез һавага игътибар итте. Ә бит Хазарстанда һәрчак аз гына булса да жил йөреп-исеп торыр иде. Монда черкиләр безелди, баланың йөзен өрфия яулык белән ябар-

га туры килә. Шулай да бу хозурлык ныграк ошый иде Айбибигә, хәер, бу табигатьтә ул Идел буендагы Болгар каласында ук гадәтләнеп, аның бер тузаны булып үскән иде. Туган ягы ич, борын-борын заманнарда бу төбәкләрдә яшәгән, көн күргән бабаларының җирләре.

Ә Хазарстанда янында һәрдаим Йосыф кахан булыр, сарай тулы хезмәтчеләр, артыннан аяк эзләрен сөртеп хәрам атакайлар йөрер иде. Ләкин шуна карамастан, ул анда курку катыш мәхәббәт сагышы белән яшәде. Чөнки башкалар көнләшерлек дәрәҗәдә бәхетле иде.

Айбиби алгы пәрдәне күтәреп, тезелеп киткән чыршыларга карады. Һава саф иде, борынга ярып әчкелтем ылыс исе керә, сулаган саен сулыйсы килә. Айбиби балага күз төшерде, имде-имде дә изрәп йокыга китте. Юл буена йоклады бугай инде бу бала. Рәшидә абыстай Айбибигә: "Баланы уятыйммы әллә?",—дип сораганда: "Йокласын, бала йоклый-йоклый үсә",—дигән иде. Хәер, бала гына түгел, Рәшидә абыстай үзе дә изрәп мендәргә башын салган, карачы хатын да мендәргә башын төрткән, күчәрбаш кына атларга: "Әйдәгез инде, малкайлар, тиздән җитәрбез, анда инде мин сезне куе сөлле Казан үләне белән сыйлармын",—дип, атлары белән сөйләшеп бара. Йосыф кахан әйткән иде: "Яратырсың син Казанны, бер дә борчылма Айбибием",—дигән иде. Айбиби ана: "Син булмагач, мин анда берьялгызым ничекләр яшәрмен Йосыфҗаным",—дип, үртәлгән иде. Моны ул ир-канатына юри генә әйтмәде, ул чынлап та Йосыфсыз тора алмам, бер көн дә тора алмам дип уйлый иде. Ә бит айга якын күрми инде, исән-имин, Аллага шөкер кыла. Һәм инде тәгаен белә, ялгызлык халәтеннән аны бала коткарды. Ләкин кем коткарыр аны Гаязетдинның күз карашыннан?.. Күрде ич, җаны-тәне белән тойды—ул аңа җиңгәчәсе итеп кенә карамады, ул аңа сокланып карады, яшь кеше бар яктан да тулынкы булган хатын-кызга караган кебек. Җуләр кеше генә бу карашның ни икәнен аңламаса аңламас. Ә Айбиби белә иде ирләрдәге ул карашны, артыгы белән яхшы белә иде. Ләкин Гаязетдин аңа ни дә булса әйтергә кыймады. Шуна карамастан, "җиңгәчәй" диде. Тик бу сүзгә нинди мәгънә, аһәң салды соң ул? Моны янә Айбиби генә тойды, башкалар өчен "җиңгәчәй" гапгади сүз булып кына калды шикелле. Йөрәккә якын сүз, күнелгә шом салырга да, курку китерергә дә мөмкин икән. Хәер, Айбиби мона игътибар итмәскә булды. Упкынга упкыннан курыккан кеше генә ташлана. Ул хәзер бернәрсәдән дә курыкмый, аның баласы бар—Ибраһимы. Бит ул күрәсен күрде шикелле инде—кырык беренче хатын булып Йосыф каханда яшәп карады. Ул чакта Айбиби болын өчен бер үлән генә иде. Нәрсәдән куркырга миллионлаган үләннәр арасында? Ул үсә, һичнигә карамый ямь-яшел кала бирә. Хак әйткән иде аңа имам хәзрәтләре, кеше ышаныч янына сыенган чарасызлык божрасында яши. Ышанычы югалса, ни кала? Чарасызлык. Ләкин Айбиби ул чиккә барып житмәс, иншалла. Гәрчә үзен кош хәлендә тойса да. Бер ояда утырды-утырды да баласын алып, яңа җиргә күчеп китте.

* * *

Алдан киткән Гаязетдин тархан утар капкаларын ачтырган, аларны көтеп тора иде инде. Утар йорты болдырында хезмәтчеләр, капка янында сөңге тоткан ике сакчы. Арба утар ишегалдына үтүгә, болдырга җитәр-җитмәс туктады. Гаязетдин арба янына килде, Айбибигә арбадан төшәргә кул бирде. Гаязетдиннең кулы кагылуга ук, Айбибинең тәне буйлап тетрәнү узды. Ләкин ул мона игътибар итмәскә тырышты. Бу хәл булган иде инде аның белән—Хазарстанда, Аккошлар култыгында, Айбиби янына килеп, Йосыф кахан аның кулыннан алганда. Кемдер әйткән иде аңа: "Яшьлек ул—яшен ташы, бер атуда йөрәгеңне яраларга мөмкин". Ә бит хак, хак әйткән. Хәер, шулай таныйдыр адәм баласы тормышны—югыйсә нигә аңа туып торырга. Тик соң нигә мона кадәр бер генә акыл иясенең дә мәхәббәтнең ни икәнен аңлата алганы юк.

Кем тарафыннан бирелә адәм баласына мәхәббәт?.. Аллаһыданмы?.. Ахыр килеп, ни өчен күрә-күргә бирәүгә тартыла да күңел, икенче бирәүдән йөз чөерәсең?..

—Башта өйгә узыйк, Айбиби җиңгәчәй, өйгә. Минем сезгә башта өйне күрсәтәсем килә. Осталар бик тырыштылар. Мин барысын да атам язганча эшләтергә тырыштым.

—Рәхмәт, рәхмәт, Гаязетдин тархан.

Ул инде аның кулын җибәргән иде. Башта беренче катны карадылар, алгы, аш якларын, ял урыннарын, бала бүлмәсен. Бала бүлмәсе якты, кояш ягында, матур итеп җиһазланган иде. Ахыр икенче катка күтәрелделәр. Икенче катта иркен бүлмә, ике якка да балконнар чыккан.

Айбиби балконның ике яклы ишеген ачып, сырлап, нәкышлап куелган терәккә барып тотынды һәм Аккошлар күлен күрде дә үзе дә сизмәстән аһ! итте.

—Ни булды, җиңгәчәй, әллә башыгыз әйләнеп киттеме?—дип, Гаязетдин аның беләгеннән тотып алды. Янә Айбиби тәне буйлап, хәтта аркаларын чымырдатып, тетрәнү узды.

—Юк-юк, болай гына, матур, бигрәк матур күл икән,—диде.

Ул арада астан баланы алып менделәр. Айбиби баланы кулына алды да аңа Аккошлар күлен күрсәтте. Анда камышлы яр буенда берничә аккош җим эзли иде.

—Аккошларны кем ашата, Гаязетдин тархан?

—Безнең кешеләр дә, ә аръяктагыларын дәрвишләр.

Айбиби Гаязетдингә таба борылды, күзләренә карады.

—Нинди дәрвишләр?

—Моннан ерак түгел, дәрвишләр авылы бар, шуннан килеп ашаталар. Аккошлар оҗмах кошлары, аларны ашаткан кеше саваплы була, диләр ич...

—Еш киләләрме?

—Юк, сирәк-мирәк кенә. Нигездә аккошларны да, күлгә төшкән казларны, үрдәкләрне дә безнең хезмәтчеләр ашаталар.

Айбиби беркайчан да өлкән равва кебек хәйләкәр була алмады. Ул һәрчак барысын да ачыктан-ачык әйтте. Рәшидә абыстай: "Син арадашчы була аласың, тик идарә итүче түгел. Арадашчы булу хатын-кызга килешә төшә, аның гомерен саклый, ә түрә булу, ил белән идарә итү аның гомерен генә кыскартачак", ди торган иде. Хакмыдыр, юкмыдыр, бу нәрсәгә беркайчан да игътибар итмәде Айбиби. Яратуны һәм ираттан сөелүне ул мең мәртәбә артыграк күрде. Әмма беркайчан да акылын җуймады. Имам хәзрәтләре әйтмешли, акыллы кешенең ихтыяр көчен кайгы да, бәхет тә сындыра алмый. Чөнки акылга, гаделлеккә, канунга таяна, чарасызлыктан ничек чыгарга белә. Акыл белән яшәү кешене күп тапкыр бәхетлерәк итә.

Борылып чыктылар, Айбиби карачы хатынга баланы бирде дә Гаязетдингә ияреп, ишегалдына чыкты. Сукмак яклап чәчкәләр утыртылган, Аккошлар күле кырында ук түбәләп ясалган ял урыннары. Алар икәү.

—Берсе кечкенәләр өчен, анда комлык та бар, икенчесе зурлар өчен. Аккошларны да шуннан ашатырга була,—диде Гаязетдин һәм гөлләр утыртылган бакча ягына таба атлады.—Алма агачлары да, балан да, карлыган да, аю камыры да, кура җиләге дә, миләш тә бар монда.

—Йөзем үсмиме?

—Йөзем үсми,—диде Гаязетдин Айбибигә таба борылып. Ул шундаен итеп карады ки, Айбиби курка калды. Нинди сорау бирәм, дип үкенеп куйды. "Беләсең ич инде, бу якларда йөзем үсми. Әллә ачуын китердем инде", дип уйлады ул гөлҗимеш агачлары тезелгән сукмак буйлап, адымын тизләтә төшкән Гаязетдинга иярде.

Сорыйсы килә иде Айбибинең: "Өйләнгәнме, хатыны бармы? Бер генәме? Аннары Йосыфының анасы Сара кай тарафта, Казанда, аның

кырында торамы? Казанда яшәсә, бире килерме, оныгын күрергә?.. Ләкин инде сорый алмады, Гаязетдин аның артык сорау бирүенә үпкәләгән кеше сыман әйләнеп килгәнче сүз катмады һәм Айбиби дә дәшмәүне артыграк күрде. Әмма юл буена үз-үзен орышты. Кеше никадәр тырышкан, ә ул аңардан мыскыл иткәндәй: "Йөзем үсмиме?" дип сорый...

—Абый комсызларча кылана. Ил артыннан ил яулый, халык артыннан халык,—дип сөйли башлады артына әйләнеп карамый гына, гүя ул бу хакта башка берәүгә сөйли иде, әйтерсең лә ниндидер аның кырына килгән күрше илнең илчесенә.—Аңа вакыт житми, ул империя өчен яши, хәтта сезне озатып куярга да вакыт тапмаган,—диде, Гаязетдин һәм туп-туры Айбибинең күзләренә карап:—Баскынчыларга хас сыйфат бу, жингәчәй, баскынчы империяләргә генә хас сыйфат. Мин ни өчен Хазарстанга кайтмадым дисез?.. Бары тик шуның өчен генә, жингәчәй. Мин бер халыкның да илен вә халкын яуларга теләмәдем, теләмим дә.

—Ләкин бит абыең син түгел,—диде Айбиби.

Гаязетдин тархан туктады һәм янә бер Айбибинең күзләренә карады.

—Мин баштан ук кахан булырга теләмәдем, жиңгәчәй. Миңа андый мөмкинлекне өлкән равва биргән иде, абыем хакына баш тарттым, абыем хакына,—диде Гаязетдин кисәк туктап.

Менә кайчан янә югалып калды Айбиби. "Бу ни инде, нигә мин аңа бәйләнәм соң әле?—дип тиргәде ул үзен һәм күз карашын аяк очына төшерде.—Килеп житмәгән килеш бит. Оял бераз, Айбиби, оял. Ул сиңа ханнар сараедай утар салдырып куйган. Сиңа, Йосыф кахан хатынына һәм Ибраһим энесенә..."

—Кичер мине, кичерә күр, Гаязетдин,—диде Айбиби аның беләгенә сарылып.—Кичер жиңгәчәңне...

Юк, кулын беләгенә салып калмады, бите белән күкрәгенә елышкандай итте.

Ул берни дә әйтмәде һәм кисәк тынып калды. Ахыр:

—Жингәчәй, бала елый башлар, сез юлдан, сез арыгансыз,—диде Гаязетдин һәм Айбибигә сарай кебек тоела башлаган өйгә таба кузгалды, һәрхәлдә ике катлы өй Айбибигә чынлап та хан сарае кебек тоела башлаган иде. Ә анда хезмәтчеләр генә түгел, Айбибиләргә ияреп кайткан гаиләләр дә аларны көтә иде инде.

—Гаязетдин углан, Гаязетдин углан,—дип ак сакаллы карт аңа таба килә башлады.—Безне Казанга алып китсәгез иде, минем анда угылым хезмәт итә.

Айбиби олау артына ияреп кайткан карт кешегә сәерсенеп карады, чөнки ул аны кайтканда бер тапкыр да күрмәде.

—Сез, хөрмәткә ия кеше—безнең белән кайттыгызмыни?

—Минем кешеләр алар,—дип аның каршына ук килеп басты олаубаш.—Өлкән равва биреп жибәрде. Авыру ул, арбадан да төшә алмады, шуңа күренмәде дә.

—Алпар йөзбаш, Алпар йөзбаш!—диде Айбиби күзләре белән йөзбашны эзләп.

—Мин монда,—дип, өйдән чыкты һәм болдырдан төшә башлады Алпар йөзбаш.—Гаҗәпләнмәгез, каханбикә, бу карт Казаннан Хазарстанга күчеп киткән заманында ефәк юлында йөргән Йосыф каханның сәүдәгәре. Миннән: "Илемә кайтып үлим",—дип, бик ялваргач, аны сезгә әйтми генә олауга алган идем...

—Гаязетдин тархан.—Олы кешегә хөрмәт күрсәтсәгез иде, үзегез белән алсагыз иде.

—Мин бу картны беләм, ил адәме, изге зат,—диде һәм картка таба борылып, баш иде тархан Гаязетдин.—Казанга кайткач, минем тарафыма кереп чыгарсыз, Габдулла агай.

Олуг карт төркиләрчә бер тезенә төште, әмма торасы итте, аягына баса алмады. Гаязетдин аның култыгыннан алып, аягына бастырды.

Айбибигә ни өчендер кыен булып китте. Нигә ул Гаязетдин алдында

гел уңайсыз хәлгә кала. Ул кырын күзе белән генә Йосыф каханның туганына карап алды һәм баланы күтәреп болдырдан төшеп килгән Рәшидә абыстайга таба китте.

—Без китик инде, җиңгәчәй,—диде Айбиби артыннан атлаган Гаязетдин.

Күр инде, рәхмәт әйтми, саубуллашмый да китеп бара ич. Нишләде әле ул, ни булды аңа?.. Әмма:

—Әйе, әйе, Гаязетдин тархан, без урнашып, җайлашып беткәч сезне дәшәрбез,—диде борылып. Рәшидә абыстай кулыннан баланы алды һәм баш ия-ия китеп барган кешеләр белән саубуллашты.

—Уф Аллам,—диде ул китеп барган олауга күз ташлап, кырындагы Рәшидә абыстайга.—Уф Аллам, абыстаем, мин аны күргәч ук саташып йөри башладым.

—Саташырлык та шул, балакай. Мин дә аны күргәч чак кына: “Йосыф кияү!” дип, дәшми калдым. Күрдем ич, син дә югалып калдың.

Айбиби Рәшидә абыстайга карап алды, әмма бер сүз дә әйтмәде. Бухак иде. Гаязетдин Йосыф атасына охшаган иде, суеп каплагандай, ике тамчы су кебек...

Ашап-эчкәч, Аккош күле тирәсен урап килделәр. Ни гаҗәп, Рәшидә абыстайның да, Айбибинең дә сөйләшәсе килми иде. Күл аларга ошады. Киң, тараеп киткән урыннары да бар. Ләкин күлдә аккошлар күренми иде. Бары тик үрдәкләр генә камышлыкларда су төбеннән нидер эзлиләр. Кинәт кенә моңсу булып китте Айбибигә. Бит анда аны аккошлары, казлары каңгылдашып шатланышып каршы алырлар иде, ә монда күзгә дә күренергә куркалар. Ни турында уйлаганын белгән кебек Рәшидә абыстай:

—Борчылма, балакай, барысы да җайланыр,—диде.

Айбиби җавап бирмәде, бары тик уфтанып кына куйды.

—Әйдә, абыстаем, безне анда мунча көтә, һич югы юл тузанын коеп чыгыйк,—диде.

Мунчаны күл буена, зур итеп салдырган иде Гаязетдин тархан. Мунча алды иркен, чәй ягы да бар, мунчаның үзенә янә бер бүлмә аша керәсе. Анадан-тума чишенеп, мунчага узгач, ләгәндәге суда үзенең йөзен күреп, Айбиби кеткелдәп көлеп алды.

—Ни булды?—дип сорады Рәшидә абыстай.

—Үземне көзгедән күргәндәй булдым. Үзем дә, үзем түгел дә икән. Шуңа көлдем.

Мунча кызу. Ләүкәгә менеп, бертын тирләп утырдылар. Рәхәт итеп тән җылына, аркалардан тир ага башлады.

—Менә хәзер күлгә чумып чыгасы иде, Айбиби,—диде Рәшидә абыстай.

—Ә нигә чумып чыкмаска икән. Мунчадан күлгә кадәр басма сузылган. Әйдә...

Балаларга хас чыр-чу килеп, мунчадан чыгып, басмадан күлгә життеләр. Килә-килүгә үк Айбиби баскычтан күлгә төште һәм йөзеп китте.

—Кер, кер, абыстаем, кер, су шундаен җылы, рәхәт.

Суга кереп чыгуга, кире мунчага йөгерделәр һәм кайнар ләүкәгә менеп кунакладылар.

Мине Казан тарафына атаң Талиб алып килгән иде. Бары бер тапкыр булды ул. Һәм шунда без тархан мунчасында юынып чыккан идек. Ул мунчаны да нәкъ шулай итеп салганнар иде. Тик басма күлгә түгел, Болакка төшәр иде. Һәй, Айбибием, ниндәен бәхетле чакларым булган—белмәгәнмен икән! Әлегә кадәр сөйләргә куркып йөрдем, оялдым. Болгарга кереп каберен күргәч, кыюланып киттем әле. Кичерә күр, балакай. Яраттым мин синең атанны, яраттым, гөнаһ булса да әйтим инде, хәтта бала табарга теләгән идем, сихерче карчык рөхсәт итмәде. Үз башына булуы бар, диде.

Айбиби бертын дәшми торды. Чынлап та аңа бу хакта сөйләшүе авыр иде. Ләкин хәзер андый хистән арынган иде инде ул. Ни өчендер бу халәт аңа нәкъ менә Гаязетдинне күргәч килде. Гөнаһ кылмагансың, абыстаем, бер дә гөнаһ кылмагансың, диясе килде аның, әмма кыймады, тыелып калды. Бары тик:

—Мин, абыстаем, Йосыфым кочагында тәмам эреп китәр идем,—диде.

—Ни дип атыйлардыр аны, әмма мәхәббәт бар, балакаем, дөньяда, бар.

—Бар, абыстаем, бар,—диде Айбиби һәм ни өчендер аның күз алдына янә кулыннан тоткан Гаязетдин килде.—Бар ул, бар!.. Әйдә әле, чап әле мине әнә шул пешекләгән себерке белән, абыстаем, Болгар мунчасындагы кебек...

Берсен-берсе чабышкач, аһ-ух килә-килә янә күлгә төшеп, сүрелеп чыктылар. Чыктылар да тагын ләүкәгә менеп кундылар. Ахыр Айбиби:

—Коеныйк та, хезмәтче хатынны дәшик, карачы хатын баланы китерсен,—диде абыстай һәм баскычка чыгып, хезмәтчене дәште.

—Баланы китерегез!

Баланы китергән арада, зур ләгәнгә су салдылар, талынкымы, бала түзәрлекме дип, Айбиби үзе суга терсәген тыгып карады.

—Бик әйбәт, түзәрлек, абыстаем.

Ул арада баланы китерделәр. Рәшидә абыстай баланың күлмәк бауларын чишеп салдырды да ләгән янына китерде һәм сак кына коендырасы итте, әмма Айбиби:

—Бир әле, абыстаем, үзем юындырыйм Ибраһимымны,—диде.

Айбиби баланы кулына алды, сак кына аякларын суга тыкты, аннары муенына кадәр житкәч:

—Күр әле, моны, күр әле, абыстаем, суда туган диярсең үзен, курыкмады да ичмасам.

—Син аның кулыннан тот та ләгән төбенә бастыр. Ике кулыннан да тот, ике кулыннан да.

—Ул курка, кулларга чат ябышты.

—Өйрәнер, без әле аны күлдә коенырга да өйрәтербез. Мин сине Идел суында да коендыргалаган идем әле, балакай.

Айбиби баланы йөздереп тә карады, су өстендә чалкан да яткырып тотты, ахыр арыгач, баланы Рәшидә абыстайга бирде.

—Мәле, абыстаем, коендыр баланы, мин дә коеныйм. Йә кәефсезләнә башлар.

Мунчада коенып, мунча җылысын тоеп кайткан бала караучы хатын кулына керүгә үк йокыга китте. Айбиби йоклап яткан бала йөзендә Йосыф кахан төсмерләрен күреп, кинәнеп куйды. Әмма шундук аның күз алдына Гаязетдин тархан килде. Айбиби ниндидер гөнаһта тотылган кешедәй тиз генә бала яныннан чыгып китте.

## XIX

Ун ел гомер үтеп китте...

—Ибраһим, Ибраһим дим, балакаем, күпме йөзәргә була инде! Аккошлар дисеңме?! Аккошларны мин ашаттым инде, ашаттым. Әнә аръяктагы дәрвишләр дә ашаталар аларны. Чык судан, житте.

Ибраһим ашыкмады, Айбиби улы судан чыгуга, аның иңбашына сөлге ташлады.

—Безне бүген Гаязетдин тархан көтә. Сарай мәктәбенә бирергә булдым мин сине, улым. Анда сезне Болгардан килгән мөгаллимнәр укытачак. Шулай диде абаң.

—Мин анда укырга теләмәсәм?

—Башта барып күрик әле, улым. Ошамаса мин сине...

—Нәрсә мине, әнием?—дип, барган җирдән туктап калды Ибраһим.—Хазарстанга илтерсеңме? Белеп тор, әнием, мин анда бармыйм да, анда укымаячакмын да.

—Нигә, улым. Нигә алай дисең?

—Хазарстаннан дәрвишләр Болгарга, Биләргә, Казанга киләләр, без Хазарстанга таба кузгалыйкмы, әнием? Хазарстанны су баскан.

—Кем шулай дип әйтте?

—Дәрвишләр. Алар белемле, бар нәрсәдән дә хәбәрдар халык, әнием. Моннан ерак түгел авылга утырганнар. Иганә исәбенә генә яшәмиләр, арпа игәләр, яшелчәләр үстерәләр.

—Әллә син дә анда баргалыйсыңмы?

—Бер тапкыр гына булдым.

—Кемнең нәрсәсе бар, табынга куялар да тамак ялгыйлар. Аннары яһүдләр кебек изге китаптагы һәр хәреф өчен бәхәс башлыйлар. Берсе бер төрле, икенчесе икенче төрле аңлата, өченчесе...

Ибраһим киенеп чыкты. Кара чәчле, кара күзле, атасыныкы кебек тутсыл йөзен күреп, Айбиби сискәнеп китте. Әтисенә охшаган иде улы, кечкенә Йосыф диярсең, йөреше дә, кыланышы да аныкы. И-и Ходаем, кая син, Йосыфҗан, кайларда саташып йөрисең? Рәшидә абыстай, әнә, Ибраһимы янына китте, иярде дә китте. Хәзер әнә өлкән раввасы Биләрдә хан сараенда утыра, имам хәзрәтләре булып. Ә бит бөтен бер Хазарстанны кулда тотучы өлкән равва иде. Хазарстанны су баскан елда Биләргә күчеп килгән дә хан сараенда имам хәзрәтләре булып алган, өченче ел бире килеп, Рәшидә абыстайны алып китте. Никахлылар иде ич. Башында чалма, өстендә кыйммәтле хөллә, аякларында болгари итек. Айбиби ни Рәшидә абыстаена, ни элеккеге өлкән равва Ибраһимга бер сүз әйтә алмады, бер сүз дә хәтта... Тегенең һәммә җирдә мөселманнарча дога кыла-кыла вәгазь укуын күргәч, тәмам зиһене чуалды. Ул гынамы, Йосыфы турында сорарга да онытты. Менә ни дәрәҗәгә каушаган иде ул. Ә бит сорыйсы булган—аның Йосыфы кая? Вафатмы, орышларда шәһит киттеме, иле-дәүләте су астында калса да каханнарын җир йотмагандыр Хазарстанның. Хак, аңа сөйләделәр, имеш, викинглар белән ызгышта Йосыф кахан кинәт юкка чыга. Мәетен таба алмыйлар. Ә менә викингларны чакырган һәм мөселманнарны таларга һәм илдән куарга өндәгән коткычы өлкән равва бүген Болгар ханы сараенда имам хәзрәтләре!.. Моңа ничекләр гаҗәпләнмәскә кирәк!

Улы артыннан кайтып, ашап утырганда да, юлга җыена башлаганда да, юл чыккач та Айбиби шул хакта уйлады. Өлкән равва исән, иманын алыштырган да исән-имин яши бирә. Ә ул күтәргән, ул Хазарстан каханы иткән аның Йосыфы кая!.. Әллә соң чынлап та викинглар кулыннан һәлак булдыңмы, Йосыфы?

Инде Казан каласының мәчет манаралары да күренә башлады, мәшһүр кальга да. Бу кальганы бик борынгы заманнардан ук күтәрә башлаганнар, диде аңа Гаязетдин тархан. Гаязетдин өйләнгән, бер хатын белән генә көн күрә икән. Хатыны чибәр, җирле халыкның морза кызы булып чыкты. Укымышлы, шигырьләр яза икән хәтта. Беренче тапкыр киленнәрен күргәч тә Айбиби бу баладан күңелендә көнләшү кебек бер хис уянып китүен тойган иде. Үзе дә белми ни өчен—ләкин бу халәт булып алды. Соңыннан Гаязетдиннең хатынын яратып яшәвен күргәч, күңелендә нииндидер кимсенү тойса да килен белән ясалма елмаю аша аралашудан ары китә алмады. Тик ул моны беркемгә дә сиздермәде, хәтта бүген Биләрдә яшәгән Рәшидә абыстайдан да яшерергә тырышты, әмма тәҗрибәле абыстай аның Гаязетдингә карата булган мәхәббәтен беренче көннән үк сизенгән иде шул... Ахыр килеп, улы Ибраһимны ул Шәмгун ханның сарай мәктәбенә дә озата ала иде. Хан сараенда дөньяга исемнәре билгеле булган галимнәр эшли, аларның күбесе сарай мәктәбендәге балаларга сабак бирәләр иде. Тик горур хатынның Гаязетдинне ешрак күрәсе килә иде шул, һәм ул, улы Ибраһимны Казан мәктәбенә бирергә булды. Хак, ул аны үзе генә түгел, утарына дәшеп, аерым имамнардан да укытты, әмма бала үскән саен аңа тирәнрәк белем кирәк, ә ул белемне кала мәктәпләрендә һәм хан сарае мәк-

тәпләрендә генә алырга була иде. Айбиби исә улы Ибраһимны Гаязетдин тархан мәктәбенә бирергә булды. Шушы ният белән Казанга юнәлүе иде. Бу хакта улы Ибраһим да белә, ләкин бер тапкыр да: "Әнием, нигә мине Болгар мәдрәсәсенә бирмисен?"—дигән сорау куймады. Рәхмәт ана.

Кучәрбаш атларны куалый башлады, сиртмәле арба жинелчә тирбәлә-тирбәлә Казан елгасы күперенә якынлашты. Кала инде гүя уч төбендә: биек таш диварлар, ук очар ара саен күзәтү манаралары, әле анда, әле монда күккә омтылган мәчет манарасындагы айлар. Утарда яшәү рәхәт, тыныч иде. Монда исә калага житмәс борын шау-шу ишетелә башлады. Кала капкасына житәрәк асма күперләр алдында арбалар тора, кальгага керергә нәүбәт көтәләр. Аларның арбасы жиденче булып, килеп туктады. Ул арада капкадан үзенең яугирләре, жансакчылары белән Гаязетдин тархан килеп чыкты. Анын башында каурый кунган, алтынга буяган очлым, өстендә ярымжинле укалы жилән, ат өстендә рум чүпрәге япмасы, япма алтын жеп белән тукылган, күзнең явын үзенә тартып тора. Ләкин Айбиби боларның берсен дә күрмәде, ул бары тик хәрби киемдәге Гаязетдинне генә күрде. Күр инде, бит анын Йосыфы да нәкъ шулай киенер иде, аты да, дирбияләре дә Йосыфныкына охшаган, очлымына кадәр.

—Саумы, жингәчәй, саумы энекәш Ибраһим!—дия-дия Гаязетдин тархан алар арбасы янына ук туктады һәм, борылып, арттан килгән жансакчысына:—Жингәчәйне алдан уздыр!—диде.

—Рәхмәт инде, рәхмәт, туганый,—дия алды Айбиби, Ибраһим исә, аягына торып басып кул изәде.

—Имам хәзрәтләре сезне көтә,—диде Гаязетдин һәм атын жилле генә юырттырып, зур күпергә таба элдерде.

—Менә, улым, син шушы калада яшәрсең инде. Абаң Гаязетдин минем сарайда яшәр дигән иде дә, мин аңа мәктәп балалары кайда яши, шунда яшәр, шунда торыр дидем.

—Рәхмәт, әнием,—диде Ибраһим.

Ашыкмадылар. Урам тулы халык, ике тәгәрмәчле арбага тауар төягән базарчылар агыла, йоннары өяләнгән этләр коерык селкеп калалар. Шулар арасында өрфия яулыклы, муенына кызыл шарф элгән, калфагы берьякка авышкан, бала итәкле зәңгәрсу аксыл күлмәк кигән кыз бала күзгә чалынып китә. Әнә шул кызны күрүгә, Айбиби Хазарстанга килеп төшкән мәлен күз алдына китерде. Ул да шулайрак киенгән иде. Яшерми, Ханбалык аңа ошамады. Пычрак сулар түккән урамнары... Ерактан ук балык исе килә. Хатын-кызлар кебек, инбашына көянтә сыман асып, озын таякка кипкән балыклар элгән сатучылар уза. Алар һәр очраган кешегә кипкән балык тәкъдим итәләр...

*Ахыры киләсе санда*



## Шамил Маннапов

# ТОРМЫШ СИРАТЫН КИЧКӘНДӘ

***

**Мин төшендем һәрбер яңалыкның
Бәхет кенә алып килмәсен:
Бәхетемнең ярар искесе дә,
Яңа бәла килә күрмәсен.**

***

**Бу дөньяны үзгәртергә теләп,
Тырышабыз инде һаман да.
Һәм үзгәрә дөнья...
Тик белмибез:
Яхшыгамы, әллә яманга?..**

***

**Уңны-сулны чамалавы кыен,
Инсаният кая юл тота?
Бик еш кына була шундый халәт:
Үлем түгел, яшәү куркыта.**

***

**Яшәү кыен үчкә—үч белән,
Яраттырып булмый көч белән.
Шул уй бирми миңа тынгылык,
Яман хәбәр килсә Чечнядан.**

***

**Безнең татар ат ярата, диеп,
Борынгыдан килдек макталып,
Ләкин, бик еш, язмыш сынаганда,
Агач атка калдык атланып...**

---

Шамил МАННАПОВ (1938) *— шагыйрь; "Тамырлар", "Кайту" һ. б. шигырь китаплары авторы. Проза җыентыклары да дөнья күрде. Казанда яши.*

***

Ахирәттә хәтәр тәмуг бар, дип,
Бүгеннән үк нигә көясе,—
Тәмугын да аның, оҗмахын да
Бу дөньяда башлап күрәсе.

***

Төнге күкне ярып, йолдыз атыла,
Әнә тагын берсе сызылып янды...
Йолдыз булып, ахры, коела шулай
Галәм агачының яфраклары.

***

Вакыт елгасы ага да ага,
Хатирәләр комын зиһенеңнән юып ала.
Туган якны, балачакны сагыну гына
Алтын бөртегедәй төпкә утырып кала...

***

Яши-яши искәрәсең
Мәшәкатьле тормышта.
Искәрәсең, сискәнәсең:
Көн—озын,
Гомер—кыска...

***

Үләрмен дә онытырлар, диеп,
Син борчылма әле алай ук,—
Бит Яхшылык кына онытыла,
Онытылмый ласа Начарлык...

***

Явызлыкның "даны" никтер олы,
Явызларны белә гавам, Ил.
Гаҗәп түгел,
Фәрештәләрнең дә
Шөһрәтлесе ләса—Газраил...

***

Доллар "кояшы"ның яктысында
Югалды "коммунизм шәүләсе".
Ачык күренә хәзер
Калын кесәлеләр
Һәм ярлының тишек әрҗәсе.

***

Туган халкым!
Заманында сиңа
Төште икән кемнең каргышы?—
Балаларың читкә сибелгәннәр,
Язмышлары—Сак-Сок язмышы.

***

Әй, туган җир!
Синнән аерылып,
Булгалады читкә чыкканым.
Шул чакларда поезд көпчәкләре

**Тәкрарлады:**
**“Татарстаным!**
**Татарстаным!**
**Татарстаным!..”**

***

**“Безнең поезд инде киткән...”—дисең,**
**Китә бирсен, әйдә, киткәннәр.**
**Вокзалда да начар булмас иде,**
**Синең белән гомер иткәндә...**

***

**Әллә кайчангыны искә алып,**
**Битәрлисең икән ник кенә?—**
**Беләсеңме,**
**Үзен рәнҗеткәнне онытмыйча,**
**Кинә саклый усал эт кенә?**

***

**Җан сөйгәнең белән яшә икән,**
**Бер кисәкне бүлеп урталай.**
**Шунда гына бәхетең тулы булыр,**
**Җаның—тыныч, йөзең—тулган Ай.**

***

**Беләм—җаның теләмәгән ярда**
**Гомер-көймәң бәйләп тотканың.**
**Аһ, бу тормыш әкият кенә булса,**
**Канатлы ат белән чыгып юлга,**
**Кайтыр идем—сине коткарып...**

***

**Авылымда мин бер кунак кына,**
**Һәм үз булалмадым калада.**
**Кабул кылынмаган уразадай**
**Яшим бугай—ике арада.**

***

**Авылымда сирәкләнә йортлар,**
**Буш нигезләр, гүя каберләр.**
**Иң хәтәре: кадер күбрәк хәзер**
**Икмәгеннән бигрәк, хәмергә.**

***

**“Һаман кызлар күзли, карт шайтан!”—дип,**
**Ашыкмагыз аннан көләргә,**
**Буйдак улын өйләндерәсе бар,—**
**Чыккандыр ул кәләш эзләргә.**

***

**Сез әйтәсез кайчак: “сагынып булгач,**
**Ник киттең, дип, туган ягыңнан?”**
**Язмыш мине, ахры, моңлансын да**
**Күбрәк җырласын, дип, аерган...**

***

**Сөйгәнеңә чәчәк бүләк итү**
**Нигә, димсең, кергән гадәткә?**
**Бу гомернең бик тиз үтәчәген,**
**Адәмнең дә бер көн шиңәчәген**
**Искәртәдер өзелгән чәчәкләр?!**

***

**Кем сөйли: "Картлык—яшьлекнең**
**Матур дәвамы..."—дия?**
**Хакыйкатьтә, картлык бит ул—**
**Яшьлеккә пародия...**

***

**Түрәләргә күпләр сәлам бирер,**
**Башын иеп, дустым, диерләр.**
**Тик түрәләр чын дусларын бары**
**Түрәлектән төшкәч белерләр.**

***

**Көзге көндәй чытык йөзеңә карап,**
**Бик әйтәсем килә:**
**"Соңлама,**
**Көлеп яшә! Чөнки мондый форсат**
**Булмаячак "теге дөньяда..."**

***

**Буш вакытта кибетләрдә йөрим,**
**Тауар—уйма! Ләкин кулым буш.**
**Кибет янындагы мәйданчыкта**
**Мактау тактасында урын буш.**
**Хөрмәтләрлек адәм калмаганмы,**
**Фотолары нишләп монда юк?**
**"Даһи башы" барельефы гына**
**Берьялгызы тора моңаеп...**

***

**Ахирәттә очрашырга язсын**
**Сезнең белән...**
**Шуңа күрә мин**
**Әҗәл килгәндә дә, хушыгыз, димәм,**
**Сау булыгыз...—гына диярмен.**

***

*Кадыйр абый рухына*

**Тәнендәге олуг зур җаны**
**Бу дөньяга, ахры, сыймады,**
**Бакыйлыкка ашкынган кебек,**
**Эчтән янды һаман—сызланды...**

***

Үлем нәрсә?—ул нибары
Җирдән алган матдәләрне
Кире Җиргә кайтару гына.
Һәм күкләр иңдергән җанының
Очуы янә Ходай хозурына...

***

“Ник болай?” да, “Ник тегеләй?”—
Балаларда мең сорау:
Әнисе янынннан бара
Гүя тере кыңгырау.

***

И Табигать,
Бу Мәхәббәт дигән татлы хисне
Кайсы оҗмахлардан алдың син?
Нәфрәт дигән иблислекне җанга
Тәмугтанмы китереп салдың син?..

***

Кешегә ышанырга кирәк, дибез,
Шушы ышануда терәк, дибез,
Ләкин кеше кешегә ничек ышансын,
Аллаһка да ышанмагачтын?!

***

Үзен кече санавыннан беләм
Олы җанлы адәмне:
Йолдызлар да күренә ласа күктә...
Бары тәңкә кадәрле.

***

Бу дөньяда һәр нәрсәнең, имеш,
Бар башы, бар азагы;
Бер генә чиксез нәрсә бар,
Ул—Мәхәббәт газабы...

2003—2004

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



**Әхмәт Рәшит**

## ГАЛИЯ АПА

хикәя

Мин озата барган товар поезды Бель-агач станциясендә тукталып калды. Каршы яктан "Литерный" килә диделәр. Озак көтәрбезме икән, дип, стрелочникка таба кузгалган идем, күптәнге танышым Жакен агай үзе очрады. Сменасын тәмамлаган. Исәнлек-саулык сораштык.

—Ике сәгатьсез кузгала алмыйсыз әле,— диде ул. —Начальство бөтен юлларны тикшереп йөри.

—Кем килә соң? Юл бүлеге башлыгымы, әллә министр үзе үкме?..

—Кем белә инде аларны? Безгә алдан әйтмиләр бит... Ярар, ашыгам... Барасы җирем бар... Бер танышыма өен сипләргә булышам, дип, вәгъдә биргән идем...

Ул ашыгып китеп барды. Кызык карт ул Жакен агай. Кыш көннәрне, поезд озак туктап торган арада мин еш кына аның будкасына җылынырга керәм. Ул ашыкмый гына тел астына насбай сала, аны төкергәч, нечкә генә "Прибой" папиросын көйрәтеп җибәрә, аннан төчкерә-төчкерә тагын әллә нинди тәмәке тузаны исни башлый. Үзе туктаусыз сөйли. Казакъчаны юньләп белмәгәч, бөтенесен аңлап та җиткермим—аны очындырып, йә баш кагып куям, йә үземчә көлгән булам. Ул арада кузгалырга вакыт җитә.

Бу юлы, Жакен агай янәшәдәге саман өйләр ягына борылып киткәч, үземнең эш урыным саналган иң соңгы вагонның буферына учым белән шапылдата-шапылдата байтак кына уйлана калдым—ул кадәр вакытны ничек үткәрергә? Ташлап китсәң, ачуланырлар—ни дисәң дә, үзенә күрә бер хуҗалык бит. Хәер, минем бу "Башмак" дигән тимер кисәгенә кемнең күзе төшсен?! Вагонның ике ягындагы фонарьлардан керосинын агызып алсалар гына инде...

Петардалар, факел-шәмнәр, тагын әллә ниләр тутырылган сумкамны кулга тоттым да, вокзал ягына кузгаласы иттем.

Һи-и! Күпме поезд килеп тыгылган—бөтенесе "Литерный"ның үтеп киткәнен көтә. Менеке кебек товарныйлар гына түгел, пассажирныкылар да тукталган икән әле. Кайда вагоннар астыннан, кайда тамбурлар аша үтә-үтә, ниһаять, киң, иркен мәйданга килеп чыктым.

---

Әхмәт РӘШИТ (1936) — *шагыйрь; «Фидаиләр», «Ике гасыр арасында», «Таң илчесе» һ.б. китаплар авторы; Г.Исхакый премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Анда, агачлар күләгәсе төшкән бер урында кавын, карбыз, кымыз, балык, көнбагыш саталар, пассажирлар белән әрепләшә-әрепләшә аз-маз көнлек акча эшлиләр. Арлы-бирле киләп сарып йөргән арада, кинәт игътибарымны өлкән яшьтәге бер ханым җәлеп итте. Ничектер, таныш иде аның йөз чалымнары. Ләкин... кайдан беләм соң мин аны?! Моңарчы бу станциядән үткәндә күземә чалынганы булмады шикелле. Шулай да... шулай да таныш иде ул миңа, күптәннән таныш иде. Бит уртасындагы миңе дә, елмайганда иреннәрен кызык итеп кысып куюы да, кешене үтәли тишәрдәй үткен карашы да... Ләкин... кем?

Мин аның каршында озаграк таптанып тордым бугай, ул ничектер уңайсызланып кына:

—Кай поездбен кетпексиң?! Жолың болсын... быр-рат!— дип куйды.

Шул "быр-рат" дигән бер сүзе җитә калды. Әйе, бу—ул! Моннан егерме ел элек гаип булган авылдашыма ике тамчы су кебек охшаган иде ул. Мин, тисә—тиенгә, тимәсә—ботакка, дигәндәй, тәвәккәлләргә булдым, татарчалап:

—Исәнме, Галия апа?!— дидем.

Ул кинәт сискәнеп, калтыранып куйды, тик барыбер казакъчасыннан аерылмады:

—Ә синең атың кандай?..

—Мин... Рөстәм...— дидем мин. Аннан аңлаешлырак булсын өчен өстисе иттем. —Пышталиун...

Ул, көнбагыш тутырылган капчыкны ялгыш аударып, каударланып аркылы атлап чыкты да, муеныма килеп сарылды:

—Пышталиун!.. Жанкисәгем минем... Ничек монда килеп чыктың? — Муеныма аның кайнар яшьләре тамды.

Мин бутала-бутала моннан ерак түгел генә, Семейдә, әниемнең апаларында торуымны, тимер юлчылар курсын тәмамлагач, товар поездларында өлкән кондуктор булып йөрүемне әйттем.

Галия апа:

—Апаң... шул Мәсрүрҗиһан апаңмы?— дип сорап куйды.

Уңай җавап ишеткәч:

—Аулак өйләргә бергә йөри идек. Ул гармун да уйный иде бит әле. Сугышка киткән егетләрне безгә ул алыштырды... Ә мин менә монда...— диде. —Дөнья шулай шул ул, пышталиун быр-рат.

Ирексездән башымда, бер-берсен этә-төртә төрле уйлар актарылды, хәтеремдә яшен тизлеге белән үткәннәр терелде.

Галия апа безнең авылның иң чибәр, иң чая кызы булгандыр. Кем генә аны үзенә каратырга хыялланмады?! Ә ул Хәлимҗан абыйны, фәкать аны гына ярата иде. Ләкин алар сөюләрен беркемгә дә сиздермәделәр—бу серне без өчебез генә белә идек. Өчебез, дим... Чөнки мин аларның эч серләрен белеп торучы бердәнбер кеше, бер-берсеннән хатлар ташучы "пышталиун" идем.

Шулай бервакыт, балалар бакчасында тәрбияче булып эшләүче Галия апа аулак җиргә минем бер үземне генә алып керде дә кәгазь кисәге сузды: "Кара аны, беркемгә дә сиздермә, кеше күрмәгәндә генә Хәлимҗан абыеңның үз кулына тапшыр, син бит акыллы, быр-рат",— диде. Шуннан китте инде—мин, алты яшьлек малай, алар арасындагы "пышталиун"га әверелдем. Галия апаны да, Хәлимҗан абыйны да ни өчендер бик-бик якын күрә идем мин. Кая ул аманәткә хыянәт итү, берәрсе бәйләнә башласа, мин аны өзгәләп ташларга да әзер идем.

Бервакыт авыл клубында атаклы "Галиябану"ны куйдылар. Хәлил ролендә Хәлимҗан абый, Галиябану булып Галия апа уйнады. Әй, шулкадәр әйбәт уйнадылар—чын артистлар да алай булдыра алмый торганнардыр. Авыл кешеләре: "И, бигрәкләр дә килештереп уйнадылар, и бигрәкләр дә пар килгәннәр инде, үзләре дә йөрешә торганнардыр әле",— дигән фаразлар әйтсәләр дә бер елдан оныттылар. Мин белгән серне аларның берсе дә белми иде!

Сугыш башланып, Хәлимҗан абый ут эченә китеп барганда гына сер сандыгы ачылды. Армиягә китүчеләрне авыл башында озатып калганда, Галия апа, хисләрен тыя алмыйча, елый-елый сөйгәненең кочагына барып сарылды. Һич кенә дә онытасым юк, атлар кузгалып, шактый киткәч тә, Хәлимҗан абыйның:

*Галиябану сылуым, иркәм,*
*Кем бәхетенә үстең син...—*

дип җырлаганы ишетелеп торды.

Минем "пышталиун" вазыйфаларым шуннан соң чын почтальон кулына күчте. Еш яза иде Хәлимҗан абый хатларын. Галиябану апа, мине берәр аулак җиргә алып кереп, аларны кат-кат укый иде. Берәр ел үтте микән, хатлар килүдән туктады. Әти-әниләре дә аптырашта иде: һәлак булган дисәң, үлгән хәбәре юк. Ләкин алар барыбер өметләрен өзмиләр, һаман ниндидер могҗиза көтәләр иде. Галия апа да көтте, елый-елый зарыгып көтте. Ләкин...

Солдатка алыныр алдыннан Хәлимҗан абый, мине ялгызымны гына очратып: "Галия апаңны сакла... Сакла Галия апаңны!.."— дип кат-кат кисәткән иде. Ә мин... саклап бетерә алмадым.

Кырык өченче елны микән, безнең авылдагы балалар бакчасын бөтенләй бетереп, Галия апаны авыл советына эшкә күчерделәр. Ул вакытта Хәлимҗан абыйдан да хат-хәбәр килүдән туктаган иде. Ләкин Галия апа аны һаман да... һаман да көтә иде.

Авыл советында ул вакыт дорфалыгы, катылыгы, дуамаллыгы белән авылда яман аты чыккан Нургали абый рәис булып эшләде. Аның бер аягы аксак иде, шуңа күрә сугышка алмадылар. Безнең бөтен бәхетсезлегебез дә нәкъ менә шул кеше аркасында башланды. Тагын "безнең", дим, чөнки мин үземне Хәлимҗан абый белән Галия апа арасындагы мәхәббәтне бәйләп торучы бер чылбыр буыны дип хис итә идем.

Көннәрдән бер көнне Галия апаны ничектер боек, борчулы, төсе качкан кыяфәттә очраттым. Ул мине кочаклады да озак кына җитен чәчләремнән сыйпап торды. Мин уңайсызланып кына:

—Хат һаман юкмы?..— дип сорадым.

Галия апа:

—Хаты килсә дә ни хәл итәсең, мин барыбер Хәлимҗан абыеңа лаек түгел инде хәзер... Шул пред тәресе генә харап итте...— диде. Аннан күз яшьләренә буылып, тиз-тиз китеп барды.

Берничә көн үткәч, авылда коточкыч хәбәр таралды: Галия суга ташланган да батып үлгән икән, диделәр. Киемнәрен яр буена салып калдырган. "Минем үлемемдә беркемне дә гаепләмәгез, яшәвемнен мәгънәсе калмады",— дигән язу гына табып алдылар. Өлкәнрәкләр суга чума-чума эзләп тә караган иделәр—гәүдәсен тапмадылар. Районнан килгән милиционер кул гына селтәде—сугыш вакыты, аның кайгысымыни, янәсе...

Ә минем сөекле Галия апам, никадәр керсез күз яшьләренә сәбәпче булган Галия апам, менә монда, туган авылдан еракта, Казакъстанның беркемгә дә билгесез диярлек Бель-агач станциясендә көнбагыш сатып басып тора.

—Авылга кайтканың бармы соң?— дип сорады ул. —Анда ни хәлләр?

—Кайткалыйм. Минем хәзер әти белән әни дә юк бит инде. Бердәнбер сеңел дә үлеп китте... Бала тапкан чагында... Сирәк кенә кайткалыйм. Хәлимҗан абыйны да күргәләгән идем...

Галия апа ничектер дөртләп кабынып киткәндәй булды, ябык бите буйлап кинәт кенә күз яшьләре агып төште.

—Ничек? Исән-сау әйләнеп кайттымыни?

—Кайтты... Сугыш бетеп ике ел үткәч тә... Әсирлектә булганы өчен төрмәгә утыртканнар. Аннан, гаебе табылмагач, чыгарганнар... Бик ябыккан иде. Миннән гел сине сорашты.

Галия апа авыр сулап куйды. Ә мин дәвам иттем:

—Кече арьяктагы Бәдертдин абыйның Галияләрен беләсеңдер. Шуңа өйләнеп, бер ел тордылар да аерылдылар... Бик каты эчүгә сабышты.

Кайчагында мине үзләренең бакча артындагы су буена алып төшә иде дә, елый-елый сине сораштыра иде...

Элек мин белгән, дөньяның тик матурлыгын, яктылыгын гына күргән, күзләрендә шаян очкыннар уйнап торган, мәзәкчән Галия апаны бу мизгелдә танырлык түгел иде. Минем үземнең дә күз читләремнән яшь бөртекләре бәреп чыкты.

—Саклана алмадык шул... Ничектер жебегән чагыма туры килде... Хәлимҗан абыеңның үлгәненә дә ышана башлаган идем инде. Иң авыры—халыктан җыйган заем акчасының юкка чыгуы булды. Нургали абыең "төрмә... төрмә..." дип котымны алды. Син дә саклап бетерә алмадың... Югыйсә, Хәлимҗан абыеңа вәгъдәләр дә биргән идең...

—Син дә сүзеңдә тормадың бит,— дидем мин.

Галия апа ничектер ачуланып, күз агы белән карап алды.

—Анысы шулай... Гаепле мин...

—Юк, аны әйтмим мин, Галия апа,— дип, үз-үземне төзәтергә ашыктым. —Хәтерлисеңме, безне—балаларны болынга алып чыккач: "Менә бу өч яфраклы үләннең дүрт яфраклысын тапсагыз, әтиегез сугыштан исән-сау әйләнеп кайта",— дигән идең. Бер малай да тапмады. Мин генә ул үләннең дүрт яфраклысын таптым. Әти... кайтмады...

—Нишлисең, язмыштан узмыш юк... Миңа да шул бер чишенгән килеш суга гына ташланасы калгандыр да... Гөнаһысыннан курыктым. Мордар китүдән... Хәлимҗан сугышка озатылыр алдыннан: "Мә, берәр җирдә яшереп сакла",— дип, затлы киемнәрен миңа биреп калдырган иде. Елга ярына баскач, үзебезнең печәнлек, шул киемнәр тутырылган бөктәр искә төште. Төн уртасында шул ирләр киеменә киенеп, яр буйлатып кача-поса чыгып киттем мин Чәчәкледән. Һәм менә көнчыгышка таба барган поездның күмер ташый торган вагонында шушы якка килеп эләккәнмен... Хәлимҗан абыеңны еш күрәсеңме соң?

—Бер-ике елдан ул кайсыдыр якка китеп барды,— дип дәвам иттем мин. —Ерак көнчыгышка диделәр... Балык тотарга... Авылда син белгән байтак кешеләр юк инде... Кайсы читкә китте... Кайсы үлде... Нургали абый да үлде.

Галия апа әйтерсең тораташ булып каткан иде.

—Шулаймыни?..— диде ул салкын гына. Аннан, авыр уйларыннан арынырга теләгәндәй, як-якка башын чайкап куйды:

—Шулай икән дөньяда хәлләр, пышталиун быр-рат. Ә мин менә казакъ малайлары үстереп ятам. Бишәү... Икесе аякка басты инде. Әнә, Жакен агаең һаман пенсиягә чыга алмый. Житмеш бишен тутырды инде... Акча җиткерә алмыйбыз...

—Стрелочник Жакен агайны әйтмисеңдер бит?!

—Шул инде, шул... Мин авылдан качып киткәч, карчыгы белән ул сыендырды мине. Башны кая куярга белмәгән чак иде бит. Аннан аның карчыгы да үлеп китте. Балаларын мин карарга калдым. Олылары шул беренче казакъ хатыныннан. Кечеләре—минекеләре дә җитлегеп килә. Төпчегебез унбиштә. Элекке хатыны үлгәч, минем ризалыгымны сорады. Әйбәт кенә, кыенсынып кына әйтте. Нишлим инде, карышмадым. Дөнья көтәргә кирәк бит.

Якыннан гына—иң беренче юлдан кычкырта-кычкырта ике яшел вагон өстәп таккан товар поезды үтеп китте. Бу—әлеге дә баягы шул "Литерный" иде. Мин хушлашырга ашыктым.

—Тагын килермен... Аннан бөтенесен сөйләшербез,— дидем мин, станция ягына таба кузгалып.

—Көтәм, пышталиун быр-рат... Иртәгә дә, берсекөнгә дә монда булам. Көтәм... көтәм...— дип кычкырып калды Галия апа. Ничектер бик өзгәләнеп кычкырып калды.

Дөнья шулай шул ул!..

Кем уйлаган бит...

Хәлимҗан абый авылга кайтып төшкәндә, мин инде шул каһәр суккан

сугыш аркасында сирәгәеп калган егетләр арасына керерлек, инде борынга кызлар исе керә башлаган яшүсмер идем. Шунадыр, ул мине үз тиңе санады бугай, инде элеккечә малайсытып карамады. Эч серләрен дә түкми-чәчми бушата торган булды. Өйләнер алдыннан да минем белән кинәште. “Бер Галия урынына икенче Галия булыр, бераз булса да йөрәк януларын басылыр”,— дидем мин. Ләкин Бәдертдин абый Галиясе безнең Галия апабызны алыштыра алмагандыр, күрәсең. Авылда: “Начар торалар икән. Хәлле кеше кызы бит, баш бирәсе килмидер”,— дигән сүзләр йөрде. Хәлимҗан абый салгалый башлады. Чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, Нургали абыйның кинәт кенә үлеп китүен дә аннан күрүчеләр булды. Ә чын дөресен фәкать без икебез генә белә идек. Фаҗига булган ул көнне авыл советы йортында Хәлимҗан абый Нургали абый белән бергә озак кына мәҗлес корып утырганнар. Исерүе җиткәч, Нургали абый, ничек Галия апа белән йоклавы турында мактана башлаган. Хәлимҗан абый салгаласа да тыныч кеше иде—аның беркайчан да күтәрелеп бәрелгәне, башкалар белән җәнҗал чыгарганы, хәтта начар сүз әйткәне, сүгенгәне дә булмады. Нургали абый, авыз ера-ера:

—Каптырдым мин синең Галиябануыңны. Үпкәләмә... Акча мәсьәләсендә тәҗрибәсез иде шул... Дебет-кредит... понимаешь... Тәҗрибәсез кешенең башын әйләндерү берни түгел... Менә үлүе генә жалко,— дип сөйләнгән.

Хәлимҗан абый:

—Кабәхәт икәнсең...— дигән дә, стаканын идәнгә бәреп ватып, чыгып киткән. Нургали абый да аның артыннан ук өенә кузгалган:

*Галиябану, сылуым, иркәм,*
*Кем бәхетенә үстең син,—*

дип җырлый-җырлый, чайкала-чайкала кайтканын күрүчеләр дә булган. Өенә кайтып җитәрәк, күрәсең, егылган да тора алмагандыр. Февраль аеның чатнама суыгы бит. Тикшерү үткәрүчеләр “Катып үлгән” дигән нәтиҗә ясадылар. Мәрхүмнең туганнары, шунда озатып куйган булса, ни була иде инде, дип, Хәлимҗан абыйга үпкәләп йөрсәләр дә, аңа каты бәрелә алмадылар. Авылдагы имеш-мимешләрне җиңәрлек дәлилләр саллы иде шул.

Хәлимҗан абый бер очрашкач ачылган иде:

—Кичер, Рөстәм энекәш, синең сүзләргә ышанмаганнан түгел... Аның үз авызыннан ишетәсем килде. Шуңа лыкынганчы эчерттем мин аны... Хәер, болай да кимен куймый иде инде...

Аннан... нигәдер тешләрен шыгырдатып алды да:

—Авылдан бөтенләйгә китәрмен инде мин. Хәзер монда якыннарымнан беркем дә калмады. Кайда да бер кояш... Йә, хуш, пышталиун быр-рат,— дип өстәде.

Шуннан соң мин аны бөтенләй күргәнем булмады. Минем күңел күгемне балкытып янган ике йолдыз еллар үткән саен ерагая, тоныклана барды.

Һәм... менә көтмәгәндә-уйламаганда бу соңгы очрашу. Очраклы очрашу. Меңнәрчә чакрымнарның төенен бер тылсымлы ноктада тоташтырган аңлаешсыз, әмма күңелне бик сиздерми генә гел-гел кыбырсытып торган сәер мизгел.

Вәгъдәмдә торам дисәм дә, тиз генә Бель-агач станциясе аша үтәргә, Галия апаны күрергә насыйп булмады. Безнең бригаданы Рубцовск юнәлешенә түгел, Алейская ягына билгеләгәннәр иде. Кондукторлар резервы башлыгына кереп үз хисабыма ял сорарга туры килде.

—Нәрсә, өйләнергә жыенмыйсыңдыр бит,— дип шаяртты җитәкчем. — Бель-агачта чибәр казашкалар күп анда. Яшь чагында минем дә күзләр төшкәли иде...

Мин борын астыннан нәрсә мыгырдаганмындыр—анысын хәтерләмим, әмма гаризама кул куелуга шул якка китәсе поездга йөгердем. Галия апага бәләкәй генә күчтәнәчемне—бик затлы шәлне тапшырырга, авыл хәлләрен бәйнә-бәйнә сөйләшергә, үзеннән дә нәрсәләрдер сорашырга иде исәбем.

Әмма ул, мин уйлаганча, теге вакытта көнбагыш сатып торган урында юк иде. Мин базардагы хатыннардан Галия апаны сораштырдым. Бөтенесе беравыздан диярлек:

—Ул юк инде,— диделәр.

—Ә кайда соң ул?— дидем мин бу сәер җавапка аптырап.

—Әнә, Жакен әкәдән сора... —Хатыннар вокзал буфетына төртеп күрсәттеләр. Мин, нишләргә белмичә, шул якка йөгердем. Кәгазь кисәкләре, балык калдыклары аунаган пычрак өстәлгә ике кулы белән таянып, бик битараф кыяфәттә исерек Жакен агай утыра иде. Җилкәсенә кагылгач кына ул күтәрелеп карады. Аннан таныпмы, нәрсәдер әйтәсе килепме, ишетелер-ишетелмәс кенә:

—Жок Галия айналаен,— дип куйды. Ул юньләп сөйләшер халәттә түгел иде. Өстәл янына милиционер килде. Башта миңа шикләнебрәк караган төсле иде—өстемдә тимер юлчылар киеме булгач:

—Сез анық кеме буласыз?— дип кенә сорады.

Мин аңлаттым.

Милиционерның чыраендагы табигый кырыслык йомшара төште—ул уфтанып алды да:

—Харап булды шул Галия апагыз. Монда көнбагыш сатарга йөри иде бит,— диде. —Үлгәненә ике атнадан артты инде. Күпме тырышып карадым, мондагы халыкны тәртипкә өйрәтеп булмый шул. Капчыгын өстерәп вагоннар астыннан гына чыкмакчы булган. Күлмәк итәгеме, капчык бавымы вагонның ниндидер тимеренә эләккән дә, нәкъ шул вакытта поезд кузгалып киткән. Менә шулай әрәм булды Галия апабыз. Бөтен поселок ярата иде аны. Жакен агай да кызганыч... Аны ябып куюдан да ни мәгънә?! Бер акылына килер әле... Кызганыч... Бик тату торалар иде...

Мин, Жакен агайны аңына китереп, ниндидер җылы сүз әйтергә, юатырга да уйлаган идем, ләкин ул өстәл өстенә салган башын күтәрмәде.

—Ярар, йокласын, бераз айныгач өйләренә үзем илтеп куярмын,— диде милиционер.

Минем дә бу исерек кеше янында өрәк кебек утыруымнан мәгънә юк иде.

Тимер юлда мондый фаҗигаләр әледән-әле булып тора. Нишлисең?! Галия апа да пассажир поезды килгәнче өлгерим, дип ашыккандыр. Бәлки әле, мин килер, дип тә уйлагандыр. Күрешергә язмагандыр, күрәсең. Күңелемдә берөзлексез, хәтерне бимазалап, инде күптәннән онытылган:

*Эзләдем, таптым, югалттым,*
*Инде табылачак түгел,—*

дигән җыр яңгырап торды.

...Поезд көпчәкләре туктаусыз бер көйгә тыкылдый. Минем, өметләрем тәмам өзелеп, өйгә кайтып барыш. Рельслар поездның иң соңгы вагоны көпчәкләре астыннан үзләреннән үзләре шуышып чыгадыр сыман. Рубцовск ягыннан состав алып кайтучы хезмәттәшем:

—Нәрсә булды сиңа? Ник бер сүз дә дәшмисең?— дип мине сөйләштерергә маташа.

Нәрсә диим соң?! Дөньяның фанилыгы, елларның болгавырлыгы, язмышларның аянычлыгы турында сөйлиммени?!

Ике гашыйк арасында сөенеп йөргән "пышталиун"ның ни әйтер сүзе, ни тапшырыр хаты юк бүген...

⁂



Луиза
Янсуар

# ЙОЛДЫЗ БӘХЕТЕ

## Өн

Кар астыннан дәшә үләннәр:
—Язга еракмы?
Язга еракмы?

Учта эри энҗе-бөртекләр:
—Без тик кунакмы?
Без тик кунакмы?

Ә җил—илче, хәбәр китереп,
Кагыла иңнәргә,
Кагыла иңнәргә:

—Йөгең сал да, адәм, бәхилләш,
Вакыт китәргә,
Вакыт китәргә.

Ни калыр соң мәңге җуелмый—
Җилме, туфракмы?
Җилме, туфракмы?

...Күкне ярып кайта таныш өн:
—Җиргә еракмы?
Җиргә еракмы?..

***

Мәхәббәттә генә тигез җаннар.
Кануннар юк монда һәм юк чикләр.
Мин, гасырлар аша урап кайтып,
Җанның нечкә кылларына чиртәм.

...Чүлләр кичәм,
Айкыйм диңгезләрне.
Үләннәргә кушылып җырым сузам.
Мин, Галәмнең күзләренә багып,
Иң-иң серле юллар аша узам...

Кануннар юк монда.
Һәм юк чикләр.
Без—дәвамы изге Хәтер-җепнең.
Бар хакыйкать шунда яшеренгән:
Мәхәббәт ул—җаны Мәңгелекнең!

Луиза ЯНСУАР — *шагыйрә; "Күзен ача умырзая" һәм "Мин күкләргә кайтам" исемле шигырь китаплары авторы. Казан дәүләт университеты аспиранты.*

***

Җил сүтә дә, үрә толымнарым,
Җил чуалтып китә хисләрем...
Мин бу юлга сине эзләп чыктым,
Нинди генә үрләр кичмәдем.

Җан җылыңны тойдым һәр туфракта,
Кошлар авазында—өнеңне.
Синең сурәтеңә әверелеп,
Җилфердәде учак һәр төнне.

Юлда... моңнарыңнан сихерләнгән
Гөлләр кинәт телгә килделәр...
Дөнья буйлап сине эзләп киләм,
Һәр тарафта—тик син, син генә!

Мин, ахры, югалтмадым сине,
Мин, ахры, таптым үземне.
...Җил сүтә дә, үрә толымнарым.
Камаштыра Кояш күземне...

## Озату

Арабызда карурманмы калка,
Җәеләме дәрья сулары?
Сихерләнгән чиктән үтә алмый,
Басып калам, сузып кулларым.

Качмыйм инде язмыш юравыннан,—
Безнең Бәхет—яра, моң ла ул!
...Минем җанда—яфрак яңгырлары,
Тамчыларның серле чыңлавы...

Җәйме, Кышмы иңгән арабызга?!—
Шәфәкъләр Моң булып кабына.
...Сихерләнгән чикләр аша үтә,
Үз сукмагын табып, җан гына...

## Моңаю

Акбүз атым суга сусагандыр,
Алып төшәм төнге елгага.
...Ай тибрәнә дулкын өсләрендә,
Сулар шундый моңсу—тын ага.

Басмалардан гына иеләм дә,
Аккан суга түгәм бар моңым.
Ләйсән тамчылары булып иңсен
Йөрәгенә аның сагынуым.

Җырым саклап йөртсен еракларда,
Кайтсын ярым данга күмелеп.
Яулык болгап каршы йөгерермен,
Чулпыларым чыңлар сер түгеп...

Татлы уйларымнан айнып китәм,
Карашымны дулкын кисә дә...
Атым мөлдерәп бага күзләремә,
Кешнәвеннән таллар сискәнә.

Ялларына җил сарылып уйный...
Без икебез—моңлы җаннар ла.
...Акбүз атта очам хыялыма
Алсуланып аткан таңнарда...

***

Ә Үткәннәр җанга кире кайта,—
Күтәрелә, кага дулкыны.
Кай мизгелдә атлап чыккан идек,
Үзебез дә сизми, упкынны?

Бәхет өчен өзелергә торган!—
Шулкадәр күпмени түләсе?!—
Үләннәрнең чыклы яше белән
Үлчәгәндер Язмыш, күрәсең...

Аһ! Киләчәк Язлар дөрләп яна—
Сөю сукмаклары ут кына...
Кай мизгелдә җиңеп-җиңелдек соң,
Нинди корбан сорый упкыннар?!

***

Какты җанга,
Түгелмичә калды,
Өзелердәй булды сулышым...
Күкрәгемне айкап,
Ярала Моң,
Тере дулкын төсле тулышып.

Таң чыгыдай
Куна керфекләргә,—
Өзелә алмый күпме сулкылдар?!
Күкрәгемә
Учым куеп түзәм...
Дөрләп торган ут күк дулкыннар.

Янартаулар
Бер бушана ласа,
Ярларыннан ташый бар сулар.
...Күкрәгемне ярып,
Күккә аша
Җырга әверелгән ярсулар...

## Йолдыз бәхете

Йолдыз бии учта
Елап-көлеп,
Әллә бәхеттәнме исереп?
Гашыйк җанын кайнар учка салгач,
Бер мизгелдә мең хис кичереп.

**Ничә гасыр кичкән**
**Серле җанның**
**Балкышыннан кабынып Төн яна.**
**Ул, тетрәнеп, аваз сала кинәт**
**Кешеләргә, Җиргә, Дөньяга:**

**"Җирдәгеләр**
**Бу бәхеткә ничек**
**Түзә ала икән, өзелми?!**
**Бәгырьләрне көйдерер наз, хыял**
**Биектәрәк ник соң сизелми?.."**

**Тик ул белми әле**
**Мизгел өчен**
**Җирдә ничек кыйммәт түләсен,—**
**Яшәү тылсымнарын бүләк иткән**
**Шул учларга ятып сүнәсен...**

***

**"Син Күкләрне колачладың. Инде**
**Җиреңә кайт,—диләр,—яңадан".**
**Гүя белми алар, нинди моңнар**
**Саркыганын шигъри ярадан.**

**Мин тамырым белән Җирне кочам,**
**Җаным белән иңлим Күкләрне.**
**Бер мизгелдә тоям йөрәк аша**
**Еллар, чорлар шаулап үткәнне.**

**Гамь һәм сагыш иңсә, туфрак ярып,**
**Серле аваз дәшә офыктан.**
**Яралганмын әллә Мәңгелекнең**
**Күкрәгендә шыткан орлыктан?**

**Ул офыклар әле туганчы ук**
**Сихер өргән, ахры, җаныма.**
**Иңнәремә куйган ике канат,**
**Нурын сипкән Хыял таҗыма.**

**Җир дә, Күк тә үз бишегем минем!**
**Меңнәр әле миндәй ымсынып.**
**...Ә җан барыбер Күкләр аша кайта**
**Тояр өчен Яшәү тылсымын...**

## Кайгы

*Перед этим горем гнутся горы...*
А. Ахматова

*Кайнар канның җирдә ачы яшькә*
*Кушылмаган көне сирәктер...*
З. Мансуров

**1**

**Нинди зарлы хәбәр илтә**
**Төнге җилләр, дымлы җилләр?**
**"Ят илләрдә афәт бар бит,**
**Уяу бул син бүген..."—диләр.**

Уяулыкны безнең канга
Язмыш үзе учлап салган,—
Күпме яулар кичкән баштан,
Күпме эзләр җанда калган.

Ник гел зарлы хәбәр илтә
Ятим җилләр, үксез җилләр?
"Дөньяларда афәт бар бит,
Гамьсез булма бүген!"—диләр.

2

Ә анда—гомерләр өзелә...
Ә анда—шундый ук саф Күкләр!
Ә анда—сабыйлар яшь түгә,—
Шул өнне тоеп, җан, җан күкрәр.

Ә анда нәфрәт бар, өмет бар,—
Барын да сыйдыра Җир җаны.
...Ник бүген һәлакәт көткәндәй
Каршылый соң йөрәк һәр таңны?!

3

Бу кайгыдан таулар бөгелерме?—
Кан-яшь тәме—чишмә суларында.
Җил, кагылып, нинди көй уятыр
Тетрәп торган күңел кылларында?

Ат уйнаган далам туфрагында,
Сөякләрне ярып, гөлләр үскән.
Дөнья күзен сөрем каплаганда,
Терелер күк җаннар—җиргә күчкән.

Бу кайгыдан таулар бөгелсә дә,
Җан кыйбласын җуймас, айлы күген...
Бабаларның каны күкрәгемдә
Әрнү өне булып кайный бүген!..

***

Күгемдә йолдызлар энҗедәй яшь кояр...
Җандагы гамьнәрне
Бары Күз, Күз тояр.

Офыклар тын гына ал шәлен ябыныр...
Өметләр Моң булып,
Җыр булып кабыныр.

Дулкынга сал салам—гөлләрдән үрелгән.
"Син" диеп, таңнарда
Кояшка үреләм.

Утлары көйдерә әрнүле бәхетнең.
Күкләрем түгел лә,
Син—җанга тәхетем.

Биектә йолдызлар юксынып яшь кояр...
Күзләрнең сагышын
Бары Яз, Яз тояр...

Солтан
Шәмси

# КҮК КАПУСЫ АЧЫЛСА...

ТАРИХИ-ФӘЛСӘФИ БӘЯН

## ДИННӘР НИ СӨЙЛИ?

*Илаһи Гакыл кешелек дөньясына төрле формаларда иңә—диннәр, рухи тәгълиматлар, пәйгамбәрләр белән акыл ияләренең өйрәтмәләре, вәгазьләре рәвешендә, шулай ук фәнни һәм фәлсәфи трактатлар, гениаль шагыйрь, язучы, рәссам, сынчы әсәрләре, уйлап табучыларның идеяләре мисалында һ.б. төрләрдә. Шулай безгә Күкләрдән рухи ярдәм килеп тора. Бу элемтә беркайчан да өзелеп тормаган. Әгәр дә без кешелек дөньясы тарихын күздән кичерсәк, әлеге элемтәнең кайсы заманда җанланганын, кайсы дәвердә сүрелебрәк торганын ачык күргән булыр идек. Җир йөзендә Нур—Яктылык һәм Караңгылык, Томаналык дәверләре чиратлашып килә, алар арасында туктаусыз көрәш бара, әле берсе, әле икенчесе өскә чыга.*

*Без бүгенге көндә кичергән заманны чын мәгънәсендә адәми затның Күкләр белән гаять актив элемтәгә кергән дәвере дип бәяләргә мөмкин. Бүгенге көндә Тәрбиячеләребездән иңгән мәгълүматлар, киңәшләр, өйрәтмәләр шул хакта сөйли.*

*Кешелек дөньясы җитди сынаулар дәверенә аяк баскан шушы заманда адәми зат үзенең нинди тарихи юллар узганын, нәрсәгә ирешкәнен һәм нинди мөмкинлекләрне кулдан ычкындырганын аңларга тырыша, чөнки фәкать шушы нигездә генә, хаталарны төзәтеп, алга барып булачагын ул аңлый.*

*Соңгы елларда диннәргә карата да мөнәсәбәт үзгәрә. Бер яктан, хәзерге көндә диннәрнең кабат җанлануы, бастырылып яткан еллар өчен реванш алырга, мөмкин кадәр күбрәк җаннарны үз канаты астына кертергә омтылуы күзәтелә, икенче яктан, җәмгыятьнең укымышлы катламы диннең һәр сүзен сукырларча кабул итүдән ерак тора. Хәзер кеше динне, аның тәгълиматын тарих, фән, фәлсәфә бизмәненә салып үлчәп карарга, хакыйкатьне эзер килеш йотып җибәрмичә, фикер иләге аша уздырырга, аны үзе эзләп табарга тырыша. Теге яки бу дини тәгълимат нинди нигездә үсеп чыккан, нинди тарихи-социаль ихтыяҗ аркасында ул көчәеп киткән, халыкларны үз байрагы астына туплый алган. Теге яки бу диннең асыл тәгълиматы ни дәрәҗәдә заман таләпләренә җавап бирә, әллә инде җавап биреп җиткерә алмый. Мәгълүм бер дин кешегә ни дәрәҗәдә бүгенге заманны, кискен үзгәрешләр чорына килеп кергән катлаулы дөньяны аңларга ярдәм итә, әллә андый йөкне инде күтәрә алмый.*

*Дөньяда диннәр күп булса да, һәр диннең үзәген кешелек дөньясына җиткерелергә тиешле төп фикерләр тәшкил итә: адәми затның Раббыбыз тарафыннан яралтылуы, кешенең илаһи зат булуы, Раббысы белән рухи элемтәдә торганда, Ул күрсәткән юлдан барганда бәхеткә, һәртөрле бәрәкәткә ирешүе, андый адәмне Раббыбызның явыз көчләрдән саклавы һ.б.*

*Моннан тыш кайбер диннәрнең төп китапларында кешелек дөньясы тарихында булып узган һәм киләчәктә көтелгән төп вакыйгалар да теркәлә, шулай алар гасырлар, мең еллар буе һәр буынның хәтеренә төшерелеп килә. Шушы күзлектән чыгып карасак, диннәр бүген без килеп кергән һәлиткеч Күчеш Дәвере хакында берәр сүз әйтәме?*

---

*Дәвамы. Башы 7 санда.*

*Без кичергән заман турында ул чыганакларданиләр бар? Нинди төп вакыйга даими рәвештә адәми затның исенә төшерелеп килә?*

*Инде диннәрне күздән кичерик. Әмма артык җәелеп китмәс өчен үзебезне чикләргә туры килер, чөнки җир йөзендә диннәр күп, аларны колачлап алу мөмкин түгел. Шуңа күрә өч классик дингә—иудаизм, христиан һәм ислам диннәренә тукталыйк. Безне кызыксындырган мәсьәлә бу диннәрдә ничек куела һәм ничек хәл ителә?*

*Шушы өч диннең төп чыганакларын барлый башласак, андый вакыйганың кешелек дөньясы кичерәчәк Хисап көне булуында бернинди шик калмый.*

*Күзәтүебезне хронологик тәртиптә алып барсак, иң әүвәл яһүдиләр диненә мөрәҗәгать итәргә тиеш булабыз. Ул әлеге өч диннең иң борынгысы—безнең эрага кадәр 1 нче меңьеллыкта ук барлыкка килгән. Иудаизмның байтак чыганаклары Библиянең борынгы өлеше Иске Гаһедтә (Ветхий Завет) тупланган. Бер уңайдан шунысын да искәртеп үтик: яһүдиләр Библиянең әүвәлге өлеше булган Иске Гаһедне генә таный, Яңа Гаһедтә (Новый Завет) Гайсә пәйгамбәр һәм аның апостоллары яктыртылганга—аны кабул итми. Бу хәл үзе үк диннәр арасында бер-берсенә көнчел, хәтта, әйтергә мөмкин, дошмани мөнәсәбәт яшәвен күрсәтә. Бу хәл бар халыклар өчен уртак булган Раббыбызны бүлгәләү галәмәте дип бәяләнергә тиештер, мөгаен.*

*Димәк, Иске Гаһед...*

## ИСКЕ ГАҺЕД ҺӘМ ХИСАП КӨНЕ

Күктәге идарәче даирәләр — Иерархия — җир йөзендә югары рухи үсешкә ирешкән аерым кешеләр белән һәр заманда элемтәдә торган, алар аша диннәр, рухи тәгълиматлар, төрле гыйлемнәр бирелгән. Пәйгамбәрләр фәкать шулай барлыкка килгән. Иске Гаһедтә борынгы заманнарда яшәгән байтак пәйгамбәрләрнең тормыш юлы, нотыклары, язмалары тупланган. Алар барысы да яһүдиләр тарихы, дине, тормыш-көнкүрешенә карый. Арада Даниил пәйгамбәр эшчәнлегенә багышланганы аерым игътибарга лаек. Ул Библиягә "Даниил пәйгамбәр китабы" *("Книга пророка Даниила")* дигән исем белән кергән.

Бу шәхеснең тормыш юлы да гаять кызыклы. Ул чыгышы белән аксөякләр нәселеннән була. Бабил падишаһы Навуходоносор, Иудеяне яулап алгач, үз хозурына хәрәм агасын чакырып ала да:

— Син Исраил егетләре арасыннан буйга-сынга камил, чибәр, акыллы һәм гыйлем үзләштерергә, сараемда хезмәт итәргә лаеклы берничәсен сайлап ал, аларны халдей телендә сөйләшергә, безнең китаплардан файдаланырга өйрәт, — дип боера. Падишаһ бу эшне башкарып чыгу өчен хәрәм агасына өч ел вакыт бирә.

Нишләмәк кирәк, падишаһ әмере үтәлми кала алмый. Шулай тиешле егетләр сайлап алына. Алар арасында Даниил да була. Аларга падишаһ өстәленнән туену да билгеләнә. Кыскасы, егетләрне уңайлы, имин һәм тук тормыш көтә. Халдей телен өйрән дә китаплар укы. Әсир итеп чит илгә китерелгән кеше өчен моннан да зур бәхет була аламы?

Әмма Даниил алдына бер мәсьәлә килеп баса — аның падишаһ эчкән шәрабларны эчеп тәнен пычратасы килми. Шулай ук ит ризыклары белән туенуны да ул өнәп бетерми. Шул сәбәпле ул хәрәм агасына бер үтенеч белән мөрәҗәгать итә:

— Миңа, падишаһ өстәленнән туенмыйча, яшелчә, ипи һәм су белән генә яшәргә мөмкин булмас микән? — ди ул.

Хәрәм агасы моңа каршы:

— Мин падишаһ әмерен боза алмыйм. Әгәр дә син, яшелчә һәм су белән генә яшәп, ябыгып китсәң, йөзең төссезләнсә, моның сәбәбе иртәме-соңмы барыбер беленәчәк. Мин падишаһ каршында гаепле булып калачакмын, — ди.

Даниил исә үзенекен тукый:

— Син безнең белән шундый тәҗрибә үткәр: безгә ун көн буе яшелчәләр ашап, су гына эчеп яшәргә рөхсәт ит. Әгәр дә шул вакыт эчендә ябыгып китмәсәк, падишаһ ашлары белән туенган иптәшләребездән төскә-биткә ямьсезрәк күренмәсәк, анда үзең нәтиҗә ясарсың, — ди.

Ун көн үткәннән соң хәрәм агасы, егетләрне тезеп куеп, чагыштырып карый һәм яшелчә белән туенган егетләрнең йөзләре чистарак та, яктырак та икәнен, тәнгә дә ябыкмаганлыкларын күреп гаҗәпкә кала.

Шул көннән хәрәм агасы падишаһ сыйларын үзенә калдыра, ә аларга теләгән хәтле

яшелчә, икмәк бирә башлый. Шулай мәсьәлә уңай хәл ителә. Яшелчә генә ашап, шәрабфәләп беләп мавыкмаган Даниил һәм аның өч иптәше уку-язуда, халдей телен һәм мәшһүр халдей гыйлемнәрен үзләштерүдә дә нык алга китәләр. Нәкъ шушы чорда Даниилның рухи дөньясында, ниндидер пәрдәләр ачылып китеп, егеттә зур үзгәрешләр башлана. Аңарда күрәзәлек итү, вакыйгаларны алдан күрә белү, күргән төшләрне юрау кебек сәләтләр барлыкка килә.

Өч ел вакыт узып та китә. Навуходоносор алдында имтихан тотканнан соң Даниил өч иптәше белән падишаһ сараенда хезмәттә калдырыла. Әсир итеп китерелгән кеше буларак, аның хәтта исеме дә үзгәртелә. Тик тарихка ул барыбер Даниил пәйгамбәр булып кереп кала.

Шулай ул Персия *(ул вакытта Халдея)* падишаһлары сараенда хезмәт итә башлый. Аның сарайда абруе үсеп китүе, зур дәрәҗәләргә ирешүе падишаһның беркем аңлатып бирә алмаган төшләрен оста һәм дөрес юрый белүенә бәйле.

Көннәрдән бер көнне Навуходоносор падишаһ куркыныч төш күрә, шул төштән күңелендә зур шом һәм вәсвәсә юкшыны утырып кала. Ә менә эчтәлеге хәтереннән чыга. Ничек кенә исенә төшерергә тырышмасын, һич булдыра алмый. Төшне исенә төшерү өчен Бабил каласының мәшһүр гыйлем ияләрен, багучыларны, күрәзәчеләрне җыя, тик берәү дә аңа җавап бирә алмый. Эчтәлеге онытылган төшне юрап бирү мөмкин түгеллеген, моны җир йөзендәге бер генә кешенең дә башкарып чыга алмаячагын падишаһка кат-кат аңлаталар, ләкин ул һаман юрап бирүне таләп итә. Тик берәүнең дә моңа көче җитми. Ахыр чиктә җен ачулары чыккан падишаһ әрәмтамак гыйлем ияләрен җәзага тартырга боера. Бу исемлеккә Даниил белән иптәшләре дә керә.

Эш болайга киткәч, Даниил иптәшләрен һәм Бабил каласы галимнәрен коткарып калу өчен падишаһның җан сакчылары башлыгына мөрәҗәгать итә, аның булышлыгы белән Навуходоносор падишаһ хозурына керүгә ирешә.

— Падишаһлар падишаһы, бөек падишаһ! Әгәр дә миңа беркадәр вакыт бирелсә, төшне юрап бирергә алынып идем, — дип теләген белдерә.

Навуходоносор падишаһ көтәргә була. Даниил бу хакта иптәшләренә кайтып сөйли, Ходайдан үлемнән коткаруын үтенеп сорарга куша. Үзе дә, Ходайдан ярдәм өмет итеп, догалар укый.

Шул төнне йокы вакытында Даниилга бер күренеш иңә, падишаһның онытылган төше дә, аның мәгънәсе дә аңа ачып салына.

Иртәгесен Даниил падишаһның җан сакчылары башлыгына килә:

— Падишаһка әйт, Бабил галимнәрен җәзага тартмасын. Мин аңа төшен юрап бирергә әзер, — ди.

Бераздан аны Навуходоносор падишаһ янына кертәләр. Падишаһ аннан:

— Син онытылган төшемне, аның мәгънәсен юрап бирергә чыннан да әзерме, — дип сорый.

Даниил башын ия дә:

— Падишаһлар падишаһы, бөек падишаһ! Мәңге яшә! — дип, Навуходоносорны сәламли, аннан сүзгә кучә. — Бу төшнең эчтәлеген дөньяда бер генә гыйлем иясе дә, күрәзәче дә белә алмас. Бу эшкә бары тик Күкләрдәге Раббыбызның гына кодрәте җитә. Ул, бөек падишаһ, минем аша сиңа серне ача. Әлбәттә, мин башкалардан зирәгрәк булганга түгел, син, бөек падишаһ, барысын төшенсен, күңелең тынычланып калсын өчен ача Ул бу серне, — ди.

Шушы сүзләрдән соң Даниил падишаһка аның киләчәк язмышына кагылган бик әһәмиятле бер вакыйганы сөйләп, аңлатып бирә. Күрсәткән олы хезмәте өчен падишаһ аны мәшһүр Бабил каласының галимнәре башлыгы итеп билгели. Шулай бирегә әсир итеп китерелгән Даниил чит мәмләкәттә искиткеч зур дәрәҗәгә ирешә. Бүгенге сүзләр белән әйтсәк, зур карьера ясый.



*Даниил пәйгамбәр арысланнар белән чокырда.*

Шушы вакыйгадан соң ул Халдея патшаларының төп күрәзәчесе, төш юраучысы һәм киңәшчесенә әверелә. Навуходоносордан соң тәхеткә утырган падишаһлар Валтасар, Дарий заманнарында да Даниил үзенең сәләтләре белән аларга күп хезмәтләр күрсәтә, аның даны тирә-якка тарала, башкалар аңлатып бирә алмаган кыен мәсьәләләр алга килеп басканда гел Даниилга мөрәҗәгать итәләр. Дарий заманында ул шундый зур абруй казана ки, падишаһ аны мәмләкәтендә идарә итүче йөз егерме вилаять башлыклары өстеннән куелган өч вәзирнең берсе итеп билгели. Бу хәл тәхеткә Кир падишаһ килгәнче дәвам итә. Билгеле булганча, безнең эрага кадәр 540 елда Халдеяны Кир исемле Ассан идарәчесе яулап ала. Ул Иудеядән әсир итеп китерелгән яһүдләргә үз ватанына кайтырга рөхсәт бирә. *(Күрәсең, берәр яшерен хезмәт күрсәткәннәрдер.)* Күп тә үтми илле мең яһүди туган илләренә юнәлә. Тик Даниил бу вакытта инде бик карт була, ул гомере бәхетле үткән мәшһүр каладан китәргә теләми. Анда бөтенләйгә кала.

Без Библиядә тасвирланган Даниил пәйгамбәр тарихын юкка гына искә төшермәдек. Эш шунда ки, Даниил пәйгамбәргә гомере буе Күкләрдән төрле күренешләр иңә һәм ул аларны теркәп бара. Шуңа күрә дә алар Библиядә урын алгандыр. Аңа иңгән күренешләр арасында илаһи мәгънәгә ия булганнары да шактый. Арада "заманнар төкәнгәндә" булачак дөньякүләм вакыйгаларга багышланганнары үзләренең масштаблылыгы белән адәм баласының аңын тетрәндерердәй көчкә ия.

Көннәрдән бер көнне Даниил пәйгамбәргә Ахырзаманда булачак Хисап көне күренешен күрсәтәләр. Бу күренешне ул болай тасвирлый:

"Менә, ниһаять, мин тәхет куелганны һәм шул тәхеткә Ходайның *(Библиядә Ходай тәгалә — Ветхий Днями дип атала — С.Ш.)* тәхеттә урын алганын күрдем. Аның өстендә кардай ак кием, чәчләре саф дулкын сыман; тәхете ут ялкыныдай, аның тәгәрмәчләре уттай дөрлиләр. Аның алдыннан сузылып утлы елга ага; Аңа меңнәр һәм меңнәр хезмәт күрсәтә, бихисап халыклар язмышы хәл ителгәнне көтеп Аның алдында тора. Хөкемдарлар урын ала һәм Китаплар ачыла". *(Даниил. 7: 9 — 10)*

"Даниил пәйгамбәр китабы"нда, Ахырзаман килгәч, адәм балаларының гөнаһларына карап ике төркемгә бүленәчәге турында да ап-ачык әйтелә: "Күпләр пакьләнер, йөзләре чистарыр һәм алар, нәфесләрен җиңә-җиңә, үзләрен нык үзгәртер; яманнар исә яманлык кылыр һәм берсе дә моны аңламас, ә зирәкләр барысын да белеп торыр". *(Даниил. 12 : 10)*

Гаҗәп хәл, бу текстны укыганда, аның Библиядән китерелгәнен белмәсәң, безнең бүгенге тормышыбыз күз алдына килә дә баса. Бу сүзләрне бүгенге газеталарда көн дә басыла торган хәбәрләрдән дип кабул итәргә дә мөмкин.

"Даниил пәйгамбәр китабы" аеруча әһәмиятле сорауга җавап бирү белән тәмамлана. "Бу гаҗәеп хәлләрнең ахыры кайчан булыр?" дигән сорауга анда мондый җавап китерелә: "... бу хәлләрнең чиге заманнар, заман һәм ярым заман төкәнгәндә, изге халыкның көче тәмам бетте дигәндә килер", — диелә анда. *(Даниил. 12 : 7)*

Чыннан да, соңгы елларда без намуслы, инсафлы, пакь җанлы һәм тыйнак "изге халыкка" көн тәмам бетеп килгән чорда яшәмәдекмени? Кешеләр табигый сайланыш, җаннарының нинди сыйфатта булуына карап күзгә бәрелеп торган ике төркемгә бүленмәде мени? Саф җаннарның бу елларда газап чигеп яшәвен күрмибезмени?

Шулай итеп, вакытлар төкәнгәндә кешелек дөньясының авыр чорга килеп керәчәге, зур сынауларга дучар булачагы турында моннан берничә мең ел элек үк пәйгамбәргә иңгән күренешләр аша адәм балаларына җиткерелә килгән һәм бу хәбәрләр дин китапларында теркәлеп калган. Икенче төрле итеп әйткәндә, Хисап көне хакындагы мәгълүматлар кешелек дөньясы хәтерендә җуелмыйча сакланып калырга тиеш булган. Шулай борынгы заманнарда ук тиешле мәгълүматлар кешелек дөньясы хәтеренә салып куелган һәм имтихан бирү вакыты якынлашканда аның калкып чыгуы, үз эшен башкаруы алдан күздә тотылган.

## ЯҢА ГАҺЕД ҺӘМ ХИСАП КӨНЕ

Иудаизм, ягъни яһүдиләр дине тарихта бер илаһка инануга нигезләнгән беренче дин буларак билгеле. Фәкать яһүдиләр аша кешелек дөньясына Бер Илаһка табыну идеясе иңдерелә. Әмма монда бер җитди сорау җавапсыз кала: әллә инде бу чорда яһүдиләрнең рухи дөньясы бу идеяне кабул итү өчен әзер булган, әллә алар, башка халыклар кебек

*(әйтик, Мисыр халкы),* күп аллалардан торган катлаулы мәҗүси дин йогынтысында яшәмичә, Бер Илаһка табыну идеясен чагыштырмача җиңел үзләштерергә сәләтле булганнар. Бу дин яһүдиләргә бирелгәндә аның тора-бара башка халыкларны да үз канаты астына алуы күздә тотылганмы, әллә инде ул фәкать шушы кавем өчен генә барлыкка килгәнме? Һәрхәлдә, безнең мондый сорауны бирергә хакыбыз бар кебек. Әмма тарих барышында шактый кызык хәл килеп чыга—яһүдиләр бу динне фәкать үзләренә генә бирелгән дин дип, үзләрен исә Ходайның иң яраткан һәм башка кавемнәр арасыннан сайлап алынган абруйлы халкы дип һич икеләнмичә игълан итәләр. Бу исә аларда милли эгоизм, үз-үзеңне башка халыклардан өстен кую кебек хисләр тәрбияли. Шулай итеп, ул чорда бер илаһка инану тәгълиматы киң дөньяга таралмый кала.

Әгәр дә без Библиянең "Иске Гаһед" өлешен ачып карасак, анда: "Господь, Бог твой; Господь, Бог наш; Господь, Бог отцов ваших..."—кебек гыйбарәләрнең тулып ятканына игътибар итми калмабыз. Кыскасы, иудаизмда Ходай Тәгалә бары тик яһүдиләр, бары тик алар белән генә Үзара Килешү *(Завет)* төзегән Илаһ буларак урын алган. Шулай бу дин күпмедер вакыттан соң тәмам кристаллашып кала, формаль яктан үтәлә торган ритуалларга урала һәм нигездә бер милләткә генә хезмәт итүче тәгълиматка әверелә. Әлбәттә инде, мондый дин җир йөзенә таралган күп халыкларга рухи таяныч була алмый, ул кечкенә бер милләт дине генә булып кала. Галимнәрнең әйтүенчә, бүгенге көндә борынгы диннең бар таләпләрен үтәп яшәгән ортодоксаль яһүди алты йөздән артык кагыйдәне башкарырга тиеш икән. Бу инде ирекле тормыштан бөтенләй баш тарту, үзеңне борынгы кагыйдәләр колына әйләндерү дигән сүз.

Шулай кешелек дөньясына яңа дин—христиан дине бирелә. Христиан динендә инде иудаизмдагы кебек чикләнгәнлек, тарлык, бер милләткә генә йөз тоту бөтенләй юк. Гайсә пәйгамбәр аша бирелгән яңа тәгълимат җир йөзендә яшәүче адәм балаларының барысы өчен дә уртак булган принципларга таяна, милләт дигән төшенчәне гомумән телгә алмыйча, барлык халыкларны үз канаты астына чакыра. Соңрак үсеп чыккан Ислам да шушы ук принципны алга сөрә.

Яңа диннең барлыкка килүе өчен тиешле ихтыяҗ һәм шартлар булырга тиеш. Коры җирдә бер нәрсә дә үсеп чыга алмый. Нәрсәнедер ясалма рәвештә кертергә азаплану да, гадәттә, зур нәтиҗә бирми. Моның өчен тормышның үзендә көчле ихтыяҗ, аңа сусау булырга тиеш. Шул вакытта гына яңа тәгълимат, тормышның үзеннән килгән рухи сутлар белән сугарылып, үсеп китә ала һәм каршы торучы көчләр белән көрәшергә, җәелеп китәргә сәләтле була.

Христиан дине шул ук яһүдиләр арасында барлыкка килә һәм бу дингә нигез салучы Гайсә *(Иисус)* пәйгамбәр үзе дә яһүдиләрдән була. Шуңа күрә яһүд дине башлыклары, яңа пәйгамбәрнең нинди идеяләр таратуын аңлап алу белән, Гайсәнең вәгазьләрен тизрәк туктатырга, төрле мәкер ятьмәләре корып, аны юкка чыгарырга тырышалар. Аңа: "Син Канунны бозарга килгәнсең",—дигән гаепләүләр ташлыйлар, вәгазьләре вакытында берәр ялгыш сүз ычкынмасмы дип , эшчәнлеген җентекләп тикшереп торалар, Гайсәнең халык арасында үсә барган абруен төшерү, аннан арыну өчен сәбәпләр эзлиләр.

Гайсә пәйгамбәр бер вәгазендә үзен Канунны бозуда гаепләүчеләргә җавап итеп: "Мине Канунны бозарга яки пәйгамбәрләрне төзәтергә килгән дип уйламагыз. Мин төзәтү өчен килмәдем, башкару, тормышка ашыру өчен килдем",—дип җавап бирә. *(Матфей. 5 : 17)* Бу сүзләре белән ул тыңлаучыларына шундый фикерне җиткермәкче була: дин әһелләре пәйгамбәрләр аша бирелгән кануннарны үзләренә яраклаштырып бетерделәр, хак юлдан читкә тайпылдылар. Моңа кадәр килгән пәйгамбәрләрнең Тәгълиматы форма өчен генә үтәлә, ул төрле кагыйдәләргә төрелде. Хәзер шул Тәгълиматны торгызырга, асылын кире кайтарырга, аның чын йөзен ачарга һәм тормышка ашырырга вакыт җитте, дип әйтмәкче була ул. Ә икенче бер очракта халыкка мөрәҗәгать итеп: "Әгәр дә әхлагыгыз китап сүзе сөйләп йөрүчеләр белән фарисейларныкыннан *(икейөзле руханилар)* өстен булмаса, Күк Патшалыгына *(ягъни Җәннәткә—С.Ш.)* керә алмаячаксыз",—дип кисәтә. *(Матфей. 5 : 20)*

Чыннан да, Гайсә пәйгамбәрнең тәгълиматы яһүдиләрнең традицион диненнән күп ягы белән аерылып тора. Әмма шунысы да бар, без ул заманда бирелгән Тәгълиматның чын эчтәлеген белүдән гаять ерак торабыз, чөнки христиан дине һәм аның идеологик йөзе формалашкан безнең эраның беренче гасырларында текстларга күп нәрсәләр өстәлә, алар махсус редакцияләнә һәм мәгънәләре үзгәртелә. Евангелиенең кабул ителгән рәсми текстларыннан үзгә нөсхәләре—апокрифларның байтак булуы шул хакта сөйли кебек.

Аларны рәсми чиркәү танымый.

Текстларның мәгънәсе махсус үзгәртелгән христиан дине вәкилләре танымас, аны яла ягу дип кабул итәр, әмма бүгенге көндә җир йөзендәге халәргә өстән карап торган һәм аларга объектив бәя биргән структуралардан да мәгълүматлар алына, алар тарихыбызның четерекле мәсьәләләренә ачыклык кертә, безгә хакыйкатьне яшереп торган кайбер мифлардан арынырга, күзләребезне ачарга ярдәм итә.

Кулымда дөньякүләм танылган арадашчы — контактёр Барбара Марсиниакның "Семья Света" дип аталган китабы. Ул АКШта яши, 1988 елның 18 маеннан бирле Плеяда йолдызлыгы вәкилләре белән элемтәдә тора, алардан алынган мәгълүматлар нигезендә инде өч китап бастырып чыгарды ("Приносящие Рассвет", "Земля", "Семья Света"). Соңгы китаптан китерелгән берничә өзек безгә христиан диненең башлангыч чорында барлыкка килгән вәзгыятьне, ике мең ел буе дәвам иткән һәм без әле генә чыккан Балык йолдызлыгы дәверенең нинди шартларда башланып китүен ачыграк күзалларга ярдәм итәр:

"... Когда эпоха Рыб лишь начиналась, пришли в воплощение многие сущности с ускорением возможностей, а остальное человечество, казалось, восхищалось ими. Эти сущности, как мужчины, так и женщины, были в состоянии мгновенно излечивать людей, ибо они понимали космические законы... В те дни люди не путешествовали далеко, лишь немногие умели читать и писать. Обладающие ускоренными возможностями появлялись повсюду, они были целителями и могли совершать чудесные поступки, и таким образом на протяжении нескольких сотен лет все вокруг гудело от открытия этой новой энергии. Эти сущности разошлись по земле, которую сейчас вы зовете Ближним Востоком, по области, очень важной в вашей планетарной истории. Они находились там, чтобы поднять частоту *(вибрации — С.Ш.)* эпохи Рыб, вдохновляя людей на то, чтобы шагнуть через портал изменения в Новую Эпоху". *(48 — 49 бб.)*

* * *

"... Когда более двух тысяч лет назад воплощались способные на многие чудесные подвиги представители Семьи Света, адепты Света и Любви, власть предержащие почувствовали угрозу. Они не желали проникновения этих учений в массы, и потому с самого начала возникло множество противостоящих группировок. Некоторые относят это пробуждение сознания к рождению христианства из-за историй о личности, известной вам как Иисус Христос. Он является в действительности, составной личностью, замышленной и складываемой на протяжении многих и многих лет. В реальности эти истории про Семью Света, пришедшую на планету, чтобы принести истину, когда существовала возможность громадных изменений" *(52 — 53 б.)*

* * *

"Ваши исторические книги не содержат ясной, точной картины о том, кто жил в то время. Люди великой силы ходили по Земле и учили истине вибрации любви; кроме того, они помогали людям разглядеть тиранию, в которой те жили. Тирания использовала страх как инструмент управления вами..." *(81 б.)*

* * *

"В начале эпохи Рыб было оглашено, что лишь определенные люди могут разговаривать с Богом, что для всех Бог не доступен, разве что через жертвы деньгами, через молитвы, через священников и пап. И на Землю опустилась эпоха Тьмы, эпоха болезней, невежества и великого страха. Вторая четверть этого 2000-летнего испытания временем была очень темной.

Однако когда бы мы ни встретили тьму, мы знаем, что и свет присутствует неподалеку. И Свет проявился, многие люди начали пробуждаться. В начале средних веков, с 1000 по приблизительно 1500 год происходило пробуждение человеческого сознания. Однако до того, как это новое свободомыслие смогло закрепиться, произошел последний взрыв тьмы — инквизиция, полная убийст и разрушения. Она была введена желающими управлять самим обиталищем Бога и способами доступа к нему; кроме того, они желали ограничить мышление людей... Частота страха была настолько сильной вокруг Земли, что, когда кто-то решался высказаться, все остальные переключались не на любовь, а на страх..." *(84 — 85 б).*

* * *

"... В эпоху Рыб Бог стал невидимым, и было объявлено, что Он более не вязан с вами телепатически. Если вы утверждали обратное, вас сжигали на костре или запирали в темницах. Похоже, что телепатия – это "опасная" возможность, таящаяся в ваших генах. Однако ваши отдаленные предки пользовались ею, чтобы заглянуть в иные точки времени, чтобы путешествовать вне тела и чтобы видеть Настоящее, Прошлое и Будущее одновременно – путешествовать по реке времени..." *(104 б.)*

Бу өзектә китерелгән мәгълүматлар нигезендә без Гайсә пәйгамбәр бөтенләй булмаган икән дигән фикергә килергә тиеш түгел, һич юк. Гайсә пәйгамбәрнең тарихи шәхес булуын беркем дә шик астына куя алмый. Бу исбатланган нәрсә. Шулай ук Гайсә пәйгамбәрнең Нур Гаиләсе вәкиле булуы да шик уятмый. Әмма ул дәвердә Нур Гаиләсе *(Семья Света)* әгъзалары тарафыннан җир йөзенә иңдерелгән Тәгълиматның бер шәхескә бәйләп куелуын белү безгә диннең ничек барлыкка килүен аңларга ярдәм итә.

* * *

Хисап көне турындагы кисәтүләр христиан дине чыганакларында тагын да көчлерәк һәм катгыйрак яңгырый, чөнки бу дин үсеп чыкканда кешелек дөньясы инде сынаулар чорына – безнең көннәргә бераз якыная төшкән була.

Әйтелгәнчә, Җирдә Нур Гаиләсе эшчәнлеге һәм шуңа бәйле рәвештә барлыкка килгән христиан дине планетабыз Балык йолдызлыгы дәверенә – йогынтысына кергәндә, моннан ике мең ел элек үсеп чыга. Ә инде шушы дәвер тәмамланып, Җир чираттагы Сукояр йолдызлыгы йогынтысына күчкәндә безгә, адәм балаларына, үзебез ирешкән акыл үсеше, рухият һәм әхлагыбыз өчен Галәм алдында имтихан тоту билгеләнә. Без хәзерге көндә күп чыганакларда телгә алынган, Тәрбиячеләребез тарафыннан кат-кат исебезгә төшерелеп килгән шушы үтә дә җаваплы елларда яшибез. Әлбәттә, адәм баласына зур дәверләрне үз эченә алган Илаһи План билгеле түгел, шулай да Галәмдә һәр эш – гамәлнең шушы План нигезендә алып барылуын ул күңеле белән сизеп яши. Шуңа күрә дә язмышын Иң Югары Зат хөкеменә тапшыра. Кешелек дөньясының эволюцион үсеше дә, аңлыймы ул аны, юкмы, шушы Илаһи План кысаларында алып барыла.

Шушы фикерләрнең дөреслегенә инану өчен христиан диненең төп чыганаклары тупланган Яңа Гаһедкә мөрәҗәгать итик. Библиянең соңгы өлешен тәшкил иткән Яңа Гаһед китабын формаль рәвештә өч өлешкә бүләргә мөмкин.

**Беренчесе** – Гайсә пәйгамбәрнең тормышын, эшчәнлеген һәм тәгълиматын тасвирлаган Евангелиелар. Аларның рәсми кабул ителгәне дүртәү – Матфей, Марк, Лука, Иоанн Евангелиеләре. Евангелие – грек теленнән тәрҗемә иткәндә "изге хәбәр" дигән мәгънәгә ия, ягъни Евангелиедә кешелек дөньясына яңа тәгълимат алып килгән Гайсә *(Иисус)* пәйгамбәр һәм аның эшчәнлеге бәян ителә.

**Икенче өлеше** – изге апостолларның кылган гамәлләре. Анда Гайсә пәйгамбәр апостоллары *(сәхабәләр)* һәм аларның яңа динне таратуда куйган хезмәтләре, шулай ук нинди зәэрлекләр кичерүләре тасвирлана.

**Өченче өлешендә** – апостолларның төрле төбәкләрдә барлыкка килгән христиан дине төркемнәренә язган хатлары, күрсәтмәләре тупланган. Яңа Гаһеднең бу өлеше христиан диненең иң әүвәлге чыганакларыннан саналган (безнең эраның 68 елы) "Иоанн Богословка ачылганнар" *("Откровение Иоанна Богослова")* дип аталган хикмәтле текст белән тәмамлана. Аның төп эчтәлеген Иоанн Богословка Ходай тәгалә тарафыннан иңдерелгән Ахырзаман күренешләре, Хисап көнендә булачак хәлләрне тасвирлау тәшкил итә. Урта гасырларның иң караңгы йөзләрендә бу чыганакны чиркәү практикасында файдалану хәтта тыелган да була, ул соңрак кына кертелә.

Христиан диненең шушы иң әүвәлге чыганагы аерым игътибарга лаек. Аның авторы Ахырзаманда булачак бер күренешне тасвирлый:

"Мин күз салдым һәм ак болыт күрдем, болыт өстендә Адәм Угылы *(Яңа Гаһедтә Гайсә пәйгамбәр шулай атала)* сыман берәү утыра иде: башында алтын таҗ, кулында үткен урак. *(Күктәге)* гыйбадәтханәдән бер фәрештә чыкты да болытта утыручыга көчле тавыш белән әйтте: "Урагыңны эшкә җик, ура башла, чөнки уракка төшәр вакыт җитте, җирдә игеннәр инде өлгерде". Һәм болытта утыручы урагын җиргә төшерде, һәм җирдә игеннәр урып алынды". *(Откровение. 14:14 – 16 )*

Библия белгечләре "болытта утыручы"ны Гайсә пәйгамбәр белән чагыштыралар. Мондый чагыштыру изге текстларны соңрак чорларда төзәткән дини редакторлар

намусында калсын. Бу өзектә безне, беренче чиратта, авторның нинди урак һәм нинди игеннәр турында сүз алып баруы кызыксындыра. Әлбәттә, Библиянең яшерен кодларын белмәгән укучы моны әкияти бер күренеш дип кабул итәргә дә мөмкин. Әмма уйлап карыйк.



Иоанн Богослов

Галәм күзлегеннән караганда, Җир планетасында тереклек итүче кешелек дөньясы тәрбия кылу объекты булып тора. Җир әле чыгыштырмача яшь цивилизация һәм үзенең Галәмдәге башка цивилизацияләр белән бер гаиләдә яшәвен аңлау алдында гына тора. Яшь булуына карамастан, аңа үсү, яңа баскычка күтәрелү өчен бирелгән вакыт инде төкәнеп килә, ул Галәмдә кабул ителгән мәгълүм рухият һәм акыл стандартына ирешүенә хисап бирергә, эволюциянең югарырак баскычына күтәрелергә тиеш. Игътибар итик: текстта "уракка төшәр вакыт җитте, җирдә *(планетабызда)* игеннәр *(халыклар)* инде өлгерде". Һәм болытта утыручы *(Иң Югары Зат)* урагын җиргә төшерде, һәм җирдә игеннәр урып алынды", – диелә.

Кешелек дөньясы үтәчәк Хисап көне турында моннан да ачык итеп әйтү мөмкинме?!

Инде икенче бер христиан дине чыганагы "Матфей Евангелиесе"нә мөрәҗәгать итик:

"Урыр вакыт җиткәнче болары да, тегеләре дә бергә үссеннәр. Уракка төшкәндә мин уручыларга әйтермен: әүвәл чүп үләннәрен җыеп алыгыз һәм яндыру өчен бергә бәйләгез; ә бодайны минем амбарыма кертегез". *(Матфей. 13:30)*

Бу очракта да яшерен кодны аңлап эш итсәк, шундый картина күз алдына килеп баса: Ахырзаман килеп, Хисап көне җиткәч, адәм балалары ике өлешкә бүленәчәк. Илаһи Программаны үтәмәгән һәм үтәргә дә омтылмаган кешеләр, "чүп үләне" кебек, эволюция чылбырыннан төшеп калачак, ә уңышлы үтәп баручылар кадерле ашлык *(бодай)* сыйфатында Ходай Тәгалә "амбарларында" урын алачак. Программаны үтәмәүчеләрнең язмышы нинди булачагын күз алдына китерүе кыен түгел.

Шул ук "Матфей Евангелиесе"ндә икенче бер урында Хисап көнендә адәм балаларын ике төркемгә бүлү күренеше тасвирлана:

"Һәм Аның каршына барлык халыклар җыелыр; көтүче көтүдәге сарыклар белән кәҗәләрне аергандай, Ул аларны бер-берсеннән аерыр. Һәм сарыкларны уң ягына куяр, кәҗәләрне исә – сулга. Шул вакыт Падишаһ уң яктагыларга әйтер: Атамның *(Ходай Тәгаләнең)* фатихасын алганнар, килегез, дөнья яралтылганнан бирле сезнең өчен әзерләп куелган Патшалыкның варислары булыгыз". *(Матфей. 25 : 32 – 34)*

Бу өзекнең мәгънәсе менә нидән гыйбарәт: Хисап көнендә имтихан үтә алганнар Ходай тәгаләнең рәхмәтеннән мәхрүм булып калмаслар, аларга мәңгелек тормыш бүләк ителер, андый җаннарга киләчәктә эволюцияләрен дәвам иттерү мөмкинлеге бирелер.

Адәм балаларын ике төркемгә бүлү мәсьәләсе "Матфей Евангелиесе"нең 10 бүлегендә дә калкып чыга. Гайсә пәйгамбәр унике апостолын үз янына җыеп ала да аларны үз тәгълиматын тарату өчен тирә-як җирләргә озатмакчы була, соңгы күрсәтмәләрен бирә. Әйтә:

"Мине җир йөзенә тынычлык иңдерү өчен килде дип уйламагыз, мин тынычлык түгел – кылыч алып килдем; Мин адәмне атасыннан, кызны анасыннан, киленне кайнанасыннан аерыр өчен килдем. Кешенең дошманнары – аның гаилә әгъзалары", – ди. *(Матфей. 10 : 34 – 36)*

Бу сүзләр белән ул кешеләр арасындагы чын кардәшлек – кан кардәшлеге түгел, ә рухи туганлык дип әйтмәкче. Бары тик рухи туганлык нигезендә берләшкәндә генә ныклык һәм үзара аңлашып яшәүгә ирешеп була. Ахырзаман сынаулары чорында да кешеләр фәкать рухи туганлык, югары әхлак, мөкәммәл акыл һәм башка шундый күркәм сыйфатлар нигезендә бергә тупланачак. Чик сызыгына килеп җиткәндә беркем беркемгә ярдәм кулы суза да, яклап кала да алмаячак. Тормышта нәрсәгә ирешсәң, нинди максатлар

куеп яшәсәң, нинди хәзинәләр тупласаң — барысы да синеке, сиңа беркем берни өсти дә, тартып ала да алмаячак. Хисап көнендә шуңа карап синең киләчәк язмышың билгеләнәчәк.

Бер караганда, борынгы заманнардан бирле адәм балаларының исенә төшерелеп килгән Хисап көне җир йөзендә 50 — 60 — 70 — 80 еллап кына яшәгән аерым кеше тарафыннан бер әкияти уйдырма кебек кабул ителергә дә мөмкин. Үзенең Җирдә күп тапкырлар яшәгәнен дә, җанының эволюция юлыннан баручы илаһи, димәк, үлемсез кисәкчә икәнен дә белмәгән кеше өчен моның ни әһәмияте бар?! Гасырлар буе дин китаплары һәм пәйгамбәрләр шул хакта сөйли, ә җир йөзендә бер үзгәрешсез шул ук кырыс тормыш бара: туктаусыз көрәш, кояш астында үз урыныңны яулау, амбицияләрне канәгатьләндерү өчен даими тырмашу, төрле юллар белән өскә чыгу, дан-шөһрәт, абруй, байлыкка ирешү өчен тартышулар дәвам итә.

Табигый, моны күреп торган аңлы кешеләрдә шундый сорау туа: ни өчен Хисап көне дигән бу хәлиткеч вакыйга гел чигерелеп килә? Гасырлар буе хәтергә киртләп киленгән бу Көн ни өчен килми дә килми? Һәм бу мәсьәләнең Яңа Гаһедтә урын алган "Апостол Петрның икенче хаты" дип аталган чыганакта калкып чыгуы очраклы хәл түгел булса кирәк. Димәк, чыннан да, мондый сорауны бирүчеләр булган һәм аларга җавап бирү ихтыяҗы туган.

Апостол Петр сорауга болай дип җавап бирә: "Сезгә бер нәрсә ачык булырга тиеш, газизләрем, Ходайның бер көне мең ел һәм мең елы бер көн кебек. Кайберәүләр моны акрынлык дип уйласа да, Ходай вәгъдәсен үтәми калмый; Ул безгә карата түземлек күрсәтә, берәүнең дә һәлак булуын теләми, барлык кешеләрнең дә тәүбә итүенә өметләнә". *(Петрның 2 нче хаты. 3 : 8 — 9)*

Апостол Петр ул Көннең ничек киләсен, нинди шартларда киләсен дә аңлатып бирә: "Ходайның ул көне, төнге угры кебек, сиздермичә килер, һәм күкләр тавышлар чыгарып урыныннан күчәр, уянган табигать көчләре таркалыр, җир һәм андагы барлык нәрсә янып бетәр". *(Петрның 2 нче хаты. 3 : 10)*

"Хисап көне килгәч, җир йөзендә шундый һәлакәтләр булачакмы?" — дигән сорау бүгенге көндә планетабызда яшәүче һәр кеше өчен иң җитди мәсьәләләрнең берсе булып кала. Әйтергә кирәк, бу хакта Күктәге даирәләрдән ышанычлы каналлар аша мәгълүматлар килеп тора. Биредә без бу зур темага тирән кереп тормабыз, ул хакта әле алда сүз булыр. Хәзергә исә шуны гына искәртеп узыйк: соңгы елларда Хисап көне якынлашу сәбәпле Раббыбыз тарафыннан Илаһи Планга шактый үзгәрешләр, төзәтмәләр кертелде һәм Хисап көне, дин китапларында тасвирланганча, зур һәлакәтләр, җир йөзендәге тормышның пыран-заран килүе белән үткәрелмичә, йомшак рәвештә генә үтеп китәр дигән өмет бар.

Раббыбыз өчен без, адәм балалары, күп акылсызлыклар кылып, Җир-Анабызны рәнҗетеп яшәвебезгә карамастан, барыбер кадерле затлар, Аның газиз балалары. Безне эволюциянең хәзерге баскычына җиткерү өчен Күкләр күп көч куйган һәм, әлбәттә инде, Алар куйган хезмәтләренең заяга китүен һич теләми. Аннан соң Кояш системасы гаиләсендә бер әгъза булып яшәгән Җирнең авыр хәлгә төшүе башка күк җисемнәренә дә зыян китерә. Галәмдә бар нәрсә бер-берсенә бәйләнгән, үзара тәэсир итешеп яши. Шуңа күрә Илаһи Планны тиешенчә тормышка ашыру өчен мөмкин булганның барысы да эшләнә. Без барыбыз да Раббыбыз ихтыярында.

## КОРЪӘН ҺӘМ ХИСАП КӨНЕ

Гарәбстан ярымутравы бары төньяктан гына Азия континенты белән тоташа. Аның көнбатышында — Кызыл диңгез, көнчыгышында — Фарсы култыгы белән Гарәп диңгезе, көньягында — Һинд океаны җәелеп ята. Өч ягыннан тоташ су, бер ягыннан гына коры җир белән тоташкан шушы зур территорияне гарәпләр яратып әл-Җәзира, ягъни Ярымутрау дип йөртәләр. Алар телендә ул "туган җирем", "сөекле ватаным" дигән мәгънәгә ия булса кирәк. Ислам дине менә шушы кырыс һәм эссе табигатьле, таулы-чүлле илдә барлыкка килә, ныгый һәм ярты дөнья халыкларын үз канаты астына ала.

Әгәр дә без соңгы алты мең еллык дәверне эченә алган һәм төрлечә теркәлеп калган "язма тарих" сәхифәләрен барларга керешсәк, Гарәбстан ярымутравында кешелек дөньясының хәтерендә уелып калырдай мәшһүр цивилизацияне искә төшерә алмабыз. Тарихның соңгы дәверендә таулар — чүлләр белән капланган, үсемлекләргә бик тә ярлы

елгасыз-сусыз бу гаять зур мәйданда бөек мәдәният учагы дөрләп китәрлек шартлар булмаганга охшый. Әллә инде булып та кешелек дөньясы хәтереннән җуелган. Шулай да Гарәбстан ярымутравының көньягында безнең эрага кадәр 8 йөз — безнең эраның 4 йөзендә яшәгән Саба цивилизациясен күрсәтеп үтәргә мөмкин. Әмма ул әле аз өйрәнелгән, аның хакында зурдан кубып сүз әйтергә иртәрәк шикелле.

Шул ук вакытта Гарәбстан ярымутравына сыенып ук торган төбәктә, Тигр — Евфрат елгалары бассейнында, безнең эрага кадәр 4 мең ел элек бөек Шумер цивилизациясе үсеп чыга. Аның дөньяны таңга калдырырдай казанышлары, дәверләр буе илдән — илгә, халыктан — халыкка күчә барып, бүгенге Көнбатыш цивилизациясенең нигезен тәшкил итә. Ә инде гарәпләр ватаныннан көнбатышка таба юнәлеп, Кызыл диңгезне кичеп чыксак, анда Нил елгасы буйлап сузылган уңдырышлы җирләр тасмасында кешелек дөньясы хәтерендә тирән эз калдырган тагын бер цивилизация — Мисырга барып юлыгабыз. Иң борынгы заманнарда Кам *(Камнар иле!)* дип йөртелгән бу мәшһүр дәүләт тә күпме дәверләр дөньяның аң һәм гакыл учагын сүндермичә саклап килә. Гарәбстанның күршесендә соңрак дәверләрдә Урта диңгез бассейны сәүдәсен үз кулында тоткан Финикия, мәшһүр калалары, мәгърур патшалары, катлаулы диннәре белән тарихта калган Аккад, Бабил, Элам, Халдея , Ассирия кебек дәүләтләр барлыкка килә. Әмма халыкларны үзара аралаштырып бер казанда кайнарга мәҗбүр иткән тарихи процесс, биек тау тезмәсенә килеп бәрелгән чүл җилләре кебек, гарәпләр ватанына үтеп керә алмаганга охшый. Бередә ничә мең ел буе тынлык хөкем сөрә, тормыш сүлпән бара, төннәрен чүл өстендә якты йолдызлар кабынса да, аларның илаһи нуры адәм балалары күңеленә үтеп керә алмый. Бу төбәктә туктап калган тарих арбасын кузгатып җибәрердәй, зур хәрәкәткә этәргеч бирердәй шәхес һаман күренми. Шуңа күрә нигездә чүлләрдән торган бу зур мәйданда яшәүче кабиләләр үсеш ягыннан тирә-күрше халыклардан бик нык артта кала, ыруглык җәмгыяте кысаларында яшәвен дәвам итә.

Гарәпләрне күп гасырларга сузылган бу торгынлыктан чыгаручы төп сәбәпләрнең берсе — ыруглык җәмгыятенең таркала башлавы һәм сәүдәгәрлек. Урта диңгез буе илләре белән Кызыл диңгез, Фарсы култыгы ярларында яшәгән халыкларны тоташтыручы сәүдә юллары гарәпләр ватаны аша узган. Һәм бу юлларда тора-бара калалар барлыкка килгән.

Мәккә — шундый калаларның иң зурысы саналган. Аның аша Йәмән белән Сүрияне тоташтыручы мәшһүр сәүдә юлы узган. Сәүдә кәрваннары тар үзәндә урнашкан, өстәвенә атаклы Зәмзәм чишмәсе дә булган Мәккәне һич тә әйләнеп үтә алмаганнар. Юлчылар анда туктап дөяләрен сугарганнар, базарга чыкканнар, кәрваннарга ял биргәннәр. Бу хәл исә ни бакчачылык, ни игенчелек, ни терлә алырлык дәрәҗәдә үскән һөнәрчелек белән шөгыльләнмәгән шәһәр халкына зур файда китергән. Мәккә Хиҗаз аша узган мәшһүр сәүдә юлында урнашуы аркасында зур һәм бай калага әверелгән.

Мәккә шәһәре тулысынча корәеш кабиләсе кулында булган. Андагы халык мал-мөлкәте, туплаган байлыгы һәм оештырган сәүдә кәрваннарының зурлыгына карап, кала үзәгендә һәм каланың читендә яшәүчеләргә бүленгән. Әлбәттә, үзәктә бай һәм абруйлы ырулар урнашкан.

## ПӘЙГАМБӘРНЕҢ ЯШЬЛЕК ЕЛЛАРЫ

Исламга нигез салучы Мөхәммәд пәйгамбәр ишле корәеш кабиләсенең хашим ыруында урта хәлле гаиләдә дөньяга килә. Ул туганчы ук атасы Габдулла вафат була, малай әнисе Әминә белән атасы ягыннан бабасы Габдел Моталлиб кулында кала.

Калада яшәгән гарәпләрдә кабул ителгән гадәт буенча, Мөхәммәдне сабый чакта чүлдә яшәүче бер бәдәви гаиләсенә тәрбиягә бирәләр, сабыйга чүл шартларында, саф һавада яшәү һәръяктан файдалы дип табылган, күрәсең. Ә Мәккә — йортлары тыгыз урнашкан, шау-шулы, тузанлы, начар һавалы кала була. Хәлимә исемле хатын булачак пәйгамбәрнең сөт анасына әверелә, ул аны ике яшенә кадәр имчәгеннән аермыйча бага.

Мөхәммәдкә алты яшь тулганда анасы Әминә дә вафат була, булачак пәйгамбәр тулы ятим килеш картайган бабасы Габдел Моталлиб кулында кала. Тагын ике елдан, малайга сигез яшь тулганда, бабасы да фани дөньяны ташлап китә. Малай әтисе белән бертуган агасы Абу Талиб гаиләсендә яши башлый. Менә шушы ятим бала киләчәктә Ислам динен дөнья халыкларына күндерүче пәйгамбәргә әйләнә.


Абзасы сәүдә кәрваннары белән ерак җирләргә йөргәнгә, Мөхәммәдне дә үзе белән алгалый, малай бик яшьли сәүдә эше белән таныша, кәрваннар йөртергә өйрәнә. Пәйгамбәрнең беренче биографиясен язган Ибне Исхак сүзләренә караганда *(милади белән 767 елда вафат)*, Мөхәммәд сәүдә кәрваннары белән чит илләргә йөргән чакларда төрле дин тоткан кешеләр белән очрашкан, яһүди һәм христиан дине нигезләре белән танышкан. Еллар узып, ул үзе Ислам тәгълиматын таратырга керешкәч, андый тәҗрибә аңа ярдәм иткән булса кирәк.

Сәүдәгәр тол хатын Хәдичәгә хезмәткә ялланганда Мөхәммәд инде кәрваннар белән йөреп шактый тәҗрибә тупларга өлгергән, әйбәт холкы һәм ышанычлы кеше булуы белән ырудашлары арасында хөрмәт казанган буйдак егет була. Хәдичә аны кәрван белән Сүриягә җибәрә. Мөхәммәд тауарларны сатып, шул акчага яңаларын алып, Мәккәгә әйләнеп кайта һәм шушы көннән бу гадел һәм тыйнак егет тол хатынның күңеленә кереп урнаша. Бераздан кораеш кабиләсендә күренекле хатыннардан саналган бай Хәдичә үзен аңа хатынлыкка тәкъдим итә. Мөхәммәд риза була. Шуннан соң аның икенче агасы Хәмзә бин Габдел Моталлиб Хәдичәнең туганнарына яучы итеп җибәрелә. Бу вакытта булачак пәйгамбәргә егерме биш яшь була. Шулай ул кәрваннар озатучы дәрәҗәле кешегә әверелә.


Пәйгамбәрнең тормыш юлын беренче тасвирлаган Ибне Исхак үз хезмәтендә бер кызыклы вакыйганы искә алып уза. Бу хәл Мөхәммәдкә утыз биш яшь тулган чакта була.

Көннәрдән бер көнне кораеш кабиләсе вәкилләре Мәккәдә генә түгел, бөтен тирә-якка даны таралган изге Кәгъбәне үзгәртеп корырга кирәк дигән карарга киләләр. Әмма берәү дә изге корылманы сүтәргә батырчылык итми. Ул кеше зурлыгындагы авыр ташлардан төзелгән була, аны тагын да биегрәк итеп төзеп, түбәсен япмакчы булалар, чөнки караклар аның эчендәге коеда сакланган хәзинәне урлап киткән булалар.

Кешеләр борын-борыннан изге саналган Кәгъбәгә кул күтәрүдән, аны ватудан бик куркалар, шулай да арадан бер Вәлид исемлесе бу эшкә алынырга була. Догаларын укып, ни булса шул булыр дигәндәй, ниһаять, ул диварны сүтәргә керешә. Җыелган халык, аңа берәр хәл булмаса без дә катнашырбыз дип, иртәгә хәтле көтәргә була. Әгәр дә Вәлид исән-сау килеш уянса, димәк, монда гөнаһ юк, дип фикер йөртәләр алар.


*Зәмзәм чишмәсе бинасы*

Иртәгесен Вәлид сау-сәламәт килеш уяна да эшне дәвам итә, башкалар да батыраеп китеп аңа булыша. Тик монда бер кызык хәл килеп чыга — бу изге эшкә өлеш кертү өчен кораеш ыруларының һәркайсы тиешле ташларны аерым җыя, шулай да сүтелгән диварны бергәләшеп өяләр. Менә диварда билгеләнгән биеклеккә Кара Ташны урнаштыру вакыты килеп җитә һәм ... зур бәхәс куба. Эш шунда ки, һәр ыру Кара Ташны үзе куярга тели, башкаларны бу эштән читләштерергә омтыла. Бәхәс шул кадәр куера ки, кешеләр хәтта бер-берсенә ташланыр дәрәҗәгә җитә.


*Зәмзәм чишмәсенең эчке күренеше*

Шул вакыт кораешлар арасында иң өлкән саналган Абу Умаййа бин әл-Могыйра бин Абдаллах бин Гомәр бин Мәхзүм исемле карт шундый киңәш бирә:

— И кораеш ырулары! — ди ул. — Сез чишә алмаган бу мәсьәләне гыйбадәтханә ишегеннән атлап кергән беренче кеше хәл итсен.

Барысы да киңәшне кабул итә. Көтә башлыйлар. Бераздан бу хәлне бөтенләй белмәгән Мөхәммәд гыйбадәтханә янына килә дә ишек урыныннан эчкә үтә. Халык җиңел сулап куя. Арадан берсе эшнең асылын аңлатып бирә. Шуннан соң Мөхәммәд берәүдән җөббәсен сорап ала да, аны җиргә җәеп, өстенә Кара Ташны китереп сала.

— Һәр ырудан бер кеше бирегә килсен, җөббәне кырыеннан тотсын, ташны урынына куешсын, — ди.

Кара Ташны күмәкләшеп күтәргәч, Мөхәммәд аны үз куллары белән билгеләнгән урынга урнаштыра. Шушы вакыйгадан соң кораешлар арасында Мөхәммәднең ышанычлы, тугры *(әл-Әмин)* дигән аты тарала. Бу хәл аңа вәхи килә башлаганга кадәр биш ел элек була.

## НИ ӨЧЕН МӨХӘММӘД?

Бу зур сорауга җавап табарга тырышып карыйк. Чыннан да, ни өчен фәкать Мөхәммәд пәйгамбәр булып киткән? Ни өчен Исламны дөньяга тарату өчен фәкать кораешларның хашим ыруында туып-үскән Мөхәммәд атлы зат сайланган?

Җиһанда бер нәрсә дә очраклы рәвештә барлыкка килми. Безнең "очраклы" дип уйлавыбыз бары тик аның чын сәбәбен белмәүдән килә. Ә инде яңа рухи тәгълимат, тора-бара дөньякүләм дингә әверелеп киткән Ислам берничек тә очраклы күренеш була алмый. Гомумән, җир йөзендә баш калкыткан рухи тәгълиматларның берсе дә очраклы күренеш түгел. Андый тәгълиматларның Җирдә барлыкка килүе алдан ук планлаштырыла, урыны, вакыты, лидеры билгеләнә. Җәмгыятьтә тиешле шартлар тугач, ул җан мәгълүм бер халыкта, милләттә гәүдәләнә, ягъни алдан билгеләнгән гаиләдә бала туа. Баланың үсүе, формалашуы өчен тиешле шартлар тудырыла. Бу эшләр барысы да алдан корылган План нигезендә алып барыла. Әгәр дә аны тормышка ашыруда көтелмәгән кыенлыклар килеп чыга калса, Күкләрнең махсус чаралары нәтиҗәсендә вакыйгалар кабат үз эзенә төшерелә. Кыскасы, Планны тормышка ашыру өчен мөмкин булганның барысы да эшләнә.

Әгәр дә без шушы закончалыкны фикер йөрткәндә төп таяну ноктасы итеп алсак, Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлы, Ислам тәгълиматын тарату өчен алып барган көрәше әлеге схемага керә дә утыра. Дөрес, монда бер нәрсәне искәртеп үтү кирәктер. Әгәр дә без Җиһанда Изгелек белән Явызлык арасында туктаусыз көрәш барганын искә төшерсәк, һәр очракта Илаһи План нигезендә алып барылган гамәлләргә каршы эшләгән Тискәре Планның да булуын онытмаска тиешбез. Бу төшенчәне эзотерик әдәбиятта КосмоЗло *(Космическое Зло)* дип атап йөртү гадәткә кергән. Без аны үз телебездә Галәми Золмәт дип атарга булдык. Кем белә, бәлки, бу төшенчә киләчәктә шушы атама белән әдәби әйләнешкә дә кереп китәр. Безнең милләт тә, иртәме, соңмы, барыбер аңы белән Галәм киңлекләренә чыгачак.

Менә шушы Галәми Золмәт вәкилләре Галәмдә дә, җир йөзендә дә һәр изге эшкә таяк тыгарга, аны ничек тә булса туктатырга, бөтенләй туктатып булмаган очракта тоткарларга, саташтырып, ялгыш юлга кертеп җибәрергә, эволюция барышына төрле киртәләр куярга тырышалар. Моның өчен аларны сүгәргә дә, нәфрәтләнеп көчәнне юкка әрәм итәргә дә кирәк түгел. Моны Җиһанда барган даими көрәш күренеше дип тыныч кабул итәргә кирәк. Раббыбызның үз Планы, тегеләрнең үз тискәре планы объектив чынбарлык буларак яши һәм һәрберсе үз вазыйфасын башкара.

Лирик чигенеш рәвешендә читкә тайпылыбрак әйтелгән фикерне шуның белән тәмамлыйсы килә. Җир йөзендә бик изге ниятләр белән башланган кайбер эшләр, күрсәтелгән сәбәпләр аркасында кайвакыт планлаштырылган юлдан читкәрәк тайпыла, куелган максат тиешенчә үтәлеп бетә алмый. Андый эшләрнең асылын җентекләп тикшерә башласаң, ничек башлануы белән тора-бара нәрсә килеп чыгуы арасында шактый зур аерма күрергә мөмкин. Моның иң калку үрнәге — христиан дине кысаларында үсеп чыккан инквизиция. Раббыбыз исеменнән эш йөртеп, рухиятка каршы көрәшкән Явызлык көчәге шул үзе түгелмени?!

Инде башланган сүзгә әйләнеп кайтыйк. Ни өчен кораеш кабиләсенең хашим ыруында үскән Мөхәммәд атлы зат пәйгамбәр булып киткән?

**Беренчедән**, Мөхәммәд пәйгамбәр гарәп дөньясының иң зур каласы, мәшһүр сәүдә үзәге Мәккәдә туа. Бу очраклы хәлме? Әгәр дә пәйгамбәребез Мәккәдә тумыйча, чүлдә күчмә тормыш белән яшәгән ком гарәбе — бәдәви гаиләсендә туса, аңа пәйгамбәрлек эшчәнлеген башлау һәм алып бару өчен тиешле шартлар булыр идеме? Һич юк! Ул заманда чүлдә яшәүче ком гарәпләренә шәһәр халкы артта калган икенче сорт кешеләр итеп караган. Чүлдән зур калага килеп, сәүдә эшендә шомарган, дөньяны әйбәт белгән алыпсатарларга ул нинди яңа сүз әйтә алган булыр иде. Гомумән, тәкәббер кала халкы

аны санга сугып тыңлаган, сүзенә колак салган булыр иде микән? Бу очракта да "юк" дип әйтергә туры килә.

**Икенчедән**, пәйгамбәребезнең иң көчле һәм йогынтылы, Мәккә каласын үз кулында тоткан, зур-зур җәмәгать кәрваннары оештырып, аларны төрле илләргә озатып, халыкара сәүдә алып барган корәеш кабиләсендә тууы да очраклы хәл түгел. Аңа "язмыш" көчле һәм абруйлы кабиләдә тууны алдан әзерләп куйган.

**Өченчедән**, пәйгамбәребезнең бабасы Габдел Моталлиб Зәмзәм чишмәсен саклаучы, бу чишмә корыганнан соң, аны казып-чистартып, чыганакка кабат җан кертүче зур абруйга ия зат була. Өстәвенә Кәгъбә ачкычы да шушы картта саклана, аның вафатыннан соң әлеге вазыйфа варисларына тапшырыла. Рәсүлебезнең фәкать шушы гаиләдә тууы, гомеренең беренче яртысы Кәгъбә тирәсендә узуы, шәһәр халкы өчен әһәмиятле күп вакыйгаларның, карарларның шушында узган җыеннарда кабул ителүе, димәк, пәйгамбәребез яшьтән үк каланың иҗтимагый тормышы эчендә кайнавы, барысын ишетеп-белеп торуы, укый-яза белмәсә дә, гаять мәгълүматлы кеше булуы да очраклы хәл түгел. Шулай аның киләчәк эшчәнлеге өчен тиешле җирлек әзерләнгән.

**Дүртенчедән**, пәйгамбәребез бик яшьли тулы ятим кала. Бу хакта уйлана башласаң, күз алдына Тукай килеп баса. Дөрес, пәйгамбәребезнең балачагы шагыйрьнеке кебек үк авыр узмаган. Мөхәммәднең көчле туганнары булган. Ул заманда гарәпләрдә әле ыруглык җәмгыяте йола-тәртипләре бик нык саклана, бер ыру да үз кешесен җәберләргә ирек бирми, аның хокукларын, иминлеген саклауны үз өстенә ала. Кан үче дигән нәрсә яши. Әгәр дә берәр ыру икенче бер ыру вәкиленә тисә, үтерә-нитә калса, үтергән ыру үзенең бер кешесе белән түләргә тиеш булган, яисә күп акча түләп кенә бу бәладән котыла алган.

Шулай итеп, пәйгамбәребез яшьлегендә атасы белән бертуган агасы Абу Талиб кайгыртуында яши башлый. Әмма агаң – атаң-анаң түгел, ул инде сиңа ераграк кеше. Бу хәл исә җитди карарлар кабул иткән Мөхәммәдкә иркенрәк эш итү мөмкинлеге биргән, ул ирекле шәхес булган. Аңа пәйгамбәрлек эшчәнлеген башлап җибәргәндә гарәпләрдә борын-борыннан яшәп килгән төрле ышануларга, гореф-гадәтләргә, тәртипләргә каршы чыгарга, аларның дөрес нәрсә түгел икәнлеген һәр вәгазендә исбатларга туры килә. Шулай ул үз халкының яшәү рәвешен, ышануларын тәнкыйтьләргә тотына, ул табынган илаһларның , потларның чын булмавын исбатлап кискен чыгышлар ясый. Халкын бердәнбер Аллаһны танырга, Исламга чакыра. Кыскасы, Мөхәммәд пәйгамбәр традицион гарәп җәмгыятенә берьялгызы каршы чыга. Әлбәттә, бу адым шәхестән зур кыюлык, үз юлының дөреслегенә гаҗәеп дәрәҗәдә ышануны, рухи ныклык таләп иткән.

Инде күз алдына китерик, таяныр тарафдарларың әле бармак белән генә санарлык чакта атасы-анасы исән булып, күпчелек кабиләдәшләре кебек, алар да Мөхәммәдне гөнаһлы эшләрдә гаепләсә, үҗәтлек белән үз юлыннан баруын күреп каргаса, гаепләп чыкса, – пәйгамбәр үтә дә кыен хәлдә калган булыр иде. Әмма аның язмышында бу мәсьәлә дә алдан хәл итеп куела – пәйгамбәр яшьли ятим калып, ирекле булып үсә. Шул ук ятимлек аны, ата-ана канаты астына сыенып ятмыйча, бик иртә киңрәк дөньяга чыгарга мәҗбүр итә. Йөргән таш тиз шомара дигәндәй, булачак пәйгамбәр шулай тормыш тәҗрибәсе туплый, киңрәк дөнья белән таныша.

**Бишенчедән**, Хәдичәгә – бай хатынга өйләнүе аңа матди мөстәкыйльлек китерә, рухи тормыш белән яшәү өчен мөмкинлек тудыра. Бу да очраклы хәлме – һич юк.

Шулай итеп, без санап үткән шартлар аның пәйгамбәрлек эшчәнлегенә алдан ук тиешле җирлек әзерли. Ә бу шартлар, тиешле җирлек – очраклылык галәмәтеме, әллә инде алдан әзерләп – планлаштырып куелган гамәлләрме, – анысы инде укучыга ачыктыр дип уйлыйм.

Әлбәттә, монда бернинди дә очраклылык була алмый. Гарәбстан ярымутравындагы кабиләләрнең иҗтимагый үсеше мәгълүм бер дәрәҗәгә җитү белән аларга этәргеч бирү, мең елларга сузылган йокымсырап яшәүдән уятып, бу кавемнәрне яңа дин байрагы астына туплау, аңнарын, әхлак дәрәҗәләрен яңа баскычка күтәрү, яшәү рәвешләрен үзгәртү ихтыяҗы туа. Һәм тарих мәйданында Мөхәммәд атлы шәхес һәм Ислам дип исем алган рухи тәгълимат үсеп чыга.

## ХИСАП КӨНЕ

Кулына Коръән алып укый башлаган һәр кеше аятьләрнең көчле хис, инану һәм дәрт белән сугарылган булуына игътибар итми калмагандыр. Бу хәтта тәрҗемә ителгән текстта да нык саклана. Шундый ук көчле хисне без пәйгамбәребез үз өммәтен туры юлга өндәгәндә, кылган барлык гамәлләрегез өчен җавап тотачаксыз, адәм балаларын киләчәктә Хисап көне көтә, дип кисәткән аятьләрдә дә ап-ачык тоябыз.

Әйе, адәми зат җир йөзендә кылган һәр эше-гамәле өчен генә түгел, хәтта уе өчен дә җавап бирә. Гомумән, вафатыннан соң Нәфис дөньяга *("теге дөнья")* күчкәндә анда нинди шартларга эләгүе, кабат җирдә гәүдәләнгәч, нинди гаиләдә, нинди тормыш шартларында яшәячәге – барысы да үткән гомерендә ирешкән нәтиҗәләргә карап билгеләнә. Кеше барысы өчен җавап тота. Шушы җаваплылыкны тоеп яшәү адәми затка эволюция баскычыннан һаман өскә күтәрелергә мөмкинлек бирә. Әгәр дә ул үзенә бүләк ителгән гомерендә уңай нәтиҗәләргә ирешсә, бер баскычка күтәрелә, ирешә алмаса – элекке урында кала; ә инде зур хаталар ясап, кыек юлларда йөрсә, хак юлдан читкә тайпылса, рухи деградация кичерсә, – аска тәгәри, үсешен тоткарлый. Бу очракта аңа инде бер үк юлны кат-кат үтәргә, күп вакытны юкка сарыф итәргә туры киләчәк. Шуңа күрә диннәр бер тавыштан адәм баласын туры юлны сайларга чакыра.

Коръәндә, гәрчә төгәл вакыты әйтелмәсә дә, Ахырзаман килгәч, Хисап көне булачагы турындагы кисәтүләр аеруча көчле яңгырый, хәтта, әйтергә мөмкин, куркыныч төс ала. Аерым кабилә илаһларына, йолдызларга, төрле тау-ташларга, дистәләрчә потларга, агачларга һ.б. табынып яшәгән мәҗүси гарәпләрнең аңына БЕР һәм БЕРДӘНБЕР АЛЛАҺ турындагы идеяне сеңдерү пәйгамбәребезгә җиңел булмаган, шуңа күрә аратирә иңеп торган сүрәләр ярдәмендә аңа даими аңлату эше алып барырга туры килгән. Бу җәһәттән кайчакта куркыту алымнары да кулланылган. Примитив аңлы бозык халыкны тагын ничек тәрбия кылмак кирәк?!

Хисап көне темасы Коръәндә төп урыннарның берсен алып тора, гаять көчле яңгырый. Ул Пәйгамбәргә вәхи иңә башлаганда бирелгән беренче сүрәләрдә үк үзен нык сиздерә. Шулай туып килгән яңа дин аша яһүди һәм христиан диннәре тапшырган хәбәр кабат кешелек дөньясының исенә төшерелә. Бу хәл үзе үк әлеге диннәрнең бер үк чыганактан һәм бер үк максат белән бирелүе турында сөйли түгелме? Бу шул ук традициянең эзлекле рәвештә гасырдан гасырга дәвам иттерелүе ләбаса! Бәс, шулай икән, ул вакытта ни өчен диннәр арасында зур каршылыклар, низаглар, килешмәүчәнлек, кирәкмәгән бәхәсләр килеп чыгып торган? Барысы да бер чыганактан, бер үк максатны – адәми затка туры юл күрсәтү, аның рухи үсешенә ярдәм итү, тормышын тәртипкә салуны күздә тотып бирелгән диннәр түгелме соң алар?

Тынычлык алмауның сәбәбе дин әһелләренең үзләренә кайтып кала шикелле. Алар диннәр арасындагы уртаклыкны алга сөрәсе, аларның бер чыганактан бирелүен аңлап эш итәсе урынга – аерымлык – үзгәлекләргә күбрәк игътибар иткәннәр, халыкларны аеру белән шөгыльләнгәннәр. Нәтиҗәдә кавемнәр бер-берсеннән ерагаеп кына калмаган, бер-берсен күрә алмас дошманнарга әверелгән. Тарихта билгеле дин сугышларында күпме кан коелган. Шулай изге ният белән бирелгән тәгълиматларга Галәми Золмәт, кара көчләр йогынтысы килеп кергән.

Хәер, читкә тайпылдык бугай. Хисап көненә әйләнеп кайтыйк. Кешелек дөньясы язмышында хәлиткеч роль уйный торган бу вакыйга Коръәннең бик күп аятьләрендә телгә алына.

"Әй, кешеләр, Раббыгызга каршы барудан куркыгыз, ата – баласына, бала – атасына ярдәм итә алмаячак ул Көннән куркыгыз. Белеп торыгыз, Аллаһ сүзе, һичшиксез, тормышка ашачак...". *(31 : 33).*

"Әй, кешеләр, Раббыгыздан куркыгыз. Чөнки ул Сәгатьтә *(Кыямәт көнендә)* сынаулар бик дәһшәтле булачак. Ул Көнне күргәч, сабыен имезүче хатын баласын онытыр, йөкле хатынның баласы төшәр. Аек кешеләр исерекләр сыман йөрер. Аллаһның җәзасы каты булыр". *(22: 1–2)*

"Ул Сәгать *(Кыямәт көне)* һичшиксез киләчәк. Мин *(аның кайчан киләсен)* белгертмәм. Һәркем ни кылса, шуның әҗерен алсын, дип". *(20:15)*

"Аллаһ хозурына баруны ялганга чыгаручылар бик мөшкел хәлдә калачак. Көтмәгәндә Сәгать *(Кыямәт көне)* сукса, алар: "Аһ, ышанмый йөрүебез өстебезгә җәза

булып төшә!" — дип үкенәчәкләр. Алар үз йөкләрен аркаларында алып барыр. Белеп торыгыз, аларның йөге яман бер йөктер". *(6:31)*

"Алар *(ул)* Сәгатьне *(Кыямәт көнен)* ялганга чыгарды, ә Без аларга Сәгатьне инкяр иткәннәре өчен Тәмуг уты әзерләп куйдык". *(25: 11)*

"Кыямәт Сәгатенең кайчан сугасын бары тик Аллаһ кына белә". *(31: 34)*

"Кыямәт көне һичшиксез киләчәк. Монда бернинди шик тә булуы мөмкин түгел. Тик кешеләрнең күбесе моңа ышанмый". *(40:59)*

Күрүебезчә, вакытлар төкәнгәндә кешелек дөньясының җитди сынау аша үтәчәге Коръәннең бик күп сүрәләрендә ап-ачык итеп әйтелә. Шулай Аллаһ исеменнән кешелек дөньясына кисәтү тапшырыла. Бу гади кисәтү түгел. Әгәр дә без Коръәннең төрле сүрәләренә чәчелгән шушы аятьләрне игътибар беләнрәк укысак, анда ялгыш юлга кереп киткән адәм балалары язмышы өчен тирән борчылу, аларның киләчәген кайгыртып сызлану, хәтта урыны-урыны белән туры юлга басыгыз, тәртибегезне, әхлагыгызны төзәтегез, сүзебезгә колак салыгыз, юкса, Сәгать суккач, бик мөшкел хәлдә калачаксыз бит, балакайлар, дип үтенү рәвешендә әйтелгән кәлимәләрнең дә булуын ачык күрербез.

Әйе, без барыбыз да Аллаһ балалары, Аның өчен кадерле затлар. Ул безгә зур өметләр баглый, Аның биһисап бурычларының берсе — бездән югары аң һәм мөкәммәл әхлакка ирешкән Галәм хезмәткәрләре тәрбияләү. Рухи үсешнең югары баскычына күтәрелгән һәр кеше аңы белән Галәм киңлекләренә чыга, андагы Иерархия белән бәйләнешкә керә, төрле вазыйфалар үти башлый. Шулай булмаса, миллион елларга сузылган дәверләр дәвамында ифрат зур түземлек һәм сүнмәс өмет белән Галәм, анда эш алып баручы Тәрбиячеләребез, зур мәшәкатьләр кичереп, безне тәрбия кылу белән шөгыльләнер, даими кайгыртыр, планетабызны төрле һәлакәтләрдән саклап торыр идемени? Адәм балалары өчен шушы хакыйкатьне тирәнтен аңлау һәм Тәрбиячеләребезгә рәхмәтләр әйтеп яшәү баскычына күтәрелү заманы килеп җитте. Хисап көнен кешеләр шундый аң белән каршы алырга тиеш түгелмени? Шундый баскычка күтәрелгән кешеләргә киләчәктә Күк Капусы ачылыр, алар үзгә шартларда үсешен дәвам иттерер. Соңгы елларда бирелгән бай мәгълүматлар, белемнәр шушы изге максатны күздә тотып башкарыла лабаса.

"Кыямәт көне һичшиксез киләчәк! Монда бернинди шик тә булуы мөмкин түгел. Тик кешеләрнең күбесе моңа ышанмый", — диелә Коръәндә. Бу аятьтә нинди зур борчылу, кайгырту ятканын ишетәсеңме, адәм баласы? Бу бит моннан 1400 ел элек әйтелгән, безне кайгыртып, безне саклап, коткарып калу өчен әйтелгән! Кешелек дөньясы Күкләрнең кисәтүен, Раббыбызның Тәгълиматын оныта башлаган саен халыкларга кат-кат пәйгамбәрләр җибәрелә торган, алар аша Хакыйкать кабат искә төшерелгән, Китаплар бирелгән, шулай диннәр барлыкка килгән. Җибәрелгән пәйгамбәрләрне халыкларның кабул итмәве, алардан көлүе, мыскыл итүе, хәтта, Мәккә халкы Пәйгамбәрне кире каккан кебек, аны исәр шагыйрьгә, килде-китте сүз сөйләп йөрүче тинтәк адәмгә тиңләве кебек мисаллар Коръән сүрәләрендә еш телгә алына. Заманнар үтә тора, ә кешелек дөньясы ялгыш юлдан баруын дәвам итә, үзгәрергә ашыкмый, дөресрәге, бик тә акрын үзгәрә.

Әмма соңгы елларда боз кузгалды. СССРның таркалуы, төрле тыюларның юкка чыгуы, фикер иреге килү, безнең илдә һич булмаганча, дөньяны җаның ниндине теләсә шундый китаплар басып китү инде үз эшен эшли. Бүгенге көндә бик күпләрнең аңнары ачыла, яңа сәләтләре пәйда була, рухият юлына басучылар төрле төркемнәргә берләшә, бер-берсенә үсәргә, рухи баскычларның яңа басмасына күтәрелергә ярдәм итә. Әллә бу очраклы хәлләрме? Һич юк! Шулай Раббыбыз, Тәрбиячеләребез безне Яңа Дәвергә атлап керү өчен әзерли. Уңай шартлар да тиктомалдан гына барлыкка килмәде, аларның тирән сәбәпләре бар. Бар нәрсә башта Күкләрдә башлана, анда хәл ителә, соңрак кына вакыйгалар, чиләк төбенә утырган юшкын кебек, җир йөзендә, физик планда гәүдәләнә. Күп корбаннар таләп иткән дөньякүләм сугышлар да әүвәл без "теге дөнья" дип атап йөрткән Нәфис дөньяда әзерләнә, аннан соң гына аерым вакыйгалар рәвешендә җир йөзендә кабынып китә. Н.К.Рерихның "Чыңгыз хан" исемле картинасы бу закончалыкны гаҗәеп дәрәҗәдә дөрес чагылдыра. Киң дала уртасында атка атланган Чыңгыз хан берьялгызы тора. Аның баш өстендә күпереп аккан кан дәрьясын хәтерләткән җете-кызыл күк. Анда киеренкелек һәм дәһшәт. Анда инде барысы да башланган, аяусыз сугышлар бара. Ә җирдә әлегә тыныч, әмма күпмедер вакыт үткәч, күктә барган яуларны җирдә дәвам иттерәчәк шәхес инде язмыш тарафыннан сайлап алынган. Ул сәгать сукканны гына көтә. Һәм сәгать сугачак, Чыңгыз хан ярты дөньяны канга батырачак, кызыл дәрьялар җирдә агачак...

Н.К.Рерих картиналарын игътибар белән тикшерә башласаң, аларда яшерен тәгълиматның байтак закончалыкларын абайларга мөмкин. Кеше гомере белән чагыштырганда Хисап көненә килеп җитәргә әле бик ерак булса да, Тәүрат, Инҗил, Коръән кебек изге китаплар аша бу дөньякүләм әһәмияткә ия вакыйга адәми затның исенә төшерелә торган. Галәм өчен Хисап көне инде бик якын, кул сузымында гына тора. Шул сәбәпле Коръәндә дә вакыт Галәм үлчәме белән билгеләнә, фикер шушы Олуг Үлчәмгә салып әйтелә. Шуңа күрә Пәйгамбәргә иңгән сүрәләрдә ул төп тема буларак яңгырый.

Табигый ки, Пәйгамбәр вәгазьләрендә әйтелгән мондый кискен кисәтүләр, аның бу хакта дулкынланып һәм ифрат дәрәҗәдә инанып сөйләве тыңлаучыларда сораулар уятмый калмагандыр. Чыннан да, нәрсә соң ул Кыямәт көне? Коръәндә бу Көн әле Хисап Көне, әле Аллаһ белән очрашу көне, әле Адәмнәрне Аеру көне, әле Халыкларны Җыю көне, әле Сәгать Сугу көне, дип төрлечә атала. Әмма мәгънәсе бер — бу Көнне планетада тереклек итүче кешелек дөньясы һәм мөстәкыйль җан булып яшәүче адәм баласы үзенең бихисап дәверләрдә кылган уңай һәм тискәре гамәлләре, ирешкән һәм кулдан ычкындырган мөмкинлекләре өчен Олуг Имтихан тотачак.

Пәйгамбәрдән сүз көткән тыңлаучыларга Коръәндә мондый җавап бирелә:

"Менә бу *(Мөхәммәд)* моңарчы килгән пәйгамбәрләр белән рәттән торучы Пәйгамбәрдер. Килергә тиешле Кыямәт көне якынлашты. Аны Аллаһтан башка һичкем чигереп тора алмас". *(30 : 12—14)*

"Ул Көнне *(эчкерле)* дуслар бер-берсенең дошманына әверелер". *(43 : 67)*

Коръәндә шулай ук бу Көннең ничек киләсе дә аңлатыла:

"Синнән Кыямәт көненең кайчан киләчәген сорыйлар. Әйт син аларга *(и Мөхәммәд)*:

— Бу хакта Аллаһ үзе генә белә, — диген. — Аның вакытын Аллаһтан башка зат ачыклый алмас . Күкләр вә җирдәгеләр өчен бу кыен мәсьәлә. Ул *(Көн)* сезгә көтмәгәндә килер". *(7 : 187)*

Шулай ук бу Көнне булачак күренешләр дә тасвирлана:

"*(И Мөхәммәд, бу Көнне)* син һәр өммәтне тезләнгән килеш күрерсең. Һәр өммәт *(үзенең саваплары — гөнаһлары теркәлгән)* Китап янына чакырылыр:

— Ни кылган булсагыз, бу Көнне сезгә шуның әҗере әйләнеп кайтыр. Китабыбыз сезнең хакта дөресен генә сөйләр. Хактыр ки, сез ни кылган булсагыз, барысын теркәтә бардык". *(45:28—29)*

Биредә һәр кешенең кылган эшләре теркәлә барган Гамәл Китабы күздә тотыла.

Бу Көннең киләсенә шик белдерүчеләрне, аңа ышанмыйча мыскыллап көлүчеләрне Коръән кисәтеп куя:

"Әйтелер: "Сез бу Көн белән очрашуны ничек оныткан булсагыз, Без дә сезне шулай онытырбыз. Урыныгыз ут булыр, ярдәмчеләрегезнең берсе дә сезне коткармас. Сез Аллаһның аятьләрен көлкегә алдыгыз. Сез фани дөнья рәхәтенә алдандыгыз". Алар *(Тәмуггтан)* чыгарылмаячак, тәүбәләре дә кабул ителмәячәк". *(45 : 34—35)*

Башка диннәрнең Төп Китапларында сурәтләнгән кебек үк, Коръәндә дә Кыямәт Көне, Хисап көне кешелек дөньясының миллион еллар дәвамында кылган гамәлләре өчен Җавап бирү көне буларак бик дәһшәтле сурәтләнә:

"Кыямәт көнендә болытлы күк урталай ярылыр, фәрештәләр гаскәре Җиргә ургылыр. Ул Көнне бар нәрсә Мәрхәмәтле Аллаһ хөкемендә булыр. Юлдан язганнар өчен ул Көн бик хәтәр булыр. Ул Көнне гөнаһлылыр, бармакларын тешләп: "Их, Пәйгамбәр белән бер юлдан киткән булсам!" — дип үкенерләр". *(25 : 25—27)*

Кешеләрнең кылган гамәлләренә карап икегә бүленүе дә Коръәндә кат-кат әйтелә: "Кыямәт сәгате суккан көнне кешеләр *(кылган эшләренә карап)* бер-берсеннән аерылыр". *(30:14)*

Алдагы бүлекләрдә без яһүди һәм христиан диннәрендә Хисап көненең ничек тасвирлануын җентекләп күздән кичергән идек. Укучы бу Көннең Тәүратта, Инҗилдә, Коръәндә бер үк тәртиптә, бер үк схема буенча тасвирлануына игътибар итми калмагандыр. Бу Көнгә Коръәндә аеруча зур урын бирелә. Әйтик, анда Аллаһ әүвәл вакытлар төкәнгәндә кешелек дөньясын Хисап көне көткәнлеген хәбәр итә, аннан төрле аятьләрдә бу Көннең нинди Көн булуын аңлата, аңа ышанмаучыларны кискен рәвештә кисәтә, бозык адәмнәрне , Аллаһ юлыннан тайпылганнарны ул Көнне нинди сынаулар, җәзалар көтүе искә төшерелә. Галәм алдында имтихан тоткан Көндә гөнаһлылыр өчен Күк Капусы ачылмаячагы аятьләрдә ап-ачык итеп әйтелә. Шулай Хисап көнендә дөнья

халыкларының Аллаһ хозурына килеп Хөкем Карары көтүе сурәтләнә, кылган гамәлләренә карап, адәмнәрне ике төркемгә – илаһи имтиханны тапшырганнарга һәм тапшыра алмаганнар төркеменә аеру күренешләре тасвирлана. Һәм әйтелгән барлык сүзләргә нәтиҗә ясагандай, 81 нче сүрәдә Хисап көненең тетрәндергеч манзарасы күрсәтелә:

"Кояш бөрешеп калыр, йолдызлар таркалыр, таулар кубарылыр, дөяләр караучысыз калыр, кыргый җәнлекләр бер урынга тупланыр, диңгезләр күпереп ярларыннан чыгар, җаннар *(кылган эшләренә карап)* бер-берсеннән аерылыр, тереләй җиргә күмелгән кыз баладан: "Нинди гөнаһың өчен сине харап иттеләр?" – дип сорарлар. Гамәл Дәфтәрләре ачылып *(бар нәрсә)* фаш ителер, күкләр бушап калыр, җәһәннәм ут бөркеп торыр, җәннәт якынаер, – шул чакта һәр адәми затның җаны үз-үзенә ниләр әзерләгәнен ап-ачык күрер". *(81 : 1 – 14)*

Һәм Хисап көненең шушы тетрәндергеч манзарасын сурәтләгәннән соң Аллаһ исеменнән кешелек дөньясына фундаменталь сорау бирелә:

*"Кая юл тотасыз?*
*Бу бит халыклар өчен,*
*Туры юлдан барырга теләгәннәр өчен*
*Бер вәгазьдер". (81 : 26—28)*

Әйе, кешелек дөньясы яшәгән чакта бу бөек сорау беркайчан да үзенең әһәмиятен югатмаячак. Аңа төгәл җавап таба алмыйча, әллә инде табарга да теләмичә, менә без өченче меңьеллыкның да капкаларын ачып кердек. Өченче меңьеллык, – әгәр дә вакыт исәбен Гайсә пәйгамбәрдән саный башласак, ә аңа кадәр күпме меңнәр һәм миллион еллар үткәнен Раббыбыз үзе генә белә. Кешелек дөньясы инде сабый бала түгел, байтак дәверләрне кичергән, нәтиҗә ясарга вакыт бик җиткәндер. Ә нәтиҗәне Раббыбыз үзе ясый – Хисап көне аша. Ә Хисап көненә барыбыз да ышанабызмы соң? Күпчелек бит аны куркытып тәрбия кылу максатында уйлап чыгарылган әкият, дини мифология җимеше дип саный. Әмма Күкләрнең меңнәрчә еллар дәвамында җир йөзендә таралган рухи тәгълиматлар аша безгә ирештереп торган кисәтүе әкият, уйдырма була аламы? Алай дип уйларга нигез бармы? Бәлки, кемдер без корган дөньяны, моннан 12,5 мең ел элек булып узган Атлантида һәлакәтеннән соң кабат аякка баскан дөньяны, иң алдынгы һәм камил акыл белән төзелгән дөнья дип уйлый торгандыр? Бәлки, кемдер үтеп киткән берничә мең ел эчендә безнең нинди комфорт һәм фән-техника казанышларына ирешүебезне дәлил итеп китерергә җыенадыр? Ул чакта ни өчен Җирдә яшәү елдан-ел кыенлаша бара, саф һава, чиста су һәм чиста азык-төлек кимегәннән кими? Ни өчен гарип туган балалар саны һаман арта? Без төзегән коточкыч зур калалар Җир тәнендәге яман шешне хәтерләтә, аларда яшәү елдан-ел авырая, кешеләр машина төтененнән тончыга. Бәс, шулай икән, димәк, без корган дөнья бигүк дөрес юлдан бармый булып чыга, ул каядыр ялгыш юлга кереп киткән.

Һәм кабат безнең алга Коръәндәге фундаменталь сорау килеп баса:

" Кая юл тотасыз?"

Бу сорау Аллаһның үзеннән, ул кешелек дөньясы өчен беркайчан да көн тәртибеннән төшмәгән. Әлеге сорау адәми заттан һәрвакыт акыл һәм рухият таләп иткән. Әмма аны ишетүчеләр, аңа колак салучылар гына санаулы булган.

Инде менә җавап бирер, өлгергәнлегебезгә имтихан тотар вакыт килеп җитте...

* * *

Алдарак китерелгән 81 "Тәкъвир" *("Төреп кую")* сүрәсе, белгечләр фикеренчә, Мәккәдә Пәйгамбәргә вәхи килә башлаган беренче елларда ук иңгән, дип санала. Бу шулай ук 82 "Интифар" *("Ярылу")* сүрәсенә дә кагыла. Анда 81 сүрәдә әйтелгән фикерләр кабатлана. Бу хәл нәрсә турында сөйли соң? Димәк, Коръән иңә башлаган беренче елларда ук Хисап көне булачагы кабат адәм балаларының исенә төшерелә. Шулай кешелек дөньясы тарихында көтелгән иң әһәмиятле вакыйга Коръән иңә башлаганда ук ап-ачык итеп әйтелә.

Инде 82 сүрә аятьләренә мөрәҗәгать итик. Анда:

"Күкләр урталай ярылып, йолдызлар таралгач, елгалар агып беткәч, каберләр кубарылгач, һәркем киләчәге өчен ни хәзерләгәнен, фани дөньяда нинди гамәлләр

калдырганын беләчәк. И адәм баласы! Нәрсәгә кызыгып, син, чиксез юмарт Аллаһ нигъмәтләреннән коры калдың?" — дип ничәнче кат адәми затка сорау бирелә. Һәм шунда ук җавап та китерелә:

"Аллаһ сине юктан бар итте, сәламәт әгъзалар биреп, *(гәүдәнне)* тигез-төгәл ясады, һәрьяктан камил итте. Ничек теләсә, шундый кыяфәттә яралтты. Юк бит! Шушы ап-ачык дәлилләрдән соң да сез Кыямәт көнен ялганга чыгарасыз. Ә сезне күзәтеп торучылар барлыгын онытгыгыз, алар барысын да язып бара. Алар ни кылганыгызны белеп тора". *(82 : 1—12)*

"Күзәтеп торучылар" мәсьәләсенә килсәк, Нәфис дөньядагы югары технологияләр адәми затның кылган барлык эш-гамәлләрен теркәп бару мөмкинлеген бирә, махсус компьютер системасы барысын да язып бара. Әлбәттә, борынгы заманнарда моны кешенең ике иңендә утырган фәрештәләр теркәп бара дип аңлатканнар. Ул заманда кешегә мондый мәгълүматны бары шул рәвештә генә җиткереп булган. Бүгенге көндә исә эзотерик әдәбиятта кешелек дөньясының Галәмдәге Көчләр тарафыннан оештырылган Илаһи Бер Эксперимент булуы ачыктан-ачык әйтелә. *(Ченнелинг. Послания Старших Братьев Человечества. "София", Киев, 1998.)*

Әйе, адәми зат махсус рәвештә барлыкка китерелгән һәм, тәҗрибә объекты буларак, даими күзәтү астында яши. Адәми затны барлыкка китерүдә бик күп цивилизацияләр катнаша, алар үз геннарыннан аңа өлеш чыгара. Шуңа күрә кешене аларның уртак иҗат җимеше, генетик тәҗрибәләр нәтиҗәсе дип санарга тулы нигез бар. Әлбәттә, адәми зат әле гаять примитив чакта барлыкка килгән диннәр бу мәсьәләгә кереп тормый, кешенең барлыкка килү тарихын да, ул яшәгән дөньяны да бик нык гадиләштереп тасвирлый. Галәм, Раббыбыз тарафыннан иңдерелгән белемнәр һәр дәвердә кешенең аңы, психикасы кабул итәрлек, сыйдыра алырлык микъдарда гына бирелгән.

Әлбәттә, Пәйгамбәребезгә Коръән иңгән чактагы гарәп җәмгыятенә мондый белемнәрне җиткерү мөмкин булмаган, аның әле вакыты җитмәгән. Өлгермәгән җәмгыятькә бирелгән белем аны һәлакәткә китерергә мөмкин. Һәрхәлдә, ул уңай нәтиҗәгә китерә алмый. Атлантида һәлакәте моның ачык мисалы булып тора. Галәмнән килгән Люцифер *(Коръәндә ул Иблис буларак сурәтләнә)* командасы Атлантидага килеп төшкәннән соң андагы идарәчеләр белән сөйләшүләр алып бара, үзләрен шул җәмгыятьтә кабул итүләрен, урын бирүләрен сорый. Шуның бәрабәренә килмешәкләр атлантларны Галәмдәге югары технологияләр, әле җир йөзендә булмаган белемнәр белән тәэмин итәргә ышандыра. Атлантлар моңа риза була.

Әйтергә кирәк, шушы белемнәр, технологияләргә ия булу аркасында атлантлар кодрәтле җәмгыятькә әверелә, империя төзи, башка халыкларны буйсындыру сугышлары башлап җибәрә. Җәмгыятьтә кара сихер, табигать көчләреннән — стихияләрдән явызларча файдалану чәчәк ата. Бу инде адәми затның Раббыбыз өлешенә керүе була. Тора-бара Атлантида җәмгыяте килмешәкләр йогынтысына кереп каба, бу йогынтыны кабул итүчеләр һәм кире кагучылар төркеменә бүленә. Кире кагучылар Люцифер *(Иблис)* китергән технологияләрнең, белемнәрнең җәмгыятьне эчтән җимерүен ап-ачык күреп торалар, шуңа күрә аерым яши башлыйлар. Алар рухи сафлык саклау тарафдарлары булып калалар. Шулай Атлантида җәмгыяте икегә бүленә. Бер лагерьдагылар бирелгән белемнәрдән дөрес файдаланмый, нәтиҗәдә җәмгыять бик авыр хәлгә төшә. Һәм, ахыр чиктә, Атлантиданың һәлакәте белән тәмамлана. Әлбәттә, бу бик зур тема. Ул хакта аерым бер хезмәт язарга мөмкин. Әлегә без аны мисал өчен генә телгә алып уздык.

Шулай итеп, безнең эраның 7 гасырында кешелек дөньясы гарәп кабиләләренә иңгән Коръән аша үзен көткән зур сынаулар — Хисап көне турында тагын бер кат кисәтү ала. Бу соңгы кисәтү булганмы, әллә инде андый кисәтүләр, хәбәрләр планетабыздагы башка берәр цивилизациядә тагын да очрыймы? Алдагы бүлектә без шушы сорауга җавап табарга тырышырбыз...

*Ахыры киләсе санда.*

*Әдәбият тарихына*

**Равил Фәйзуллин**

# ГЫЙБРӘТЛӘР АЛЫРЛЫК ҮТКӘН ЮЛ

## ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНЫҢ 70 ЕЛЛЫГЫ УҢАЕННАН КАЙБЕР КҮЗӘТҮЛӘР, ХАТИРӘ-УЙЛАНУЛАР

Татарстан Язучылар оешмасына 70 ел... "Мең еллап тарихы булган татар әдәбияты оешмасына житмешме?" дип уйлап куяр кемдер. Әйе, сүз нигезе совет чорында корылган һәм әле бүген дә структур асылы шул ук калган язучыларның рәсми оешмасына нәкъ 70 ел. Дөрес, бер Татарстанга гына килгән юбилей түгел: безнең күрше республикаларга да, элек союздаш саналып йөртелгән бүтән халыкларның күбесенә дә кагыла торган юбилей бу. Үткәннәргә мөнәсәбәтнең һәм тарихи хәтернең ниндилегенә карап төрле җирләрдә төрлечәрәк билгеләп үттеләр әлеге датаны. Безнең каләмдәш агай-эне арасында да, бигрәк тә соңгы ярты елда, бу хакта сүз чыккалап торды. Төрле характердагы әдәби кичәләрдә, очрашуларда да халык колагына әйтелгәләп киленде. Без дә бу очракта үзебезне хәтерсезлектә битәрли алмыйбыз. Моннан ике ел элек журналыбызда оешма эшчәнлеге турында әтрафлы гына документаль язма бастырган идек. Соңгы елларда, "Казан утлары" архивыннан" дигән баш астында язучыларыбыз тормышының төрле якларын чагылдырган фотодокументлар чыгарып киләбез. Традицион "Әдәбиятыбыз тарихыннан", "Әдәби мирас", "Юбилейлар" рубрикаларында да, табигый, сүз шул ук әдәби елъязмабыз турында...

Иҗат оешмалары хакында нинди генә фикерләр (иҗатчыларның үзләре арасында да андый берлекләргә скептик караучылар бар) булмасын, реаль фактны танымый мөмкин түгел: иҗат союзлары, ягъни берлекләре (төрле чорда төрлечә әйтелгән, сүз сөрешенә карап һәм синоним буларак, язмабыздагы бу сүзләр һәр икесе дә кулланылыр) соңгы 70-80 ел эчендә әдәбият һәм сәнгать үсешенә йогынты ясаучы мөһим бер фактор булып торды. Әйтик, яңа заман татар әдәбияты елъязмасын Язучылар берлеге тарихыннан башка күз алдына китерү кыен. Оешма—XX гасырның байтак дистә елларында язучыларның иҗади хезмәтен оештыруда һәм бәяләүдә үзгә бер идеологик үзәк ролен үтәп килде.

Мәгълүм хакыйкать: иҗат эше күңел халәтенә—илһамга бәйле үтә индивидуаль хезмәт, хәтта аны интим шөгыль дип тә әйтеп буладыр. Оешма—сүзнең тамырыннан күренгәнчә, күмәклекне белдерә, ә иҗат итү дигәч, нигездә, ялгыз калып эшләү күз алдына килә. Бөек әсәрләрне—җырмы, көйме, рәсемме—исегезгә төшерегез—күбесен талантлы Шәхес ялгызлыкта—Дөнья белән бергә-бер калып, серле тынлыкта иҗат иткән бит! Әсәр туу—үзе бер тылсым! Аны, өстән яки кырыйдан әмер биреп, кушып тудырып булмый. Андый очракта тудырганың да ясалма, гарип чыга. Попугайны нәрсәләрнедер кабатларга өйрәтә алсаң да, сандугачны көчләп сайратып булмас, бөркетнең канатларын сындырсаң да, күз карашын кисә алмассың. Иҗат—асылы белән ирекле шөгыль. Иҗат иреге дигән гыйбарә тикмәгә генә тумаган! Шулай да...

Әйе, шулай да, нинди генә индивид һәм индивидуалист булып, "Аллалар белән генә сөйләшә торган" ялгыз халәттә калып, үзең өчен бөек тоелган нинди генә әсәр тудырсаң да, син аны үзең өчен генә иҗат итмисең. Күңел җимешен кемнәр беләндер бүлешәсе килә. Язучы икәнсен—әсәреңне китап итеп чыгарасы, кешеләргә ирештерәсе килә, рәссам икәнсен—эшләреңне җыеп, күргәзмә ясап күрсәтәсе, артист икәнсең—сәхнәне иңлисе килә... Менә шунда инде кешеләргә елышасың, аңлашуга өметләнеп коллегаларыңа барасың, теге яки бу мәсьәләне чишәр өчен хакимдарларга, оешмаларга

мөрәҗәгать итәсең... Ялгызың иҗат итеп булса да, ялгызың гына яшәп, тормыш итеп булмый. Булса да бик кыен. Ә дөньялыкта адәм баласына, һай, күп кирәк!

Очрашу-аралашу урыны да, иҗатың турында кеше сүзен ишетү яки бүтәннәр турында үз фикереңне белдерү өчен трибунасы да, нәрсәгәдер дәгъва итеп белешмә-тәкъдимнамәсе дә... Ахыр килеп, яшәр өчен түбә-куыш та кирәк бит әле, үлем-каза килгәч, күмелергә урын... Ә кая барасың?..



Озынга сузылырга охшаган бу язмамны нигә дип яза башладым соң әле? Акыллыга сабышып, бүтәннәрне нәрсәләргәдер өйрәтергә, сабак бирергә теләгем юк, кемнәрдер алдында кемлегемне күрсәтү ихтыяҗы юк. Хаҗәте дә юк. Яшьлектә максат итеп куелган үрләремнең күбесенә менелде... Нәрсә өчен язып, бастырып чыгарырга ниятлим соң алайса? Мөгаен, иң әүвәл, үзем куйган сорауларга үзем җавап эзләп азаплануымдыр бу. Алга таба әдәбиятыбызның язмышы ничек булыр? Без элгәргеләрдән эстафета итеп алган арбаны алга этәр өчен кемнәргә калдырабыз? Гомумән, ул әдәбият дигән арбаның кирәк-хаҗәте ни дәрәҗәдә булыр? Бу сораулар күпләрне борчыйдыр дип уйлыйм (шулай булса, димәк, язуым аклана). Язучылар оешмасының бу юбилей датасы уйлану-фикерләшү өчен бер сәбәп кенә. Төп мәсьәлә—безнең рухи киләчәгебез. Киләчәк турында төпле фикер йөртер өчен, үткәннәрне белеп, гыйбрәт алу, бүгенгене хәлкадәри анализлау фарыз. Алда әйткәнемчә, соңгы чор әдәбиятыбыз тарихы язучылар оешмасы белән тыгыз бәйләнгән. Бу язманың авторы буларак искәртеп узыйм, минем дә, бу оешма белән гомерем тоташкан, аның өчтән ике өлеше турыдан-туры аңа бәйле. 40 елга якын Язучылар союзында әгъза булып торып, шуның 37 ел дәвамында тоташтан шушы оешманың идарә әгъзасымын. Уйлап баксаң, үзе бер гомер. Шуңа күрә, Язучылар оешмасы, аның эшчәнлеге турында уйланып фикер әйтергә хакым бар шикелле. Күрәсең, мемуар-истәлекләр язар чак та җиткәндер. Беркөн язучылар исемлеген актарып аптырабрак калдым: миңа кадәр СССР Язучылар союзына кабул ителгән язучылар нибары 5-6 гына калган... Теләсәң-теләмәсәң дә, әдәби хезмәт вахтасында ветеран булып чыгам икән...

Иң әүвәл шуны ассызыклап узыйк: СССР дигән держава яшәгән чорда иҗтимагый әһәмияте зур булган иҗат берлекләре—иҗат союзлары эшләп килде. Шул оешмаларның иң зурысы һәм иң абруйлысы—Язучылар союзы булды. Саны ягыннан да, дәрәҗәсе ягыннан да дөньяның бүтән илләрендә андый оешма юк иде. Язучылар союзы әгъзасы булу иҗат кешесе өчен зур казаныш саналды. Югары гыйльми дәрәҗә алулардан бер дә ким түгел иде бу әгъзалык. Алай дөньяда тиңе булмаган нинди оешма соң бу, нинди максат белән төзелгән дә нинди идеалга һәм нинди даирәгә хезмәт иткән? Профессионаллар берләшмәсе дияр идең, мәдәният, шул исәпкә язучылар да кергән аерым профсоюз системасы бар иде. Союз эчендә аның бүлекчәләре бар иде әле... Үзара ярдәмләшү, социаль яклау берләшмәсе дияр идең, бу функцияләрне башкаручы, Россиядә тарихы XIX гасырга ук тоташкан Литфонд (әдәби фонд) бар... Әйе, иҗат союзларының, бигрәк тә Язучылар союзының социаль функциясе бүтәнрәк, тирәнрәк. Аны аңлау, асылына төшенү өчен, объектны, мотлак, шул иҗтимагый чор идеологиясе аша, үтелгән Вакыт призмасы аша карап анализлау мөһим. Чишмә башын, тора бара аңа кушылган бүтән чыганакларны белсәң генә елганың зурлыгын, агышының куәт-көчен чамалый аласың.

СССР Язучылар союзы төзелү 1934 елдан саналса да, аның башлангычы 1932 елга—ВКП(б) Үзәк Комитетының 23 апрельдә чыгарган карарына тоташа. Язучылар союзын оештыру мәсьәләсе, нигездә, шул елны хәл ителә. 1934 елга кадәрле калган ике ел әзерлек эшләренә китә. Үзәктә һәм республикаларда бу юнәлештә кызу эшләр башлана. Шул ук елның маенда Татарстан совет язучыларының Бердәм

союзын төзү буенча Г. Нигъмәти җитәкчелегендә оештыру комитеты төзелә. Комитетның максаты—төрле төркемнәргә бүлгәләнгән (ТАПП, СУЛФ, «юлаучылар» һ. б.) язучыларны бер максатка юнәлтеп берләштерү. Сүз уңаеннан әйтеп узыйк: башлангычы «Безнең юл» булган журнал да ул елларда бүлгәләнеп, «Яналиф», «Атака», исемнәре белән чыккан иде. Алар урынына «Совет әдәбияты» исемле журналның чыга башлавы әнә шул берләштерүнең бер чагылышы иде.



*Мәскәүнең Колонналы залы.*

СССР Язучылар Союзының нинди максат белән, нинди социаль нигезгә салынуын аңлау өчен, әйткәнемчә, шул чорның атмосферасын күз алдына китерергә тырышыйк. Октябрь инкыйлабы үтүгә 15 ләп, СССР төзелгәнгә 10 еллап вакыт үткән. Советлар Союзында моңарчы дөнья күрмәгән хәл—сыйныфсыз җәмгыять төзелә. Шәхси милек юк дәрәҗәсендә: завод-фабрикалар күптән национализацияләштерелеп дәүләткә күчкән, җирләр башта алпавытлардан, соңрак крестьянның үзеннән дә тартып алынып, күмәк хуҗалыклар-колхозлар төзелгән. Авылның хәлле кешеләре сөрелгән. Пролетариат, юксыллар, социализм сүзләре гегемоник яңгыраш алган мохиттә, милек, мөлкәт төшенчәләре бөтенләй контрсүзләр булып кабул ителә. Олы-кечене
нме, наданнынмы, укымышлынынмы колак төбендә яңгыравыклы шигарьләр: Иске Дөньяны штурмлау бара! Капитализм җәмгыяте бетәчәк! (Шул заманда, капиталистик мөнәсәбәтләрнең 60-70 елдан соң СССР кинлекләренә янәдән кайтачагын, уртак байлыкның талап-урланып, халыкның аз сандагы бик байларга, күп сандагы бик хәерчеләргә аерылып бетәчәген күз алдына китерүчеләр булдымы икән?), Кешелек капиталь изүеннән азат ителәчәк! Яшәсен Бөтендөнья революциясе! Яшәсен коммунизм!.. Интеллегенция аптырашта! Дворян тәрбиясе, университет белеме алганнарның байтагы эмиграциядә, бер өлеше тавыш чыгармый, дәшми, сагаеп нидер көтә, бериш аумакайлар партия җырын җырлап көн үткәрә... Вәзгыять бер дә көлке түгел. Европа, гомумән Тышкы Дөнья арасына “Тимер пәрдә” корылган. Демократия сүзе архаик төшенчәгә әйләнгән. Аны кирәксенүче дә бик юк... Ни гаҗәп, бәлки, парадокстыр: дөнья җәмгатьчелегенең СССРга игътибары гаять зур. Планетаның алтыдан бер өлешендәге бөек социаль экспериментлар бара! СССРда һәркем тигез, сыйныфсыз, гадел җәмгыять төзелә. Кешелекнең хыялы бит бу! Капитализм—берәүләрнең хәләл хезмәте бәрабәренә икенче берәүләрнең череп баюына корылган капитализм, гасырлар буе байтак акыл ияләренең нәфрәтенә юлыккан строй. Советлар Союзына, сирәк булса да, дөньякүләм мәшһүр язучылар килә. Ромен Роллан, Анри Барбюс, Бернард Шоу һ. б. Алар Сталин һәм башка дәүләт җитәкчеләре белән очрашалар. Россия, Советлар Союзы турында гаять зур фикерләр, канәгатьлек хисләре белән кайталар туган илләренә. СССР турында матур-матур интервьюлар бирәләр, социалистик стройның өстенлекләре турында сөйлиләр, язып чыгалар. Зур талантлар икейөзләнмәс: алар күңелләгеләрен ихлас сөйләгәннәрдер дип уйлыйм. Күрәсең, аларны чыннан да яхшы каршылаганнар: ул шәхесләр яхшыны гына күргәннәр, яхшыны гына ишеткәннәр дә. Дөньякүләм мәшһүр язучыларның СССР турындагы фикерләре ил башлыклары өчен, әлбәттә, зур сәяси отыш булган. Әгәр илдә яшәгән күп санлы язучылар армиясен шундый рухта—максат итеп алынган идеологиягә хезмәт иттергәндә? Сүз—зур көч. Язучылар—“кеше рухының инженерлары”. Безгә, без күрергә теләгән җәмгыятьтә

без күрергә теләгән масса кирәк... Шулай уйлаганнар хакимдарлар. Менә шундый вәзгыятьтә оеша башлый СССР Язучылар оешмасы.

* * *

**1934 ел. 17 август. Мәскәү. Колонналы Зал. Әдәбиятлар тарихында моңа кадәр тиңе булмаган язучылар җыены. 52 милләт вәкилләрен тәшкил иткән 591 делегат. Кунак сыйфатында төрле континентлардан килгән 40 чит ил язучысы. Совет язучыларының I нче Бөтенсоюз оештыру съезды ике атнадан артык (!) дәвам итә. 17 августта ачыла, соңгы—26 нчы ябылу утырышы 1 сентябрьдә була.**

Бу урында Мәскәүдә үткән грандиоз съезд турында беразга тукталып торып—алда бу хакта тәфсилләбрәк сөйләү булыр—шул чорның үзебезнең җирлектәге иҗтимагый-сәяси вәзгыять һәм әдәби мәйдан-мохит турында берничә сүз әйтеп узыйк.

Татарстанда "солтангалиевчелек"не "фаш итү" тәмамланган чор, татарның байтак акыллы башлары юк ителгән, зыялы катлам өркетелгән, куркытылган чор... Әдәбият дөньясы да таркау, чуар; өстәвенә зур фигуралар аренадан китеп бара... Г. Исхакый—эмиграциядә, Такташ инде юк, Г. Камал яңа гына вафат, Г. Ибраһимов—авыру, Казаннан еракта, Кырымда яши, Г. Газиз—Бакуда, Г. Кутуй, Н. Исәнбәтләр "җидегәнчелек"тә гаепләнеп, әдәби хәрәкәттән читләштерелгән, Г. Бәширов, С. Баттал, Ә. Еникиләр—әле яшь, башлап язучылар санала... Шулай да, шәхес буларак колоритлы язучылар шактый әле Казанда. Татарстанда туып үскәннәр дә җитәрлек, төрле төбәкләрдән килеп кушылганнар да байтак. 1934 елның беренче яртысында СССРның төрле почмакларында—республикаларда, өлкәләрдә язучыларның корылтай-съездлары үтә, җирле оешмалар төзелә, ил күләмендә узачак Зур Съездга вәкилләр—делегатлар сайлана. Татарстанда да башкарыла бу эш.

**Язучыларның беренче җыены рәсми рәвештә совет язучыларының Беренче бөтен Татарстан съезды дип аталган. Съезд Татар Дәүләт академия театрында 1934 елның 25 июлендә ачыла, һәм Мәгариф эшчеләре йортында дүрт көн дәвам иткәннән соң, 29 июльдә ябыла.** Беренче оештыру съезды шул заманнарга хас булганча үтә тантаналы һәм патетик рухта үтә. Почетлы президиум, плакатлар, котлаулар, көчле кул чабулар... Съездны кыскача кереш сүз белән язучы Кави Нәҗми ача. Язучылар союзын оештыру комитеты председателе Г. Ризвановның өч сәгатьтән артыкка сузылган докладын тыңлана. Съездда иҗат мәсьәләләре буенча Гомәр Гали, Галимҗан Нигъмәти, Кәрим Тинчурин, Риза Ишморат, Фатих Кәрим докладлары тыңлана. Чыгыш ясауларда Гази Кашшаф, Хәбра Рахман, Гомәр Толымбайский, Фәтхи Бурнаш, Әхмәт Фәйзи, Мирсәй Әмир, Шамил Усманов, Ибраһим Салахов, Хәсән Туфан, Муса Җәлил һ. б. катнаша. Съездның оештыру эшләре мондый нәтиҗә белән тәмамлана: Татарстан Язучылар союзының беренче идарә составына 9 кеше сайлана. Алар: Кави Нәҗми (председатель), Кәрим Тинчурин, Гомәр Гали, Гомәр Толымбайский, Хәсән Туфан, Ләбиб Гыйльми, Г. Ризванов, В. Красный, Кәшшаф Төхфәтуллин (секретарь). Бөтенсоюз съездына 12 делегат җибәрергә карар кылына. Бу 12 делегатның 9 ы әле саналган идарә әгъзалары, калган 3 се идарә әгъзалыгына кандидатлар: Ибраһим Гази, Галимҗан Нигъмәти, Фатих Сәйфи-Казанлы. Аерым исемнәрне искә алмаганда, нигездә, мәгълүм шәхесләр, татар әдәбиятыннан хәбәрдар булган кешеләр өчен билгеле язучылар. Ул вакытта алар әле яшь: 30-40 лар тирәсендәге гайрәтле ир-егетләр. Алдагы 10-15 елда нинди әсәрләр язарлар да, үзләренә нинди язмыш язылыр?..

Совет Язучылары союзы оешу турыдан-туры Максим Горький исеме белән бәйле. Ул аның идея җитәкчесе, фактик оештыручысы. Бу грандиоз башлангычны күтәреп җибәрер өчен, әлбәттә, дөньякүләм абруйлы бер бөек шәхес кирәк булган. Ул—М. Горький. Язучылар арасында аңа тиң кеше юк ул заманда. Шуңа күрә дә, оештыру комитеты рәисе буларак, совет Язучыларының беренче бөтенсоюз съездын ул ачып җибәрә дә. Протокол тәртибе буенча, ВКП(б) ҮК секретаре А. Жданов нотыгыннан соң, төп докладны да М. Горький ясый.

Ул көннәрнең язма рәвештәге иң ышанычлы шаһиты—съезд стенограммасы (съездда катнашкан берәр кеше исән микән әле? Исемлектә мина азмы-күпме таныш фамилияләрне барлап чыктым,—очрамады. Бу җыенда яшь журналист яки язучы булып катнашкан берәрсенең исән булуы да мөмкин). 50 басма табакка якын күләмле документ. Үзе бер энциклопедия! Булмый ни, чыгыш ясаучыларның саны гына да

224 кә житә. Котлау-тәбрикләүдә катнашучыларны да исәпләсәң, трибунадан 300 дән артык кеше нотык тота! Без бу стенографик язмалардан цитата рәвешендә кайбер чыгышлардан өзекләр, җөмләләр китереп узарбыз. Фактан да дөресрәк факт юк. Алар, нигездә, СССР Язучылар союзының Уставын тәшкил иткән тезислар. Ә Устав инде үзенчә бер канун дигән сүз.

М. Горький съездны ачканда беренче җөмләсендә үк мондый сүзләр әйтә *(кайбер цитаталарны съездда сөйләнгәнчә, рус телендә бирергә булдык—Р. Ф.)*: "...разрешаю себе сказать несколько слов о смысле и значении нашего съезда. Значение это—в том, что прежде распыленная литература всех наших народностей выступает как единое целое перед лицом революционного пролетариата всех стран и перед лицом дружественных нам революционных литераторов".



*СССР язучыларының I съездында алынган рәсем. Беренче рәттә сулдан уңга: Кави Нәҗми, Алексей Толстой, Максим Горький; икенче рәттә: Ләбиб Гыйльми, Хәсән Туфан, Гомәр Толымбайский, Фатих Сәйфи-Казанлы, Галимҗан Нигъмәти. 1934 ел.*

М. Горький доклады һәркем өчен, бигрәк тә язучы өчен, бүген дә кызык һәм гыйбрәтле. Бөек язучы күтәргән кайбер мәсьәләләр бүген дә бик актуаль. Әйтик, Көнбатыш әдәбиятчыларының күп әсәрләрендә кешенең түбән инстинктларын уята торган мотивларны; үтерү, көчләү, талау, зина кылу фонында каһарман итеп сурәтләнгән персонажларны тәнкыйтьли (Дәрдмәнд әйтмешли, "нә дәригъ"—бүген китап базарларыбыз шундый "әсәрләр" белән тулган!), дөнья барышының үзәген тәшкил иткән гади хезмәт кешесен олыларга өнди. Докладның иң төп тезисларның берсе, ул—халык иҗатына игътибарны юнәлтү. Һәр әдәбиятның нигезендә фольклор ята дип саный Горький. Бу дөрес фикер, аксиома кебек хакыйкать, бик вакытлы яңгырап, язучылар өчен дистә еллар буена директива, үзенә күрә бер күрсәтмә булды. Бигрәк тә яңа туып яки терһәкләнеп килүче әдәбиятлар өчен файдалы булды бу девиз. Күп кенә халыклар рухи тарихларыннан—халык иҗатыннан үзләренең мифик яки реаль геройларын "казып" чыгардылар, нәфис әдәбиятларына нигез салдылар.

М. Горький докладында күпләребез, бигрәк тә безнең өчен бик тә кадерле, чын мәгънәсендәге интернациональ рухлы фикерләр тагын бар. Ул, мәсәлән, болай ди: "Мы не имеем право игнорировать литературное творчество нацменьшинств только потому, что нас больше. Ценность искусства измеряется не количеством, а качеством. Если у нас в прошлом—гигант Пушкин, отсюда еще не значит, что армяне, грузины, татары, украинцы и прочие племена не способны дать величайших мастеров литературы, музыки, живописи, зодчества..." Гомумән, "тормыш университетлары"н тирән үзләштергән, яшәешендә төрле милләт вәкилләренең төрле катламнарын яхшы белгән Горький, жир йөзендәге һәр халыкка тирән ихтирам белән карый. Татар халкын аеруча якын күрүе аның һәм әсәрләрендә, һәм җәмәгать эшчәнлегендә ачык сизелә. Ул үзенең бу докладында да, милләтләр турында сөйләгәндә, татарларны гел искә ала. СССРдагы дүрт-биш милләтне санаган чакта татарны телгә алмый калмый. Бер татар язучысы менә нәрсә язган дип докладында өзек тә (ул үзе машинкада 1,5 бит булыр) укып күрсәтә. Йә, хәзер кайсы рус язучысы безнең хакта дөньякүләм трибунадан шулай әйтер микән? Солженицынмы? Распутин яки Беловмы?.. Юк, алар әйтмәсләр, бүтәннәре дә әйтергә охшамаганнар.

Бу съездда Татарстаннан 12 вәкил катнашканын искәртеп узган идек. Аларның тавышы ишетелгәнме бу җыенда? Гомумән, татар әдәбияты турында нинди сүз булган? Моңа җавап ачык: татар язучылары съезд эшендә актив катнашкан һәм татар әдәбиятының рейтингы югары булган. Дәлил рәвешендә шуны гына әйтү дә җитә: съездда милли әдәбиятлар буенча украин һәм белорус вәкилләреннән соң, өченче итеп сүз Татарстан Язучылар союзы рәисе Кави Нәҗмигә бирелә һәм ул татар әдәбиятының торышы турында зур доклад белән чыгыш ясый (грузин, әрмән, әзәрбәйҗан, үзбәк, төрекмән, таҗик әдәбияты вәкилләренә сүз әле соңрак бирелә. Гомумән, милли әдәбиятлар буенча, М. Горький докладын санамаганда, нибары тугыз халыкның әдәбияты турында гына махсус докладлар ясала. Кызык, 70 елдан соң, хәзер шундыйрак халыкара форум булса, безгә сүзне кайчан бирерләр, гомумән, бирерләр иде микән?). Шуна өстәп, тагын бер татар язучысы чыгыш ясый әле бу съездда. Ул—Кәрим Тинчурин. Бу хакта белүчеләр аз. К. Нәҗми һәм К. Тинчурин чыгышлары турында шәрехләп сөйләп тормыйм—аларны үзенә уку кирәк—берничә сүз белән генә төп фикерләрен әйтеп узам. К. Нәҗми, язучылар рәисе буларак, татар әдәбиятының шул чордагы торышы турында тәфсилле сөйли, заманы, дөресрәге партия кушканча, элекке тормышны, буржуазия вәкилләрен, милләтчеләрне, әлбәттә, яхшы ук сүгә. Шулай ук, замандашлары Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ш. Камал, Ф. Бурнаш, Х. Такташ, Х. Туфан, Ш. Усманов, К. Тинчурин, М. Әмир, И. Гази, М. Җәлил, Ф. Кәрим һ. б. турында уңай фикерләр әйтә, иҗатларын югары бәяли. Кәрим Тинчурин съездда партиясез делегат сыйфатында чыгыш ясый, күбрәк татар драматургиясенең хәле, үсеш перспективалары турында сөйли. Һәр ике оратор да, партиягә бирелгәнлекләрен демонстрацияләүгә дәлил итеп булса кирәк, сыйнфый нәфрәт белдереп, Гаяз Исхакыйны каты тәнкыйть итәләр... Ничек кенә булмасын, зур трибунадан алар татар халкы, аның язучы вәкилләре булып чыгыш ясаганнар. Ялгышларын Алла ярлыкасын, әмма аларның файдалы гамәлләре дә сагынып искә алырлык.

Мандат комиссиясе белдерүе дә игътибарга лаек. Делегатларның милли составы ягыннан караганда хәл болайрак: руслар—201 (алар арасында яһүдләр дә шактый булган дип исәпләргә кирәк), украиннар—30, грузиннар—28, татарлар—19 (бу санга бүтән өлкәләрдә яшәүче татарлар да кергән; мәсәлән, Габдрахман Теләш—Чиләбедән), әрмәннәр—19, үзбәкләр—12, төркмәннәр—5... Икенче бер момент—яшь ягы (бүгенге көн күзлегеннән караганда бу бик мөһим): съездда катнашкан делегатларның уртача яше—35,5 яшь! Ә менә хатын-кыз депутатлар бу съездда аз булган: нибары 21 кеше. Эмансипация, күрәсең, әле уянып кына килгән чор...

Шулай итеп, август уртасында башланган съезд сентябрь башында эшен тәмамлый. Докладлар укылган, нотыклар сөйләнгән, котлаулар яңгыраган, Сталинга, партиянең башка җитәкчеләренә сәламантлар юлланган... Чыгышлар турында өстәп шуны гына әйтәсе килә: шул чорның иң күренекле язучылары катнашкан һәм сүз әйткән бу съездда. Совет чорының классиклары саналганнардан—М. Горький, М. Шолохов, С. Маршак, А. Толстой, К. Федин, А. Фадеев, Л. Сейфуллина, Н. Тихонов, А. Сурков, А. Серафимович, И. Эренбург, Б. Пастернак, К. Чуковский, И. Бабель, Л. Соболев, М. Шагинян...; милли әдәбият вәкилләреннән—С. Айни, М. Бажан, К. Нәҗми, Т. Табидзе, И. Кадыр, С. Стальский, С. Сәйфуллин, Я. Колас...; чит ил язучыларыннан—Луи Арагон, Жан-Ришар Блок, Рафаэль




*Максим Горький—татар язучылары өчен рухи остазларның берсе иде. Алгы планда—язучы Нәби Дәүли. 70 еллар фотосы.*

Альберти, Антал Гидаш, Андре Мальро, М. Андерсен Никсе... Төп һәм кызыклы докладларның тагын берсе турында әйтми узсак, дөреслеккә хилафлык булыр; ул— Н. Бухарин доклады. "Поэзия, поэтика һәм СССРда поэтик иҗат проблемалары". Коммунистлар партиясенең югары эшолонындагы бүтән берәр кешенең шигырь турында шундый характерда доклад ясаганы, мөгаен, тарихта бүтән юктыр.

Әйе, съезд тәмамлана. М. Горький йомгаклау сүзе белән чыга (нишләптер, стенограммадан берничә гыйбарә хәтергә нык сеңеп калды: "мы живем и работаем в начале первого акта последней трагедии трудового человечества". Монысы— сискәндергәне, икенчесе—күңелгә ятышлысы: "Не менее важно знание нами языков армян, грузин, татар, тюрков..." Съездда 101 язучыдан торган Идарә сайлана. Идарә әгъзасы итеп Татарстаннан Кави Нәҗми кертелә. Аерым докладлар буенча (М. Горький, К. Радек, С. Маршак) махсус резолюцияләр кабул ителә... Иң мөһиме— "бөтендөнья пролетариаты Ватаны"—СССРда рәсми рәвештә Совет Язучылары союзы оеша һәм аның төп кануны—Устав кабул ителә. Еллар узып, аз-маз үзгәрү-редакцияләнүләр кичерсә дә, бу Устав ким дигәндә ярты гасыр кагылгысыз булды, 1934 елда кабул ителгән маддәләр XX гасырның 90 нчы елларына кадәр язучылар өчен канун булып яшәде.

Уставның асылын аңлар өчен аннан берничә маддә-өзек китереп узу мәслихәт булыр. "Писатели Союза Советских Социалистических Республик, стоящие на позициях Советский власти, желающие активно участвовать своим творчеством в классовой борьбе пролетариата и в социалистическом строительстве, решили объединиться в единый Союз советских писателей."




"Союз советских писателей ставит генеральной целью создание произведений высокого художественного значения, насыщенных героической борьбой международного пролетариата, пафосом победы социализма, отражающих великую мудрость и героизм коммунистической партии. Союз писателей ставит своей целью создание художественных произведений, достойных великой эпохи социализма".

Бу съездда, шулай ук, совет әдәбиятының үзәге, дөресрәге, принцибы саналган "социалистик реализм" дигән термин тәмам формалашып канунлаштырыла. Бу хакта Уставта болай диелә: "Социалистический реализм обеспечивает художественному творчеству исключительную возможность проявления творческой инициативы, выбора разнообразных форм, стилей и жанров."

Менә шушы дөньякүләм идеологик акциядән сон үткән язучылар мохитен—шул 70 еллык чорны ничегрәк итеп системалаштырырга соң? Нинди принциптан чыгып, нинди периодларга бүлергә? Бу мәсьәлә галим-голәмә өчен дә, әлбәттә, актуаль булып килә. Әйтик, "Татар әдәбияты тарихы"ның 6 томлыгын карасаң, анда үзенчә бер тәртип: дистә елларны иҗтимагый-сәяси вакыт берәмлегенә карап бүлү һәм бәһаләү. Ә әдәбиятның үз үсеш-торгынлык чорларын исәпләп системалаштырсаң, бүтәнчәрәк бүленеш килеп чыга. Чоры катлаулы һәм болганчык булгач, бернинди бүленеш тә фәнни объектив кысаларга сыеп бетә алмый. Шулай да, үзем тоемлаган һәм аңлаганча *дүрт периодка бүлеп карар идем бу житмеш елны: 1934 елдан сугыш ахырына кадәрге еллар; сугыш соңыннан башлап 50 еллар ахырына кадәрге еллар; 1960-90 нчы еллар; 90 еллардан бүгенге көнгә кадәрге еллар.* Әлбәттә, мондый бүленеш тә шартлы һәм ясалма. Ә миңа үз фикеремне белдерер өчен унай булгач тагын нәрсә кирәк?

Әйдә, шул шартлы бүленеш кысаларында татар әдәби хәрәкәтен, шул нисбәттән яңа оешкан Язучылар союзы эшчәнлеген күз алдыннан кичереп карыйк.

## I

Әйе, зур тарихи съездан рухланып, канатланып кайта язучыларыбыз. Эшкә тотыналар... Ә алда? Фаҗигаи еллар, сугыш афәтләре... Шуны гына әйтү житә: Зур

Съездда яхшылар рәтендә макталган язучыларның яртысыннан күбесе репрессия корбаннарына әверелә!?. Гарәпчә мантыйкка, грекча логикага сыймас хәлләр...

Шулай да, Язучылар союзы оешу мөнәсәбәте белән әдәби хәрәкәттә жанлану нык сизелә. 1934 ел тоташы белән Язучылар союзын оештыру елы. Әйтик, май аенда "Кызыл Татарстан"да СССР Совет Язучылары союзының уставы басыла. Июнь аенда Совет Язучылары союзына кабул итү Үзәк Комиссиясенең утырышы була. Союзның беренче әгъзалары кемнәр соң? Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, К. Нәжми, К. Тинчурин, Ш. Камал, Г. Гали, Г. Толымбай, Ф. Бурнаш, М. Әмир, Х. Туфан, М. Жәлил, Ф. Сәйфи, М. Гали, И. Гази, М. Крыймов, Ә. Фәйзи, И. Туктаров, М. Максуд, Ф. Кәрим, С. Баттал, Т. Госманов (Хатип Госманның абыйсы). Совет язучылары союзына кандидат итеп Ш. Усманов, Р. Ишморат, Б. Зернит, А. Шамов, Галимжан Мөхәммәтшин, Т. Гыйззәт, Ә. Ерикәй, Н. Баян. Алда әйтеп үтелгәнчә, июль ахырында Татарстан совет язучыларының Беренче съезды үткәрелә... Сонрак—язучылар союзы инициативасы белән төрле секцияләр оештырыла, яшь язучылар белән эшләү буенча консультация бюросы төзелә. Язучылар төрле юбилей чараларында актив катнаша (Пушкинның үлүенә 100 ел, Тукайның тууына 50 ел, Горький, Г. Камал, Ш. Камал, Такташка багышланган кичәләр h. б.)... Әлбәттә, жыелышлар (гомумиләре дә, партиялеләрнеке дә) үтә, мотивлары "татар совет әдәбиятының яна үсеш баскычлары" дигән яки шуңа охшашлы формулировкадагы докладлар сөйләнелә... Союзның шул чордагы эшчәнлегендәге бер үзенчәлекне искәртеп үтү кирәк: тәржемә эшенә, нигездә русчадан татарчага тәржемә итүгә бик нык игътибар бирелә әлеге чорда. Бу—аңлашыла да. СССР Язучыларының Беренче съездында ил халыкларының әдәбиятларын тәржемә аша пропагандалау—төп мәсьәләләрнең берсе итеп куелган иде. Горький докладында да, башка чыгышларда да күп әйтелә бу хакта. 1934 елда ук Татарстан Язучылар оешмасы каршында тәржемәчеләр секциясе эшли башлый. Житәкчесе—Ибраһим Гази. Бу вакытта Казанда инде марксизм-ленинизм институты оешкан. Ул, нигездә, Ленин—Сталин әсәрләрен татарчага тәржемә итү белән шөгыльләнде (бу жәһәттән, татарлар илдәге күп халыкларны уздырып, — милли республикалар арасында бердәнбер түгел микән әле?—Ленинның ул заманда русча чыккан бөтен әсәрләрен татарча бастырып чыгарды). Татарстан китап нәшриятында оператив рәвештә М. Горькийның татарча өч томлыгы дөнья күрә. М. Шолоховның "Күтәрелгән чирәм"е, Ф. Гладковның "Энергия" исемле романы, А. Корнейчукның "Эскадраның һәлакәте" дигән пьесасы, А. Гайдарның "Мәктәп" повесте басылып чыга... Тәржемәчеләре А. Шамов, Ш. Камал, Ф. Бурнаш, С. Әдһәмова h. б. "Совет әдәбияты"ның шул еллардагы саннарын алып карасаң да, журналның иң күп өлеше тәржемә әсәрләргә бирелгән. Күрәсең, директив күрсәтмә арттырыбрак үтәлгән. Бер яктан, татар укучысы рус әдәбиятын туган телендә укый алган. Әсәрләрнең идея-художество дәрәжәсе нинди булуга карамастан, телне саклау жәһәтеннән бу гамәл аклана да кебек. Әмма... Хәрәкәт бер яклы гына булган шул. Дөрес, "Огонек", "Лит. Газета" битләрендә татар язучыларының кайбер кечкенә күләмле әсәрләре басылу очраклары да булган...



*Әдип Фәтхи Бурнашның кулга алынган көннәрдә (1940) һәм төрмәдә утырганда (1942) алынган рәсемнәр.*

Болар, нигездә, 1934-36 нчы еллар, Язучыларның оештыру съездлары үткәннән соң беренче еллар. Ниһаять, ил тарихының шомлы 37-38 еллары. Әйткәнемчә, аңларга һәм аңлатырга авыр чор... Язучылар лидеры булып, союзны оештырып йөргән яки бу башлангычны күңеле һәм гамәле белән хуплаган байтак әдипләр кулга алынып төрмәләргә утыртылган. Әле бер ел элек кенә 25 еллык ижат бәйрәме үткәрелгән

К. Тинчурин ябылуда, Г. Ибраһимов төрмәдә... Вакыт аралыкларында бераз аерымлыклар булса да, шул ук язмышка дучар булган И. Салахов, Ш. Усманов, Г. Толымбай, Г. Гали, М. Галәү, Г. Нигъмәти, Ф. Бурнаш, Ф. Сәйфи-Казанлы, К. Нәҗми, Ф. Кәрим, М. Әмир, С. Рәфиков, Л. Гыйльми, Х. Туфан... Исемлекне дәвам иттерергә була. Кайсылары юкка чыгарылган, кайсылары алтын гомерләре мәхбүслектә үткәч кенә кайта алган, кайсылары фәлән ай гына утырып, куркытылып, кушканны үтәүчеләр булып калган... Әдәби фигураларның байтагы кулга алынгач, көчләр таркатылгач, табигый, Союзның тулы канлы эшчәнлеге турында сөйләү кыен... Чор "таләбе" буенча оешма житәкчелегендә дә яңа "лидерлар" пәйда була. Т. Имаметдинов, И. Вахитов, Х. Жәмил... Бу исемнәрне өлкән буын язучыларының да бик сирәге, ишетеп кенә белә булыр... Архив тарихында бар саналсалар да, әдәбиятта алар юк. Шулай да, еллар хроникасына күз салсаң, оештыру эшләре бер дә бармаган дип әйтеп булмый. Әйтик, 1937 елның 28 апрель—5 май көннәрендә Татарстан язучыларының гомуми жыелышы була (докладчы Т. Имаметдинов), июнь аенда Т. Гыйззәтнең "Ташкыннар" пьесасын укып тикшерү уздырыла, сентябрьдә иң яхшы опера либреттосына игълан ителгән конкурсның комиссия составына берничә язучы кертелә, "Совет әдәбияты"ның 6-7 саннары тулысы диярлек М. Горький ижатына багышлана. 1938 елның апрелендә Тукайның үлүенә 25 ел тулуга багышланган зур кичә үтә, июньдә язучыларның гомумжыелышы уздырыла (докладчы—Н. Баян). 1939 елның башында яшь язучыларның зур бер төркеме оешмага әгъза итеп алына (Ф. Хөсни, А. Шамов, Г. Бәширов, Г. Галиев, Г. Гобәй, А. Әхмәт, А. Алиш, Ә. Исхак, Р. Ишморат, Г. Хужи, И. Гази, Г. Кутуй, Н. Дәүли, Х. Госман, М. Бубеннов, С. Хәким, Г. Хәбиб, Г. Халит, Л. Жәләй, М. Вәдүт, М. Әблиев; ел ахырында бу төркемгә Н. Исәнбәт, Х. Садри, С. Урайский, Ә. Камал һәм тагын берничә айдан—З. Солтанов, Ә. Ерикәй дә өстәлә), язучылар союзының фольклор секциясе әзерләгән "Халык ижаты" дигән жыентык басылып чыга, СССР Верховный Советы Указы белән Ш. Маннур Хезмәт Кызыл Байрагы, Т. Гыйззәт Почет Билгесе орденнары белән бүләкләнә, бер елдан соң Ш. Камалга СССРның иң зур ордены—Ленин ордены бирелә (соңрак "орденлы шагыйрь", "орденлы язучы" дигән сүзтезмә әлеге язучыларның исемнәренә озак дистә еллар синоним-тагылма булып йөриячәк). Язучылар оешмасы өчен бу елның иң мөһим вакыйгасы, мөгаен Муса Жәлилнең Язучылар идарәсенең жаваплы секретаре, ягъни житәкчесе итеп сайлануыдыр. Әдәби житәкчелекнең очраклы кешеләрдән арынуы—бу инде репрессиянең бетүгә, илдә сәяси-рухи тормышның беркадәр савыгуга таба баруын күрсәткән фал иде. Гомумән, сугыш алдындагы ике елда татар жәмәгатьчелеге өчен күңел булырлык гамәлләр кылына башлый. Татар дәүләт опера һәм балет театры ачыла (Беренче куелган тамаша Н. Жиһановның "Качкын" операсы. Ә. Фәйзи либреттосы). Татарстан хөкүмәте Тел, әдәбият һәм тарих гыйльми-тикшеренү институты төзү турында карар кабул итә. СССР халык комиссарлары Советы карамагында Сәнгать эшләре комитеты 1941 елның ахырында Мәскәүдә татар сәнгате декадасын үткәрергә планлаштыра... Югалтулар табулардан күбрәк булса да, ниндидер стимул бар!



*Татар язучыларыннан бер төркем Васильево ял йортында. Беренче рәттә сулдан уңга: Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Муса Жәлил, Әхмәт Фәйзи; Арткы рәттә: Әхмәт Исхак, Шәйхи Маннур.*

Шул чорда (яки беркадәр алданрак) язылган кайбер әсәрләрне хәтеребезгә

төшермәсәк, сүз сөрешенең мәгънәсе тулы булмас. Алар—“Тапшырылмаган хатлар” (Г. Кутуй), “Агыйдел” (М. Әмир), “Мәрҗәннәр” (К. Тинчурин), “Хуҗа Насретдин” (Н. Исәнбәт), “Флейталар” (Ә. Фәйзи)... Бу әсәрләрне язуда язучылар оешмасының тәэсире никадәр булгандыр, аны гүр иясе булган ул язучылар үзләре генә белгәннәрдер, без фәкать фараз итә генә алабыз. Хронология буенча шул елларга туры килә үзләре... 1940 елда “Совет әдәбияты” журналында “Идегәй” дастанының дөнья күрүе үзе бер вакыйга була. Бу бөек дастан әдипләр, бигрәк тә шагыйрьләр өчен бик озак еллар осталык мәктәбе булып хезмәт итәчәк әле.

Сугыш еллары... Бөек Ватан сугышы еллары. Сугыш сүзе алдындагы эпитетларга гасыр ахырында төрле кешеләрнең төрлечәрәк фикере булса да, барыбер, илдәшләрнең илбасарларга каршы сугышы иде ул. Шуңа күрә “канга—кан, үлемгә—үлем” дигән сүз—шигарь генә түгел, халык күңеленә иңдерелгән һөҗүмчән максат та иде. Менә шулай килеп чыга икән дөньяда: татар сәнгате декадасы уздырасы Мәскәү шәһәрен иң әүвәл үзен саклыйсы бар икән әле! Шул бәйрәмдә катнашырга тиешле башкала язучыларын Казан вокзалында каршылап, Казанның үзендә, яшәү өчен аннан да аулаграк Чистай, Алабуга шәһәрләренә күчереп урнаштырышасы бар икән! Үзебезнекеләргә шинель киеп Карелия, Волхов, Украин фронтларында карлы-бозлы окопларда ятасылар, атакаларга күтәрелеп ут астына керәселәр бар икән! Сөйлиләр бит: Свияжск станциясендә ике поезд очрашканнар. Казан ягына баручы Мәскәү язучылары татар язучыларыннан сорыйлар икән: «Сез кая?» «Фронтка!» «Ә сез?» «Эвакуация белән Чистайга!..»



*Бөек Ватан сугышында катнашкан язучылардан бер төркем. Сулдан уңга, беренче рәттә— Н. Арсланов, Г. Иделле, М. Садри, Р. Ишморат, Ә. Исхак, Г. Галиев, Х. Госман, С. Баттал; икенче рәттә—Ш. Шаһгали, Ә. Еники, М. Мазунов, М. Хөсәен, И. Нуруллин, А. Расих, С. Сабиров, Ә. Кәримуллин, Б. Гыйззәт; өченче рәттә— Н. Дәүли, С. Шәкүров, Ә. Маликов, К. Латыйп, М. Насыйбуллин. 1985 ел.*

Шулай итеп, татар язучыларын 37 еллар бер “чабып” ташлаган булса, икенче бер афәт—сугыш янә байтагын кырып салды. Бүтән халыклар белән чагыштырганда сан нисбәтендә язучылардан иң күп югалту татарда, диләр. Булгандыр, саның башласаң да байтакка чыга бит: М. Җәлил, Ф. Кәрим, А. Алиш, Г. Кутуй, Н. Баян, Х. Мөҗәй, М. Вәдүт, Р. Ильяс, К. Басыйров, М. Әблиев, Р. Саттар, Д. Фәтхи, Х. Кави... Әзтабар-журналист, язучы Шаһинур Мостафин язып чыкканча, Ватан сугышында 104 татар язучысы һәм журналисты (яшь һәм башлап язучыларны да кертеп) катнаша, шуларның 31е корбан була. Өчтән бере дигән сүз!

Исән булып кайтканнарның да күбесе фронт яраларыннан җәфаланып яшәде.

Фронтовикларның кайберләре—Ә. Давыдов, Ш. Мөдәррис, С. Урайскийлар һ. б. 50 яшьләренә дә житми дөнья куйдылар. Гомумән, физик яктан сау килеш теге яки бу формада фронтта булмаган татар язучысы бик аз. Мин белгәннәрдән Гариф Гобәй белән Галимжан Латыйп кына иде бугай.

Язучылар союзы эшчәнлегенә кайтыйк. Сугыш башлануның беренче көннәреннән үк Союз идарәсе утырышларында оешманың эшен хәрби шартларга яраклаштыру мәсьәләсе карала. Тукай исемендәге кабинет (соңрак Клуб дип йөртелгән зал ул елларда шулай аталган, хәзер бу залда "Мәгариф" нәшриятының техник хезмәткәрләре—компьютерчылар, корректорлар эшли) үзенә күрә бер штабка әверелә. ПВХО төркеме оештырыла, Мәскәүнең качак язучыларын үзенә сыендыра, интернационал составтагы язучылар жыелышлары уздырыла (Мәсәлән, бу залда А. Фадеев "Совет язучылары Ватан сугышында" дигән доклад ясый), оборона фондына акчалар жыйнала (Т. Гыйззәт, Ш. Камал 1000 әр сум, Г. Кутуй—650 сум акча кертә), сугыш шартларында язучының барлык ижат эшләрен яңача кору, бөтенләе белән фронт өчен хезмәткә буйсындыру һәм активлаштыру, шуларга житәкчелек итү өчен язучылар идарәсе каршында агитация-пропаганда бүлеге оештырыла (жаваплылар—Ш. Маннур, Т. Гыйззәт, Р. Ишморат, Г. Кутуй)... һәм 1942 елның 8 январенда Казандагы совет һәм чит ил язучылары катнашында Тукай клубында М. Жәлилне фронтка озату була (Мәңгелек Бөеклеккә озату! Жаны һәм бармаклары Ходай тарафыннан музыка өчен яратылган икенче бөек талантны—Фәрит Яруллинны, белмим, ничек озатканнардыр?..).



*Фронтовик язучылар: Муса Жәлил, Фатих Кәрим, Абдулла Алиш, Гадел Кутуй.*

Татарстанга Мәскәүдән эшелонлап дигәндәй (ике йөздән артык язучы үзләренең гаиләләре белән килә безгә) олуг-олуг язучылар килеп төшкәч, Казаннан тыш, Чистай да үзенчә бер әдәби мәркәзгә әйләнә. Шулай булмый ни!—кемнәр генә юк анда! К. Федин, Н. Асеев, М. Исаковский, Л. Леонов, Б. Пастернак, Л. Ошанин, К. Тренев, Д. Бедный, А. Сурков, В. Инбер, А. Тарковский, В. Борков... Тагын күп дистә исемнәр санарга мөмкин. Алар турында уйлаганда сугыш чорында Чистайда яшәгән Л. Леоновның мәгълүм сүзләре искә төшкәли. «Если бы только и было суждено в жизни телом остановить пулю, летящую в сторону Родины, то и для этого стоило рождаться на свет».

1941 елның көзенә таба Чистайга Мәскәү язучыларының байтак гаиләләре дә күчеп килә. Аларның күбесе биредә ике еллап яшиләр. Гаиләләре янына фронттан А. Твардовский, А. Сурков, С. Щипачев, И. Сельвинский һәм башка күренекле шагыйрьләр кыска сроклы командировкаларга кайтып йөриләр. Чистайда СССР Язучылар союзы житәкчесе А. Фадеев та берничә мәртәбә була. Чистайда яшәүче язучылар, мораль яктан булса да, фронтка ярдәм итүдә үзләренчә байтак эш башкаралар. Әдәби кичәләр, коллективларда, мәктәпләрдә очрашулар, матбугатта һәм радио аша чыгышлар... Ижат һәм оештыру эшләре дә тукталып тормый: Л. Леоновның "Нашествие" пьесасы буенча премьера булып уза, Б. Пастернак Шекспер әсәрләрен тәржемә итә, Л. Ошанин СССР Язучылар союзына тәкъдим ителә... Эвакуациядәге язучылар тормышы турында Г. Мухановның 1987 елда Казанда чыккан "Чистопольские страницы" дигән китабында тәфсилле язылган. Чистайдагы Б. Пастернак музеенда да бу хакта шактый материал бар. Эвакуацияга килгән

язучылар бер Чистайда гына яшәмәгәннәр. Әйтик, сугыш алдыннан гына "Спи, младенец! Не то злому псу—татарину отдам!" дигән юллар язган шагыйрә М. Цветаеваның гомере Татарстан җирендә—Алабугада очлана... Дөнья бу!

Ил өстенә килгән уртак афәт, һичшиксез, кешеләрне берләштергән, туганлаштырган—максат бер, күңел ачык булгач, тар җирне дә киң итеп качакларны сыендырган татар җире. Кайбер Мәскәү язучылары татар язучысы гаиләләрендә дә сыену тапкан. Максат уртак—дошманны җиңү! Сугыш башында ук "Совет әдәбияты" (хәзерге "Казан утлары") "Бөтен көч—дошманны җиңүгә" исемле редакцион мәкалә бастыра. Анда мондый юллар бар: "Йөз миллионнарча кешеләрнең ирке, бәхетле тормышы, якты киләчәк һәм намусы өчен бара торган бу бөек көрәштә культура фронтының бөтен армиясе ярдәм булып фашизмга каршы аяусыз сугышка күтәрелде. Туры сүз массаларда дошманга каршы ачы нәфрәт, каты ачу тудырсын, миллионнарга үзенең туган иле каршындагы мөкатдәс бурычын төшендереп бирсен... Шагыйрьләрнең шигыре сугышчыларны геройлыкка рухландыра торган көчле чаң булып яңгырасын!.." Сүз уңаеннан билгеләп узыйк: сугыш чорында шигырь, чаң булып кына яңгырамады, меңләгән укучылары аша дошман йөрәгенә ук булып кадалды, бәгырен ут булып өтте... Дистәләгән шагыйрьләребез иҗаты, беренче чиратта М. Җәлил һәм Ф. Кәрим иҗаты шуны дәлилли.

Шул еллар хроникасына янә күз салыйк. Нинди генә шартлар булмасын, фронттагы, тылдагы тормыш, барыбер дәвам итә, үлем-хәсрәт тә, кайгы-яшь тә кешеләрнең яшәүгә омтылышын туктата алмый. Язучылар оешмасында да эш-хәрәкәт бара. Язучылар тарафыннан (К. Нәҗми, Г. Кашшаф, Х. Ярми) күмәкләшеп "Татар халкының фронтовик татарларга сәлам хат"ы языла. Соңрак миллионнан артык кеше кул куйган бу хат "Правда", "Известия" газеталарында игълан ителә (март, 1943), аннан соң республика һәм фронт газеталарында басылып чыга. Классикларның, бигрәк тә рус язучыларының төрле уңай белән (М. Лермонтовның үлүенә 100 ел, М. Горькийның тууына 75 ел. И. Крыловның үлүенә 100 ел, А. Грибоедовның тууына 150 ел һ. б.) юбилейлары уздырыла,апрель айларында Г. Тукайны искә алу кичәләре үтә. ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитетында "Татарстан Язучылар союзы идарәсенең эше" турында карар кабул ителә. Шул чор хроникасыннан искә алырлык тагын бер мөһим вакыйга: 1943 елның октябрь аенда СССР Язучылар союзы Президиумында татар әдәбиятының Бөек Ватан сугышы елларындагы торышы махсус тикшерелә. А. Фадеев рәислегендә үткән бу җыелышта Казаннан—Т. Гыйззәт, К. Нәҗми, Н. Исәнбәт, Г. Кашшаф; шуларга өстәп, фронттан чакырып кайтарылган Г. Кутуй, Ә. Ерикәй, М. Садри, Г. Галиев катнаша. Шул еллардагы татар әдәбияты турында Г. Кашшаф доклад ясый (сугыш елларында Г. Кашшаф Казан әдәби хәрәкәтендә иң үзәк фигураларның берсе була. М. Җәлилнең васыять рәвешендә язган язмасында аның исеме беренчеләрдән булып аталуы тиккә түгел!). Татар әдипләренә М. Горький кебек туганнарча карауы А. Фадеев язучылар делегациясен ВКП(б) Үзәк комитеты пропаганда һәм агитация бүлегенең җаваплы хезмәткәрләре белән дә очраштыра. "Авыр сугыш елларында татар телендәге әдәби журналның ("Совет әдәбияты") саклануын партия Үзәк Комитетында хупладылар гына түгел, бәлки югары бәяләделәр: "Бу—сезнең каһарманлык!" Партия Үзәк комитеты безгә тиражны өч тапкырдан күбрәк арттырырга (ул елларда журналның тиражы уртача 4 мең ) һәм 10 мең данәгә кадәр җиткерергә рөхсәт итте һәм кәгазь ягыннан ярдәм күрсәтте" дип язды соңрак журналның шул еллардагы редакторы Гази Кашшаф.



*Татар шагыйрьләре Европада. Мөхәммәт Садри (сулда) һәм Гали Хуҗи. Вена. 1945 ел.*

Фронтта да байтак язучыларыбыз, каләмне штыкка тиңләп, алгы сызыктагы сугыш операцияләрендә катнашу белән бергә, фронт газеталарын чыгаралар (ул газеталарның тарихы болай: 1942 елның башыннан Германия идеологлары инициативасы белән СССР халыкларының күп телләрендә газеталар чыгарыла башлый, аларны совет сугышчылары арасында таратырга тырышалар. Мәсәлән, татар телендә "Идел-Урал", "Хәбәрче" исемле газеталар, "Татар әдәбияты" дигән журнал чыгарыла. Шуңа каршы җавап итеп, ВКП(б)ның Үзәк Комитеты, ашыгыч рәвештә дигәндәй, "Матбугат өлкәсендә партиянең ин әһәмиятле бурычлары" дигән карар кабул итә һәм тиздән милли телләрдә газеталар чыга башлый. 1942 елның июленнән башлап, төрле фронтларда татарча уналты газета чыга. "Ватан өчен", "Алга, дошман өстенә!", "Сталин байрагы", "Совет сугышчысы" h. б.). Үз вакытында аларда Г. Кутуй, А. Шамов, М. Максуд, Ә. Ерикәй, Р. Ишморат, Г. Әпсәләмов, И. Гази, А. Әхмәт, Х. Госман, Ә Исхак, Ш. Маннур, Г. Насрый, Ә. Фәйзи, Ш. Мөдәррис, Б. Рәхмәт, Г. Галиев, һәм башка язучылар эшләгәннәр. Шулай ук, Г. Бәширов, М. Әмир, Ф. Хөсни, Г. Иделле, Х. Хәйри һәм башкалар, озак вакытлы командировкаларга барып, бу газеталарда эшләп-эшләп алалар.

Сугыш чорының бер төере булып, зыялылар, шул исәптән язучылар аңына сенеп калган тагын бер документ турында әйтми китеп булмый. Ул—1944 елның 9 августында ВКП(б) Үзәк Комитетында кабул ителгән "Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеологик эшләрнең торышы һәм аларны яхшырту чаралары турында" дигән карар. 1944 ел... Сугышның Советлар Союзы файдасына бетәчәге тәмам ачыкланган ел. Бөтен совет халкын, төрле милләт вәкилләрен рухландырып, уртак җиңүгә бер йодрык булып барасы иде дә... юк! —тагын репрессияләр—тулы бер халыкларны көчләп үз илләреннән куалар: балкарлар, калмыклар, Кырым татарлары, чеченнар, греклар, карачайлар... Бу Карар—Идел буе татарларына да үзенчә бер мәгънәле "күз агы белән карау" иде. Карар, иң беренче чиратта, тарихчыларга, язучыларга юнәлтелгән, "тарихыгызны ныклап өйрәнеп, аннан каһарманнар эзләп маташмагыз! Тарихны кушылганча гына аңлагыз һәм аңлатыгыз!" дигән мәгънә ята иде бу документта. Карарның шаукымы шактый еллар барды. 60 еллар башында без студентларга әдәбият белгечләре лекцияләрендә, сабак-нәсихәт рәвешендә бу карардан цитаталарны бик мул китерәләр иде әле...

Гаделлек өчен 1944 елда булган позитив ике вакыйганы да искә алып үтик: шул ук август аенда Татарстанның крайны өйрәнү музее каршында әдәбият музее оештыру, Ш. Камалның квартира-музеен булдыру турында РСФСР Халык Комиссарлары Советы карары, һәм икенчесе—Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылу. (Бу бүлеккә быел 60 ел. Татар әдәбияты-мәдәнияты тарихында бүлекнең әһәмияте әйтеп бетергесез. Бүгенге әдәбиятны тудыручылар, нигездә, университеттан, шушы бүлектән үсеп чыккан язучылар).

Шул ук айда Берлинның Плетцензее төрмәсендә Муса Җәлилнен, Абдулла Алишның һәм тагын тугыз батырның башлары киселә. Берничә атнадан Дахауда Хәйретдин Мөҗәй мичтә яндырыла... Болары да сугыш чорының тетрәндергеч фактлары...

Менә без булдыра алган кадәр әдәби хәрәкәтнең, шул исәптән, Язучылар оешмасы эшчәнлегенең дә бик тә катлаулы чорын үзебезчә күзаллап, күзәтеп чыктык. Шәхес культы һәм сугыш елларын, күп дистә миллионнарның фаҗигасен эченә алган бу чор анализ өчен ифрат кыен чор. Кайбер нәтиҗәләрне, киләчәк хакына уйланулар рәвешендә, укучылар үзләре ясар. Күзәтү барышында аерым вакыйгалар яки факт-документлар нисбәтендә кайбер фикерләремне әйткәләдем. Бу чор әдәби хәрәкәтенә нәтиҗә ясап берничә штрих кына өсти алам. Зур күтәренкелек, зур планнар белән төзелгән Язучылар союзы, яшәвенең беренче елларында ук бик нык сирәкләндерелсә, хәлсезләндерелсә дә, сугыш елларында авыр югалтулар кичерсә дә, барыбер, оешма булып сакланып кала алды, иҗат көчләрен ниндидер бер мобилизацияләүче штаб ролен үтәде (бу очракта Язучылар союзының башында торган берничә шәхеснең исемнәрен атап үтү дөрес булыр: К. Нәҗми (1934-37), М. Җәлил (1939-41), Т. Гыйззәт (1942-44)...) Автономик кысаларда, житмәсә экстремаль сугыш чорында, рухи терәк һәм бергәлекне тояр өчен генә булса да, татар язучыларының үз оешмалары, үз үзәкләре булуы уңай бәяләнергә хаклы.

Бу чорда "әдәбиятның әнкәсе" саналган поэзиянең көче, халыкчанлыгы,

яшәүчәнлеге тагын бер мәртәбә расланды. Мона дәлил итеп М. Җәлилнең "Моабит дәфтәре", Ф. Кәримнең сугыш чоры әсәрләрен (әйтик, "Кыңгыраулы яшел гармун", "Идел егете") искә алу да җитә. Бүтән жанрларда, бәлки, ул кадәр үк казанышлар булмагандыр (табигый, сугыш чорында—фронттамы, тылдамы—киң полотналы зур романнарның тууы икеле), шулай да, кайбер әсәрләр язылып калынган. Әйтик, "Миңлекамал" драмасы (М. Әмир), "Йөзек кашы" (Ф. Хөсни)... Сугыш елларында, ул чакта әле яшь, ә соңрак әдәбиятта зур урын тотачак байтак язучылар гыйбрәтле тормыш мәктәбе генә түгел, иҗади үсү мәктәбен дә үттеләр. Ә. Еники, Г. Әпсәләмов, Ә. Фәйзи, А. Шамов, А. Расих, И. Гази, Ш. Мөдәррис, Ә. Давыдов һәм башкалар.

## II

Сугыштан соңгы елларга күчик. Алдан әйтелгән бүленеш буенча, бу чор 1945-1960 елларны (60 еллар башын) үз эченә ала. Алдагы дистә еллар белән чагыштырганда, аңлаешлырак, тотрыклырак чор! Сугыш беткән, ачлык-ялангачлык хәттин ашса да (дистәләгән төрдәге салымнар, мәҗбүри заемнар...), кешеләр күңеленең өметле чагы: җимереклекне торгызабыз, илдә социализм—гаделле җәмгыять төзибез, киләчәктә, һичшиксез, яхшы яшәячәкбез! Һәрхәлдә, күпчелек шулай уйлаган. Әмма шунысы бар: бу чор Сталин хакимиятенең иң "кикрикле" чагы, "генераллисимус доктринасы"ның халыкара дәрәҗәдә санлаштыра торган чагы... Әлбәттә, реаль тормыш шартлары, куелган максат-шигарьнең ясалма-декоратив булуы, кемнәрдәдер протестлы тойгылар да уяткан. Юкса, 50 еллар башында яшь-яшь студентлар, башлап язучы талантлы егетләр—А. Гыйләҗев, Г. Тавлин, М. Рафиков, А. Тимергалин һ. б. төрмә-зинданнарга юлыгыр идеме?

Язучылар союзы эшчәнлегенең төп этапларын, гамәл-нәтиҗәләрен, максат-юлларын билгеләүче төп маяк-ориентир, ул—съездлар, соңгы дәвердәгечәрәк әйтсәк, корылтайлар. Чөнки съезд язучылар оешмасының идарә органнарын сайларга вәкаләтле иң зур җыен. Съездлар аша әдәби хәрәкәт дисбесенең төп төеннәрен (бу очракта, тенденцияләрен) тоеп, чамалап була. Әйе, алда тәфсилләп әйтелгәнчә, беренче оештыру съезды, Казанда да, Мәскәүдә дә 1934 елны узды. Шул ук елны СССР Язучылар съездында кабул ителгән Устав нигезендә язучылар съездлары өч елдан өч елга уздырылырга тиеш диелгән. Ә ничек килеп чыкты? СССР язучыларының икенче съезды нәкъ егерме елдан соң—1954 елда гына җыелды! Ирексездән, русларның "закон как дышло..." дип башлана торган әйтеме искә төшә. Егерме ел бит! Сугыштан соң да ун елга якын вакыт үтә... Димәк, бу оешма, табигый ихтыяждан бигрәк, хакимиятнең ихтыяр көче белән идарә ителә торган оешма булып чыга.



*"Әдәбиятлар дуслыгы—халыклар дуслыгы" шигаренең рәсми девиз булып яңгыраган чорлары. Рәсемдә: сулдан уңга—латыш Вилис Лацис, татар Кави Нәҗми, кыргыз Аалы Токомбаев, рус Александр Фадеев. Үткән гасырның 50 еллары.*

Шулай да Татарстан язучылары 1950 елда үзләренең II съездын үткәрәләр. (СССР Язучылар союзының II съездыннан дүрт ел элек!) Үзәк кушуы беләнме, әллә җирле инициатива өстенлек иткәнме? Мөгаен, соңгысыдыр. 1950 елның язында КПССның Татарстан өлкә комитеты "Татарстан совет язучылары союзының эше турында" дигән махсус карар кабул итә. Бу инде үзенә күрә съезд алды прелюдиясе дигән сүз. Конкрет съездлар эшчәнлегенә кадәр, сугыштан соңгы унбиш эл эчендәге кайбер факт, вакыйгалар белән танышып үтик. Тукайның 60 еллыгы зурлап билгеләнә (Мәскәүдә Союзлар йортының Колонналы залында

тантаналы кичә үтә; Казан университеты һәм педагогия институты студентлары өчен Г. Тукай исемендәге стипендияләр билгеләнә; СССР Фәннәр Академиясендә шагыйрьгә багышланган фәнни сессия уздырыла һ. б.). Татарстан мәгариф комиссариаты һәм Язучылар союзы балалар өчен татар телендә язылган иң яхшы әсәрләргә конкурс игълан итә. Шагыйрь Ә. Ерикәй СССР Верховный Советына (1946), К. Нәҗми Татарстан АССР Верховный Советына депутатлар итеп сайлана. Чистай шәһәре музеенда "Язучылар Чистайда" дигән яңа бүлек оештырыла. Рус телендә "Литературный Татарстан" дигән альманах чыга (1947-1958). 1951 елда К. Нәҗминең "Язгы җилләр", Г. Бәшировнең "Намус" романнары Сталин (соңрак аны Дәүләт премиясе дип тә йөрттеләр) премиясе белән бүләкләнә. 1953 елда М. Җәлил өстеннән "кара болытлар" алып ташлана, берничә елдан аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә, "Моабит дәфтәре" Ленин премиясенә лаек була. Сугыш елларында тукталып калган "Яшь сталинчы" ("Татарстан яшьләре") газетасы, "Чаян", "Пионер" ("Ялкын") журналлары кабат басыла башлый. Хәзерге "Идел" журналының яралгысы саналырга тиеш "Үсү юлы" дигән альманах чыга (1950-1958). 1957-58 еллар әдәби-мәдәни вакыйгаларга бигрәк тә бай. 1957 елның 24 май-4 июнь көннәрендә Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгать декадасы гөрләп үтә (алда әйтелгәнчә, ул декада 1941 елның ахырына планлаштырыла, сугыш башлану сәбәпле булмый кала). 1958 елда "әдәбият, музыка һәм сынлы сәнгать өлкәсендә идея эчтәлеге һәм художество дәрәҗәсе ягыннан аеруча әһәмиятле әсәрләр өчен һәм сәхнә әсәрләрен иң яхшы башкару өчен" Г. Тукай исемендәге премияләр булдырыла. Шул ук елның 9 августында Казан үзәгендә Тукайга һәйкәл торгызыла (соңрак бу урын Тукай мәйданы дип йөртеләчәк). Бу еллар елъязмасының тагын бер кадерле сәхифәсе—шәхес культы корбаннары аклана. Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, М. Гәләү, Г. Газиз, Ш. Усманов, Ф. Бурнаш, Г. Нигъмәти һәм башкаларның әсәрләре кабат басыла башлый, зиндан-сөргеннәрдән исән калган Х. Туфан, И. Салахов, С. Рафиков кебекләр әдәби сафка кайта... 50 нче еллар ахырында, соңрак халык язучылары, халык шагыйрьләре булачак, әле ул вакытта өметле яшь язучылар саналган Г. Ахунов, И. Юзеев, Ш. Галиев, Г. Афзал, Х. Камаллар әдәбиятта яңа буразналар сала. 1957 елны беренче мәртәбә Татарстан язучылары турында белешмәлек—биобиблиографик китап чыга (анда 126 язучы турында мәгълүмат бирелгән. Соңрак мондый характердагы китаплар 1970 һәм 1984 елларда дөнья күрде). Медицина институты студенты (!) Шәриф Хөсәеновнең Камал исемендәге академия театрында "Профессор кияве" исемле спектакле куела...



*Шәхес культы елларында төрмә-сөргеннәрне кичкән татар әдипләре: сулдан уңга—язучы Сөббух Рәфыйков, шагыйрь Хәсән Туфан, язучы Ибраһим Салахов. Озак еллар үткәч янә Казанда очрашу. 1956 ел.*

Әйе, тыныч тормышка хас вакыйгалар хроникасы. Әйтергә кирәк, чагыштырмача матур хроника! Язучыларның төп жыены булган съездлар үткәрү дә билгеле бер тәртипкә салына башлый.

**Татарстан язучыларының II съезды 1950 елның 13-15 июнь көннәрендә үтә.** Съездда язучылардан тыш, республика җитәкчеләре, СССР Язучылар союзы һәм үзәк нәшрият вәкилләре, фән эшлеклеләре, журналистлар, укытучылар, әдәби иҗат белән шөгыльләнүче студент яшьләр катнаша. Татарстан совет язучылары союзы

идарәсенең эше турында хисап докладын Гази Кашшаф ясый. Ревизия комиссиясе отчеты белән Гариф Гобәй чыга. Фикер алышуларда 29 кеше катнаша. Алар арасында—Г. Әпсәләмов, К. Нәҗми, Н. Исәнбәт, Г. Гулиа (Мәскәү), С. Баттал, Ш. Мөдәррис, С. Кирьянов (Мәскәү), З. Мансур, М. Хөсәен, М. Максуд, И. Нуруллин, Ә. Давыдов, М. Елизарова, Х. Рәхмәтуллин (ВКП(б) өлкә комитеты секретаре), Г. Насрый, А. Гомәр һ. б.


*Төркмәнстанның халык язучысы Берды Кербабаев Татарстан җирендә. Сулдан уңга—Хатыйп Госман, Мирсәй Әмир, Әмирхан Еники, Берды Кербабаев, Гомәр Бәширов. Үткән гасырның 50 еллар ахыры.*

Съезд Татарстан совет язучыларының эшен канәгатьләнерлек дип тапмый һәм киләчәктә эшне яхшыртуга юнәлтелгән карарлар кабул итә. Съездда яшерен тавыш бирү тәртибендә Татарстан Язучылары союзы идарәсенә түбәндәге язучылар сайлана:

Гариф Гобәй (председатель), Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир, Гали Халит, Риза Ишморат, Константин Лебедев, Әхмәт Исхак, Нәкый Исәнбәт, Ибраһим Гази, Салих Вәлиди (җаваплы секретарь).

“Совет әдәбияты” журналының җаваплы редакторы итеп Гази Кашшаф раслана.

Шулай итеп, съезд язучылар союзы идарәсе эше канәгатьләнерлек дип табылмый. Совет дәверендәге идарә механизмында болай бәяләнү сирәк очрак. Язучылар союзы эшенә, съездан бигрәк, КПСС өлкә комитетының бәясе бу. Съездда элеге бәя кабатлана, дөресрәге кабатлаттырыла гына. ВКП(б) ҮКның 1944 елдагы алда әйтелгән карары, шул ук ВКП(б) ҮКның “Звезда” һәм “Ленинград” журналларын нык тәнкыйть иткән еллар бит (1946 елның 14 августында чыккан карар). Өстән директива бар! Каләм әһелләрен кысада тотар өчен, урыннарда да, бу очракта Татарстанда нигә аналогик карар чыгармаска? Алда телгә алынган ВКП(б) Өлкә комитетының “Татарстан совет язучылары союзы эше турында” дигән карар тулысы белән тәнкыйтькә корылган (“зур кимчелекләр бар”, “тиешенчә җитәкчелек итми”, “өйрәнүдән читтә торалар”, “бер-берсен тәнкыйтьләмиләр”, “үсеш юлларын дөрес чагылдырмый”, “ярдәм күрсәтмиләр”, “буржуаз язучының чын йөзен ачмыйлар”, “зур хаталар җибәрелә”, “тирән анализ ясалмый”, “тикшерүләр аз үткәрелә”, “канәгатьләнерлек түгел” һ. б.). Арада дөресләре дә бар, әлбәттә. Ә язучыга шәхес культы, сугыш елларында киң полотналы, хакыйкатькә хилафлык китерми торган әсәрләр язарга мөмкинлек булдымы соң? Бу чор өчен доклад ясаган Г. Кашшафның хәлен аңлап була: югары оешмаларга да ярарга кирәк, каләмдәшләр иҗатын да булдыра алган кадәр дөрес бәяләргә кирәк! Бу съездда 1945-50 елларда идарә рәисе булып торган Ә. Ерикәй нык тәнкыйтьләнә. “Идарә (Ә.Ерикәй А. Шамов, М. Әмир, Б. Зернит, Х. Хәйри, Г. Кашшаф, Т. Гыйззәт), гомумән, язучыларның иҗат эшенә тиешенчә җитәкчелек итмәде”, дип табыла.

**Тагын дүрт ел үткәч, 1954 елда янә бер съезд—Татарстан язучыларының III съезды үтә.** Ике съезд арасында Союз эшчәнлеге шактый активлаша. Иҗат секцияләренең эше җанлана (проза секциясе җитәкчесе—Г. Әпсәләмов, поэзия секциясенеке—С. Хәким, драматургия—Р. Ишморат, тәнкыйть секциясенеке—Г. Халит), яшь язучыларның республика конференцияләре эшли, иң яхшы яңа

әсәрләргә ябык конкурслар игълан ителә, җыелышларда конкрет әсәрләр тикшерү белән бергә, теоретик мәсьәләләр турында дискуссияләр дә оештырыла.

Съезд 24-26 июнь көннәрендә Казанда үтә. Съездда төп ике доклад тыңлана. "Татар совет әдәбиятының торышы һәм бурычлары" (Гомәр Бәширов), "Татар совет әдәби тәнкыйте һәм бурычлары" (Гали Халит). Көн тәртибенең калган мәсьәләләре нигездә хисап һәм оештыру эшләренә бәйле: ревизия комиссиясе эшен тыңлау, идарә һәм II Бөтенсоюз съездына делегатлар сайлау (Шунысы игътибарга лаек: моннан 50 еллар элек тә әдәби тәнкыйть мәсьәләсе актуаль һәм әдәби җәмәгатьчелекнең күз уңында булган (Ирексездән Тукайның "тәнкыйть кирәкле шәйдер" дигән сүзләре хәтергә килә). Докладлар буенча фикер алышуда С. Хәким, М. Дудин (Ленинград) Г. Әпсәләмов, М. Әмир, Ю. Лебединский (Мәскәү), Ф. Хөсни, К. Нәҗми, И. Гази, Г. Мөсрепов (Казакъстан), М. Максуд, Х. Хәйри, Ә. Давыдов һ. б. (барлыгы 28 кеше) катнаша. Яшерен тавыш бирү тәртибендә Татарстан Язучылар союзы идарәсенә түбәндәге язучылар сайлана:

Гомәр Бәширов (председатель), Сибгат Хәким, Гази Кашшаф, Хәсән Хәйри, Фатих Хөсни, Таҗи Гыйззәт, Әнвәр Давыдов (җаваплы секретарь), Габдрахман Әпсәләмов, Бруно Зернит.

Игътибар иткәнсездер: хисап докладын алдагы съездда рәис булып сайланган Г. Гобәй түгел, ә 1953 елда аны алыштырган Г. Бәширов ясый. Г. Гобәй шул чордан идарә даирәсеннән китә, фәкать профессионал иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Үз вакытында "Маякчы кызы", "Замана балалары", "Без үскәндә" кебек әсәрләре белән танылган язучы, соңрак "Коръән серләре" исемле әсәр язып, дин тотучыларның бәддогасына юлыкты. Киң катлам укучылар арасында каршылыклы фикерләр тудырган бу әсәр заман идеологиясенә ярарга тырышып иҗат итүнең бер гыйбрәтле сабагы булып тора.



*Бер төркем татар язучылары Мәскәүдә үтәчәк татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына юлга чыгар алдыннан Казан тимер юл вокзалында. Сулдан уңга: Габдрахман Әпсәләмов, Афзал Шамов, Гали Халит, Нур Гыйззәтуллин. 1957 ел.*

Бу съездда 1954 елның декабрь аенда үтәчәк Совет язучыларының II Бөтенсоюз съездына делегатлар да сайлана. Унбер кешелек делегация арасыннан Татарстан исеменнән чыгыш ясау янәдән К. Нәҗмигә йөкләнә. I съездда да татар әдәбияты турындагы докладны ул ясаган икәнне искә төшерсәк, нинди генә катлаулы чорда да К. Нәҗминең үз биеклеген саклап калуын, ныклыгын таныпга туры килә.

**Чираттагы IV съезд 1958 елда уза. 16 июнь көнне Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында ачыла һәм дүрт көн дәвам итеп, 19 июньдә тәмамлана.** Съездны Нәкый Исәнбәт (стенографик язмада ул күренекле карт

язучыбыз дип теркәлгән. Аңа ул вакытта 59 яшь) ача. Съездда Татарстан Язучылар союзы идарәсенең эше турында Гомәр Бәширов, татар поэзиясенең торышы турында Сибгат Хәким, проза әсәрләре турында Хәсән Хәйри, драматургия турында Гази Кашшаф, Татарстанда яшәүче рус язучылары турында Геннадий Паушкин докладлар белән чыгалар. Татар язучыларының съездын котлап килгән кунаклар В. Кожевников (Мәскәү), Б. Кербабаев (Төрекмәнстан), С. Смирнов (Мәскәү), С. Кудаш (Башкортстан), Ә. Мохтар (Үзбәкстан), Ж. Муллагалиев (Казакъстан) һ. б. чыгыш ясый. Докладлар буенча фикер алышуларда Ф. Хөсни, Н. Дәүли, Х. Госман, И. Пехтелев, С. Баттал, Ә. Ерикәй, Н. Фәттах, М. Максуд, Г. Ахунов, Х. Якупов, Ж. Фәйзи, Ш. Хөсәенов һ. б. катнаша. 19 июньдә Татарстан язучыларының IV съезды яңа идарә, ревизия комиссиясе һәм РСФСР язучылар съездына делегатлар сайлый. Идарә составына түбәндәге язучылар кергән: Афзал Шамов (председатель), Мирсәй Әмир, Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов, Фатих Хөсни, Ләбибә Ихсанова, Зәки Нури (җаваплы секретарь), Гази Кашшаф, Геннадий Паушкин, Гариф Ахунов, Абдулла Гомәр.



*Гариф Гобәй, Абдулла Әхмәт, Гомәр Бәширов укучылар арасында. 50 еллар ахыры.*

Шул ук көнне яңа сайланган идарәнең беренче утырышы була, "Совет әдәбияты" журналының җаваплы редакторы итеп Абдулла Гомәр раслана.

Хроникаль рәвештә съездлар турында сөйли киткәч, бу урында янә бер җыен—РСФСР Язучыларының I нче оештыру съезды турында аерым әйтеп үтү кирәк. Моңарчы әле үзәкнең бер югары җыены—СССР Язучылар съезды гына бар иде. 1958 елдан соң ул ике Үзәклегә әйләнде: русның атаклы уенчыгы "матрешка" принцибы барлыкка килде. СССР оешмасы, РСФСР оешмасы, ТАССР оешмасы. Кыскасы, күкәй эчләрендә күкәй... Бер караганда Россиянең үз оешмасы булу кирәк тә булгандыр. Бу гамәл белән үзәктәге рус язучылары мәнфәгатен кайгыртуда яңа мөмкинлекләр ачылды, шулай ук, дистәләгән аз санлы халыкларның әле яңа формалашып килгән профессиональ әдәбиятларын аякка бастыруда реаль адымнар ясалды. Әйтик, Төньяк Себер (эвенк, чукча һ. б.) яки Кавказ (карачай, авар, ногай һ. б.) халыкларының профессиональ язучылары барлыкка килде, җирле милли колорит белән сугарылган кызыклы әсәрләр язылды.

Россия язучылар оешмасы төзелү мең еллык тарихы, ике гасырдан артык басма китап традицияләре булган татар әдәбиятына ни бирде соң? Уңай җавап бирергә кыенсынам. Чынлыкта, без Зур союздан (СССР Союзыннан) Кече союзга (РСФСР) күчтек. Кечерделәр. Безнең рәсми статус—автономия, союздаш республикалар рәтендә тормый булып чыкты. Гәрчә зур Союз белән бәйләнешләр өзелмәсә дә (кайбер абруйлы язучыларыбыз СССР язучылар дәрәҗәсендәге чараларда катнашып килде, хәтта югары органнарга да сайланды), һәммәбез СССР Язучылар союзы әгъзасы дигән таныклык йөртсәк тә, без инде рәсми рәвештә турыдан-туры РСФСР язучылар оешмасына беркетелдек. СССР язучылар съездларына РСФСРдан делегатлар булып бардык. Зур съездларда безнең язучыларыбызның тавышы тоныграк, әсәрләребез турында сүзләр сирәгрәк ишетелә башлады. 1934 елдагыча язучыларның илкүләм җыенында татар әдәбияты турында махсус докладлар тыңлау, тәфсилле чыгышлар ясау татлы истәлек булып калды. Зур съездлардагы төп

докладларда татар әдәбияты—чуваш, башкорт, якут, бурят кебек әдәбиятлар белән бер яссылыкта телгә алына башланды.

РСФСРның бу беренче съездына Татарстаннан 11 кеше делегат булып бара (Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, Г. Гобәй, Ә. Еники, Т. Журавлев, Н. Исәнбәт, Л. Ихсанова, Г. Кашшаф, И. Гази, З. Нури, А. Шамов. Бу төркемнән бүгенгә бердәнбер исән кеше—Ләбибә апа Ихсанова. Хәзер аңа 81 яшь, ул чакта аңа 35 булган). Бу съездда Татарстан вәкилләре сыйфатында ике язучы чыгыш ясаган—Ф. Хөсни, А. Шамов. Ф. Хөсни чыгышы (стенографик язма буенча әйтүем) укыр өчен әле дә кызык, фикере искермәгән. А. Шамов Язучылар союзы рәисе сыйфатында чыгыш ясый, түрәләргә хас пафос, реверанс, рәсмилек... Шулай да, чыгышта заманы өчен бик тә мөһим мәсьәлә—яшь язучылар өчен журнал кирәклеге мәсьәләсен күтәреп чыга (ә мәсьәлә утыз еллап гомер үткәч, партия диктаты йомшап, демократик үзгәрешләр булгач кына—1989 елда хәл ителде. Мәскәү йогынтысыннан тыш, республика җитәкчелеге "Идел" журналын чыгаруны үзе хәл итте).



*Язучыларның иҗат һәм ял йортлары урнашкан «Аккош күле»ндә 60 нчы елларда яшәгән язучылардан бер төркем. Сулдан уңга: Фатих Хөсни, Риза Ишморат, Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Нәби Дәүли һәм Зәки Нури (улы белән). 70 еллар.*

Татарстан язучыларының 1958 елда үткән IV нче съезды да, шулай ук РСФСР язучыларының I оештыру съезды да, элгәрге җирле һәм бөтенсоюз съездларыннан үзләренең рухлары белән шактый ук аерылалар иде инде. "Алга! Коммунизмга!" кебек шапырынулы шигарьләр күп булса да ("член СП СССР обязан всей своей творческой и общественной деятельностью активно участвовать в строительстве коммунизма"), шәхес культы елларына хас шомлылык, куркынулык, "урра, сталин!"лык юк иде. Җәмгыятьтә, эмбриологик хәлдә булса да, демократик чалымнар барлыкка килде. Партиянең ике ел элек (1956) үткән XX съездының нәтиҗәләре, "Хрущев жепшеклеге" рухи тормышта сизелә иде инде... Әмма... СССРның "Тимер капкасы" әле ачылмаган диярлек (чит илләргә бик сирәк язучы чыга!). Сәясәттә ике идеология (берсе, әлбәттә, буржуаз идеология) бугазлаша. Кариб кризисына да ерак калмый... Рәсми иҗади оешмалар Пастернак һәм аның ише "декадент интеллигентлар"ның тетмәсен тетә...

Хуш, без үзебезнең хәлләргә кайтыйк. Үзебезнең җирлектә, үзебезнең әдәби хәрәкәт нисбәтендә сугыштан соңгы унбиш елга (шартлы рәвештә үзебез бүлгән классификация буенча) беркадәр гомумкүзәтү ясаганнан соң, кайбер йомгак-нәтиҗәләргә дә килик.

Әйе, үзенчә авыр чор бу! Бигрәк тә сугыштан соңгы еллар... Әмма халыкның рухы сынмаган киләчәккә ышанычы ныгыган чор. Җиңү, шиксез, ышанычны ныгыткан. Ә уйласаң, ач-ялангач чор бит, авыл халкы "таяк"ка эшләгән чор, чабаталы чор, черек (туңган) бәрәңге чоры (Соңрак бу еллар турында Н. Фәттахның "Артта калган юллар", А. Гыйләҗевнең "Язгы кәрваннар", М. Мәһдиевнең "Без—кырык беренче ел балалары" кебек әсәрләрендә ачык язылачак)... Әмма—китаплы чор! Шул чорда ачлы-туклы яшәп, тырышып белем алган, китаптан аерылмаган

буын XX гасыр ахырына кадәр дөньяның тоткасы булып тора алды да.

Алдарак бу чордагы (1945-60 еллар) мәдәни-әдәби хроникадан вакыйга саналырлык кайбер фактларны санап узган идем инде. Шуларга өстәп әйтергә була: "Татар поэзиясе антологиясе" чыга (1956), дөнья һәм рус әдәбияты классикасыннан йөзләрчә әсәрләр татар теленә тәрҗемә ителә (татар авылларында берничә буын, шул исәптән безнең буын да, шул китапларны укып үсте дә инде! Сүз уңаеннан әйтеп үтик: 60 еллар башында башка телләрдәге матур әдәбият әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү буенча Татарстан—СССРда дүртенче урында, ә татар теленнән башка телләргә тәрҗемә ителү ягыннан бишенче урында торган).

Әдәбиятның, гомумән язу эшенең дәрәҗәсе югары заман бу. Әдәбиятыбызның халыкара танылуына ике зур форсат чыккан еллар. Беренчесе, алда әйтелгәнчә, К. Нәҗминең "Язгы җилләр"енең, Г. Бәшировның "Намус" романнарының Сталин премиясе алуы. Заманы өчен ифрат зур вакыйга. Шушы премия уңаеннан бу әсәрләр дөньяның байтак телләренә тәрҗемә ителделәр, татар әдәбиятының данын еракларга тараттылар. Икенчесе—М. Җәлилгә Герой исеме һәм Ленин премиясе бирелү. Җәлил поэзиясе татар шигъре данын тагын да югарырак күтәрде. Соңрак—40-50 ел эчендә талантлы әсәрләр байтак язылса да, аларның авторлары халыкара масштабта алай ук яңгырый алмадылар. Субъектив һәм объектив сәбәпләр булды бугай (Хәер, соңрак, 60-70 елларда Г. Әпсәләмов әсәрләре шактый ук популяр булып алды). Без тикшерә торган сугыштан соңгы бу унбиш ел эчендә, табигый, әдәбият мәйданын ир уртасы егетләр, сугышта катнашкан фронтовиклар тотты. Төп әсәрләрне дә алар язды. "Тукай" (Ә. Фәйзи), "Онытылмас еллар" (И. Гази), "Газинур" (Г. Әпсәләмов), "Суд залында" (С. Хәким), "Яшәү белән үлем арасында" (Н. Дәүли)... Һәр чор әдәбиятының лидерлары була. 50 еллар әдәби хәрәкәтенең ин эре фигурасы, һичшиксез, Гомәр Бәширов. Сталин премиясе лауреаты. СССР Верховный Советы депутаты, Язучылар союзы рәисе... Тел остасы, фольклорчы, гомумән, аксакалларга хас зирәк кеше. Язучылыгыннан тыш, оешма хуҗалыгын ныгыткан шәхес. Ярты гасырдан артык тарихы булган язучылар дачаларын—Аккош күле иҗат йортын оештырган, нигезләгән кеше дә шул ук Гомәр ага Бәширов ("Аккош күле"ндәге иҗат йорты аерым бер язмага, андагы табигать күренешләре аерым альбомга лаек. Ярты гасырлык тарихы булган бу "Әдәбият бишеге"ндә кемнәр генә яшәмәгән дә, нинди генә әсәрләр иҗат ителмәгән! "Аккош күле"нә бәйле кайбер исемнәрне генә атап узыйк: Х. Туфан, Г. Бәширов, С. Хәким, И. Гази, А. Шамов, Ф. Хөсни, Р. Ишморат, Ш. Мөдәррис, Н. Дәүли, З. Нури, М. Рафиков, Х. Хәйри, И. Нуруллин, Г. Латыйп, Н. Юзиев, Г. Сабитов, Ф. Шәфигуллин, Г. Шәрәфетдинов, Ф. Сафин... Болары яшәп киткән язучылар. Әле исәннәрдән янә дистәләгән исемнәр санарга мөмкин. Бүгенге көндә дә биредә дистәдән артык күренекле язучылар яшәп иҗат итә). Ходай Гомәр аганың үзенә дә мәрхәмәтле булды: ул озак яшәп, 98 яшендә (1999 елда) иҗатының кадерен, халыкның ихтирамын тоеп дөньядан китте. Бу чордагы язучылар оешмасының җитәкчеләрен дә янә искә төшереп үтик: председательләр—Ә. Ерикәй (1945-50), Г. Гобәй (1950-53), Г. Бәширов (1953-58), А. Шамов (1958-61), рәисләрнең урынбасарлары—җаваплы секретарь вазифаларын фронтовик шагыйрьләр Ә. Давыдов, З. Нурилар башкарган. Сүз уңаеннан шуны да билгеләп узыйк: 50 еллар ахырында, дөресрәге 1959 елның 18-23 май көннәрендә Зур съезд—СССР язучыларының III съездындаТатарстаннан делегат булып җиде язучы (Г. Бәширов, М. Әмир, А. Шамов, Р. Ишморат, С. Хәким, З. Нури, Ш. Галиев. Араларыннан бүген исәне—Ш. Галиев, аңа хәзер 76 яшь) бара. Бу съездда татар язучылары исеменнән М. Әмир чыгыш ясый. Шул чорның, шул зур җыеннарның тагын бер характерлы ягы: СССР күләмендәме, Россия яки республикалар күләмендәме, язучылар съездына илнең иң югары постында торган җитәкчеләр төркеме белән киләләр иде, чыгыш-докладлар ясап, банкет-приемнарда да утыралар иде. Әдәбиятның, язучыларның дәрәҗәсе югары икәнен дәлилләүче күренеш. Әдәбиятка ил башлыкларының мөнәсәбәтен, игътибарын күреп, гади халык та, әлбәттә, язучыларны зурлый, олылый иде...

*Икенче өлеше киләсе санда*

*Дискуссия: "Безнең заман герое"*

## ЯҢА МАЯКЛАР ЭЗЛӘГӘНДӘ...

Соңгы елларда татар әдәбиятында, татар шигъриятендә нинди төп күренеш, тенденция күзәтелә дигән сорауга мин түбәндәгечә җавап бирер идем: татар әдәбияты, татар шигърияте көчләп тагылган коммунистик идеологиядән соң үзе өчен яңа, чын маяклар эзләде... Бу яңа маякларны эзләп алу бәһасе яшәешнең, чынбарлыкның олы мәгънәсен эзләп табуга тиң иде. Чөнки, үткән гасыр урталарында фәлсәфәче-экзистенциалист Жан-Поль Сартр дөрес язганча: "Ирекле булырга хөкем ителгән кеше дөнья өчен бар җаваплылыкны да үз өстенә ала".

Чыннан да, үткән гасырның җитмеш елы буена: гыйсъянчылык аша революцион романтизмга килгән Такташлардан алып татар совет лирикасын тудырган Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Әхмәт Ерикәй, Әнвәр Давыдовларга кадәр татар шигъриятенең төп маягы коммунизм һәм коммунистик кыйммәтләр иде. Рухи традициягә карауч кыйммәтләр исә — Яхшылык, Сафлык, Иптәшлек, Дуслык һ.б. коммунистик идеологиядә "эретелделәр", "аныкы" ителделәр...

Гаделлек, Тигезлек һ.б.ш. белән бәйле коммунистик кыйммәтләр, билгеле, һич тә начар түгелләр иде! *(В. И. Ленин һәм аның тарафдарлары безгә изелүчеләрнең билгеле бер чиктән соң бунтка, инкыйлабка хакы барлыгын дөрес искәрттеләр...)* Әмма, алар террор һәм тоталитарлык аша "иңдерелү" алгач, һәм "фәнни" атеизм белән дә бәйләнелгәч, үзләренең уңай якларын җитәрлек дәрәҗәдә югалттылар, кыйммәтсезләнделәр... "Яхшы максатлар хакына начар чаралар куллансаң, максат та начарга әвереләчәк", — дигән бер Рухи Укытучы...

Күпмедер дәрәҗәдә "көчләп" тагылган әлеге маяклар сүндерелгәч-сүнгәч, югалтылгач-югалгач, тоныклангач Кеше-Шагыйрь бар җәмгыять төсле үк ирекле сайлау алдында калды: ни өчен яшәргә, кемгә-нигә табынырга; нәрсәне хак, изге саф, бөек диеп санарга?

Билгеле, мәңгелек рухи традициягә карауч, шигъриятнең җанын билгеләүче тема-идеяләр элеккечә кала бирделәр: мәсәлән, мәхәббәт, ата-ана, Туган җир, Ватан, табигать... Бары тик алар коммунистик идеология белән бәйләп караудан арындырылдылар, үз-үзләренә кайтарылдылар.

Ә соң нинди максатлар хакына барды бу коммунистик идеологиядән "юылып алу" процессы? Бәлки, тоталитарлыктан, коллыктан ваз кичтерүче Үзгәртеп кору, Ирекләлек, Хәбәрдарлык дигән изге төшенчәләр хакына? Алар бер мәл безнең маякларыбызга әверелеп калдылар төсле... Торгынлык чорында туңган күңелләрдә Өмет уянды... Бу, мәсәлән, шунда да чагылды: М. Горбачевның Үзгәртеп кору сәясәте башланганнан соң илдә үз-үзеңне үтерү күренеше нык кына кимеде. Менә татар шагыйре Зөлфәт тә 1985 елда "Адашкан болыт" шигырендә болай дип өметләнеп язды:

*Әллә ниләр үзгәрер күк илдә —*
*Заманнарның тын-сулары кайнар!*
*Бусы, бәлки, безнең яңгыр булып*
*Безнең коргаксыган җиргә явар?..*

Ирек тойган җәмгыять исә үзенең күптәнге тормыш маягын һәм аңа алып барган юлны тәнкыйтьләүгә күчте. Беренче чорда Үзгәртеп кору процессы аша шул коммунистик маякка тугры калу да күздә тотылды бит!..

Әмма... вакыйгалар башка төс ала башлады. Кем әйтмешли, "процесс башланып китте"... Ренат Харис шушы чор турында түбәндәге шигъри шаһитлыгын калдырды:

*Үзгәрәбез... Әйе, үзгәрәбез...*
*Үзгәрешләр шушы бүгенгә:*
*уйга ирек бирдек — ул сугыша,*
*телгә ирек бирдек — сүгенә,*
*каргый, әрни, вөҗданыңа тибә,*
*чәнчи, сутә, кисә, фаш итә...*

*("Үзгәрәбез", 1988)*

Башланып киткән бу иҗтимагый-сәяси процессның үзеннән-үзе иртәме-соңмы коммунистик маяктан баш тартуга, яңа, чын маяклар эзләүгә китерәчәге җитәрлек ачык иде инде...

Мәгълүм булганча, коммунизм тәгълиматыннан баш тарту аның тоталитар тарихын, террорга буялган үткәнен искә төшерү, хәтерләү белән бергә барды. XX йөзнең сиксәненче еллары ахырында, туксанынчы еллары башында сталинизмны, 1937 елгы террорны, ГУЛАГ системасын тәнкыйтьләүгә багышланган шигырьләр аеруча күп иде. Кайчандыр шагыйрьләр атом-төш сугышы куркынычы янаганда тынычлык турында шигырь язмый кала алмаган төсле, бүген инде алар кызыл террорның начар икәнен, антигуманистик ягын искә төшереп узуны үзләренең гражданлык бурычы санадылар. Әдәбиятка әле генә аяк баскан Зөлфәт Хәким дә 1990 елны шәхес культы һәм сталинизм чорының кешелексез, дәһри атмосферасын искә төшерә:

*Сагайды йорт...*
*Авыр тынлык...*
*Шәүлә урам чатында.*
*Бу тирәдән нидер йөри,*
*Кемдер бар өй артында.*
*Үлем килеп керде өйгә,*
*Эт өрүдән туктагач...*
*Тора... киеме бик таныш:*
*Галифе һәм күн плащ.*

"1937"

Яки менә Рөстәм Мингалимнең шул чорларның фаҗигале чынбарлыгына багышланган "Ул чор безне ничек каршылар" шигырендә түбәндәге юллар:

*Без кичкәндә тормыш диңгезен,*
*Ямьсезләнеп беттек, имгәнеп.*
*Гарип уйлар-сүзләр кычкырдык,*
*Озак шулай аңга килмәдек...*

Әйе, социалистик-коммунистик системаның террор, тоталитарлык кебек тискәре якларын тәнкыйтьләү, аларның кешеләргә алып килгән күп төрле фаҗигаләрен даими искә төшерү кайчандыр күңелләрне яулап ала алган коммунистик Маяктан баш тартуга китерде... КПСС үзендә һәм илдә Үзгәртеп кору башлап җибәреп тә таркалырга, тарихи сәхнәдән төшеп калырга мәҗбүр булган елларда шагыйрьләр болай дип язды:

*Без ашкынып бардык! Бер үк булган*
*Коммунизм белән ГУЛАГ юлы.*
*Даһи һәйкәл дәртләндереп торды,*
*Мәйданнардан сузып бөек кулын:*
*"Дөрес юлдан барасыз, иптәшләр!"*

*(Фәрит Габдрахим. "Дөрес юлдан барасыз, иптәшләр!")*

Әмма, кызганычка, Михаил Горбачев чорында башланып киткән демократик романтизм чоры озак бармады... Ә бит тоталитар коммунистик системадан баш тарту нинди генә өмет-хыялларга юл ачмаган иде! Иреклелек, Хәбәрдарлык, демократия,

сайлау хокукы, шәхси милеккә хокук... —болар яшәешебезне кыска гына вакыт эчендә яхшы яка үзгәртерләр, элеккеге совет халкы тиз арада Көнбатыштагы кебек үк ирекле, бай, мул, шат яши башлар төсле иде! Җәмгыять тагын да гуманлырак, гаделрәк булыр, халыклар озак гасырлар көткән милли Азатлыкка, ниһаять, ирешерләр кебек иде!..

Ләкин... аннан соңгы еллар күз алдына бастырырга мөмкин булганыннан да начаррак нәтиҗәләргә китерде түгелме?!. 1993 елны Мәскәүдә Югары Совет танклардан аттырылганнан соң Россиядә демократик романтизм чоры тулысынча тәмамланды бугай. Бу чор, мөгаен, киләчәктә, күбрәк кара тоннарда искә алыныр. Капиталистик системага юл тоту икътисадны, җәмгыятьне тиз арада криминальләштерде, кешелексезләндерде... Гаҗәеп пародокс ачылды бу чорда: бер яктан илдә йөзләгән чиркәүләр, мәчетләр төзелүен, яңартылуын дәвам иттеләр, ә икенче яктан исә Рәсәй дөньяда кеше үтерү буенча икенче *(Колумбиядән кала)*, балаларның үз-үзен үтерүе буенча беренче урынга чыкты!

Кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре еш кына криминал, "законлы карак"лар төшенчәләре, кануннары нигезендә төзелә башлады... Изге, игелекле юлдан азган залимнәргә, әхлакның ни икәнен дә белмәгән үзләренең түбән инстинктларын тормышка ашыру өчен юллар ачылды. Моңа өстәп милли бәйсезлеген игълан иткән Ичкериягә каршы алып барылган мәгънәсез, канлы колониаль сугышны да искә төшерергә була.

Бу еллар илаһи кыйммәтләргә хезмәт иткән шагыйрьләрне дә тетрәтте. Заманның ачы дисгармониясе аларның шигырьләрендә тегеләйме-болаймы чагылыш тапты. "Бүгенге хәлләребез" шигырендә Роберт Миңнуллин түбәндәгечә ачынып язды:

*Йодрыклар чыкты кесәдән,*
*Бүген һәркем гайрәтле!*
*Буташтырып бетерделәр*
*Яман белән әйбәтне.*

*Өскә чыкты еллар буе*
*Сөрсеп яткан явызлык.*
*Тыялмый ул явызлыкны*
*Бернинди дә авызлык.*

Асылда Мәхәббәт темасына мөкиббән, романтик рухлы Рәдиф Гаташ та заман турында сүз йөрткәндә кыргый капитализмның рухсызлык, имансызлык, алдануга корылган атмосферасын сурәтләргә мәҗбүр булды:

*Заман дигәнем, син—кемнәр заманы?*
*Мәхәббәткә, сафлыкка көн калмады...*
*Тагын—алтын, байлык итә патшалык,*
*Акыл, вөҗданны—дәрәҗә алдады.*

Шуның белән бергә бу елларда демократик романтизм белән үрелеп туган милли романтизм безнең төп Маягыбызга әверелде. Ул чакта Туган Ил, Ватан, халык төшенчәләре яңа мәгънә үзгәреше алды. СССР таркала башлагач, ә таркалганнан соң бигрәк тә, татар шагыйре уйлана калды: кая ул чын Ватан? Ватан "катлы-катлы" буламы, әллә бер генәме? Сиңа милли ирек бирмәгән, синең нинди имля белән язарга тиешлегеңне өйрәткән Ил Ватан була аламы соң? XX йөзнең 90 елларында бу яссылыкта күп кенә борчулы шигъри сораулар туды һәм аларга шигъри җаваплар да бирелде...

Милли романтизм дигәннән, татар язмышына караучы темалар бик тиз беленде: алар—1552 ел, ягъни Казанның алынуы темасы; башта патша империясендәге, аннан сталинизм чорындагы милли-дини изелү темасы, милли коллыкта татар яшәешенең деградацияләнүе, татар яшьләренең маңкортлаша баруы темасы; тоталитар коммунистик система җимерелгәч яңа милли Яңарыш—Ислам диненең кайтуы, татар теленең күтәрелүе, татарның югалган дәүләтчелеген торгызу темасы һ. б. ш...

*Җырда—бөек,*
*Моңда—бөек,*
*Дастаннарга тиң булдым,*
*Алыплардан тусам да мин.*

*Тарихтан гафил булдым.*
*Әйтерме бер күреп, җиһан:*
*"Бабаңнарга тиң булдың!"*

*(Илдар Юзеев, "Мин нигә гафил булдым?", 1992.)*

Татар фаҗигасе, билгеле, 1552 елны Казанның алынуы белән, татар халкы эчендә инде күптән яшәп килгән бердәмсезлектән башланды... Бу—татарның үзе эчендәге бердәмсезлек, хыянәт, хакимият өчен барган мәгънәсез көрәшүләр өчен кан, коллык белән җавап бирү чоры иде...

Зөлфәтнең "Сөембикәнең хушлашу догасы" шул бердәмсезлек, хыянәт китергән коточкыч фаҗигале, катастрофик җиңелү турында иде...:

*Алар җиңде... Безнең кулдан кылыч төште.*
*Миңа—әсирәгә—әзерләнде бөят.*
*Алып китә алар мине түгел, халкым,*
*Китә алар синең шөһрәтеңне тәяп.*

Моннан соңгы чорның 440 ел буена татар өчен искиткеч зур югалтулар чоры булганлыгын сөйләп тору кирәкме икән?! Моны милли аңлы һәр татар да белә...

*Бармы җиңгәннәрнең Җирдә*
*яшьтән, каннан туйганы?*
*Җиңелгәннең нәселен кортып,*
*буганнар да суйганнар...*

*Кол калганын, бил бөгәргә*
*җәһәннәмгә куганнар.*
*Туң якларга, чүл якларга*
*илтеп олактырганнар.*

*...Петербур нигезендә дә*
*күпме ята туганнар!*
*Соңрак чорда "вербовка"га*
*"ирекле" кул куйганнар—*
*Кем илендә йотылдылар*
*ул—меңнәр, миллионнар?..*

*Туган илдә бакча-җирләр*
*Һич иясез калмаган.*
*Җир-суларны баскыннарның*
*Утарлары камаган.*

*(Равил Фәйзуллин, "Айну яки тарихи махмыр", 1994)*

Шушы милли коллык, дини изелгәнлек, физик яктан юкка чыгарылу чоры кайбер елларны санамаганда *(әйтик, 1905 нче елгы революциядән соңгы берничә елны)* 440 еллап дәвам итте...

Ниһаять, ирек, азатлык җилләре исә башлагач, ирекле, цивилизацияле дөнья белән арада булган "тимер пәрдә" алып ташлангач, татар халкы, Татарстан күтәрелә башлады: гасырлар буе көткән мөстәкыйльлек игълан ителде, татар гимназияләре ачылды, рухи-хакыйкый-бакый юлга чакырып мәчетләр төзелә башлады... Халык күңелендә дә Иман, Тел, Тарих үлмәгән иде әле. Ркаил Зәйдулла 1989 елны "Бисмилла" шигырендә образлы язганча:

*Ә без? Ә без? Без—имансыз түгел,*
*Ул—күз яшьтә, аккан каннарда...*
*Алар җирдә ятмый!—Сөңге булып*
*Кабат калкып чыга манара.*

Тик, татар халкы башка кавемнәргә Азатлык алып килгән ирек җилләренең шифалы йогынтысын тойса да, кызганыч, милли Бәйсезлеккә ирешә алмады әле! XXI гасырның башында да аның язмышы Мәскәү кулында кала. Шуңа күрә Газинур Моратның түбәндәге "Аран" шигыре үткәнгә дә, бүгенгегә дә карыйдыр.

*Бәйсезлегең бәйдә бәргәләнә,*
*Бәйсезлегең бәйле әлегә.*
*Бәйсезләрдә бәйге тоткан кавем,*
*Бәйсезлегең тоткын хәлендә,*

—ди автор. Аның өчен Татарстан бәйсезлеге аранда калган Ат образында чагылыш таба:

*Сугымчылар арта: суга алар,*
*Күсәк белән суга Атыңа.*
*Атсыз йорттан мал-бәрәкәт китә,*
*Дәүләт китә...*
*Арба ватыла.*

*Атсыз да һәм Ватансыз да калгач,*
*Үзең җигеләсең арбага...*
*Бүген әнә тышаулаган Атың*
*Сугымчыны көтә аранда.*

Шагыйрь мондый коллык язмышына баш ияргә теләми, ул араннан Атны урлап чыгарга—Бәйсезлекне кайтарып алырга чакыра:

*Атны бүген урлап чыгу кирәк,*
*Урлап чыгу—башка чара юк.*
*Артта—Ил-йорт.*
*Алда—имперфронт—*
*Чигенергә инде чама юк.*

Г. Моратның татарның империя коллыгындагы язмышы турындагы уйлануларга багышланган "Ачлык" исемле поэмасы түбәндәге сүзләр белән тәмамлана:

*Ач торабыз. Ачыгабыз.*
*Асылда без—*
*Үлемсез.*
*Үлгәндә дә тик яртылаш*
*Үләрбез без—*
*Күрерсез!*

Бу шигъри юлларның олы мәгънәсе поэмага бирелгән эпиграфта табыла. Ул француз фәлсәфәчесе-экзистенциалисты Альберт Камюның мәшһүр сүзләрендә: "Ирек хакына шәһит китү генә мәгънәгә ия була. Тик шул чагында гына кеше үзенең бөтенләй үк үлмәячәгенә ышана..."

Әмма ни генә булмасын, милли җан ничек кенә өзгәләнмәсен, 440 елдан соң беренче тапкыр татар халкы үз Ватаны, үз Дәүләте турында ачыктан-ачык сүз йөртергә мөмкинлек алды! 1990 елның 30 августында Мөстәкыйльлек турында татар өчен онытылмас, әһәмиятле Декларация кабул ителде. Татар шагыйрьләре, билгеле, шат иде. Мөдәррис Әгъләм шул көннәрдә "Түземлекләр бирсен" шигырендә түбәндәгечә язды:

*Түземлекләр бирсен сиңа, илем,*
*Түземлекләр бирсен!*
*Башкаеңны горур тоткан хәлдә*
*Каршыларга язсын иртәгәсен.*
*Үз дәүләтең аяк баскан чакта,*
*Түземлекләр бирсен!*

Ичкериядә башланган фаҗигале сугыш исә 500 еллык гомере булган империянең әле тиз генә бирелергә теләмәвен бик ачык күрсәтте... Шуңа да карамастан, татар шагыйрьләре күңелендә Азат Татарстан идеясе яшәвен дәвам итә...:

*Җилләр безне юатмакчы була:*
*Тәкъдиреңә, туган, түз, диптер.*
*Бу Рәсәйне бурлак сыман тартып,*
*Сөйрәп бару—бәхетсезлектер.*

*И котлыйсы һәм сөйлисе иде*
*Бәйсез Татарстан турында!*
*Танк тавышларын кумә-кумә,*
*Өмет кайный әле җырымда...*

*(Рашат Низами. "Татарстан турында моңсу җыр", 1995)*

Әмма, әмма... иртәме-соңмы күңелгә ниндидер бер ару төсле халәт килә икән. Бәлки, бу инанган маякларны яңадан барлау вакытыдыр?! Әгәр демократик романтизм кыргый капитализмның тынчу атмосферасында җан бирсә, милли романтизм да шул ук кыргый капитализм, Ичкерияне канга батыру атмосферасында югалды дигән сүз. Җәмгыятьнең криминальләшүе, бай-ярлыга бүленүе, полярлашуы, рухи яктан саегуы да милләт эчендәге бердәмсезлекне арттырды түгелме?! "Татарстанның халык яулап алган чагыштырмача мөстәкыйльлеге татар түрәләренә генә әйбәт булды",—дигән фикерләр дә яңгырады... Җитмәсә, "үзәк" үзенең басымын арттыргач, татар өчен мөһим булган дәүләтчелек идеясе арткарак чигенде... Бүген инде без дәүләтчелек, милли Бәйсезлек идеясеннән "уртак Ватан" һәм "андагы тигез хокуклар" дигән темага күчеп барабыз кебек... Билгеле инде, французга Аурупа Берлегендә булган төсле, татарга да уртак Федерациядә яшәүнең уңай яклары күптер. Әмма... тигез хокуклар асылда юк бит! Әгәр Татарстанның бу Федерациядән чыгып китәргә хокукы юк икән, ул нинди Федерация була ала?! Әлеге дә баягы Империя дигән сүз ул: чыннан да, әгәр синең язмыш һаман әле Мәскәү кулында икән, бу шул ук күңел кайтаргыч милли коллык түгелмени?!.

Бүген романтизм чоры узды кебек. Социаль системаларны алыштыру җәмгыятьне кешелеклерәк ясамады. Дин тоту ирегә кайтты, әмма, кызганычка, дин әле җәмгыятьтә үзенең лаеклы урынын ала алмады. Ә асылда бит Ислам бүгенге татар халкы өчен табылган төп Маяк булып тора! Ләкин, ни өчен Ислам кебек дини маяклар булганда да җәмгыять гуманлашу кичерми, кешеләр күңеленә Миһербанлык, Мәхәббәт, Яхшылык, Сафлык, Дуслык кебек хис-тойгылар кайтмый? Әллә без шул Маякларның яктысын күрә алмыйбызмы, әллә инде шул Маякларга таба юнәлергә дә теләмибезме?!...

Сораулар күп, төрле... Минемчә, коммунистик Маяктан баш тартканнан соң һәм демократик романтизм, милли романтизм, кыргый капитализм чорларын кичергәннән соң татар шигърияте фәлсәфилеккә юл алачак. Чөнки, бүгенге заман һәм аның сораулары шуны таләп итә. Җиңел җаваплар чоры узды төсле... Билгеле, дәүләтчелек һәм милли Бәйсезлек идеясе, дини Яңарыш һәм демократик җәмгыять идеясе дә калачак. Әмма бу идеяләргә өр-яңадан, югарыдан карарга вакыт җиткәндер...

Нәрсәдән туа бу фәлсәфилек? Мөгаен, ул сорауларга гади җавап була алмавын аңлаудан, югары кимәлдәге рухи эзләнүләрдән, мәсьәләнең соңгы чыганагын табарга теләүдән, мәңгелек сорауларның бүгенге заман өчен дә актуаль булуын тоюдан туа...

Асылда, шагыйрьләр һәрвакыт Чынбарлыкның, Мәңгелекнең серен үз иҗатлары аша чишәргә омтылганнар. Теләсә кайсы заманда. Идеологияләр, системалар, вәзгыятьләр алышынып торган бүгенге заманда да бу шулай кала.

*Җан Мәңгелек учларында ята—*
*Бер гөнаһсыз яфрак шикелле,—*

—дибез без шагыйрә Луиза Янсуарга ияреп.

Әйе, татар шигърияте фәлсәфиләнә төште. Бу өлкән буын шагыйрьләр иҗатында да, урта буын һәм яшьләр иҗатында да ачык күзәтелә.

**Илшат ВӘЛИУЛЛА**

* * *

Гөлчәчәк Галиеваның "Өзелгән өмет" повестен ("Казан утлары" № 5, 2003 ел) бер укый башлагач, укып бетермичә, туктап булмады. Иң элек, үзенә тартканы— әсәрнең теле. Үзе җиңел, кирәкмәгән катлаулы троплар белән шәрехләп язу юк. Мондый стильгә ия булган язучының бу отышлы ягы, дип кенә әйтергә кала. Укучы күңеленә ятышлы тагын бер ипле ягы—сюжетны кора белүе, укучыга аның сискәндерерлек очын тоттырмыйча, яшерә алуы кызыклы.

Ә менә житешмәгән ягы—геройларының рухи кичерешләргә ярлырак булуына пошынып куярга туры килә. Портрет детальләренең житмәве дә үзен нык сиздерә. Автор киләсе әсәрләрендә бу турыда уйланып, персонажларның киеренке тойгы катламнарын үстерүгә борылыш ясар дигән теләкне исендә тотар әле. Чөнки язучының моңа ирешү мөмкинлекләре инандыра, минемчә.

"Өзелгән өмет" күпьяклы уйларны ассоциацияли торган атама: Талия өчен ул — Касыймның һәлакәте, ялгыз ана булып, бала белән билгесез тәкъдир каралта торган фажигасе; менә дигән гаиләсен югалткан Ахыярга—ун еллар сөяркә булыр торган" хатынга өйләнүе, аңа тормышның өметсез сабагы, кинәт суккан, хыянәттән алданган ирнең фажигасе; дүрт ятим белән ялгыз калган Кәмәриянең олуг бәхетсезлеге, бизнеста байлык туплап, һәр җәһәттән рәхәт яшәгән Касыймның үлем газабы—өзелгән өмете. Сүз дә юк, повестьның исеме персонажларның үкенечле тәкъдирен сурәтли алган, авторның отышлы табышы ул.

**Мәдинә ҖӘЛӘЛИЕВА,**
*Казан*

* * *

Журналның былтыргы 10нчы санынннан алып редакция "Бүгенге заман герое?" дигән фикер алышуга чакырды. Быелгы саннарда шул дискуссиядә катнашучыларның беренче язмалары да күренә башлады. Катнашучылар беравыздан диярлек хәзерге әсәрләргә тәнкыйть һәм канәгатьсезлек белдерәләр.

"Казан утлары"н туган тел онытылмасын өчен күптәннән алып киләм. Басылган әсәрләрнең сыйфаты бик төшкән вакытларда туктап тормадым. Менә хәзер дә шул вакытлар житте ахрысы. Әле кайчан гына *(1999)* сокланырлык әсәрләр чыгадыр иде *(Нур Әхмәдиевнең "Амбирак яки кара каен кыйссасы", Камил Каримовның "Ком сәгате" һ. б.).* Соңгы елларга күз ташлыйк.

Профессиональ тәнкыйтьчеләр күбрәк әдипләрне күккә чөеп мактыйлар гына. Ф. Латыйфинең "2002 ел прозасына бер караш" дигән мәкаләсендә "Әдәби телнең камил, матур, йомшак һәм ягымлы телнең тәмен тоеп, аның барча мөмкинлекләрен, эчке куәтен, резервларын тоеп һәм кулланып язган әсәрләр калмады диярлек" дигән юлларны укый башлагач "менә бу хәзер дөреслекне яза, бирә кирәкләрен" дигән идем. Берничә шәп әсәрне дөрес бәяләгәннән соң *(З. Зәйнуллинның "Гарасатлы юллар", М. Кәбировның "Сары йортлар сере", Ә. Салахның "Соңгы вальс")* ул да кулын селтәп барысын да мактап бетерде.

Р. Зарипов *("Кашка тәкәме, кәҗә тәкәсеме?" № 9, 2003)* биргән бәяләр белән мин тулысынча килешәм. Ф. Сафинның "Гыйбрәт алыйм дисәң..." мәкаләсе дә күп очракта дөрес язылган. Ул болай дип яза: "Мондый әсәрләрнең эчке энергиясе юк. Милли идеягә дә хезмәт итми алар, актуальлеге дә чамалы". Бу бит язучылар корылтаенда ясалган чыгыштан. Шулай булгач ник бер нәрсә дә үзгәрми? Редакция сыйфат планкасын түбән төшердеме, әллә сайларлык әсәрләр юкмы?

Дөньякүләм танылган әсәрләр белән чагыштырырлык язмалар бездә юк инде. Гарәпләр әйтмешли: "Даһилар юк урында тәбәнәк тә биек күренә". Аннары чагыштырып та булмый бит, татар телендә андый әсәрләр чыкмый, татар әдипләренең дә әсәрләре чит ил телләренә тәрҗемә ителми. Инде тәрҗемә эшен карап карыйк.

Татар теленә тәрҗемә ителгән әсәрләр бик аз, күбрәк өзекләр, кыска әсәрләр генә. Ә бит Тукаебыз да Пушкин, Лермонтов, Кольцов шигырьләрен тәрҗемә итүдән чирканмаган. Ә. Синугыл тәрҗемәсендә Йосыф Баласагунлының "Котадгу белек"тән бер өзек басылган иде. Менә шундый әсәрләр татар шигъриятенә яңа сулыш бирә алыр иде. Тулаем шул әсәрне тәрҗемә итсә Ә. Синугыл татар әдәбияты тарихында Н. Гнедич *(Илиада белән Одиссеяне рус теленә тәрҗемә иткән)* шикелле калыр иде.

Дөньяда татар әдәбиятын таныту өчен иң зыялы татар әдипләренең әсәрләрен русчага һәм бүтән телләргә тәрҗемә итү кирәк. Ә татарчага мөселман илләренең, бигрәк тә гасырлар буе бәйләнештә булган Урта Азия, Иран, Гыйрак, Мисыр, Төрек язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итәргә иде. Детективларны мин урыс телендә дә укый алам.

Дискуссиядә катнашучылар күбрәк проза турында яза һәм алар белән тулысынча

килешмичә булмый. Үткән вакытларда да хәзерге шикелле авыр еллар булган, ләкин шул хәтле оятсыз әсәрләр язылмагандыр, әхлакның эзе дә калмады бит. Иң пычрак әсәрләрдән түбәндәгеләрне санарга була: Әсгать Салахның "Каеннар юлы", Сәйдә Зыялының "Югалту", Рафаэль Сибатның "Инабәт", Марат Әмирхановның "Тояк эзе" һ. б. "Әдәбият— тормыш көзгесе" имеш. Ул тормышны без әдәбиятсыз да күрәбез, андый натурализм укучыларга кирәк түгел дип беләм. Нинди герой, кая чакыра андый әсәрләр?

Әдәбият көзге генә түгел, ул бит сәнгать тә әле, яшьләргә милли үрнәк бирүче. Андый әсәрләр бик сирәк очрый башлады, алар арасында Айдар Хәлимнең "Казыктагы итальян", Барлас Камаловның "Соңгы көннәрдә" дигән хикәяләрен күрсәтергә була. Ә дискуссиядәге сорауларга җавап эзләгәндә бер генә булса да мисал китерергә була. Ул да булса Р. Батулланың "Алып батыр маҗаралары". Менә ичмасам чын батыр, чын герой. Пушкинның сүзләрен шул әсәргә юнәлдерсәң: "Анда татар исе, татар рухы" дип әйтергә була.

Шигырьләрне мин сирәк укыйм, рифмасыз шигырьләрне абына-сөртенә ерып чыкканчы интегеп бетәсең. Кайчагында әллә татар теле шигырь язарга яраксыз микән дигән уй да килгәли. Тукай томнарын аласың да, юк, матур, салмак кына агылган шигырьләр татар телендә дә бар икән дисең үзеңә. Ә хәзерге шигырьләр пешеп җитмәгән шул, шагыйрь ни турында язганны да аңлап булмый, хиснең эзе дә юк— робот язган диярсең.

Кыскасы, бүгенге татар әдәбиятында мактанырлык әсәрләр юк диярлек. Бу торгынлыкны тизрәк үтәр өчен анда күбрәк яшь көчләрне тупларга һәм өйрәтергә кирәк дип уйлыйм.

**Ким НАСРЕТДИНОВ,**
*Мәскәү*

*Хәтер*

Тәлгат
Галиуллин

# ТӘНКЫЙТЬ КҮГЕНДӘГЕ ЙОЛДЫЗ

ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Алтын тутыкмас, бәясен югалтмас, ди халык. Татар әдәбиятының олуг белгече, гаярь тәнкыйтьчесе, милләтнең язмышы, киләчәге өчен җан атып яшәгән Фәрваз Миңнуллин турында уйланганда шул мәкаль зиһенгә килә. Безнең арабыздан киткәненә быел ун ел тула, дөньяга килгәненә жиде дистә була икән инде. Ә ул һаман тере килеш күңелдә, истә: як-якка салынып төшкән, хуҗасы төсле үк башбирмәс конгырт чәчләрен тимер тарагы белән тәртипкә чакыра-чакыра, бөтен ак чыраена елмаю җәеп каршыңа килеп чыгар да: “Тәлгат, нихәл, гаиләң тәртиптәме?” дип белешкәннән соң, әдәбият мәсьәләләренә күчәр, яңа чыккан йомшак әсәрләргә ачы бәясен биргәч, “Әмирхан абыйның затлы “Тынычлану” хикәясе басылды, укыдыңмы”, дип сорар кебек тоела. Танышып өлгергән булсаң, мактап куяр, “вакыт җитмәде әле” дисәң, эрерәк тешләренең бер читен, хисләр өермәсен бастыргандай, суырып куяр да: “Күп нәрсә югалткансың”, дип кырыс вердиктын чыгарыр, үзен борчыган башка *(шул ук әдәбият булыр)* проблемаларга күчәр.



Үткән гасырның алтмышынчы-сиксәненче еллар татар әдәби тәнкыйтен Ф. Миңнуллин исеменнән, аның агымдагы прозабызга багышланган фәлсәфи, иҗтимагый эчтәлекле, вакыты белән торма кебек ачы, өермәдәй усал, әмма һәрвакытта гадел, итагатьле мәкаләләреннән, ел йомгакларына багышланган төпле *(В. Белинский үрнәгендә дисәк тә зур хата булмастыр)* чыгышларыннан, аерым әсәрләргә бәяләреннән башка күз алдына китерүе кыен. Ул яшәгән һәм иҗат иткән дәвердә: “тәнкыйть үсми, урында таптана, әдәби процесска юнәлеш бирә алмый, арбаның бишенче көпчәге төсле арттан сөйрәлә” дип, һәр чорда кабатлана килгән лаф орулар, зарланулар да тукталып торды бугай.

Фәрваз Миңнуллинның тормыш юлында, әдәби, әхлакый эзләнүләрендә максатчанлык ярылып ята. Ул Арчадан 50 чакрым ераклыктагы тау-чокырлары, үз урманы, чылтырап агып торган күпсанлы чишмәләре, гаҗәеп хуш исле аланнары белән әкияти хозурлыкка ия, беренче күрүдә үк үзенә гашыйк итәрлек Ишнарат дигән мәгънәле һәм күркәм исемле кечкенә генә авылда туа. Фәрвазларның бер читтәрәк урнашкан өйләре яныннан ук диярлек зәңгәр күк астында иген кырлары җәйрап ята. Шигъри җаны, матурлыкны аңлавы, табигатькә мөкиббән китеп яшәве туган якларының Швейцария дәрәҗәсен бәйгегә чакырырлык матурлыгыннан килә торгандыр. Туган авылы, шунда көн күрүче энесе Малик, аның балалары турында сөйли башласа, Фәрваз илһамланып китә, ихлас һәм самими күзләреннән бәхет нурлары чәчеп, “коеп куйган” шагыйрь була да куя торган иде.

Балачакта ямьле табигать кочагында озак иркәләнеп булмый шул. Сәгате суккач Фәрваз да Казан артының киләчәктә мәшһүр язучылары булып китәчәк

Г. Ахунов, М. Мәһдиев үрнәгендә, аркасына биштәрен асып, "бәхет дагасы"н эзләп, Арча педагогия училищесына килә. Шунда белем эстәгәндә үк, ул киләчәген татар мәдәни дөньясына багышларга дигән ныклы карарга килә. Бигрәк тә татар әдәбияты ана якын дигән уен күнеленә беркетеп куя. Иманына, жаны дәшүенә тугрылыклы калып, яшь егет Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә юл тота. Сугышка чаклы, аннан кайткач та колхоз рәисе булып унышлы эшләгән әтисе Мөхәммәдулла юлыннан китсә, Фәрваз хужалык, сәвит оешмаларында да соңгы кеше булмас иде кебек. Юк шул, рухи омтылышы аны милләт мәнфәгатьләре белән бәйле башка юлга алып чыга.

Дәрелфөнүндә уку чорында ул үзенә чаклы яшәп килгән фәнни-әдәби түгәрәккә эзләнү, бәхәс рухы алып килә, аның танылган житәкчесе, старостасы булып китә, шул чорда ук сүз сәнгатен тирәнтен аңлавы, өстән төшерелгән өлгеләрне, трафаретларны кабул итмәве белән аерылып тора. Кыскасы, Фәрваз гыйлемлек юлын сайлар дигән фараз өчен зәмин житәрлек иде. Югары уку йортын тәмамлаган елны ук аны "Совет әдәбияты" (хәзерге "Казан утлары") журналына эшкә чакыралар, озакламый бүлек мөдире итеп билгелиләр (1959—1961). Ә 1961—1964 елларда ул Казан университетының татар әдәбияты кафедрасында, профессор Хатип Госман житәкчелегендә аспирантурада укый. Бу галим холкы-фигыле белән гаять үзенчәлекле, катлаулы зат иде. Гомерен татар шигыре төзелешен өйрәнүгә багышлаган, хисси жанлы, әмма пафоска бирелүчән ошбу шәхес бер чиктән икенчесенә күчүчән характеры белән аерылып торды. Кул астына килеп кергән яшь тикшеренүче аңа тулысынча баш бирсә, буйсынса, ул ярдәм итәргә, үстерергә, уртакул хезмәтләрне дә дөньясын онытып мактарга мөмкин, ә инде аспирант мөстәкыйльлек күрсәтсә, үз фикерен бирмәсә... ул чагында инде Ходай үзе сакласын! Башбирмәс Фәрваз язмышы да әлеге кагыйдәдән чыгарма булмады: марксизм тәгълиматын үзләштерү ихтыяжы мәсьәләләрендә житәкчесе белән бәхәскә кереп, ул әзер фәнни хезмәтен яклауга чыгарудан баш тартты. Казан арты егете Х. Госман белән арасын өзеп, Татарстан мәдәният министрлыгына өлкән инспектор булып урнаша, ә 1965 елда янәдән "Казан утлары" журналына тәнкыйть бүлеге мөдире булып кайта.

Шул чорда ул матбугатта тәнкыйть мәкаләләре белән катнаша, үзен әдәбиятны нечкә аңлаучы, сүзнең эчке аһәңен, моңын тоемлый торган әдәбиятчы итеп таныта.

Күренекле галим В. Шкловский "телгә-сүзгә сизгер тәнкыйтьче, укылырлык роман яза ала", дигән. Каләм иясе өчен төп шартларның берсе булган туган телгә мәхәббәт, аның сыгылмалы байлыгын сиземләү—жырга һәм башка һөнәргә маһирлык кебек, Ходай Тәгалә, табигать бүләге. Бу жәһәттән Фәрваз бәхетле язмышлы кеше иде. Ә инде хезмәт урыннары—"Казан утлары"ның бүлек мөдире, Язучылар берлеге рәисе урынбасары, Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлеге мөдире, шул ук оешманың баш мөхәррире—әдәбият язмышына береккән әлеге жаваплы вазифалары аңа әдәбият серләрен тагын да тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Бер очракта да ул хиссез һәм гакылсыз башкаручы булмады, һәрчак жаны-тәне белән язучы халкын яклады, аның тормышын аз булса да жиңеләйтү мөмкинлеген эзләде, фатирлар юнәтү, бакча өчен жир алып бирү, пенсияләрне арттыру өчен йөрәген фида кылырдай булып көрәште. Каләм әһелләрендә ул халык намусын, милләт тарихын, аның киләчәген күреп яшәде.

Тел-сүз—аның өчен могжиза, халыкның төп байлыгы, серле хәзинәсе. Шул ышанычы Джек Лондонның "Мартин Иден", Герберт Уэллсның "Күренмәс кеше", "Галәмнәр сугышы" кебек тәржемә әсәрләрендә, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Мирсәй Әмир, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләжев, Рафаил Төхфәтуллин, Нурихан Фәттах, Әхсән Баянов кебек сүз осталары иҗатына багышланган хезмәтләрендә ачык чагыла. Ф. Миңнуллин каләменнән төшкән мәкаләләр әдәби әсәр кебек жиңел, бер тын белән укыла. Шуңар да ул, гадәттә, корама, ясалма жөмләләр белән язылган әсәрләрне әйләнеп үтәргә тырыша. Зәвыгы инде 1960 елда дөнья күргән "Нәби Дәүли" исемле тәүге мәкаләсендә үк төсмерләнә. Язучыга биргән бәясендә дә ул матурлыкны юлдашы, маягы

итеп ала, рухи балкышка—тел бизәкләренә—ифрат игътибарлы.

Алдагы елларда анын фикерләү диапазоны киңәя, тирәнәя барды, ул төрле стиль юнәлешләрендә иҗат итүче өлкән һәм яшь буын каләм ияләре эзләнүләренә гаҗәеп сизгер тәнкыйтьче буларак күтәрелде.

Прозада анын аеруча мөкиббән китеп, мәгънәви һәм эстетик ачышларын кайта-кайта өйрәнгән язучылары бар иде. Шулар арасында татар прозасының энҗесе—Әмирхан Еники иҗатына мөнәсәбәте аеруча җылы. Әдипнең иҗаты анын ике саллы мәкаләсенен үзәгендә тора: "Намус эше" (1964—1983), "Затлылык" (1989). Әдип турында язганда тәнкыйтьченең холкы үзгәреп, усаллыгы кимеп, җаны пакьләнеп киткәндәй тоела. Чөнки "Әмирхан Еники күбрәк хисләр киеренкелегенә, рухи һәм психологик халәткә игътибар юнәлтә". Әсәрләренен тәэсир көчен тәнкыйтьче шигъри ялкын, табигый сизгерлек белән ачып бирә: "күздән яшь китерә, бәгырьне телгәли анын әсәрләре... гүяки алар каләмне язу карасына түгел, ә бәлки хискә-моңга-сагышка манып язылганнар. Анын әсәрләрендә, моң-сагыш белән бергә, сине сафландыра һәм пакьләндерә торган, сине баета, зур эшләргә дәртләндерә һәм канатландыра торган рухи көч тә бар..."

Мавыктыргыч вакыйгалы, чытырман сюжетлы, холыклар кискен чәкешкән әсәрләргә бәя биргәндә дә ул, беренче чиратта, язучынын тел байлыгына, өслүбенең җырлап, җебе-җепкә ятышып торуына игътибар итә.

Инде без тәнкыйтьченең иҗатын әдәбиятта матурлык, эстетик ләззәт эзләүгә, нечкә зәвыкка, халтураны, тѳссезлекне, уртачалыкны кабул итмәүгә генә кайтарып калдырсак, бу ифрат берьяклы булыр иде. "Әдәбият—тормыш агышына тәэсир итәрлек, аны уңай якка үзгәртерлек олы иҗтимагый көч" дигән ышанычта яши ул, шуңа күрә дә язучынын дөньяга карашын, позициясен ачуга әһәмият бирә. Мисал рәвешендә анын ин соңгы мәкаләләреннән берсенә—"Балта явызлар кулында" язмасына тукталасы килә. Тәнкыйтьче биредә Аяз Гыйләҗев иҗатына булган төпле, нигезле һәм әтрафлы бәяне берничә биткә сыйдыра алган. Сүз күренекле прозаик, үзенчәлекле драматург, үткен каләмле тәнкыйтьче, очеркист, кыскасы, күләмле әдәби хәзинә калдырган шәхес турында бара. Ә тәнкыйтьче А. Гыйләҗев иҗатының буеннан-буена сузылган үзәк иҗтимагый юнәлешне эзли. "Коммунистик диктатура һәм шәхес, социализм һәм гаделлек кебек мәсьәләләр А. Гыйләҗев иҗатында төп урынны алды. Шул чордагы норматив әдәбият иске тормыш күренеше, капитализм калдыгы дип раслап килгән гарип күренешләрнең (икейөзлелек,әхлаксызлык, имансызлык, эчкечелек, караклык һ. б.) байтагын ул совет чынбарлыгы үзе тудырды, алар социализмның үз җимеше, дип барды. Шуның белән партия алга сөргән лозунгларның дөреслеген, без табынган идеалларның изгелеген шик астына алды. Утны капитализм өстеннән социализм өстенә күчерде. Безнен әдәбиятка Аяз Гыйләҗев алып килгән иң зур яналык шул иде". Язучы иҗатына сәяси яссылыктан бәя биргәндә моннан югары мөһер юктыр. Биредә язучының төп иҗат казанышы да ачык ярылып ята, яратып тасвирланган кыйбласын да тәнкыйтьче берничә җөмләгә сыйдыра: "А. Гыйләҗев үз иҗатында Галимҗан һәм Хәбибрахман карт, Шәмсегаян һәм Бибинур карчык кебек саф күңелле,



*Беренче рәттә сулдан уңга: Ренат Харис, Илтазар Алиев, Фәрваз Миңнуллин;*
*Икенче рәттә: Туфан Миңнуллин, Гариф Ахунов*

намуслы, тырыш, унган хезмәт кешеләренә күп урын бирә. Шулай да аның аеруча яратып, үз итеп һәм җан җылысын салып тудырган геройлары—яшьләр. Алар арасындагы мәхәббәт хисләрен тасвирлаган төшләр аның әсәрләрендәге иң матур урыннардан санала".

Мәкаләне тулысы белән үзегез укырсыз. Әмма шул ике өзектән дә үзенең фәлсәфи дөньясы, сәяси-икътисадый хәлләргә бәясе, уңай һәм тискәре каһарманнары, илаһи мәхәббәтләре белән, сокландыргыч вакыйга-хәлләр аша ачылган җанлы кеше килеп баса.

Ф. Миңнуллин язучыларның иҗат портретларына биргән исемдә үк сүз остасының бер үзенчәлеген калкытып куя. Әмирхан Еники иҗатына багышланган мәкаләне "Затлылык" дип атый икән, тәнкыйтьче матурлык кануннарына юл ала, әсәрләрне нәкъ менә шул ноктадан килеп тикшерә.

"Яшьлекне сагыну" гыйбарәсе исә Мөхәммәт Мәһдиев иҗатына яңача юл ача. Чыннан да, аның бөтен язганнары диярлек яшьлеген җырлауга, малай, үсмер, егет чаклары үткән 30-50 нче еллар татар авылы тормышын, татар рухын, моңын, нәзакәтен, фикерләү рәвешен аңлауга багышланган икән.

Фәрваз ихтыяҗ булганда, язучыларны яклап, кыю эзләнүләрен хуплап, үз канаты астына ала белде. Узган гасырның соңгы чирегендә Х. Камаловның 1941—1945 еллар афәтенә багышланган романнары шактый бәхәс уятты. Ф. Миңнуллин төпле фикере белән язучыны каралтулардан саклап калды, дисәк тә зур ялгыш булмастыр. Тәнкыйтьче сугышны героик пафос белән генә сурәтләмичә, гадәти ваклыкларын, көндәлек мәшәкатьләрен яшермичә реалистик тасвир юлына чыккан, психологик анализга киң таянган Х. Камалов прозасының яңачалыгын күреп ала, бу төр иҗатның үсешен шул юнәлештә күрә.

Сугышны бизәмичә, фаҗигале авырлыгы белән күрсәткән Виктор Некрасов заманында "В окопах Сталинграда" әсәре өчен илдән сөрелде. Дөньяны танып-белү, сурәтле күзаллау алымнары, психологизмы белән белорус язучысы В. Быковка якын юлдан атлаган, ә үзебездә артык җылауда, әрнүдә гаепләнгән Хисам Камалов эзләнүләренә дөрес бәяне Ф. Миңнуллин бирде. Х. Камаловның төп үзенчәлеген "бик тә гадиләштереп һәм гомумиләштереп әйткәндә, сугыш турында дөресен язу, сугышның кырыслыгын һәм рәхимсезлеген күрсәтү, кырыс буяулар белән язылган хакыйкать дип атарга булыр иде". Хәлбуки, Х. Камалов теленең шактый катлаулы булуын, урыны-вакыты белән тәрҗемәгә охшап китүен искәртүне дә кирәк саный тәнкыйтьче.

Шул ук вакытта Ф. Миңнуллин көн кадагына суккан, вакыйга сөйләү, каһарманнарны маңгайга-маңгай терәп, күз яше чыгару юлына баскан язучылар каршында да әдәбият ишеген шап итеп ябып куймый. Тик алар сүз осталары—затлы язучылар, художниклар рәтенә дәгъва итмәсеннәр, түрдән урын дауламасыннар, үзешчәннәр сафында калсыннар, ди ул.

Ләкин бу төр әдәбиятны тынычлыкта калдырырга намусы кушмый. 1988 елда "Бугазына төер тыгылмаса" мәкаләсендә ул "соры" әдәбиятка каршы күтәрелә. "Урта кул әдәбият, бөтен плацдармнарны яулап алып, гөрләп чәчәк ата. Тәнкыйть берни эшли алмый калды... Иҗат мәйданына өере-өере белән талантсыз, аның каравы, үтә әрсез, тырыш һәм эшчән "ибдәшләр" килде". Ф. Миңнуллин күптән түгел ил күләмендә алдынгылар рәтендә йөргән татар прозасының Идел һәм Урал арасындагы автономияле республикалар прозасы дәрәҗәсенә төшүенә ачынып, әрнеп яза.

Прозаның сыйфаты турында сүз йөрткәндә аның тавышы кырыслана. "Үр артында үрләр бар", "Хикәя һәм хикәячеләр", "Реаль хәлләргә күз салыйк" кебек гомумирәк характердагы мәкаләләрендә әдәбиятчы шактый катлаулы, четерекле мәсьәләләрне үзәккә ала, мисалларга таянып, теоретик фикерләрен калкыта, татар прозасының үсеш юлларын, якты ачышлары белән беррәттән күләгә төшкән аланнарын да барлый.

"Романга ни булды" исемле чыгышында ул М. Хәбибуллин, Ж. Рәхимовларның һәм гомумән татар прозасының производство, колхоз-совхоз темалары тәртәсеннән авырлык белән чыга килүен, ягъни каршылыклы хәләтен

ачып бирә. Өлешчә, әнә шул тәнкыйть сүзеннән соң югарыда телгә алынган авторлар үзләрен тарихи темада таптылар, "Кубрат хан", "Батырша" кебек, әдәбиятыбыз тарихында ныклы урын алган әсәрләрен иҗат иттеләр.

Тәнкыйть сүзен авторлар колагына индергәндә дә Ф. Миңнуллин әтрафлы булып, "сүгенүендә" дә гадел, зәвыклы шәхес дәрәҗәсендә кала алган. Мәгәр ул каләмдәшләренә бәһасен томанга төрмичә, ачык һәм төгәл итеп ярып сала, ярым төсләргә, кинаяләргә урын калдырмый. "Язучыларның унынчы һәм унберенче съездлары арасында 17 роман басылган",— ди ул "Кичермәсләр безне, кичермәсләр" исемле мәкаләсендә. —"Кода-кодагыйлыкны оныта төшеп, таләпчәнлекне аз гына арттырганда, аларның санын җиңел генә 10 га калдырып булыр иде. Чиле-пешле 7 роман басылмый калганнан, билгеле, татар прозасы берни дә югалтмас иде".

Язучылар союзын төрле юллар белән графоманнар басып китүенә гарьләнеп, әрнеп, шундый сораулар куя: "Ходаем, кая барабыз? Әйтегез әле, кемгә кирәк бу?" Жаны әдәбият белән яшәгән кеше генә шулай сыкрана ала! Табигый тыйнаклыгы аның усал тәнкыйтьче булуына зарар китерми. Тәссезлек, халтура белән очрашканда ул, янына дошман килгән керпе кебек, энәләрен тырпайта.

Прозаның без теләгән сыйфатка ирешә алмавының сәбәбе нәрсәдә соң? Кайберәүләр ак эт бәласын кара эткә сылап, тәнкыйтьне генә гаепләү юлына басалар: янәсе ул "һәвәскәрләрне һәм үзешчәннәрне профессионал әдипләрдән аерып бирә" белми. Ф. Миңнуллин мондый фикер белән килешми һәм үз карашын көтелмәгән сюжет борылышына маһир прозаиклар кызыгырлык алым белән исбат итә.

"Әмма бер нәрсәне онытабыз:

Әгәр Туфан Миңнуллинның ванна бүлмәсендә ут янмый икән—моңа ул үзе гаепле; Бауман урамындагы кибеткә чи ипи килгән икән—моңа Казанның 6 нчы икмәк заводы гаепле...

Инде әдәби тәнкыйть мөшкел хәлгә килгән икән—моңа барыбыз да гаепле..." Житди тонга күчеп, бу хәлнен иҗтимагый нигезләрен ачып бирә. "Мәрткә киткән кешеләр кебек, без күп еллар буе артык ваемсыз яшәдек. Бүген килеп җитәр, иртәгә килеп җитәр дип—коммунизмны көттек. Без көткән гадел җәмгыять һаман күренмәде".



*Шигърият бәйрәмендә катнашучылардан бер төркем: Галимҗан Латыйп, Исмәгыйль Иляхов (атаклы музыкант, мандолиначы), Нәби Дәүли, Фәхри Насретдинов (җырчы), Фәрваз Миңнуллин, Роберт Миңнуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Заһид Хәбибуллин (композитор). 1983 ел, 26 апрель*

Тәнкыйтьченең игътибар үзәгендә хәзерге әдәбият булса да, ул мирасны да читләтеп үтми. Бу яктан аның Галимҗан Ибраһимов иҗатына бәясе үзенчәлекле, гыйбрәтле. Әдипне тоташ мактап, олуг революционер, большевик, күренекле җәмәгать эшлеклесе буларак һәрьяктан үрнәк-өлге шәхес итеп күкләргә чөеп йөргән чорда Ф. Миңнуллин аңа карата шактый четерекле башкорт сүзе—"узаман"ны куллана. Һәр өлкәдә алда, беренче, узаман булырга омтылуы Г. Ибраһимовның иң төп сыйфатларыннан, ди тәнкыйтьче. Ләкин замана, "власть өчен көрәш узаманнарны да аяп тормаган. Аларны бигрәк тә аяп тормаган төсле... Кайчакларда Галимҗан Ибраһимов күз алдына революция солдаты булып түгел, ә бәлки аның корбаны булып килеп баса. Хәзер без аларның барсын да уптым-илаһи шәхес культы корбаннары дип йөртәбез. Хәлбуки, термин төгәл түгел..."

Г. Ибраһимовның иҗатын һәм шәхесен хәзер яңача бәяләргә омтылыш

бәхәс уятмас кебек. Тәнкыйтьче исә бу язучыны әзер калыплардан, коры социологик бәяләрдән арындыруны инде күптән үк башлады.

Дөнья әдәбиятыннан хәбәрдар булса да Фәрваз Миңнуллин өчен татар сүз сәнгате бөекләр арасында тигез хокуклы иде. Кайберәүләр кебек: кыргызның—Чыңгыз Айтматовы, Башкортстанның—гел абруйда йөртелгән Мостай Кәриме, Дагыстанның йөзек кашы Рәсүл Гамзатовы бар, без хәзерге әдәбиятка кемне бирдек, ни өчен безне танымыйлар, санга сукмыйлар дип лаф ормый, вакланмый, урыс әдәбияты казанышларына мөкиббән китеп, татар язучыларын кимсетү, түбәнәйтү юлына төшми иде ул. Һәр милли әдәбиятның үз казанышы булу өстенә, язучыларга ранглар биргәндә, бүләкләр таратканда олы сәясәтнең хәлиткеч катнашы барлыгын аңлый, аңлатырга тырыша иде тәнкыйтьче.

Әлбәттә инде Ф. Миңнуллин төп үз жанрына—тәнкыйть өлкәсенә—кагылышлы проблемаларга еш әйләнеп кайта, аңа бәясендә ул катгый. “Тәнкыйть—тиз искерүчән жанр” дип, чигенү юлын калдырса да, аның күпчелек чыгышлары бүген дә заманча яңгырый.

Хәзерге “тәнкыйтьнең адресаты үтә тар, радиусы бик бәләкәй... Бездә тәнкыйть күп дигәндә әдәби җәмәгатьчелек өчен, еш кына хәлләрдә исә иҗаты тикшерелә торган язучының үзе, аның якыннары, танышлары өчен языла”. Бу фикерләр белән әдәбиятка бөтенләй битараф кеше генә килешмәс. Шул ук вакытта, тәнкыйть—Ф. Миңнуллин фикеренчә, иң кагыла, сугыла торган жанр. “Аның комплиментар, хезмәтче һәм лакей характерында булганын гына яраталар, хуплыйлар. Чын, принципиаль тәнкыйть берәүгә дә кирәкми. ...Р. Мостафин белән М. Вәлиев курка-курка гына булса да урамга чыккалап караганнар иде, ташлар-таяклар ыргыта-ыргыта, “һау-һаулап” кычкыра-кычкыра аларны шунда ук элеккеге ояларына куып керттек”.

Ф. Миңнуллин даими рәвештә игътибар үзәгендә тоткан тагын бер өлкә—ул әдәбият белеме, әдәбият теориясе мәсьәләләре һәм аның үсешенә мөһим өлеш керткән галимнәр эшчәнлеге. Егерменче-утызынчы елларның күренекле тәнкыйтьчесе, әдәбият белгече Галимҗан Нигъмәти өстеннән нахак ялалар алып ташланып, исеме җәмәгатьчелеккә кайткач, 1960 нче елда ук Фәрваз “Галимҗан Нигъмәти” исемле төпле мәкаләсен язып чыга. Сонрак галим иҗатын үзәккә алып, берничә кандидатлык, хәтта докторлык диссертацияләре язылды, әмма аның иҗатына Миңнуллин биргән бәя искермәде, бүген дә көчендә кала. “Әдәбият фәне өлкәсендәге тикшеренүләрен Г. Нигъмәти әдәби тәнкыйть эшчәнлеге белән үреп алып бара... Замандашлары арасында гадел һәм объектив булуы, салмак, тыныч тонда язуы белән аерылып тора”. Ул аның чор шаукымы “пролеткультчылык һәм вульгар-социализм йогынтысына бирелеп” китүләрен, теория өлкәсендә романтизмны берьяклы бәяләвен урынлы искәртеп үтә. Шул чорда яшәп иҗат иткән, әдәбиятыбызның күренекле галиме, теоретигы Гали Халит иҗатын да читләтеп үтми, тәнкыйтьчеләрнең эзләнүләренә игътибарлы, Р. Мостафин, И. Ахунҗанов, М. Вәлиевләр турында әйтер җылы сүзен таба.

Ф. Миңнуллин үзен “саф” әдәби тәнкыйтьче итеп кенә санамады, татар халкы язмышына, аның теленә, киләчәгенә бәйле һәр вакыйга өчен җаваплы сизде, аерым алганда республикабыз җирендә табылган нефтьнең әрәм-шәрәм итеп бетерелүенә, ямьле табигатьнең пычрануына аның йөрәге әрнеде. Бу хәлләргә бәясендә ул усал, тавышы кырыс иде.

“Матур-елгыр егетләр, республика табигатенең гүзәл төшләрен тәмам пычратып, гигант заводлар, яңа калалар салдылар да, күкрәкләренә йолдыз тагып алгач, өскәрәк үрмәләделәр. Без аларны мактап, том-том очерклар, документаль китаплар яздык...”,—ди ул “Бугазыңа төер тыгылмаса” мәкаләсендә.

Кешеләр характерлары белән төрле булган кебек, алар турындагы хатирәләр дә берүк була алмый. Берәүләр бик тиз онытыла, икенчеләре йөрәгенә тирәнтен кереп утыра. Син аны үзеңнән аерып куя алмыйсың. Дуслары, туганнары белән аралашып яшәүне бәхет санаган, көләч йөзле, хиссиятле Фәрваз Миңнуллин шундый шәхесләрдән иде. Кәефе яхшы вакытларда ул шаяртып алырга, каләмдәшләрен “сараннар” һәм “юмартлар” төркеменә бүлгәләп үртәшергә,

хәтта иң якын дусты Мөхәммәт Мәһдиев адресына да йомры сүзләр ычкындырырга мөмкин иде. Ә тегесе "незрелый" дигән бәяне мактауга санапмы, Фәрвазның тәнкыйтен җитдигә кабул итмичәме, әллә инде үзен "саран" язучылар исемлегенең беренче рәтенә үк теркәмәгәнгә шатланыпмы, теннис шарыдай түгәрәк конгырт күзләре белән офыкны иркәләп, бәхетле елмаюын белә... Фәрвазга үпкәләп булмаган төсле, аны үзгәртергә маташуның да файдасыз икәнен анлый. Чөнки ул шатлыгында да, кайгысында да ихлас табигать баласы иде.

Күбебездән аермалы буларак, аңа көнләшү хисе, кемнеңдер уңышына, байлыгына, табышына, сөяркәсенә кызыгу дигән нәрсә хас түгел иде. Менә шул сыйфаты белән ул үзен саклап кала алды. Уңай искән җилләргә бөгелмәде, сыгылмады, "шәүлә яисә көя" төсле төссез, умырткасыз кешеләрне яратмады.

Гадәти кануннарга буйсынып, "шыпырт" кына яши белмәве аңа тормышында мәшәкатьләрне аз тудырмады. Матавыкны ул үзе эзли. Дәрәҗәлерәк эшкә күчтеме, анын эреләнеп, иркәләнеп, мендәр өстенә аягын бөкләп утырып аласын көт тә тор! Теләсә кем алдында түгел—иң якын дуслары, туганнары белән мөнәсәбәттә булыр бу хикмәт. Анысы да, бәлки, рыясызлыктан, һәр нәрсәне чынга кабул итүдән килә торгандыр. Каен тузы тиз яна. Фәрваз да җиргә төшеп, үз гадәти халәтенә кайта, үзенең: "малайлар, бу дөньяда без бер тапкыр яшибез, әлегәчә начар яшәмәдек, киләчәктә дә шулай булсын", дигән атаклы җөмләсен кабатлый.

Фәрваз алдап-йолдап, шомартып яши белмәде. Бәлки, теләмәгәндер. Беренче хатыны—мөлаем, ачык чырайлы, үткен телле Сания белән тату гына яшәп, бер кыз, бер малай үстерделәр. Шәһәр үзәгендә, иске таш йортта урнашкан иркен фатирларында бик күп татар язучылары, галимнәре әгъла өстәл, тәмле тел таптылар. Балаларын аякка бастыргач, гомер кояшы үрдән төшү ягына авышкач, тәнкыйтьчебез көтмәгәндә-уйламаганда яшь шагыйрәнең үзенә дә, лирикасына да гашыйк була. "Адәм баласының фани дөньяда кимендә ике тапкыр, шул исәптән минем дә сөяргә һәм сөелергә хакым бар", диде Фәрваз дус-ишләренең "тәртипкә" чакыруына җавап итеп. Күпчелек ирләр кебек ике ханымга да ярап яшәргә теләмичә, Фәрваз көйләнгән, җайлы фатирын гаиләсенә калдырып, икенче тормыш иптәше белән кеше өендә тора башлады. Ләкин кемнеңдер гайбәт сөйләгәнен, начар яктан абзыйны хөкем иткәнен хәтерләмим, андыйлар булмагандыр, дип уйлыйм. Киресенчә, язучылар, аерым алганда, үзе дә мондый хәлләрне башыннан кичергән кеше буларак, Р. Батулла ярдәм кулын сузарга ашыкты...

Инде шул мелодраматик вакыйгалардан соң да күпме гомер узган! Буесыны, күзләре, хәрефләрне басмача чыгарган язуы белән тач әтисен хәтерләткән олы кызы КДУның татар факультетында уңышлы укый. Фәрваз кебек милләтенә, әдәбиятка хезмәт итәр дигән өмет бар.

Фәрваз алтмышын тутыруга тыныч кына диярлек безне ташлап китте. Тормышка, матурлыкка, шигъри яңгырашлы сүзгә мөкиббән бу олы затның үлеменә дуслары, туганнары һаман ышанмый. Үзе дә соңгы сулышына чаклы китап нәшриятына эшкә чыгып, хыялларын тормышка ашыру өмете белән яшәде бит ул...

Үлем көтмәгәндә сырттан каптырып ала диләр... Татар әдәбияты өчен янып яшәүче, тәнкыйтебезнең бу асыл йолдызы белән чын-чынлап хушлашырга да өлгерә алмый калдык. Туган көнендә сагынып, юксынып, иртә киткәненә үкенеп искә алуларын белсә, Фәрваз дус үзенең мактау рәтендә йөрткән "нормальненко" сүзен теш арасыннан гына кысып чыгарыр иде.

Ул безнең йөрәктә, күңелдә яши. Рухы, җаны тыныч булсын мәшһүр тәнкыйтьчебезнең!

*Казан университетына 200 ел*



# Сәвия Михайлова

## РОССИЯ ХАЛЫКЛАРЫНЫҢ МИЛЛИ МИРАСЫ

**Автор турында кыскача мәгълүмат**

*Михайлова Сәвия Мөхәммәтдин кызы—тарих фәннәре докторы, Казан дәүләт университетының сәясәт тарих кафедрасы мөдире.*

*Ул Көнчыгыш, Европа һәм Себер төрки халыкларының тарихын, аларның рухи һәм сәяси культуралары формаларын, Шәрекъ дөньясын һәм Россия Көнчыгыш халыкларының мәгърифәтчелек үзенчәлеге мәсьәләләрен, хәзерге заманда милләтара мөнәсәбәтләр һәм милли мәдәниятләрнең үзара багланышлары проблемаларын өйрәнә.*

*Академик Сәвия Михайлова тарафыннан 150 дән артык фәнни хезмәт иҗат ителгән; шулар арасында "Идел буе татарларында мәгърифәтчелекнең формалашуы һәм үсеше" (1800—1861) (Казан, 1972), "XIX гасырда—XX гасыр башында Идел буенда иҗтимагый-сәяси фикернең торышы". /Р. И. Нәфыйгов белән берлектә (Казан, 1977), Россия Көнчыгыш халыкларының рухи мәдәниятендә Казан университеты" (Казан, 1991) монографияләре бар. О. Н. Коршунова белән берлектә тагын 4 монография яза (болар—"Милләтара мөнәсәбәтләрнең культурасы формалашу (Казан, 1996); "Идел буе халыкларының мәдәниятләре багланышы традицияләре" (Казан, 1997); "Культурология" (Казан, 1998); "Идел буе һәм Урал төбәге: күпмилләтле провинция мәдәнияте"./ Югары уку йортлары өчен уку әсбабы (Казан, 2001) дигән хезмәтләр).*

*Сәвия Михайлова Татарстан Республикасы ФАнең "Рухи культура һәм гуманитар белемнәрнең үсеше" дигән фәнни Советының рәисе; 1991 елдан ТРның атказанган фән хезмәткәре; 1994 елдан Халыкара Төрки академиянең академигы.*

Университетлар Европа цивилизациясе үсешендә һәм гомумән бөтен дөнья фәне формалашуда мөһим роль уйнап килделәр. Иске континент—Европа халыклары берләшүенең беренче адымнарында универсаль хокукый һәм дини мәдәниятнең үсешенә китергән үз институтлары һәм законуставлары барлыкка килә. Һәм шушы чорларда аларны таратуга юнәлтелгән кадрлар әзерләүче университетлар да үсеп чыга. "Университет" латиннан күчергәндә, "җыелма" дигән мәгънәне аңлата, ягъни университетлар укытучылар һәм студентларның уртак корпорациясе буларак төзелә. "Университет" термины XIV гасырда Германиядә канунлаша. В. Даль сүзлегендә университет барлык төр фәннәр буенча беренче баскычлы югары уку-укыту йорты буларак билгеләнә.

XX гасырга университетлар турында дәүләт химаясеннән-күзәтчелеген-

нән азат булган, фәннәрнең барлык тармакларын да ирекле укытуны тәэмин итүче һәм үстерүче һәм тыңлаучыларына үзидарә һәм укытылачак фәннәрне сайлап алуда һәм шул ук вакытта шәхси үсештә дә киң мөмкинлекләр бирүче югары уку йорты диген караш урнаша *(Милюков П. Университеты в России. / Энциклопедический словарь. Брокгауз Ф. А., Ефрон И. А.— Т. XXXIV.—СПб., 1908.—С. 751).*

Университетларның иҗтимагый-культура функцияләре озак вакытлар тотрыклы булган. Яшәешләренең башлангыч чорында укыту теле "латинча" булып, дине буенча христиан культурасын һәм канунлашкан Рим папасы—Ватикан хакимияте идеяләрен тараталар. Мондый типтагы беренче уку йортлары XI гасырда һәм XII гасыр башында Италиянең төньягында (Солерно һәм Болоньяда) барлыкка киләләр. XII—XIII гасырларда Англиядә аксөякләр өчен атаклы Оксфорд (1150 еллар тирәсе) һәм Кембридж (1209) университетларына нигез салына. 1215 елда исә Париж Университеты ачыла. Беренче славян университетлары Краковта (1368) һәм Прагада (1348) ачыла. 1385 елда Гейдельберг һәм 1388 елда Кельн университетлары ишекләрен ачалар. XV гасырда Европада барысы алтмыш университет исәпләнә.

Көнбатыш университетларының культура язмышы да парадоксаль: Сорбонна, Болонья, Оксфорд һәм Кембридж университетлары, фәнни тикшеренү үзәгенең чәчәк ату синонимы булып хисаплансалар, баштарак "ересь" белән—хөкем сөрә торган диннең кагыйдәләренә каршы килә торган тәгълимат белән көрәшергә тиеш булалар. Урта гасырларда өстенлек иткән укыту алымы—диспутлар системасы җәмгыять үсешендә интеллектуаль башлангыч стимулы булып торалар һәм шул ук вакытта компромисска ирешү сәнгате белән тәгаенләнгән сәяси культура формалашу алымы булып хезмәт итәләр.

Россиядә университетны ачу XVIII йөздә милләтнең культура үсешен "вестерн", ягъни Көнбатыш нигезендә үзгәртеп кору башлангач кына мөмкин була. XVIII йөзнең чорлар панорамасындагы урынын Ю. М. Лотман: "XVIII гасыр культурасы ул—безнең беренче нигезебез; аңа кабат-кабат әйләнеп кайту, аны бөтенләй башкача күзалларга омтылу, безнең аңлавыбызча, алга таба хәрәкәт итүнең беренче адымы",—дип билгеләп үтте. Әйе, үзенең рухы белән кадимилеккә каршы торган һәм башлангыч уку дәреслекләре хәзерләү белән тыгыз бәйләнгән укыту системасының беренче типологик төсмерләре нәкъ менә XVIII гасырларда формалаша. Университетның пәйда булуы культура өлкәсен һәм мәгарифнең офыкларын гына киңәйтеп калмый, ә бәлки тулаем рухият һәм җәмәгатьчелек тормышына да яңача факторлар өсти.

Университетларны ачу һәм идеологик яктан гамәлгә ашырып чыгу Петр I үткәргән реформалардан соң тәгаенләнә. Россия дәүләте өчен нәкъ менә шушы хәлиткеч чорда мәгариф системасының эше дәүләткүләм мөһим чаралар дәрәҗәсенә күтәрелә, ә гыйлемгә ия булу һәр дәүләт түрәсенә дә, гади бер гражданга да, ватанпәрвәр шәхескә дә абруйлы сыйфатларның берсе булырга тиеш диеп куела. Россиядә, шул рәвешле, фән император Указы нигезендә киң җәелдерелә. Университет ачу мәсьәләсендә Петр I Лейбниц һәм Вольф белән язышып тора, Ф. Салтыков һәм П. Курбатов белән киңәшләшә. Алар императорны булачак белгечләрне чит илләргә җибәрү бәрабәренә үз университетыбызны ачу кирәклегенә басым ясап әйтәләр.

Университетларны ачуда император сайлаган юл анык һәм тормышчан, төптән уйланылган концепцияләргә нигезләнә. Аларда фәннәр академиясе, университетлар һәм гимназияләр бердәм чылбырның буыннары итеп карала; академиклык белән профессорлык дәрәҗәсен бергә алып тору күздә тотыла; фәнни эшчәнлекне фәнни агарту һәм мәгърифәтчелек белән бергә алып бару кире кагылмый. Менә шуңа күрә дә Сенатның университет һәм гимназия "комитетында" Академия оештыру турындагы (1724 ел, 28 гыйнвар) карары Россия университетлары тарихында һәрвакыт өйрәнелергә тиешле законлы акт булып исәпләнергә хаклы.

Петр I башлангычын гамәлгә ашыру кайчак кызыклы хәлләр дә китереп чыгара. Әйтик, унжиде чит ил профессорларын тынлаучылар бөтенләй булмый, алар бер-берләренең лекцияләрен тынларга йөрергә мәҗбүр булалар. Тарихка беренче студентның исем-фамилиясе дә теркәлеп калган, ул—Филипп Анохин атлы берәүсе. Аннары, тел аерымлыгы, тәҗрибә булмау, абитуриентлар җитешмәү, ул чордагы дворяннар тоткан мәсләк, уку-укытуның гомуми торышы һәм тагын кайбер сәбәпләр император башлангычына "таяк тыгып" киләләр. Шулай да Россиядә Петр I үткәргән реформалардан соң мәгариф өлкәсендә дә билгеле сәясәт үткәрү төсмерләнә башлый.

1755 елның 12 январендә Мәскәү университеты ачылу Россия мәдәнияте тарихында билгеле бер эз калдырган вакыйга. И. И. Шувалов һәм М.В. Ломоносовның актив тырышлыгы нәтиҗәсендә ул немец университетларының алдынгы традицияләренә нигезләнә. Университет тормышының әһәмиятле шушы ягын билгеләп үтеп, М. Ломоносов О.К. Тредиаковскийга болай дип яза: "Университет һәм академия чит илләренекенә охшаш нинди дә булса өстенлек вә ирек ала алсалар бу бердә начар булмас иде; аерым алганда, алар полиция күзәтүеннән азат ителерләр иде".

Яңа университетлар пәйда булу белән бергә яңа ритуаллар да барлыкка килә. Студентлыкның символы булган шпага тагып йөрү белем алуның дәүләти әһәмиятен билгеләп тора: ул дәүләт хезмәте белән тиңләштерелә. Укытудагы ярышучанлык принцибы үзара үткәрелгән диспутларда гамәлгә ашырыла. Беренче университетның җәмәгатьчелек аңына ясаган шифалы йогынтысы турында университет директорының улы, затлы нәселләр өчен ачылган пансионны һәм Геттенгин университетын тәмамлаган Н. И. Тургенев та язып калдыра. Ул Мәскәү университетын тәмамлаган студентларның югары әхлакый сыйфатларга ия булуларын "хәзер сирәк очрый торган зыялылык, затлылык, намуслылык кебек сыйфатларның дәүләт хезмәтендә дә чагылыш табуын билгеләп үтә" *(Тургенев Н. И. Россия и русские.—М.,—2001. —С. 308).*

Мәскәү университеты төзелгәннән соң яңа университетлар ачу озак вакытларга онытылып торыла. Училищеларны оештыру комиссиясе проектында (1786—1787) Псковта, Черниговта һәм Пензада университетлар ачу кирәклеге күрсәтелә *(Росссийский государственный исторический архив Российской Федерации (алга таба: РГИИ РФ), ф. 730, оп. 1, ед. хр. 86; оп. 2, ед. хр. 5, 6.).*

Мондый планнар дворяннар җәмгыятендәге теләкләргә туры килеп бетми; ул чакта югары катлам вәкилләре чит ил университетларында белем алырга омтыла, ә күпчелек хәрби карьера һәм өйгә килеп укытучылар хезмәте белән канәгатьләнә. Дәүләт мәктәбе укытучылары—мәгърифәтнең төп фигурасы асылда хәерчелектә җан асрый, халык мәктәбенең дә хәле мөшкел була. Укытучылар мәктәпкә күп очракта яланаяк, теләсә нинди сәләмә киеп йөриләр. Шул чорлардагы бер укытучының төс-кыяфәте сакланып калган. Кышын да, җәен дә ул бер үк бишмәт киеп йөргән, йон оекбаш урынына аягын кәгазь белән ураган. Аның үлеменнән соң, билгеле, гаиләсе сукыр бер тиенсез калган *(Георгиева Т. С. История русской культуры.—М., 1998.—С. 195).*

Мондый хәлләр, монархия традицияләре белән катлауландырылу сәбәпле, университетлар ачу, аларда үзидарә урнаштыру бик авыр эшкә, күп газапларга мәхкүм ителгән башлангычка әверелә. Яңа университетларны ачу кадрлар җитмәү белән тагын да катлаулана төшә. Александр I хакимлек иткән дәвердә түләүсез һәм сословиеләргә бүленгән гимназияләр системасы барлыкка килгәч кенә университетларның саны арта башлый. 1809 елда утыз ике гимназиядә латин, алман, француз телләре, тарих, география (статистика, дәүләт төзелеше турында өйрәтмәләр), нәкешь сәнгате, сәяси икътисад, теоретик һәм гамәли математика, табигый фәннәр, коммерция һәм техник фәннәр башлангычы укытыла. Аерым гимназияләрдә "предметлар" тагын да күбрәк кертелә. Гимназистларга—димәк, булачак студентларга фәннәрнең болай күп укытылуы университетлар челтәрен

тагын да киңәйтергә мөмкинлек бирә.

Александр I нең новаторлык башлангычларының бер өлеше булган университет мәгариф системасын торгызу идеясе немец моделен кабул итүне күз алдында тота. Аның характеристикалары, үз чиратында, тамырлары белән урта гасыр Европа традицияләренә килеп тоташа. Хәлбуки, Россия, үзенең үзенчәлекле тарихи тәҗрибәсенә таянып һәм җәмгыять, һәм башка дәүләт мөнәсәбәтләре арасында башка төрле алгоритмнар хөкем сөргәнлектән, бу мәсьәлә үзенчәлекле хәл ителә. Университет автономиясенең авырлык белән аякка басуы культура-мәдәни катламның "юка" булуы белән дә аңлатыла. Укытуда ирекле профессорлар составының аз санлы булуы, тыңлауда ирекле—студентларның мөстәкыйльлегенә ышанып җитмәве белән тагын да авырлаша төшә.

Яна традицияләрне үзләштерү культура өлкәсендә Европа йогынтысы көчле булган Россия башкалаларында чагыштырмача җиңел барса да, провинцияләрдәге университетлар үсеш юлларында зур каршылыкларга дучар була.



*Казан университеты ачылу турындагы документ.*

Европадагы "кардәшләреннән" күпкә соңрак пәйда булган Россия университетлары бөтендөнья университет тәҗрибәсен үзенчәлекле традицияләр белән баеталар. Гражданлык җәмгыятьләре институтының тулы бер системасына бәйле Көнбатыш университетларыннан аермалы буларак, Россия университетлары илнең тулаем социаль-мәдәни үсешенә юнәлеш һәм импульс бирү чыганагына әвереләләр. Танылган рус галиме, Казан дәүләт университетында тәрбияләнгән А. Н. Бекетов университетларның ил цивилизациясе үсешенә күп тармаклы һәм тирәнтен йогынты ясарга сәләтле булулары хакында болай дип яза: "Россиянең университетлы шәһәрләре чүлдәге оазислар кебек сибелгәннәр".

Россия университетлары, чит илләрнекеннән аермалы буларак, күп кенә аерымлыкларга ия була. С. М. Степняк-Кравчинский билгеләп үткәнчә, "рус университетлары аерым үзенчәлекле һәм бөтенләй гадәти булмаган урын алып торалар. Башка илләрдә университетлар—укыту йортлары гына, башка бер нәрсә дә түгел", Россиядә исә университетлар һәм гимназияләр сәяси тормышның "иң давыллы һәм ялкынлы" үзәкләре булып торалар *(Степняк Кравчинской С. М. Россия под властью царей.—М., 1964.—С. 242)*. Университетларны тирәннән үзгәртеп коруны "фикер хөрлеге һәм сүз иреге мәсьәләсен хәл итү"дә күргән профессор Н. И. Пирогов бәяләмәләре дә моңа аваздаш булып тора. "Барыннан да бигрәк фәннең бәйсезлегенә ирешергә кирәк",—дип тирәнтен анализ белән сүзен җөпләп куя танылган медик-галим *(Пирогов Н. И. Избранное сочинение.—М., 1953.—С. 353)*.

Университет чынбарлыгын илнең сәяси үсешендә хәлиткеч әһәмияткә ия булган 1812 елгы Ватан сугышыннан, чит илләргә ясалган хәрби походлардан, декабристлар хәрәкәтеннән, крепостное правоны бетерү кебек һ. б. вакыйгалардан аерым карап булмый. Ватан сугышы яшәү рәвешендә гражданлык һәм патриотик мотивларның киң колач алып җәелүенә китерә. Шәхеснең һәм аерым гражданның табигый хокукларын яклау фикерләү рәвешенең төп предметына әверелә. Иҗтимагый үзгәрешләр, яңа либераль һәм радикаль хәрәкәт-башлангычларның беренче яралгылары башлыча шулай ук университетлар мохитында үсеш ала, һич югы яклау таба һәм идея өслүбенә төрелә.

Мондый хәл, әлбәттә, яшьләрнең социаль категория буларак формалашу

үзенчәлекләренә бәйле. “Безнең ватаныбызның иң якты өметләре университетларга тупланган,—дип кистереп яза Д. И. Писарев,—алар гамәли-көндәлек тормышка якты намуслы омтылышлар, яңалык алып керә, һәр тармак төрле искелеккә рәхимсез көрәш уты ача” *(Писарев Д. И. Соч. в 4 т.—Т. 2.—М., 1955,—С. 214).*

Мәмләкәтнең университет системасы ныграк үсеш алган саен, фән белән мәгърифәт иҗтимагый аңның алдынгы карашларын чагылдыра башлый. Моның төп сәбәбе шунда ки, режимның нигезен тәшкил иткән традицион хәрби-түрәлек ныгытмасы—дворянлык—сословиегә бүленгән ябык уку йортларында белем бирүгә корылган була. Аннары уку-укыту, шөгыль буларак, идарәчел, өстен катлам вәкилләре арасында бик үк яклау да тапмый. Нәтиҗәдә, университетлар дворян булмаган катламнар арасында шөһрәт казана: чөнки алар демократик рухны чагылдыралар һәм шул рухны үзләренә сеңдергән булалар.

Россиядә университет системасының икенче бер үзенчәлеге булып, аның башта ук дәүләтнеке буларак формалашуы тора. Бу нисбәттән ул Европа һәм Төньяк Америка университетларыннан һәм дини корпорацияләргә буйсынган университетлардан аерылып торган. Моннан тыш, Көнбатышта XIX гасыр ахырына кадәр университетларда дини факультетлар мәҗбүри саналган. Хәлбуки, Россия университетларында, Дерпт һәм Веленск университетларыннан кала, уку-укыту программасына дин өйрәтмәләре кертелүгә дә карамастан, мондый факультетлар беркайчан да булмаганнар. Шулай да, “мәгариф консерватизмыннан азат булмауга карамастан, университетлар “укымышлылык оясына” *(А. Герцен)*, Россиянең сәяси һәм мәдәни тормышындагы барлык әһәмиятле үзгәрешләрнең башлангычына әвереләләр.


*Казан университетында 1827-46 елларда ректор булып эшләгән атаклы галим Н.И. Лобачевский.*

Шул рәвешле, Россия университетларына җәмгыятьне алга җибәрү функциясе йөкләнә. “Өстән һәм астан, көньяктан һәм Себердән килгән чуар холыклы яшьләр бик тиз арада иптәшләргә-кумәклеккә берләшәләр,—дип язды Герцен.—Бездә иҗтимагый аерымлыклар Англия мәктәпләрендәге һәм казармаларындагы кебек мыскыллы мөнәсәбәтләр төсен алмыйлар; мин монда Англия университетлары турында сүз алып бармыйм, алар баштан ук аксөяк һәм байлар катламы өчен тәгаенләнгәннәр”.

Югарыда күрсәтелеп үтелгән үзенчәлекләр Россиядән чыккан студентларның барлык Европа югары уку йорты үзәкләрендә белем алуы кебек фактлар белән бергә яшәп киләләр. Һәм әйтергә кирәк, Александр I үткәргән реформалар нигезендә Россия белән Европа арасында фәнни арадашлык урнаштырыла. Югары катлам дворян даирәләрендә тагын йөз елга якын, Россия университетларын тәмамлаганнан соң, укуын Европа университетларында дәвам итү тәҗрибәсе яшәп килә.

Россия студентларының Көнбатыш Европа университетларында уку традицияләренең көчле булуы хакында 1845 елда Императорның “Фәнни белемнәрен арттыру өчен чит илләргә китүче яшьләрнең хокуклары хакында”гы Указның пәйда булуы да сөйли. Европа югары йортларында белем алучы дәүләт стипендиантлары да, шулай ук шәхси кешеләр дә 1861 елгы реформага кадәр хөкүмәт күзәтчелегендә торганнар. Күзәтчелек режимы йомшару белән чит илләрдә белем алырга теләүчеләр саны күбәя төшә. Әмма бу вакытта Россиянең үзендә дә университетлар челтәре барлыкка килә. Александр I патшалык иткән дәвердә мәгърифәт яхшылык һәм ирек тарату чыганагы буларак исәпләнә. Нәкъ шушы чорда илнең

фәнни үзәкләре барлыкка килүгә алшартлар туа.

Яңа университетлар ачу урыннары тиз генә тәгаенләнми: 1803 елның 24 гыйнварында кабул ителгән "Халык мәгърифәтенең башлангыч кагыйдәләре" Казан, Санкт-Петербург һәм Харьковтан соң Киев, Тобольск, Великий Устюг шәһәрләрендә дә университетлар ачуны күздә тота, ләкин бу тулаем гамәлгә ашырылмый кала. Мәгълүм булганча, Казан университеты империянең галәмәт зур киңлекләргә җәелгән көнчыгыш биләмәләре белән идарә итү нәүбәтеннән чыгып ачыла һәм аның язмышы Россиянең нинди милли сәясәт алып баруына турыдан-туры бәйләнгән була. Монда өстәп шуны әйтергә кирәк, Казан губернасы үзенең оешу чорында (1708) Россиядә ин зурлардан исәпләнә. 1755 елда яңа административ бүленеш нәтиҗәсендә аннан Сембер, Самара, Әстерхан һәм Пермь губерналары аерылып чыга. Әмма моннан соң да әле Казан губернасы Россиянең көнчыгышында сәүдә-икътисади, сәяси һәм мәдәни үзәк буларак хезмәт итеп килә. 1763 елны ревизия мәгълүматларына караганда, бу губерна халкы сан ягыннан, Мәскәү губернасыннан кала, өченче урынны алып тора *(Арсеньев К. Статисческие очерки России.—СПб., 1948.—С. 2-7)*.

Тулаем алганда, XVIII гасыр ахырларында—XIX гасыр башында Идел буе Россиянең Көнчыгышка үтеп керү сәясәтендә үзәк урынны алып тора. Нәкъ менә шушы өлкәләрдә үзәк үткәргән дини һәм милли сәясәтнең төп юнәлешләре эшләнә. Әйтик, 1818 елның 1 гыйнварына Казан губернасында яшәүчеләр саны 1,5 млн.га җитә, шуларның 450 менен татарлар, 615 меңен руслар, 330 меңен чуашлар, 85.229 ын марилар, 23.697 ен мордвалар һәм удмуртлар тәшкил итә *(Лаптев М. Материалы для географии и статистики, собранные офицерами Генерального штаба Казанской губернии.—СПб., 1861.—С. 153, 162, 214)*.

Озак вакытлар Россия һәм Көнбатыш җәмәгатьчелеге Шәрекъ белән өстән-өстән генә таныш була һәм Шәрекъне өйрәнү белән, нигездә, аерым белгечләр генә шөгыльләнә. Казанның Шәрекъне өйрәнүче белгечләре иҗтимагый анда Шәрекъкә карата булган карашларны үстерү-яңартуда үзләреннән лаеклы өлеш кертәләр.

Университетларның көндәлек тормышына хөкүмәтнең шәркый сәясәте дә зур йогынты ясый. Россиянең геополитик урнашуы Ватан цивилизациясен үстерү өчен колонизацияләү сәясәте алып баруга этәрә. Шул рәвешле, Шәрекъкә "ымсыну" тышкы сәясәттә, әйтеп үткәнебезчә, Себерне һәм Урта Азияне "үзләштерүгә" кайтып кала. Икенче яктан, "мәдәниләштерелгән абсолютизм" сәясәтенең либераль алгарышлары булуга да карамастан, XVIII гасыр ахырына көнчыгыш халыкларының реаль социаль-хокукый халәте һаман да тигезсез булып кала бирә. Әйтик, Екатерина IIгә җибәрелгән хатында Казан адмиралтейство конторасы татарлар турында болай дип хәбәр итә: "Оные иноверцы, яко безгласный народ, приходят в бедность и разорение, и хотя они, мурзы и татары, по тем своим делам и весьма были неповинны,... но никогда правыми быть не могут" (*Сборник Россияского исторического общество.—Т. 43.—СПб., 1885.—С. 65)*.

Россиянең ислам дөньясына, ягъни көнчыгышның мәдәни дөньясына ташламалар ясау сәясәте үткәрү Идел буе һәм Урал төбәкләрендә социаль-сәяси хәлнең катлаулылыгы белән генә түгел, ә бәлки Себерне, Казакъстанны һәм Урта Азияне яулап алу бурычлары белән дә бәйләнгән була. Госманлылар империясе белән көрәш алып бару мәсьәләсе дә һәрвакыт үзен сиздереп килә. Екатерина IIнең Россия буйлап ясаган сәяхәтендәге (1767) Казан этабы да шушындый тышкы сәясәт мәнфәгатьләреннән чыгып бәяләнергә тиеш.

Тышкы сәясәтнең Европа һәм Азия башлангычларына бәйлелеге университетлар сәясәтен дә билгели. Университетлар системасында социаль-культура мәсьәләләре дә чагылыш тапмый калмый, әлбәттә. Башлангыч чорда "Европага йөз тоту" өстенлек итә. Ләкин әкренләп, Россия чынбарлыгының һәм аңа гына хас мәдәни багланышларның йогынтысы

нәтиҗәсендә ул үзенчәлекле формалар ала. Мәскәү университеты төзелүгә багышлап үткәрелгән юбилей көннәрендә профессор С. Шевырев "Россия университетлары немецларның фәннәрне фәлсәфи-системага салып тирәнтен өйрәнүгә корылган абстракт фикерләүләрен генә түгел, ә бәлки французларның, инглизләрнең һәм шведларның практик-гамәли нигезләрен дә кабул иттеләр" дип билгеләп үтә.

Илнең университетлар тарихында, шул исәптән, Казан университеты тарихында да, немец милләтеннән булган укытучылар аерым урын алып торалар. Аларның XVIII гасыр ахырында Россиягә күпләп күченеп килүләре илнең мәгърифәт һәм аграр өлкәсендә сизелерлек эз калдыра. Идел буенда, Саратовтан ерак түгел, нигездә немецлардан торган барлыгы 23 мең кеше яшәүче йөздән артык колония исәпләнә. XX гасыр ахырында Россиядә ике меңнән артык немец торак урыннары теркәлә. Тулаем алганда, немецлар Россиядә сан ягыннан сигезенче урынны алып торган этник группаны берләштерә *(Немцы России: Энциклопедия. Т. 1.—М., 1999.—С. 10)*.

Яңа университетларга чит ил профессорларын укытырга чакыру да яңа мәшәкатьләр өсти. Немец укытучылары үзләренең хокуклары саналган нәрсәләрне бозу белән килешмиләр. Аларның иң хәзерлеклеләре университетлардан китә яки шәхси мәнфәгатьләрен кайгыртып яши башлый. Профессор Д. Карсаков сүзләренә караганда, XIX гасырның икенче яртысында Казанда "галим-голәмәнең немец формациясе" моделе "немец академик схоластикасының үлеп баручы абстракт-фәлсәфи калдыгын" тәшкил итә. 40 елларда математика факультетыннан кала, барлык факультетларда да немецларның өстенлек алуы турында Э. П. Янишевский да язып уза. Немец укытучылары "русча бик тә начар сөйләшәләр һәм башка сыймаган ахмаклыклар белән аерылып торалар" *(Янишевской Э.П. Из воспоминаний старого Казанского студента.—Казань, 1893.—С. 39)*. Икенче яктан, немец профессорлары һәм укытучылары тырышлыгы белән студентлар Европаның күмәк культурасы белән танышалар һәм, үз чиратында, Гейдельберг, Мюнхен, Берлин һ. б. шәһәрләрдән килгән җырларны өйрәнәләр. Студентларның мондый фольклор үрнәкләре рус теленә тәрҗемә ителәләр һәм рус холкына яраклаштырылалар. *(Карсаков Д. А. Былое из жизни Казанского университета 1856-1860 гг. // Былое университетской жизни: Литературный сборник к 100 летию Императорского Казанского университета.—Казань, 1904.—С. 168, 141)*.

Россиядә университетларның "Евразия" төсмере җәмгыять белән университетлар арасындагы үзенчәлекле мөнәсәбәт аша да билгеләнә. Баштарак яңа уку йортларына, кагыйдә буларак, һич югы урта мәктәпләрдә укытучы булып эшләргә теләгән яшьләр килә. XIX гасыр башында дәүләт хезмәтенә яшүсмерләр 15-16 яшьләрдә үк алыну сәбәпле һәм университетта укулар соңрак башланганлыктан, дворяннар балаларын университетта укырга бирмәгәннәр диярлек. 23-24 яшьләрдә дворяннар хәрби баскыч буйлап үрмәләп, гражданлык хезмәтендә дә югары дәрәҗәгәирешкәннәр. Шулай да әкренләп мәгърифәткә караш үзгәрә төшә һәм университет белеме алу да җәмгатьчелекнең төрле катламнарында уңай күренеш буларак бәяләнә башлый.

Университет сәясәтенә шулай ук бюрократик чынбарлык һәм тормыш ихтыяҗлары да билгеле бер йогынты ясый. XIX гасыр башына кадәр Россиядә түрәләр өчен белем "цензы", ягъни махсус белемгә ия булу мәҗбүри итеп куелмаган була. Ләкин Александр I хакимлек иткән чор башында билгеле бер алга китеш сизелә башлый. "Училищеларны торгызу турында"гы 1803 елның 24 гыйнвар Указында биш елдан соң аны тәмамлау турында таныклык күрсәтмәүчеләр хөкүмәт эшенә алынмыйлар дип кисәтелә. М. М. Сперанскийның илне үзгәртеп кору планын гамәлгә ашыру да укымышлы түрәләр хәзерләүне таләп итә. 1809 елның 6 августы Указы нигезендә түрәләр VIII класс (коллежский асессор) һәм V класс (статский асессор) дәрәҗәләрен алу өчен нинди дә булса Россия университетын тәмамлау турында таныклыкка ия булырга тиеш булалар, әгәр таныклыклары

булмый икән, нинди дә булса университет каршындагы махсус комиссиягә рус теленнән, берәр чит телдән, табигать белеменнән, арифметикадан, географиядән, физикадан, гомуми һәм рус тарихыннан, Рим, гражданлык һәм жинаять хокукыннан имтихан тапшырырга тиеш булалар *(Ерошкин Н. П. Крепостническое самодержавие и его политические институты. (Первая половина XIX века).—М., 1981.—С. 69)*. Бу проектның ачы язмышы күптән мәгълүм нәрсә...

XIX гасыр дәвамында университетларның роле һәм җәмгыятьтә тоткан урыны зур үзгәрешләр кичерә. Бу Казан университетына да кагыла. Катлаулы торгызу чорын кичереп, XIX гасырның 20 елларына ул җитлегү чорына керә һәм иҗтимагый көчләр хәрәкәтенең үзәгенә әйләнә. Гасыр ахырына инде ул Россия халыкларының үзенә күрә мәдәни мәркәзе ролен үти башлый.

Фәнни эшчәнлеге буенча XIX гасырның 20-60 елларына Казан университеты алдынгы урыннарга чыга һәм башкала университетларыннан калышмый диярлек. "Мәмләкәт мәгарифенең учагы" булган Мәскәү университетының 100 еллык юбилее уңае белән Казан университетыннан җибәрелгән истәлек хатында барыннан да бигрәк ватанның лөгатен, тарихын һәм закон төзелешен өйрәнүдәге уңышлары билгеләп үтелә *(Столетный юбилей императорского университета.—М., 1855.—С. 26)*. Казан университеты XIX гасырның беренче яртысында математика, химия, астрономия һәм Шәрекъне өйрәнү буенча үзәккә әйләнә, Казан галимнәренең математика, физика, астрономия һәм лингвистика буенча ясаган ачышлары бөтендөньяда танылу ала.

Күп кенә күренекле галимнәр Казан университеты Советының мактаулы әгъзалары итеп сайлануларын зур хөрмәт күрсәтү дип кабул итәләр. Университет Советының мактаулы әгъзалары булып XIX гасыр башында принц Иоган Саксонский, Саксония корольлеге министры, Зееберг обсерваториясе директоры барон Линденау торган. Француз галиме Брегет Казан университеты әгъза корреспонденты булып хисапланган (XX гасыр ахыры—XXI гасыр башында Швейцариядән Нобель премиясе лауреаты Карл-Алекс Мюллер (1998), Гиссен университеты профессоры, икътисадчы Бонет Арман (2001), медицина буенча белгеч Хайнц Бауэр (1994), инглиз физигы Фидаин Блинн Бребис (1994) Казан университетының чит илләрдәге мактаулы әгъзалары булып торалар). Гасырлар алмашынган чорда Казанда химик А. М. Зайцев, медик Е. В. Адамюк, Шәрекъ белгечләре И. Ф. Готвальд һәм Бодуэн де Куртенэ да мактаулы әгъза булып сайланганнар. Бу мактаулы исемгә ватанның Лев Толстой, Дмитрий Менделеев, А. П. Карпинский, К. А. Тимирязов, И. И. Мечников, Н. Е. Жуковский, А. С. Фоминицын, А. М. Ляпунов кебек күренекле галимнәре һәм мәдәният вәкилләре дә лаек булалар. Соңрак Складовская Кюри, Макс Планк, Д. Рэлей кебек галимнәр һәм язучылар лаек булалар.

Казанның Шәрекъне өйрәнү мәктәбенең—ориенталистиканың тарихы еракларга барып тоташа *(кара: Казан утлары, 2002, N 12)*.

Россиядә Көнчыгыш телләрен һәм көнчыгыш халыкларының тормышын өйрәнү кирәклеген беренче булып Петр I күтәреп чыга. Миссионерлык, сәүдә һәм геополитик гоманлаулар 1700 елның 18 июнь Указы тууда сәбәпче булалар һәм Указ нигезендә Себер митрополитына Тобольскида кытай һәм монгол телләрен өйрәнүче монахлар табу-тәрбияләү бурычы йөкләнә. XIX гасырның беренче дистә елларында мәмләкәтнең ориенталистика фәне берничә үзәккә туплана. Алар арасыннан Лазарев институтын һәм Мәскәү университетын, Казан университетын, Рухани академияне һәм гимназияне, Тышкы эшләр министрлыгы университетын, Азия департаментын һәм Петербургның Азия музеен, Одессадагы Ришелье лицее каршындагы Көнчыгыш институтын, Харьков университетын күрсәтергә мөмкин. Мәскәү университетында көнчыгыш телләрне укыту ара-тирә генә алып барыла. Беренче булып "яһүдиләр Библиясен" һәм гарәп телен А.В. Болдырев укыта башлый.

Фән буларак Көнчыгышны өйрәнү Казан дәүләт университетында XIX гасырның беренче чирегендә чәчәк ату чорын кичерә. Бүгенге югарылыктан торып караганда, без XIX гасыр ориенталистика фәне көнчыгыш халыкларын, социумнарны һәм культураларны адекват кабул итүгә үзеннән зур өлеш кертте дип әйтә алабыз. "Көнчыгышка игътибар белән караган бер генә кеше дә моны көяз, тәкәббер Көнбатыш үзе дә хәл итә ала дип әйтергә җөрьәт итмәс иде",—дип билгеләп үтә XIX гасыр көнчыгыш белгече А. Васильев. Фәннәрнең хәзерге бүленеше буенча бу өлкә белән имиджеология шөгыльләнә. Фәннең бу тармагы һәркайсы кешенең җирдәге тормыш стратегиясен генә түгел, ә бәлки галәм, космос моделен дә кертеп, цивилизацияләр арасындагы үзара нечкә бәйләнешләрне да анларга мөмкинлек бирә *(Россия и Европа в XIX-XV веках: Проблемы взаимного восприятия народов социумов, культур.—М., 1996.—С. 13).*

Казан көнчыгышны өйрәнүчеләренең бу юнәлештәге эшчәнлеге тагын шунысы белән илтифатка лаеклы, чөнки XIX гасырда Көнбатышның массакүләм аңы Россиядә аң-белемнең торышы, Россия халыкларының тормышы турында бик тә соры, өзек-өзек мәгълүмати калыплардан гыйбарәт иде. XIX гасыр ахырында чит ил матбугаты тәкъдим иткән стереотипларны "Волжский вестник" газетасы хәбәрчесе Молчанов китереп үтә. Аның чит ил басмаларын күзәтүдән ясаган нәтиҗәләре түбәндәгедән гыйбарәт: "Түбән Новгородта православие соборлары белән рәттән мәчетләр һәм әрмән чиркәве басып тора икән; Чабаксар—чирмешләр башкаласы... Казанның татар халкы көчләп чукындырылган" икән *("Волжский вестник".—1887, N 239).*

Казан ориенталистика мәктәбе яңа традицияләргә нигез сала һәм шуның белән чит илләрдә дә танылу таба. Казан ориенталистларының эшчәнлеге дөнья ориенталистикасы кулланган чыганаклар мохитен киңәйтеп җибәрә, Шәрекънең рухи һәм мәдәни-тарихи кыйммәтләренең гаҗәеп бай булуын дөньяга танытуга һәм раслауга күп көч куя.

Хәзерге вакытта глобаль масштабларда дини һәм милли үзбилгеләнү мәсьәләсе халыкларның үзаңында аеруча кискенләшкән бер заманда Россия туплаган тәҗрибә аерым игътибарга лаек. Географик һәм геополитик мәсьәләләр, дини ышанулардагы аерымлыклар, дәүләт үткәргән милли сәясәт һәм гасырлар дәвамында этник бәйләнешләрдәге традицияләр шул факторларны билгели дә инде. Татар халкына үзенең көнчыгыш тамырын саклап калырга гына түгел, төбәкнең башка этник төркемнәренә дә мәдәни йогынты ясарга туры килгән.

Идел буе һәм Урал төбәгенең рус булмаган халыкларының көнкүрешендәге охшашлык, тәңгәллекләрне билгеләп, XIX гасыр тарихчысы С. А. Ташкин болай дип күрсәтә: "Әгәр бер халыкның икенчесенә тәэсир итү көчен тикшерә башласаң, бу русларга түгел, башка халыкларга килеп тоташа". Дини эзәрлекләүләргә дучар ителгән татар мәдәнияте, ә ул XVIII гасырда бигрәк тә дәһшәтле төс ала, күпмедер күләмдә шәрекъ-мөселман компонентлары белән өретелгән үзенчәлеген дә саклап кала килә. XIX гасыр ахырына менә шулар Идел буе—Урал төбәгенең мәдәни хасиятләрен барлыкка китерә. Бу процесста Казан университеты билгеле бер роль уйный. Шул рәвешле, Казан университетының социаль-мәдәни үзенчәлеген өйрәнү, гомумән татар мәдәниятендә Казанның нинди урын тотканлыгын билгеләргә ярдәм итә. Аны Россиядә яшәүче башка халыкларның үзара аралашып яшәү концепциясеннән аерып карап булмый.

Мәгълүм ки, рус һәм татар культураларының мәдәниятләре бәйләнешының бер чиген Россиядә зыялы ыруларның килеп чыгышы мәсьәләсе билгели. Россиянең күп кенә культура, әдәбият һәм фән вәкилләренең генеологик тамыры татарга килеп тоташа. Алар арасында Менделеев, Мечников, Павлов, Достоевский һәм Тургенев, Арцибашов һәм Булгаков кебек мәгълүм титаннар да бар *(Карташев. М. Д. Русь и татары.—Арабески истории. Кн. 1, М., 1999).* Генеалогик аралашуны тәшкил итүчеләрнең күп кенә вәкилләре Казанда яшәгәннәр. Бу спектрны тутырып торучы көнбатыш өлешенең

күпчелеген немецлар, поляклар һәм французлар һәм аларның оныклары тәшкил итә. Мондый сюжетлар Казан университеты тарихында менә инде ике гасыр дәвам итеп килә.

1917 елга кадәр Казан университеты Идел буе, Урал төбәге һәм Себер халыкларының мәдәниятендә, мәгарифендә һәм фәнендә үзәк урынны алып тора. Бу роль 1917 елдан соң да зур була. Шул рәвешле, Казан университеты өчен аның тарихының һәм социокультура миссиясенең Евразия компоненты мәсьәләсе дә үзәккә килеп баса.

Бу теманың чишмә башы XIX гасырга барып тоташа. Шушы дәвер эчендә төрле юбилейларга һәм иҗтимагый вакыйгаларга багышланган беренче мәкаләләр дә күренә *(Иконников В. И. Русские университеты в связи с ходом общественного развития. // Вестник Европы, 1876, N 9—11)*. Тулы бер эпоханы тәшкил иткән профессорларга багышланган мәкаләләр дә урын ала. Шулай ук Казан университетының мәгърифәт һәм агарту өлкәсендәге эшчәнлеге турында очерк характерындагы язмалар басыла.

Казан төбәгенең һәм университетының җирле-өлкә колоритына беренче булып Н. П. Загоскин игътибар итә. Ул төбәкнең болгар һәм монгол башлангычларын искә алып үтә дә, шулай да болгар һәм монгол-татар "патшалыгы" рус культурасының Азия башлангычына тәэсир итү көчен озак вакытлар тоткарлап килде дип билгеләргә мәҗбүр була. Беренче рус университетларының барлыкка килүен Загоскин өлгергән рухи мәнфәгатьләрдән түгел, ә бәлки дәүләт башлангычыннан эзли. Николай Павловичның Казан университеты турындагы дүрт томлык хезмәте, гомумән, Александр эпохасындагы университетлар тарихы турында эзләнүләрнең иң әтрафлысы була *(Загоскин Н. П. История императорского Казанского университета за первые сто лет существования 1804—1904., Т. 1.—Казань, 1902.—С. XXI—XXII)*.

Казанның шәрекъне өйрәнү фәнє тарихы аеруча өйрәнелгәннәрдән исәпләнә. Казан ориенталистларының казанышы турында Н.И. Веселовский, А. К. Казембәк, О. М. Ковалевский һ. б. язып чыккан. Казан университетына караган күмәк хезмәтләрдә университет дәүләт учреждениесе буларак өйрәнелә. Әмма университетның төбәк халыклары культурасына ясаган йогынтысы актив өйрәнү объекты буларак каралмый диярлек.

Совет тарихчылары университет тарихын периодларга бүлүдә башка принципларга таянды, үзенчәлекле структуралар һәм хронологик калыплар белән эш итте. Аларда университетларның иҗтимагый тормыштагы урыны алгы планга куелды. Университетлар белән хакимият арасында капма-каршылыклар эзләү гомуми проблемалар һәм университетның эчке торышы мәсьәләсен икенче планга күчерде. Хәтта аеруча документлаштырылган һәм фундаменталь хезмәтләрдә дә университет совет хөкүмәтенең беренче унъеллыкларында бары тик Идел-Кама төбәге халыкларын галәмәт изү машинасының бер "шөребе" буларак кабул ителде. Ләкин совет чорында мәмләкәтнең Көнчыгышны өйрәнү тарихы буенча фундаменталь хезмәтләр дә пәйда булды *(Очерки по истории русского востоковедения.—М., 1956; Смирнов Н. А. Очерки изучения ислама в СССР.—М., 1954)*.

Татарстан, Мордва, Удмуртия, Казакъстан республикаларының тарихына караган 50-80 еллардагы басмаларда Казан университетының Россиянең көнчыгыш халыклары мәгарифендә, мәдәниятендә һәм мәгърифәтендә зур роль уйнавы билгеләп үтелә. Күрсәтелгән унъеллыкларда университетның тарихы буенча эзләнүләре революцион һәм милли хәрәкәт мәсьәләләре белән дә бәйләп карала.

XIX гасырның беренче яртысында—XX гасырның башында мәгариф мәмләкәтнең икътисади үсеш факторы буларак кабул ителә. Ләкин шулай булуга да карамастан, Россия студентлар саны ягыннан алда бармый. Әгәр АКШта бер студентка биш, Англия белән Франциядә унбер кеше туры килсә, Россиядә исә 150 кешенең бары тик берсе "мәктәп эскәмиясенә" утырган булып чыга. Билгеле ки, университетларның ролен аерымланган рәвештә, студентларның күпчелеге һәм үсеш динамикасы яктылыгында

гына карарга ярамас иде. Бередә университетларның мәгариф өлкәсендәге оештыручанлыгы, фәнни һәм цивилизацион эшчәнлеге миссиясе дә алгы планга чыга. Чөнки илнең культура тормышына университетлар ясаган йогынты милли зыялылар тәрбияләү зарурлыгы белән дә бәйләнгән. Бу яктан караганда, Б. Л. Кенжетаевның хезмәте аерым әһәмияткә ия *(Кенжетаев Б. Л. Казанские учебные заведения и процесс формирования казахской интеллигенции в середине XIX—начале XX века.—Казань, 1998, С. 10).* Ул XIX гасырның икенче яртысында—XX гасырның башында Казан уку йортларының казакъ зыялыларын тәрбияләүдәге урынын билгеләүгә багышланган. Тикшерүче китергән лейтмотив дәлилләрнең асылы революциягә чаклы булган казакъ зыялыларының күп өлешен "казанлылар" алып торганнар дигән нәтиҗәгә кайтып кала. Мондый "резюме"—Казан университетының казакъ зыялыларын тәрбияләүдәге урынын билгеләү күп санлы материаллар җирлегендә генә туа ала, әлбәттә.

Әйтергә кирәк, университет тарихының мондый юлы фәнни мәктәпләргә багышланган хезмәтләрдә тагын да ныграк чагылыш таба. Бу җәһәттән С.М. Михайлованың Казан университеты тарихына багышланган монографиясе аерым игътибарга лаек *(Михайлова С. М. Казанский университет в духовной культуре народов Востока России.—Казань, 1991).* Ләкин Казан университеты тарихына кагылышлы яңа басмаларны матбугатка хәзерләгәндә Казан университетының Россия халыклары фәне һәм мәдәниятендә тоткан урынын Көнбатыш белән Көнчыгыш дөньясының социокультура яссылыгында карау сорала.

Казан университеты турында бай архив материаллары Татарстан Республикасының Милли архивы фондында һәм Казан дәүләт университетының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең сирәк кульъязмалар һәм китаплар бүлегендә саклана. Мәскәү һәм Санкт-Петербург архивлары да хөкүмәтнең университетлар сәясәтенә кагылышлы күп кенә мәгълүматларны саклыйлар.

Кыскасы, Казан университеты—Россия университетлары арасында иң өлкәннәрдән исәпләнә. "Яңа барлыкка килгән университетлар мәмләкәтнең үзәңы үсешендә гасырлык традицияләре булган университетлар белән һичкайчан ярыша алмаслар"—дип язган үз вакытында Казан университеты турында А. Васильев *(Васильев А. Значение Н. И. Лобачевского для императорского Казанского университета.—Казань, 1896,—С. 40).* Киләчәктәге "рухи үсешләрнең бишеге булган" университетлар *(Н. Булич)* җәмгыятьне үзгәртеп коруда билгеле бер күләмдә традицияләр туплыйлар. Университет бетергән студент уку барышында шундый үзгәрешләр кичерә ки, "университетны тәмамлаган студентны кайчак гаиләдә дә танымый торалар. Ул башка илдән килгән кунак кебек кабул ителгән" *(Корсаков Д.А. Былое из университетской жизни. // Былое из жизни Казанского университета.—Казань, 1904,—С. 38).*

...1914 елда Казан университеты ачылуга 110 ел тула. Университет Советы тәгъдиме буенча, мәмләкәтнең иң атаклы галимнәре һәм иҗтимагый көчләре яклавы нәтиҗәсендә, бу юбилейны билгеләп үтәргә карар кылына. Ләкин Беренче бөтендөнья сугышы башлану "киртәгә" китереп суга. Совет чорында юбилейны үткәрү 1930 елга билгеләнә. Университет ачылуның 125 юбилеена профессорлардан Висс *(Швейцария)*, Винклер, Козак *(Германия)*, Догген *(АКШ)*, Инуйо *(Япония)*, Финдаль *(Норвегия)* кебек күренекле галимнәр дә чакырыла. Чакыруны олылап кабул итеп алуга хөрмәт йөзеннән һәм үз вәкилен Казанга кунакка җибәрергә җай тапканнары өчен Казан университеты директоры Г. Баһаветдинов Токио университеты җитәкчелегенә рәхмәт хаты да юллый. Анда хөрмәтле Инуйо әфәндене Казан университетының галимнәре җәмгыятендәге утырышта ясаган чыгышы зур кызыксыну тудыруы турында әйтелә.

Әйтергә кирәк, университетның 175 еллык юбилее тарихы бик тантаналы шартларда үткәрелде (1979). Шөт, 200 еллык юбилей да да бу нәүбәттән искәрмә булып тормас.

# КАЗАН—РОССИЯНЕҢ КӨНЧЫГЫШ УНИВЕРСИТЕТЫ МӘРКӘЗЕ

Казан университетының социаль культура өлкәсендәге урыны гомумән Казан шәһәренең үзенчәлекләре белән бәйле. "Шәрекъ башкаласы" турында татар тарихчысы һәм археологы Г. Әхмәров бик дөрес һәм төпле итеп әйтә. Ул, "шундый да үзенчәлекле, драматик характерлы, нечкә сюжетлы, кайсыбер ягы белән каршылыклы да булган Казаннан башка шәһәрне кайдан таба аласың", ди. Шәһәр тарихының назик сыйфатлары һәм капма-каршылыклы яклары аның географик урыны һәм анда яшәүче халыклар белән билгеләнә.

Герцен 1837 елда Казанны Көнбатыш белән Көнчыгышны бәйләп торучы бер капка буларак тасвирлап, Европа һәм Азия цивилизацияләрен тоташтырып торучы бөек кәрван-сарай, дип атый. Шушы образга һәр эпоха үзенең тамгасын салып үтә. Шул рәвешле, Евразия Казаны үзенең тарихы, архитектурасы һәм яшәеш рәвеше белән, Көнчыгыш һәм Көнбатыш башлангычларын берләштереп, төрки, славян, финн-угор культура дөньяларының үзара бәйләнешләрен чагылдыра. Көнбатыш һәм Көнчыгыш биредә "бер-берсенә туктаусыз йогынты ясап яшәүләре нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр, дуслашканнар һәм характеры белән кабатланмас берлек тудыралар" *(Герцен А. Письма в будущее.—М., 1983,—С. 32-33).* Инде XVIII гасырның икенче яртысыннан Казанның төс-кыяфәтендә татар мәдәнияте төсмерләре өстенлек итә башлый. Бу фактор соңрак университетның фән үсешенә дә йогынты ясамый калмый, әлбәттә.

Казан университетында Шәрекъ телләре укытуның торышына Казанның Урта Азия, Иран, Ерак Шәрекъ илләре белән сәүдә урнаштыруы да билгеле бер эз калдыра. Кытай белән сәүдә итү *(аеруча тире сәүдәсе киң җәелә)* дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштырылганчы ук барлыкка килә. Казан сәүдәгәрләре Кяхт шәһәрендә үзләренең ширкәтләрен ачып җибәрәләр. "Казанские известия" газетасы ул көннәрдә: "Казан шәһәре дворяннар шәһәре булудан битәр, сәүдәгәрләр шәһәре; сәүдә аны бизәп тора, тормышны җайга салырга ярдәм итә һәм күтәрә"—дип язып чыгарга мәҗбүр була *(1816, 8 ноябрь).*

XIX гасыр башына Казан Россиянең Көнчыгышка үтеп керүендә хәрби һәм дипломатик форпост ролен үтәүдән туктый. Аның урынына ул мәдәният һәм гыйлем бирү өлкәсендә үз урынын тагын да ныграк яулый башлый. Шул ук вакытта шәһәр ике дөньяны берләштереп торучы шәрекъ калоритын да югалтмый. Халыкның шәркый экзотик ягын сәфәргә чыккан патшаларга да күрсәтергә тырышалар. Ләкин Казанның шәркый йөзе чынлыкта катлаулырак һәм күп төрлерәк, әлбәттә.

Казанда беренче басылып чыккан басма да шәһәрнең төсе-кыяфәтендә шәркый башлангыч күп булуын билгеләп үтә. "Заволжский муравей" журналы билгеләп үткәнчә, Югары Ослан тавы һәм "Иделнең текә яры һәм елга үзе элеккеге географларга Европа белән Азия арасындагы чикне Идел аша үткәрергә һәм безне, казанлыларны, Азия халыкларына кертеп исәпләргә мөмкинлек бирде. *(1832, N 15).* Көнчыгышка публицистик һәм фәнни кызыксынуның алшарты булып, төбәкнең этник яктан күптөрле булуы да тора. Н. П. Загоскин билгеләп үткәнчә, "бу төбәкләрдә яшәүче күпсанлы төрки-монгол һәм финн кабиләләре көнкүреш, дини һәм лингвистик үзенчәлекләре, тарихи һәм хәзерге чынбарлыкны кабул итүдәге аерымлыклары булу белән бергә, төбәк- туфракка аерымланган кабатланмас этнографик төс-кыяфәт тә бирделәр" *(Загоскин Н. П. История императорского Казанского университета.—Т. 1.—С. XXII).*

И. П. Фалькның XVIII гасыр ахырында алынган мәгълүматлары шәрекъ компонентының күп төрле булуы хакында сөйли. Алардан күренгәнчә, 1773

ел метрика кенәгәләре буенча Казанда Грек-Россия динендәге кешеләр саны 8326 ир кешене, 10306 хатын-кызны берләштерә. Чукынганнар арасында 439 чирмеш һәм 105 татар булган. Моннан тыш 952 татар жан башына хезмәт хакы алып яшәгән; немецлар 87 кеше тәшкил иткән; болардан тыш биредә 24 фарсы, 8 кыргыз, 5 калмык һәм 11 чиркәс исәпкә алынган *(Фальк И. П. Полн. собр. ученых путешествий по России. // Знаменитые люди Казани.—Казань, 1999,—С. 424)*. XVIII гасыр ахырында Казан шәһәре замандашлары арасында соклану хисләре уята, әлбәттә... Г. Р. Державинның "Отечества и дым сладок и приятен" дигән юллары да шушы хакта сөйли, ләбаса.

Наполеон белән булган сугыш халык хәтерендә җуелмас эзләр калдырып үтә. Халык ополчениесенең үзәге булган Казан да зур тетрәнү кичерә. 1812 елда төбәк халыклары Ватанны саклауда патриотизм үрнәкләре күрсәтәләр. Уртак мәмләкәт өчен көрәштә татарлар да, калмыклар да, башкортлар да яу кырына чыктылар.

XVIII гасырда Петр I үткәргән реформалардан соң хуҗалык итү потенциалы зур булган Казан акрынлап сәүдә һәм сәнәгать үзәгенә әверелә башлый. Мәктәпләр, рухани һәм укытучылык семинарияләре ачылу, Гурия исемендәге тәрҗемәчелек комиссиясе барлыкка килү *(ул 1867 елдан башлап Шәрекъ халыклары телләрендә дини китаплар һәм әсбаплар чыгару белән шөгыльләнә)*, музейлар һәм нәшрият эшчәнлеге белән берлектә каршылыклы рәвештә, әмма бертуктаусыз җирле халыкның укымышлылыгын күтәрүгә ярдәм итә.

Рәсми хакимият Казанның максатын миссионерлык идеяләрен үткәрүдә православиегә табынучанлык рухы тәрбияләүдә активлык күрсәтәләр, "шәрекъ башкаласы" зыялылык, мәдәни күтәрелеш, гуманизм чәчәк ату учагына әверелә. Шушы хәл җирле халыкнын үзаңы формалашуда зур роль уйнап килә. "Рәсми программаларны гамәлгә ашыручылар арасында башка халыкларның мәнфәгатьләрен аңлаган рус булмаган халыклар күп яза" *(Домокош Л. С. Формирование литератур малых уралских народов. /Перевод с венгерского.—Йошкар-Ола, 1995. С.—126-127)*. 1829 елда Казанга килгән галим А. Гумбольдтның ассисенты Г. Розе болай дип язып калдыра: "Шәһәрдә, башлыча, руслар яши; шәһәргә кушылып торган бистәләр дә шәһәрдән аерылып тормыйлар, аларда татарлар яши. Алар шәһәр халкының өчтән бер өлешен тәшкил итәләр". Казанда ул вакытта 50 мең тирәсе кеше яши, татарлар шуның 15-17 меңе чамасын тәшкил иткән дигән сүз. Татарлар, башлыча, сәүдә белән шөгыльләнәләр, дирбия һәм сабын кайнату фабрикалары тоталар, алар житештергән тауарлар Россия мәмләкәтенең барлык төбәкләренә, хәтта Европа һәм Азия илләренә дә озатыла торган була. Казан кунагы татар йортларынын чисталыгына һәм гадилегенә шакката *(Гарзавина А. В. "В Казань, профессору К. Ф. Фуксу..."—Казань, 1997.—С. 120-121)*.

Үзәктәге корылмаларның монументальлеге ягыннан шәһәр Россия башкалары белән тиңләшә ала. 1833 елда инглиз Гамерсен болай дип яза: "Казан, сүз дә юк, Россиянең иң төзек шәһәрләреннән саналырга хаклы. Яңача төзелгән биналар, кальга-крепость һәм манаралары күккә ашкан мәчетләре Казанны бизәп, аңа үзенә күрә ямь биреп торалар." Шул ук вакытта Казан контрастлар шәһәре дә булып кала бирә. Ул халыкның бик тә чуар булуы белән генә түгел, ә бәлки юлларның начар булуы белән дә аерылып тора. Икътисади реформага кадәр булган торгынлык шәһәр тормышына да үзенең эзен салып үтә. Беренче курста укыган студент В. Назарьев 40 еллар Казанын менә ничегрәк тасвирлый: "Тузаны шулхәтле әче, хәтта күзләрне авырттыра башлый. Тирә-юньдә шундый өметсезлек, бушлык; извозчикларның сөрхәнтәй атлары пычракка батып беткән өсте ябулы жинел арбалар университет бинасынын "акшары кубып беткән колонналары" рәте белән тулыланып, бу фәкыйрьлекне тагын да арттыра төшәләр" *(Былое из университетской жизни: Литературный сборник.—Казань, 1904.—74-75)*.

Шушы ук елларда университетта инглиз телен укыткан Э. Турнерелли билгеләп үткәнчә, шәһәр халкы тантаналы кичәләр оештыруга бер-берсе белән ярышып, "эчкечелек һәм күнел ачу мәжлесе" уздыруга хирес булса да, шәһәр үзенең әдәби, иҗтимагый һәм фәнни җәмгыятьләре белән башкалардан аерылып торган. Бу нәүбәттән ирле-хатынлы Фуксларның түгәрәкләре ихтирамга лаек. Аларның фатирын "фән һәм сәнгать сарае" дип атарга мөмкин булыр иде. Биредә зиннәтле басмаларны һәм татарча, русча һәм гыйсъянчылык рухында сирәк кульъязмаларны туплаган галәмәт зур китапханә, шулай ук зоология, ботаника, минерология буенча коллекцияләр бар иде *(Пинегин М. Казань в ее прошлом и настоящем: Очерки по истории, достопримечательностям и современному положению города.—СПб, 1890 г.—С. 293-294).*

Иске Татар бистәсе исә дүрт йөз елдан артык Казан милли тормышының үзәге булып хезмәт итеп килә. Аның архитектура төзелешенә дә, көндәлек тормышына да үзенчәлекле колорит сеңгән. Чип-чиста итеп себерелгән урамнар, ишек аллары, иске татар өслүбендә салынган өйләр, мәчетләр һәм мәчет манаралары, базарлар һәм ашханәләр шәрекъ мохитен торгызуга хезмәт итәләр.

Бистә турында беренче мәгълүматлар 1566—1568 елларга туры килә. Ул вакытта биредә йомышлы татарлар яшәгәннәр, аларның роле Россия дәүләт машинасында һәм гаскәрендә яңача төзелгән полклар (XVII гасырның беренче яртысында) пәйда булгач кына кими төшә. Билгеләнгән линияләрнең чикләрен саклау кирәклеге калмагач, йомышлы татарлар лашманнар—урман кисүчеләр һәм флот төзүчеләр булып китәләр. Халык саны алу мәгълүматларына караганда, XVII гасыр уртасына егерме меңле шәһәр халкының 6 меңе чамасын бистәдә яшәүче халык тәшкил иткән. 1749 елгы янгынга кадәр аларның өйләре болгар архитектурасы үрнәкләрен саклап килгәннәр.

1782 елда Иске һәм Яңа бистә эшләре белән идарә итүче Татар раштуасы тәгаенләнә. Кешеләргә җирле мәсьәләләрне хәл итүдә мөстәкыйльлек һәм бургомистр сайлауда йогынты ясау хокукы бирелә. Кабан аръягында урнашкан Иске Татар бистәсендә яшәүчеләр Казан татар сәүдәгәрләренең "каймагын" тәшкил иткәннәр. Болак артында, шулай ук, һөнәрчеләр һәм мещаннар көн күргәннәр. Бистәнең төп урамы булган Захарьевскида *(хәзер К. Насыйри урамы)* Камай һәм Баткай ыруының торыннары яшәгәннәр—болар югары мөселман руханиларын һәм иң бай Юнысовлар һәм Апанаевлар нәселеннән чыккан кешеләр. 1782-1785 елларда Иске Татар бистәсенең бургомистры булып җиде еллык сугышта катнашкан, танылган татар мәгърифәтчесе Сәгыйть Хәлфиннең туганы Мөхәммәтрәхим торган. Татар Бистәсенең 150 дән артык кешесе кул куйган татар телендәге Мактау кәгазе аның эшчәнлегенә бәя бирүче бер "характеристика" булып тора. Анда иң катлаулы мәсьәләләрне хәл иткәндә дә бургомистрның хакыйкать ягында торуы билгеләп үтелә. Соңрак Мөхәммәтрәхим Хәсән улы намуслы һәм карышусыз рәвештә казый вазифасын башкара.

XIX гасыр урталарына Казан Идел буендагы иң зур шәһәрләрдән исәпләнә: анда илле меңгә якын кеше яши, шуларның өчтән икесен руслар, калганын татарлар алып торган *(Бабст И. Речная область Волги. // Магазин землеведения и путешествий: географический сборник Т. I.—М., 1852.—С.498).* Замандашларының истәлекләренә караганда, 1842 елгы янгыннан соң Казан шәһәре "яшь килен" кебек көязләнеп китә, төзекләнә, башкаладан кала икенче үзәк шәһәргә әверелә *(Второв И. А. Москва и Казань, в начале XIX века/ Русская старина—1891, апрель.—С. 17).* Һич югы империя чорыннан башлап хакимият үзәге генә булып калмаган өчен генә дә Казанны бары тик дворяннарзыялылар шәһәре дип атап булмый. Ул этнографик яктан да, фәнни яктан да сәүдә-икътисад ягыннан да "Шәрекънең башкаласы"на әверелә. XX йөз башына күп милләтле Казан Уралны, Себерне, Казакъстанны, Урта Азияне һәм Себерне бәйләп торучы сәүдә юлы хезмәтен үтәп килә, Россияне Ерак Шәрекъ илләре белән бәйләп торучы күпер була. XIX гасырда Казан Урта

Идел, Урал төбәге һәм Себер халыклары өчен рәсми рәвештә православие миссионерларының үзәгенә әверелә.

Адмиралтействода кораблар төзүчеләрне хәзерләү өчен ачылган мәктәп (1718) Казанда беренче халык уку йорты була. Беренче Казан гимназиясендә, Рухани уку йортында көнчыгыш телләре укытыла башлый. Рухани уку йортында көнчыгыш телләрне укыту император Павел I нең Указы нигезендә Казан рухани академиясе каршында "Татар теленең махсус классы" оештырылгач кертелә (1800). Казан рухани укыту округына кергән башка шәһәрләрдә дә татар телен укыту карала.

Казан гимназиясендә татар телен укыту икенче төрле, гражданлык төсмерен ала. Казан гимназиясе Россиядә фән буларак татар телен укыта башлаган өченче уку йорты була. 1762 елда Мәскәү университетын тәмамлаган бер төркем студентлар Казанга гимназия укытучылары итеп җибәреләләр. Күбесе киләчәктә Казан университетының профессорлары булып китә. Алар арасында математик Г. И. Карташевский, физик Запольский, тел белгече Н. Ибраһимов була.

Мәскәү университетының элеккеге профессоры, М. Ломоносовның биографы Михаил Веревкин әнә шундыйлардан. Казан укыту округының беренче попечителе С. Я. Разумовский да Ломоносовның якын шәкерте була. Ул үз чорының бик тә дәрәҗәле шәхесе, Казан университетына укытучылар сайлауга җитди әһәмият бирә. Ломоносов традицияләрен дәвам итеп, Степан Яковлевич гимназиядә дә, университетта да шәрекъ телләрен укытуга зур игътибар бирә. Математика өлкәсендә Г. И. Карташевский Мәскәү белән тоташтырып торучы "күпер" ролен үти. Н. Лобачевский аның студенты була. С. Г. Аксаков билгеләп үткәнчә, Карташевский "яшь" университетта математика фәнен укытуны шундый дәрәҗәгә күтәрә, үз фәнен шундый кызыксынырлык һәм бирелеп укыта ки, хәтта аның тырышы белән мәшһүр Бартельс та кызыксына *(Аксаков С. Т. Семейная хроника и вспоминания. Изд. 2-е. М., 1856,—С. 116-119).* 1769 елда Казан гимназиясендә укытырга җибәрелгән, Мәскәү университетының талантлы шәхесе Н. М. Ибраһимов та була.

Казан университеты тарихында Мәскәү университетыннан чыккан Иван Иванович Запольский да (1773—1810) якты эз калдыра. 1805 елда гамәли математика адъюнкты Запольский университетта бик тә абруйлы профессор дәрәҗәсенә үсеп җитә, физика кабинеты белән җитәкчелек итә, 1810 елдан башлап университет Советы сәркәтибе вазифасын башкара. Запольский рус һәм татар телләрендә чыгарылачак "Казанские известия" газетасының проекты авторы буларак та мәгълүм.

Мәскәү университеты Казанның китапханәләр фондын тулыландыруның башында тора. 1760 елның 6 февралендә Мәскәү университетының кураторы И. Шувалов Казан гимназиясендә китапханә ачу турындагы хәбәрне игълан итә. Шушы максаттан чыгып, Мәскәү университетында басылып чыккан китапларның берешәр нөсхәсен Казанга җибәреп тору кирәклеге күрсәтелә. Император Павел I нең Указы нигезендә Г. А. Потемкинның В. И. Полянскийга биргән китапханәсе Казан гимназиясенә тапшырыла (1798); ягъни Сәнгать академиясенең элеккеге сәркәтибе Полянскийның князь Потемкин китаплар җыелмасы да кергән шәхси китапханәсе гимназия карамагына килеп элэгә.

Гимназиянең беренче директоры М. И. Веревкин шәрекъ телләре белгече булмый, ләкин ул Рус империясе тарихын көнчыгыш кульязмаларыннан өйрәнүне максат итеп куеп, шәрекъ телләрен өйрәнүнең дөрес юлын билгели. Аның тырышлыгы аркасында 1769 елның 12 маенда гимназиядә татарча 2 класс оештырыла. 1836 елның 2 гыйнварында Николай I Беренче Казан гимназиясендә "Шәрекъ телләрен укыту буенча положение" кабул итә. 1849 елның 21 марты Дәүләт Советы карары нигезендә Казан гимназиясендә гарәп, фарсы, төрки-татар, монгол-калмык һәм кытай телләре укытыла башлый. Укыту теоретик һәм гамәли цикллар буенча алып барыла.

Бу вакытта Казанда инде берничә ел гимназиядә татар классы эшләп килгән була. Урындагы хәлләрне һәм Казан гимназиясендәге татар классы традицияләрен җентекләп тикшергәннән соң, Н. И. Веселовский мондый нәтиҗәгә килә: "Шәрекъ телләрен өйрәнү чик буе һәм чик аркылы багланышларның ихтыяҗларын үтәү, "инородецлар" утырган төбәкләрдә хакимиятне урнаштыру өчен зарур иде" *(Веселовский Н. И. Сведения об официальном преподавании восточных языков.—СПб., 1879,—С. 5).* В. Владимиров исә, Казан гимназиясенең тарихын "безнең бөтен мәгърифәт тарихы—безнең тарихның миниатюрадагы чагылышы дип атый *(Владимиров В. Описание празднования 100 летнего юбилея в Первой Казанской гимназии.—Казань, 1867,—С. 37).* Шушы мәсьәлә XIX гасыр башында нәкъ менә Казанда яңа университетның ачылуына һәм тамыр җибәрүенә сәбәпче була да инде.

Шулай итеп, административ һәм социаль культура "параметрлары" Казанны, чынлыкта "университет шәһәре" дип атарга мөмкинлек бирә. XIX гасыр уртасында университеттан тыш күп кенә мәгариф учреждениеләре белән бергә Рухани академия, Рухани семинария, Родионовск гыйффәтле кызлар институты, ике гимназия, епархиаль училище һ. б. эшләп килә.

Рус культурасы үзәге булу белән бергә, Казан борынгы шәрекъ культурасы үзәге дә булып кала. XVII—XIX гасырлар чигендә татар зыялылары җәмгыятендә дәүләт укыту йортларында да белем алу белән кызыксынуга алшартлар туа.

*

**Авторлар игътибарына**

**Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:**

**1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме**
**2. Яшәү урыныгыз**
**3. Туган ел, ай, көнегез**
**4. Паспорт мәгълүматларыгыз**
**5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры**
**6. ИНН номеры**
**8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.**
**7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)**

Ғәп
Фән

# Адлер Тимергалин

## МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ЕРТАУЛ*** *тар.* — Разведкага җибәрелә торган *туплан (отряд).* Мирфатыйх Зәкиев бу терминны *ерту* сүзе белән бәйли. Рус теленә дә кергән *(Петр патшага кадәр алгы атлы гаскәрне шулай атап йөрткәннәр).*

Монгол гаскәрендә — *хәбәргири.* Чыганакларда шушы мәгънәдә *"күзәт"* сүзе очрый.

***ҖАМИ ҖАМ*** *ф.* — Иран хорафатында хәмерне уйлап табучы *Җәмшид җамаягы (бокалы), җам-и Җәмшид.* Бу тылсымлы җамаякка карап бөтен галәмдәге хәлләрне күреп булган. Гакыл һәм гыйлемлелек билгесе. Күңел тынычлыгы, күңел рәхәтлеге символы итеп тә карала *("Суфичылык серләре").* Башкача *Җәмшид касәсе* дә диләр, *җам-и җиһани нәгъма* дип атау да очрый.

Тагын кара: ***ҖӘМШИД.***

***ҖАН-ФӘРМАН*** — Р.Әхмәтьянов бу сүзне борынгы төрки *җаң* "зур сугыш" һәм фарсыча *фәрман* — әмер сүзләреннән чыгара *("җаң фәрманы").* Ягъни *җан-фәрман* — сугыш хәбәре, сугышка чакыру *(ашыгыч мобилизация әмере)* диган мәгънәгә ия, аңарда "җан" *(рух)* сүзе катнашмый. Бу сүз электә сугыш игълан ителгәндә халыкның эш-хәрәкәтләрен күзалларга ярдәм итә.

***ҖАҺИЛЕ МӨРӘККӘБ*** *г.* — Үзен галим дип санаган надан, икеләтә надан, белмәве өстенә үзенең белмәгәнлеген дә белмәүче; чеп-чи наданлык, профанлык. *// Халыкны җаһиле мөрәккәб итеп тотарга, башка нәрсәне уйларга башының кабилиятен калдырмауга болар төсле хезмәт иткән нәрсә булмаган.* Г.Исхакый *("элгәреге болгарларда фәннәр укылмавы, төрле фәннән, төрле гыйлемнән, төрле китаплардан дибаҗәләр башлары гына укылу" аркасында).*

***ҖӘБӘЛ*** *г.* — Тау. *// Җәбәл әл-Камәр* — Камәр таулары *(Комор таулары, Ай таулары — Африканың көнчыгыш ярларында). Җәбәл Гәрәфәт — (Мәккә янындагы)* Гәрәфә тавы. *Җәбәләте Нур тавы* — бу таудагы Һира куышында Мөхәммәдкә беренче вәхий килгән. *Җәбәл Муса* — Тур тавы, Библиядә — Синай тавы. *Җәбәл-Рәхимәт* — Рәхимлек тавы *(җәннәттәге биек тау)*

Күплек саны шәкеле — *җибал.*

***ҖӘВАНБАЗЛЫК*** *фт.* — Яшь егетләр белән уйнаш кылу мәгънәсендә. Ир җенесендәге кешеләрнең үзара җенси мөнәсәбәткә керүе, гомосексуализм, педерастия, күтләклек. "Көтлүк" сүзе "Древнетюркский словарь"га да теркәлгән, ягъни борынгы төркиләргә педерастия мәгълүм булган.

***ҖӘДИТНЕ ӨРКҮ*** — Электә мәдрәсәгә яңа килгән шәкертләрне җәдит дип атаганнар *(русча "новичок" сүзенә туры килә).* Шәкертләр яңа шәкертне поднослар кагып, кәвешләр, утын агачлары белән бәреп, кыйнап, сугып җәберләгәннәр. Мондый "дедовщина" җәберен, мәсәлән, Гаяз Исхакыйга Казанда "Күл буе мәдрәсәсе"ндә шактый татырга туры килгән. Г.Исхакыйда "җәдит дип өркү" формасындагы гыйбарә очрый.

***ҖӘЗА, ҖӘЗАЭ*** *г.* — Бу сүздә үч алу мәгънәсе дә бар *(возмездие).*

Татарча "Коръән тәфсире"ндә "Аңлатма" сүрәсенең тәфсирендә (98:8) "җәза" сүзе "бүләк", "түләү" мәгънәсендә кулланылган: "Раббылары хозурында аларның җәзасы Гаден

*Дәвамы. Башы журналыбызның алдагы саннарында.*

исемендәге җәннәтләредер..." *(монда "алар" дигәндә "изге гамәлләр кылган хак мөэминнәр" күздә тотыла).* "Җир селкенмәк" сүрәсендә (99:7) дә бу сүзгә "бүләк" мәгънәсе салынган: "Берәү тузан хәтле генә яхшылык кылган булса, аның *җәзасын* күрер". Моннан соңгы аятьтә ул татар телендә гомум кабул ителгән мәгънәдә: "Вә берәү тузан бөртеге хәтле гөнаһ эшләсә, аның *җәзасын* күрер". "Аеручы" сүрәсендә (25:15): "Әйт: "Шулай мәңгегә утка керү хәерлеме? Яки тәкъва мөэминнәргә вәгъдә ителгән җәннәт хәерлеме? Ул җәннәт аларга изге гамәлләренә *җәза* һәм кайтачак мәңгелек урыннарыдыр".

Уразасын бозган кеше 61 көн түләү *(түләм)* яки йолым уразасы — *җәза уразасы (кәффарәт уразасы)* тота.

// *Җәзаэ сәйсәтен сәйсәтен мислеһа* — явызлыкның җәзасы *(түләве)* үзе мисалында булыр. *Яуме җәза* — ахирәт җәзасы.

*Мәлики голәмәләр җинаять кылуда гаепләнгән кешене камап куеп, гаебен таныту өчен җиңелчә җәзаларга рөхсәт биргәннәр.* "Ислами хокукларның нигезләре. Шәргый хөкемнәр" китабыннан. *(Монда сүз барган җәзалауның шәргый хөкем түгеллеген әйтергә кирәк.)*

Мәгънә аныксызлыгыннан котылу өчен татар телендә *җәза* һәм *җәзаэ* сүзләрен аерыбрак йөртү муафыйк булыр иде сыман *(мәс., матдә белән маддәне аерган шикелле).*

***ҖӘЙГЕ НАРДУГАН*** *тар.* — Җәйге иң озын көннәрдә *(22—25 июньнәр)* билгеләп үтелгән борынгы бәйрәм. Борынгы чорларда шушы көннәрдә елга-күлгә җитмеш җиде төрле чәчәк корбан итү йоласы булган, ягъни чәчәк бәйрәме үткәрелгән. Гомумән, 25 июнь — 5 июль арасы анабыз табигатьне *аяу атнасы* дип исәпләнгән.

***ҖӘЙЛӘҮ*** — *Лагерь* мәгънәсендә куллану очрый. // *Ислам җәйләве* — Ислам лагере *(соңгы елларда яшьләргә Ислам нигезләрен өйрәтү өчен оештырылган җәйге кыска курслар).*

***ҖӘЛЛАД*** *г.* — Палач, баш кисүче. Ләкин сүзнең төп мәгънәсе — *тире тунаучы.*

Е.Н.Шипованың "Словарь тюркизмов в русском языке" сүзлегендә *"палач"* сүзе төрки сүз буларак теркәлгән. Р.Әхмәтьянов "палач" госманлы төрек телендәге *палачы* — пычакчы сүзеннән кергән дип яза *(пала — "кеше үтерә торган зур пычак").*

***ҖӘМЕГЪ ГАЛӘМӘТЕ*** яки ***ГАЛӘМӘТЕ ҖӘМГЫ*** *тар.* — Математикада кушу билгесе. Арифметика буенча иске мәдрәсә дәреслекләрендә плюс билгесенең тәрегә охшавыннан куркып, аның янына өске сул яктан кыйгач итеп сызыкча өстәгәннәр һәм 4 легә охшаган тамга килеп чыккан. Плюс билгесен ай рәсеме белән алмаштыру очраклары да булган. // *"Хисапнамә" рисаләсендә "мөгаллим әфәнде" җәмегъ галәмәтләре ясауны миллият вә мөдарага хилаф күреп, алар урынына ай ясый барган иде. (Ф.Әмирхан).*

***ҖӘННӘТ*** *г.* — *Бакча* мәгънәсендәге гарәп сүзеннән. Фарсы телендә — *биһишт.*

Җәннәтләр сигез *(кат)*: 1) *Җәннәтел-Фирдәвес*, 2) *Җәннәтел-Мәэва*, ягъни Җәннәт йорты *(ул иман китереп изге гамәлләр кылган хак мөэминнәр өчен)*; 3) *Җәннәтел-Гаден*, ягъни Җәннәт-бакча; 4) *Җәннәтен-Нәгыйм*, ягъни Бәхет җәннәте; 5) *Дарес-Сәлам*, ягъни Иминлек йорты; 6) *Дарел-Карар*, ягъни Карар йорты; 7) *Дарел-Җәлал*, ягъни Бөеклек йорты; 8) *Җәннәтел-Холд*, ягъни Мәңгелек йорты.

Насретдин Борһанетдин Рабгузиның "Пәйгамбәрләр тарихы"нда җәннәтләр башкачарак аталып, түбәндәге тәртиптә күрсәтелгән: 1) *Дарүл-Җәлал*, 2) *Дарус-Сәлам*, 3) *Җәннәтүл-Мәэва*, 4) *Җәннәтүл-Хәмид*, 5) *Дарүл-Вәсилә*, 6) *Җәннәтүл-Фирдәвес*, 7) *Җәннәтүн-Нәгыйм*, 8) *Җәннәтү-Гаден.*

"Суфичылык серләре" белешмәсендә Мөхәммәд Чәләби Язычыоглу буенча *("Мөхәммәдия" китабы)* сигез җәннәтнең исемнәре һәм аларга хас сыйфатлары янә башкачарак бирелгән:

1)җәннәтүл-хулд; мәңгегә калу урыны булган бу җәннәт сары мәрҗәннән салынган;

2)җәннәтүл-мәгъва *(шул ук җәннәтел-мәэва)*; ул яшел зөбәрҗәттән. Кайбер чыганакларга караганда, *мәэва җәннәте* сидрәтелмөнтәһа агачы янында икән.

3)җәннәтүл-гаден; бөтен җәннәтләрнең уртасында урнашкан, ялтыравыклы энҗедән;

4)җәннәтүл-фирдәвес; бу җәннәт бакча рәвешендә һәм кызыл алтыннан эшләнгән —

бакчаның уртасыннан Сәлсәбил суы ага;

5)җәннәтүн-наим; хуш тереклек мәгънәсендә, ул ак көмештән төзелгән;

6)дарус-сәлам – гөнаһларны ярлыкау урыны; кызыл якуттан төзелгән;

7)дарул-карар;

8)дарул-җәлал.

Кыскасы, җәннәтләрнең бүленеше һәм аталышы хакында чыганаклар бер сүздә түгел. Өстәвенә бүгенге чыганакларда атамаларның язылышында да гадәттән тыш чуарлык күзәтелә.

Кайчагында *гиллийүн* атамасы җәннәт мәгънәсендә кулланыла (83:18, 19).

Суфичылык терминологиясендә каралган җәннәт төрләре:

1)җәннәт-ел-әфгаль – фигыльләр вә гамәлләр җәннәте. Яхшы гамәлләр кылып, нәфесләрен тыеп яшәгән кемсәләрнең барлык теләкләре шушында тормышка ашачак. Шуңа күрә бу җәннәтне "нәфес җәннәте" дип тә атыйлар.

2)җәннәт үс-сыйфат – сыйфатлар җәннәте. Суфилар бу җәннәтне Аллаһының күркәм исемнәре һәм сыйфатлары турында уйлаганда тоялар, шуңа ул аларда "күңел җәннәте" дип тә атала.

3)җәннәт-үл-вәрасәт – мирас калган җәннәт, варислык җәннәте. Тышкы һәм эчке яктан Мөхәммәд галәйһиссәламгә охшарга омтылу халәте.

4)җәннәт-үз-зат – илаһи матурлыкны тамаша кылу. Моңа суфичылык йола-мәрасимнәре вакытында ирешелә.

Югарыдарак аталган сигез җәннәтнең баштагы дүртесе гөлбакча, калган дүртесе бакча-сарайлар рәвешендә булып, аларында зиннәтле пулатлар корылган. Пулатларның иң биеге Әбү-Бәкер Әс-Сыйддикка, кечерәкләре Пәйгамбәрнең сәхабәләре Гомәр, Госман вә Гали өчен дип билгеләнгән.

Җәннәт зиннәтле сарайлар вә җимешле бакчалар белән тулы. Җәннәт бакчасы мәгънәсендә *рауза* сүзе дә кулланыла. Андагы хөрмәт вә нигъмәтләрне бәян кылып бетерү дә мөмкин түгел.

Ошбу хәдистә җәннәт бакчаларына карата башкачарак фикерне күрәбез. Изге Пәйгамбәребез әйтә: "Мин мигъраҗ кичәсендә Ибраһим хәзрәтләрен *(галәйһиссәлам)* очратканымда ул миннән өммәтемә аның сәламен ирештермәк илә үтенде һәм дә җәннәттәге җирләр-туфракларның бик тә йомшак, яхшы вә уңдырышлы булуын һәм дә аны сугару өчен бик яхшы сулар барлыгын әйтергә кушты. Тик ул җирләр тоташ бер чирәм икән һәм дә ул чирәм җирләрдә һәр үлән бөртеге "Сөбханәл-лаһи үәл-хәмдү лил-лаһи үә ләе илаһа илләл-лаһу үәл-лаһу әкбәр"дән гыйбарәт икәнлеген дә әйтергә кушты," – ди. Ягъни һәркем андагы үлән-чирәмне никадәр теләсә, шулкадәр үстерә ала.

Җәннәт сүзенең телдәге мәгънәсе "бакча" икәнлеген искә төшерсәк, монда капма-каршылык килеп чыга сыман. Ләкин галимнәр фикеренчә, җәннәт инсаннарга тапшырылганда кешеләр ул җәннәттә бик күп вә гүзәл бакчалар табачаклар икән. Кайбер галимнәр исә җәннәтнең кайбер төшләре агач-бакчалар белән бизәлмеш булыр, ә башка төшләрендә бакчалар булмас, анда агачлар бәндәнең зикер вә хәмедләренә күрә үсеп торырлар дип исәплиләр.

"Коръән тәфсире"ндә җәннәттә ике чишмә бар диелә һәм, гомумән, Коръәндә бәхетле тормыш символлары буларак һәрвакыт ике бакча турында сөйләнә. Ләкин башка абруйлы белешмә ("Ислам. Энциклопедический словарь". М., 1991) җәннәттә 4 бакча булып, һәркайсында берәр чишмә булуын искәртә. Җәннәттәге елгалар *(чишмәләр, сулыклар)*: 1)*Нәһрел-Рәхмәт (Рәхмәт елгасы – ул Дарел-Карардан чыгып, барча җәннәтләргә таралмыштыр)*, 2)*Кәүсәр елгасы*, 3)*Сәлсәбил (чишмә)*, 4)*Тәсним (чишмә)*. "Тәфсир Ногмани"да: "Ул чишмәдән Аллаһуга иң якыннар гына эчәрләр" диелә. Ривайәткә караганда, Мөхәммәд Пәйгамбәр Тәсним чишмәсе суында чылатылган җәннәт туфрагыннан яратыла. Кайбер чыганакларда җәннәттәге *Зәнҗәбил* елгасы да телгә алына.

Кәүсәрдән бер тармак аерылып китеп, ул Җир йөзендәге *Зәмзәм* чишмәсенә ирешә икән.

Сәлсәбил – *шәраб чишмәсе* дигән сүз дә бар. Сәлсәбил чишмәсе *Сидрәтелмөнтәһа* агачының төбеннән агып чыга вә аңардан Кәүсәр һәм *Бәхрел-Бәхет дәрьясы* барлыкка килә дип тә сөйләнелә.

Хәзрәти Әнәс тапшырганча, Рәсүл Әкрам болай дигән: "Тәхкыйк, җәннәттә *Рәҗәб* дип аталган елга бар, төсе сөттән дә аграк, тәме балдан да татлырак. Кем булса да

Рәҗәб аенда бер көн булса да ураза тотса, Аллаһы Тәгалә үзен шул елгадан эчертер".

Ривайәтләргә караганда, Мөхәммәд Пәйгамбәр җәннәттәге чишмәләрнең берсендә — сөт, берсендә — су, берсендә шәраб, берсендә бал акканлыгын күрә.

Халык арасында тагын җәннәттә *Зәгъфран чишмәсе* барлыгы да телгә алына. Кәүсәрне *хаузы кәүсәр* дип, күл яки чишмә дип әйтү дә очрый. 1812 елда Казан университеты рус телендә нәшер иткән бер китапта *("Козе Корпяч и Баян Сылу")* җәннәттә *Кәфур елгасы* һәм *Куз-ашляр (Күз яшьләре)* елгасы булуы әйтелсә дә, соңгысы башка чыганаклар белән расланмый. Билгеле булганча, *Зәмзәм суы* шигърияттә "күз яше" мәгънәсендә дә очрый, ривайәткә караганда исә, Кәүсәрнең бер тармагы Җир йөзендәге *Зәмзәм* чишмәсенә тоташа. Ихтимал, тәрҗемәче яки аның информаторы шуның белән буталгандыр. "Инсан" сүрәсенең 5 нче һәм 6 нчы аятьләрендә чыннан да: "Тәхкыйк, яхшы мөселманнар тәмле сулар эчәрләр, ул суның исе һәм тәме кәфур *(камфора)* кебидер. Ул кәфур чишмәдер, аннан эчәрләр Аллаһының итагатьле коллары, вә ул чишмәне ничек кирәк — шулай агызырлар" — диелгән *("Коръән тәфсире" буенча)*. Ләкин башка тәфсирчеләр биредә дөньялыкта кәфур *(камфора)* матдәсе катыштырылган суны касәдән эчү турында сүз бара дип саныйлар, ягъни җәннәттә Кәфур чишмәсе булу-булмау мәсьәләсе хәл ителмичә кала.

"Сахих Мөслим"дә *(2 том, 351 бит) Сәйхан* һәм *Җәйхан, Фурат (Евфрат)* һәм *Нил* елгалары җәннәт елгалары дип телгә алынган.

Кайбер китапларга караганда, җәннәттә "...елгалар күптер, хисабын бер Аллаһ белер" һәм "һәр җирендә татлы сулы елгалар вә ширбәтле чишмәләр агып тормактадырлар".

"Яшәеш китабы"на *("Книга Бытия")* караганда, Эдемда (оҗмахта) сугару өчен бер елга агып чыгып, аннары *дүрт* тармакка бүленгән. Аларның исемнәре: *Физон (соңыннан Һинд яки Һанг елгалары, кайчагында Дунай елгасы белән тәңгәлләштерелгән), Гион (яки Нил), Хиддекель (яки Тигр, Диҗлә)* һәм, ниһаять, *Евфрат (Форат)*.

Борынгы грек мифологиясендә Аидада, ягъни җир асты дөньясында *(үләләр дөньясы) Лета, Стикс (җир асты патшалыгын әйләндереп алган бу елганың алиһәсен — нимфасын да Стикс дип атаганнар, Стикс суы белән ант эчү аллалар һәм кешеләр өчен изге булып саналган), Коцит* һәм *Ахерон* елгалары *(сулыклар)* телгә алына. Андагы утлы елга исә грек мифологиясендә *Флегетон (Пирифлегетон)* дип атала. Соңгысын җәһәннәм уты белән тиңләштерергә мөмкин.

Җәннәттәге бер биек тау *Җәбәл-Рәхимәт тавы (Рәхимлек тавы)* дип атала.

Оҗмах кояшы беркайчан да баемый һәм аның эсселеге мөэминнәргә кагылмый икән. Чыганаклар җәннәт күгенең җирдә таң беленгән вакыттагы күккә охшаганлыгын искәртәләр.

Җәннәткә кергән кешеләр Аллаһы Тәгаләнең нурын да күрәчәкләр.

Җәннәт әһелләре яшел төстәге кием киеп йөриләр.

Җәннәт ишеген *(капкасын)* саклаучыны *бәүбаве җәннәт* дип атыйлар. Җәннәт хезмәтчеләре — *гыйльманнар (вилданнар)*. Җәннәт капкалары берничәү һәм төрле сыйныф кешеләре өчен җәннәтнең берничә *дәрәҗәте* бар.

Җәннәттә фәкать ураза тоткан кешеләр генә керә ала торган "Рәйан" *("әр-Рәйан")* исемле бер капка бар.

Коръәннән соңгы әдәбиятта җәннәт баскыч-баскыч менгән пирамида рәвешендә сурәтләнә, ул йолдызлы күктән биегрәк, әмма Аллаһы тәхетеннән түбәнрәк урнашкан.

Ривайәтләргә караганда, җәннәткә ун хайван керәчәк: 1) Салих пәйгамбәрнең дөясе; 2) Ибраһим пәйгамбәрнең бозавы; 3) Исмәгыйль пәйгамбәр урынына чалынган корбан тәкәсе; 4) Муса пәйгамбәрнең сыеры; 5) Йосыф пәйгамбәрне йотып үз карынында тоткан балык; 6) Гозәер пәйгамбәрнең ишәге; 7) Сөләйман пәйгамбәрнең кырмыскасы; 8)Билкыйснең һөдһөде; 9) Мөхәммәд галәйһиссәламнең дөясе; 10) "әсхафе кәһәф"нең *("Мәгарә кешеләре" — кяфирләрдән качып, Аллаһы ихтыяры белән бер мәгарәдә 300 еллар йоклап уткәргән яшь егетләр)* эте.

*Җәннәт — юмарт мөселманнарның йортыдыр.* Хәдис.

Җәннәт башкача *оҗмах (борынгы төркичә шәкеле — очмак?)* һәм *биһишт (ф.)* дип атала. Әдәбиятта җәннәтне тагын *дарелрәхәт* дип атау очрый.

*// Нәгыйм җәннәтләре. Җәннәтле итү. Ахирәттә җәннәтле булу.*

Җәннәт сүзенең күплек саны шәкеле — *җинан*.

# СӘХИПҖАМАЛНЫҢ ДӘВАМЫ

Әле Бөек Ватан сугышы кырларында ил азатлыгы өчен кырылып сугыш барган бер мәлдә, Татарстан хөкүмәте театрларның киләчәге турында кайгыртып, аңа яшь кадрлар әзерләү хәстәренә керешә. Шул рәвешле Мәскәү Дәүләт театр сәнгате институты (ГИТИС) каршында татар студиясе ачарга карар бирелә. Моның инициаторы, башлап йөрүче көнчыгыш халыкларының театр һәм кино сәнгатенен чишмә башында торган, инде Татар Академия театрында лидерлык иткән артист Хәлил Әбҗәлилов була. Мәгълүм ки, аңа сонрак татар артистлары арасында беренче буларак, СССРның халык артисты дигән исем бирелде. Менә шул Хәлил абыйның, башка корифейларның тырышлыгы белән, алар тарафыннан сайлап алынып, Мәскәүдәге студиягә студентлар туплана. Студиянең директоры итеп татар сәнгатен үстерүгә гаять зур өлеш керткән җырчы һәм сәнгатькяр Асия Измайлова куела. Студентлар арасында иң яше, әле генә 7 сыйныфны тәмамлаган, әмма фәннәрне яхшы үзләштергән, музыкага да өйрәнгән Асия Әмир кызы Галиева була. Гомуми мәктәптән тыш, Асия Галиева мәшһүр музыка педагогы Поляков житәкләгән I нче номерлы музыка мәктәбендә белем ала. Зыялы ата-анадан туган бу кыз бала, зирәк акыллы, нечкә зәвыклы була. Бала вакыттан ук Сәлих Сәйдәшев белән "дуслашып" китә, чөнки Сәйдәшев аларның гаиләсе белән аралаша, еш кына өйләренә килеп йөри, кызчыкның музыкаль мәктәптәге уңышлары белән кызыксына һәм махсус, Асиягә багышлап, фортепиано өчен пьеса яза. *(Аның клавиры бүген дә Асия Галиеваның шәхси архивында саклана.)*



Шулай итеп, көннәрдән бер көнне студия укучылары Мәскәүгә юл ала. Һәм алар бик яхшы педагогларга—инде күп артистлар укытып чыгарган, кайчандыр үзе дә МХАТ артисткасы булган Ольга Ивановна Пыжова һәм аның ире Борис Владимирович Бибиков классына эләгәләр. Бу—үзе үк зур бәхет дигән сүз! Асия яхшы укый. Башта Хмелев исемендәге стипендия, өченче курстан Сталин стипендиясе ала. *(Ә бу стипендия, аның шарты буенча, чынлап та өченче курстан гына бирелә башлый.)*

Республика хөкүмәте һәм театр әһелләре моның белән генә чикләнмичә, 1945 елда, сугыш тәмамланган көннәрдә тагы бер театраль уку йорты—Татар Дәүләт театр училищесын ачалар. Бу сугышка кадәр эшләгән Театр техникумының дәвамы була. *(Бу юлларның авторына да шушы училищеда атаклы педагоглар Шириаздан Сарымсаков, Сәет Булатов, Кәшифә Тумашева житәкчелегендә уку насыйп булды.)*

Без, ягъни татар театры училищесы студентлары өченче курста укыган чакта, инде берничә диплом спектакле әзерләгән идек. Директорыбыз Сәет

Булатов, шул спектакльләрне күрсәтергә дип, безне Мәскәүгә алып барды. Менә шушы сәяхәт вакытында без ГИТИС укучылары белән очрашып аралаштык. Безгә аларның спектакльләренең кайбер өлешләрен карарга да насыйп булды. Алар үзләре тәрҗемә итеп, казакъ драматургы Габид Мөсреповның "Кузы-көрпеш һәм Баян-сылу" трагедиясеннән өзек күрсәттеләр. Асиянең телендә ул чакта русча мәктәптә укыганлыгы сизелсә дә, тудырган трагик образы гаять дулкынландыргыч иде. "Бу яшь кыз баланы берәр мәктәптән шушы роль өчен махсус алганнар инде" дигән уй күңелгә килде. Соңыннан аңлатып бирделәр: ул үзе шушында укучы "Студия кызы" икән. Яшь булса да алганнар. Кузы-көрпешне аңардан унбер яшькә олы, әмма үзенең ыспайлыгын югалтмаган Гали Хөсәенов уйный иде. Анда, гомумән, күбесе "төз буйлы" студентлар Празат Исәнбәт, Хәйдәр Гыйматдинов, Гариф Хөснуллин, Шәхсанәм Әсфәндиярова, Асия Әхмәтшина, Шакир Розаутдинов, Мәхмүт Хәсәнов укый иде. Алар арасында Асия Галиеваның миниатюр гәүдәсе аеруча күзгә ташлана. Ул чакта без әле аларның эшенә бәя бирерлек "белгечләр" түгел идек, әлбәттә, шулай да алган тәэсирләребез шактый тирән булды. Миңа калса, андагы егетләрнең күбесе Асияне үзләренең бер "назлы гөлкәе" итеп исәплиләр. Кайберләре исә аңа чын-чынлап гашыйклар да иде кебек. Ләкин Асия горур, мөстәкыйльлек күрсәтә иде. Ул Казанга әйләнеп кайткач та шулай булды.

Менә без дә 1949 елда училищены тәмамлап, безне—кызыл дипломлы биш кешене Академия театрына алдылар. ГИТИСныкылар да, шул ук елны укуларын тәмамлап, бер укмашкан труппабызны таратмыйбыз, дип русча эшләп килгән яшь тамашачылар театрының татар труппасы булып эшләп киттеләр. Күрәсең, аларның бу башлангычын хөкүмәт хупламады. Алар барысы да безнең театрга *(Академия театрына)* кушылдылар. Шулай итеп, театр берьюлы шактый яңа көчләр алды.

ТЮЗ чорында Гали Хөсәенов, Гариф Гобәй повесте буенча "Маякчы кызы" дигән пьеса язып, аны сәхнәгә чыгардылар. Аны Кәшифә Тумашева сәхнәләштерде. Төп геройны—Илсөярне—маякчы кызын Асия Галиева уйнады. Бу образ махсус аның өчен язылган кебек иде. Шулай ук күренекле драматург һәм педагог Абдулла Әхмәт пьесасы буенча "Үги кыз" пьесасында да үги кыз Зөһрәне Асия Галиева башкарды. Бу әсәрне дә сәхнәгә Кәшифә апа Тумашева куйды.

Академия театрына күчкәч тә Асия коллективның бер сөйкемле сөягедәй иң игътибар һәм ихтирам җәлеп иткән кешесенә әйләнде. Беренчеләрдән булып Мәскәүгә кабат барып югары белемгә имтихан тотты. Ул театрга I категорияле актриса дигән ставка белән алына. Ә бу күп нәрсәне аңлата. Аны арадагы иң яшь һәм чибәр кеше буларак та, иң яхшы башкаручылардан берсе булган актриса буларак та яраталар иде. Мәсәлән, Хәлил абый Әбҗәлилов, Хөсәен ага Уразиков аны үз балалары дип күрәләр һәм, уйлавымча, шул тойгыдан үзләренә энергия дә алалар иде. Режиссерлар да аны игътибар үзәгендә тоттылар. Шуны әйтергә кирәк, бала чагында рус мәктәбендә укыган булса да, ул татар телен бик тиз камилләштерде, аның үзенчәлекләрен, аһәңнәрен тиз тоемлый башлады, өлкәннәрнең киңәшләренә колак салды. Шуның аркасында бик тиз арада радиолаштыруларда да катнаша башлады һәм тиздән иң актив радио артисткасы булып китте.

Академия театрына килгәч беренче рольләре—Сәет Кальметовның "Тын алан шаулый" пьесасындагы шаян кыз Әсмәгөл, Островскийның "Яктырта, тик җылытмый" әсәрендә драматик Оля образы, татар классигы Галиәсгар Камалның "Бәхетсез егет" драмасындагы Гайни образы. Гайни ролен инде күп атаклы артисткалар башкарган була. Мәсәлән, Волжская, Ильская. Әмма бу юлы образ үзенең элек уйналып килгән традицион Гайни образыннан аерылып торуы белән тамашачының да, театр белгечләренең дә игътибарын җәлеп итте. Элек Гайнине, гомумән, бер фахишә итеп уйнасалар, бу юлы аның үзенең дә "бәхетсез кыз" булуы ачыла. Бу уңайдан Нәкый Исәнбәтнең "Совет Татарстаны" газетасының 1955 ел, 29 январь санында басылган

мәкаләсе ачык әйтә: "...Гайнигә аеруча әһәмият бирелгән. Чынлап та, Гайни кем ул? Монарчы ул сатлык кыз итеп кенә уйнала, аның эчке дөньясына әһәмият бирелми иде. Бу юлы капиталистик дөнья тудырган һәм тормыш авырлыгыннан чыгып, үзен сатарга мәҗбүр булган кызның шактый бай җан кичерешләрен күрдек, аның эчке бушлыктан моңаюларын ишеттек. Зур гына драма кичереше булган Гайни образын яшь артистка Асия Галиева уйный. Роль хәзер социаль хәле буенча дөрес кичерешләрдә ачыла..."



*Гыйззәтуллина-Волжская һәм Асия Галиева*

Монардан соң да Асия Галиеваның репертуары байый, тулылана бара. Ул татар драматурглары әсәрләре белән беррәттән, рус һәм чит ил классик әсәрләрендә дә зур уңыш казана. Горькийның "Соңгылар" спектаклендә тормышка якты күзлектән карап, соныннан бәхетсезлеккә очраган Верочка, Эмиль Золяның "Рабурден варислары"нда төп рольләрдән Шарлотта һәм башкалар. Анын Вильям Шекспирның "Король Лир" трагедиясендәге Лирның кече кызы Корделия образына аерым тукталасы килә. Күпләр белә, Король Лир мактаулардан башы әйләнеп, үзенең патшалыгын өч кызына бүлеп бирергә була. Ике олы кызы әтиләрен чамадан тыш мактыйлар, ә кече кыз Корделия "кыз әтисен ничек яратырга тиеш булса, мин шулай яратам, артык та түгел, ким тә түгел" дигән сүзләре белән Лирның ачуын куптара. Һәм Лир Корделияне мирастан мәхрүм итә. Бу фаҗигадә һәм аннан соңгы вакыйгаларда Корделия үзен күркәм тота. Тик соңыннан гына, өлкән кызларының хыянәтен белгәч кенә Лир аны аңлый, ләкин эш соң була.

Трагедия артисттан аеруча көчле тавыш, буй-сын, гәүдә һәм итагать манералары таләп итә. "Лир"ның электәге 1944 елгы куелышында Корделияне Фатыйма Ильская уйнаган. Ә 1957 елда Галимә Ибраһимова белән Асия Галиева бергә уйнадылар. Асия, әйтеп киткәнебезчә, матур булса да, миниатюр сынлы иде. Әмма ни гаҗәп, ул ягымлы тавышы, бөтен барлыгы белән сәхнәне тутыра белә иде. 1957 елда Мәскәүдә узган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасыннан соң, бу хакта "Театр" журналының 1957 елгы санында театр белгече Е. Шамович үзенең "Бәйрәм атмосферасында" дигән мәкаләсендә болай язып чыкты: "Лишь одна Корделия—Асия Галиева может стать в спектакле рядом с Лиром-Абжалиловым. Она близка ему и цельностью своего характера и мужественностью, которую лишь подчеркивает ее хрупкая красота и пленительная грация".

Нәкый Исәнбәт әсәре буенча куелган "Гөлҗамал" спектакле Асия Галиеваның тагы бер яулаган биеклеге булды. Әсәрнең татар театрының беренче корифейларыннан булган Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяга багышлануы төп рольне башкаручыга җаваплылыкны тагы да арттыра төшә иде. Аның хакында әле бөек Тукай да болай дип язып калдырган бит:

*Күр ничек, иртә кояш чыкса, җиһанда нур тула—*
*Һәр күңелләр нурланадыр чыкса Гыйззәтуллина.*
*Бу икәүгә тәңре биргән бертигез зур мәртәбә:*
*Берсе уйный күк йөзендә, берсе уйный сәхнәдә.*

Асия Галиева үзенә бирелгән бу рольне шушы Тукаебыз әйткән кимәлдә

башкарып чыкты. Ул хакта инде күп сөйләнде, күп язылды. "Гөлҗамал" спектакле беренче тапкыр Уфада, аннан Алма-Ата, Фрунзе, Ташкентта уйнала. Һәм һәр юлы җирле артистлар сәхнә артына кереп, "Сез бу спектаклегез белән татар театрының, халкыгызның һәм шәһәрегезнең абруен бермә-бер күтәрдегез", дип үзләренең рәхмәтләрен, соклануларын, котлауларын әйттеләр. Әмма иң мөһиме—аны Сәхипҗамал апа үзе исән чакта күреп калды һәм югары бәяләде.



Менә аның 1963 елда Татарстан радиосында язып калдырган бер чыгышыннан өзек: "Сентябрь аенда килдем татар спектакленә... Куела иде "Гөлҗамал". Беренче мәртәбә карадым. Бу пьеса турында нәрсә әйтә алам? Орышмыйм да, мактамыйм да. Яхшы спектакль килеп чыккан. Житешсез урыннары да бар. Бәгъзе бер артистлар рольләргә дөрес куелмаганнар. Миңа охшаган бер нәрсә булды—бөтен нәрсәмне онытып Гөлҗамал ролен карап утырдым. Бу рольне уйный торган Галиева рольне сокландыргыч алып бара. Бик күп кешеләрнең күзләренә яшь килде. Мин дә шул хәлдә булдым. Минем барып үбәсем килде Гөлҗамалны. Беренче мәртәбә уйнаганда ук артистка шулай матур, дөрес тоеп, аңлап һәм дәрәҗәсен белеп уйнады. Ул артисткага теләгәнем—тагы да тырышыбрак эшләсен, тагы да зуррак артистка булсын. Яшәсен безнең Гөлҗамал-Галиева! Шуны гына әйтә алам".

Инде ике артистка—героиня һәм аның прототибы бергә очрашкач Сәхипҗамал апа Галиевага үзенең фоторәсемен бүләк итә. Һәм артына болай дип яза:

"Минем иң яраткан артисткаларымнан А. Галиева ханымга истәлек өчен. Җуймагыз, үзегездән чыгармагыз. Мой единственный друг. Волжская. 13.04.1964 г.".

Тагы бер фоторәсем. Анысын Уфада спектакльне карагач Сәхипҗамал Волжская белән бергә төшкән Башкорт Академия театры артисткасы, аны оештыручыларның берсе булган, Сәхипҗамалның дусты Бәдәр Йосыпова җибәргән. Артына болай дип язган:

"Кадерле Асия!

"Гөлҗамал" спектаклендә иҗат иткән образыгыз сезне тагы да ныграк яратырга мәҗбүр итте. Котлап, Волжская белән төшкән рәсемне бирәм. Сез дә шундый булыгыз!"

Чынлап та, Асия шундый була, Сәхипҗамалның дәвамчысы була. Бу урында Бәдәр апаның тагы бер хатын да искә төшерми булмый. Ул аны русча язган. *(Татарчага тәрҗемәдә бирелә)*:

"Кадерле Асия! Кичәге "Гөлҗамал" спектакленнән соң сезгә үземнең тойгыларны белдерергә рөхсәт итегез.

Сезнең тавышыгыз, сезнең гаҗәеп күзләрегез инде күптән мине әсир итә иде, әмма мондый рольдә сезне беренче күрүем.

Сез ул вакыттагы татар кызын—"җәмгыять" ихтыярына, әти-әниләренә каршы, бөтен реакцион көчләргә каршы баручы актриса образын тудырдыгыз. Мин сездә үземне таныдым һәм эпоханы тойдым. Сез шатланырга, дулкынланырга мәҗбүр иттегез. Мин Сәхипҗамалны бик яратам һәм, һичшиксез, аңа язачакмын. Бездән, ике халыкның театрын башлап җибәрүчеләрдән, зур рәхмәтебезне кабул итегез һәм актриса исеме безгә бик кыйммәт бәя белән алынганын исегезгә төшерегез. Артист исемен яратыгыз һәм театрны саклагыз. Сезгә озак елларга зур иҗади уңышлар телим. Сезне яратучы актриса Йосыпова Бәдәр. 1963 ел, 5 июль".

Асия Галиева башкарган хисапсыз рольләр арасында тагы берсен искә алмыйча булмый. Ул да булса—Островскийның "Талантлар һәм баш иючеләр" драмасындагы Негина образы. Бу спектакль гаять зур уңыш белән барды. Аны 1955 елда кабатланмас талантлы режиссер Габдулла абый Юсупов куйган иде. Һәм анда театрның иң көчле артистлары уйнады. Габдулла абыйның режиссер буларак үзенчәлеге шунда—ул спектакльдәге рольләргә тиешле артистларны гаять төгәл билгели, бөтен спектакльнең сурәтен—актерларның рухи хәрәкәтләрен һәм физик хәрәкәтләрен *(ягъни мезансценаларын)* алдан ук төгәл билгеләп, әзер материал белән килә һәм репетиция вакытында артистларга шушы нәрсәләрнең сәбәбен, мәгънәсен аңлатырга, анык бурыч куеп, шуларны үтәргә мәҗбүр итә. Аның спектакле, чыннан да, зур уңыш казанды. 1956 елда Россия күләмендә яшь артистлар иҗатына конкурс уздырылгач, Асия Галиева бу конкурста Негина образы белән беренче урынны алды һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының мактау грамотасына лаек булды. Пьесадагы яшь актриса Негинага үзенең иҗатын дәвам иттерү өчен бер генә юл бар: ул бай бер спонсор сайларга, ягъни бай кешегә кияүгә чыгарга тиеш. Үзенең сөйгәне яшь интеллигент Мелузовны сайласа—юл ябылачак. Вәзгыять аны бай кешене сайларга мәҗбүр итә. Мелузов-Биктимеров белән соңгы аңлашу һәм хушлашу күренешендә залдагы һәр тамашачының күзендә яшь бөртекләре җемелди иде.

Асия Галиеваны театрның фанаты дип атаргамы, әллә каһарманы дипме, белмим, әмма аның бар яшәеше театр булды. Ул бервакытта да рольләр өчен интригаларга кермәде, бу рольне бирегез дип сорап йөрмәде. Әгәр бер рольгә ике кеше куела икән, үзенең дублеры белән дә эшләүне таләп итә иде. Йөздән артык рольне исә дублерсыз гына уйнады. Бу артисткага эшне нык арттыра, кайчак көненә икешәр спектакль уйнарга туры килә, тын алырга да мөмкинлек калмый. Менә шундый кеше буларак ул артистлар арасында бераз сәеррәк тә тоела иде. Әмма Асия боларның берсенә дә игътибар итмәде, эшләвен белде. Шул ук вакытта ул кинодубляжларда да, радиоспектакльләрдә дә, телевидениеда да катнаша. Бу эшләр барысы да спектакльдән буш вакытта, ял исәбенә эшләнә иде, ягъни төннәрен. Тормышы аның җиңелләрдән булмады. Бәлки шуның аркасындадыр, гаилә тормышы да китек булды. Баласы—Динараны ялгыз үстерде. Ана үзе ирешмәгән музыка өлкәсендә иң югары тәрбия бирде һәм югары класслы фортепиано остасы итеп үстерде. Динара Абдуллинаның безнең радио фондында да язмалары саклана. Хәзер ул чит илдә музыка буенча сабаклар бирә, күп илләрдә зур һәм тыгыз концерт эшчәнлеге алып бара. Моннан соң Асия ханым кызының улы—оныгы Ренатны да кечкенәдән тәрбияләп үстерде. Ана да югары белем бирде.

Асия ханым инде бик күп еллар буена педагоглык хезмәте алып бара. Башта ул сәнгать һәм мәдәният университетында студентларга гримм, сүз сәнгате, актерлык осталыгы, сөйләү техникасы буенча дәресләр бирә, бер үк вакытта шул ук дәресләрне консерваториядә, музыка училищесында, хореографик училищеда да алып бара. Аның студентлары арасында Татарстан һәм татар яшьләре генә түгел, чит өлкә һәм республикалардан килгән яшьләр дә була, хәзер күбесе инде сәнгать өлкәсендә күренекле кешеләргә әверелгән. Алар остазларына рәхмәт сүзләре әйтәләр, чит шәһәрдәгеләре хатлар язып, телефоннан шалтыратып тора.

Асиянең кешелек сыйфатларыннан аның табигый интеллектын, кешелеклелек, ярдәмчеллек кебек сыйфатларын әйтеп китәргә кирәк. Моны исбат итү кирәк тә түгел, аның белән эшләгән, аралашкан кешеләр бу хакта үзләре белә. Шәхсән мин үзем Асия Әмир кызына тормышым белән бурычлы. Бу хәл җәйге гастрольләр вакытында булды. Кайсы спектакль белән йөрүебез хәтердә түгел, без маршрут буенча Апас районына барып төштек. Кичке спектакльгә кадәр әле ерак, көн кызуына чыдый алмыйча, без барыбыз да диярлек Зөядә коенып кайтырга булдык, чөнки машина белән килгәндә үк ялтырап, кызыктырып калган иде. Әйберләрне кайсыбыз квартираларга, кайсыбыз "дом крестьян" дигән "отельга" урнаштыргач, машинага төялеп, унлап кеше су коенырга киттек. Без барып туктаган яр

буе комлы, кайберебез кызынырга ятты, кайберәүләр шундук суга кереп китте. Мин дә, чирканыч алып, эчкәрәк керә башладым. Зөя бу урында шактый каты агым белән ага, әмма тирәнлеге зур булмагач, бату куркынычы юк кебек. Уртасында да су күкрәктән генә. Рәхәт! Әмма кинәт минем бер аякны көзән җыерып алды *(сугышта яраланган аякны түгел, икенче уң аякны)*, башта курыкмадым, бер аяк белән этеп ярга чыгарга уйладым. Әмма, мин таза аякны терәп басуга, агым мине әйләндерә дә каплап сала. Тагы шул ук хәл кабатлана. Коенучы иптәшләремә кычкырам: “Егетләр, батам бугай, коткарыгыз!” “Ха-ха-ха” дип көлешәләр—“Монда батам дисәң дә бата алмыйсың, су күкрәктән генә!” Тагы эндәшәм, колакка да элмиләр. Мин бик каты тәшвишкә калдым. Әйләнәм дә капланам, әйләнәм дә капланам. Шунда колагыма тавыш килде: “Госман, кулыңны миңа таба суза төш!” Бу Асия тавышы иде. Кызынып яткан җирендә минем курыккан күзләрне күреп алган да яр буйлап миңа таба килгән. Чөнки мин инде шактый ерагая бара идем. Суга кереп миңа таба кулын сузган. Су аның муенына ук житкән. Мин әйтәм: “Асия, минем янга ук килмә, кабаланма, әкрен генә тарт”, дип кулны суздым, шулай итеп, Асия мине судан суырып чыгарды. Җиргә чыккач, тыраклап барып комга яттым. “Асия, энәле берәр булавкаң юкмы?” дигәч, каяндыр күлмәгеннән табып китерде. Кан чыкканчы аякның балтырына чәнечтем. Юкса, авыртуына чыдар әмәл калмаган иде. Ниһаять, җибәрде. Асияга рәхмәт әйтергә дә онытып ятам. Соңыннан әйткәч, Асия: “Ярый әле аяк җирдән ычкынмады, юкса икебез дә бата идек, мин юньләп йөзә дә белмим бит”, ди. Ни булса булды, Асия мине коткарды. Ул минем коткаручы фәрештәм булып калды, ә мин су керергә, һәрхәлдә, тездән югары суга керергә курка торган булып калдым.

Инде, радио режиссеры буларак, Асиянең безнең радиода башкарган эшләре турында да әйтмичә булмый. Менә әле соңгы көннәрдә генә Татарстан радиосыннан Илдар Юзеевның 50 елларда ук “Таныш моңнар” поэмасы буенча Хәким абый Сәлимҗанов тарафыннан куелган радиоспектакль янгырады. Бүгенге өлкән буын кешеләре ул чакта аны ничектер үзләренең яшьлегендә булган бер якты эпизод буларак кабул иттеләр. Асия радиога Мәскәүдән кайту белән үк катнаша башлады. Башта балалар өчен тапшыруларда кечкенәләр ролен башкарды, аннан мөстәкыйль хикәяләр укый башлады. Шәүкәт Биктимеров армиядән кайткач, “Пионерлар һәм мәктәп балалары өчен радиогазета”ны даими алып баручылар булдылар. Шуны әйтергә кирәк, баштагы чорларда, ягъни магнит тасмасына язуга кадәр, микрофон алдында турыдан-туры эфирга чыгарга туры килә иде. Монда да Асия эшне тиз үзләштерде. Аның укуы вакытында ялгышулары, четерекле вәзгыятьләр булмады. Ул вакытта штаттан тыш эшләгән режиссерлар Шакир Мәҗитов, Хәким Сәлимҗанов, Хәйдәр Гыйматдинов, Халит Кумысников, Ләбиб Айтуганов, Вакил Закиров аны үзләренең постановкаларына бик еш чакыралар иде һәм ул анда төрле пландагы рольләрне башкарды. Соңгырак елларда ул классик хатын-кыз язучылардан Анна Ахматова, Марина Цветаева, Белла Ахмадуллина һәм, әлбәттә, үзебезнең татар шагыйрәләренең шигырьләреннән үзе композиция төзеп, чын радиоспектакльләр итеп эшли башлады. Һәм тагы Александр Пушкин әсәрләре буенча композиция төзеп укыды.

Соңгы вакытта ул Сажидә Сөләйманова әсәрләреннән композиция, Җәүдәт Дәрзамановның Гөлсем Сөләйманова турындагы поэмасына үзенең консерваториядәге студентлары белән музыкаль композиция өстендә эшләвен әйтте.

Асия ханым, сезгә еллар җиле кагылмасын, һаман да шул мөлаем тавышыгыз, сылу гәүдәгез, якты күңелегез белән дөньябызны, сәнгатебезне тутырып яшәгез. Сезнең белем, сезнең тәҗрибә, сезнең зәвык яшьләребезгә бик кирәк.

**Госман ӘХМӘТҖАН**

Kitap küzətü
Китап күзәтү

# БЕРГӘ КӨЛҮ КҮҢЕЛЛЕ

Башкортстанда иҗат итүче билгеле язучы-сатирик Марсель Сәлимовның (Мар. Сәлим) Казанда "Бергәләп көлик! Бергәләп көләйек! Посмеемся вместе!" (Идел-Пресс, 2003) исемле яңа китабы дөнья күрде. Өч бүлектән торган бу җыентык татар, башкорт һәм урыс телләрендә басылган. Аңа йөз илледән артык сатирик һәм юмористик әсәр кергән.

Китапны кулыма алганда күренекле татар шагыйре Шәүкәт Галиевнең: "Көлке көлә килә, елатып китә",—дигән сүзләре исемә төште. Сатира-юмор яратучы буларак "Көлдерә белгәнме икән?" —дип, җыентыкны игътибар белән укып чыктым. Ахырда аның хакында фикер әйтү теләге туды.




Әсәрләрнең күпчелеге миңа бик тә ошады. Аларның кыскалыгы, җыйнаклыгы, үзенчәлекле сюжетка корылуы укучылар күңеленә хуш килерлек. Бу уңайдан тагын да шул ук Шәүкәт Галиевнең: "Кыскалык—талантның сеңлесе булгач, озынлык—халтураның апасыдыр",—дигән сүзләре искә төште. Бик урынлы әйтелгән бит!

Марсель дә озын язарга яратмый, кайбер әдипләребез кебек, кирәксә-кирәкмәсә дә образлар һәм детальләрне катлауландыруны, сүз уйнатуны хуп күрми. Мин аның иҗади җимешләрен күптәннән күзәтеп киләм. Яза башлавының тәүге елларында сатира-юмор өлкәсендә ул бераз кыюсызрак булса да, соңгы елларда иҗат комарын көчәйтте, нәтиҗәдә күпләрнең яраткан язучысына әйләнде. Ел саен диярлек яңадан-яңа китаплары чыгып тора. "Һәнәк" журналында баш мөхәррир булып эшләве дә әнә шул әдәби активлыгын үстерүгә унай йогынты ясыйдыр, күрәсең.

Язучы үз әсәрләрендә тормыш чынбарлыгыннан читкә тайпылмаска, чорны дөрес итеп, үз төсендә (карамы ул, акмы) чагылдырырга тырыша. Юкка гына: "Чорың нинди, җырың шундый",—димәгәннәр. Марсель бүгенге ил, халык язмышы, замандашларының көнкүреше, әйләнә-тирәдәге четерекле вакыйгаларга мөнәсәбәтен үзенчә, сатира-юмор алымнарын бары тик Марсельчә генә кулланып укучыларга житкерә. Характерларны психологик яктан тирәнтен ача, материалларны, детальләрне сайлаганда таләпчән эш итә. Күпчелек әсәрләрендә теге яки бу вакыйганы кешеләрдән ишетеп кенә түгел, ә үзе күреп-белеп язганлыгы сизелеп тора. Ә бит язучы үзе яшәгән чор сулышын тоюдан бигрәк, аңа төгәл бәя бирергә дә тиеш.

Моны яхшы аңлаган Мар. Сәлим, белешмәләрдән табып булмаслык бай материалны тормыштан, конкрет яшәеш рәвешеннән алып, иронияле көлү җебенә тезә дә укучылары алдына китереп сала. Әсәрләре күпләрне "кытыклап", әле көләргә күңелләрендә урын һәм вакыты булмаганнарны да елмаерга, уйланырга мәҗбүр итә. Бу исә язучының иҗат көче, әсәрләренең тормышчанлыгы турында сөйли.

Марсель Сәлимов әдәби әсәрләр язу белән генә чикләнми, зур җәмәгать эшләре дә алып бара. Ул Башкортстан Республикасының Журналистлар берлеге рәисе, Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы, Журналистлар союзларының халыкара конфедерациясе вице-президенты итеп сайланды. Юмористларның халыкара "Алеко" премиясе лауреаты (Болгария), Русия Федерациясенең һәм Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре. Матбугат,

Марсель Сәлимов. Бергәләп көлик.—Казан: «Идель-Пресс» нәшрияты, 2003 ел.

мәдәният өлкәсендәге, халыклар арасында дуслык һәм хезмәттәшлекне ныгытудагы хезмәтләре, озак еллар уңышлы эшләгәне өчен Дуслык ордены белән бүләкләнде.

Әйе, язучыда гражданлык хисләре югары биеклектә. Вакыт табып, сатира, юмор өлкәсендә көчен дә, сәләтен дә кызганмыйча, чын күңеленнән бирелеп эшли. Билгеле, тырышлык үзенең җимешләрен бирми калмый. Язучы-сатирик елдан-ел иҗат офыкларын киңәйтә килә. Аның геройлары да—бүгенге тормыш үзәгендә кайнаучылар.

Мар. Сәлим җәмгыятебездәге тискәре күренешләргә тыныч карый алмый, йөрәгендәге әрнешне, борчылуын замандашлары күңеленә дә күчерә. Без бүген гаҗәеп үзгәрешле, катлаулы чорда яшибез. Илебезне үзгәртеп коруның кайбер нәтиҗәләре чынбарлыкта безнениләргә генә китермәде. Аңлаешсыз буталчык баткаклыклар кешеләрне нинди генә пычракка буямады?! Ил арбасы череп, ватылып таралу чигенәчә барып җитте. Марсель, сатира-юмор остасы буларак, шул күренешләргә үз бәһасен бирә. Язган әсәрләрендә заман сулышы, көзгедәге кебек, аерым-ачык чагыла.

Сатира-юмор аша көлү—ул ирексезләп, әйткәнемчә, "кытыклап" көлдерү генә түгел. Ул аңлы, шул ук вакытта бик тә урынлы, файдалы көлү булырга тиеш. Мин андый көлүне заман басуындагы чүпләрне утауга тиңләр идем. Укучыларынны кимендә елмайту өчен тормышыбыздагы кимчелекләрдән акыл хисләреңне кушып көлә белү зарурый. Әнә шундый максатлы көлү чордашларың күңеленә үтеп керә дә инде. Җитешсезлекләрдән аңлы рәвештә, заманча көлү, аларның асылын ачып, сәбәпләрен күрсәтеп, тамырына сатира-юмор балтасын чабу—үтә мөһим һәм җаваплы эш.

Марсель бүгенге тормышны үзенчәлекле сатира күзлеге аша үтәдән-үтә күрә. Шуңа аның китабындагы җан хисләре белән тукылган әсәрләре укучыны битараф калдырмый. Ул үткән, бүгенге, иртәгәсе көннәр турында борчылып, аек акыл белән уйланырга дучар итә. Хәзерге яшәешкә сизгерлек һәм шул ук вакытта сафлык, сабырлык белән карарга өйрәтә. Аның сатирик геройлары кыланышлары белән нинди дә булса бер нәтиҗә ясарлык итеп күңел түренә килеп керә дә, хәтердә уелып кала. Язучы беренче карашка кечкенә булып тоелган вакыйганы тотып ала да, шуңа таянып, зур фикерләр әйтергә омтыла. Уйлана, фикер йөртә белгән кешеләргә аның әсәрләре бик күп нәрсә турында сөйли. Марсельнең язганнарын кат-кат укып торасы юк. Бер тапкыр уку белән аның кызыклы фикерләре зиһенгә сеңә.

Әдип сүзләрнең кадерен белә, шуңа алар белән сак эш итә. Җөмләләрнең тиешле иҗади кагыйдәләргә буйсынуы үтә мөһим икәнлеген яхшы аңлый. Әдәби осталыкның бер тармагы—күп фикер сыйдырышлы тыгыз җөмләләр төзү һәм аларны тиешле урында гына файдалану. Мар. Сәлим әсәрләрендәге юмор төргәгенә төрелгән җөмләләрне укыгач, аларның дәвамы итеп күңеленнән үзенчә уйламыйча калмыйсың. Укучы әнә шул уйлануы белән әсәрнең көчен тагын да арттыра. Бу инде язучының иҗади осталыгын раслый, аның әйтәсе фикерләре тормышчан һәм заманыбызга кирәкле икәнен күрсәтә.

Менә мисалга "Алтын ыштан" исемле шаян монологыннан өзекләр: "Ирем була язды..", "Фатирыбыз зур сейфны хәтерләтә...", "Иремнең иң зур байлыгы—мин...", "Төнлә: "куркам!:"—дигән идем, ирем тән сакчысына уртабызга ятарга кушты...", "Безнең президентның комы коелырга тора..."

Бер үк күренешне, вакыйганы төрлечә тасвирлап була. Әмма аны тәэсирле итү язучының күңел күзе белән күрә белүеннән, образлы фикерләү осталыгыннан, тел үткенлегеннән тора. Сатирик каләменең сихри көче янә шунда: читтән карауга игътибарга лаек булмаслык нәрсәләрне, кечкенә детальләрне элеп алып, аларны урынлы уйнату һәм шул рәвешле мавыктыргыч сюжет бауларын үрү, гыйбрәтле хәл-күренешләрдән, замандашларыннның җитешсезлегеннән, хәтта үз-үзеннән көлә белү. Җыентыкның төзелеше, анда тупланган әсәрләрнең композиция камиллеге дә әнә шул хакта сөйли.

Дөрес, бүгенге буталчык заманга кырт кисеп кенә бәя бирү җиңелдән түгел. Капма-каршылыклы тормыш җепләренең очлары чуалып югалган чак. Җепләре чуалган ошбу йомгакны сүтеп кара! Ә Марсель аны сүтәргә тырыша. Кино, телевидение, пычрак сәхнә әсәрләре, эротик (дөресрәге, порнографик) гәзит-журналлар яшүсмерне

нәрсәгә генә өйрәтми! Илдә фахишәлек чәчәк ата. Кызлар урамда тәмәке тарта, аракы эчә... Болар бит барсы да киләчәк буын тамырына балта чабу. Мар. Сәлимне, заман сатиригы буларак, әлеге күренешләр тетрәндермәсә, китабындагы күп әсәрләр тумас та иде. Ватаныбыз түрендәге сугыш, үтереш, урлашу, сәясәттәге пычраклык, алдашу һәм башка әшәкелекләр борчылып уйланырга мәҗбүр итә аны.

Тормышыбызның болганчык сулы, кирегә табан ашкынган ташкынына каршы тору өчен, әлбәттә, кыюлык та, тәвәккәллек тә кирәк. Язучының бу сыйфатларга ия булуына шигебез юк.

Җыентыкка кергән әсәрләр моны раслый. Марсельнең сатира коралы белән явызлыкка каршы чыгуы—үзе батырлык.

Шуны да әйтеп үтик: әдип күпчелек әсәрләрен язганда, аңлы рәвештә "Улым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла!" принцибы белән эшли. Кечкенә бер вакыйганы көлкеле сөйләп тә, шуның аша заманның чын йөзен ачарга тырыша. Тормыштагы гыйбрәтле күренешләргә бәя биргәндә нинди дә булса берәр конкрет проблема күтәрә. Фикерләренең ачыклыгы, хисләренең табигыйлеге, тирәнлеге белән укучы игътибарын үзенә җәлеп итә. Заманыбыз ничек кенә яман булмасын, автор, барыбер, акыл кыюлыгына исәп тота. Декларатив кычкырынуларга урын юк аның иҗатында. Марсельнең образлы фикерләү офыгы киң. Җыйнак әдәби формаларга да зур фикерләр сыйдыра ала ул. Ә монысы инде—юмористның таланты!

Язучы тормыш күренешләрен, вакыйгаларны гадәти теркәп баручы гына түгел. Ул аларны гомумиләштерергә, кирәк икән, күпертебрәк, калкурак итеп, тик чама тойгысын югалтмыйча, чынбарлыкка зыян китермичә сурәтләргә тиеш. Марсель бу яктан да саклык белән эш итә. Шуңа күрә аның әсәрләрендәге кайбер "күпертелгән" вакыйгалар сизелми дә, алар юмор канаты белән каплана.

Автор кайберәүләрнең беркатлылыгын, йә булмаса мәкерлелеген, комсызлыгын ачыграк, тулырак чагылдыру ниятеннән күп кенә әсәрләренең төп героена үзе әйләнә, үз исеменнән сөйли. Бу алым китаптагы "Башлы бажа", "Хәерсез хәер", "Кәкре мөгезле тәкә", "Хәл белүчеләр", "Фермер", "Рәхмәт", "Көлеп кенә йәшәйек", "Демократия емештәре", "Суверенлы төш", "Педагогика серзәре", "Тугандартыумасалар", "Мин нисек кейәүгә сыктым", "Заботливый муж", "Бережливость", "Башковитый мальчик", "Путевый бабай" һәм башка әсәрләрендә уңышлы кулланылган.

Җыентыкта сәхнәдән рәхәтләнеп укырлык уймак хикәяләр, монологлар бихисап. Алар жылы юмор белән сугарылганнар, тормышчан, заманча янгырыйлар. "Әссәламегаләйкем, әфәнделәр!", "Күк кешесе", "Әйбәт абый", "Дура, дура, дурасел", "Мисс Чибәркәй", "Татлы чишмә", "Безнесмен", "Алтын ыштан", "Һабантуй", "Агас тел", "Әгәр", "Ярай матриархат түгел", "Как я стал юмористом", "Кошелек или жизнь", "Десять копеек" исемле хикәяләре бер сулыштан укыла.

Үзгәртеп кору елларындагы четерекле вакыйгалардан, ил язмышындагы буталчыклардан, җилкуарлардан, дәүләт милкен үзләштерергә яраклашкан комсыз, елгыр житәкче-түрәләрдән, азгын ир, хатыннардан, гаиләдә була торган каршылыклардан, ачыгавызлардан автор "Тутый карга", "Сексуаль хатын", "Әфсен-төфсен", "Кызык карак", "Үзебезнең агай-эне", "Ак әбейзең кара кайгыһы", "Ата демократ", "Бисә әрләшә", "Мескен мендәр", "Сеанс юморотерапии", "Болтократия", "Гарифулла не при чем", "Свидание" исемле әсәрләрендә көлә.

Китапта авторның бүгенге тормышыбыздан алынган мәсәлләре, мәзәкләре, шаян җырлары, фельетон, төртмәле багышлау, тукмаклы такмаклары да игътибарны үзенә җәлеп итә. Шигъри әсәрләрдән "Капитаннар һәм тычканнар", "Бу кем була?", "Исәр ишәк", "Замана балалары", "Үкенеч", "Белмәс идем", "Өлешле бүлеш", "Кәнфитле гыйшыйк", җырлардан "Тып-тып тама", "Чибәр кызга", "Ярый әле", "Их-ма!", "Көнсел ир", "Үпкәләмә", фельетоннардан "Әзерлек", "Батыр исемле бахыр" һ. б. аеруча уңышлы.

Сатирик язучы фикерен кинаяле юлларга салып, үзенчәлекле чагыштырулар белән әйтә. Мисалга "Капитаннар һәм тычканнар" исемле шигырен алыйк. Автор ана Дәрдмәнднең "Ил корабын җил сөрә!.." дигән билгеле сүзләрен эпиграф итеп куя. Ләкин Мар. Сәлимнең "корабы" илебезнең соңгы еллардагы

хәлен чагылдыра. Урынында тик торган зур корабны вак юнгалар үзләренчә боргалый: берәүләре—уңга, икенчеләре—сулга, кемдер—алга, кемдер артка каера. Бәгъзеләре батырырга план кора.

*Ә кайсыбер "кызу башлар",*
*рульгә менеп атланып:*
*"Алга!"—дип канатланып,*
*артка бара.*

Ил язмышын үз язмышы белән бергә кичергән автор ахырда шундый нәтиҗәгә килә:

*Әмма бүген*
*әйтә алам*
*дөнья ярып:*
*җил уңаена да хәтта*
*булмый барып,*
*ертык җилкән тагып,*
*агып.*

Бу юлларга аңлатма биреп торуның кирәге юк. Сатирикның нәрсә әйтергә теләгәне болай да әйбәт аңлашыла.

"Котлауграммалар, төртмәграммалар" бүлегендә кызыклы дүртьюллыклар урнаштырылган. Менә берничә мисал:

Борис Ельцинга

*Сабан туенда күз буып,*
*Татарны шак катырды*
*Илебезнең иң-иң оста*
*Чүлмәк вату батыры.*

Геннадий Зюгановка

*"Бурлар урыны төрмәдә!"—*
*Дип сөйләп телең талыр.*
*Бурларны утыртып бетсәң,*
*Русиядә кем калыр?*

Шул ук вакытта язучы-юморист тугандаш Башкортстан һәм Татарстанның акыллы житәкчеләренә—булдыклы ир-узаманнарга изге теләген дә житкерә:

*Минтимер Шәймиев белән*
*Мортаза Рәхимовның*
*икесенә бер теләк*

*Президентларның иң шәбе—*
*Минтимер вә Мортаза.*
*Татар, башкорт бәхетенә*
*Булсыннар алар таза!*

Китапка кергән күпсанлы скетч, интермедияләр дә күңелгә ятышлы язылган. Сәхнә осталарының аларны үз репертуарында файдаланачагына иманым камил. Тамашачыларыбыз күптән сусаган иде мондый әсәрләргә.

Шуны да әйтү кирәк: китапта күзгә ташланган житешсезлекләр дә юк түгел. Җыентыкка автор ни өчендер үзенең "Уян, туган!" исемле өндәү шигырен урнаштырган. Ул уңышлы гына әсәр булса да, китапның жанрына туры килми. "Кайтам әле Борайга" дигән җыр тексты да урынсызга килеп эләккән, минемчә. Алар чәнечкеле гөл тутәлен матурламый, ниндидер чит, ят чәчкәне хәтерләтә.

Яхшы гына лирик шигырьләр булсалар да, "Зимний роман", "Летний роман", "Хочется быть вместе", "Пальма", "Огонь жизни" кебекләрнең дә китапка кертелүе артык шикелле. Җыентык баштанаяк сатира-юмор калыбына салынган әсәрләрдән генә торырга тиешле бит!

Ә инде сүземне йомгаклап әйткәндә, көлке остасының бу китабы, һичшиксез, сатира-юмор киштәсе түрендә урын алырга хаклы. Бүген ул—укучыларыбызга әйтеп бетергесез зур бүләк. Язучы-сатирик әйтмешли, бергәләп көлик, агай-эне! Бергә көлү күңелле.

**Рәшит ФАЗЛЫЕВ,**
*Уфа.*



## 108—КӘҮСӘР (БАЙЛЫК) СҮРӘСЕ

*(Кәүсәр сүрәсе 3 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Мәдинәдә иңгән, дип санала. Кәүсәр–төкәнмәс байлык, дигән сүз. Җәннәттәге мәңгелек чишмәнең исеме дә–Кәүсәр.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

1. Хактыр ки, Без сиңа Кәүсәрне (күп байлык) бирдек. (2) Шулай булгач, син Раббың ризалыгына намаз укы. Корбан чал. (3) Сиңа хәсетлек тотучының нәселе корыр. Дөресе шул!

## 109—КЯФИРУН (КЯФЕРЛӘР) СҮРӘСЕ

*(Кяфирун сүрәсе 6 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Кяфирун–кяферләр.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әйт син:

–Әй, кяферләр,–диген. **(2)** Мин сез табынганнарга табынмам. **(3)** Сез дә мин гыйбадәт кылганга табынмассыз. **(4)** Сез табынганнарга мин дә табынмам. **(5)** Сез дә мин гыйбадәт кылганга табынмассыз. **(6)** Сезгә–үз динегез, миңа–үз динем!

## 110—НАСЫР (ЯРДӘМ) СҮРӘСЕ

*(Насыр сүрәсе 3 аятьтән тора. Мәдинәдә иңгән. Насыр–ярдәм.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Аллаһтан ярдәм килеп, җиңүгә ирешсәгез, **(2)** кешеләр төркем-төркем булып, Аллаһның диненә күчәчәк. **(3)** Бәс, Раббыңны мактап, тәсбих әйт. Аннан ярлыкау сора. Шик юк ки, Аллаһ тәүбәләрне күпләп кабул итүче.

## 111—ТӘББӘТ (КУЛЫ КОРЫСЫН) СҮРӘСЕ

*(Тәббәт сүрәсе 5 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Бу сүрәнең башка исемнәре дә бар: Мәсәд, Ләхәб.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әбү Ләхәбнең ике кулы корысын! Үзен дә ләгънәт орсын! **(2)** Аңа кәсеп итеп җыйган малы да, байлыгы да ярдәм итмәде. **(3)** Ул ялкынлы утта яначак; **(4)** хатыны да, утын күтәргән килеш. **(5)** Хатынының муенында хөрмә мунчаласыннан ишелгән бау булыр.

*(Әбү Ләхәб белән аның хатыны Өмми Җамал кешеләрне Пәйгамбәр (галәйһиссәләм)гә каршы кешеләрне өзлексез рәвештә котыртып, динебезгә зыян китергән кяферләрдер. Кешеләр арасына дошманлык уты ягып йөргәненә күрә, сүрәдә Өмми Җамал учак ягар өчен муены-җилкәсе аркылы утын бәйләме күтәреп йөрүчегә тиңләштерелә. М. Али исә «утын күтәрү»не «яман сүз йөртүче» дип аңлата.)*

## 112—ИХЛАС (ИХЛАС) СҮРӘСЕ

*(Ихлас сүрәсе 4 аятьтән тора. Мәккә белән, Мәдинәдә иңгән санала. «Ихлас» сүзен «Бердәмлек» яки «Пакьләнү» дип тә тәрҗемә ителә.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әйт син:

–Аллаһ–берәү генә! **(2)**–Аллаһ–мәңге (яши). **(3)** Ул тудырылмаган да, тудырмаган да. **(4)** Аллаһка тиңдәш юк.

*(Аллаһ–берәү генә, ягъни башка Ходайлар юк һәм була да алмый. Аллаһ–мәңге яши, ягъни Аллаһ һәрвакыт булган һәм һәрвакыт булачак–ул үлемсез. Аллаһны бер зат та тудыра алмый һәм Аллаһ үзе дә өйләнми, ата булмый, чөнки Аның бу эшләргә ихтыяҗы юк. Бөтен нәрсә: Җир, Күк, хайваннар, бөҗәкләр, кош-кортлар Аллаһка мохтаҗ, Аллаһ үзе бернигә дә мохтаҗ түгел.)*

# 113—ФӘЛАК (ТАҢ АТУ) СҮРӘСЕ

*(Фәлак сүрәсе 5 аятьтән тора. Мәдинәдә иңгән. Фәлак–таң ату дигән сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әйт син аларга:

–Таңның Раббысы–Аллаһка сыенамын,–диген. **(2)** Яралтылганнарның мәкереннән, **(3)** дөм караңгы төннәрдәге мәкердән, **(4)** ырым төеннәрен өшкерүче им-томчыларның *(бозучыларның)* мәкереннән, **(5)** көнчел кешенең хөсетлегеннән Аллаһка сыенамын.

# 114—НӘС (КЕШЕЛӘР) СҮРӘСЕ

*(Нәс сүрәсе 6 аятьтән тора. Мәдинәдә иңгән. Нәс–инсаннар, кешеләр, дигән сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.**–Әйт син:

–Кешеләрнең Раббысына сыенамын,–диген. **(2)**–Кешеләрнең Алласына, **(3)** кешеләрнең Хөкемдарына, **(4)** шайтанның мәкерле котыртуыннан, **(5)** кешеләрнең күңеленә вәсвәсә салучы шайтаннан, **(6)** (ул яманлыкка котыртучы) җен токымыннан булса да, кешеләрдән булса да *(Аллаһка сыенамын)*.

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**

**Журналыбызның бу санында Сез Коръән Кәримнең соңгы сүрәсен укыдыгыз. Сүрәнең исеме "Нәс" булса да, ул үзенә күрә саубуллашу сүрәсе дә. Шулай итеп, Коръәннең татар телендәге вариантын (аны язучы Рабит Батулла әзерләде, Наис Гамбәр редакцияләде) бастырып чыгаруны тәмамладык. "Казан утлары"н даими укып баручы милләттәшләребез хәтерли булыр: без бу изге эшне дүрт ел элек башлаган идек. Шул еллар буе Коръән сүрәләрен теге яки бу күләмдә 45 санда урнаштырып, аларны киң катлам укучыларыбызга ирештердек. Бу уңайдан байтак кешеләрдән хуплау-рәхмәт сүзләре ишеттек. Шуңа күрә, без — журнал хезмәткәрләре бу гамәлебездән канәгатьлек һәм җан тынычлыгы хисе кичерәбез.**

**Дин — җәмгыять тормышының аерылгысыз мөһим бер өлеше. Диннәргә карата төрле чорларда төрле карашлар яшәп килде: "дин — иҗтимагый аңның бер күренеше", "дин — кеше акылы ирешмәслек Бөек Көчнең кануннар җыелмасы", "дин — афьюн ул", "дин— кешенең фани дөньядагы юл күрсәткече", "дин — яшәү чыганагы"... Ничек кенә димәсеннәр, диннең беткәне юк. Гасырлар дәвамында күпмедер дәрәҗәдә үзгәрешләр кичерсә дә, дин үсә, дин көчәя...**

**Без — татарлар (керәшен кардәшләребездән тыш) ислам дине тарафдарлары. Ислам — дөньяда таралган өч төп диннең берсе. Социологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, Мөхәммәт Пәйгамбәр дөньяның иң популяр шәхесе булып исәпләнә. Җир йөзендә 1 млрд.тан артык кеше ислам динен тота. Ислам дине татар халкының милли үзаңын билгеләүдә, мәгърифәте, фәне, мәдәнияте үсешендә төп, аерылмас сыйфаты булган һәм яшәү рәвешен билгеләгән. Октябрь инкыйлабыннан соң, мөселманнар яшәгән җирләрдә руханиларны җәберләү, юк итү, мәчетләрне бетерү киң колач ала. XX йөз башында Казан губернасында 1152 мәчет булып, һәр 150 кешегә бер мәхәллә-мәчет туры килсә, 1980 елларда Татарстанда нибары 18 дини җәмгыять (мәхәллә-мәчет) кала. Илдә үзгәрешләр булып, 90 еллар башында дини конфессияләр эшчәнлекләрен җәелдерү өчен яңа мөмкинлекләр туды. Бүгенге көндә Татарстанда 1000 нән артык мәчет эшләп килә.**

**"Казан утлары" журналы дин тәгълиматын үстерү юнәлешендә даими рәвештә эзлекле эшчәнлек алып бара. Бездә дин һәм әхлак мәсьәләләренә багышланган хезмәтләр еш басыла. Әйтик, Коръән Кәримне басып чыгарыр алдыннан без мәшһүр галим, гарәп теле белгече, академик Мирза Мәхмүтовның зур хезмәтен бастырып чыгарган идек (2000 ел, 5-7 саннар). Киләчәктә дә "Казан утлары" журналы дин тәгълиматы, ислам йолалары, әдәп-әхлак һәм дини тәрбия мәсьәләләре буенча галимнәребез, дин белгечләренең хезмәтләре белән таныштырып барачак. Мәсәлән, алдагы саннарда ТР Фәннәр Академиясенең тарих институты директоры Рафаэль Хәкимовның "Кайда безнең кыйбла?" исемле күләмле язмасы дөнья күрәчәк.**

*Хәтер*

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЫ

Төркиядә яшәгән елларымда мин андагы бик күп татарлар белән танышып аралашу мөмкинлеген таптым, күп кенә татар гаиләләрендә кунак булдым. Милләттәшләребез кайда гына яшәсәләр дә, җәмгыятьләр корып, бер-берләре белән аралашырга, телләрен, мәдәниятләрен онытмаска тырышалар. Төрек илендәге милләттәшләребез белән танышуларыбыз да, күбесенчә, шул җәмгыятьләр оештырган чаралар вакытында булды.

Кызганычка каршы, татар җәмгыятьләре белән бәйләнештә тормаган, инде туган телләрен оныткан милләттәшләребез дә бар Төркиядә. Шундыйларның берсе булган Сәма ханым Елмаз белән Анкарада уздырылган бер конференция вакытында таныштык. Белгечлеге буенча төзелеш инженеры булган әлеге яшь ханым татар җырлары язылган кассеталар табып бирүемне үтенде. Кечкенә вакытында әбисеннән ишеткән көйләрне еллар үткән саен тагын да ныграк сагынуын әйтте. Шул рәвешле, Истанбулда яшәүче Сәма ханымга татар кассеталары алып барырга вәгъдә иттем.

Истанбулга баргач, вакыт кысан булу сәбәпле, аларга ярты сәгатькә генә кереп чыга алдым. Ире төрек кешесе икән. Мәхмәт әфәнде белән Сәма ханым мине бик җылы каршы алдылар. Кассеталарны тапшыргач, Сәма ханымның сабый балалар кебек сөенүе әле дә күз алдымда.

Яшь ханым әтиләренең Япониядән күчеп килеп, Истанбулга урнашуларын аңлатты. Әти-әнисе бик яшьли вафат булган икән. Мин аннан үз гаиләсе белән бәйле истәлекләрне язып җибәрүен сорадым. Инде ишектән чыгып киткәч, Сәма ханым мине янадан чакырып алды һәм әби-бабаларыннан калган берничә иске китап тапшырды.

Анкарага кайткач, гарәп хәрефләре белән язылган китаплар белән танышканда, бер китап эченнән Гаяз Исхакыйның хаты килеп чыкты. Әлеге хатның аларга ничек итеп килеп керүен белергә теләп Сәма ханымга шалтыраттым. Ләкин ул хат турында бер нәрсә дә әйтә алмады.

Кызганыч, Сәма ханымнар белән элемтәбезне дәвам итә алмадык. Башка фатирга күченгән әлеге гаиләне күпме генә эзләсәм дә таба алмадым. Соңгы очрашуыбыздан соң берничә ай үткәч үземнең дә адресым үзгәрде.

Хатка килгәндә, аны Гаяз Исхакый 1954 елның 29 мартында төрек генералы Мостафа Рүштү Әрдәлһунга язган булган. Исхакыйның авыруы көчәйгән көннәр ул. Бу хакта бөек язучыбыз үзе дә әйтә. Конвертка Гаяз Исхакый "Рүштү пашага мәктүп" дип язган. Мөгаен, хат кулдан тапшырылырга тиеш булгандыр. Сәманың әби-бабалары төрек генералы белән Г. Исхакыйның уртак танышлары булган булулары да мөмкин. Хат шуннан гыйбарәт:

*Истанбул; 29 март, 1954*

*Бик мөхтәрәм Пашам[1]!*

*Америкадан кайтышлый Истанбулда берничә сәгать кенә торып Анкарага китүегез Сезне күрү шәрәфеннән безне мәхрүм итте. Моның өчен борчылдым.*

*Газагыз[2] мөбарәк булсын. Бу сәяхәт белән мәмләкәт өчен зур файдаларга ирешелде. Хөрмәтле Илбашының һәрберсе аерым әһәмияткә ия булган чыгышларын без монда дулкынланып тыңладык. Белмим, бер үк вакытта бәхетсезлеккә дучар ителгән төрек илләрен хәтерләтү өчен форсатлар табылды микән?*

*Америкадагы яшьләребездән алган язуларда хөрмәтле Илбашыбызның төрек диаспорасын кабул иткәндә үзләре күргән илтифатны горурлык белән аңлаталар. Иншаллаһ, сөенечебез моның белән генә чикләнмәгәндер. Кире әйләнеп кайтканчы, үзара сөйләшкән мәсьәләләрне хөрмәтле җитәкчеләребез белән карап чыгу һәм Америкадагы моның белән кызыксынучы затлар белән очрашу форсатларын таптыгызмы?*

*Кызыксынуымны канәгатьләндерү өчен, яшем һәм авыруым аркасында Әрзинҗанга[3] баруым мөмкин булмаганга күрә, сабырсызлык белән хатыгызны көтеп калам һәм форсаттан файдаланып иң тирән ихтирамнарымны җиткерәм, мөхтәрәм Пашам.*

***Адресым:***
***Эски Чичәкчи сокак, 40***
***Бәйоглу—ИСТАНБУЛ***

---

[1] Паша – Госманлыдан калган бу сүз "югары чинлы хәрби", күбесенчә "генерал" мәгънәсендә кулланыла.

[2] Газа – дин өчен алып барылган изге көрәш. Бу очракта дин, милләт, ватан өчен кылынган изге эш.

[3] Әрзинҗан – Төркиянең көнчыгышындагы шәһәр.

Мостафа Рүштү Әрдәлһун белән Гаяз Исхакый утызынчы елларда Япониядә таныша. Г.Исхакыйны якыннан танып белү мөмкинлеген тапкан Гали ага Акыш үзенең истәлекләрендә болай дип яза: "Кызының өенә килеп урнашкан лидерыбыз мәгънәви көчен югалтмады. Калган 27 көнлек гомереңең 25 көнендә кешеләр белән аралашты. Ул бигрәк тә 1934 елда Токиода танышкан һәм дусты булган хәрби атташе майор Рүштү Әрдәлһун белән күрешергә теләде. Фәкать аның бу теләгенә кызы бик үк уңай карамады. Моңа да карамастан, Гаяз әфәнденең нык торуы нәтиҗәсендә, дустым Хәйрулла Батуның ярдәме белән сөйләшүләренә мөмкинлек тудырылды. Бу идеалист офицер белән язучы Гаяз Исхакый яхшы килешенәләр иде."

Кайчан һәм ничек танышуларын Рүштү Әрдәлһун үзе дә Гаяз Исхакыйның тууына йөз ел тулу мөнәсәбәте белән Анкарада басылган китапта аңлата. Ләкин башта генерал Әрдәлһун турында бераз аңлатып узу урынлы булыр.

Мостафа Рүштү Әрдәлһун 1894 елда Төркиянең Әдирнә шәһәрендә туа. 1914 елда тупчы кече лейтенант дәрәҗәсе белән Хәрби уку йортын тәмамлый. Беренче дөнья сугышына катнаша, тупчы берлекләрендә взвод командиры һәм адъютант булып хезмәт итә. 1921 елның 2 апрелендә Измир Корал тапшыру комиссиясендәге вазыйфасын ташлап, Анталиядә Мостафа Кәмаль җитәкчелегендәге Милли азатлык көрәшчеләре сафына кушыла. 1923 елда Хәрби академиягә укырга керә. Академияне 1926 елда тәмамлап, штаб офицеры чинын ала. 1945 елга кадәр хәрби берлекләрдә хезмәт итә һәм Токио, Рим, Лондондагы төрек атташелекләрендә вазыйфа башкара. 1945 елда генерал-майор, 1947 елда дивизия генералы, 1952 елда корпус генералы (генерал-полковник) һәм 1956 елда армия генералы (Төрек кораллы көчләрендәге иң югары чиннарның берсе) дәрәҗәсен ала. 1956 елда гомум штаб җитәкчесе итеп билгеләнә. Ләкин Әрдәлһун ике еллык срогын тутыра алмый, 1960 елның 27 маенда Төркиядә хәрби түнтәрелеш була. Дәүләт җитәкчеләре белән бергә Рүштү Әрдәлһун да кулга алына һәм шул ук елны отставкага җибәрелә.

Мостафа Рүштү Әрдәлһун 1983 елның 9 ноябрендә вафат була.

М.Р. Әрдәлһун Г. Исхакыйның тууына йөз ел тулу мөнәсәбәте белән бастырылган "Мөхәммәтгаяз Исхакый- тормыш юлы һәм эшчәнлекләре" дип аталучы китапта үзенең истәлекләре белән уртаклаша. Сезгә шул язманы да тәкъдим итәргә телибез.

## Идел-Урал азатлык хәрәкәте лидеры Гаяз Исхакый белән бәйле истәлекләр

1933—1937 елларда Токиода хәрби атташе булып торганда, Беренче дөнья сугышы ахырында барлыкка килгән рус революциясе аркасында Казаннан һәм тирә ягыннан Япониягә күчеп килгән төрекләр *(татарлар—М.Т.)* белән гаилә буларак танышкан идек. Японнар бу мөһаҗирләргә һәр төрле ярдәм күрсәткән һәм уңайлыклар тудырган, исламият ягыннан да, иҗтимагый тормыш ягыннан да ирек биргәннәр иде. Токионың Шибуя бистәсендә бер мәчет, бер мәктәп төзелгән һәм бер төрекчә *(татарча—М.Т.)* журнал нәшер ителә иде. Ул вакытларда Токио һәм Кобе калаларында өч йөзләп гаилә һәм моның яртысы кадәр Мукден, Харбин вә Хайларда яши һәм Япониядәгеләрнең имамы Корбангали исемле мулла иде.

1934 елда Гаяз әфәнде Исхакый Токиога килде. Токиодагы төрекләр *(татарлар—М.Т.)* Казан кешеләре булганга һәм Гаяз әфәнде Исхакыйның аңа кадәр дөнья күргән милли азатлык басмалары белән үзаннарын арттырганга күрә, аның Токиога килүе шатлыклы вакыйга булды һәм бик күп милли чаралар үткәрелүенә мөмкинлек тудырды. Бу вәзгыять исә, ул вакытка кадәр анда милли һәм дини җитәкче булып торган кешеләрдә ризасызлык тууына сәбәп булды. Төрек *(татар—М.Т.)* җәмәгатенең күпчелеге Гаяз әфәнде Исхакый җитәкчелегендә берләшү юнәлешендә иде. Гаяз әфәнде Исхакыйның милли вә әдәби әсәрләре халыкны бергә җыйганга һәм милли үзаннарын ныгытканга күрә, аның лидерлык дәрәҗәсе арткан һәм ул һәр җирдән чакырулар ала иде. Шул сәбәпле, бераз Кореядагы милләттәшләре белән дә танышу өчен Мукденга китте.

Гаяз әфәнде Исхакый киткәннән соң якынча ун көн үткәч Токиодагы төрекләрнең *(татарларның—М.Т.)* танылган вәкилләреннән Әхмәт әфәнде Ваһап илчелегебезгә һәм мина мөрәҗәгать итеп, Гаяз әфәнде Исхакыйның Мукдендә кулга алынуын белдерде һәм азат ителүен сорады. Үткәрелгән тикшерү вакытында Гаяз әфәнде Исхакыйның бер яла ягуның корбаны булуы аңлашылды. Япон Гомум штабы һәм Тышкы эшләр министрлыгы белән элемтәгә керелеп, кыска гына вакыт эчендә күп михнәт күрергә өлгергән Гаяз әфәнде Исхакый төрмәдән коткарылып, хөрриятенә кавыштырылды. Бу исә минем өчен бер әһәмиятле хатирә булып калды.

Идел-Урал идеалы өчен хезмәт иткән Гаяз әфәнде Исхакый белән шул чактан соң вакыт-вакыт Анкара һәм Истанбулда очрашып сөйләшә,үткәннәрне искә төшерә идек. Мине һич онытмый иде. Вазыйфа буенча Америка һәм Англиягә киткәндә, мине андагы дусларына хат җибәреп таныштыра иде.

Мәрхүмгә ярлыкаулар, бакыйларына озын гомер һәм уңышлар телим.

**Мостафа Рүштү Әрдәлһун.**

Сәхифәне журнал өчен **Марс Тукай** һәм **Фәрит Уразаев** әзерләде.

*Котлыйбыз!*

## Яхъя Халитовка 75 яшь



Яхъя Мөхәммәтгали улы Халитов 1929 елның 22 августында Татарстан АССРның Тәтеш районы Үтәмеш авылында крестьян гаиләсендә туган. Башлангыч һәм җидееллык белем алганнан соң, башта Арча педагогия училищесын, аннары 1972 елда В. И. Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Университетның соңгы курсында укыган чагында ук "Совет әдәбияты" (хәзерге "Казан утлары") журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли башлый. 1952-1955 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантурада укый, аны тәмамлагач, журналдагы хезмәтенә яңадан кире кайтып, унтугыз ел буе диярлек (1960-1963 елларда Я. Халитов— Татарстан китап нәшриятында редактор хезмәтендә) шунда эшли, 1963 елдан башлап редакциянең проза бүлегенә җитәкчелек итә. 1976 елның гыйнварыннан бирле Я. Халитов Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә өлкән редактор вазифаларын башкара.

Яхъя Халитов — иҗади сәләтен тулысынча әдәби тәрҗемә эшенә багышлаган каләм осталарының берсе. Аның бу өлкәдәге эшчәнлеге 1952 елдан, рус язучысы Н. Тихоновның хикәяләр җыентыгын тәрҗемә итүдән башлана. Шул вакыттан бирле ул, иҗади активлыгын һәм әдәби осталыгын елдан-ел үстерә, камилләштерә барып, дөнья әдәбияты классиклары, рус совет язучылары, тугандаш халык әдәбиятлары вәкилләренең зур күләмле дистә ярымнан артык роман һәм повестьларын, дүрт-биш дистә хикәясен тәрҗемә итте. Алар арасында М. Шолоховның мәшһүр "Тын Дон" ("Тихий Дон") роман-эпопеясенең беренче һәм өченче китаплары, "Күтәрелгән чирәм" ("Поднятая целина") романы, В. Каверинның "Ике капитан" ("Два капитана"), Ю. Бондаревның "Кайнар кар" ("Горячий снег"), латыш әдибе В. Лацисның "Яңа тормышка" ("К новому берегу"), татар әдибе Мәхмүт Галәүнең үз вакытында рус телендә генә дөнья күрергә өлгергән "Болганчык еллар" ("Муть") романнары, күренекле кыргыз язучысы Ч. Айтматовның "Бәхил бул, Гөлсары!" ("Прощай, Гульсары"), "Анам кыры" ("Материнское поле"), "Дөя күзе" ("Верблюжий глаз") исемле повестьлары, чит ил классикларыннан америкалы Майн Ридның "Башсыз җайдак" ("Всадник без головы"), бельгияле Шарль де Костерның "Уленшпигель турында риваять" ("Легенда об Уленшпигеле"), француз Александр Дюманың "Өч мушкетер" ("Три мушкетера") кебек әсәрләре бар.

Я. Халитов нечкә зәвекъле, әдәби телгә бик сизгер һәм таләпчән редактор буларак, татар язучыларының әсәрләрен югары сыйфатлы итеп чыгаруга үзеннән зур өлеш кертә, бай тәҗрибәсен һәм эрудициясен каләм тибрәтүче чордашлары, бигрәк тә яшь язучылар белән нәтиҗәле уртаклаша.

Матбугат өлкәсендәге хезмәтләре өчен Яхъя Халитов 1980 елда Татарстан АССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, 1990 елда РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре исемнәренә лаек булды.

Я. Халитов — 1966 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы.

Каләмдәшебезне юбилее белән ихлас котлыйбыз, яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез!

## «Казан утлары» архивыннан



*Мәшһүр язучы ханымнар. Сулдан уңга: Сәрвәр Әдһәмова (Кави Нәҗми хатыны), Гөлсем Мөхәммәдова (Галимҗан Ибраһимов хатыны), Ләбибә Ихсанова (Шәрәф Мөдәррис хатыны). 1958 ел.*



*Язучылар Барлас Камал һәм Мөсәгыйт Хәбибуллин. Язучыларның Тукай клубында. 2000 ел.*



*Мәшһүр җырчы Усман Әлмиев Рәссамнар берлегенең күргәзмә залында чыгыш ясый. 1997 ел.*



*Язучылар җыелышында. Таныш йөзләр, якын каләмдәшләр: Мөхәммәт Мәһдиев, Туфан Миңнуллин, Фәннүр Сафин, Марсель Галиев, Ркаил Зәйдулла, Нурислам Хәсәнов... 1990 ел.*



*Күренекле журналист-фотограф Мидхәт Шакирҗанов ("Казан утлары" архивыннан" рубрикасында аның фоторәсемнәре даими урын алып килә). 2003 ел.*



*Шагыйрь Илдус Гыйлаҗев. 1999 ел.*

## *Язучылар берлегенең яңа әгъзалары*

### **Вакыйф Нуриев**



*Вакыйф Вәкил улы Нуриев Арча районы, Сеҗе авылында туган. Шушы авылда урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1975 елда Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә. V курста укыганда "Яшь ленинчы" (хәзер "Сабантуй") газетасы редакциясендә хезмәткәр булып эшли. 1980 елда университетны тәмамлагач, "Яшь ленинчы" газетасы редакциясенә корреспондент булып килә. Аннары җаваплы сәркатип, баш мөхәррир урынбасары була. 1987-1990 елларда В. Нуриев—Татарстан китап нәшриятының сәясәт редакциясе мөдире.*

*1990 елда аны яңа оешып килгән "Шәһри Казан" газетасы редакциясенә эшкә чакыралар. Ул башта бүлек мөхәррире, 1995 елдан 2000 елга кадәр әлеге газетада баш мөхәррир урынбасары була. "Шәһри Казан"ны аякка бастыруга, дөньяга танытуга зур өлеш кертә.*

*Бүгенге көндә Вакыйф Нуриев—"Салават күпере" һәм "Сәхнә" журналларының баш мөхәррир урынбасары.*

*Татар журналистикасында В. Нуриев—яхшы исәптә йөргән каләм ияләренең берсе. Ул 1987 елда СССР журналистларының соңгы VI съездына Татарстаннан делегат итеп сайланды. Аңа Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән исем бирелде.*

*80 нче еллар башында мәктәп укучылары өчен хикәяләр яза башлаган Вакыйф балалар әдәбиятына бүгенгәчә тугры. Ул—"Сабантуй" "Вечерняя Казань" газеталарында, "Салават күпере", "Ялкын", "Мәгариф", "Чаян" журналларында басылган 70ләп хикәя авторы. 1990 елда Татарстан китап нәшриятында аның "Бүре кадәр бүрек" дигән хикәяләр җыентыгы дөнья күрде. 2003 елда урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен чыгарылган "Татар балалар әдәбияты" дигән китапта бу җыентыкка менә мондый бәя бирелә: "Бүре кадәр бүрек" әдәбиятыбыз өчен табыш буларак бәяләнергә хаклы. Әлеге китапка кергән әсәрләрнең ("Әкрәм законы", "Кем ныграк суга?", "Ашыгудан ни файда?", "Бәхетле билет", "Җәйге кар", "Элмәк" һ. б.) геройлары дөньяны үзләренчә аңлаучы, кабул итүче һәм бәяләүче яхшы күңелле, ара-тирә бераз ялкаурак, бераз хәйләкәррәк, малайларча бераз мактанчыграк, азрак шуграк Ирекләр, Әкрәмнәр, Әдһәмнәр, Сәетҗаннар... В. Нуриевның әсәрләре мавыктыргыч башланып, көтелмәгәнчә кызык һәм гыйбрәтле тәмамлана".*

*Күренекле шагыйрь Роберт Миңнуллин "Шагыйрь генә булып калалмадым" дигән китабында болай яза: "Яшь ленинчы" белән "Ялкын"да соңгы вакытта әдәби фельетон жанры җанлану чоры кичерә. Әлеге жанрда нигездә өч автор—В. Нуриев, Л. Леронов һәм Р. Зәйдуллин эшли. Өчесендә өч төрле алым. Һәркайсының үз темасы, үз сүзе. Аеруча В. Нуриевның фельетоннары үзләренең үткенлекләре, тапкыр концовкалары, мавыктыргыч сюжетлары белән үзләренә җәлеп итеп торалар".*

*Татарстан Язучылар берлегенең 31 майда узган идарә утырышында Вакыйф Вәкил улы Нуриев берлеккә әгъза итеп кабул ителде.*



# Ictimağí-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## БӨТЕНДӨНЬЯ МИРАС ШӘҺӘРЛӘРЕ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Июнь аенда Казанда Евразия Бөтендөнья мирас шәһәрләренең 1 конференциясе булды. Анда Латин Америкасы, Европа һәм Азиянең 30 иленнән 500дән артык вәкил катнашты. Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев әлеге җыенның шәрәфле кунагы булды. Ул форумда катнашучыларны, кунакларны республика халкы һәм үз исеменнән тәбрикләде.

Кунакларны Бөтендөнья мирас шәһәрләре оешмасы вице-президенты, Казан хакимияте башлыгы Камил Исхаков сәламләде.

Бөтендөнья мирас шәһәрләре оешмасы Генераль секретаре Дени Рикар үз чыгышында мәдәни мирас эшенә яшь буынны җәлеп итү зарурлыгына игътибарын юнәлтте. РФнең ЮНЕСКО эшләре комиссиясе җаваплы секретаре Григорий Орджоникидзе кунакларны Россия Тышкы эшләр министрлыгы һәм РФ ЮНЕСКО эшләре комиссиясе исеменнән котлады.

Форум кунаклары пленар утырышта, төрле очрашуларда, милли бәйрәмебез—Сабантуенда катнашты.

## САБАНТУЙНЫ—ЮНЕСКО ИСЕМЛЕГЕНӘ

Татарларның милли бәйрәме Сабантуй ЮНЕСКОның материаль булмаган мирасы исемлегенә кертелергә мөмкин, дип хәбәр итте Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев "Интерфакс" агентлыгына.

"Татарларның әлеге үзенчәлекле бәйрәме бик борынгыдан килә һәм ул язгы кыр эшләренең тәмамлану билгесе санала. Безнең әби-бабаларыбыз Сабантуйны сабан бәйрәме буларак билгеләп үткәннәр",— диде М. Шәймиев.

Сабантуйның татарлар күпләп яшәүче Россия өлкәләрендә, шул исәптән Мәскәү һәм Санкт-Петербург кебек шәһәрләрдә дә елдан-ел киңрәк бәйрәм ителүен ассызыклады республика җитәкчесе. "Быел Сабантуй илнең кырыклап төбәгендә—Төмән, Әстерхан, Чиләбе, Ульяновск өлкәләрендә, шулай ук Россиянең башка төбәкләрендә шаулап-гөрләп узды",—дип хәбәр итте Татарстан Президенты. Моннан кала АКШ, Финляндия, Төркия, Германия, Канада, Австралия, шулай ук Балтыйк буе һәм БДБ илләрендә дә берничә ел рәттән Сабантуй уздырылуын искәртеп узды. "Шулай итеп, татарларның борынгыдан килгән традицияләрен, гореф-гадәтләрен саклап, Сабантуй үсешен дәвам итә. Әлеге бәйрәм—халкыбызның тарихи ядкаре ул",— диде М. Шәймиев.

"Бер ел элек без ЮНЕСКО генераль директоры Коитиро Мацуурой белән Татарстан һәм ЮНЕСКО арасындагы мәгариф, фән һәм мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлек турындагы коммюникега кул куйдык. Анда Татарстанның Сабантуй бәйрәмен ЮНЕСКОның кешелекнең материаль булмаган мирасына керүче шедеврлары исемлегенә кертү тәкъдиме чагылды. Кирәкле документлар ЮНЕСКО комиссиясенә һәм секретариатына җибәрелде",— диде республика җитәкчесе. Ул Казан Кремленең ЮНЕСКОның мәдәни объектлары исемлегенә кертелүен дә искәртте. Сабантуйның кешелекнең материаль булмаган мирасы исемлегенә кертелүе әлеге милли бәйрәмнең бөтен дөньяда танылуын күрсәтәчәк.

## МИЛЛИ БӘЙРӘМ ЭМБЛЕМАСЫ

ТР Президенты каршындагы Геральдика советы Сабантуй бәйрәменең рәсми билгесен раслады.

Сабантуйның иң яхшы символы конкурсына 10нан артык хезмәт алынды. Геральдика советы һәм ТР Мәдәният министрлыгы белгечләре тәкъдим ителгән вариантларны анализлап, фикер алышкач, Нияз Хаҗиәхмәтов җинүче дип табылды. Аның эше татар милләтенең кызыл башлы сөлгесе—тәңречелекнең кояшка табыну билгесеннән (символда мондый сөлгенең булуы мәҗбүри шартларның берсе иде) гыйбарәт. Билгедә тоташтыручы элемент булып лалә чәчәген хәтерләтүче зәңгәрсу күк йөзе—янарыш символы тора.

Яңа эмблема үрнәге республика шәһәрләренә һәм районнарына, шулай ук Россиянең татарлар яши торган 54 төбәгенә җибәрелде.

## ЯШЬЛӘР ҖЫЕНЫ ЯШЬНӘП ҮТТЕ

24-28 июньдә Казанда Татар яшьләре форумы үтте. Аның эшендә 550 делегат катнашты. Аларның 150се чит илләрдән, 250се—Россия төбәкләреннән һәм тагын 150се Татарстаннан иде. Килгән көнне яшьләр иҗат әһелләре белән очрашты.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров кунакларны тарихи ватаннарына исән-имин аяк басулары белән котлады. Форумны үткәрүнең максаты—яшьләрне берләштерү, аларны милли идеологиябезне гамәлләштерүдә катнаштыру, диде ул. Аннары язучылардан Туфан Миңнуллин Рабит Батулла, Резеда Вәлиева, Гәрәй Рәхим чыгыш ясады.

Икенче көнне яшьләр, берничә төркемгә бүленеп, төрле темаларга эшлекле сөйләшүләр башлап җибәрде. Милли мәгариф һәм фән; мәдәният һәм рухи мирас; эшмәкәрлек; яшьләр һәм дин; татар дөньясында информацион технологияләрнең роле турында фикер алыштылар, Йошкар-Ола федераль Сабантуенда булдылар.

Татар яшьләре форумында Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары З. Вәлиева, яшьләр эшләре һәм спорт министры М. Бариев, башка рәсми кешеләр катнашты.

## БЕЗНЕКЕЛӘР—ЯХШЫЛАР РӘТЕНДӘ

Краснодар краенда узган массакүләм мәгълүмат чараларының "Бөтен Россия-2004" IX Бөтендөнья фестивалендә Татарстанның алты басмасы биш номинациядә билгеләп үтелде.

Июнь аенда үткән әлеге фестиваль илебезнең 89 төбәгеннән меңгә якын журналистны, шулай ук чит ил кунакларын, РФ хөкүмәте әгъзаларын, Дәүләт Думасы депутатларын, төбәк җитәкчеләрен, танылган сәнгать әһелләрен үзенә җыйды. Татарстан делегациясе республиканың Журналистлар берлеге рәисе, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, "Татмедиа" массакүләм коммуникацияләр агентлыгы генераль директоры урынбасары Фәрит Шаһиәхмәтов, республиканың массакүләм мәгълүмат чаралары—"Татарстан" ТРК вәкилләре, "Татарстан", "Казан утлары", "Ялкын" журналлары, "Республика Татарстан", "Ватаным Татарстан", "Мәдәни җомга", "Казанские ведомости" һәм республиканың район газеталары вәкилләреннән тора иде.

Газета, журнал, телеканал редакцияләре арасындагы иҗади конкурс нәтиҗәләре буенча Татарстан массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре алты мәртәбә сәхнәгә күтәрелде. Мәсәлән, "Шәһәр газеталары" номинациясендә икенче урын "Челнинские известия" (Чаллы) газетасына бирелде. Икътисад реформаларын яхшы яктырткан өчен "Казанские ведомости" газетасы да икенче урынны яулады. Ә "Район газеталары" номинациясендә өченче урын "Зеленодольская правда" газетасына бирелде. "Хатын-кызлар, йорт һәм гаилә басмасы" номинациясендә "Сөембикә" журналына икенче премия бирелде. "Вечерняя Казань" газетасы һәм "Нижнекамское время" газеталары да дипломнар белән билгеләп үтелде. "Бөтен Россия-2004" Бөтенроссия фестивале күргәзмәсендә массакүләм мәгълүмат чараларын югары дәрәҗәдә тәкъдир иткән өчен "Татмедиа" массакүләм коммуникацияләр агентлыгына лауреат дипломы тапшырылды.

Фестиваль эшендә язучыларыбыз—«Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, «Мәдәни җомга», «Саба таңнары» газетасының баш мөхәррирләре Зиннур Мансуров һәм Тәлгат Нәҗмиев катнашты.

## ХАЛЫКАРА ИСЛАМ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Мәскәүдә Союзлар йортының Октябрь залында «Мөселманнар тынычлык һәм килешү өчен» дигән темага халыкара конференция үтте.

Ул Мәскәү Җәмигъ мәчетенең 100 еллыгына багышланды һәм Россия мөфтиләр Шурасы һәм "Ислам чакыруы" Бөтендөнья ассоциациясе тарафыннан Россия Президенты администрациясе, Дәүләт Думасы һәм Мәскәү мэриясе ярдәме белән оештырылды.

Форум эшендә Президент хакимияте хезмәткәрләре, федераль округлар, Россия хакимияте һәм Дәүләт Думасы, төрле министрлык вәкилләре, Россия һәм БДБ илләрендә мөселман дини идарәләре җитәкчеләре, яһүд һәм христиан дине әһелләре, ислам белгечләре, шулай ук илчеләр, җәмәгать эшлеклеләре һәм гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашты.

Сүз башлыча ислам диненең тынычлык саклау потенциалын тормышка ашыру һәм мөселманнарга бүгенге көндә Россия җәмгыятендә лаеклы урын биләргә мөмкинлек тудыручы механизмнар эзләү турында барды.

## ЯЗУЧЫЛАРЫБЫЗ ИЛ ГИЗӘ

Июнь аенда Татарстанның бер төркем язучылары (Фоат Галимуллин, Роберт Миңнуллин, Нурмөхәммәт Хисамов) Татарстан делегациясе составында Башкортстанга барып, башкорт халкының милли каһарманы, шагыйрь Салават Юлаевның тууына 250 ел тулуга багышланган тантаналарда һәм Сабан туе бәйрәмендә катнашып кайттылар.

Казакъстанда Россия көннәре үткәрелү уңаеннан, Жаекта (Уральскида) халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайга багышланган зур тантана уздырылды. Анда Татарстан вәкилләре, шул исәптән Татарстан Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы, галим Хатыйп Миңнегулов та катнашты.

Язучыларыбыздан Мәдинә Маликова—Владимирда, Рәшит Ибраһимов—Ульяновскида, Рәшит Ягъфәров—Пермь өлкәсендә, Хатыйп Миңнегулов—Йошкар-Олада, Рәдиф Сәгъди—Ивановода, Әхәт Сафиуллин—Чиләбедә, Шаһинур Мостафин Удмуртиядә үткән Сабан туйларында булдылар һәм милләттәшләребез алдында чыгыш ясадылар.

## ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ СТАТУСЫ ӨЧЕН

Башкортстан татар милли хәрәкәте оешмалары Башкортстан Президенты

Мортаза Рәхимовка яна мөрәҗәгать белән чыкты.

Анда алар янә дә бер тапкыр Башкортстан татар теленә дәүләт теле статусы бирү мәсьәләсен хәл итүне сорый. Әлеге хатта татар милли оешмалары җитәкчеләре һәм актив вәкилләре быелның 6 январенда ук Мортаза Рәхимовка бу мәсьәлә буенча бергәләп мөрәҗәгать итүләрен искә төшерә. Аннан соң ул хакта хөкүмәт ягыннан да, республиканың тиешле министрлыклары тарафыннан да бернинди җавап һәм реакция булмавы искәртелә.

Мөрәҗәгатьтә татар милли оешмаларының татар теле статусын күтәрү буенча күп санлы хатларын һәм белдерүләрен игътибарсыз калдыру, татар халкын санламау билгесе дип әйтелә. Әлеге мөһим мәсьәләне хәл итүгә башкорт галимнәренең дә киртәләр коруы хакында белдерелә.

Мортаза Рәхимовка бу мөрәҗәгатьтә татар милли оешмалары киләчәктә дә үзләренең таләпләренә колак салучы булмаса, татар теленә дәүләт теле статусы бирү мәсьәләсен башка юллар белән хәл итә башлау хакында кисәтә. Шундый чараларның берсе булып референдум оештыру тора.

Шулай да, татар милли оешмалары әлеге мөһим мәсьәләне татар белән башкортның гасырларга сузылган туганнарча дуслыгын бозмый гына хәл итүгә өмете булуын да ассызыклый.

Президентка чираттагы хатка барлык татар оешмалары исеменнән Башкортстан татар милли оешмалары берлеге президиумы рәисе, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты әгъзасы Рамил Бигнов белән Башкортстан татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Эдуард Хәмитов кул куйган.

## ХАННАР КАБЕРЛЕГЕ ТАБЫЛДЫ

Сөембикә манарасы алдында биш хан кабере булганлыгы ачыкланды. Аның икесен моннан 30 ел элек үк казып алганнар иде. Мөхәммәт Әмин белән Мәхмүт ханнарның сөякләре тарих институтында саклана. Калган өчесенең дә каберен ачып, ханнарны тантаналы рәвештә төрбәдә (мавзолейда) күмәргә ниятли галимнәр. Әмма әлегә андый бина юк.

1977 елда ук Альфред Халиков җитәкчелегендәге төркем Кремль биләмәсендә казу эшләре алып барган булган. Эзләнү вакытында алар ике хан каберен тапканнар. Каберләр ярым түгәрәк капкач, тире белән капланган һәм чәчәк сыман көмеш кадаклар белән ныгытылган була.

30 елдан соң казу эшләре кабат кузгатылды. Моның белән хәзер Фаяз Хуҗин төркеме шөгыльләнә. Бүген Сөембикә манарасы алдында ханнар басып йөргән иданнәрне күрергә мөмкин. Заманында алар нык итеп, берничә кат таш плитәдән түшәлгән булса да, гасырлар буена торып җиргә иңеп, бата төшкәннәр. Табылган каберлекләр арасында кечерәкләре дә бар. Бу йә хатын-кызларныкы, йә үсмерләрнеке булырга тиеш, дип фаразлый археологлар.

## ЧЫН ТАРИХКА ЯКЫНАЮ

Татар ПЕН-үзәге "Мәгариф" нәшриятында инглиз телендә тарих фәннәре докторы, профессор Равил Фәхретдиновның "История татар" ("Татарлар тарихы") дигән китабын бастырып чыгарды. Татарстан Милли китапханәсендә шул китапны киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү кичәсе булып узды.

Бу китапның әһәмияте аның инглиз телендә чыгуында гына түгел, ә бәлки татар халкы тарихының киң итеп күрсәтелүендә: ул 1552 елның көзенә, ягъни халкыбыз үз дәүләтчелеген югалтканчыга кадәрге тарихыбызны эченә ала.

Кичәдә автор буларак чыгыш ясаган Р. Фәхретдинов бу чарага килгәннәрне китапның язылу тарихы белән таныштырды, совет чорында тарихыбызның бөтенләй ялгыш күрсәтелеп килүен әйтте.

Чыгыш ясаган галимнәр Мәхмүт Әхмәтҗанов, Равил Әмирхан һәм башкалар Равил Фәхретдиновның чын тарихыбызны халкыбызга кайтару буенча һәм бик тырышып эшләвен, бу китапның искиткеч әһәмияткә ия булуын билгеләп үттеләр.

## КИТАПНЫ ОЛЫЛАУ

"Идел-Пресс" басмаханәсе генераль директоры Ислам Әхмәтҗанов Буа районы Норлат авылында "Китапка мәдхия" дигән әдәби музыкаль кичә оештырып, авыл китапханәсенә шәхси кулланыштагы 2 мең китап бүләк итте.

Әлеге кичәдә Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, шагыйрь Әхмәт Рәшит, "Татспиртпром" берләшмәсе генераль директоры, Дәүләт Советы депутаты Рәшит Шәйхетдинов, Татар дәүләт филармониясе директоры Кадим Нуруллин, артистлар Алмаз Хәмзин, Искәндәр Биктаһиров, Лилия Муллагалиева катнашты.

## ТУГАННАР КОЧАГЫНДА

Инде байтак еллардан бирле ямьле җәй урталарында безгә Башкортстанда яшәүче милләттәшләребез кунакка килеп төшә. Алар, гадәттә, Агыйдел, Кама, Идел суларын кичеп теплоход белән киләләр. Быел да шулай булды. "Болгарга сәяхәт" дип аталган республикаара мәдәни-агарту программасын Башкортстанда яшәүче татар халкының рухи һәм мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү, икътисади, мәдәни һәм мәгариф өлкәсендә Татарстан казанышларын пропагандалау, татар һәм башкорт халыклары арасында дуслык элементләрен тагын да ныгыту максатларында күрше республиканың "Рамазан" төрки милли-агарту җәмгыяте оештырды.

Кунаклар арасында Башкортстан парламенты депутатлары, оешма җитәкчеләре, эшчеләре, иҗат һәм фән, җәмәгать

оешмалары вәкилләре, артистлар, югары уку йортларының татар бүлекләре студентлары бар иде.

Күрше республика делегациясен казанлылар—мәдәният министрлыгы вәкилләре, язучылар, артистлар каршы алды.

Бу— Башкортстан татарларының Казанга 12 нче сәяхәте иде. Башка елларда ул халык язучысы Әмирхан Еники, халык җырчысы Фәридә Кудашева, халык шагыйрьләре Нажар Нәҗми, Илдар Юзеев һәм башка шәхесләргә багышланды. Монысы исә Татарстанның халык артисты Хәйдәр Бигичев истәлегенә үткәрелде. Сәяхәтчеләр зиратта булып, аның каберенә чәчәкләр куйдылар.

## АТАКЛЫ ГАЛИМ ЮБИЛЕЕ

Башкортстанда яшәүче күренекле татар галиме, профессор һәм татар милли хәрәкәтенең актив әгъзасы Радик Гали улы Сибәгатовка 70 яшь тулды. Шушы уңайдан Уфала, атаклы милләттәшебезне хөрмәтләү йөзеннән, юбилей кичәсе узды.

Кичәгә юбилярның Башкортстан дәүләт университетындагы хезмәттәшләре, дуслары һәм татар җәмәгатьчелеге вәкилләре килгән иде.

Башкортстан Президенты Мортаза Рәхимов исеменнән килгән Котлау хатында атаклы галимнең республика мәгарифе үсешенә керткән өлеше югары бәяләнә һәм аның җәмәгать эшләрендә актив катнашуы билгеләп үтелә.

Чыннан да, Радик Гали улы Сибәгатов соңгы 15 елда Башкортстан дәүләт университетының татар кафедрасына җитәкчелек итүе вакытында бик күп игелекле эшләр башкарды. Аның филология фәне өлкәсендә яңа ачыш булган фәнни хезмәтләре Башкортстанда гына түгел, Татарстанда һәм башка төбәкләрдә дә мәгълүм. Ул татар кафедрасында югары әзерлекле галимнәр һәм мөгаллимнәр коллективы туплый алды.

Радик Сибәгатов соңгы ун елда татар милли хәрәкәтендә дә актив катнаша һәм халкыбыз мәнфәгатьләрен яклауга күп көч куя. Башкортстан татар конгрессы Башкарма комитеты рәисенең алыштыргысыз урынбасары да ул.

Соңгы вакытта Радик Сибәгатов Башкортстанда татар теленә дәүләт теле статусы алу өчен көрәшнең алгы сафында.

## ЯҢА БАСМА

"Минарет" исемле яна фәнни-дини мөселман журналының беренче саны басылып чыкты. Аны Россиянең Европа өлеше, Татарстан һәм Түбән Новгород мөселманнары Диния нәзарәтләре гамәлгә куйды.

Журнал, беренче чиратта, мәчет имамнарына, ислам дине һәм җәмәгать эшлеклеләре, исламны өйрәнүчеләргә h. б. исәпләнгән.

Мәскәү Җәмигъ мәчетенең 100 еллык юбилее уңаеннан нәшер ителгән бу беренче санда күренекле мөселман галимнәренең мирасы, ислам әхлагы, фәтвалар һәм тарихи белешмәләр бар. Аерым бер бүлектә ислам темасына уздырылган конференцияләр һәм китаплар турында язылган.

## ТҮБӘН НОВГОРОДТА—ФӘЕЗХАНОВ УКУЛАРЫ

Түбән Новгород өлкәсенең Пилнән районы Сафаҗай авылында беренче тапкыр Фәезханов укулары үткәрелде. Төрек, гарәп телләрен укыткан, "Мәктәп реформасын" төзегән татар галиме, мәгърифәтче Хөсәен Фәезханов шушы авылда туып-үскән.

Фәезханов укулары уңаеннан үткәрелгән фәнни-дини киңәшмәгә Түбән Новгород өлкәсе губернаторы Геннадий Ходырев, мөселманнарның Диния нәзарәтеннән Гомәр хәзрәт Идрисов, Дәүләт Думасы депутатлары, Пилнән районы хакимияте башлыгы, Анатолий Дудкин, Казаннан, Мәскәүдән дә кунаклар килгән иде. Казан дәүләт университеты доценты Раиф Мәрданов Шиһабетдин Мәрҗани нәселен дәвам итүчеләр ярдәме белән табылган, фән өчен зур яңалык алып килгән Хөсәеннең тарихи хезмәтләре язылган дәфтәре белән таныштырды. Казаннан тарих фәннәре кандидаты Айрат Төхфәтуллин Фәезхановның мәгариф буенча эшчәнлеге турында чыгыш ясады.

Сафаҗайда беррәттән әдипнең мирасын, авыл тарихын чагылдырган музей да ачылды. Сафаҗай—зур авыл. Авылда дүрт таш мәчет бар, хәзер бишенчесе төзелеп килә. Очрашу фәнни конференция белән тәмамланды.

* * *

2004 елның 30 июнендә күренекле әдәбият галиме, тәнкыйтьче **Нур Габделхәй улы Гыйззәтуллин** вафат булды.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казан дәүләт университетының төп бинасы.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* галим **Равил Фәхретдинов**.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Шаһинур МОСТАФИН. **Хәтер яктысы:** документаль-публицист язмалар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.—191 б. Тиражы—5000 данә.

"Архивта эзләнүләргә багышланган киеренке һәр көн нинди дә булса тетрәндерерлек хәлләр, сискәндерерлек фактлар белән очраштыра... Күпме каһарманнар, үзләренә "икенче гомер" бүләк иткәнне көтеп, архив киштәләрендә калын томнар аша сүзсез генә безгә карап торалар..." Китапның "Батырларны барлар чак!" дип аталган кереш сүзендәге юллар бу. Китапка танылган язучы-журналист Ш. Мостафинның дәһшәтле сугыш өермәләре аша үткән билгесез каһарманнарга яисә аз билгеле булган батырларга багышланган документаль язмалары туплап бирелгән.


Китап ахырында Р. Сибатның автор турында "Үзе дә—каһарманнар токымыннан!" дигән язма урнаштырылган.




Ирек САБИРОВ. **Манзара:** шигырьләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.—111 б. Тиражы—1000 данә.

Ирек Сабиров—рус һәм татар телләрендә иҗат ителгән берничә китап авторы. Аның лирик-фәлсәфи шигырьләре Туган жир, Туган ил, Туган тел язмышына бәйле. Тумышы белән Татарстаннан булса да, ул бүгенге көндә Уралда—Еманжелинск шәһәрендә яши, шәһәр башлыгының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары булып эшли. Ул—2002 елны Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.

Шагыйрьнең бу китабына соңгы елларда язылган яңа шигырьләре тупланган.



Равил Фәхретдинов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)